# КАЮМ НАСЫЙРИ

## САЙЛАНМА ӘСӘРЛӘР

ДҮРТ ТОМДА

**2**

ТОМ

КАЗАН
ТАТАРСТАН КИТАП НӘШРИЯТЫ
2004

УДК 820/89 470
ББК 84 (2Рос = Тат)–4
Н 26

Төзүчесе, гарәп графикасында сакланган текстларны гамәлдәге язуга күчерүче — ***Мәсгуд Гайнетдин***

**Насыйри Каюм**

Н 26 Сайланма әсәрләр. 4 томда, 2 том.— Казан: Татар. кит. нәшр., 2004.— 400 б.

Каюм Насыйри «Сайланма әсәрләренең» бу томында әдипнең төп хезмәтләреннән саналган «Фәвакиһел җөләса» һәм «Җәваһирел хикәят» дигән әсәрләре тупланды.

ISBN 5–298–01362–7 © Татарстан китап нәшрияты, 2004

## ФӘВАКИҺЕЛ ҖӨЛӘСА*

...Мәгълүм була ки, гыйлем вә мәгърифәт әһелләре каршында гамәли фәлсәфә фәненең файдалы — тәдбирлелек шәхес активлыгы вә ислах әхлак мәсьәләләренә каратыла вә нечкә фикер әһле каршында бик мәкъбулдер. Мисыр авылларыннан Әбшиһ дигән карьягә мәнсүб сигезенче йөзнең (XIV гасыр) ахырындарак килгән голямадан Шәех Мөхәммәд бин Әхмәд әл-Хатыйб хәзрәтләренең «Китап Фихриясе»ннән вә дәхи Харәзм авылларыннан Зәмәхшәр карьясенә мәнсүб биш йөз утызынчылар (1130) әснасендә зоһур итмеш арасында мәшһүр шәрих голяма Мөхәммәд бин Касыйм бин Ягъкуб (Зәмәхшәри) хәзрәтләренең ошбу фәндә «Риязел әбрар» исемле китабыннан сайланган «Раузел әхбар» китапларыннан җыеп, диярымыздагы[1] әһле исламның теленә тартым тәрҗемә вә тәәлиф кыйлдым. Тәрҗемә вә имлясында хатасын күргән хөрмәтле затлардан өмид итәм ки, төзәтергә каләм тәртеп, фәкыйрь мөтәрҗимне тәгайебле вә шелтәле кыйлмагайлар. Ошбу сөйләячәк сүзләрем голүм гарәбия вә фөнүн әдәббә[2] җөмләсеннән бер фәндер. Мәҗлесләрдә вә сохбәтләрдә мөкяләмә[3] арасында, сүзнең җаена күрә, хикәяте тарикынча гайре кешенең сүзен нәкыль кыйлмактан гыйбарәтдер. Бәс, бу гыйлемне әңгәмә гыйлеме, диләр.

Вә дәхи бу фәннән җимешле тәсмия кыйлынганы бардыр ки, ясигъдан соң мөсәхәбәт кыйлганда сөйләнәчәк бер гыйлемдер. Моннан мөкаддәм «Кырык бакча» тәсмия кыйлынмыш рисаләм моның мөкаддимәсе урынында иде. Теләгем — бу фәнне белдермәк иде. Бу фән лисанемездә юклык сәбәпле, әүвәл дәфгадә кариәләр[4] өчен билгесез булмактан тыш, гади сүзләр

---

*К.Насыйриның төп хезмәтләреннән. Урта гасыр әдәббә (әдәп фәне) жанрында язылган. К.Насыйри аны гамәли фәлсәфә дип атый. Татар әдәбиятында булмаган жанрны тудыру теләгеннән чыгып язылган. Оригиналда ничек булганын күрсәтер өчен, өченче, дүртенче бүлеген үзендәге рәвешендә (беркадәр хәзерге телгә тартымлы итеп) китерәбез. Китап шундый 40 бүлектән тора.

[1] Диярымыздагы — үз ягыбыздагы.

[2] Әдәббә — әдәп, гадәткә өйрәтү фәне.

[3] Мөкяләмә — сүз, сөйләшү.

[4] Кариәләр — укучылар.

белән әйткәндә, ят вә гараиб нәрсә күренсә дә, соңыннан мәфһүменә төшенмешләрдер. Бу тәэлифем дәхи «Рауза» тәсмия кыйлынып, садә гыйбарәтчә, кәкре белән бөкре мәнзилендә булды. Чөнки бу фән китабын рауза дип атамак фәһемне үстерә. Вә бу фәндә гарәп телендә вә фарсы телендә күп олуг галимнәр ничә китаплар тасниф кыйлмышлардыр, — әгәр исемнәрен язсак, ике бит кәгаземезне алса кирәк. Ләкин анча файдасы булмас. Вә дәхи: тәрбияи нәфес вә әхлакны пакьләү өчен хайванат теленнән язылмыш бик мәшһүр «Кәлилә вә Димнә» китабы әүвәл һинд теле үзәренә булып, «Мала шаһнамә» китабы аннан тәрҗемәдер вә мәкъбуль китаптыр. Инде бу дәфга рауза хисабы күп артмаса да, ләкин һәрбер раузада ничә-ничә нәфис җимешле агачлар утырттым. Тәгамын белгән кемсәнә ашар, белмәсә, түкереп ташлар. Ләкин голяма вә хәкимнәрдән мирас калган җимешләрдер. Вә Рәсүлемез хәдисләреннән содур иткән җимешләрдер ки, «Мөстәтраф»нең сиксән дүрт тарафыннан вә «Раузел әхбар»ның илле раузасыннан илсәкат кыйлынды.[1]

## *Өченче рауза*

Зан[2]. Гакыл. Фирасәт[3]. Зәка[4]. Хәмак[5]. Тәдбир. Тәҗрибә. Мәшвәрәт[6]. Гали разыйаллаһу ганһу әйтте: «Мөэминнәрнең занынннан сакланыңыз, аның өчен Аллаһы Тәгалә хакны алар телендә кыйлды» — диде. Димешләр, күбрәк халык ни-нәрсәне сөйләсә, шул һәм вакыйг буладыр.

*Зан* — гөман кыйлмак вә уйламак мәгънәсендә, ягъни шулайдыр, болайдыр дип шик белән чын арасында бер халәттер. Чын тарафы галиб булса, гыйлемнең мөрадифе[7] булыр ки, явызны вә күркәмне һәр икесен берләштерә. Мәсәлән, бер кешене: бу әхлак Хәмидә белән сыйфатланмыш кешедер дип уйласаң, моны «хөсне зан» диерләр. Яки: бу кеше фәләндер, дип яман фигылен уйласаң, моны «сүи зан» диерләр. Хәзрәти Галинең сүзе дә «мөэминнәрнең сүи занынннан сакланыңыз!» дигән мәгънәдә булыр.

Бер галимнән сорадылар: «Явыз хәлле кемдер?» — диделәр. Галим әйтте: «Явыз хәлле кеше шулдыр, берәүгә дә ышанмас, үзенең сүи заны булган өчен. Дәхи аңа берәү дә ышанмас, шул яман фигыле булган өчен», — диде.

---

[1] Илсәкат кыйлынды — ябыштырылды.
[2] Зан — шик.
[3] Фирасәт — инициатива.
[4] Зәка — зирәклек.
[5] Хәмак — ахмаклык.
[6] Мәшвәрәт — киңәшлелек.
[7] Мөрадифе — синонимы.

Бер суфидан сорадылар: «Синең ни сәнагатең вә ни һөнәрең бар?» — диделәр. Аллаһы Тәгаләгә хөсне заным бар, халыкка сүи заным бар, дип җавап бирде.

Ибн Зөбәер хәзрәтләре димештер ки: «Берәү күзе белән күрмәгән нәрсәне уе авазы белән күрмәсә, аның тереклегендә хәер юктыр. Берәү сине колагы белән танымаса, күзе белән дә танымас».

*Гакыл.* Тыймак вә мәныйг кыйлмак мәгънәсендә. Мәгълүм була ки, гакыл ике кыйсем үзәренәдер. Бер кыйсме артмак вә кимемәкне кабул итмәс — моны гакыл табигый, диерләр, вә гакыл гарызи дәхи, диерләр. Мондый гакыл табигый барча гакыл ияләре арасында була. Икенче кыйсме гакыл тәҗриби тәсмыя кыйлыныр ки, артмак вә кимемәкне кабилдер. Вә артмаклыгы дәхи кәсибидер. Мисырда бер кеше бар, мескиннәргә тәгам бирәдер, ятимнәрнең куенын тутырадыр, диделәр. Минем углым Йосыфтыр, алайса ул, диде. Һәм дәрвакыйг күрделәр: Йосыф, имеш.

Гали разыйаллаһу ганһу әйтте: «Берәүнең күңелендә яшерен нәрсә булса, теле төбеннән вә йөзеннән беленәдер», — диде. Кешенең күзенә карап, күңелендәге нәрсәгә игътибар кыйл, диерләр. Дуслык вә дошманлыкка шаһид күз коерыгыдыр. Күз — сөйләшер, серне белерсең. Бер хәкимнән сорадылар. «Кешенең гакыллы икәнен ни-нәрсә белән дәлиллисең?», — диделәр. Хәким әйтте: «Берәүнең гакылын тәҗрибә кыйлган вакытымда сөйләшәмен вә әрепләшәмен. Әгәр сүзендә күбрәк сүзе дөрес булса вә хатасы аз булса, гакыллы дип беләмен», — диде. Янә әйттеләр: «Әгәр аның белән сөйләшмәк мөмкин булмаса, ерак булса, кайдан белерсең?» — диделәр. Хәким әйтте: «Аның тарафыннан килгән, аның дусты булучы кешедән яки җибәргән хатыннан вә һәдиясеннән[1] беләмен», — диде. Бәгъзеләр димешләр ки, кешенең гакылына дәлил һәрбер җенес халык белән хуш мөгамәләседер, Аллаһы Тәгаләнең тәүфыйкына мазһар булган кеше һәркемгә хөсне мәдарат кыйла беләр, димешләрдер. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте, кеше халык белән яхшы мөгамәләдән мәхрүм булса, Аллаһы Тәгаләнең тәүфыйкыннан һәм мәхрүмдер. Вә дәхи бәгъзеләр димешләрдер ки, заманасы халкы белән яхшы мөгамәлә кыйла белгән кеше гакыллыдыр, димешләрдер. Мәдарат[2] диерләр шундаен эшне ки, анда ялганчылык вә хилаф шәрыг эш булмас, теле күңеленә муафыйк булып, халык белән күркәм мөгамәлә кыйлып, даиман халыкны изге эшкә дәләләт кыйлмактыр. Вә тел белән, вә күңел белән, вә кул белән, вә гайре әгъзалар белән һичбер адәмгә зарар тидермидер. Әмма ялагайлык шундаен

---

[1] Һәдиясеннән — бүләгеннән.

[2] Мәдарат — ягымлылык.

гамәлдер ки: кешенең үзендә булмаган күркәм сыйфаты белән алдында мәдех кыйлып вә мактап, артында ул кешене кабахәт сыйфат белән яманламактан гыйбарәттер. Бу ялагайлык сыйфаты икейөзлелек сыйфаты булып, ялагайлык иясен түбәнлеккә төшерер бер сыйфаттыр вә гакылга каршыдыр, ягъни ялагайлык иясендә гакыл юклыкка дәлилдер. Гобәйдә бин Гали димештер ки, гакыл адәмнең бәдәнендә, падишаһ мәнзилендә[1]: вә адәмнең күркәм фигыльләре вә күркәм холыклары — рәгыять вә хезмәтчеләр мәнзилендәдер. Әгәр гакылда зәгыйфьлек пәйда булса, күркәм фигыльләргә кимчелек хасыйл булыр. Бу сүзне мәзкүр Гали бин Гобәйдәдән бер гарәп ишетте дә диде: «Бу бер сүздер ки, балы тамар, татлы сүз мәалендәдер.[2] «Бәгъзе хәкимнәр димештер ки: «Гакылның кулы нәфеснең тезгенен тотар, нәфеснең тезгене гакылның кулындадыр — нәфесне яман юлга җибәрмәс. Һәрбер нәрсә күп булган саен, бәһасе арзан булыр, кадерсез булыр. Әмма гакыл арткан саен, бәһасе вә кадере һәм артыр. Вә һәрбер нәрсәнең чик вә азагы бардыр. Әмма гакылның чиге вә чамасы юктыр. Инде гакылның маһиятендә[3] ихтилаф бардыр». Бәгъзеләр әйттеләр: «Гакыл дигәнемез күз нуры кебек бер нур илаһидыр, адәмнең калебенә буйсынулы итеп куелмыштыр, артмак вә кимемәкне, китмәк вә кайтмакны кабул итәр. Сизелерлек булган нәрсәләр, күз белән күренгән шикелле, гакыл белән дәхи яхшы яман вә нәтиҗәсе яшерен булган нәрсәләрне беленер. Зәгыйфь гакыллылык күңел күзенең сукырлыгы кебектер, көзгеседер», — диделәр.

Гамир бин Кайс димештер ки: «Әгәр гакылың сине динеңә, вә дөньяңа, вә ахирәтеңә файдасы булмаган фигыльләрдән вә сүзләрдән туктатса вә мәныг кыйлса, син гакыллысың. Дөньяда гакылдан шәрифәтле нәрсә юк вә күңел байлыгыннан артык байлык юк». Хәкимнәр димешләрдер ки: «Арыслан куәте вә шәҗагате белән һәр җирдә тереклек кыйлган шикелле, гакыллы адәм шулай үзенең гакылы белән һәр җирдә тереклек кыйла белер. Бер кемсәнең гакылы юк булса, байлык вә мәртәбә җәһәтеннән никадәр мал иясе булса да, кадер вә гыйззәт тапмас. Ләкин гакылның артыгragы — диянәт иясенең гакылыдыр. Вә гакыллы кешене олуг мәнсаблар вә дәрәҗәләр гакылга тап булучы тәкәбберлек белән мөтәссыйф итмәс. Нитәкки никадәр куәтле җил булса да, тауны хәрәкәткә китереп, урыныннан кузгатмаган кебек. Гакылның галәмәте — тыйнаклык вә ахмаклыкның галәмәте — тәкәбберлектер».

Мансур хәлифә үзенең углына әйтте: «Әй угыл, миннән ике нәрсә ал вә үгрән ки. Сиңа кирәк нәрсәләрдер: бере — һәрни

---

[1] Мәнзилендә — урынында.
[2] Мәалендәдер — мәгънәсендәдер.
[3] Маһиятендә — үзенчәлегендә.

сөйләсәң, фикерсез сөйләмә; вә бере — һәрни кыйлсаң, уйламый кыйлма», — диде.

Хәзрәти Галинең риваятенә күрә, мөкәрриме әхлак ундыр, әхлак гашрә, диерләр. Гакыл, дин, гыйлем, хилем[1], юмартлык, күркәм фигыль, ихсан, сабыр, шөкер, мөлаемлык. Вә дәхи димешләрдер ки, гакыллы шулдыр, үзенең гакылы белән белемсез халыкны юлга кертә вә мәнсез халыкка ярдәмче булып сүзе тугыры вә фигыле күркәм булган кешедер. Ахмак вә надан үзенең наданлыгын белмичә, газапта вә сүзендә тормыйча, бозыклыкта булып, сүзе мактанчык вә фигыле түбәнлек булган кешедер. Вә дәхи хәкимнәрдән мәнкульдер ки: кешенең өстендәге киеме — яхшы вә нәфис булмак, буе-сыны ыспай, күркәм булмак, вә зур сакаллы булып, мәһабәтле бер сыйфатта булмак тиеш. Әмма сурәтенең күркәмлеге вә «мин беләмен» дип дәгъва кыйлмакы аның гакыл вә фирасәтенә дәлиләттә кифая кыйлмас, ягъни кешенең өстендә төлке тун вә башында камчат бүрек, һәркөн көзгегә нәзарән, хатыннарча төзәтенеп вә авыз тирәсен бик шома кыркытып йөргәнне дә бу кеше гакыллы дип әйтеп булмайдыр. Дөньяда азмы моның кебек мәгънәсез зиннәтләр.

Әсмәгый әйтте: «Басра шәһәрендә күп гомер иткән бер кешене күрдем, өстендә нәфис кием вә әтрафында хезмәтчеләр. Гакылын тәҗрибә өчен, барып: «Ма исма сәйидүна?» — дип, исемен вә күниясен сорадым, һич пәрвайсыз: «Әбү Габдер Рахманәр Рәхим, маликәл яумиддин», — диде. Мин дәхи биззарур көлеп, ахмак, вә җаһил, вә надан икәнен белдем», — димештер.

Хикәят кыйлынмыштыр ки, казый Әяс дигән мәшһүр бер адәм гокаляи галимнең олугларыннан булып, гакыл сәлим вә табгы мөстәкыйм белән ничә хакыйкать хәлне ачкан иде. Ул мәзкүр Әясның гакыл дәрәҗәсен күрсәтә торган вакыйгаларыннандыр: салих[2] вә әманәтдарлык белән мәшһүр бер кемсәнә бар иде. Бервакыт хаҗ сәфәренә китәчәк бер кеше, үзе сәфәрдән кайтканчы сакламак өчен, ошбу әманәтдар адәмгә бер кисә алтын әманәт куеп сәфәргә китте. Вә хаҗны әда кыйлып кайткач, мәзкүр кешедән үзенең әманәт куйган алтыннарын барып сорады. Ул кеше, наданлык кыйлып, инкарь тарикына[3] барды. Бу кешенең дәгъвасын исбат кыйлырдай гуаһлары юклык сәбәпле, бичара хәйран булып казый Әясның хозурына килеп вакыйганы сөйләде. Казый Әяс әйтте: «Бу вакыйганы башка кешегә сөйләдеңме?» — диде. Ул кеше әйтте: «Юк, сездән гайрегә сөйләгәнем юк», — диде. Бәс, казый Әяс әйтте: «Бар, син бүген өеңә кайт. Ләкин бу вакыйганы берәүгә дә сөйләмә, янә иртәгә монда кил», — дип җибәрде.

---

[1] Хилем — йомшаклык.
[2] Салих — яхшы, изге.
[3] Инкарь тарикына — кире кагуга.

Бу киткәч, ул залимны чакыртып, кадер-хөрмәт вә йомшаклык белән, гуяки яшерен сердәше итеп, хәйлә тарикынча: «Әй ага, син — әманәтдар кеше икәнең мәшһүрдер. Сиңа сер итеп әйтәмен ки, миндә үземә карашлы күп мал хасыйл булды, сиңа әманәт куймага ниятем бар. Миңа кирәк вакыткача үзеңдә бер имин урынында әманәт итеп сакла», — диде.

Ул кеше әманәт сакларга урын хәзерли торсын. Әмма казый мәзкүр бичара әманәт иясен янә чакыртып әйтте: «Инде ул кешедән әманәтеңне сора. Янә инкяр кыйлса, казый Әяс алдына хөкемгә бараек дип чакыр», — диде. Бәс, бу әманәт иясе дәрхаль ул инкарь итүченең ханәсенә барып, казый үгрәткән рәвешчә әманәтен сорады. Ул мөнкәр янә үзенең комсызлыгыннан, мәзкүр казый әманәт куямын дип вәгъдә кыйлган акчаны эләктермәк нияте белән, казый бу вакыйганы белмәсен дип, әманәт иясен риза кыйлмак өчен, шундук алтыннарын чыгарып тапшырды вә йомшаклык белән: «Инде бу вакыйганы кешегә сөйләмә, мәзәк кыйлган идем, бу эш арамызда бетсен», — дип үтенеч белдерде. Ул хажи үзенең өмет өзгән малын кайтарып алгач, тугыры казый Әяс хозурына килеп хәбәр бирде, күп дога вә сәна кыйлды. Ул мөнкәрнең хыянәте заһир булганнан соң, казый аны үзенең хозурына китертеп тәгъзир кыйлды[1] вә, Аллаһы Тәгалә синең кебек явызларны дөньядан алгай, дип бәддога кыйлды. Инде бу казыйның гакылын күз алдыңа китер.

Гарәпләр бер мәсәл йөртерләр. Ибн Габбас зирәк фикерле иде. Вә Әяс дәхи гаять фирасәт иясе иде. Гомәр разыйаллаһу ганһу ибн Габбастан сорады: «Йә ибн Габбас, Рамазанда кадер кич кайсы кичәдә?» — диде. Ибн Габбас әйтте: «Аллаһы Тәгалә күкне вә җирне яратты, бер елдагы көннәрне җидешәр итеп атналарга бүлде. Бәс, кадер кич Рамазанның ахыргы җидесендәдер», — диде. Гомәр разыйаллһу ганһу әйтте: «Йә ибн Габбас, син тәхкыйкыл мәгыйсың, ягъни сәригылфәһемсең[2]», — диде.

Әяс бин Мөгавия бервакыт эт улаган тавыш ишетте, әйтте: «Караңыз, бу эт капу янына багланмыштыр». «Кайдан беләсең?» — диделәр. Әйтте: «Әүвәл эт тавышын ишеттем, соңыннан шыңшып улаганын ишеттем, шуннан нәтиҗә чыгардым», — диде. Бу аның фирасәтеннәндер. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Гакыл калебдә бер нурдыр, аның белән хак вә ялган аерылды», — диде.

Әнәс разыйаллаһу ганһудан риваять кыйлынмыштыр ки, пәйгамбәр галәйһиссәламгә әйттеләр: «Йә Рәсүлуллаһ, кайбер кешенең гакылы да күркәм буладыр, гөнаһысы да күп буладыр. Гакылына күрә ул кеше гөнаһ кыйлмаса кирәк иде», — диделәр.

---

[1] Тәгъзир кыйлды — шелтәләде.
[2] Сәригылфәһемсең — тиз аңлап алучысың.

Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Бәли, һич гөнаһсыз кеше юк, гөнаһны адәм үзе кәсеп кыйладыр. Ләкин әгәр дә кешенең гакылы вә тегәллеге дәвамлы булса, гөнаһысы зарар бирмәйдер», — диде. «Бу ничек болай?» — диделәр. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Аның өчен, һәрбер гөнаһ кыйлган саен, ул кеше үзеннән садыр булган[1] гөнаһыны белеп, тәүбә вә үкенүен кичектермәйдер, гөнаһысын тәүбә белән яшереләдер. Гакылының өстенлеге һаман каладыр», — диде.

Хәкимнәр димешләрдер ки, кешегә дәүләт каршы килсә, шәһвәте гакылына хезмәтче буладыр, әмма дәүләте арт биргәндә, гакылы шәһвәтенә хезмәтче буладыр. Гакыллы кеше үзенең сәүгәнен ташлыйдыр. Таки сәүмәгән нәрсәсен чыра итеп котылыр өчен.

Вә дәхи димешләрдер ки: Адәмнең, ягъни Адәм пәйгамбәрнең гакылы җәмигъ әүладының гакылы кадәр иде. Дәхи падишаһларның гакылы бөтен мәмләкәт гакылына бәрабәр димешләрдер.

Гамир бин Кайс әйтте: «Әгәр гакылың сиңа файдасыз булган нәрсәне белсә, син — гакыйльсең», — диде. Мөгыйн бин Заидә әйтте: «Мин кешенең җилкәсен күрсәм, гакылының чамасын беләмен», — диде. «Әгәр йөзен күрсәң, ничек?» — диделәр. Әйтте: «Ул вакытта йөзе — бер китаптыр, укыймын», — диде. Галимнәр әйттеләр: «Гакыйль шулдыр: әүвәлге фикере белән үк эшнең ахырын күрер, эшләрендә куркыныч пәрдәсенең караңгылыгын ертыр, күңелендә булган үткерлеген эшләтеп яшерен булган фикер саклаган малын нәтиҗәле итәр».

Хәкимнәр әйттеләр: «Әгәр берәү белән мосахиб[2] булсаң, аның гакылына кара, диненә карама, чөнки аның дине үзенә генәдер, гакылы сиңа һәм үзенәдер. Ягъни дине белән үзе генә файдаланыр, әмма гакылы белән син һәм файдаланырсың. Эшнең ахырын карый торган күзге тәҗрибә әһленең кулындадыр ки, ул — гакылдыр». Бер фәйләсуф әйтте: «Гакыл табигый гаклы тәҗрибәгә баскычтыр. Гакыл иясе берәм-берәм аларның икесенә дә дикъкать кыйлыр, җаһил кыйлыр, аларны файдаланмагай, үзенә йөкләр. Галимнәр димешләрдер ки, әгәр гакыл сурәтләнсә, ягъни дөньяда гакылның сурәте булса иде, гакылның нуры кояшның нурын каплар иде. Вә әгәр ахмаклык сурәтле нәрсә булса иде, аның караңгылыгыннан караңгы кич яктырак күренер», — иде.

Локман хәким әйтте: «Шәрәф вә олуглыкның гаясе гакылдыр. Кемнең күркәм гакылы булса, җөмлә гаепләре мәстүр вә дуслары разый булыр». Димешләрдер ки, һәрнәрсә гакылга мохтаҗ. Гакыл вә тәҗрибә бер-беренә ярдәмче булмакта җир

---

[1] Садыр булган — йөз биргән.

[2] Мосахиб — утырдаш, иптәш.

белән су кебектер, нитәкки су белән җир бер-береннән башка бернәрсә үстерә алмайдыр.

Бер хәкимнән сорадылар: «Кай вакыттан бирле син гакыллысың?» — диделәр. Хәким әйтте: «Туганнан бирле мин гакыллымын», — диде. «Мөмкинме, нарасидә баланың ниткән гакылы булсын?» — диделәр. Ул хәким әйтте: «Карыным ачса — еглададым. Иртә булса, имчәк сорадым, бирсәләр, сөкүт кыйлдым», — диде. Ягъни: кеше үзенең хаҗәтенең микъдарын белсә, ул — гакыйльдер, димәктер.

Батлаимус[1] хәким димештер ки: «Һәрбер гамәл гакыл рөхсәт бирсә, файдалы, ягъни гакылга тугыры килгән эш хата булмас. Гакыйль шулдыр ки: үзенең янында булган даруга ышанып, агу эчмәс. Ибраһим галәйһиссәламнең китабында мәзкүр иде ки: гакыйль булган адәмгә лаектыр ки, замана әһелен таныган: телен саклаган. Әгәр берәү заманасының әһелен танымаса, ул җаһилдер».

Локман хәким әйтте: «Берәүнең кавеме дошман булса, төне озын булыр, йокысы очар», — димештер.

Гали разыйаллаһу ганһу әйтте: «Хилем[2] — өреткүче пәрдәдер вә гакыл кискен кылычтыр, хилемең белән халыкның пәрдәсен сәтер кыйл[3], һаваланууыңны гакылың кылычы белән кис. Хилем дигән нәрсә адәмдә бер сыйфаттыр ки: юашлык вә йомшаклык, вә миһербанлык тәгъбир кыйлыныр». Җәбраил галәйһиссәлам Адәм галәйһиссәламгә өч нәрсә китерде: гакыл, хәя, дин. Вә әйтте: «Ошбу өч нәрсәнең берен ихтыяр кыйл», — диде. Бәс, Адәм галәйһиссәлам гакылны ихтыяр кыйлды вә әйтте: «Хәя вә дин безнең эшемездер, — гакылдан аермасы юк», — диде. Гакыл иясенә киңәш кыйлсаң, аның гакылы сиңа йогар вә аның гакылыннан сиңа файда тияр. Үз фикерен генә караган кешенең фикере фикер түгелдер, димешләрдер. Хәкимнәр әйттеләр: «Мең кешегә әйт, бер кешегә киңәш ит: бер эшне күп кешегә мәшвәрәт кыйлган кешенең эше җимерелүдән хали булмас». Киңәш белән эшләп хата вакыйг булган эш киңәшсез эшләп дөрес чыккан эштән яхшырактыр, дип хәдистә килмештер, ягъни киңәш ярты мәгыйшәттер.

Пәйгамбәр галәйһиссалаты вәссәлам үзенең сәхабәләре белән һәр эш хосусында мәшвәрәт кыйлышмага ошбу аять белән мәэмүр[4] булмыштыр. Пәйгамбәр саллаллаһу галәйһиссәлам бер нәрсәне кыйлмага теләгән вакытында, Аллаһы Тәгалә аның әмеренә җитәкче булып, сәхабәләрнең фикереннән һәр никадәр мохтаҗ түгел булса да, сәхабәләргә мәшвәрәт белән

---

[1] Батлаимус — Птолемей.
[2] Хилем — йомшаклык.
[3] Пәрдәсен сәтер кыйл — оятын пардалә.
[4] Мәэмүр — берәр эшне үтәүче кеше.

мәэмүр булды. Хикмәт будыр ки: өммәтләре һәр никадәр галимнәр булса да, мәшвәрәт кыйлышыңыз, дип, өммәтләренә тәгълим өчендер, диделәр. «Мөстәтраф» иясе монда бер хәдис китермеш: «Истихарә кыйлган өметсез булмады, киңәш иткән үкенмәде, хаҗәтендә үлчәм үзә булган мохтаҗлык күрмәде».

Бер әгъраби димештер: «Гакылдан артык мал, вә наданлыктан олуг фәкыйрьлек, вә мәшвәрәттән куәтлерәк таяныч юктыр», — димештер. Бәгъзе гакыйль димештер ки, әүвәл истихарә[1], аннан соң истишарә[2] кыйлган кешенең тәхкыйк фикере вә тәдбире өметсез булмас.

Мөлүк Сасанияннан мәлик Әрдәшир бин Бабик димештер ки: «Дүрт нәрсә дүрт нәрсәгә мохтаҗдыр: хәсәб[3] әдәбкә мохтаҗдыр; шатлык иминлеккә мохтаҗдыр; якынлык мәхәббәткә мохтаҗдыр; гакыл тәҗрибәгә мохтаҗдыр». Бәгъзе хәкимнәр димешләрдер ки: «Дусларыңнан бер кеше белән мәшвәрәт итеп, аның фикере белән гамәл кыйлганыңнан соң, нәтиҗә вә уңышы гүзәл чыкмаса, саклан ки, ул дустыңа син әйттең, синең фикерең белән эшләдем, кяшки син әйтмәсәң дип, үпкә вә шелтә кыйлма. Зирә ошбу рәвеш шелтә кыйлмак хәфиф гакылдандыр[4]. Чөнки һәр кеше үзенең фикерен вә тәдбирен, минем тәдбирем яхшыдыр, дип, гөман кыйлмак табигый эштер. Аның бер хатасы белән күңелен калдырган тәкъдирдә үзенә зарар килер вә күңеле калыр. Икенче мәртәбә мәшвәрәт кыйлган вакытында, фикере савап булса да, хата булмак ихтималы белән фикерен синнән яшерер. Фикер дигән нәрсә һәр никадәр яхшы күренсә дә, гакыйбәтен Ходадан гайре берәү дә белмәс. Мәгълүмдер ки: хәкыйкый җитәкче — Аллаһы Тәгаләдер».

Әфләтун хәким димештер ки, әгәр синең бер дошманың үз эшендә синең белән мәшвәрәт кыйлышса, нәсыйхәтне вә аңа мәслихәтне вә хәерхаһлыкны аңа сарыф ит. Ягъни бу минем дошманымдыр, барсын, бәласен күрсен дип алдап, яман юлга сөрмә. Зирә сиңа киңәш кыйлмакы белән, сиңа дошманлыгын куеп, дуслык итмеш булыр. Инсаниятькә лаек булган хәерхаһлык ошбудыр. Вә бәгъзе хәкимнәр дәхи димештер ки, нәсыйхәтне, хәерхаһлыкны белмәгән наданга вә изгелек кадерен белмәгәнгә сарыф кыйлган кеше тозлы җиргә вә ташлык җиргә иген иккән кеше кебектер. Әхнәф әйтте, ач кеше белән карыны туймаенча, вә сусамыш кеше белән сусылык кайтармыйча, вә әсир кеше белән итлак кыйлынмаенча, вә фәкыйрь белән хаҗәтен әда кыйлмаенча мәшвәрәт итмә.

---

[1] Истихарә — төшлек салдыру.
[2] Истишарә — киңәшү.
[3] Хәсәб — дан, дәрәҗә.
[4] Хәфиф гакылдандыр — җиңел акылдандыр.

Беркөн солтан Мөхәммәдхан үзенең нәдимнәреннән[1] булган мөнәҗҗим[2] башы Әхмәд Мәүләвигә боерды: «Ниятемдә булган хосус өчен, гыйлме нөҗүм үзрә, заирчә тәхрир кыйлып карачы», — диде. Әхмәд Мәүләви дәхи дәрхаль сәгатькә карап, солтан Мөхәммәд хозурында куенынннан бер кәгазь чыгарып, бер тәхрир вә дәлаләт нөҗүмиясен[3] тәкърир иткәннән соң, ул мөхәррир кәгазьне янә куенына салганда Солтан Мөхәммәд: «Ул тәхриренне миңа бирче», — диде. Әхмәд Мәүләви һаман ул кәгазьне солтан кулына бирде. Мәгәр ул кәгазьнең бер ягында Әхмәд Мәүләвинең бурычларын язарга тотылган хәраҗаты[4] язылып, кемгә күпме бирәчәге бар, аны язылыр дәфтәре, имеш. Ашыкканлыгыннан карамаенча, буш кәгазь санап, үзенең мәсраф дәфтәренә язмыш, имеш. Бәс, ул дәфтәргә солтан Мөхәммәднең күзе төшеп, ниндәен кәгазь икәнен фәһемләгәч, мәшвәрәт кыйлынмыш: кемсәнәнең зиһенендә дин, ягъни бурыч фикере булса, аннан тугыры фикер өмет ителмәс дип, дәрхаль Әхмәд Мәүләви әфәндегә ашамак, эчмәк, акча вә әнваг малдан ихсан кыйлмага фәрман боерып, Мәүләви әфәндене шат итмештер, рәхмәтуллаһи галәйһи. Вә дәхи хәкимнәр димешләрдер ки: «Балалар укытучысы белән, куй көтүчесе белән, хатыннар белән вә хатыннар тигрәсендә күп маташкан кеше белән, вә синдә ихтыяҗы бар кеше белән, куркак кеше белән, вә йөрәксез кеше белән, вә адәм үтергән кеше белән киңәш итмә», — димешләрдер. Ягъни хәкимнәр бу мәзкүрләрнең зиһеннәре саташмыш кемсәнәләрдер димәгә баралар. Бәгъзе галимнәр димешләрдер ки, бер кемсәнә үзенең мәслихәтенә керешүдән мөкаддәм Аллаһы Тәгаләгә истихарә кыйлып, аннан соң дустына киңәш итсә, ул кеше үзенә лазем булган нәрсәне үтәгән булып, Аллаһы Тәгалә аның мәслихәтен күңелендәгечә хөкем итәр. Вә дәхи хәкимнәр димешләрдер ки, гакыл иясе булган адәмгә лаектыр ки, җиде төрле кеше белән киңәш итмәгәй: надан, дошман, көнче, икейөзле куркак, саран вә җиденчесе — һава вә һәвәскә иярүче кешедер. Аның өчен надан кеше наданлыгы сәбәпле хата вә ярамас киңәш бирер; дошман кеше синең һәлакеңне касд кыйлыр; көнче кеше синнән нигъмәт китүен эстәр; риялы кеше һәркайчан адәмне кайсы юл белән булса да разый кыйлмак ягын күзәтер, кешенең хәтерен саклап киңәш салыр; вә саран кеше үзенең мал җыймага хирыслыгы җәһәтеннән мал җыймактан гайре нәрсә фикеренә килмәс. Нәфес арзусы артыннан йөргүче дәхи даим ләззәт нәфсания вә шәһвәт белән мәшгуль булып, үзенең нәфесенә хи-

---

[1] Нәдимнәреннән — ярдәмчеләреннән.
[2] Мөнәҗҗим — астролог.
[3] Нөҗүмиясен — йолдызлар таблицасын.
[4] Хәраҗаты — чыгымнары.

лафлык кыйлмага кадир була алмаганлыктан, гакыл җанибе ябылган яки киртәләнгән булып, тугыры фикер анда юкка чыккан.

Әһеленнән бер адәм хикәят кыйлмыштыр ки: «Бервакытны бурычым күбәеп, бурыч ияләре бик таләп иткәннән соң бәгъдендә, дөнья башыма-зиндан вә бәла йорты булып, ни эшләргә белмәенчәрәк ышанычлы вә мөрәүвәт[1] иясе бер дустым белән мәшвәрәт кыйлдым. Ул заманда Гыйракта киң күнелле юмарт Мәһләб дигән вали бар иде, аңа барып хәлемне бәян кыйлмага мәшвәрәт итте. Гыйрак бик ерак, анда мин бара алмамын, дип, башка бер дустыма киңәш иттем. Ул дәхи һаман шул мәшвәрәтне биреп, мин һәм мәшвәрәтне кабул итмәк — кире качудан хәерледер дип, тәвәмә атландым. Бәгъзе юлдашлар белән Гыйрак сәфәренә тәвәҗҗеһ кыйлдым. Мәһләб хозурына барып, гадәтчә тәгъзыйм вә дога вә сәнадән соң, гарзымны бәян кыйлып: «Мин фәкыйреңез Мәдинәи Мөнәввәрәдән бурычлы кешемен. Бурычым күплегенә гаҗиз булып, бәгъзе дусларым белән мәшвәрәт кыйлганымнан соң, сахиб мөрәүвәт булгучы җәнабыңызга хаҗәтемне гарыз итмәгә мәслихәт кыйлдылар. Шул сәбәпле җәнабыңызга килдем». Мөрәүвәт сезнеңдер, дип, телем белән хәлемне гарыз кыйлганнан соң, Мәһләб әйтте: «Синең белән минем якынлыгым вә өлфәтем вә синең дәхи безгә хезмәтең юктыр», — диде. Мин дәхи: «Бәли, юктыр, ләкин синнән хаҗәт эстәмәгә сине әһел күрдем. Әгәр хаҗәтемне әда кыйлсаң, син аңа әһелсең. Әгәр дә кәефеңезгә тугыры килмәенчә, хаҗәтемне әда кыйлмасаң, ошбу көндә үпкәм юк, иртәгә булса һәм хуп», — дидем. Мәһләб һаман капучыларына әмер итте: «Барыңыз, хәзинәмдә һәрни тапсаңыз, бу адәмгә бүләк кыйлыңыз», — диде. Хәзинәсенә бәрабәр бардык, хәзинәдә сиксән мең дирһәм бар, имеш, миңа бирделәр. Аннан соң мин дәхи бу кадәр җумартлыкны, бу кадәр малны күргәч, кәмаль шатлыгымнан үлә яздым. Янә аннан мине Мәһләб хозурына китерделәр. Мәһләб әйтте: «Әй адәм, хаҗәтеңне әда кыйлырлык кадәр нәрсә хасыйл булдымы?» — диде. Мин дәхи тәшәккер теле белән: «Әй җумартлык мәгъдәне булгучы әмир, җумартлык дәфыг зарурәт итәчәк кадәр түгел, аннан да артыграк булды», — дидем. Мәһләб әйтте: «Яхшы, алайса тырышуың бушка китмәде, мәшвәрәтеңнең җимешләрен җыйдың», — диде. Аннан соң Мәһләбнең хозурында аяк үзрә хәмед вә сәна укып, шөкер итеп Мәдинәгә кайтып, бурычларымны әда кыйлдым. Вә әһле әүладыма бәхшишләр вә мәшвәрәт кыйлганнарга һәдия белән икрам кыйлдым. Моннан соң барча эшемдә киңәшсез эш кыйлмадым», — дип, хикәят кыйлмыштыр.

Хәсән разыйаллаһу ганһу әйтте: «Адәм өч төрледер: кеше,

---

[1] Мөрәүвәт — егетлек, ирлек.

ярты кеше, кеше түгел. Кеше дигәне шулдыр: үзенең фикере дә тугыры булыр, киңәш һәм итәр. Ярты кеше дигәне шулдыр: үзенең фикере тугыры фикерле булыр да, киңәш итмәс. Дәхи кеше түгел кеше дигәне шулдыр: үзенең һәм тугыры фикере юк, киңәш тә итмәс. Инде кеше түгел кеше белән синең эшең һәм булмасын. Дәхи кеше түгел кешенең кешедә ни эше бар? Кешенең ниндәен гакыллысы да киңәштән азат түгелдер. Нитәкки ниндәен яхшы ат булса да, чыбыркыдан мохтаҗлыксыз түгелдер. Вә ниндәен пакь хатын булса да, ирдән мохтаҗлыксыз түгелдер.

Бәзер Җәмһәр әйтте: «Бер эш хосусында берәүнең берничә төрле фикере булса, бу кеше, мәсәлән, энҗе җуйган кеше хәлендәдер, энҗесене җуйган кеше энҗе төшкән җирдәге туфракны бер микъдар җирдән себереп җыядыр, шул туфракны актарып, энҗесен табып аладыр вә кәзалик[1] ул кеше, берничә раэ булса, бер-беренә сугып, халис раэн чыгарадыр. Тәкъдир чишелсә, тәдбирләр җуяладыр, тәкъдир синең тәдбиреңә ияреп йөрмидер, бәлки тәдбирләр һәммәсе тәкъдиргә табигъдыр».

Локман хәким әйтте: «Әй угыл, һәр эшеңдә тәҗрибә әһленә киңәш ит, ул сиңа кыйммәт төшкән фикереңнән мәшвәрәт бирер. Әмма сиңа ул тәдбир бушка килер», — диде.

Искәндәр әйтте: «Хур, хәкыйрь[2] кемсәнәдән ишеткән киңәш вә тәдбирләрне хур, хәкыйрьгә салма, аның өчен диңгездән чумып энҗе алган кешенең хур, хәкыйрьлегенә карап энҗенең бәһасе ким булмайдыр», — диде. Берәү тәдбирне тәрк кыйлса[3], һичбер нәрсә дә уйламаса, рәхәт тереклек кыйлыр. Күп фикерләгән кешенең кыюлыгы булмас.

Аллаһы Тәгалә гакылның газиз вә шәриф нәрсә икәнен үзенең Кәләмендә ничә җирдә зикер кыйлды. Гакылдан шәриф вә газиз нәрсә юк. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Аллаһы Тәгалә иң әүвәл гакылны яратты вә әйтте, әй гакыл, миңа каршы бул, диде. Каршы булды. Артыңны әйлән, диде. Артын әйләнде. Вә дәхи әйтте, әй гакыл, синнән олуг вә газиз нәрсә яратмадым. Әмма синең сәбәпле шелтә кыйлырмын, синең сәбәпле хисап кыйлырмын вә синең сәбәпле гыйкаб кыйлырмын, диде».

Мәҗнүннәргә хисап вә гыйкаб[4] булмас, имеш. Аллаһы Тәгалә гакылны яратты, бертөрле якты җәүһәр иде. Аның урыны — мидәдер, нуры калебтәдер, һәммә мәгълүм нәрсәләр гакыл белән беленәдер. Вә бәгъзе күрелмәмеш нәрсәләр дәхи гакыл васитасы белән беленәдер. Кешенең гакыллы икәнен беләсең

---

[1] Кәзалик — шулай, тагы.
[2] Хәкыйрь — сүгелгән.
[3] Тәрк кыйлса — ташласа.
[4] Гыйкаб — җәза.

сүзеннән, фигыленнән вә һәрбер башка мөгамәләсеннән. Чөнки гакыл дигәнемез күзгә күренә торган нәрсә түгелдер. Бу кеше гакыллы дип беләсең аның гакылына дәлаләт кыйла торган эшләре белән. Мәсәлән, аның яхшы эшләргә вә яхшы нәрсәләргә мәйле барыннан. Вә явыз, вә бозык эшләрдән йөз чөермәге белән, вә дәхи үзенә гарьлек китерә торган эшләрдән сакланмакы белән. Аз сүзле булмак вә читләтеп сөйләмәк кешенең гакылына дәлилдер. Ләкин гакыл сәбәпле адәмнәр берберенннән өстен буладыр. Ягъни берәүнең гакылы берәүнең гакылына тугыры килмәй. Кеше үзен үзе танымак кәмаль гакылдандыр. Ахмак үзен үзе танымас.

Гакылның башы адәмгә катыша белмәк, торышта, йөрештә уртача булмак вә үзен, үзе сөекле күрсәтә белмәктер. Һәрбер эшне гакылыңа салып кара, гакылың тиеш күрсә, әлбәттә, ул эш саваптыр. Үзенә-үзе сокланучы кешедә гакыл юктыр. Гакыл иясенең сүзен колакка алмаган кешенең гакылы үләр. Сакалның зурлыгы һәм гакылга киртә, имеш.

Берәү бер китапта күрде ки: ахмак кешенең башы кечкенә, сакалы зур булыр, димеш. Хәзер көзгегә барып карады, күрде: үзенең башы кечкенә, сакалы зур. Бераз уйлап торды да, тукта, башны зур итәр хәл юк, һәрничек сакалны кечерәйтергә мөмкин, дип, сакалын учлап тотты. Учыннан артканына ут төртте. Сакалы яна башлады, кулы пеште, «абау!» дип, кулын тартып алды, сакалы бөтенләй янып китте. Хәер, бу һәм ахмаклыгымнандыр, диде. Мәсәлән, ирле-хатынлы кешегә дөньяда тереклек өчен, әлбәттә, йорт-җир кирәк. Бәс, гакыл — ир мәнзилендә, нәфес — хатын мәнзилендә, тән — йорт мәнзилендәдер. Әгәр гакыл нәфескә мәдәббир вә мәсәллат булса, ягъни гакыл нәфескә өстен булса, нәфес гакылга итагать кыйлыр вә тәннең төзеклеге белән мәшгуль булыр. Ягъни нәфес вә һәм тән гакылның тәдбире белән һаман төзек торыр. Ул вакытта гакыл, тән — барчасы сәламәт булыр. Нитәкки иргә мотыйга вә монкадә[1] булган хатын йортның төзеклеге белән мәшгуль булып, йорт төзек торыр, хатын үзе һәм тыныч, ире һәм рәхәттәдер. Әмма әгәр нәфес гакылга галиб[2] булса, нәфес һаман тәннең бозыклыгына тырышыр, нитәкки бер хатын иренә галиб булса, аслан йортның төзеклегенә сәгый кыйлмас, һаман йортны бозарга сәгый кыйлыр[3], ире һәм рәхәт күрмәс, үзе һәм рәхәт күрмәс.

Мәгълүм була ки, фирасәт ике кыйсем булып, әүвәлгесе тәҗрибә белән хасыйл булыр. Хөкәма моны хикмәт табигыйдән хисаплыйлардыр. Вә бере дәхи фирасәти шәргыядер ки, нәфесне тәмам явыз холыклардан пакь итеп, әгъмәл хәсәнәи

---

[1] Мотыйга вә монкадә — буйсынучы һәм сүз тыңлаучы.
[2] Галиб — җиңүче, өстен чыгучы.
[3] Сәгый кыйлыр — тырышыр.

шәргыя[1] вә риязати бәдәния вә калбия бәдәнне, калебне тыю белән матурлау сәбәпле хасыйл булган нур гыйрфан вә якыйннан ышаныч тәгаллек мөстәфад булыр дигән хәдис тә ошбу фирасәти шәргыягә ишарәттер. Вә фирасәти табигыя җәмигъ хайванаттан гакыл вә сөйләү кувәте белән мөмтаз булгучы һәр адәмнең нәфесе вә рухы Аллаһы Тәгалә тарафыннан ул сыйфат үзрә табигый булмыштан халык ителмештер. Вә ләкин ул фирасәт көзгесе күбрәк адәмнәрнең мизаҗендә бер аптырау бирүче нәрсәгә мохтаҗ булганнары хәлдә, фанилыкка бәйлелеге белән тутыгып калмыштыр, ягъни фирасәт нуры хасыйл булмамыштыр. Хикмәт табигыя тармагыннан булган нәүгы фирасәт фәнендә Әбүгалисинаның мөстәкыйлән бер китабы бардыр.

Әбү Сәгыйд Хаззаз әйтте, беркөн Бәйтуллаһта бер фәкыйрьгә раст килдем, өстендә гаурәт тупаслыгын каплый торган пәрдәсеннән башка нәрсә юк иде. Нәфесем аннан бу хәленә бинаән нәфрәт итте. Мәзкүр фәкыйрь дәрхаль минем нәфрәтемне тәфәррәс итеп, аять укыды. Мин дәхи, нәфрәт иткәнемә үкенеп, истигъфар кыйлган идем, янә фәкыйрь аять әйтте. Мөтәрҗим димештер ки, ул фәкыйрьнең бу кәшфе фирасәти табигыядән югары булгучы кәрамәт булмак ихтималдыр. Бу хосуста «Мөстәтраф» гүзәл хикәятләр бардыр. Бер чүлмәктә май булса, эчендә май барын тышыннан белеп буладыр. Мәсәлән, берәүнең күңелендә бер яшерен сер булса, ул кешенең тел төбеннән, йөзеннән, күз каравыннан сизеләдер.

Имам Шәфыйг белән имам Мөхәммәд бервакытны юл белән барганда, каршыларына килгән берәүне күреп, бер-береннән сораштылар. Берсе әйтте: «Бу кеше сәүдәгәрдер». Икенчесе әйтте: «Бу кеше тимерчедер». Ахыр ул кеше каршыларына килеп җиткәч: «Син ни кеше?» — дип аннан сорадылар. Ул кеше әйтте: «Мин элгәре тимерче идем, хәзердә сәүдә кыйламын», — диде.

Әйтәләр, бер кеше бар иде, бер агачны тотып, бу агачның фәлән кадәр яфрагы бар дип әйтсә, санап карасалар, төгәл ул әйткәнчә чыга торган иде. Берәү синең белән утырганда арыбире караса, бел: ул кеше бер сүз әйтмәгә тели. Бәгъзе кеше бер сүз әйтәсе булса, әүвәл авызын кыймылдатып торыр. Көтеп тор ки, ул кеше бер сүз әйтер. Берәү озак сөйләшеп утырганда кузгалып, әле бер ботын, әле бер ботын салса, истибрага кысталадыр, хаҗәтханә юлына дәлаләт кыйл. Әгәр берәү янына барып, бик озак утыргач, ул кеше урыныннан кузгалса, яки киемен барып тотса, яки урындыкны вә башка нәрсәне кузгатып куйса, бел: ул кеше синең озак утырганыңа ялыгып китүеңне тәказа кыйладыр, чыгып китмәкең дәркярдер[2].

[1] Әгъмәл хәсәнәи шәргыя — шәригатькә тугры гамәл.
[2] Дәркярдер — ачык, аңлашыладыр.

Шәһәр әһеленнән берәүгә бер кичне берничә кунак килде. Нигъмәтеннән тәнавел кыйлдылар[1]. Чәй эчтеләр. Ашап-эчеп тәмам булганнан соң да мөсамәрә[2] кыйлып озак утырдылар. Бу кеше кунакларны бик җибәрәсе килә ки, китмиләр, һаман утыралар. Бу кеше инде, бар, китеңез, дип әйтә алмый, чишенде. Аякларын салып ташлады. Ахыр бүлмә ишегенә барды, ишекне ачты да, хатыннар ягына таба карап, хәзер китәләр, диде. Гүяки, китәләрме, дип, хатыны сораган, имеш тә, аңа җавап бирә.

Берәүгә бер кунак килде. Кич белән иде. Бик озак утырды. Бу кеше куеныннан сәгатен алып карады да әйтте: «Сәгать ки бер сәйд бер сәр ун, дикерменшингә ступай вон».

Ахмаклык дәхи адәмдә бер табигатьтер ки, аны үзгәртмәктә вә алыштырмакта бер хәйлә әсәр итмәс. Вә ахмаклык адәмдә бер авырудыр ки, аның дәвасы үлемдер. Ягъни надан вә ахмакка үлемнән башка дәва юктыр. Берәү шигырь укый. Шигырьнең мәгънәсе: ахмаклык авыруыннан башка һәртөрле авыру өчен дару бардыр. Мәгәр ахмаклыкка вә наданлыкка гыйлаҗ иткән кешегә гаҗизлек вә мәлаләт хасыйл булыр, мәгәр аңа файда бирмәс.

Ахмаклык шәригать вә гакыл йөзеннән бозык холыктыр, Аллаһы Тәгаләнең яратмаган нәрсәседер. Чөнки ахмак кеше иң газиз нәрсәдән мәхрүмдер ки, ул — гакылдыр. Хәкимнәр кешенең ахмаклыгын тышкы күренеш әгъзасыннан һәм истидлал кыйлалар ике җәһәттән: бере — озын сакаллы кешенең ахмаклыгы. Сакалның үсеп чыга торган җире — мидер. Озын сакаллы кешенең мие аз. Мие аз булган кешенең гакылы зәгыйфь булыр вә гакылы зәгыйфь исә ахмактыр, димәктер. Вә дәхи бере — ахмакның фигыльләре хасиятеннән. Галәмәте будыр ки; барлы-юклы гакылына ни килсә — аны эшләр, эшнең гакыйбәтен фикер итмәс. Тәҗрибә кыйлынмаган вә мәгърифәте мәгълүм түгел адәмнең сүзенә игътимад кыйлыр, үзенә соклануы күп булыр. Вә мактаганны яратыр. Бернәрсә сөаль кыйлсалар, ашыгып җавап бирер. Вә һәр хосуста гаҗәлә калыр: мәгърифәттән хали вә буш; золым вә хатасы күп булыр, уңга-сулга күп карар, вәкарсыз шәлпәк булыр. Олы сымак вә саллылык кыйлмас. Хаҗәтсез вә халыктан нәрсәдер өмид итмәгән булса, тәкәбберлеге вә горурлыгы күп булыр. Ни сөйләсә — фәхеш сөйләр. Ни сорасалар — саранлык кыйлыр. Үзе сораса, ялынып сорар. Дорфа вә тупас сөйләшер, тәмле сүз сөйләмәс, кеше сүзен фәһемләмәс. Көлсә — кычкырып көләр. Егъласа — кычкырып егълар.

«Мөстәтраф» иясе димештер ки: «Күп кешене тәҗрибә кыйлдым, ахмакларны бу сыйфатта таптым», — димештер.

---

[1] Тәнавел кыйлдылар — авыз иттеләр.
[2] Мөсамәрә — әңгәмә.

Гайсә галәйһиссәлам: «Даруны кабул итмәгән бәрәс[1] зәхмәтенә вә анадан күзсез туганнарга дәва итеп, Аллаһның изне белән тергездем, әмма ахмакка дәва кыйлмады вә ахмаклык авыруы китмәде», — диде.

Җабир бин Габдулладан риваять кыйлынмыштыр ки, бәни Исраилдән бер кеше үзенең саумәгасында гыйбадәт кыйлыр иде. Яз көне. Рәхмәт ягъмурлары явып, җирдән нәбатат вә үләннәр үскәч, үзенең аты утлап йөргәндә, әйтте: «Әй Раббым, синең һәм атларың булса иде, минем атым белән бергә утлап йөрсә иде», — дип, Аллаһы Тәгаләгә мөнәҗәт кыйлды. Ошбу Аллаһы Тәгаләнең шанына лаек булмаган нәрсә белән мөнәҗәт кыйлганын шул заманның пәйгамбәренә хәбәр бирделәр. Вә ул пәйгамбәр бу кешене лаексыз дога кыйлган өчен ачуланырга теләгәч, Аллаһы Тәгалә аңа вәхи кыйлды ки: «Ул бәндәм озак заман үз саумәгасында үзенең микъдарынча миңа мөнәҗәт кыйлыр. Мин бәндәләремне гакыллары кадәренчә җәза вә һәр кешенең ихласы кадәренчә бүләк бирермен, тимә», — диде. Күңеле дөрес вә сәламәт булып, халыкка изасы тимәгән ахмакны гарәпләр «җәннәт үгезе» диерләр. Халыкка зәхмәт вә һәр кешегә иза биргән ахмакны «бәкаре сәкар», ягъни «җәһәннәм үгезе» диерләр. Нитәкки телемездә андаен кешене «Самар үгезе» диерләр.

## *Дүртенче рауза*

Гыйлем. Хикмәт. Әдәп. Китабәт. Хата. Тәхриф[2]. Наданлык. Мөгаллимнәр. Мәгаз бин Җәбәл разыйаллаһу ганһудан риваять кыйлынмыштыр ки, пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Гыйлем үгрәнмәк фарызлардан бер фарыздыр. Гыйлемнән дәрес әйтмәк — тәсбихдыр. Гыйлемдә бәхәс итмәк — җиһадтыр. Замана халкын күрәмез ки, үзеннән наданлыкны китәреп гыйлем белән гамәл кыйлмак өчен, аслан гыйлем эстәгән кеше юк. Мәгәр мөфахәрә[3] вә мөкябәрә[4] өчен вә ризык, кәсептә сәбәп өчен гыйлем үгрәнерләр».

Имам Хәлил әйтте: «Галим кешенең ялгышы вә хатасы белән табыл орылыр, надан кешенең ялгышын вә хатасын наданлыгы каплар». Максуд: «Галим кешегә тәкъва булмак кирәк»,— димәктер.

Ибн Мәсгуд разыйаллаһу ганһу укучыларны күрсә: «Мәрхаба, әй гыйлем вә хикмәт чишмәләре вә әй наданлык караңгылыгының якты кандилләре[5], киемнәре иске, күңелләре хәзинә,

---

[1] Бәрәс — махау, проказа.
[2] Тәхриф — буташтыру, үзгәртү.
[3] Мөфахәрә — горурлык.
[4] Мөкябәрә — масаю.
[5] Кандилләре — лампалары, люстралары.

һәр шәһәрнең чәчәкләре вә гөлләре!» — дип рухландыра иде. Әмма бу ибн Мәсгуд заманасында иде. Хәзрәти Гали разыйаллаһу ганһудан мәнкульдер ки: «Гыйлеме булмаган кешеләрнең гыйлем вә белү дәгъвасын кыйлмаклары гыйлемнең шәрафәтле нәрсә икәненә дәлил кяфидер. Әгәр син аларга: «Син — галимсең, син беләсең», — дисәң, куркусыз вә шат булырлар».

Янә бер галим димештер ки: «Гыйлемнең шәрафәтле нәрсә икәненә шул дәлил җитәр ки, гыйлеме булмаган кеше, мин галим, дип, гыйлем дәгъвасы кыйлыр. Син галимсең, беләсең, дисәң, сине яратыр, рәхәтләнер вә сине дус тотар. Вә дәхи наданлыкның хур вә түбән нәрсә икәненә шул дәлил җитәр ки; җәмигъ халаик наданлыктан затлы күренер. Вә начарсың, надансың, белмәйсең, дисәң, рәнҗер, мөтәаллим[1] булыр, үзенне дошман тотар. Хасыйле кәлям, наданлыкны һичкемнең күтәрәсе килмәй. Вә шуңа да карамастан надан күп.

Гали разыйаллаһу ганһу пәйгамбәр галәйһиссәламнән риваять кыйлмыштыр ки: «Оҗмах ишеге төбендә бер олуг агач бардыр. Аның астында хәзер сауган сөт кебек бер чишмә агар. Кыямәтнең каты эссе көннәрендә халык сусаган вакытта галимнәр вә талибелгыйлемнәр эчеп тукланырлар», — димештер.

Әнәс разыйаллаһу ганһудан риваять кыйлынды: «Фәкать дөнья өчен гыйлем эстәгәннәргә пәйгамбәр галәйһиссәлам бәддога кыйлмыштыр».

Әхлак хәсәнә[2] белән мөттәсыйф булмаган галимгә бер шагыйрь язды. Мәгънәсе: бер галимнең гыйлеме күңеленә тугры юл вә тормыш юлына гадаләт, вә әхлакына хөсне тәрбият арттырмаса, ул галимгә хәбәр бир ки, Аллаһы Тәгалә аны фитнә белән мөбтәля итеп, аны кайгы-хәсрәт чорнап алыр да имин вә әмандан мәэюс булыр, димәктер. Вә галимнәр димешләрдер ки: «Бер галимнән берәү бер мәсьәлә сораса, ул вакытта син никадәр галим булсаң да, ул галим тарафыннан җавапка кул тыкма, зирә галимне вә саилне хөрмәтсезләгән булырсың».

Гали разыйаллаһу ганһу әйтте: «Бер кемсәнә халыкка имам вә моктада[3] булса, әүвәл үзен вә әхлагын тәрбия кыйлып, аннан соң гайреләрне тәрбия кыйлсын. Зирә нәфесен тәрбия кыйлмак вә әхлагын төзәтү адәмне тәгълим вә тәэдиб[4] кыйлмактак әүвәледер», — диде. Вә дәхи үзе гамәлсез галимгә берәү язды ки: «Әй гайреләрне тәгълим иткән кемсәнә, үзенне-үзең үгрәнсәң, бу сиңа гайреләрне үгрәтмәктән зиядә лазем түгелмедер? Гыйлемгә омтылучан түгелсең. Авыруларга гыйлаҗ бирерсең, ни өчен, үзең хаста икән, үзеңә гыйлаҗ итмәс-

---

[1] Мөтәаллим — нәүмиз, кайгылы.
[2] Хәсәнә — матур холык.
[3] Моктада — житәкче, үз артыннан ияртүче.
[4] Тәэдиб — әдәпкә өйрәтү.

сең? Без сине калебләремезне иршадкә салих күрермез ки, гыйрфаның[1] бардыр, ләкин үзеңдә иршад юктыр. Үзеңне тәрбия кыйлудан башлап, үзеңне зәляләттән нәһи вә мәнгъ кыйл. Әгәр үзең зәляләттән кайтсаң, ул заман хәким вә галим икәнеңне белеп, сүзеңне тотармыз, сиңа иярермез вә безгә тәгълимең тәэсир итәр. Халыкны тыйган яман холыкны үзең эшләмә ки, сиңа олуг гарьдер»,— диде.

Тәварихларда мәзкүрдер ки: Фисагурис[2] хәким хикмәтне Сөләйман галәйһиссәламнән әхәз кыйлды, Мисырда музыка гыйлемен ул истихраҗ кыйлды. Көйләрне ул язды. Вә әйтер иде ки: «Ошбу гыйлемне мишкатеннәүбәттән яктырткычыннан истифадә кыйлдым». Гыйльме хикмәттә бу Фисагурисның дәрәҗәсе бик олугдыр, Сократ аның шәкертедер.

Әфләтун хәким димештер ки: «Хикмәт ияләре хикмәтләре белән вә гыйлем ияләре гыйлемнәре белән нәбиләр дәрәҗәсенә ирешә алмаслар. Минем гыйлемем юк, мәгәр мин галим түгелмен дигән гыйлемем бар», — димештер. Ягъни: үземнең белмәгәнемне генә беләмен, димәктер.

Җалинус[3] әйтте: «Гыйльме риязыйны атамнан укыдым ун яшемә кадәр, аннан соң өч ел гыйльме тыйбны укыдым», — диде. Бәгъзеләр Җалинус хәкимнән сорадылар: «Гыйлем артыкмы, мал артыкмы?» — диделәр. Җалинус әйтте: «Әлбәттә, гыйлем артыктыр», — диде. Әйттеләр: «Ник алай булса галимнәр байлар капкасына баралар, әмма байлар галимнәр капкасына килмәйләр?» — диделәр. Җалинус әйтте: «Бу аның өчендер ки, галимнәр малның файдасын беләләр, әмма байлар гыйлемнең файдасын белмәйләр. Шуның өчен байлар галимнәр капкасына килмәйләр», — диде.

Сәһел бин Габдулла әт-Тәстәри әйтте: «Наданлыктан яман белән Аллаһы Тәгаләгә һичкем гасый булмады. Әйттеләр: «Йә Мөхәммәд, наданлыктан яман нәрсә бармыдыр?» — диделәр. «Бар», — диде. «Ни-нәрсәдер?» — диделәр. Әйтте: «Белмәгәнеңне белмәслектер, ягъни берәү белмәс, үзенең белмәгәнен дә белмәс, бу наданлыктан да ямандыр, моны катлы наданлык диерләр», — диде. Наданлык бер аттыр, кем атланды, таеп егылды. Кем наданнар белән сохбәт кыйлды, хур булды. Наданнар белән сохбәт наданлыктыр. Надан мал эстәр. Гакыйль кәмальлек эстәр. Фазыйләтне белмәгәнлек хәсислекнең вә асылсызлыкның да кабахәтрәгедер.

Софьян Сүри әйтте: «Гыйлем эстәмәктән артык вә фазыйләтле нәрсә юктыр, әгәр ниятең дөрес булса, гыйлемлекне эстәңез, гыйлемлектән файда тапмасаңыз да яки гыйлем хасыйл итә

---

[1] Гыйрфаның — белемен.
[2] Фисагурис — борынгы грек философы Пифагор.
[3] Җалинус — борынгы Рим врачы Гелен.

алмасаңыз да». Бәгъзеләр димешләрдер ки, гыйлемнән морад дүрт төрле гыйлемдер: бере дин өчен — фикъһе гыйлеме; бәдән өчен — тыйб гыйлеме; замана өчен — нөҗүм гыйлеме; тел өчен — нәхү гыйлеме.

Хәзрәти Гали разыйаллаһу ганһу әйтте, хәмәләи Коръәннән[1] берәү гыйльме һәйят[2] вә гыйльме нөҗүмнән икътибас кыйлса, иманы вә тәгәллеге артыр, диде. Аннан соң аятьне ахырынача укыды.

Аллаһы Тәгаләнең берлегенә вә кәмаль кодрәтенә дәлил эстәп, йолдызларга фикер кыйлып карамак тагатьләрнең олугысыдыр, диделәр. Ибн Габбас разыйаллаһу ганһу әйтте: «Йолдызларга фикер кыйлып карамак гыйльме нәбүвәттән[3] бер гыйлемдер, кяшки мин һәм белсәм, ни гүзәл эш булыр иде», — димештер.

Идрис галәйһиссәлам нөҗүмгә вә гыйльме хисапка караганнарның әүвәлгесе иде, ягъни гыйльме нөҗүм вә гыйльме хисап Идрис галәйһиссәламнән чыкмыштыр. Мәймүн бин Мәһран әйтте: «Нөҗүм гыйлемен «ялган» диюдән сакланмак лаземдер ки, ул нөҗүм гыйлеме гыйльме нәбүвәтдер», — диде.

Бәни Исраилдән бер кеше утыз ел гыйбадәт кыйлды. Бәни Исраилдән бер кеше утыз ел гыйбадәт кыйлса, өстендә бер болыт күләгә булыр иде, әмма бу кешенең өстендә болыттан күләгә юк. Бу кешенең анасы бар иде, бу вакыйганы анасына шикаять кыйлды. Анасы әйтте: «Бу елларда бер-бер гөнаһ эшләгән булсаң кирәк», — диде. Углы әйтте: «Юк, бер гөнаһ та кыйлмадым». Анасы әйтте: «Күзеңне күтәреп, һичбер фикерсез күккә караганың бармы?» — диде. Углы әйтте: «Бәли, караган идем». Анасы әйтте: «Алайса, шул гөнаһың сәбәпледер», — диде. Чөнки бәни Исраил галимнәре каршында күккә карап, Аллаһы Тәгаләнең кодрәтен фикер кыйлмак гыйбадәттән саналыр иде.

Димешләрдер ки, бәни Исраил голямасы ике төрле гыйлемне яшерерләр иде, ягъни тыйбб гыйлемен вә нөҗүм гыйлемен балаларына өгрәтмәсләр иде. Падишаһлары бу гыйлемнәргә мохтаҗ булган өчен, падишаһ сохбәтенә сәбәп булыр да, динемез юкка чыгачак дип фаш итмәсләр иде. Падишаһлар сохбәтендә булмактан нәфрәт кыйлырлар иде. Горрә хосусында[4] мөнәҗҗим сүзенә ышануда зарар юктыр, диделәр. Мөхәммәд бин Мөкатил мөнәҗҗимнәрдән ай башын сорашыр иде. Әгәр дә аларга берничә җәмәгать кушылса, игътимад кыйлыр иде.

Бәгъзе мөнәҗҗимнәрдән риваять кыйлынмыштыр ки, пәйгамбәрләрнең мәүледе күбрәк Сөнбәлә вә Мизан йолдызыдыр.

---

[1] Хәмәләи Коръәннән — биредә: Коръәнне яхшы аңлаучылардан.
[2] Гыйльме һәйят — астрономия.
[3] Гыйльме нәбуvәттән — пәйгамбәрлек гыйлеменнән.
[4] Горрә хосусында — йолдызлар турында.

Камәр[1] Гакрәбдә[2] булган вакытта вә камәрнең соңгы төне вакытында сәфәр кыйлмакны мәкрүһ күрер иде хәзрәти Гали разыйаллаһу ганһу. Ибн Дәкин дигән мөнәҗҗимнән сорадылар: «Мөштәри[3] сәгыйд[4] дип әйтәсең, дәлилең нидер?» — диделәр. Ул мөнәҗҗим әйтте: «Мөштәринең күркәмлегедер», — диде. Мөнәҗҗимнәр димешләрдер ки: «Зохәлгә[5] карамак көенеч пәйда кыйлыр вә Мөштәригә карамак шатлык пәйда кыйлыр», — димешләрдер. Хәзрәти имам Әбү Йосыф әйтте: «Һәрбер гыйлемне үгрәнеңез. Мәгәр өч төрле гыйлемне үгрәнмәңез ки: гыйльме нөҗүм, гыйльме кимия[6], гыйльме җәдәл[7]. Чөнки нөҗүм гыйлемен үгрәнмәк шомлык китерә, гыйльме кимияне үгрәнмәк ифлас китерер, гыйльме җәдәлне үгрәнмәк диндә зиндикълык пәйда кыйлыр», — диде.

Гали разыйаллаһу ганһу әйтте: «Хикмәт — мөэминнең качкан нәрсәседер, тиз табып алыңыз, кирәк мөшрикләр[8] авызыннан булса да», — диде. Янә бер риваятьтә хикмәт мөэминнең качып киткән нәрсәседер, кайда гына тапса, тизрәк тотып алсын, димештер.

Имам Әгъзам хәзрәтләре остазы Хәммад хәзрәтләренә гыйлем укымага килгәч, Хәммад әйтте: «Һәркөн өч мәсьәлә үгрән, аннан арттырма, таки сиңа гыйлем хасыйл булыр», — диде. Бәс, имам Әгъзам остаз мәслихәте белән гамәл кыйлды, барча халыктан әгъләм булды. Имам Әгъзам хәзрәтләре әйтте: «Аллаһы Тәгаләдән вә Рәсүлуллаһтан ни килде (баш өсте, дип), кабул иттек; сәхабәләрдән ни килде — яхшысын ихтыяр кыйлдык, сүзләреннән чыкмадык; табигыйннәрдән ни килде — безләр адәм, алар һәм адәмнәрдер», — диде. Имам Әбү Йосыфтан бер мәсьәлә сорасалар, җавап биреп әйтер иде: «Бу имам Әгъзам сүзедер», — диер иде. Димешләрдер ки: «Голямадан дүрт кемсәнә кебек кешеләр дөньяга килмәде: имам Әгъзам — фикъһедә; имам Хәлил — нәхүдә[9], имам Җахыйз — таэлифтә[10]; Әбү Тәмам — шигырьдә».

Мөхәммәд бин Җәрәб әйтте: «Голяма арасында Әбү Хәнифә — өмәра арасында хәлифә кебектер», — диде.

Пәйгамбәр галәйһиссәламнән бер кемсәнә сорады: «Йә Рәсүлулла, кайсы гамәл изгерәктер?» — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Аллаһы Тәгаләне белмәк изгерәктер», — дип, өч

---

[1] Камәр — ай.
[2] Гакрәбдә — Чаян йолдызлыгында.
[3] Мөштәри — Юпитер.
[4] Сәгыйд — бәхетле.
[5] Зохәл — Сатурн.
[6] Кимия — химия, алхимия күздә тотыла.
[7] Җәдәл — талаш, сугыш.
[8] Мөшрикләр — мәҗүсиләр.
[9] Нәхүдә — грамматикада.
[10] Таэлифтә — язуда.

мәртәбә тәкрар кыйлды. Ул кеше әйтте: «Йа Рәсүлуллаһ, мин гамәлдән сорадым, син гыйлемнән хәбәр бирәсең», — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Гыйлем белән сиңа аз гамәл һәм файда кыйлыр, надан булсаң сиңа күп гамәл дә файда кыйлмас», — диде. Гыйлемсез гыйбадәт кыйлган кеше тегермәнгә жиккән ишәк кебектер ки, әйләнә-әйләнә, барып житә алмай.

Имам Малик «мәүтаә»дан дәрес әйткәндә, Һарун әр-Рәшит боерды, мәҗлесне хали кыйлдылар, ягъни башка талибларны мәҗлестән чыгарып, үзләре генә калдылар. Имам Малик әйтте: «Гыйлемнән гаммә читләтелсә, асыл затлар файдалана алмас», — диде. Бәс, изен бирде, керделәр.

Гыйлем эстәгән кешегә гыйлемеңне сарыф кыйл вә үгрәт, вә эстәмәгән кешеләрне дә гыйлем эстәмәгә дәляләт кыйл. Юкса мисалең шуңар охшар ки, берәүгә берәү һәдия алма җибәрсә, аны үзе дә ашамай, кешегә һәм ашатмай череп бетә. Хәкимнәр димешләрдер ки, тәннең азыгы — ашамак-эчмәк. Гакылның азыгы — гыйлем вә хикмәт.

Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Өммәтемнең һәлак булмакы ике нәрсәдәдер: мал җыймакта вә гыйлем үгрәнмәенчә надан калмактадыр. Гыйлем — йозактыр, сөаль-ачкычтыр: сорашмак вә сөйләшмәк белән гыйлем ачыладыр. Берәү кечкенә чагында гыйлем үгрәнмәсә, зур булгач, алга чыкмас, ягъни гыйлем арттыра алмас. Бер ел гыйлем үгрәнмәк ике ел гыйбадәт кыйлмактан хәерлерәктер. Әдәпнең җимеше — гакылны үстерү. Гыйлемнең җимеше — изге гамәле. Бәндәгә дөньяда бирелгән нәрсәләрнең артыграгы хикмәттер вә ахирәттә рәхмәттер». Имам Хәлил әйтте: «Кайсы галимгә юлыксам да, аннан гыйлем алдым вә аңа гыйлем бирдем». Димешләрдер ки, имам Мазниның кулында имам Сибәвәйһ китабы егерме мәртәбә тузды вә ертылды, ягъни күп укыганнан вә күп истигъмаль кылганнан гыйбарәттер.

Әфләтун хәкимгә бер кеше әйтте: «Йә хәким, бу кадәр гыйлемне ничек үгрәнеп бетердең?» Әфләтун әйтте: «Тәхсил гыйлем вакытымда мин яндырган майны үлчәп карасаң, гомерем буенча эчкән нәрсәдән күбрәк яндырганмын», — диде, озак тәхсил кыйлдым, димәктер.

Имам Әбү Йосыф әйтте: «Бервакытны углым вафат булды. Имам Әгъзамның гыйлем мәҗлесеннән мәхрүм каламын дип куркып, җеназасына чыкмадым», — диде. Әй угыл, дәрескә мөлязим бул[1]. Дәрес укымак — җимеш агачы утыртмак кебектер. Берәү озак дәрес укымага ялкауланса, нәфесен мәшәкать чиктермәсә, гыйлем эстәгән атлы түгелдер. Ибн Габбас разыйаллаһу ганһудан сорадылар: «Ни-нәрсә белән син бу кадәр

[1] Мөлязим бул — ябыш.

гыйлем дәрәҗәсенә ирештең?», — диделәр. Ибн Габбас әйтте: «Сорагучы тел белән, белгүче калеб белән вә түземле остаз белән», — диде. Бәзер Җәмһәрдән сөаль кыйлдылар: «Йә мәлик, син ни белән бу кадәр гыйлемгә ирештең?» — диделәр. Бәзер Җәмһәр әйтте: «Карга кебек иртә тордым, дуңгыз кебек комсыз булдым, эт кебек сабыр булдым, мәче кебек тәвазыглыклы[1] булдым да, гыйлем дәрәҗәсенә васыйл булдым, максуд хәзинәләре михнәт күпере өстендәдер», — диде.

Һиндвани хәзрәтләре Бохарадан кайткач, Бохара әһеленең хәленнән хәбәр сораштылар. Һиндвани әйтте: «Мин аларны фәкыйһ күрдем — галимнәрдер, вә ярты фәкыйһ күрдем, ягъни ярты галим күрдем», — диде. Фәкыйһ дигәненнән морады мәйданы иде вә ярты фәкыйһтән морады Мөхәммәд бин Фазыйл иде, чөнки Мөхәммәд бин Фазыйлның хисабияттан[2] хәбәре юк иде. Мөхәммәд моны ишеткәч, тиз заман гыйльме хисап белән мәшгуль булып, хәтта бу хисап гыйлемендә үрнәк, җитәкче дәрәҗәсенә ирешмештер.

«Мөхите борһани»[3] иясе берничә сәнәд белән риваять кыйлмыштыр ки, тарикаи хатаин вәхи белән беленмештер. Хәсән разыйаллаһу ганһу әйтте: «Берәү гыйлем эстәмәктән хәя[4] пәрдәсе белән йөзен өретсә, ягъни гыйлем эстәмәктән оялып торса, наданлык күлмәген кияр, ягъни тәмам үзен наданлык белән каплар», — диде.

Гайшә разыйаллаһу ганһадан риваять кыйлынмыштыр ки: «Мәдинә мөселманнары хатыннары ни изге хатыннардыр ки, дин гыйлемен үгрәнмәктә хәя аларны мәнгъ кыйлмады», — димештер. Гыйлем үгрәнергә оялган кеше вә мөтәкәббир[5] кеше гомердә гыйлем үгрәнә алмаслар. Бәс, әй утыл, инде гыйлем үгрәнмәктән оялма, гыйлем үгрән, наданлык — гарьлек вә хурлыктыр, наданлыкка ишәктән гайре кемсәнә разый булмас.

Гали кәррәмәллаһу вәҗһәһи әйтте: «Берәү белмәенчә фәтва бирсә, җир күк ләгънәт кыйлыр». Ибн Мәсгуд разыйаллаһу ганһу әйтте: «Һәрбер сораганга фәтва биргүче — мәҗнүндер». Имам Әгъзам хәзрәтләре әйтте: «Кем миңа ачу дошманлык кыйлса, Аллаһы Тәгалә аны мөфтилек белән мөбтәля кыйлсын». Һәйсәм бин Җәмил әйтте: «Бервакытны Малик бин Әнәс янында идем, бер кеше килеп кырык сигез мәсьәлә сорады. Малик хәзрәтләре утыз ике мәсьәләсенә белмимен дип җавап бирде», — диде. Имам Шәгъбидән бер мәсьәлә сорадылар. «Белмимен», — диде. Әйттеләр: «Ике Гыйракның фәкыйһысы булып

---

[1] Тәвазыглыклы — тыйнак.
[2] Хисабияттан — хисап гыйльменнән.
[3] «Мөхите борһани» — китап исеме.
[4] Хәя — оялу.
[5] Мөтәкәббир — үз-үзен эре тотучы.

торасың, белмим дип әйтергә оялмадыңмы?» — диделәр. Шәгъби әйтте: «Фәрештәләр оялмаган нәрсәдән мин оялмаймын, ягъни фәрештәләр дә Аллаһы Тәгалә сораган вакытта «бездә син өйрәткән гыйлемнән башка гыйлем юк» дип җавап бирделәр», — диде. Бервакытны Гали разыйаллаһу ганһу минбәрдә иде, берәү килеп бер мәсьәлә сорады. Гали әйтте: «Белмим». Җәмәгатьтән берсе әйтте: «Бу минбәрдә син торасың, ул — наданнар урыны түгелдер», — диде. Гали әйтте: «Бу шундаен кешеләр урыныдыр ки, бер нәрсәне белер, бер нәрсәне белмәс. Әмма галимнең вә җаһил түгелнең урыны юктыр», — диде.

Имам Әбү Йосыфтан бер мәсьәлә сорадылар. «Белмим», — дип җавап бирде. Әйттеләр: «Һәр көндә бәйтелмалдан[1] фәлән кадәр эш хакы аласың, «белмим» дип әйтәсең», — диделәр. Әбү Йосыф әйтте: «Мин гыйлемем кадәр аламын, әгәр наданлыгым кадәр алсам иде, бөтен дөньядагы нәрсә минем эш хакыма җитмәс иде», — диде. Әбү Бәкер әл-Кабатыйдан берәү бер сүз сорады. Кабатый минбәрдә иде, «белмим» дип җавап бирде. Әйттеләр: «Бу урын белмәгәннәр урыны түгелдер», — диделәр. Кабатый әйтте: «Мин гыйлемем кадәре мендем. Әгәр наданлыгым кадәре менсәм иде, күккәчә менәр идем», — диде.

Белмәгәненне әйтмә, белгәненне фәһемлә. Әристу[2] әйтте: «Әдәпнең күркәмлеге нәсәбнең кабахәтен фазыйләт — гыйлем вә әдәп беләндер, асыл белән вә нәсәб белән түгелдер. Берәү әдәпсез булса, нәсәбе заегъ[3] булыр», — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Ата балага нәрсә бирсә, биргән нәрсәсенең иң әгъләсе — әдәптер», — диде. Гали разыйаллаһу ганһу әйтте: «Адәмиләр галим яки укучылар, калганы һәмәҗ[4] вә гавамдыр».

Бервакыт Васикъ биллаһ хәлифәнең остазы килде, остазын гаять гыйззәт вә икрам кыйлды. Һай-һай, бәрәкаллаһ, остазыңны бик гыйззәт вә икрам кыйлдың, диделәр. Васикъ әйтте: «Иң әүвәл Аллаһы Тәгаләнең зикере белән минем телемне ул ачты, Ходаның рәхмәтенә якын ул кыйлды», — диде. Искәндәргә әйттеләр: «Анаңны тәгъзыйм кыйлганнан да бигрәк остазыңны тәгъзыйм кыйласың, имеш», — диделәр. Искәндәр әйтте: «Анам мине күктән җиргә иңдерде, остазым җирдән күккә күтәрде», — диде. Вә дәхи Бөзерҗмәһәрдән сорадылар: «Ник бу кадәр остазыңны атаңнан да артыграк итеп тәгъзыйм кыйласың?» — диделәр. Бөзерҗмәһәр әйтте: «Атам — фани яшәешкә сәбәп, остазым бакый яшәешкә сәбәп булды. Аның гыйлеме дәрьясыннан сугарылам, хикмәт агачыннан җимешләрен җыямын», — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Галимнәр йөзенә карамак —

---

[1] Бәйтелмалдан — казнадан.
[2] Әристу — Аристотель.
[3] Заегъ — әрәм, файдасыз.
[4] Һәмәҗ — варвар.

гыйбадәттер». Мөхәммәд бин Җәгъфәрдән бу хосуста сөаль кыйлдылар, ягъни пәйгамбәрнең бу сүзен бәян кыйл, дип илтимас кыйлдылар. Мөхәммәд әйтте: «Галимнәр йөзенә карамак шуның өчен гыйбадәттер ки, алар сиңа ахирәт бурычларын исеңә төшерерләр», — диде. Хәлил әйтте: «Галимнең ялгышы вә хатасы тиз фаш булыр, җаһилнең ялгышы җәһаләте астында өретелмештер». Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Дөньяда фитнә килер, халыкны тар-мар китерер. Әмма галим котылыр», — диде. Хәкимнәр димешләрдер: «Әгәр хирыслык булмаса, дөнья харап булыр иде. Әгәр шәһвәт булмаса, нәсел киселер иде. Вә әгәр остазлык дәрте булмаса, гыйлем батыйль булыр иде», — димешләрдер. Зөннун әл-Мисри хәзрәтләре васыять итеп димештер ки: «Наданлык белән гыйлем эстәмәктән сакланыңыз, наданлык белән гыйлем эстәмәгез», — диде. «Наданлык белән гыйлем эстәмәк ничек булыр?» — диделәр. Зөннун әйтте: «Кайчан ки дәрес вакытында остаз янына барсаң, артка калып, кешенең җилкәсеннән атлап-атлап керсәң, таләбе гыйлем вакытында картларны хөрмәтләмәсәң, үзеңне олы тота белү тыну вә әдәпне истигъмаль кыйлмасаң, моны наданлык белән гыйлем эстәмәк, диерләр», — диде. Әбү Гобәйдә әйтте: «Һичбер галимнең ишеген какмадым, чөнки кешенең ишеген какмак бер төр иза бирмәктер ки, һичбер галимне иза кыйлмадым», — димәктер.

Димешләрдер ки, малның тогъяны[1] булган кебек, гыйлемнең һәм тогъяны бардыр. Берәү белмәенчә гамәл кыйлса, ислах кыйлудан артыграк әфсад кыйлыр. Мәсәлдә килмештер ки, гыйлемсез гамәл кыйлган кеше юлсыз җирдән йөргән кеше белән бәрабәрдер. Бәс, гыйлем эстә, гыйбадәтеңә зарар бирмәсен, вә гыйбадәт гыйлем эстәмәкеңә зарар бирмәсен. Бер кемсәнә пәйгамбәр галәйһиссәламгә әйтте: «Мин хәдисләр вә яхшы сүзләр ишетәмен, хәтеремнән чыгадыр», — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Кулыңнан ярдәм эстә, ягъни ишеткәнеңне язып куй», — диде.

Мәсәлдә килмештер: күңелгә бикләгән качар, язып куйган карар кыйлыр. Гыйлем — аудыр, язмак — баудыр. Шәгъби әйтте: «Гыйлем бабыннан һәрни ишетерсең, язып куй, кирәк дивар үзәренә булса да», — диде. Риваять кыйлмышлардыр ки, имам Фараби хәзрәтләре тәхсиле гыйлем вакытында бик фәкыйрь иде. Кәгазь сатып алырга да акчасы юк иде. Урманга чыгып йөреп, күңеленә төшкән хикмәтләрне агач яфракларына язып йөрер иде. Кәгазь тапкач, барып күчереп алыр иде.

Гали разыйаллаһу ганһу әйтте: «Дөньяда гыйлем хисапсыз күптер, яхшырагын вә файдалырагын кабул ит», — диде. Һәрни китап кулыңа төшсә укы, яхшысы белән гамәл кыйл. Гыйлемнең

---

[1] Тогъяны — бозыгы.

ниһаяте юктыр, мең ел укысаң да, белмимнән башка булмассың, һаман гыйлемнән туймассың. Әристу әйтте: «Ниндәен хәерле вә файдалы нәрсә язарсың, гүзәл вә укырлык булсын, гүзәл хат белән яз. Вә ниндәен хәерле вә файдалы нәрсә өйрәнсәң, язарлык булсын, ягъни хифыз өйрәнгәнеңне онытма, күңелеңнән чыгарып тасниф кыйлырлык бул, каләм — сүзнең илчеседер, язу — кулның теледер. Әкълидис[1] хәким димештер ки: «Хат вә язу-рухани һәндәсәдер[2] аләт җисмания[3] зоһур итте», — димештер. Язу язмак фәкыйрьләр янында малдыр, байлар янында җәмалдыр, олуглар янында кәмальдер. Кораллрның файдалырагы каләм, кара савыттыр, димешләрдер, мәгънәсе: каләм, кара савыт — алтын пәрәсеннән һәм файдалырактыр. Кара савыт бер күлдер ки, аннан хикмәт чишмәсе агар, тамчыларыннан бәлягать болыты хасыйл булыр, димешләрдер.

Сәһел бин Һарун әйтте: «Каләм — күңелнең борыныдыр, кайчан канаса, серләрен сачар, әсәрләрен атар». Бер гарәп әйтте: «Каләм язуы кара сурәтләрдер, күңелләрдә вә күзләрдә актыр», — диде. Әюб бин Гассан әйтте: «Минем каршымда шул күлмәктән вә шул киемнән күркәм вә гүзәл нәрсә юктыр ки, әтрафына кара тамган әсәре булса. Вә шул бармак ни гүзәл бармактыр ки, каләмнән йоккан карасы булса», — диде.

Димешләрдер: күркәм язу яза белмәк — ярты гыйлемлектер вә ризыкның күбәюенә сәбәптер.

Каләм үгрән, каләм изгегә тартыр. Каләм берлән кешенең ризкы артыр, димешләрдер, кадимнән бар сүздер.

Бер гарәп бер китапка карады да әйтте: «Монда хикмәт йолдызлары икән», — диде. Бер галим бер кешене күрде: язу яза, ләкин язуы начар иде. Галим әйтте: «Каләмеңнең ботын озын ит, очын кыек кис, акрын яз, язуың гүзәл булыр», — диде.

Хәзрәти Гали кәррәмәллаһу вәҗһәһинең Гобәйдулла бин Әбү Рафыйг исемле язучысы бар иде, аңар әйтте: «Кара савытыңны куй, каләмеңнең ботын озын ит, юл арасын ачык ит, хәрефләрне бер-беренә янәшә куй, язучыларга бу лаек эштер», — диде.

Габдулла ибн әл-Могътәз әйтте: «Китап бер бакчадыр ки, язулары нәрҗисләредер, ягъни гөлләредер». Әбү Бәкер әл-Харәзмигә үлем авыруында әйттеләр: «Ни-нәрсәдән иштиһа кыйласың, нәфесең ни теләйдер?» — диделәр. Әйтте: «Китап йөзенә бер карар идем», — диде.

Мәнкульдер ки, Маэмүн хәлифәнең берничә углы бар иде. Беркөнне күрде: бер кечкенә углы бер китапны алган да актарып утырыр. Әйтте: «Әй углым, ул ни-нәрсәдер?» — диде. Уг-

---

[1] Әкълидис — Евклид.
[2] Һәндәсәдер — геометриядер.
[3] Аләт җисмания — физик корал.

лы әйтте: «Бу бер шундаен нәрсә икән ки, зирәкләрнең зиһенен шаяртыр, ялгызларга җан дусты булыр», — диде. Маэмүн хәлифә күңеленнән әйтте: әлхәмделиллаһ, Аллаһы Тәгалә миңа мондаен бер угыл рузый кыйлмыштыр ки, баш күзе белән күргәннән яхшырак гакыл күзе белән күрә, имеш, дип шөкер кыйлды.

Гарәпләр арасында начар язуны фәрештәләр язуы, диләр, чөнки фәрештәләрнең язуы бәян түгел, имеш. Язуның яхшырагы бәянырагыдыр вә ачыграгыдыр. Начар вә килешмәгән каләм ата вә анасын рәнҗетүче бала кебектер. Вә һәм богыз вә гадавәт итүче карендәш кебектер, димешләрдер. Әмма язганда ярты кәлимәне куйгач, каләмдә кара бетеп китсә, һәм кызыксыз буладыр. Бер рафизыйга[1] әйттеләр: «Гомердә нәсыб галәмәте ни-нәрсәдер?» — диделәр. Рафизый әйтте: «Галинең дошманлыгы», — диде.

Бер гарәпкә әйттеләр: «Син Исраилне һәмзәлимесең?[2]». Гарәп әйтте: «Әгәр һәмзәләсәм мин явыз кеше буламын», — диде. Бер гарәпкә әйттеләр: «Син фаэрәне һәмзәлисеңме?» — диделәр. Гарәп әйтте: «Мачы аны һәмзәлидер», — диде.

Имам Сибәвәйһ ишегенә беркөн берәү килде. Сибәвәйһ бер хезмәтчесен чыгарды: «Бар, әйт, ул кеше монсариф[3] булсын», — диде. Чыкты да әйтте: «Әй кеше, син монсариф бул!» — диде. Ул кеше әйтте: «Мин — Әхмәд исемлемен, Әхмәд монсариф булмайдыр», — диде. Хезмәтче янә Сибәвәйһ янына керде, шулай дип әйтә, диде. Сибәвәйһ әйтте: «Бар аңар чыгып әйт, Әхмәд монсариф булмайдыр мәгърифә булса, әмма билгесез булса, монсариф буладыр», — диде.

Бервакытны бер катиб язу яза, артыннан аны бер кеше карап моталяга кыйлып[4] тора. Бу язучыга унайсыз булды да, кәгазенә яза, әгәр артымда бу ахмак минем язганымны карап моталяга кыйлып тормаса, күңелемдә булган нәрсәне язар идем», — дип. Бу кеше арттан торып: «Юк, тәкъсыйр, валлаһи, моталяга кыйлмадым», — диде. Язучы әйтте: «Үзең инкяр кыйлган нәрсәне икърар кыйлдың», — диде.

Бервакыт ишек төбендәге сакчысы кереп Хәҗҗаҗга әйтте: «Ишек төбендә фәлән катиб бар», — диде. Хәҗҗаҗ янында ибн Карә бар иде, ул әйтте: «Йә әмир, катибләр алар усал булалар», — диде. Катиб керде, Хәҗҗаҗ аны икрам кыйлып хөрмәтләп чыгаргач, Хәҗҗаҗ әйтте: «Йә Ибн Карә, сохбәтең хакы булмаса, муеныңны ордырыр идем, Аллаһы Тәгалә катиблар хакында кирамән катибин[5] боермыштыр», — диде. Ибн Карә әйт-

---

[1] Рафизыйга — еретикка.
[2] Хәмзәлимесең — аеру билгесе куеп язасыңмы?
[3] Монсариф — узып китүче.
[4] Моталәга кыйлып — укып.
[5] Кирамән катибин — фәрештәләр.

те: «Әй әмирел-мөэминин, мин диван катибләрен әйтәмен, — диде, — мәлаикәррахманны, Алланың әмерен язучы фәрештәне әйтмәймен», — диде, Хәҗҗаҗ көлде дә гафу кыйлды.

Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Күк йөзен Аллаһы Тәгалә өч нәрсә белән зиннәтләде: кояш, ай, йолдызлар белән. Җир йөзен дәхи өч нәрсә белән зиннәтләде: гыйлеме белән гамәл кыйлгучы галим, хайванат вә җәмадатка[1] шифа биргүче ягъмур вә гадаләтле булгучы падишаһ», — диде. Янә пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Галимнәрнең язу яза торган карасы вә һәм шәһидләрнең каны кыямәт көнендә үлчәнер: катибләрнең карасы шәһидләрнең канына бәрабәр килер», — диде.

Гыйлем эстәмәктә бер иртә сәер итмәк, Аллаһы Тәгалә каршында йөз иртәдән сөеклерәктер. Бер кемсәнә таләбе гыйлем сәфәренә чыкса, һәр заман бер мөәккәл фәрештә бергә йөрер, оҗмах белән сөенеч бирер. Бер кемсәнә таләбе гыйлем вакытында вафат итсә, кыяметкәчә таләбе гыйлемдә булыр, каберендә фәрештәләр тәгълим бирерләр. Хәзрәти Гали димештер ки, кемнең гыйлеме азрак — кыйммәте һәм азрак. Дөньяның кыямы[2] дүрт нәрсә беләндер: галимнәрнең гыйлеме белән, падишаһларның гадаләте белән, әбдал изге, дәрвиш ирләрнең гыйбадәте белән, жумартларның сәхавәте белән, димештер. Вә дәхи һәрбер диннәрдә дүрт нәрсә макталадыр ки: гыйлемлек, заһидлек, изгелек, әманәт. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Гыйлем үгрәнеңез, гыйлем үгрәнмәк Аллаһы Тәгалә каршында изге эштер».

Мәсәлдә килмештер ки: кеше белмәгән нәрсәсенә дошмандыр. Ул нәрсәне үгрәнә башласа, белә башласа, дуслыгы артадыр вә рәгъбәте артадыр. Дәрес әйтмәк вә гыйлемдә бәхәс кыйлышмак дин юлында җиһад кыйлмак кебектер. Вә гайре кешегә гыйлем үгрәтмәк садакадыр. Гыйлем сәбәпле хәлялне харамнан аерып беләсен, гыйлем оҗмах юлын күрсәтәдер. Курку вакытында вә кайгы-хәсрәт вакытында юаныч буладыр, ялгыз вакытта әңгәмәдәш буладыр, сиңа шатлык юлын ачадыр, михнәт юлын баглыйдыр. Дусларыңнан гыйлемең сәбәпле хөрмәт күрәсең. Дошманнарың янында белем бер коралдыр. Гыйлемлек сәбәпле изгеләр дәрәҗәсенә ирешәсең. Олугларга таныш буласың. Аллаһы Тәгаләне таныйсың, шәригатьне беләсең, яхшы ашыйсың, яхшы, нәфис кием киясең — болар бар да гыйлем аркасында. Гыйлем әһеленең кигәне нәфис, пакь булып, гыйбадәтенең мәкъбульлегенә сәбәптер.

Галимнәргә иярсән жефәк кием киярсен,
Наданнарга иярсәң, көрән чикмән киярсең, —

дип, ни өчен әйткәннәрдер?!

---

[1] Җәмадатка — минералларга.
[2] Кыямы — аякта торуы.

Бер кемсәнә вафат булып, үзеннән соң язган китаплары, каләме, кара савыты бер гыйлем әһеленә мирас булып калса, аңа оҗмах белән сөенеч бирелер. Гыйлемлек — бер дәрьядыр. Фәлсәфә — бер диңгездер. Галимнәр тирәсендә йөриләр вә хәкимнәр диңгез уртасында йөзәләр. Әгәр берәүгә гыйлем үгрәтергә теләсәң, әүвәл үзеңне үгрәт. Изге гадәтләреңне тот, таки гайреләр күреп тәгълим алсыннар. Кеше гыйлем сәбәпле ничә бәладән котыладыр. Вә гыйлем сәбәпле хатыннар талактан котыладыр.

Мәзбәд дигән бер кеше үзенең хатынын күрде: биек баскычтан югары менеп барыр. Хатынына кычкырды: «Әй хатын, югары менсәң, сиңа миннән талак; урынында туктап торсаң — талак, төшсәң дә талак», — диде. Хатыны бу сүзне ишеткәч тә үзен-үзе җиргә атты. Аннан соң ире әйтте: «Йә хатын, атам-анам сиңа фида булсын, әгәр имам Малик вафат булса, шәһәр халкы синең гыйлемеңә мохтаҗ булырлар иде», — диде. Имам Малик заманы иде. Бәс, бу хатын үзенең гыйлеме сәбәпле, талактан котылды. Кешенең гыйлеме булса, әдәбе һәм булсын. Әдәп гакылга бирелгән нәрсәдер. Гакыл өстенә әдәп нур галә нурдыр. Олуглык гакыл вә әдәп беләндер, әмма нәсел вә нәсәб белән түгелдер.

Локман хәкимнән сорадылар: «Син бу кадәр әдәпне кемнән үгрәндең?» — диделәр. Локман әйтте: «Наданнарның әдәпсезлегеннән вә наданлыгыннан гыйбрәт алдым, сакландым, әдәпкә үгрәндем», — диде. Гакылның кадере әдәп белән, байлыкның кадере җумартлык белән, куәтнең кадере бәһадирлык белән, димешләрдер.

*Ахмаклык—наданлык.* Мәгаз бин Җәбәл разыйаллаһу ганһүдан риваять кыйлынмыштыр ки, пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Галим кеше наданлыктан качканнан артыграк, гыйлем үзе наданнан качар. Комсызлык авыруына дәва юк, наданлык сырхавына табиб юк», — диделәр. Гакыйльгә сүз — куәт, җаһилгә — җавап, сөкүт. Әристу хәким әйтте: «Гакыллы гакыллыга муафәкать кыйладыр, надан наданга муафәкать кыйлмайдыр, галимгә дә муафәкать кыйлмайдыр. Моның мисалы шулдыр ки, төз агач төз агачка чат ята, кәкре агач төз агачка да, кәкре агачка да ятмайдыр».

Әфләтун хәким әйтте: «Өч кешенең хәленә күңелем бик зәхмәт чикте: байдан фәкыйрь булган кешенең хәленә; олуглыктан хурлыкка төшкән кешенең хәленә; вә дәхи наданнар сохбәтенә мөбтәля булган галимнең хәленә», — диде. Әристу хәким әйтте: «Надан үзенә-үзе дошмандыр, гайрегә кайчан дус булсын», — диде. Надан фәсад кыйладыр, зирә төзеклеккә һидаяте юк. Ахмак фәсад кыйладыр, әмма фәсад кыйлудан ләззәт табадыр, хәтта эшнең төзек булмакына хафа буладыр.

Мәслимә бин Габделмәлик берәүдән сорады: «Син ни исем-

ле?» — диде. Ул кеше әйтте: «Мин Габдулла атлы», — диде, далның өсте белән. «Кем углысың?» — диде. Ул кеше әйтте: «Бин Габдерахмани», — диде, нунның асты белән. «Ник ялгыш әйтәсең?» — дип, Мәслимә бу кешене сукмага әмер итте. Янә ул кеше камчы астына ятканда, «бисмиллаһи» диде, мимнең өтере белән. Мәслимә әйтте: «Тимәңез, куеңыз, камчы астында да төзәлмәде», — диде.

Ибн Сәмәк әйтте: «Адәмнең гакыллырагы үзе изгелек кыйла торып хәвеф итәр, вә наданрагы үзе явызлык кыйла торып имин булыр». Зөннун әл-Мисри әйтте: «Берәү үзенең кадерен үзе белмәсә, үзен оятка калдырды», — диде.

Габдулла бин Габбас янында бер кеше бик күп хата сөйләде. Бәс, Габдулла үзенең колларыннан бер колны чакырды да азат кыйлды. Ул кеше әйтте: «Гаҗәп, бу колны азат кыйлмакыңа сәбәп ни булды?» — диде. Габдулла әйтте: «Аллаһы Тәгалә мине синең кебек надан итмәгән дип күңелемә килде дә, шөкер итеп, азат кыйлдым», — диде. Сократ хәким әйтте: «Кешенең хатасын төзәтә күрмә, чөнки ул синнән гыйлем дә алыр, сине дошман да тотар», — диде. Бу бик хак сүздер. Әгәр дә наданнар сөкүт кыйлган булсалар иде, каршы торулар вакыйг булмас иде. Берәү бер кешегә әйтте: «Фәһемләгәнеңне ник әйтмәйсең?» Ул кеше әйтте: «Син әйткәнне ник фәһемләмәйсең?» — диде. Җәлалетдин әд-Дәвани әйтте: «Әгәр галимнәр вә язучылар, мосаннифлар үзләреннән соң ихтилафат күп буласын белсәләр иде, китапларын үзләре белән бергә кабергә күмәргә васыять итәрләр иде. Бәлки, күкрәкләрендәген дә изһар кыйлмаслар иде, таки наданнарның кулы уйнамасын, дип», — диде.

Әгъмәшнең мәҗлесенә берничә кеше хәдис тыңламага килделәр. Әгъмәш әйтте: «Бу көн ни көндер?» Аларның берсе әйтте: «Әсниндер», — диде. Әгъмәш әйтте: «Әснан, дип әйт. Бар, кайтып торыңыз, сүзләреңезне әгърабланыз,[1] аннан соң хәдис тыңламага килеңез», — диде.

Имам Сибәвәйһ әүвәл мәртәбәдә фикъһе вә хәдис гыйлемнәре белән мөсахәбәт кыйлыр иде вә алардан фикъһе вә хәдис гыйлемен үгрәнер иде. Беркөн имам Хәммад алдында хата сөйләде. Хәммад аның сүзен яратмады, нәхү[2] белмәй, имеш. Аннан соң Сибәвәйһ имам Хәлилнең дәресенә мөлязим булып, хәтта нәхү гыйлемендә голямалык дәрәҗәсенә иреште.

Бервакытны бер имам намазга соңга калды. «Йә хәзрәт, ник соңга калдың?» — диделәр. Имам әйтте: «Корьән төзәтеп соңга калдым, «сафа-сафа», «дәка-дәка» дип кат-кат язганнар, кыра-кыра җаным чыкты», — диде.

---

[1] Әгърабланыз — гарәпчәләштерегез.
[2] Нәхү — синтаксис.

Бер кеше Ибраһим патшага килеп: «Бу кич төшемдә Аллаһы Тәгаләне күрдем, сезнең өчен дога әйтәдер иде», — диде. Ибраһим әйтте: «Аллаһы Тәгалә дога кыйлса, аны кем кабул итсә кирәк», — дип, ул кешене җәзага тартылды. Наданлык кешене яхшы итмидер. Инде бу кадәр ахмаклар хикәятеннән бер нәрсә хисса фәһем итәргә тиеш. Кирәк, гыйльме шәригатьме, кирәк, гыйльме сәнгатьме булсын. Җиренә житкереп гамәл кыйлмак кирәк. Гыйбадәт кыйлсаң вә дога укысаң, кәма һүә[1] хәрефләрен житкереп гамәл кыйлмак тиеш. Дөнья мөгамәләсендә, мәсәлән, син арба ясасаң яки гайре нәрсә ясасаң, житәр-житмәс аннан-моннан эшлә, көн саен бер жирен төзәтерсең, зәхмәт чигәрсең. Йә чөе төшеп, яки көпчәге чыгып калыр. Намаз укысаң, шулай ук кыйраәтне, рәкагатен сәждәләрен вә һәм рөкуг вә сәждә тәсбихләрен вә дәхи каумә вә жәлсәне ригая кыйлып, намаз шартларында әйтелгән рәвешчә шартларын кәма һүә шартына вә хәрефенә житкереп кыйлмак кирәк. Гыйлем белән гамәл кыйлу дип шуны әйтерләр. Син үзең фәһем итеп кара: дөнья мөгамәләндә бик пөхтә кыйласың лабаса! Мәсәлән, көндез кибетеңдә сәүдә кыйласың, кич булгач, нәрсәләреңне жыештырасың, аннан соң кибетеннән чыгасың, кибет ишегенне яхшылап ябасың, йозак белән кибетеңне биклисең, йозак белән бикләгәч тә, яхшы бикләнде микән, дип, йозагынны тартып карыйсың. Бу намаз дигәнемез вә гайре гыйбадәтләр Ходай кушкан фарыз эшләрдер, бу хосуста мең мәртәбә пөхтә булырга тиеш. Бу заманның намаз укытучыларын күрсәң, кайсының каумәсе юк, кайсының рөкугысы юк, кайсының жәлсәсе юк, кайсының сәждәсе жирдән тавык тары чукыган кебек. Кайсысы имамыннан мөкаддәм йөри — намазны шулай укырга ярамый.

Углым, ахмаклар вә наданнар хакында күп сүзләр ишеттең. Инде саклан, ул жөмләдән булма, ахмаклык вә наданлык шәригатьтә дә, гакыл үлчәмендә дә яман холыклардыр.

Ахмак ниндәен кешедер, мина тәгъриф кыйлсана, дип, берәү бер кешедән сорады. Ул кеше әйтте: «Ахмак шул кешедер ки, эшнең ахырын карамас; үз белгәненнән кайтмас; кешенең киңәшенә ышанмас; белмәгәнен беләмен дип белер; үгрәнмәк эстәмәс; үгрәтсәң, ачигъланыр; белгән кешегә дә, белмәгән кешегә дә серен сөйләр; мәжлес әдәпләрен ригая кыйлмас; белсә-белмәсә дә, һәркемнең сүзенә катышыр; кеше сөйләп бетергәнчә тыңлап тормас; үзенең мәгънәсез сүзе белән гайре кешенең сүзен бүләр», — диде.

Гали разыйаллаһу ганһу әйтте: «Аз гына ахмаклыгы булмаган һичкем юктыр. Адәм нәүгы[2] ахмаклыгы белән тереклек

---

[1] Кәма һүә — шулай ук.
[2] Нәүгы — биредә: заты.

кыйладыр», — диде. Адәмдә тугыз өлеш гакыл булса, бер өлеш ахмаклыкка мохтаҗдыр, таки адәм өлешчә ахмаклык сәбәпле үзенең эшенә керешсен. Вәһәб бин Мәнбә әйтте: «Адәм угланнары ахмак яратылдылар. Әгәр ахмаклылыклары булмаса иде, тереклекләре сеңешле булмас иде. Ягъни әгәр ахмаклыклары булмаса, тереклекләреннән ләззәт алмаслар иде», — диде. Ахмак белән мәҗлес кыйлмак хәтәрдер вә аның мәҗлесеннән качмак зафәрдер[1].

Берәү бер су янына килде, кулында китаплары бар иде. Су якасына утырды, бер китабы кулыннан суга төшеп китте. Кулын сузып карады, җитмәде. Янә кулындагы китап белән тартып китермәкче булды, ул китабы һәм суга төште.

Имам Шәфыйг әйтте: «Һәрбер галим вә фәкыйһкә бер ахмактан башка чара юктыр. Таки аның ахмаклыгына галиб булып, каршы торып ахмаклыкдан сакланыр өчен», — диде.

*Гафләт.* Әбү Габдеррахманга бер кеше әйтте: «Йә Әбү Габдеррахман, мина акыллы киңәш кыйлсана», — диде. Әбү Габдеррахман әйтте: «Саклан, гафләт вакытында Аллаһы Тәгалә шелтә кыйлмасын, ягъни искәртмәстән әҗәл килеп бәреп ташламасын, сакланып тор», — диде. Гафләт вә гафиллек алдату вә җебегәнлек мәгънәсендәдер. Бу һәм гакыл ияләре каршында яманатлы сыйфаттыр.

Хыянәтсез хәйлә вә куәтне урынына күрә истигъмаль кыйла белмәк — гафләткә бәйле сыйфаттыр. Бер вакыйга булгач кына хәйләгә тотынмак гакыллы кешенең эше түгелдер. Ләкин гакыйль шулдыр, алдан сакланып, ул вакыйгага төшмәскә хәйләсен карар, моны чарасын табу, диләр. Әгәр сиңа бер эшәке эш вакыйг булса, кара: әгәр хәйлә булса, гаҗиз булма, әгәр хәйлә белән дә мөмкин түгел икән, үртәнмә, илермә.

Захак бин Мөзахим бер яһүдигә әйтте: «Мөселман булмайсыңмы?» — диде. Яһүди әйтте: «Исламга минем мәхәббәтем бар, әмма минем хәмер эчәргә дәхи мәхәббәтем бар, исламда хәмер харамдыр», — диде. Захак әйтте: «Мөселман бул, эч син хәмереңне», — диде. Бәс, яһүди мөселман булды. Захак әйтте: «Инде мөселман булдың, әгәр хәмер эчсәң, сине җәзалап сугармыз, әгәр яңадан яһүдилеккә кайтсаң, үтерермез», — диде. Яһүди әйтте: «Мина сәламәтлек кирәк, мөселманлыктан чыкмам, хәмер эчмәм», — дип, хәмердән һәм тәүбә кыйлды. Димешләрдер ки, бәгъзе вакытта хәйлә куәт урынына йөридер, бәлки, куәттән һәм яхшырактыр. Хәйлә тау кисәр, диделәр.

Берәү бер кешегә бирәчәген инкяр кыйлды. Казый Әяс бин Мөгавия алдында хөкемгә тырыштылар. Казый Әяс дәгъвачы гаепләүчегә әйтте: «Син ул акчаны аңа кай җирдә биргән идең?» Ул кеше әйтте: «Фәлән җирдә, фәлән агач астында биргән идем».

---

[1] Зафәрдер — җинүдер.

Әяс әйтте: «Гуаһым юк дип әйтәсең, бар, имеш, ләбаса! Бар, шул агачтан гуаһлык алып кил!» — дип, мәддәгыйне җибәрде. Мөнкир казый янында утырып калды. Казый икенче эш белән мәшгуль икән, шул арада мөнкиргә хитап кыйлып әйтте: «Йә фәлән, син ничек уйлыйсың, ул кеше шул агач янына барып җитте микән?» — диде. Мөнкир әйтте: «Барып җитмәгәндер», — диде. Казый әйтте: «Һи Аллаһының дошманы, хыянәт синдә икән! Әгәр ул агач астында алмаган булсаң, кайсы агач, ул агачны мин белмәймен, дип әйтер иден», — диде. Бәс, ул мөнкир икърар кыйлды. Әяс моны бер хөсне тәдбир вә хәйлә белән икърар кыйлдырды. Бу хикәят «Кабуснамә»дә тәфсиллерәк язылмыш иде.

Мәсәлдә килмештер ки, мөэмин бик туктагучыдыр, алдакчы бик сикергүчедер. Ягъни мөэмин һәр хосуста бик сабыр кыйлыр вә алдакчы ашыгып ашка төшәр. Берәү сабыр вә акрынлык белән эш кыйлса, теләгән нәрсәсенә ирешер димәктер.

Адәм галәйһиссәлам балаларына әйтте: «Ни гамәл кыйлырга теләсәңез дә, берәр сәгать сабыр кыйлыңыз, әгәр мин бер генә сәгать тәвәкъкыф[1] кыйлган булсам иде, минем башыма килгән эшләр килмәс иде», — диде.

Димешләрдер ки, бик ялкынлана торган утның сүнүе дә бик тиздер, эшеңдә ашыкма. Гарәпләр әйтемеедер: лазем булсын сезләргә, ашыгудан сакланмак, зирәки гарәпләр ашыгуны «үкенечләрнең анасы» дип исем кыйлмышлардыр. Һәр үкенеч ашыгудан туадыр. Мәгәр дүрт хосуста ашыктырмага боермышлардыр ки: мәетне дәфен кыйлмакта, кыз бирмәктә, кунакны хөрмәт итмәктә, җәнабәттән госел итмәктә.

*Габавәт.* Безнеңчә, аңгыралык тәгъбир кыйлыныр. Сизгерлек вә зирәклекнең киресеедер. Бу — фәһемсезлек вә аңгыралыкта яман сыйфаттыр. Ләкин Аллаһы Тәгалә берәүнең табигатендә җитезлекне вә зирәклекне яратмаган булса, сатып алыр хәл юк.

Бер үзен-үзе җыя алмаган аңгыра кызны кияүгә бирделәр. Кияү кыз янына кергәч, күрде: кызның кулы камырлы, тырнак төпләре бар да камыр. Кияве пакьлекне ярата торган адәм, имеш. Кызның кулын юдырырга бер хәйлә табып: «Абау, эчем авырта», — дип угалана башлады. Кыз, хафа булып: «Ай-һай, ни дару итәек?» — дигәч, егет әйтте: «Эчем авыртканда, әнкәй кулын юып эчерсә, шифа таба торган идем», — диде. Аннан соң кыз: «Тукта, мин һәм шулай итеп караем, бәлки, шифа булмас микән», — дип, бер табакка су салып кулын юды, суны егеткә бирде. Егет күрде: кулындагы камырлар һаман бетмәгән, имеш. Әнкәй ике кат юдыра торган иде дип, янә бер кат юдырды. Бераз торгач: «Аллага шөкер, инде эчем авыртуы ба-

[1] Тәвәкъкыф — тукталыш, туктау.

сылды, ул суыңны чыгарып түк», — диде. Кыз дәхи ул суны чыгарып түкте. Хәйлә белән юдырганын фәһем итмәде.

Бер егет өйләнеп кыз атына баргач, егеткә аш пешереп китерделәр. Кыз барды да иң әүвәл ашны кабып карады. Кайнар, имеш, авызы пеште. «Һай, безнең әнкәй һәркайчан ашны суытып китерә», — диде. Егет дәхи, мин дә кабып караем, дип барды да, салкын аш капкан кебек алып, кисәктән кабып йотты. Авызы пеште, тамагы пеште, бик күңелсез булды. Кыз һәм хафаланып тышка чыгып керде. Егет әйтте: «Тышта һава ничек?» — диде. Кыз әйтте: «Тыштагы һаваны сорасаң, авызы пешкән егет кебек», — диде. Чөнки һава болытлы вә томанлы иде.

### *«Фәвакиһел җөләса»дан хикәятләр*

Җалинус хәким әйтте: «Тупас вә пәс дәрәҗәдә булган бер адәмнең углы әдип вә галим булса, атасының барча гаепләре мәстүр булып, халык арасында кадере артыр. Вә әгәр бер нәселе вә нәсәбе затлы адәмнең углы надан вә биәдәп булса, атасының шәрәфенә вә фазылына ноксан ирешер», — диде.

———

Гавамен настан ике мөтәдәййин адәм тагать вә гыйбадәт бабында мөкяләмә кыйлышып утырганда, сүзләре истинҗа хосусында вакыйг булып, берсе әйтте: «Йә фәлән ага, син истинҗа кыйлганда истинҗа җирең пакьләнгәнен кайдан беләсең?» — диде. Ул кеше әйтте: «Мин комганыма су тутырып чыгамын, беткәнче коямын, аннан соң пакьләнде дип беләмен», — диде. Иптәше әйтте: «Йә фәлән ага, синең эшең хата булмаса ярар иде», — диде. Ул кеше әйтте: «Алайса, син кайдан беләсең пакьләнгәнен?» — диде. Ул иптәше әйтте: «Мин шыкырдагыйнча ышкып-ышкып юамын, аннан соң инде пакьләнде дип шөбһәм калмайдыр», — диде. Ахыр боларның сүзе низагка китеп, бу кечкенә мәсьәлә түгелдер, бер галимнән сораек дип, үзләренең карьясендә бер галим янына бардылар, мәсьәләләрен гарыз кыйлдылар. Ул галим әйтте: «Бәли, шулай кирәк, шул мәгъкульдер», — диде, ягъни шыкырдагыйнча ышкып югач, пакь булыр, шөбһә калмас, димәкне ирадә кыйлды.

———

Вә дәхи Әсмәгый хикәят кыйлмыштыр ки: «Бервакытны Басрага бармага чыктык, бәни Әсгад елгасы янында туктадык, күрдек ки: бер гарәп хатыны йоклап ятыр, намаз вакыты китте, тор, дип уяттык. Торды, су янына килде, мәгәр су бик салкын иде, таһарәт алмады, кыйблага каршы торды, намазга кереште, тәкбир тәхримә кыйлды. Без әйттек: «Йә хатын, бу ниндәен намаз син укыдың?» — дидек. Хатын әйтте: «Минем бу намазым, әлбәттә, кырык көнге намаздыр», — диде.

———

Берәү бер кешене күрде, хәзиран аенда Ягус дигән елга янына килеп суга керде, суга чума да калка, чума да калка, чумган саен бер төен бәйли. Әйттеләр, бу ни эшендер, диделәр. Ул кеше әйтте: «Кыш көнендә берничә мәртәбә җөнеб булып госел лазем булган иде, шул госелнең казасын бу җәй көнендә эда кыйламын», — диде.

———

Бер гарәп бер кавемгә имам булып сурәи Фатихәне бик фәсахәт вә хуш аваз белән укыды. Бервакытны мәгъруф Хәҗҗаҗ ибн әл-Мәсиб янында намаз укыды. Ибн әл-Мәсиб күрде, Хәҗҗаҗ имамдан мөкаддәм башын күтәрер вә имамдан мөкаддәм рөкугга вә сәҗдәгә барыр. Намаз укып, дога кыйлып тәмам булгач, ибн әл-Мәсиб башмагын кулына алды, Хәҗҗаҗ янына барды да: «Йә сарык, йә хаин, башмак белән башыңны ярырмын, син ниндәен намаз укыйсың?» — диде...

———

Бер гарәп бер кавемгә имам булып сурәи Фатихәгә Әлкаригат сурәсен кушты, «фа өммәһү һавия» диясе урында, «фа өммәһмү зания» диде. Һәммә халык намазларын бозып, моны кыйный башладылар. Ул әйтте: «Тимәнез, моңа яһүдиләр сәбәпле, мине ни өчен кыйныйсыз?» — диде.

———

Бер кеше иртә намазында бер кавемгә имам булды. Фатихәдән соң Изашшәмсе күрт... сурәсен «Фаиннә тәзһәбүн»гә чаклы укыды, тукталды, Фаиннә тәзһәбүн, дип күп тәкрар кыйлды, хәтта кояш чыгарга якын булды, берәү дә фәтех кыйлгучы булмады. Җәмәгать эченнән берсе торды, капчыгын күтәрде дә, мин өемә барамын, әмма бу калтәбаннар кайда бара торганнардыр, дип чыгып китте, ягъни мин белмәймен, димәктер.

———

Берәү бер намазда бер кавемгә имам булып сурәи Фатихәгә Иннә әрсәлна Нуха сурәсен кушты, мәгәр Иннә әрсәлна нуха дигәч тә тукталды, бик озак торды. Имам артында бер гарәп бар иде, торды да әйтте: «Нух бармаса, башка кешене җибәр, безне моннан коткар», — диде.

———

Һади биллаһ хәлифә бер иртә намазында имам булып җәмагать белән намаз кыйлды, сурәи Фатихәгә Гаммә ятәсаулүн сурәсен кушты, дигән сүзгә җиткәч тукталды, хәтереннән чыкты, «мәһада-мәһада» дип ничә мәртәбә кайтарды, фәтәх кыйлмага берәү дә җөрьәт итмәде, чөнки Һади биллаһ хәлифә гаять мәһабәтле адәм иде. Үзе һәм моны, ягъни халыкның җөрьәт итмәгәнен белеп әйтте: «Ә Ләйсә минкүм рәжлү рәшид», — диде, аннан соң берәү фәтәх кыйлды, бу аның мөнакыйбеннәндер.

———

Бер мөтәкәббир кемсәнәгә әйттеләр: «Йә фәлән, син ник бер дә җәмәгать намазына бармайсың?», — диделәр. Ул кеше әйтте: «Бәккальләр, вак-төяк халыклар миңа мөзахәмә кыйлырлар дип куркамын», — диде.

Бер гарәп намазны бик җиңел, аннан-моннан укып тәмам кыйлды. Хәзрәти Гомәр күреп торыр иде, намазны тәхфиф кыйлдың дип, дәрә суктырды[1]. Гарәп намазны кайтарды, әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, әүвәлгесе яхшы булдымы, соңгысымы?» — диде. Гомәр разыйаллаһу ганһу әйтте: «Бәлки, әүвәлгесе яхшырак иде, чөнки әүвәлгесен Аллаһы өчен укыдың, соңгысын дәрәдән куркып укыдың, моннан соңгылары яхшы булыр», — диде.

———

Берәү бер имамнан сорады: «Йә хәзрәт, фәлән адәм рөкугда тәсбихларын ни арада әйтеп өлгерә, бик тиз сәҗдәгә китә?» — диде. Имам әйтте: «Ул рөкугда тәсбихны бер генә мәртәбә әйтә торгандыр», — диде. Яннарында өченче кеше бар иде: «Юк, тәкъсыйр, ул кеше рөкугда бары чеп-чеп-чеп дип кенә тора», — диде.

———

Берәү бер галимнән сорады: «Йә тәкъсыйр, «сәб зим» дигән сүзнең ни мәгънәсе бар?» — диде. Ул галим көлде дә: «Сәб зим»нең мәгънәсен мин белмимен, ләкин сәб сүку зим перакәндә вә мөтәфәррикъ мәгънәсендә дип бер лөгать китабында күргән идем», — диде. Ул кеше әйтте: «Мин берәүне ишеттем, рөкугда «сәб зим», «сәб зим», «сәб зим» дип әйтте, алайса, аның намазы дөрес булырмы?» — диде. Ул галим әйтте: «Әгәр дә шулай дисә, дөрес булмас шул», — диде. Янә берәү бер галимнән сорады: «Намаз укыганда бер адәмне күрдем, имам рөкугдан калкып житкәнче, ул сәҗдәгә барып житә, аның намазы дөрес булырмы?» — диде. Ул галим әйтте: «Имамга икътиданы ният иткән булса, дөрес булмас шул», — диде.

———

Берәү бер имамга әйтте: «Бервакытны мин намаз укыганда, алдымда бер кеше бар иде, рөкугдан калкып кыска гына каумә кыйлды да, бөтен гәүдәсе белән берьюлы төшеп, сәҗдәгә барды, тун итәге белән башымдагы чалмамны төшерде», — диде. Имам әйтте: «Алай булса ул Мөхтәсәр викаядән сыйфатессалат фасылын укыганда дәрестә йоклап калгандыр, — диде, — намазны вәкар вә сәкинә[2] белән бер дә ашыкмаенча укырга тиеш», — диде. Ул кеше әйтте: «Артындагы кеше аңар рәнҗидер ләбаса, ул намазның савабы булырмы?» — диде. Имам әйтте: «Аны

---

[1] Дәрә суктырды — кабатларга кушты.
[2] Вәкар вә сәкинә — горурлык һәм күңел тынычлыгы.

Аллаһы Тәгалә белер, ләкин намазда түгел, башка вакытта да кешегә иза бирмәк мәнһи[1] эштер», — диде.

---

Берәү бер галимгә әйтте: «Мин бервакытны намаз укыганда янымда бер кеше бар иде, һәрни укыса, бик пышылдап укыды», — диде. Галим әйтте: «Ул кеше алай булса укыганымны кеше ишетсен дип, рияланып укыгандыр», — диде. Ул кеше әйтте: «Ул теләсә ни ният белән укысын, әмма мин намазымны ялгышып беттем», — диде.

---

Берәү бер кешедән сорады: «Мин намазга төрле мәсҗеткә йөреп карадым, һәркайчан халык уңга-сулга сәлам биргәч тә, бик тиз мәсҗеттән йөгерешеп чыгалар, әллә мәсҗеттә бәйләп куялар дип куркалар микән?» — диде. Ул кеше әйтте: «Син ишеткәнең юкмы, әл-мәсҗиду сиҗнүл — мәнафыйк[2], зинданда кемнең торасы килсен», — диде.

---

Бәдәви гарәплəрдән бер гарәп, хаҗилар хаждан кайтканда, бер хаҗи белән бәйләнеп, низаглашып торган заманда, бәгъзе кемсәнәләр ул гарәпкә гыйтаб кыйлып[3] вә орышып әйттеләр: «Әй гарәп, хаҗиларны хөрмәтләмәк вә экрам кыйлмак тиеш иде вә догаларын алмак тиеш иде, әмма син аларны рәнҗетәсең вә кычкырышасың», — диделәр. Бу бәдәви гарәп аларга җавабын хитап кыйлып, бер шагыйрьнең шигырен укыды ки, ул шигырь ошбудыр: Аллаһы Тәгалә гөнаһларны мәгъфирәт кыйлсын өмиде белән хаҗ Шәрифкә барылыр икән, бу адәм мәгъфирәт түгел, гөнаһ ясап кайтты мәгънәсендәдер.

---

Хаҗ сәфәрендә күп мәшәкать күргән бер адәмнән әхвәлен сорашканда, бу хаҗи әфәнде һәрбер күргән мәшәкатен сөйләп, хосусән ул тарафның тимер юл хезмәтчеләре вә ут көймәсенең хезмәтчеләре хакында, аларның йөзе бер рус чаклы юк, димеш.

---

Бер кеше хаҗ кыйлып кайтты, вә карендәшләре күрешмәгә килделәр. Берсе әйтте: «Йә фәлән, хаҗ кыйлдың, хаҗәре әсвәдне үптеңме?» — диде. Ул хаҗи әфәнде әйтте: «Үбүен үпмәдем, әмма күрдем, бик картайган, имеш, Мәдинәдә хөрмә сатып утырыр иде», — диде.

---

Икътибас тарикынча, Коръәннән сөйләшкән бер хатынның хикәяседе́р. Габдулла бин Мөбарәк хәзрәтләре риваять кыйл-

[1] Мәнһи — тыелган.
[2] Әл-мәсҗиду сиҗнүл — мәнафыйк — мәчет икейөзлеләр өчен төрмәдер.
[3] Гыйтаб кыйлып — шелтәләп.

мыштыр ки: көннәрдән бер көн Кәгъбәтуллага зыярәт кыйлмак нияте белән юлга чыгып сәфәр кыйлган заманымда бер юл үзәрендә фәсахаи[1] гарәптән өстенә йоннан бер дөррәгә кимеш вә бөркәнчек белән йөзен өртмеш бер хатынга очрашып сәлам бирдем. Бу хатын Коръәннән икътибас кыйлды. Белдем ки: минем сәламемне кайтармак морад итте. Аннан соң, монда ни эшләрсең, дидем. Белдем ки, юл адашмыштыр. Аннан соң янә әйттем, йә хатын, кайда бармага чыкмыш идеңез, дидем. Белдем ки: Мәккәдән чыгып Кодескә бара, имеш. Күптәнме монда адашып калдыңыз, дидем. Фәһем иттем ки, бу җирдә өч көннән бирле торыр, имеш. Йә хатын, үзең белән тәгамың, бер нәрсәң дә юк, ни белән ризыкландың, дидем.

Белдем ки, тәвәккәл үзрә, имеш. Таһарәт алырга су кайдан аласың соң, дидем. Белдем ки, тәяммим[2] белән намаз кыйлыр, имеш. Тәгам бирәемме, ашармысың, дидем. Белдем ки, руза тотар, имеш. Хәзер дә Рамазан ае түгелдер, дидем. Нафилә руза тотар, имеш, дип белдем дә, сәфәрдә руза тотмаслык мөбахтыр[3], дидем. Белдем ки, мөбах булса да, тотмак әүладыр димәкне теләде. Аннан соң ни өчен минем кебек адәм сүзе белән сөйләшмәйсең, Коръәннән икътибас кыйласың, дидем. Мала ягънине[4] сөйләмәймен димәкне ирадә кыйлды. Йә хатын, син кайсы шәһәрдәнсең, дидем. Белдем ки, шәһәремне сорама дип тәгъриз кыйлды. Мин дәхи гафу өстәп, гаеп итмә, хатамны гафу кыйл, дидем. Гафу кыйлдым димәкне белдерде. Янә әйттем, йә хатын, сине үземнең тәвәмә утыртып, кафиләгә ирештерәемме, дидем. Ризалык изһар кыйлды. Аннан соң тәвәмне чүктердем, боерыңыз, утырыңыз, дидем. Миңа карама, йөземне күрмә димәкне тәнбиһ кыйлды. Аннан соң күземне йомдым, тәвәгә утырганда тәвә кузгалып, бераз киеме ертылды, галә әлфур, диде, ягъни гөнаһ шомлыгым булды димәкне изһар кыйлды, тәвәнең тезгенен бир, дип ишарәт кыйлды. Бераз сабыр ит, тезгенен бәйләем, дидем. Морадыны фәһем иткән өчен тәхсин мәгънәсен белдерде. Инде тәвәгә тәмам яхшылап утыр, дидем.

Әлхәмделиллаһ, шөкер, диде. Мин дәхи тәвәнең тезгененнән тотып, «ну!» дип кычкырып йөгертебрәк бара башлаган идем, кычкырма, акрынрак бар, димәкне белдерде. Аннан соң мин дәхи акрынлап шигырь әйтмәгә башладым. Мала, ягъни булган шигырьне көйләмә, дип нәһи иткәненнән соң, мин дәхи вәгазеңне кабул иттем димәкне белдердем. Вәгазене тотканыма тәхсин кыйлды. Акрынлап барганда янә сорадым, зәүҗеңез бармы, дидем. Сораганымны яратмады. Аннан соң мин һәм

---

[1] Фәсахаи — матур һәм дөрес итеп сөйләшүчеләр.
[2] Тәяммим — су булмаганда чиста туфрак яки ком белән таһарәт алу.
[3] Мөбахтыр — тыелмаган эштер.
[4] Мала ягънине — мәгънәсез сүзне.

кафиләгә җиткүнчә һич сүз сөйләмәй бардым. Кафиләгә җиткәч, йә хатын, кәрванда зат вә әсбапларыңыз бармыдыр, дидем. Белдем ки: кафилә эчендә балалары бар, имеш. Балаларыңыз бу кәрванда ни хезмәттәдер, аларны мин ни галәмәт белән табаем вә балаларың ни исемлеләрдер, дидем. Белдем ки: балалары кафилә кулагузлары[1], имеш, вә дәхи бер углы Ибраһим, бер углы Муса, бер углы Яхъя исемлеләр, имеш. Бәс, эзләп чатырларын таптым вә хатынның ишарәте үзрә йә Ибраһим, йә Муса, йә Яхъя дип нида кыйлдым. «Ләббәйкә» дип кәрван эченнән өч егет чыкты, аналарын үз чатырларына китерделәр. Хатын, аять укып, балаларына дирһәм биреп, тәгам алмага җибәрде. Бер углы барып тәгам китерде, алдыма куйды. Хатын әйтте, тәнавел кыйлмага тәклиф вә әкрам кыйлды[2]. Мин дәхи угланнарына хитап кыйлып әйттем: «Йә егетләр, вәлидәңезнең хәлен бәян кыйлмай торып, тәгамыңызны капмасмын», — дип вакыйганы сораштым. Әйттеләр: «Бу вәлидәмезнең хәле кырык елдан бирле, бәлки, сүземдә хатасы вакыйг булып, Аллаһы Тәгалә газабына грифтар булырмын дип куркып, Коръән сүзеннән гайре сүз сөйләмәс», — дип җавап бирделәр.

———

Риваять кыйлмышлардыр ки: беркөн Гайшә разыйаллаһу ганһа хәзрәтләренә ике кулы да корымыш бер хатын килде вә әйтте ки: «Йә Гайшә, минем атам гаять җумартлык белән мотасыйф булганына күрә, даим фәкыйрь-фокарага садака бирмәкне сәвәр иде, вә анам саранлык белән моттасыйфә булганлыктан, асла садака бирмәкне сәүмәс иде, бөтен гомере эчендә фәкыйрьгә биргәне бары бер кисәк май вә бер иске кием иде. Бер кичне төшемдә күрдем: гүяки кыямәт купмыш, барча мәхшәр әһле гарасат мәйданында ялангач вә кояш эсселегеннән сусаганнары хәлдә хәйран вә сәргәрдан торырлар. Шул вакыт анамны күрдем ки: үзенең садака биргән иске киемен гаүрәт җиренә өретеп вә садака биргән маен ялап, хәрарәтне дифаг кыйлмага[3] газап чигәр. Аннан соң җумарт булгучы атамны күрдем ки: бер олуг чишмә янында торып, адәмнәргә су өләшер, анамның хәленә зиядә шәфкатемнән наши[4] атамнан бер касә су алып анама эчергән заманымда тәхкыйк аңа кем эчерер исә, Аллаһы Тәгалә аның ике кулын корытсын, дип, бер нида ишеттем, куркуымнан уянып китсәм, ике кулым корымыш күрдем», — диде.

———

Бер хатын кич белән тәгам ашап утырганда, ишегенә бер саил[5] килеп туктады. Ул рәхимле хатын ул садакачыга бер

---

[1] Кулагузлары — юл күрсәтүчеләре.
[2] Тәклиф вә әкрам кыйлды — боерды һәм юмартлап әйтте.
[3] Хәрарәтне дифаг кыйлмага — эсселекне бетерергә.
[4] Шәфкатемнән наши — шәфкатем аркасында.
[5] Саил — сораучы.

локмә тәгам бирде, садакачы ул тәгамны ашап, азрак тамагын туйдырып китте. Вә бу хатын иртә торып ире белән игенлекләренә барып, балаларын бер җиргә куеп, игеннәрен урмага башладылар. Ул арада бер ач бүре килеп, бер баласын күтәреп китте. Хатын бу вакыйганы күргәч, Аллаһы Тәгаләдән гайре ярдәмче юклыгын белеп: «Йа Рабби, балам харап булды!» — дип, фөрьяд кыйлып егълады. Нагяһ бер мәҗһүл[1] адәм зоһур итеп баланы һич зарарсыз бүре авызыннан алып: «Кичә саил авызына каптырган локмәңнең мөкабиле[2] бу локмәдер, ал!» — дип, хатын кулына тапшырды.

———

Рәбигъ бин Хисмәдән риваять кыйлынмыштыр ки: беркөн мәзкүр Хисмә бик суык вә ягъмурлы кичәдә башына кәрбастан башлык киеп, йортыннан чыгып, юлда барган вакытта бер саилгә очрап, башлыгын ул фәкыйрьгә бирде.

Аять укыбрак мөгътәнәм булды. Аятьнең мәгънәсе: әй бәндәләрем, сезләр Аллаһы Тәгаләнең ризалыгына вә рәхмәтенә васыйл булмассыз, мәгәр каршыңызда мәхбүб вә сөекле нәрсәңезне Аллаһы Тәгалә юлына нәфәкаләндермәенчә, димәктер.

———

Казый Бәйзави бу аятьнең тәфсирендә китермештер ки: бу аять назил булгач, сәхабәләрдән Әбү Талхә разыйаллаһу ганһу пәйгамбәр галәйһиссәламнең хозурына килеп: «Йә Рәсүлуллаһ, зиядә мәхәббәтле булган малларым — тәвәләремдер», — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам Әбү Талхәне мәдех вә тәхсин[3] итеп: «Бәрәкаллаһ, якыннарыңа вә фәкыйрьләргә сарыф ит», — дип әмер кыйлды.

———

Зәид бин Харисә хәзрәти Рәсүл хозурына бер ат китереп: «Йә Рәсүлулла, зиядә мәхәббәтле булган малым ошбудыр, мохтаҗларга сарыф кыйлсаңыз ла», — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам атны тотты да Зәиднең углы Өсамәгә бирде. Зәид әйтте: «Йә Рәсүлулла, минем морадым садака итмәкеңез иде, углымга бирдеңез», — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Углың Өсамә атны садака итеп кабул итте, морадың хасыйл булды», — диде.

———

Бер кемсәнә углын сәүдә өчен бер ерак шәһәргә күндереп, озак заманнар углының исәнме, үлгәнме, һичбер хәбәрен белмәде. Беркөн углымның сәламәтлеге өчен дип, бер фәкыйрьгә ике икмәк садака биреп, углына дога өстәде. Тәмам бер елдан соң углы күп файда хасыйл итеп, сәламәт кайтып килде. Атасы

---

[1] Мәҗһүл — билгесез.
[2] Мөкабиле — тиңдәше.
[3] Мәдех вә тәхсин — мактау.

әйтте: «Әй углым, сәламәт йөрдеңме, бәла вә каза күрмәдеңме?» — дип, хәл-әхвәл сорашканнан соң, углы әйтте: «Әлхәмделиллаһ, әй ата, диңгез сәфәрендә идек, беркөн гаять каты җил булып, көймәмез вә һәммә халкы суга гарык булды, мин дәхи, инде гарык буламын, дип, җанымнан өмид кисеп торганда, ике егет пәйда булып, мине корыга чыгарып ташладылар вә әйттеләр ки, атаңа сөйлә, монда хәлас булмакыңның сәбәбе атаңның фәкыйрьгә биргән ике икмәгедер, дип хәбәр бирделәр», — диде.

---

Бер заһид бер мәгарәдә асла мәгъсыять вә гөнаһ эшләмәенчә, җитмеш ел Аллаһы Тәгаләгә тагать вә гыйбадәт кыйлып ятыр икән. Бер кичәдә бер гүзәл хатын мәгарәгә килеп, мине мәгараңә керт, дип, габидтән риҗа итте, ләкин габид илтифат итмәде, һаман гыйбадәте белән мәшгуль булды. Ахыр ул хатын китеп барганда, заһид хатынның артыннан карап күрде: дәрхаль бичара заһидның күңеле хатынга мәел кыйлып, гыйшкына мөбтәля булды, ахыр гыйбадәтен ташлап, кайда китәсең, дип, хатынның артыннан китте. Хатын дәхи, истигъна кыйлып, теләсәм кайда китәрмен, диде. Заһид дәхи морад иде — мөрид булды, азат иде — кол булды.

Бәс, заһид морадын хасыйл итмәкне касд кыйлып, ул хатынны мең гозер нияз белән мәгарәсенә алып керде, җиде көн микъдары хәлвәт кыйлып, шәһвәтен симертте. Аннан соң тәүфыйк вә инсафка кайтып, җитмеш еллык гыйбадәтен җиде көнлек мәгъсыятькә алыштырганына үкенеп, Аллаһы Тәгаләгә тәүбә кыйлды, һушы китеп егылганчы күзләреннән яшь агызып еглады. Һушына килгәннән соң хатын, ул заһидка хитап итеп, бу гамәл фахишәне вә мәгъсыятьне синнән гайре кеше белән кыйлып та, бу кадәр гыйкабка мөстәхак булмаган идем, син дәхи бу зинаны миннән гайре белән кыйлмаганлыгың йөзеңнең сафлыгында заһирдыр, әлгәргечә Аллаһы Тәгаләгә гыйбадәтеңне төзәтсәң, мине дә зикер кыйл, минем өчен Аллаһы Тәгаләдән мәгъфирәт өстә, дип исәнләшеп китте. Ул бичара заһид сахраларда хәйран вә сәргәрдан булып, ач вә сусап, гаҗәба, кай җирдә кич үткәрсәм икән, дип йөргәндә, ун нәфәр[1] күзсез фәкыйрьләр мәкаменә тугыры килеп, алар янына керде. Ул күзсезләрнең ашарга нәрсәләре юк, имеш, якыннарында бер раһиб бар иде, аларга һәркөн ун данә кечерәк икмәк күндерер иде. Беркөн гадәте үзрә ул раһиб хезмәтчесе аркылы боларга ун икмәк җибәрде. Бу гасый заһид бичара, гаять ачлыгыннан бер икмәкләрен алды, ул күзсезләр икмәкне өләштеләр, бере икмәксез калды; ул икмәк китергән хезмәтчедән, кайда, мин өлешсез калдым, ни ашармын дип, егъламага башлады. Ул заһид моның егълаганын ишетеп, бакчы, кеше хакын алдым дип егъ-

---

[1] Нәфәр — кеше.

лап, ул икмәкне күзсезгә тапшырды. Ул кич ач ятты вә ачлыгыннан һәлак дәрәҗәсенә ирешкәндә, Аллаһы Тәгалә үлем фәрештәсенә әмер кыйлды, мәләкелмәүт дәхи Аллаһы Тәгаләнең әмере буенча бу заһидның җанын аласы булды. Ул арада, рәхмәт фәрештәсе килеп, мәләкелмәүт белән мөхасамә[1] кыйлышып, рәхмәт фәрештәсе әйтте, бу бер кешедер ки, гөнаһыннан качып Аллаһы Тәгаләгә тәүбә истигъфар кыйлды дип дәгъва кыйлды, вә газап фәрештәсе дәхи, бу бер гөнаһлы бәндәдер ки, житмеш еллык гыйбадәтен җиде көнлек мәгъсыятькә сатты дип дәгъва иттеләр. Бу дәгъвада торганда Аллаһы Тәгалә боларга, житмеш еллык гыйбадәт белән җиде көнлек мәгъсыятьне үлчәп караңыз, дип вәхи кыйлды. Аллаһының әмеренчә үлчәп карадылар, мәгъсыять авыр килде. Янә Аллаһы Тәгалә боерды. Ул заһидның мәгъсыяте белән үзен һәлаклеккә салып күзсезгә биргән икмәкнең савабын үлчәделәр, икмәкнең савабы авыр килде. Бәс, Аллаһы Тәгалә ул заһидның тәүбәсен кабул иткәч, рәхмәт фәрештәләре, әтрафын ихата кыйлып, тәгъзыйм вә тәкрим белән җанын алдылар.

———

Көннәрдә бер көн бер кеше үзенең җәмәгате белән утырып, кәбаб тавык ашаганда, бер садакачы килеп ишек какты, Аллаһы өчен, дип, садака сорады. Мәзкүр кеше бу садакачыны орышып-кырып, буш кайтарып җибәрде. Ахыр тиз заманда бу кешенең кулындагы дәүләте китеп, симез тавыклары очып бетте. Фәкыйрь халь булып калды вә, җәмәгатенең нәфәкасенә гаҗизлектән, хатынын талак кыйлып, саилчелеккә керește. Вә хатыны икенче бер адәмгә никяхланып, иттифакан ул икенче ире белән беркөн кәзалик тавык кәбабы ашап утырганда, бер садакачы ишек кагып, садака сорады. Бу кеше хатынына әмер кыйлды, тавык итеннән бер микъдар ул садакачыга чыгарып бирде. Хатын садаканы биргәндә, ул кеше үзенең әүвәлге ире икәнен таныды, кызганып егълап, ире янына керде. «Ник егъладың?» — дип, ире сорады. Хатын әйтте: «Ул садакачы минем элгәреге ирем, имеш. Шул рәвешчә бервакытны тавык ашап утырганда, бер садакачы килеп, аңа садака бирмәенчә буш кайтарып җибәргән иде, хәзердә садакага йөри, имеш, үз дип, хәлемезгә сөенеп егъладым», — диде. Ире уйлап торды да: «Ул вакытта сезгә килгән садакачы мин идем, әлхәмделиллаһ», — диде.

———

Имам Фазыйлдан риваять кыйлынмыштыр ки: ирле-хатынлы бер кеше бар иде, хатыны җеп эрләп, ире аны базарга чыгарып сатар иде, акчасы белән ризыкланырлар иде. Көннәрдә бер көн ире җепне базарга илтеп, бер дирһәмгә[2] сатты. Кайтып

[1] Мөхасамә — бирелә: бәхәс.
[2] Дирһәмгә — борынгы көмеш тәңкәгә.

килгәндә күрде: ике кеше низаглашып торырлар. «Ник кычкырышасыз?» — дип сорады. Алар әйттеләр: «Бер дирһәм өчен низагымыз бардыр, безгә хаким бул», — диделәр. Бу кеше әйтте: «Сезгә хаким кирәк түгел, низагыңыз бер дирһәм өчен, имеш, алыңыз», — дип, бер дирһәмне аларга биреп низагларын кисте.

Өенә кайтты, хатынына вакыйганы сөйләде. Хатыны әйтте: «Бәрәкаллаһ, муафыйк эш кыйлырсың», — диде. Икенче көндә дәхи бу кеше җеп алып базарга барганда, бер балык сатучы очрады, җеп белән алыштырып, бер балык алды. Өенә кайтты. Хатыны балыкны пешерергә дип эчен пакьләде, күрде, балык эченнән бер данә энҗе чыкты. Аны саррафка илтеп, йөз егерме мең дирһәмгә сатты. Шул вакыт бу кешегә бер саил килде, садака сорады. Бу кеше дәрхаль ул саил белән ул дирһәмнәрне уртаклашты, ягъни йөз егерме мең дирһәмнең яртысын ул саилгә биреп җибәрде. Күп заман кичмәде, бер сурәте хәсәнә үзрә берәү заһир булып: «Әй фәлән, мин Алланың илчесемен, бәшарәт китердем. Аллаһы Тәгалә сине фәкыйрьлеккә мөбтәля кыйлды, сине сабыр кыйлгучы күрде, сиңа шатлык бирде вә сине шөкер кыйлгучы күрде, бер дирһәмең бәрабәренә бу кадәр нигъмәт бирде», — дип гаиб булды.

---

Бер садакачы, йорт саен кереп, Коръән укып, садака сорап йөрер иде. Әйттеләр: «Оялмаймысың Коръән белән теләнчелек кыйлмага», — диделәр. Саил әйтте: «Тик торыңыз, әгәр дә сез минем кебек ачыксаңыз вә мохтаҗ булсаңыз, Коръән китерүче Җәбраил фәрештәне үзен сатар идеңез», — диде.

---

Бер адәм берәүгә язарга чынаяк бирде. Ул кеше чынаякка сату карасы белән, тимер каләм белән язды. Яздырган кеше, ул чынаякны җуып, истигъмаль кыйлды, чынаяктан караны китәрә алмады. Аннан соң, доганың файдасыннан да кичтем, кяшки чынаягым харап булды, дип шикаять кыйлмыш.

---

Казый Әяс дигән мәшһүр бер адәм гакыйлаи галәмнең олугларыннан булып, гакылы сәлим вә табгы мөстәкыйм белән ничә хакыйкать хәлне кәшеф итмеш иде. Ул мәзкүр Әяснең гакыл ражихына[1] дәлаләт кыйла торган вакыйгаларыннандыр ки, салах вә әманәтдарлык белән мәшһүр бер кемсәнә бар иде. Иттифакан хаҗ сәфәренә китәчәк бер кеше, үзе сәфәрдән кайтканчы сакламак өчен, ошбу әманәтдар адәмгә бер кесә алтын әманәт куеп, сәфәргә китте. Вә хаҗны әда кыйлып кайткач, мәзкүр кешедән үзенең әманәт куйган алтыннарын барып сорады. Ул кеше тәҗаһел[2] кыйлып инкарь тарикына барды. Бу

---

[1] Гакыл ражихына — зур акыл иясенә.
[2] Тәҗаһел кыйлып — наданлык.

кешенең дәгъва исбат кыйлырдай гуаһлары юклык сәбәпле, бичара, хәйран булып, казый Әяснын хозурына килеп, вакыйганы сөйләде. Казый Әяс әйтте: «Бу вакыйганы башка кешегә сөйләдеңме?» — диде. Ул кеше әйтте: «Юк, сездән гайрегә сөйләгәнем юк», — диде. Бәс, казый Әяс әйтте: «Бар, син бу көн өеңә кайт, ләкин бу вакыйганы берәүгә дә сөйләмә, янә иртәгә монда кил», — дип җибәрде. Бу киткәч, ул залимны чакыртып, әгъзаз, вә әкрам, вә йомшаклык белән, гүяки мөхәррәм әсрар итеп, хәйлә тарикынча: «Әй ага, син әманәтдар кеше икәнең мәшһүрдер, сиңа сер итеп әйтәмен ки, миндә үземә караган күп мал хасыйл булды, сиңа әманәт куймага раэем[1] белән мәслихәт кыйлдым, миңа кирәк вакыткача үзеңдә бер имин урынында әманәт итеп сакла», — диде.

Ул кеше әманәт сакларга урынын хәзерли торсын, әмма казый мәзкүр бичара әманәт иясен янә чакыртып әйтте: «Инде ул кешедән әманәтеңне сора. Янә инкяр кыйлса, казый Әяс алдына хөкемгә бараек дип чакыр», — диде. Бәс, бу әманәт иясе дәрхаль ул мөнкирнең[2] ханәсенә барып, казый үгрәткән тарикча әманәтен сорады. Ул мөнкир, янә үзенең тамгыннан наши мәзкүр казый, сиңа әманәт куямын, дип, вәгъдә кыйлган акчаны эләктермәк сәүдәсе белән: «Казый бу вакыйганы белмәсен», — дип сакланып, әманәт иясен риза кыйлмак өчен дәрхаль алтыннарын чыгарып тапшырды вә йомшаклык белән: «Инде бу вакыйганы кешегә сөйләмә, мәзах кыйлган идем, бу эш арамызда бетсен», — дип игътизар кыйлды. Ул хаҗи, үзенең өмид өзгән малын кайтарып алгач, тугыры казый Әяс хозурына килеп хәбәр бирде, күп дога вә сәна кыйлды. Ул мөнкирнең хыянәте заһир булганнан соң, казый аны үзенең хозурына китертеп тәгъзир кыйлды вә, Аллаһы Тәгалә синең кебек явызларны дөньядан алгай, дип бәддога кыйлды.

---

Беркөн солтан Мөхәммәдхан үзенең нәдимнәреннән булган мөнәҗҗим башы Әхмәд Мәүләвигә боерды: «Ниятемдә булган хосус өчен гыйльме нөҗүм үзә заирчә тәхрир кыйлып карачы», — диде. Әхмәд Мәүләви дәхи дәрхаль сәгатькә карап, солтан Мөхәммәд хозурында куеныннан бер кәгазь чыгарып, бер тәхрир вә дәляләт нөҗүмиясене тәкърир иткәннән соң[3], ул мөхәррир кәгазьне янә куенына салганда, солтан Мөхәммәд: «Ул тәхриреңне миңа бирче», — диде. Әхмәд Мәүләви һаман ул кәгазьне солтан кулына бирде, мәгәр ул кәгазьнең бер ягында Әхмәд Мәүләвинең мәсрафенә тотылган хәраҗаты[4] язылып,

---

[1] Раэем — фикерем, карашым.
[2] Мөнкирнең — ышанмаучының.
[3] Тәкърир иткәннән соң — сөйләгәннән соң, аңлатканнан соң.
[4] Хәраҗаты — чыгымнары.

кемгә күпме бирәчәге бар, аны язылыр дәфтәре, имеш, ашыкканлыгыннан карамаенча, үзенең мәсраф дәфтәренә язмыш, имеш. Бәс, ул дәфтәргә солтан Мөхәммәднең күзе төшеп, ниндәен кәгазь икәнен фәһемләгәч, мәшвәрәт кыйлынмыш кемсәнәнең зиһенендә дәйн, ягъни бурыч фикере булса, аннан раэе саиб[1] өмид ителмәс, дип, дәрхаль Әхмәд Мәүләви әфәндегә ашамак, эчмәк, акча вә әнвагы малдан ихсан кыйлмага фәрман боерып, Мәүләви әфәндене шат итмештер.

---

Хикәят кыйлынмыштыр ки: Мәдинәи Мөнәввәрә әһеленнән бер адәм хикәят кыйлмыштыр ки: «Бервакытны бурычым күбәеп, бурыч ияләре мозаяка кыйлганның[2] бәгъдендә, дөнья башыма зиндан вә бәла йорты булып ни эшләргә белмәенчәрәк, ышанычлы вә мөрәүвәт иясе бер дустым белән мәшвәрәт кыйлдым. Ул заманда Гыйракта җәвәд вә сәха[3] иясе Мәһләб дигән вали бар иде, аңа барып хәлемне бәян кыйлмага мәшвәрәт итте ки. Гыйрак бик ерак, анда мин бара алмамын, дип, башка бер дустыма киңәш иттем. Ул дәхи һаман шул мәшвәрәтне биреп, мин һәм мәшвәрәтне кабул итмәк мөхаләфәттән хәерледер, дип, тәвәмә атландым, бәгъзе юлдашлар белән Гыйрак сәфәренә тәвәҗҗеһ кыйлдым[4] вә, Мәһләб хозурына барып, гадәтчә тәгъзыйм вә дога вә сәнадән соң гарызымны бәян кыйлып, мин фәкыйреңез Мәдинәи мөнәвәрәдән бер фәкыйрь бурычлы кешемен, бурычым күплегенә гаҗиз булып, бәгъзе дусларым белән мәшвәрәт кыйлганымнан соң, сахибе мөрәүвәт булгучы җәнабыңызга хаҗәтемне гарыз итмәгә мәслихәт кыйлдылар. Шул сәбәпле җәнабыңызга килдем, мөрәүвәт сезнеңдер, дип, телем белән хәлемне гарыз кыйлганнан соң, Мәһләб әйтте: «Синең белән минем карабәт вә өлфәтем[5] вә синең дәхи безгә хезмәтең юктыр» — диде. Мин дәхи бәли, юктыр, ләкин сеннән хаҗәт өстәмәгә сине әһел күрдем, әгәр хаҗәтемне әда кыйлсаң, син аңа әһелсең, әгәр дә кәефеңезгә тугыры килмәенчә, хаҗәтемне әда кыйлмасаң, ошбу көндә үпкәм юк. Иртәгә булса һәм өмидемне өзмәймен, ягъни җумарт син, бу көн булмаса иртәгә булса һәм хуп, дидем. Мәһләб һаман капучыларына әмер итте: «Барыңыз, хәзинәмдә һәрни тапсаңыз, бу адәмгә игъта[6] кыйлыңыз», — диде. Хәзинәсенә бәрабәр бардык. Хәзинәдә сиксән мең дирһәм бар, имеш, миңа бирделәр. Аннан соң мин дәхи бу кадәр җумартлыкны, бу кадәр малны күргәч, кә-

---

[1] Раэе саиб — дөрес фикер.
[2] Мозаяка кыйлганның — кырыс рәвештә таләп итүнең.
[3] Җәвәд вә сәха — затлы, юмарт.
[4] Тәвәҗҗеһ кыйлдым — ... гә юнәлдем.
[5] Карабәт вә өлфәтем — якынлык һәм дуслыгым.
[6] Игъта — бүләк.

маль шатлыгымнан үлә яздым, янә аннан мине Мәһләб хозурына китерделәр. Мәһләб әйтте: «Әй адәм, хаҗәтеңне әда кыйлырлык кадәр нәрсә хасыйл булдымы?» — диде. Мин дәхи тәшәккер теле белән: «Әй җумартлык мәгъдәне булгучы әмир мөкәррәм[1], дәфгы зарурәт[2] итәчәк кадәр түгел, аннан да артыграк булды», — дидем. Мәһләб әйтте: «Яхшы, алайса сәгыйең бушка китмәде, мәшвәрәтеннең җимешләрен җыйдың», — диде. Аннан соң Мәһләбнең хозурында каимән хәмед вә сәна укып[3], Мөтәшәккирән Мәдинәгә кайтып, бурычларымны әда кыйлдым вә әһел әүладыма бәхшишләр вә мәшвәрәт кыйлганнарга һәдия белән икрам кыйлдым. Моннан соң барча эшемдә киңәшсез эш кыйлмадым», — дип хикәят кыйлмыштыр.

———

Әбү Сәгыйд Хәззаз әйтте: «Беркөн Бәйтуллаһта бер фәкыйрьгә раст килдем, өстендә гаурәт гализасын сәтер кыйла торган[4] пәрдәсеннән башка нәрсә юк иде, нәфесем аннан бу хәленә бинаән нәфрәт итте. Мәзкүр фәкыйрь дәрхаль минем нәфрәтемне тәфәррәс итеп, аять укыды. Мин дәхи, нәфрәт иткәнемә үкенеп, истигъфар кыйлдым».

———

Җабир бин Габдулладан риваять кыйлынмыштыр ки: бәни Исраилдән бер кеше үзенең саумәгасында гыйбадәт кыйлыр иде. Яз көне рәхмәт ягъмурлары явып, җирдән нәбатат вә үләннәр үскәч, үзенең аты утлап йөргәндә әйтте, әй Раббым, синең һәм атларың булса иде, минем атым белән бергә утлап йөрсә иде, дип, Аллаһы Тәгаләгә мөнәҗәт кыйлды. Ошбу Аллаһы Тәгаләнең шанына лаек булмаган нәрсә белән мөнәҗәт кыйлганын шул заманның пәйгамбәренә хәбәр бирделәр, вә ул пәйгамбәр бу кешене лаексыз дога кыйлган өчен, таганә кыйлмага теләгәч, Аллаһы Тәгалә аңа вәхи кыйлды ки: «Ул бәндәм озак заман үз саумәгасында үзенең микъдарынча миңа мөнәҗәт кыйлыр, мин бәндәләремне гакыллары кадәренчә җәза вә һәр кешенең ихласы кадәренчә мөкяфәт[5] бирермен, тимә», — диде.

———

Пәйгамбәр галәйһиссәламнән бер кемсәнә сорады: «Йә Рәсүлаллаһ, кайсы гамәл изгерәктер?» — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Аллаһы Тәгаләне белмәк изгерәктер», —

---

[1] Мөкәррәм — хөрмәтле.

[2] Дәфгы зарурәт — мәҗбүри түләү.

[3] Каимән хәмед вә сәна укып — басып торган килеш Аллаһыга хәмед (мактау) укып.

[4] Гаурәт гализасын сәтер кыйла торган — алдын-артын каплый торган.

[5] Мөкяфәт — бүләк, әҗер-савап.

дип, өч мәртәбә тәкрар кыйлды. Ул кеше әйтте: «Йә Рәсүлаллаһ, мин гамәлдән сорадым, син гыйлемнән хәбәр бирәйсен», — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Гыйлем белән сиңа аз гамәл һәм файда кыйлыр, надан булсаң, сиңа күп гамәл дә файда кыйлмас», — диде.

———

Көннәрдән бер көн Һалид бин Сафуан хәммамга[1] керде. Ишетте, берәү үзенең фәсахәт вә бәлягатен Халидкә белдерәсе килеп углына әйтте: «Йә Халид, хәзер дә бу сүзнең әһеле китте, ягъни хәзер дә бу фәсахәт белән сөйләгән кеше юк», — диде. Халид әйтте: «Бу сүзнең әһелен Аллаһы Тәгалә яратмады да», — диде.

———

Габдулла бин Габбас янында бер кеше бик күп хата сөйләде. Бәс, Габдулла үзенең колларыннан бер колны чакырды да азат кыйлды. Ул кеше әйтте: «Гаҗәп, бу колны азат кыйлмакына сәбәп ни булды?» — диде. Габдулла әйтте: «Аллаһы Тәгалә мине синең кебек надан итмәгән дип күңелемә килде дә, шөкер итеп азат кыйлдым», — диде.

———

Имам Сибәвәйһ әүвәл мәртәбәдә фөкаһа вә мөхәддисин белән мөсахәбәт кыйлыр иде вә алардан фәкыйһә вә хәдис гыйлемен үгрәнер иде. Беркөн имам Хәммад алдында хата сөйләде. Хәммад аның сүзен яратмады, нәхү белмәй, имеш. Аннан соң Сибәвәйһ имам Хәлилнең дәресенә мөлязим булып, хәтта нәхү гыйлемендә голямалык дәрәҗәсенә иреште.

———

Берәү ишетте ки, бер кеше Коръән укыды. Бу кеше әйтте: «Юк, алай түгел, ялгыш укыйсың», — диде. Ул кеше әйтте: «Һи, бар да бер, һәммәсе кыйтагыттарикъләрдыр[2]», — диде.

———

Бер кеше Ибраһим патшага килеп: «Бу кич төшемдә Аллаһы Тәгаләне күрдем, сезнең өчен дога әйтәдер иде», — диде. Ибраһим әйтте: «Аллаһы Тәгалә дога кыйлса, аны кем кабул итсә кирәк», — дип, ул кешене тәгъзир кыйлдырды.

———

Ибраһим бин Ясар димештер ки: «Ибраһим бин Әдһәмнән сөаль кыйлдым, бу сөлүк вә тәҗриденә[3] ни сәбәп булды, дидем.

[1] Хәммамга — мунчага.
[2] Кыйтагыттарикъләрдыр — юлбасарлардыр.
[3] Сөлүк вә тәҗриденә — бу яшәү рәвешенә һәм читләшүенә.

Сиңа бу сөаленне үзгәртмәк кирәк иде, дип җавап бирәсе килмәде, ләкин мин тәкрар сөаль кыйлып гозер иткәч әйтте: «Мин Хорасан падишаһларыннан бер падишаһ идем. Беркөн, ауга чыккан вакытымда бер аһуның[1] артыннан киттем. Шул вакыт артымнан, әй Ибраһим, мин сине моның өчен яратмадым, дип, бер нида килде. Бу ниданы ишеткәч, төкләрем торып, хәйран булып уңга-сулга карадым, берәүне дә күрмәдем, шайтан микән бу, дип, әгузе бисмиллаһ укып, атымны типтем. Янә икенче мәртәбә бу тавышны ияремнең кашы тарафыннан ишеттем, бу Аллаһы Тәгаләдән миңа нәзирдер[2], аңа гасый булмаем, дип, дәрхаль чатырыма кайттым. Тәхте рәгыятемдә булган хирасәт әһеленнән беренең киемен алып кидем, үземнең яхшы киемемне аңа кидердем. Аннан Шамга тугыры китеп, Тарсус шәһәренә життем, ризыгым өчен анда берәүнең бакчасына каравылга керештем, ләкин монда мәшһүр[3] булмагай идем, дип куркып качтым», — дип, сәбәбе сөлүкене бәян итмештер».

Бер кеше Хәсән Бәсри хәзрәтләренә әйтте: «Мин, Коръән ачып, бөтен көн Коръән укыймын», — диде. Ягъни эш вә кәсеп белән мәшгуль булмаймын димәкне морад итте. Хәсән Бәсри әйтте: «Сәхәрдә вә ахшамда Коръән укы, көндезләрдә ризыгың өчен һөнәр вә сәнәгать белән вә хаҗәтеңә зарур эшләр белән мәшгуль бул», — диде.

Дауд галәйһиссәлам бер башмакчының дөкяненнән узганда, башмакчының эшләп утырганын күреп, тәхсин кыйлып: «Әй кемсәнә, эшлә, аша, зирә Аллаһы Тәгалә кул көче белән ризыкланган кемсәнәдән разый булыр, эшләмәенчә ашаган кешедән разый булмас», — диде.

Бер ялкау кызны бер ялкау егеткә никях итеп бирделәр. Никяхтан соң, йомшак түшәкләр вә гайре җиһазлар хәзерләп кызны озатканда, атасы әйтте: «Ятыгыз кызым, рәхәтләнеңез, шик юктыр ки, фәкыйрьлектән гайре нәрсә тудыра алмассыз», — диде.

Бер бүзче Ибраһим әл-Хәзми хәзрәтләренә әйтте: «Йә әфәндем, бер кемсәнә гаед укып, аннан соң гаед хәлвәсе сатып алмаса, аңа ни лазем килер», — диде. Ибраһим хәзрәтләре әйтте: «Ике дирһәм садака лазем килер», — диде. Ул бүзче бу сүзне сорап киткәннән соң, Ибраһим хәзрәтләре көлде дә үзенең яран-

---

[1] Аһуның — киекнең.
[2] Нәзирдер — туры юлга күндерүчедер, кисәтүчедер.
[3] Мәшһүр — биредә: фаш.

нарына әйтте: «Ошбу ахмакның малыннан бер фәкыйрьне сәвендермәктән безгә ни зарар», — диде.

———

Әрдәшир падишаһ, начар вә игътибарсыз һөнәр әһеленең балалары никадәр һөнәрле вә мәгърифәтле булсалар да, нәдимлеккә кабул итмәс иде, диләр.

———

Хәзрәти Мәрьям разыйаллаһу ганһаның юлы бер бүз тукучы таифәсенә тугыры килеп, юл сорады, алар хәзрәти Мәрьямгә хилаф юлны күрсәттеләр. Хәзрәти Мәрьям, аларга рәнҗеп, Аллаһы Тәгалә кәсебеңездән бәрәкәтне күтәрсен, дип дога кыйлды. Шуңар күрә бүзчедә хәер юктыр, диделәр.

———

Мал күп җыймак белән мәшһүр бер адәмгә әйттеләр: «Бу кадәр мал җыеп, син ни эшләмәкче буласың?» — диделәр. Ул кеше әйтте: «Мин ошбу малны замананың инкыйлабыннан куркып вә яраннарның саранлыгыннан сыгынып, кайгымны китәрмәк өчен җыямын, — диде, — ягъни ошбу вакыйгалардан үземне сакламак мәслихәте өчен», — диде.

———

Бер кемсәнә нәкыль вә хикәя итмештер ки: «Мин беркөн Софьян хәзрәтләре белән бер сәфәрдә булдым. Юлда бер фәкыйрь саил Софьяннан лиллаһи бер нәрсә сорады. Софьян ул фәкыйрьгә бирергә нәрсәсе юклыгыннан егъламага башлады. Мин әйттем, йә әба Мөхәммәд, егъламагыңның сәбәбе нидер, дидем. Софьян әйтте: «Моннан олуг мосыйбәт[1] булырмы ки, синнән бер кемсәнә хәер сорасын, ул хәерне синдә тапмасын», — дип, малның мәдаре хәер[2] булмакын бәян кыйлды».

———

Бер сабый бала кояшлы көн бер җирдә йөргәндә, үзенең күләгәсене күреп, күләгәсе артыннан житмәкче булды. Күләгә артыннан җитәмен дип бара, ул барган саен, күләгә һаман алга китә. Бу баланың ачуы килеп, күләгәнең өстенә басарга теләп йөгерә башлады, ул йөгерсә, күләгә һәм йөгерә. Бала тәмам арыды. Әйләнеп, янә киткән урынына кайтып барганда, артына әйләнеп караса, күләгә артыннан ияреп килә. «Һи, мин юкка йөгердем, ул миннән үзе дә калмай икән», — диде. Дөнья эстәгүчеләр һәм шөйләдер.

———

Бәгъзе хәкимнәр углына васыять кыйлып: «Әй углым, дөньяда гыйлем хасыйл кыйлмага вә мал кәсеп итмәгә иҗтиһадыңны зиядә сарыф кыйл, чөнки халык ике фиркадыр ки: бере —

---

[1] Мосыйбәт — кайгы.
[2] Мәдаре хәер — хәер эшләрнең үзәге.

хавас вә бере — гавамдыр. Хавас фиркасеннән булган адәм сине гыйлемең вә кәмалең өчен тәкрим вә тәгъзыйм кыйлырлар», — димештер.

———

Кадим падишаһларыннан бер падишаһ бер су яныннан барганда күрде: бер карт судан сикереп чыкты. Аның белән дәхи бер яшь егет бар иде, су аркылы чыга алмаенча гаҗиз булып тик торыр. Бу падишаһ, моңар гаҗәпләнеп, бу карт белән егетне сөйләштереп карады, алар һәм хәлләрен бәян кыйлдылар. Карт кешенең янында мең алтыны бар, имеш, әмма егет фәкыйрь, имеш.

———

Хәсән Бәсри хәзрәтләре беркөн хәдис укыды. Мәҗлесендә бер кеше, байлар таифәсеннән түгел иде, әйтте: «Йә шәех, мин байлар таифәсеннәнме?» — диде. Хәсән әйтте: «Бу көн ашадыңмы?» Ул кеше әйтте: «Бәли, ашадым». Хәсән әйтте: «Янә кич ашарга тәгамың бармы?» Ул әйтте: «Бәли, бар». Хәсән әйтте: «Бу сурәттә син байлар таифәсеннәнсең», — диде.

———

Бер гарәп кулына бер динар тоткан да карап тора: «Ни гаҗәп, синең җөссәң[1] бу кадәр кечкенә, әмма һиммәтең бик зур», — диде. Әйттеләр: «Бәли, дөньяның эше өч түгәрәк нәрсә өстендә әйләнәдер: динар, дирһәм, рәгыйф[2]», — диделәр.

———

Ибраһим Әдһәмгә бер кеше әйтте: «Йә шәех, кабул ит, бу чапанымны сиңа һибә кыйлаем», — диде. Ибраһим әйтте: «Әгәр син бай кеше булсаң, кабул итәрмен». Ул кеше әйтте: «Әлхәмделиллаһ, мин бай кеше». Ибраһим әйтте: «Күпме акчаң бар?» Ул кеше әйтте: «Ике мең акчам бар». Янә Ибраһим әйтте: «Әгәр дүрт мең булса сөенер идеңме?» Ул кеше әйтте: «Бәли, сөенер идем». Ибраһим әйтте: «Юк, алайса, син һәнүз фәкыйрь икәнсең, чапаныңны кабул итмәймен», — диде.

———

Ибраһим Әдһәм әйтте: «Беркөн байлар мәҗлесендә булдым. Миннән кайгылырак кеше булмады, чөнки киемнәре минем киемемнән яхшырак, атлары минем атымнан яхшырак иде. Аннан мескиннәр мәҗлесенә бардым, миннән шат кеше булмады», — диде.

———

Берәү вафат булып, мирасыннан бер яхшы тунын бер фәкыйрь имамга җибәрделәр. Ул имам әйтте: «Вафат булганын ишетеп, бик кайгырган идем, тунын күргәч, сөендем тагы», — диде.

---

[1] Җөссән — гәүдән.
[2] Рәгыйф — икмәк.

---

Бер фәкыйрьнең йортына бер угры керде. Эзләп карады, йортта бернәрсә дә тапмады. Чыгып барадыр, йорт иясе әйтте: «Әй угры, чыксаң, ишекне бикләп чык», — диде. Угры әйтте: «Хәзинәңдә юк нәрсәңне угырлады дип, мине хезмәткә кушасыңмы?» — диде.

---

Бер фәкыйрь саил, үзенең бер кечкенә баласы белән барганда, күрде: бер хатын бер җеназа артыннан: «Әй хуҗам, сине ишексез, тәрәзәсез йортка алып баралар. Түшәге вә әсбабы юк йортка алып баралар. Вә тәгамы вә шәрабы юк йортка алып баралар», — дип, нәүхә кыйлып егълап барыр. Бу саилнең углы әйтте: «Әти, әти, безнең йортка алып баралар микән әллә?!» — диде.

---

Бер бай баласы бер ит кибетендә ит сатып алды, итчегә бирергә кесәсеннән акча капчыгын чыгарды, капчыгы тузган, имеш. Әйтте: «Үземне дә Аллаһы орды, капчыгымны да Аллаһы орган, имеш, иткә җитәрлек акчам да юк», — диде.

---

Ике фәрештә очрашып, бер береннән хәл-әхвәл сораштылар. Берсе әйтте: «Фәлән яһүдинең балык ашасы килә, имеш, диңгездән чыгарырга маэмүр булдым[1]», — диде. Икенчесе әйтте: «Фәлән габиднең зәйтүн мае ашасы килә, имеш, ул майны түгәргә маэмүр булдым», — диде.

---

Бер мәдайни әйтте: «Бер адәмне күрдем, Сафа белән Мәрвә арасында яхшы атка атланып таваф кыйлыр. Янә шул кешене берзаман сәфәрдә күрдем, җәяүләп барыр. Әйттем, әй фәлән, халык атка атланып барыр, син җәяү барасың, дидем. Ул кеше әйтте, мин атка атланып йөргәндә, халык җәяү иде, инде Аллаһы Тәгаләнең икътизаи хикмәтенә лаек булды ки, халык ат белән йөргәндә, мине җәяү йөртәдер, диде.»

---

Бер бүз тукучы Әгъмәшкә әйтте: «Бүз тукучы артында намаз укымак хакында ни әйтәсең?» — диде. Әгъмәш әйтте: «Таһарәтсез укыган кешегә зарар юктыр». Ул кеше янә әйтте: «Аның гуаһлыгы хакында ни әйтәсең?» Әгъмәш әйтте: «Гуаһлыгы мәкъбульдер, әгәр аның белән ике гадел булса», — диде.

---

Бераз атлы вә җәяүле кешеләр сәфәргә чыктылар. Юлда өсләренә бик каты җил вә давыл чыкты. Бик куркып: «Кыямәт, кыямәт», — дип кычкыра башладылар. Берсе әйтте: «Бәли, бәли, дөрес әйтәсез, атсыз кешеләргә кыямәт», — диде.

---

[1] Маэмүр булдым — мина эш кушылды.

---

Берзаман кыш гаять суык булып, бер бака әрләннән азык сорады: «Ашарыма юк, бераз ризыклык рәхим итсәнә?!» — диде. Әрлән әйтте: «Җәй көне көн буенча авыз күтәреп кычкырып тордың, ни эшләдең, ник кыш өчен азык хәзерләмәдең?!» — диде.

---

Ибн Сәбабә дигән кеше бервакытны юлда күрде: бер татар мөбарәк яхшы атка атланып барыр. Ибн Сәбабә башын һавага күтәрде дә әйтте: «Илаһи, йа Рабби, бу ишәкнең дә аты бар, мин адәммен, минем ишәгем дә юк», — диде.

---

Берәү күрде: бер кеше бер начар ишәккә атланып барыр. «Әй карендәш, кая барасың?» — диде. Ул кеше әйтте: «Җомга намазына барырга чыктым». Бу кеше әйтте: «Сөбханалла, бу көн сишәмбе көндер, белмәденме?» Ул кеше әйтте: «Ни сөенеч булыр иде миңа, әгәр дә бу ишәгем мине шимбә көн мәсҗеткә илтеп җиткерсә», — диде.

---

Имам Әбү Йосыф хәзрәтләре Һарун әр-Рәшит белән икесе ике атка атланып чыктылар, әмма имам Әбү Йосыф артка калды. Һарун әр-Рәшит әйтте: «Йә казый, арттан бармак миңа тиеш иде», — диде. Казый әйтте: «Йә хәлифә, синең атың кусаң оча, куйсаң — сәер кыйла, минем атым кусам — сөртенә, кыймылдасам, туктый, син мине көт», — диде.

---

Бер гарәп бер хатынны күрде: чикерткә ашар. Гарәп әйтте: «Сөбханаллаһи, гаҗәба, мин чикерткәнең игенне ашаганын күргәнем бар иде, әмма иген чикерткәне ашаганын күрмәдем», — диде.

---

Бер карчыга әтәчкә әйтте: «Дөньяда мин синнән вафасыз кешене күрмәдем. Синең җәмәгатең йомырка эченнән чыгып үсә, үзеңә якын килмәйләр. Килсәләр: «Анда кит, монда кит!» — дип сөрәсең. Мине таудан тотып алалар, күзләремне бәйлиләр, караңгы җиргә ябып ач тоталар. Шикяргә[1] җибәрәләр, кошны тотамын, алып кайтамын, хыянәтсез иямә тапшырамын», — диде. Әтәч әйтте: «Син бер карчыганы да тимерчыбыкта күргәнең юктыр, әмма мине ашханәләрдә тимерчыбыкта күрерсең», — диде.

---

Һишам бин Габделмәлик хәлифәлеккә җөлүс иткәч[2], хәлифәлек мөбарәк булсын, дип, халык җыелганда, Һишам шөкер

---

[1] Шикяргә — ауга.
[2] Җөлүс иткәч — утыргач.

сәҗдәсе кыйлды, вә янындагылар дәхи һәммәсе сәҗдә кыйлдылар, мәгәр Кәлби сәҗдә кыйлмады. Һишам әйтте: «Сине сәҗдә кыйлмактан ни-нәрсә мәнгы кыйлды, ягъни син ник сәҗдә кыйлмадың?», — диде. Кәлби әйтте: «Кичә көндез бу көн танда мин синең белән бергә идем, инде син күккә ашарсың, мин сине кайдан табармын?» — диде. Һишам әйтте: «Мин күккә ашсам, сине һәм калдырмамын», — диде. Кәлби әйтте: «Алай булса мин егерме мәртәбә сәҗдә кыйлырмын», — диде. Янә мәзкүр Һишам бервакытны чалмасын төзәтер иде, Кәлби торды да Һишамның чалмасын төзәтә башлады. Һишам әйтте: «Тимә, тимә, мин карендәшемне кол итмәймен», — диде. Янә бер кеше әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, безгә әмер кыйлмадыныз, без төзәтер идек», — диде. Һишам әйтте: «Мәҗлестәшләремә хезмәт иттермәк мөрәүвәт[1] түгелдер», — диде.

---

Фозаладан бер кемсәнәгә әйттеләр: «Йә фәлән, синең күпме дусларың бар?» — диделәр. Ул фазыйл әйтте: «Белмәймен, чөнки хәзердә икъбалем кәмальдәдер[2]. Вә дәүләтемнең арткан заманыдыр, малым, милкем күптер. Кайчан ки икъбалем кирегә китсә, шул вакытта ничә дустым бар икәнен белермен дә сезгә әйтермен», — диде.

---

Әсмәгый әйтте: «Бервакытны имам Хәлилгә кердем, бер кечкенә палас өстендә утырыр. Утыр, дип, миңа ишарәт кыйлды. Мин әйттем, үзеңә дә урының бик тар, дидем. Хәлил әйтте, ике дошман бөтен җир йөзенә сыймас, әмма ике дус бер карыш җиргә дә сыяр, диде».

---

Исхак әл-Мәусыйли дигән берәү бер дустының ханәсенә керде. Үзе өйдә юк иде, өендә бер җариясе бар иде. Мәусыйли ул җариягә әйтте: «Кайда, хуҗаңның акча капчыгын китерче монда», — диде. Җария китерде, Мәусыйли ике дирһәм алды да чыгып китте. Хуҗасы кайткач, җария моны хәбәр бирде. Хуҗасы әйтте: «Әгәр дә раст әйтсәң, бә ризаэ лиллаһи син миннән азат», — дип, ул җарияне азат кыйлды.

---

Көннәрдә бер көн бәгъзе адәмнәр Мөгайрәгә шикаять кыйлдылар ки: «Синең сакчыларың үзләренең дусларын синең дусларыңнан әлгәре кертәдер», — диделәр. Мөгайрә әйтте: «Танышлык этләргә дә вә хайваннарга да файда бирәдер, адәмгә кайчан файда бирмәс?!» — диде.

---

[1] Мөрәүвәт — яхшылык, егетлек.
[2] Икъбалем кәмальдәдер — бәхетем камилдер.

---

Хәзрәте Гомәр разыйаллаһу ганһу кулыннан бераү кателгә мөстәхак булган[1] кеше хәйлә вә хөсне тәдбир белән котылмыштыр. Кыйссасы будыр ки: Гомәр разыйаллаһу ганһу бервакыт Һөрмезне кател иттермәк теләде. Һөрмез бер хәйлә тәдбире белән эчмәк өчен, бер касә су сорады. Суны китерделәр, касә белән суны алды, эчәргә такате булмаган кебек, озак тотып торды. Һөрмез тотты да суны җиргә ыргытты: «Гаһедкә вафадыр, әй әмирел-мөэминин, бер нур баһирдыр», — диде. Гомәр разыйллаһу ганһу аңа да карамады, үтермәгә боерды. Һөрмез әйтте: «Син миңа әман бирмеш идең, янә кател булырмы?» — диде. Гомәр разыйаллаһу ганһу әйтте: «Ни кәйфияттә сиңа әман бирдем, әйт»! — диде. Һөрмез әйтте: «Диден, бу сүзендә ла баэс кәлимәсе әмандыр, гая кыйлганың шәриб иде, ул миннән вакыйг булмады», — диде. Аннан соң Гомәр разыйаллаһу ганһу әйтте: «Аллаһы Тәгалә лаекынны бирсен, мин белмәгәнем хәлдә миннән әман алдың», — диде.

---

Дауд галәйһиссәламнең заманында Бәйтелмөкаддәстә сахрәтулла кашында күктән асылынып тора торган бер зәнҗер[2] бар иде. Халык бер-бере белән дәгъвада хөкемгә торсалар, ул зәнҗер янына килеп, тарафыннан һәрбере кулларын зәнҗергә сузарлар иде. Һәркем сүзендә садыйк булса, зәнҗер ул кешенең кулына килер иде, әгәр ялган булса, югары тартылыр иде. Ахыр бу зәнҗер хосусында бер хәйлә вә хыянәт булып, ул зәнҗер күккә күтәрелмештер ки, бер кемсәнә бер кешегә әманәт бер җәүһәр куймыш иде. Ул әманәт алган кеше ул җәүһәрне бер таяк эченә куеп саклады. Берзаман иясе килеп, куйган әманәт җәүһәрен сораганда, ул кеше: «Мин әманәтеңне кайтарып бирдем», — диде. Вә ул кеше: «Мин алмадым», — дип, низаг кыйлышып гаделлек зәнҗере янына килделәр. Мөвәддәгъ, ягъни әманәт иясе: «Йа Рабби, сүземдә тугыры булсам, зәнҗерне миңа якын кыйл», — дип, дога кыйлып, зәнҗергә кулын сузды. Кулы зәнҗергә тиде. Аннан соң мөвәддәгъ, ягъни әманәт саклаган кеше мөнкир: «Таякны тотып тор», — дип, мөддәгый кулына бирде. «Йа Рабби, үзең белерсең ки, мин җәүһәрне иясенә тапшырдым. Бу сүземдә тугыры булсам, зәнҗергә кулым җитсен», — дип, кулын сузды. Кулы зәнҗергә җитте. Халык бу хәлне күреп: «Хәйфа ки гадел зәнҗере хак белән батыйльне бәрабәр кыйлды, хак белән ялган беленмәде, хаклык җуялды», — диделәр. Дәрхаль бу алдашуның сәбәбе белән, зәнҗер күздән гаиб булды. Вә зәнҗернең муәккат[3] хөкеме бетте.

---

[1] Мөстәхак — лаек.
[2] Зәнҗер — тимер чылбыр.
[3] Муәккат — вакытлы.

Аннан соң Дауд галәйһиссәлам халык арасында хөкем итмәк үзрә вәхи булып, шаһид вә ямин ул заманнан бирле мәшрут булмыштыр.

---

Хәзрәти Сөләйман галәйһиссәламгә бер кеше килеп: «Йә нәбиуллаһ, минем казымны күршеләремнән бер кеше алмыш. Әмма кем икәнен белмәдем», — дип шикаять кыйлды. Сөләйман галәйһиссәлам: «Халык мәсҗеткә җыелсын, бер мәслихәт бар», — дип нида иттерде. Халык мәсҗеткә җыелгач, Сөләйман галәйһиссәлам, минбәргә чыгып: «Әй адәмнәр, сезләрдән берегез күршесенең казын алып, каз мамыгы башына ябышып калган, имеш, ул хәл белән дәхи мәсҗетткә кермеш», — дип, тавыш бирде. Казны алган кеше халык арасында кулы белән башын сыпыра башлады. Сөләйман галәйһиссәлам әйтте: «Тотыгыз шул кешене», — диде. Тоттылар. Филхәкыйкать, тәфтиш бәгъдендә, казны алган кеше ул, имеш, мәгълүм булмыштыр.

---

Әбү Һөрәйрәдән риваять кыйлынмыштыр ки. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте, бәни Исраилдән ике хатынның үзләре белән бергә икесенең дә берәр ир балалары бар иде. Үзләре югында бер бүре килеп, ул ике баланың берсен күтәреп китте. Берзаман үзләре әйләнеп килсәләр, калдырган җирләрендә бер бала юк, калган бер баланы икесе дә, бу минем баламдыр, дип, Дауд галәйһиссәламгә хөкемгә тордылар. Дауд галәйһиссәлам ул калган бер баланы олуграк хатынга хөкем итте. Аннан соң бу ике хатын янә Сөләйман галәйһиссәламгә бардылар вә низагларын сөйләделәр, әмма берсенең дә дәлилләре юк иде. Сөләйман галәйһиссәлам әйтте, миңа бер пычак китерегез, бу баланы уртага кисеп, һәрберегезгә яртышар бала итеп бирәем, диде. Яшьрәк хатын әйтте, йә нәбиуллаһ, Аллаһы Тәгалә сиңа рәхмәт итсен, зинһар, алай итмә, гәрчә минем балам икәне хак булса да, баламнан кичтем, миңа тиясе яртысы да аңа булсын, диде. Бәс, Сөләйман галәйһиссәлам, ул хатынның сүзеннән, баласына шәфкать итмәкенә истидлал кыйлып[1], ул яшь хатынга хөкем итте.

---

Вә дәхи «Мөстәтраф»та мәзкүрдер ки, әл-Госманнан солтан Сөләйман хәзрәтләренең бер гаҗәп тәдбире булмыштыр. Шөйлә ки, аның заманында Әдернә әһалисеннән бер мәтәмәвил, ягъни мал иясе вә бай кемсәнә вафат итеп, хатыны вә бер сеңлесе калды. Ләкин аның хатыны, ире мәразы мәвет[2] белән сырхау яткан мөдәттә: «Хәмәлем бар», — дип изһар кыйлып, вә вафатыннан соң дәхи корсагын бер кәйфияттә зур вә үзен корсак-

---

[1] Истидлал кыйлып — нәтиҗәгә килеп.
[2] Мәразы мәвет — үлем хастасы.

лы хатын итеп күрсәтеп, гүя бала табар заманы килде дип, варис итмәк өчен, бер хәйлә белән шул көндә тапкан бер фәкыйрә хатынның баласын яшертен үзенә китертеп: «Бала таптым», — авазәсен шаигъ кыйлды. Варисе бар дип, ул мәтәүәфинең һәмширәсен мирастан мәхрүм кыйлды. Ләкин ул һәмширәи мәзкүрә: «Фәлән колыңыз вафат булып, зәүҗәсе[1] бер хәйлә белән, углым булды, дип, мәйданга бер бала чыгарды, ихкак хак боерылса икән?» — дип, солтан Сөләйманга барып шикаять кыйлды. Солтан Сөләйман әйтте: «Минем хезмәтемдә булган кемсәнәнең нәсәбенә әҗнәби катышмак җаиз түгелдер, инде углыдыр, — дип, мәтәүәфигә иснад кыйлынган баланы китереп күз алдымда яндырылсын», — дип, фәрман язып игълан кыйлды. Вә бу фәрман белән, дәхи һәмширәсенә хәбәр итеп, һәмширәсе ул сабыйны вә дәхи: «Ул — үлгән иремнән булган бала», — дип дәгъва кыйлган хатынны алып, солтан хозурына китерде.

Бу әхвәлне ишетеп, дәхи ул баланың хәкыйкый анасы фәкыйрә хатын, үзен танытмаенча, җан атып, баласына шәфкатән, ул мәйданга чыкты. Солтан ул заман ат мәйданы дигән җиргә каршы утырыр иде. Вә халык дәхи ошбу углан хакында тәгаҗҗәбән мәзкүр мәйданга кат-кат җәмигъ булып: «Ни була икән?» — дип, хәйран булып торырлар иде. Солтанның әмере белән мәйданга утын китертеп, ут яктылар вә ул баланы, бишеге белән утка ташламак өчен, халыкны ярып ут мәйданына күтәреп керделәр. Бу хәлдә халык арасыннан ул баланың хәкыйкый анасы, аналык шәфкатеннән: «Һай, балам харап булды!» — дип атылып, баласы артыннан ут мәйданына керде. «Әман падишаһым, балама тимә, минем баламдыр, гаять фәкыйрьлегемнән, бер хаҗәтемә ярар дип, ул хатыннан бернәрсә алып, аңа бирмеш идем», — дип, фәрьяд кыйла башлагач, халык солтанның тәдбирен фәһемләп бер авыздан «Галәйкә гаунеллаһи»[2] догасыны коббәи асманга ирештерделәр. Солтан янә әмер кыйлды: бала белән ул ике хатынны солтан хозурына китерделәр. Ул хатынның инкяргә мәҗале калмаенча[3], баланың хәкыйкый анасы ул фәкыйрә хатын икәненә икърар кыйлды.

---

Мөгайрә бин Шәгъбә разыйаллаһу ганһу бер мәрәи хәсәнәгә, ягъни бер гүзәл хатынга никяхланмак өчен яучы җибәрде. Бу вакытта дәхи гарәптән бер бай кеше шул хатынга яучы җибәрмеш иде. Ләкин ул гарәп егет вә күркәм кеше иде. Хатын әйтте: «Инде хатипларым ике булды, икесе дә ханәмә килсеннәр, күрәем», — дип, җавап күндергәннән соң, болар хатынның ханә-

[1] Зәүҗәсе — хатыны.
[2] Галәйкә гаунеллаһи — Аллаһының ярдәме синадыр.
[3] Мәҗале калмаенча — хәле калмыйча.

сенә бардылар. Вә хатын пәрдә артыннан боларның сүзләрен тыңлап торыр иде. Бәс, Мөгайрә бу гүзәл егетне күреп, ахры, бу егетнең гүзәллеге хатынның гакылын алыр дип, бер хөсне тәдбиргә вә хәйләгә тотынып: «Әй гүзәл егет, Аллаһы Тәгалә сиңа ихсан кыйлган җәмалыңда сүз юк, ләкин моннан башка һөнәрең вә кәмалең бармыдыр?» — дип сөаль кыйлды. Аннан соң ул егет үзенең сыйфат хәсәнәсеннән берничә нәрсә тәгъдад кыйлды. Мөгайрә әйтте: «Алыш —бирештә вә саррәфтә[1] диккатең вә гыйльме хисапта бәһрәң ни кәйфияттәдер?» — диде. Егет әйтте: «Гыйльме хисаптан миңа бер мөшкел мәсьәлә юктыр ки, мин бу хосуста хәрдәл[2] данәсеннән дә нечкәрәк хисапларны чыгарамын», — диде. Мөгайрә әйтте: «Мин хәрдәл данәсе кебек нечкә хисапларны белмим, бер бәдрә нәкыдне ханәмә китереп куямын, җәмәгатем кирәк саен, алып-алып сарыф кыйлалар. Беткәнен белмим. Бетте, дисәләр, янә китереп саламын», — диде. Бәс, мәзкүрә гүзәл хатын моны ишеткәч: «Валлаһи, тәхкыйк ошбу минем белән мөхасәбә кыйлмаячак карт ошбу хәрдәл микъдары үзрә масрәфен[3] сайган гүзәл егеттән сәвеклерәктер», — дип, Мөгайрәне кабул итмештер.

---

«Адәм керә алмастай тауларда мәкам тотучы көрд таифәсеннән берничә кыйтагыттарикълар[4], чыгып, узган барган мөсафирларны вә таҗирләрне талап вә газаплап, малларын алалар, янә качып, мәкамнарына китәләр», — дип, гозадеддәүләт хәлифәгә хәбәр бирделәр. Хәлифә аларга каһәр кыйлмак өчен, бер хөсне тәдбир кыйлды ки: таҗирләрдән бәгъзесене китертеп, алтын көмеш савытлар эченә зәһәр белән мөрәбба[5], хәлвә вә татлы тәгамнар тутырып, бер ишәккә йөкләтте. Вә ул таҗиргә фәһемләтте ки, бу йөк фәлән әмирнең хатыныннан фәлән әмирнең хатынына һәдиядер дип шаигъ кыйлдылар. Мәзкүр таҗир кәрван белән барганда, ул кыйтагыттарикълар чыгып, кәрванны таладылар. Вә кыйтагыттарыйкның берсе ул мәзкүр ишәкне йөге белән ялгыз җитәкләп китте, мәкаменә барып, йөкне ачып карады. Күрде ки: алтын-көмеш савытларда нәфис нигъмәтләр. Гайреләренә бирмәскә касд[6] кыйлып, яшермәкче булды, ләкин юлдашлары сизеп, һәммәсе ач булганнары хәлдә, бу зәһәрле хәлвәләрне талашып ашадылар. Күп заман кичмәде, һәммәсе бердән һәлак булдылар. Мал ияләре һәркайсысы малларын алып, хәлвәдән татлы догага хәлифәне гарык иттеләр.

---

[1] Саррәфтә — алыш-биреш эшендә.
[2] Хәрдәл — горчица.
[3] Масрәфен — чыгымын.
[4] Кыйтагыттарикълар — юлбасарлар.
[5] Мөрәбба — варенье.
[6] Касд — ният, уй.

———

Бер шәһәр валисенең хозурына угрылык төһмәте белән ике кешене тотып китерделәр. Ул гакыл иясе вә хөсне тәдбир иясе вали бер тәдбир кыйлып, ул ике угры алдында бер касә су сорап алды. Касәне кулына алып, гаять ачигъланып, сулы касәне җиргә ыргытты. Угрыларның берсе сискәнеп, башы әйләнеп егылды, берсе һич кыймылдамаенча урынында торыр. Бәс, вали ул сискәнеп егылган кешегә, бар син юлыңа кит, диде, икенчесенә малны алгансың, син китереп бир, дип тәхвиф кыйлды. Ул угры, дәхи икърар кыйлып, малны бирде. Ул валидән сорадылар: «Бу фәрасәтеңез ничек булды?» — диделәр. Вали әйтте: «Угры кешенең күңеле каты вә куәтле буладыр, вә ул берсе гафләт белән торганда, касә җиргә төшкәч куркып китте, аның калебе угры калебенә охшамады, белдем ки, угры түгелдер», — диде.

———

Мәнкульдер ки, бер кемсәнә, хаҗ шәрифкә ният итеп, бераз малын сурәттә изгегә охшаган бер кешегә әманәт куйды. Шаһидләре юк иде. Хаҗ кыйлып кайтканнан соң, малын таләп кыйлгач, ул әманәт алган кеше инкяр кыйлып, бу хаҗи бичара казый Әяска барып шикаять кыйлды. Әяс әйтте: «Синең монда килгәнеңне кеше белдеме?» Хаҗи әйтте: «Юк, берәүгә дә әйткәнем юк». Казый әйтте: «Алай булса бар кайт, өеңдә ике көн утыр, бу вакыйганы берәүгә дә сөйләмә», — дип тәнбиһ кыйлды. Аннан соң әманәт алган кешене чакыртып, йомшаклык белән гыйззәт вә икрам кыйлып, мәслихәт тарикынча аңа әйтте: «Миндә ятим маллары, вәкыфләр вә әманәтләр бик күп җыелды, миңа бу көннәрдә озак сәфәр кыйлмак зарур булды, синең диянәтеңне вә әманәтеңне ишеттем. Бар, ханәңдә минем малымны сакламак өчен бер урын хәзерлә, өч көннән соң яучылар алып кил, сандыкларны алып китәрсең», — диде. Ул мәзкүр хаин, баш өсте, дип китте вә ул мал иясе дәхи вәгъдәсе көнендә казый Әяска килде. Казый әйтте: «Инде ул кешегә бар, малыңны сора, бирмәсәң, казыйга барып сине шикаять кыйлырмын, дип әйт», — диде.

Бу кеше казыйның үгрәтүе буенча барып, ул әманәт алган кешегә күренгәч тә, әй борадәр, сиңа уйнап мәзах кыйлмыш идем, мә, малларыңны ал, дип, тәмамән иясенә кайтарып тапшырды. Бу хаҗи әфәнде малын кайтарып алгач, тәшәккәран[1] казыйга барып хәбәр бирде, янә ул хаин дәхи вәгъдәсе көнендә атлар белән казый әфәндегә мал төяргә килеп җитте. Казый әйтте: «Инде ул хаҗи синнән малын кайтарып алгач, ул раэем мөнкалиб булды, сәфәрне куйдым, бар кит, Аллаһы Тәгалә синең кебекләрне халык эченнән алсын!» — дип, бәддога кыйлып җибәрде.

---

[1] Тәшәккәран — рәхмәт йөзеннән.

Һарун әр-Рәшит өч углын вәли гаһед итеп, эркан дәүләтне җыеп, бу хосуста бәйгать[1] иттереп гуаһландырды, ләкин эркан дәүләттән бер мәгъруф кеше бу бәйгатькә тәхәллеф кыйлды. Һарун хәлифә, ул кешене чакыртып: «Ни сәбәпле син безнең бәйгатемезгә тәхәллеф кыйласың?» — дип сорады. Ул кеше әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, мин, шөгылем барлык сәбәпле, бәйгать мәҗлесенә килә алмадым», — дип игътизар кыйлды. Аннан соң хәлифә әмер кыйлды, гаһед намәне китереп укыдылар, бу кеше ишетте, әй әмирел-мөэминин, ошбу бәйгать кыям сәгатькәчә минем муенымдадыр, дип ризалык күрсәтте. Хәлифә бу сүздә тәүрия барлыгын фәһемләмәенчә, кыям сәгатьтән морады яүме хәшәр булмакын зан итте, әмма ул кешенең морады хәлифә мәҗлесеннән кыяме, имеш.

Мөгайрә бин Шәгъбә әйтте: «Мине Харис кабиләсеннән бер егет алдады. Аннан гайре кешегә алдатканым юк иде. Шөйлә ки, ул мәзкүр кабиләдән бер хатынны тәзәүвеҗ итмәгә дип, ирадә кыйлып, ул егеттән сораштым. Егет әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, ул хатында синең өчен хәер юктыр», — диде. «Нидән?» — дидем. Егет әйтте: «Мин ул хатынны бер ир кеше үпкәнен күрдем», — дигәч, ул хатыннан игърaз кыйлдым. Филхаль ул егет үзе барып, аны никях итте. Бервакытны ул егеткә күреп әйттем: «Әй фәлән, ул кеше үпкән хатынны ни өчен алдың? Үзең аны кеше үпте дип әйткән иден», — дидем. Егет әйтте: «Бәли, ул хатынны кечкенә чагында атасы үпкәнне күргән идем», — дип, мине мәсһүт кыйлды», — диде.

Бер кеше бәни Тәмим кабиләсенең сәеде булгучы Әхнәфкә килеп, бер сәллә орды[1]. Әхнәф ул кешегә әйтте: «Бу яман эшкә син ни вәҗеһтән җөрьәт кыйлдын?». Ул кеше әйтте: «Бер кемсәнә миңа, бәни Тәмимнең сәеде булгучы Әхнәфне латма[2] орсаң, сиңа фәлән кадәр акча бирермен, дип җәгаль тәгаен кыйлмыш иде», — диде. Әхнәф әйтте: «Юк, алайса син хата кыйлдың. Бәни Тәмимнең сәеде мин түгелмен. Аларның олугысы Харисә бин Кавамәдер», — диде. Ул кеше мәүгуд булган акчаны алмак хирысы белән барып, Харисәне сукты. Дәрхаль Харисә аны тоттырып, кулын кистерде. Җәзасын тапты.

Вә дәхи риваять сахихә үзрә дәфгы зарар[3] заманында булган хөсне тәдбирдәндер ки, Рәсүл чама белән саллаллаһу га-

---

[1] Бәйгать — берәүнең хакимиятен тану һәм аңа буйсыну өчен сүз бирү.
[1] Сәллә орды — сукты.
[2] Латма — сугу, бәрү.
[3] Дәфгы зарар — зарарны бетерү.

ләйһиссәлләм хәйбәрне фәтех кыйлып, мөселманнарны шатландырганнан соң, ислам шәүкәте булган заманда Хәҗҗаҗ бин Галабат дигән кеше, дәхи мөселман булып, Рәсүлуллаһ хозурына килде, әйтте: «Йә Рәсүлуллаһ, минем Мәккәдә һәмширәм өмме Шәйбә янындадыр вә дәхи Мәккә тәҗирләрендә өләшкән малларым бардыр. Минем мөселман булган хәбәрем аларга ишетелмәс борын, Мәккәгә кайтаем, куркырмын ки, мөселман булганымны белсәләр, Мәккәдә булган барча малым китәр», — дип изен алганнан соң, янә: «Йә Рәсүлуллаһ, мин сүз сөйләшмәгә мохтаҗмын», — диде. Моннан морады бер мәслихәт өчен исламын яшереп, әгәр икътиза кыйлынса, әһле исламга дошман күренеп, ислам зарарына сөйләшмәген белдереп, бу вәҗһе белән рөхсәт сорады. Пәйгамбәр галәйһиссәлам рөхсәт бирде. Аннан соң Хәҗҗаҗ разыйаллаһу ганһу чыгып, Мәккә Мөкәррәмә җиварында Сәниятелбәйзаә дигән җиргә барды, анда Корәештән берничә кеше Рәсүл галәйһиссәламнең Хәйбәргә сәфәр кыйлмакыннан бер хәбәр ишетмәк өчен, Корәеш тарафыннан чыкмышлар иде. Ул кешеләр Хәҗҗаҗны күргәч, шаять монда бер хәбәр бардыр, дип, Хәҗҗаҗ янына килделәр: «Йә Хәҗҗаҗ, Мөхәммәднең Хәйбәргә киткәнен без ишеттек, син ни хәбәр ишеттең, сөйлә?» — диделәр. Хәҗҗаҗ әйтте: «Мөхәммәд Хәйбәргә китте, минем дә сезгә сөрүр[1] китерәчәк бер хәбәрем бар», — диде. Филхаль бу хәбәрне сорашмага Хәҗҗаҗның тәвәсен чорнап алдылар: «Йә Хәҗҗаҗ, ни хәбәрең бар, сөйлә», — диделәр. Хәҗҗаҗ әйтте: «Мөхәммәд шундаен бер һәзимәт белән мөнһәзим[2] булды ки, Мөхәммәд әсир булды, монда кател итмәенчә, Мәккәгә җибәрәек, анда Мәккә әһеле арасында аны вә һәм әсир төшкән кешеләрне кател итсеннәр, диделәр», — диде.

Моны ишеткәч, алар Мәккә җанибенә китеп, инде хәбәр килде, һаман Мөхәммәд киләчәктер, шөйлә булыр дип, нида иттерделәр. Хәҗҗаҗ аларга әйтте: «Минем халык өстендә булган малымны җыймага ярдәм итешеңез, зирә мин тәҗирләрдән мөкаддәм Хәйбәргә барып, Мөхәммәднең нәрсәсеннән вә малыннан вә сәхабәләренең нәрсәләреннән ни булса сатып алаем дип ният итмеш идем», — диде. Аннан соң Хәҗҗаҗ белән торып, Хәҗҗаҗның эстәгәненнән артык ярдәм итешеп, малын җыеп бирделәр. Кайчан ки ошбу кара хәбәр Мәккәдә шаигъ булды.

---

Габбас бин Габделмоталлаб разыйаллаһу ганһу дәхи бу хәбәрне ишетеп, мәзкүр Хәҗҗаҗ тәҗирләр чатырында иде, яны-

---

[1] Сөрүр — шатлык.
[2] Мөнһәзим — җиңелгән кеше.

на килеп: «Әй Хәҗҗаҗ, бу син ниндәен хәбәр китердең?!» — диде. Хәҗҗаҗ әйтте: «Сиңа әйтәсе бер сүзем бар ки, син аны сакларга кадирмысың?!» — диде. Габбас, касәм итеп: «Кадирмын, валлаһи, саклармын», — диде. Хәҗҗаҗ әйтте: «Монда сөйләшергә булмас, аулакта сөйләшермен, зирә күрәсең ки, малымны җыймактамын», — диде. Аннан соң Хәҗҗаҗ тәмам малын җыеп бетергәч, Габбас белән мөләкат булып[1] әйтте: «Әй Әбү әл-Фазыйл, сүземне сакла, зирә куркамын ки, артымнан дошманнар барыр, ләкин өч көннән соң теләсәң ни сөйлә», — диде. Янә Хәҗҗаҗ әйтте: «Әй Әбү әл-Фазыйл, карендәшең углы мәнсүр вә мозаффар булганнары хәлдә Хәйбәрне фәтех кыйлды вә, малларын ганимәт итеп, ул өлкәгә пәйгамбәр галәйһиссәлам вә сәхабәләре малик булдылар. Хәйбәр милке мәкътүл булды, кызы Сафия Сафвәт ислам белән мөшәррәфә булып, пәйгамбәр галәйһиссәлам тәзәввеҗ кыйлды. Хәзер дә зифафта шәрәфъяб булды, диде. Габбас моны ишеткәч, кәмаль сөрүреннән син ни сөйләрсең, йә Хәҗҗаҗ, диде. Хәҗҗаҗ әйтте: «Инде Аллаһы Тәгалә белер ки, хәл биләдер, мин дәхи мөселман булып монда килдем, заһирдә син ишеткән сүзләрем вә син күргән фигыльләрем рөхсәте һомаюн нәбәви беләндер, малымны тәхсил өчен иде, зирә болай итмәгән булсам, малым тәләф булыр иде, ләкин мин киткәч өч көннән соң әмереңне изһар кыйл вә, әлхасыйль, пәйгамбәр хак галәйһиссәлам әфәндемез, валлаһи, син теләгән хәл үзрәдер», — диде вә юлына рәван булды.

Инде Хәҗҗаҗ ошбу тәякъкыз белән малын тәхсил кыйлмага хәйлә тапмыштыр.

---

Бер шәһәрдә бер байның амбарыннан мамыгы угырланды. Ул мамык иясе, падишаһка килеп, шикаять кыйлды. Падишаһ мамык угырлаган кешеләрне эзләтте, тапмадылар. Бер вәзир, падишаһка килеп, гарыз кыйлды ки: «Әгәр падишаһның фәрманы булса, мамык угырлаган кешене табармын», — диде. Падишаһ әмер кыйлды. Бу вәзир, өенә кайтып, олуг зыяфәт хәзерләде, барча шәһәр халкын, олуг вә кечекне берсен калдырмаенча, һәммәсен чакырды. Олуг, кечек һәммәсе җыелдылар. Падишаһ һәм килде, халык һәммәсе утырдылар. Мәзкүр вәзир чыгып, һәммә халыкның йөзләренә берәм-берәм карап: «Һи харамзадә хәясыз вә ахмаклар, мамык угырламышлар, мамык бөртекләре сакалларына ябышмыш, шул хәл белән падишаһ мәҗлесенә килергә оялмадыңызмы?» — диде. Мамык угырлаган кешеләр һәммәсе сакалларын куллары белән сыпыра башладылар. Мәгълүм булды ки: мамык угырлаган кешеләр

[1] Мөләкат булып — очрашып.

ошбулардыр, падишаһ дәхи вәзирнең хикмәтенә тәхсин кыйлып, мамыкны ул кешеләрдән алып, иясенә тапшырдылар.

———

Бер данишмәнд[1] бер гаттарга[2] мең алтын әманәт куеп, үзе сәфәргә китте. Берничә көннәр сәфәрдә йөреп кайткач, ул гаттардан куйган әманәтен барып сорады. Гаттар, миңа һичнәрсә куйганың юк, ялган әйтмә, дип инкяр кыйлды. Данишмәнд белән низаг кыйлыштылар, гауга купты, халык җыелды, барчасы, бу гаттар яхшы кеше, диянәтле кеше, хыянәт кыйлмас, дип, данишмәндне ялганчыга чыгардылар. Ахыр данишмәнд гаҗиз булып, бу хәлне бер кәгазьгә язды вә падишаһка гарыз кыйлды. Падишаһ әмер кыйлды: «Бар, син ул кешенең дөкяненә бар, өч көн шул урында тор, бер җиргә китмә. Дүртенче көн мин анда барырмын, сиңа сәлам бирермен, сәламемне кайтарырсың, башка бер җавап бирмәссең. Әмма мин узып киткәч, гаттардан алтыннарыңны сора, ул ни җавап бирсә дә, миңа барып хәбәр бир», — диде. Бәс, бу данишмәнд падишаһ фәрманынча ул гаттарның дөкяне янында өч көн торды, дүртенче көн падишаһ вәзир-вөзәрасы белән гаттарның дөкяненнән узганда, атын туктатып, данишмәндкә сәлам бирде. Данишмәнд падишаһның сәламен алды. Падишаһ әйтте: «Әй борадәр, миңа бер дә барганың юк, хәл-әхвәлеңне бер дә сөйләгәнең юк ла», — диде. Данишмәнд һич җавап бирмәде. Гаттар бу вакыйганы һәммәсен күреп торыр иде, бик курыкты. Падишаһ узып киткәч, гаттар әйтте: «Әй данишмәнд, син миңа әманәт куйдым дип әйтәсең, син әманәт куйганда, мин кайда идем? Минем янымда кешеләр бар идеме? Яңадан сөйләп карачы, әллә хәтеремнән чыкты микән», — диде. Бу данишмәнд әхвәлне һәммәсен яңа баштан сөйләде, Гаттар бераз уйлап торды да, раст әйтәсең, хәзер исемә төште, биргән идең, дип, алтыннарны чыгарып тапшырды вә гозер теләде.

Бер шәһәрдә бер олуг бай хуҗаның колы качып китте. Берничә көннән соң хуҗа сәүдә белән икенче шәһәргә барды. Ул шәһәрдә йөргәндә үзенең качкан колын күрде, ник качтың, дип барып якасыннан тотты. Ул кол дәхи хуҗаның якасыннан тотты, син минем колым идең, ник качтың, фәлән кадәр малымны угырлап качтың, дип, гауга кубарды. Икесе дә, син минем колым, дип якалашып, казый каршына бардылар, инсаф эстәделәр. Бәс, казый боларны икесен ике тәрәзә төбенә утыртты: «Икегез дә тәрәзәдән башыгызны чыгарып торыгыз», — дип әмер кыйлды. Икесе һәм тәрәзәдән берьюлы башларын чыгарып тордылар. Шул вакытта казый әфәнде дәррәү кычкырды:

---

[1] Данишмәнд — белгеч, гыйлем иясе.
[2] Гаттарга — хушбуй сатучыга.

«Йә җәллад, кылыч белән колның башын кисеп төшер!» — диде. Кол, бу сүзне ишеткәч тә, башын тартып алды, хуҗа һаман башын тәрәзәдән чыгарган хәлендә калды, асла кузгалмады. Аннан соң казый ул колга сәясәт кыйлды вә хуҗасына тапшырды.

---

Бер дәүләт иясе адәм бер саррафка күп мал әманәт куеп, үзе сәфәргә китте. Сәфәрдән кайткач, куйган малын сарраф-тан кайтарып сорады, сарраф инкяр кыйлды, миңа тапшырганың юк, дип ант эчте. Бәс, бу кеше, казыйга барып, әхвәлен гарыз кыйлды. Казый бераз фикер итеп торды да әйтте: «Йә фәлән, сарраф малымны кайтарып бирмәде, дип, һичкемгә сөйләмә, малыңны кайтарып алмага бер тәдбир кыйлырмын», — диде. Икенче көн казый ул саррафны үзенә чакырды, әйтте: «Йә фәлән, минем эшем бик күбәйде, җитешеп булмайдыр, сине үземә наиб вә мөгайян[1] кыйлмага ирадәм бар, синең бурычың да күп дип әйтәләр, сиңа да файда булыр, миңа да булышлык итәрсең», — диде. Сарраф кабул итте.

Аннан соң казый, сарраф киткәч, ул мал иясен чакырып дәхи әйтте: «Инде бар, саррафтан малыңны сора», — диде. Бәс, бу кеше сарраф янына килде, сарраф, бу кешене күргәч тә: «Хуш киләсең, кил, кил, синең малыңны оныткан идем, бу көн хәтеремә төште, менә малыңны ал», — дип, малны бу кешегә тапшырды. Наиб булмак өмиде белән казый янына китте, казый әйтте: «Бу көн падишаһ янына бармыш идем, ишеттем ки, сиңа падишаһ наиблектән дә олуг эшне тапшырмакчы буладыр, шөкер ит, олуг мәртәбәгә ирешәсең, инде мин үземә наиблеккә икенче кешене табармын», — дип, бу хәйлә белән саррафны кайтарып җибәрде.

---

Бервакытны бер бай адәмнең йортыннан бер капчык алтын югалды. Ул кеше казыйга барып хәбәр бирде. Казый ул кешенең йортында булган адәмнәрне һәммәсен чакырды вә һәрберсенә берәр таяк бирде, һәммәсе бер озынлыкта, бер үлчәүдә иде. Әйтте: «Кем дә кем угры ул булса, кешенең таягы бер бармак кадәр озын булыр, — диде, — бар кайтыгыз, — дип, — һәммәсен кайтарып җибәрде». Ул капчык белән алтынны угырлаган кеше курыкты да бер бармак кадәр казый биргән таякны кисте. Икенче көн янә казый ул кешеләрне һәммәсен чакырды, һәммәсенең таякларын карады, берсенең бер бармак кадәре таягы кыска. Мәгълүм булды, алтынны ул кеше угырлаган, имеш, алтынны иясенә тапшыртып, ул угрыны сәясәт кыйлды.

---

[1] Наиб вә мөгайян — урынбасар.

Мансур хәлифәнең хозурына гоммалдан бер залим вә кабахәт эшле кешене тотып китерделәр. Ул кеше, игътизардан гаҗиз булып, хәлифә алдында башын бөгеп тик торды, гозер итәргә дә кодрәте булмады. Хәлифә әйтте: «Әй җинаять кыйлган кеше, бу катылык вакытында башыңны иеп, йөзеңне чытып сөкут үзрә[1] торырсың, мин синең гаять мөнши вә бәлигъ икәнеңне беләмен ләбаса. Бу мөхазарәле вакытта ник бер сүз дәшмәй торасың, нияз вә игътизарың кайда?» — диде. Ул кеше әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, монда мөншилек[2] белән мөфәхәрәт[3] вә мактану урыны түгелдер, бәлки тәүбә вә нәдамәт урыныдыр. Тәүбәм вә нәдамәтем ошбу хозугымдыр[4]», — диде. Аннан соң хәлифәнең күңеле йомшап, гафу кыйлды.

Мәнкульдер ки, бер кабахәт эшле кешене маэмун хәлифә хозурына китерделәр. Хәлифә, тәүбих вә гыйтаб кыйлып. «Әй син фәлән, бу җинаятьне вә гаепне ни йөзең белән эшләдең, сәясәтемнән курыкмадыңмы?» — диде. Ул кеше әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, сезнең гафуыңызга таянып, нәфесемә золымлык кыйлган эшемдер, тәкъсыйр», — диде. Хәлифә гафу кыйлды вә гаебен багышлады.

Але Габбастан Һади хәлифә хозурына бәгъзе төһмәт[5] белән берәүне тотып китерделәр. Хәлифә ул кешегә гатаб вә тәүбих кыйлганнан сон, ул кеше әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, минем хәлем икедән хали түгелдер, әгәр ул миңа иснад кыйлынган гөнаһны икърар кыйлсам, үзем кыйлмаган гөнаһны үземә илсирам кыйлмыш булырмын. Төптә мин кыйлмаган бәла миңа ябышыр, юк, әгәр инкяр кыйлсам, син мине гаепле дип торганда, сүзеңне рәд белән сиңа мөгарәзә[6] кыйлмыш булырмын, ләкин әйтермен ки, әгәр мине гакубәт вә җәза кыйлмак эстәсәң, үзеңә гафудан хасыйл булачак савапны да онытма», — диде. Хәлифә ни эшләсен, гафу кыйлды.

Һарун әр-Рәшит беркөн Хәмид әт-Тауси дигән кешегә ачигъланып аны, үтермәгә әмер кыйлды. Хәмид егълады. Һарун әйтте: «Нигә егъларсың, гөнаһыңны белмәйсеңме?» — дип гыйтаб кыйлгач, Хәмид дәхи, валлаһи, әй әмирел-мөэминин, үлемнән куркып егъламаймын, чөнки адәм кайвакыт булса да бер үләчәктер, әмма әмирел-мөэминин миңа мөнфәгыйль хәлдә, ягъни

[1] Сөкут үзрә — дәшми, сөйләшми.
[2] Мөншилек — оста итеп яза белүчелек.
[3] Мөфәхәрәт — мактану.
[4] Хозугымдыр — тыйнаклыгымдыр.
[5] Төһмәт — яла.
[6] Мөгарәзә — гауга, низаг.

хәлифә миңа ачигъланмыш хәлендә үлмәкемә кайгырамын, диде. Һарун әр-Рәшит аннан соң гафу кыйлды.

---

Бәни Өмәйянең вәзирләреннән Зияд бер мөҗримнең[1] башын кисмәгә әмер итте. Ул мәзкүр мөҗрим әйтте: «Әй әмир, минем синдә хакым бардыр, гафу кыйл», — дип мәрхәмәт өстәде. Зияд әйтте: «Миндә ни хакың бар?» — дигәч, ул мөҗрим әйтте: «Минем атам Басрада синең күршең иде», — диде. Зияд әйтте: «Атаң ни исемле?» — иде. Ул мөҗрим әйтте: «Әй әмир, хәзер дә атамның исемен түгел, үз исемемне дә оныттым», — диде. Зияд көлде дә гафу кыйлды.

---

Мәсгаб бин Зөбәер бер кешене кател итмәгә боерды. Ул кеше әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, үлмәгә хәсрәт чикмәймен, бу күркәм сурәтең вә нурлы йөзең белән кыямәт көнендә итәгенә ябышып, йа Рабби, Мәсгаб дигән бәндәңне сөаль кыйл, мине ни өчен үтерде, дип шикаять кыйлган вакытымда, синең башыңа яман эш киләчәгенә кайгырамын», — дигәннән соң, Мәсгаб гафу кыйлды. Янә бу кеше әйтте: «Йә әмир, инде гомерем дә булды, миңа син багышлаган гомеремне дәхи синең арканда рәхәт кичерәсем киләдер», — диде. Янә Мәсгаб йөз мең дирһәм ихсан кыйлды.

---

Миһербанлык белән мәшһүр ибн Гаун дигән бер кемсәнә бар иде. Беркөн хезмәтчесе тәвәсенең күзен сугып чыгарды. Ибн Гаун зиядә хәлим кеше, ләкин бу тәвәнең күзе чыкканын күрсә, алай да ачигъланыр, зирәки бу тәвәне бик сәвәр иде, дип көтеп торырлар иде. Ибн Гаун тәвәне күзсез күргәч, дөшнам[2] урынына: «Әй егет, Аллаһы Тәгалә сине гафу кыйлсын вә ярлыкасын», — диде.

---

Бер кемсәнә пәйгамбәр галәйһиссәламгә килеп: «Йә Рәсүлуллаһ, Аллаһы Тәгаләнең газабыннан качмакның тарикы[3] нидер?» — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Аллаһы Тәгаләнең газабыннан имин булаем дисәң, ачигъланма», — диде.

---

Риваять кыйлынмыштыр ки: яһүд таифәсеннән бер кавем бәгъзе хосус өчен пәйгамбәр галәйһиссәламнең хозур шәрифләренә килеп, табигать хәбисәләрендә мәркүз[4] булган хыянәт икътизасынча «әссәламегаләйкем» урынына «әссам галәйкем»

---

[1] Мөҗримнең — җинаятьченең.
[2] Дөшнам — сүгү, әрләү.
[3] Тарикы — юлы.
[4] Мәркүз — биредә: хас.

диделәр. Моны хәзрәти Гайшә разыйаллаһу ганһа ишетеп сабыры китте. Дәрхаль пәйгамбәр галәйһиссәлам хәзрәти Гайшәгә: «Йә Гайшә, Аллаһы Тәгалә һәрнәрсәдә йомшаклык вә хыйлемгә[1] мәхәббәт итәр», — диде.

---

Бер кемсәнә бер гакыйль вә кямил адәмне әлфазе кабихә[2] белән сүгеп торыр. Ул кеше аңа әйтте: «Әй кеше, мине сүкмә, синең белән җавап кайтарышмамын. Мин кечкенә вакытымнан бирле кеше белән сүгешмәкне үтердем, инде зур булгач та аны ихъя кыйла алмамын, ягъни интикамыңны алмамын», — диде.

---

Хәлифәләрдән берәү Нәсар бин Минәгъ дигән кешене кател итмәгә хөкем кыйлмыш иде. Һаман бу Нәсар: «Әй әмирелмөэминин, мине кател кыйлмастан мөкаддәм миннән бер сүз ишет», — дип, изен сорады. Әмир әйтте: «Сөйлә, ни сүзең бар?» Бәс, бу Нәсар мәсәл тарикынча: «Әй әмир, бер карчыга бер гасфурны тотып очканда, бичара чыпчык карчыганың тырнагында икән, карчыгага әйтте, бу аз вә кечкенә нәрсә синең кебек олуг кошка локмә булмас, ягъни минем белән карының туймас, мине азат кыйлсана, дип, мәрхәмәт эстәде. Бәс, карчыга ул чыпчыкка кәрәм итеп, тырнагыннан ычкындырып азат кыйлды», — дигәч, хәлифә дәхи Нәсарны азат кыйлды.

---

Хәзрәти Гомәр разыйаллаһу ганһу хәлифә заманында бер исереккә раст килеп, хәдде шәрабны иҗра кыйлмак өчен, ул исерекне тотмага әмер кыйлды. Ул мөрдар исерек сүгенмәгә җәсарәт кыйла башлагач, Гомәр разыйаллаһу ганһу: «Җибәрегез аны», — дип әмер кыйлды. Әйттеләр: «Йә әмирел-мөэминин, хәмер эчкән өчен хәддегә мөстәхак вә сүккән өчен тәгъзиргә мөстәхак булмыш иде, җибәрдегез, ни хикмәттер?» — диделәр. Гомәр разыйаллаһу ганһу әйтте: «Сүгеп мине ачигъландырды. Моның үзәренә тәгъзир итсәм, нәфесемә носрәт бирмеш булырмын. Мин бер мөселманга химаять нәфес зыймнында[3] җәза бирмәкне мәгъкуль күрмәдем», — диде.

---

Мансур хәлифә катибләрдән бер кешене җинаяте вә кабахәте сәбәпле ачигъланып, сукмага әмер иткән иде. Катиб бер бәетне билбәдаһәт[4] нәзым итте. Бәс, Мансур ул катибны гафу кыйлды вә аның өстенә дәхи ихсан кыйлды. Бәетнең мәгънә-

---

[1] Хыйлемгә — миһербанга.
[2] Әлфазе кабихә — начар сүзләр.
[3] Зыймнында — сәбәпле.
[4] Билбәдаһәт — кинәт, көтмәгәндә.

се: без катиблар зөмрәсеннәнбез, безләр сүи әдәп[1] кыйлган булсак, барча халыкның әхвәлен язмага мөвәккәл булгучы кәрам катибин фәрештәләре өчен багышла, димәктер.

Кадимге падишаһлардан бер падишаһ тәгам ашаганда, аш йөртә торган хезмәтчеләреннән бер хасс хезмәтчесе ашны дәстәрханга куйганда, падишаһның мәһабәтеннән каушап, аягы сөртенде. Тәгамның шурпасыннан бер микъдар падишаһның киеменә сачрәде, падишаһ, ачигъланып, мәзкүр хадимнең муенын ормага әмер итте. Бу хадим падишаһ, мине үтерер, дип, җәзмән белеп, алай да үләм, болай да үләм, дип, һаман ашны дәстәрханнан күтәреп алды, тәмам падишаһның башыннан аягына кадәр өстенә түкте. Падишаһ, бу хәлне күреп: «Әй егет, шаштыңмы син, син ни эшләдең?!» — дип хәйран булды. Хадим әйтте: «Әй падишаһым, мин шашмадым, гакылым сахихтыр[2], бу җөрьәтне мин өстемдә булган икмәк тозыңның хакын ифа кыйлмак өчен, касдан иттем, хак иттем, ягъни халык бу аз гына хата өчен бигайри хак бичара хезмәтчене мондаен олуг падишаһ тәләф итмеш дип, шаэнегезгә тәгънә[3] итмәсеннәр өчен, бу олуг кабахәт эшне кыйлдым. Таки ишеткән кешеләр минем хакымда кабахәт эше белән җәзасын тапты димәкләре белән зат мөлүканәңез мәламәттән котылыр», — диде.

Падишаһ берзаман фикердә торганнан соң: «Әй фигыле кабих вә игътизары гүзәл егет, синең бу яман эшеңне хөсне игътизарың өчен багышладык, ливәҗһи Аллаһ, азат бул», — дип, аның өстенә дәхи күп ихсан кыйлды.

Көннәрдән бер көн бер шагыйрь гаепле булды. Падишаһ җәлладка әмер кыйлды: «Шагыйрьне күзем алдында үтер», — диде. Шагыйрь зиядә куркып калтырый башлады. Падишаһның нәдиме[4] әйтте: «Бу ниндәен егетлек, егет кеше калтырармы?» — диде. Шагыйрь әйтте: «Әй нәдим, әгәр егет булсаң, кил, минем урыныма утыр, башыңны кисәм дип торсыннар, калтырамассың микән», — диде. Падишаһ бу ләтыйфәне хуш күрде, көлде вә гафу кыйлды.

Ибраһим бин Мәһди берзаман качып йөрде, ахыр Маэмүн хәлифәгә тотып китерделәр. Хәлифә хозурына кергәч әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, минем гөнаһым шулкадәр олугдыр ки, гозерем ихата кыйла алмас. Вә синең гафуың дәхи шулкадәр

---

[1] Сүи әдәп — әдәпне бозу.
[2] Сахихтыр — сәламәттер.
[3] Тәгънә — тел тидерү.
[4] Нәдиме — бергә яшәүче иптәше.

олугдыр ки, минем гөнаһым аннан олуг була алмас», — диде. Биззарур Маэмүн хәлифә аны гафу кыйлды.

———

Маэмүн хәлифәнең каршында кешенең гаебен вә гөнаһын гафу кыйлудан сөеклерәк нәрсә юк иде, вә әйтер иде ки: «Әгәр халык минем гафу сәүгәнемне белсә иде, гөнаһ кыйлып, миңа якынлык эстәрләр иде, валлаһи, шулкадәр гафу минем каршымда ләззәтле нәрсәдер, хәтта гөман кыйламын ки, Аллаһы Тәгалә миңа аның өчен әҗер бирер микән», — ди иде.

———

Кыйсаска[1] мөстәхак булган кешеләрдән берәүне Мәһди хәлифә берничә мәртәбә тәкрар гыйтаб вә шелтә кыйлды. Әйтте: «Әй фәлән, инде кай замангача хата вә гөнаһ кыйлудан туктамайсың?» — диде. Ул кеше әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, син хәлифә булып торганда гөнаһ бездән, гафу синнән», — диде. Мәһди гафу кыйлды вә разый булды.

———

Әяс бин Мөгавия әйтте: «Бер гарәп белән юлдаш булып бер җиргә сәфәргә чыкмыш идем, бер су янына туктап ял иткән заманымызда, юлдашымның агасы бер карт кеше белән янымызга килде. Бер-бере белән, син кайда калдың, безне ташлап киттең, дип, берең-бере гыйтаб кыйлыша башладылар. Һаман ул карт әйтте, мәхәббәтеңез артсын, туктаңыз, зирә мөгатәбә җинаятьне, җинаять мөхасамәне, мөхасамә гадавәтне мөстәлзәмдер[2]. Бернәрсә ки гадавәтне мөнтих[3] була, анда хәер юктыр», — дип, нәсыйхәт кыйлды.

———

Мөхәммәд бин Хәсәннең дус вә мөсахибләреннән бер кемсәнә, бер мәртәбә тарлык вә фәкыйрьлеккә төшеп йөргәннән соң, янә бәхете ачылып, бер җиргә гамил булды. Әүкаты яхшы булгач, Мөхәммәд бин Хәсән һәм зиярәт һәм тиҗарәт нияте белән ул кемсәнәгә барып күрсә, ул гамил билкөллия үзгәреп, хәтта Мөхәммәдне танымады. Бәс, Мөхәммәд, бин Хәсән аның белән мөсахәбәт кыйлмастан, кайтып, аңа бу кыйтганы язып җибәрде: «...әй дус, һәрни кадәр дөнья сиңа сәрвәт вә иркенчелек бирмеш исә дә, элгәре фәкыйрьлектә икәнсең. Бу мәртәбәдә бәхетең ачылып, мохтаҗлыктан чыккан булсаң да, мәкярим әхлакың булмаганлыктан, ул икъбалың бераз мөламәтне мөстәлзәмдер вә бераз әхлак зәмимәң мөнкәшиф[4] булды ки: мө-

---

[1] Кыйсаска — «үлем өчен үлем» кагыйдәсенә.
[2] Мөстәлзәмдер — котылгысыз итә.
[3] Мөнтих — сәбәпче.
[4] Әхлак зәмимәң мөнкәшиф — түбән әхлагың ачык.

каддәм ул әхлакың фәкыйрьлек киеме астында мәстүр, имеш, фәкыйрьлек киеме арканнан төшкәч мәгълүм булды, хокукышнаслык итмәдең», — димәктер.

---

Мәшһүр Әхнәф беркөн сәер кыйлып йөргән вакытында, еракган берәү Әхнәфне сүкте. Әхнәф аңа якынрак баргач, янында туктап: «Әй кеше, мине сүгеп бетермәгән булсаң, монда янә өзмә, әйт, зирәки мине сүккәнеңне кавемнең егетләре ишетсәләр, гайрәт итеп сине кыйнарлар, без интикамда гайре кешенең ярдәмен эстәмәсмез», — диде.

---

Локман хәким хәзрәтләре углына васыять итеп әйтте: «Әй угыл, өч кеше беленмәс, мәгәр өч нәрсә вакытында беленер: бере — хәлимдер ки, ачу вакытында мәгълүм булыр; бере — бәһадирдыр ки, сугыш вакытында беленер; бере — дәхи дустыр ки, ихтыяҗ вакытында беленер», — диде.

---

Хәзифәт әл-Гадәви әйтте: «Хәзрәти Гомәр заманында Рум газасында мәгърәкәдә[1] идем. Шәһидләр вә мәҗрухлар арасында агамның углы дәхи бар иде, кулыма су алып, хәятыннан рәмәкъ[2] калмыш исә бирәем, дип эзләп табып, су эчәсең килмәйме, дидем. Бәли, эчәсем килә, дигәч, суны биргәндә, мәҗрухлардан бере дәхи «әһ» дип ятыр. Ибн Гамәм, суны эчмәенчә, ул аһ иткән мәҗрухка бир, дип ишарәт кыйлды. Бирәем, дип, аның янына бардым. Күрдем ки: Һишам бин әл-Гасдыр. Су эчәсең килмәйме, дидем. Бәли, эчәр идем, дисә, янә бер кеше аһ итеп ятыр, аңа бир, дип ишарәт кыйлды. Бирәем дип, аның янына бардым, вафат булмыш күрдем, инде Һишамга эчерәем, дип килдем. Алар дәхи мин килгәнче вафат булмышлардыр», — диде.

---

Янә Исар гаҗибдән бере дәхи будыр. Әбү Мөхәммәд нәкыль кыйлмыштыр ки, Мисыр Каһирәдә булгучы бер мәсҗет җәмигъ казадан янып китмеш иде. Халык: «Нәсара[3] яндырмыштыр», — дип гөман кыйлып, нәсарага махсус бер олуг хан бар иде, аны яндырдылар. Соңыннан тәфтиш кыйлып мәгълүм булды ки, бу эштә нәсараның гөнаһлары юк, имеш. Мисырның валисе шөбһә тоткан кешеләрдән берничәсен тотып, алар гадәденчә берәр кәгазьгә язып, бәгъзесенә таяк, бәгъзесенә катгы йәд[4] вә бәгъзесенә кател дип кәгазьне бөгеп аларга тәкъсим

---

[1] Мәгърәкәдә — сугыш мәйданында.
[2] Рәмәкъ — соңгы сулыш.
[3] Нәсара — христиан.
[4] Катгы йәд — кулны кисү.

итеп бирдерде. «Кәгазьдә ни язылган булса, ул җәзаны иҗра кыйл[1]», — дип, җәлладларга әмер кыйлды. Вә бу хөкемне иҗра кыйлганда, берәүнең кәгазендә кател язылган тугыры килеп: «Әй, әгәр аначыгым булмаса иде, кателдән курыкмас идем», — дип егълаганын янындагы бер егет ишетте ки, аның кәгазенә таяк язылмыш иде, әйтте: «Әй борадәр, минем анам юк, кәгазьләремезне алыштыраек», — дип, кәгазьләрен алыштырып, аның юлына җанын фида кыйлды.

———

Дәхи мәшһүр җумартлардан Кайс бин Сәгыйд дигән кеше бар иде, аңа әйттеләр: «Дөньяда сездән җумартрак булган кешене күргәнең бармы?» — диделәр. Кайс әйтте: «Бәли, күргәнем бар. Беркөн сахраларда бер хатынның чатырына мөсафир булдым. Хатын безне, мәрхаба, дип кабул итеп, чатырына утыртты, ире өйдә юк, имеш. Ире кайтып килгәннән соң, дәрхаль бер тәвә бугазлап тәгам пешерде, боерыңыз, дип, алдымызга куйды.

Иртәсе көн янә бер тәвә бугазлап, тәгам кыйлып зыяфәт итте. Элгәре көн бугазлаган тәвәнең ите һәнүз беткәне юк иде, янә безнең янымызга берничә кеше чакырып зыяфәт итте. Кичәге тәвәнең ите җиткән иде, бу көн янә бер тәвә бугазладың, дидем. Без мөсафирымызга кичәге тәгамны ашатканымыз юк, диде. Көн ягъмурлы булганга күрә, биззарур анда берничә көн калдык, һәркөн бер тәвә бугазлады, һава ачылып, ягъмур туктагач, чатырында яткан җиремездә йөз алтын калдырып, Аллаһы разый булсын, дип, иртә торып киттек. Бераз мәсафәт киткәч, артымыздан, әй, ләим булгучы атлы кемсәнәләр, зыяфәтемнең акчасыны бирмешсез, туктаңыз, дип тавыш ишеткәч, туктадык. Мәгәр чатырымызның иясе, имеш, килеп җитте, бу алтыннарны алыңыз, юкса һәммәңезне сәнчермән, диде, без дәхи биззарур алтыннарны алып юлымызга киттек», — димештер.

———

Хәсән бин Сәһлә исрафта: «Хәер вә мәнфәгать юктыр дигән сүзгә хәердә исраф юктыр», — дип җавап бирмештер, морады изге эшләр ифрат үзрә булса да, сарыф кыйлынган нәрсә исраф булмас, димәктер. Мәзкүр Хәсән бин Сәһләгә беркөн күп мөсафир кунаклар килеп, хәсне әнваг төрле[3] тәкәллефле тәгамнар хәзерләмеш вә бик күп шәмнәр яндырып-яндырып куймыш иде. Мөсафирлардан берсе әйтте: «Исрафта хәер юктыр», — дип, бәгъзе шәмнәрне сүндерде. Хәсән әйтте: «Хәердә исраф юктыр», — димәке белән дәрхаль шәмнәр үзеннән-үзе яна башлады.

---

[1] Иҗра кыйл — башкар.
[2] Хөсне әнваг төрле — төрле сорттагы.

Кадим заманнан калган бер таш табылып, өстендә гарәп лөгате үзрә казылмыш гыйбарәт бар иде. Тәрҗемәсе ошбудыр ки: мөмкин булганда, форсатны күзәт. Ягъни изге эшләр кыйлмакка кодрәтең бар икән, эшлә, кичектермә, зирә адәм зәвал үзрәдер[1], ягъни бай булса, бөлә, терек булса, үлә, соңыннан изгелек бик кыйлыр иде, вакыт булмас. Дөнья эшләреннән вә дөнья дәүләтеннән сиңа килмәгән нәрсә өчен кайгы чикмә, ягъни малым булгач, сарыф итсәм, үзем ач калырмын бугай дигән кебек сүзләрне хәтереңә китермә ки, синең ашамай, эчмәй вә изгелеккә сарыф кыйлмай ифрат үзрә саранлык белән җыйганың гайре кешенең хәзинәсен тутырмактан гыйбарәттер, димеш иде. Ягъни мирас хурларны вә малыңны аласы кешеләрне баетмактыр. Күп кешеләр бардыр ки, кызганып акча җыялар. Әмма бу кызганмаклары хатыннарының ирләре өчендер, ягъни үзеннән соң хатыны, икенче иргә барган тәкъдирдә, иҗтиһад кыйлып, аларга хезмәт итмәкләредер. Вә аларның казганып зәхмәт чигеп җыйганын һич белмәгән бер адәм вафадар хатыным дип йөргән хатыны белән җенбешләнерләр[2] вә рәхәтен татырлар, димәктер.

———

Талхә бин Госман райзыйаллаһу ганһуның игүлек җире бар иде, җиде йөз мең дирһәмгә сатты. Тәмам акчасын алгач, бер кемсәнәгә, иртәгә кадәр хәятта торырмы, тормасмы белмәс икән, өендә асрамак моннан артык мәгърурлык булырмы, дип, дәрхаль һәммәсен фәкыйрь мөселманнарга өләште.

———

Табигыйннәрдән Мәүрак әл-Гаҗли дигән бер кеше бар иде. Бер кешегә ихсан кыйлмак теләсә, бирәсе нәрсәсен бер капчыкка салып, ул кеше оялмасын, мөляхәзәсе[3] белән әүвәл әманәт кыйлыр, ягъни, борадәр бу нәрсә әманәт синдә торсын, янә алырмын, дип, аның кулына биргәннән соң, инде ул нәрсә сиңа хәлял булсын мәгънәсендә язып, аңа ихсан кыйлганын бу тарикъча белдерер иде ки. Бер гаҗәеп хуш мөгамәләдер.

———

Беркөн мәзкүр Талхә разыйаллаһу ганһуның хозурына бер кемсәнә килеп, бер җәһәттән, арамызда якынлык та бар, дип, фәкыйрьлегенә дәва эстәде. Талхә әйтте: «Бу арада фәлән җирдә, фәлән сыйфатта бакчам бардыр. Берәү йөз мең дирһәмгә алмакчы булып сәмәнен бу көн китермәк булды. Сатаем сиңа багышлармын яки эстәсәң ал бакчаны, үзең сатарсың», — дип, җумартлык кыйлмыштыр.

---

[1] Зәвал үзрәдер — юкка чыгадыр.
[2] Җенбешләнерләр — кәеф-сафа корырлар.
[3] Мөляхәзәсе — уе.

---

Бер кемсәнә, Мөгавия хәзрәтләренә килеп: «Арамызда якынлык вә карабәт һәм бардыр, хаҗәтемне әда кыйлсана», — дип, хаҗәтен гарыз кыйлды. Мөгавия разыйаллаһу ганһу әйтте: «Сезләр Корәеш кабиләсеннәнме, сез ки арамызда карабәт бар дип әйтәсез», — диде. Ул кеше әйтте: «Юк, мин үзем Корәештән түгелмен, әмма хәзрәти Адәм әуладыннан булмакымыз җәһәтеннән әйтәмен», — диде. Мөгавия фикерләп торды да: «Бәли, бу нәүгы карабәттер[1] ки, халык бу карабәтне ригая кыйлмаенча, бер-беренә җәфа кыйлырлар. Валлаһи, бу карабәтне ригая кыйлганнарның әүвәле булаем», — дип, ул кешегә күп хәзинә биреп, хаҗәтен әда кыйлды, дип, Әбү Гали әмалисендә билә язмыштыр.

---

Бер кеше үзенең дустына хаҗәтен эстәп килде, ишеген какты. Ханә иясе, чыгып: «Нихәл? Йомышың ни-нәрсәдер?» — диде. Ул кеше әйтте: «Фәлән кадәр бурычым бар иде, бурыч иясе бирәчәгемне сорап дучар кыйлды», — диде. Ул кеше моны ишеткәч тә, гаҗәләт[2] өенә кереп, сандыгын ачып, аның бурычына җитәрлек кадәр акча ул кешегә чыгарып бирде дә ханәсенә егълап керде. Хатыны фикер кыйлды ки: күп бирелде, дип, егъласа кирәк. Әйтте: «Бер хәйлә белән бирмәй җибәрсәң, булмасмы иде?» — диде. Ире әйтте: «Юк, һич тә син уйлаганча түгел, мәгәр бер дустым заруратькә дучар булып та, мин белмәй калдым. Ул килеп сорамас борын, хаҗәтең юкмы, дип истифсар[3] кыйлмадым, дип егълармын»,— диде.

Дәхи Кайс бин Сәгыйд мәшһүр җумартлардан бередер ки. Көннәрдә бер көн мәзкүр Кайс сырхау булып дуслары вә кардәшләре гыйбадәткә килмәгәнлекләреннәнсөаль кыйлды. Әйттеләр: «Барча дус вә карендәшләреңез сезгә бурычлы булганлык сәбәпле, гыйбадәтеңә килергә хәҗаләт[4] кыйлалар», — дигәч, Кайс әйтте: «Ул дусларымның вә карендәшләремнең гыйбадәткә килмәкләренә манигъ булган малны Аллаһы Тәгалә казаландырсын», — диде. Филхаль һәркемнең Кайскә бирәчәге булса, бәхеш вә һибә кыйлды, хәлил булсын, дип нида кыйлдырды. Аннан соң шулкадәр гыйбадәткә күп халык килде ки, хәтта кермәкләренә ханәсенең ишекләре тар булды.

---

Беркөн Габдулла бин, Зөбәер хәзрәти Мөгавиянең мәҗлесенә кереп, шикаять хәл сиякында бер нәзым әйтте. Мөгавия разыйаллаһу ганһу аның масрәфенә мәдар булмак[5] өчен йөз

---

[1] Нәүгы карабәттер — туганлыкның төре.
[2] Гаҗәләт — ашыгыч рәвештә.
[3] Истифсар — сораштырып белү.
[4] Хәҗаләт — оялу.
[5] Мәдар булмак — биредә: ярдәмче булу.

мең дирһәм игъта кыйлмыштыр. Нәзымның мәгънәсе ошбудыр: күп заманнар халыкның мизаҗын вә табигатен тәҗрибә иттем, хәйләкәр вә хыянәт иясеннән гайре кешене күрмәдем вә халыкның бер беренә гадавәтеннән башка дәвасыз авыру күрмәдем, һәрбер нәрсәнең ачылыгын татыдым, сөаль ачылыгыннан башка ачы нәрсә тапмадым, димәктер.

---

Бер кемсәнә фәкыйрь хәлгә төшеп, заруратькә дучар булмак җәһәтеннән, үзенең сәүгән вә мәгъшука җариясен Гомәр бин Габдуллага сатып, акчасын кабыз кыйлып, җарияне тәслим кыйлганнан соң, җариясе, дәхи үзенә гашыйка, имеш, тәхәссерән бу бәетне укыды: «Әй минем гашыйк хуҗам вә сәедем, алган малың, ягъни минем бәһам сиңа гафият булсын, минем кулымда тәхәссер[1] вә иштияктан гайре нәрсә калмады. Моннан соң синең фиракыңнан хәсрәткә рөҗуг итәрмин вә даим кайгы-хәсрәт эчендә калдым ки. Ул күкрәгемдәге озак тәфәккер белән мөнәҗәт итәрмен», — дигәч, җариянең ошбу кыйтгасына күрә саткан хуҗасы дәхи ошбу бәетне укыды: «Әгәр миндә замананың мохтаҗлыгы булмаса иде, сине миннән, мине синнән үлемнән гайре нәрсә аера алмас иде. Хак Тәгаләнең сәламәт вә гафияте сиңа булсын ки, моннан ары арамызда ни зыярәт вә ни васләт фикере калды, мәгәр ки ибн Мөгаммәр ни-нәрсә ирадә кыйлыр[2], ягъни сине сатып алган Гомәр, бәлки, миңа сине һибә кыйлыр яки никях белән сине миңа күрсәтер», — диде. Кайчан ки ошбу хәсрәт шигырьләрен әйтешкәнне ибн Габдулла ишетте, дәрхаль кәрәменнән: «Әй кеше, кавышмакыңызны морад итеп җарияне вә сәмәнене сиңа һибә кыйлдым, ал, кит», — дип җумартлык кыйлды.

---

Әхмәд ибн Тулун солтан күп ингам вә ихсан иясе адәм иде, йортында фәкыйрь-фокара өчен хәзерләнгән тәгамыннан вә биргән нөкуденнән[3] башка һәрбер шәһәргә вә карьяләргә садака өчен мең алтын күндерер иде, бу эшкә Сәлим исемле бер хезмәтчесе тәгаен кыйлынмыш иде. Бу хадим беркөн Әхмәд ибн Тулунга әйтте: «Йә әмир, мин мәэмүр булынмыш, садаканы өләшер өчен шәһәрләрне вә карьяләрне гизмәктә вә ишекләрне какмактамын, бәгъзе капулардан алтын беләзекле куллар, алтын йөзекле бармаклар, кыналы тырнаклар сузыладыр, аларга да бирәемме?» — диде. Әхмәд берзаман таәммел кыйлып торганнан соң: «Һәммәсенә бир, рәд кыйлма», — дип тәнбиһ кыйлды.

---

Бер кемсәнә, дәүләт исламия олугларыннан Гали бин Сөләйман дигән вәзирнең хозурына килеп: «Аллаһы өчен вә пәйгам-

[1] Тәхәссер — хәсрәт.
[2] Ирадә кыйлыр — теләр.
[3] Нөкуденнән — акчадан.

бәр хөрмәтенә мине дошманымның золымлык кулыннан коткар», — дип эстәде. Вәзир әйтте: «Дошманың кемдер, бәян кыйл ки, хәлас итәем», — диде. Ул кемсәнә әйтте: «Дошманым — фәкыйрьлек вә мохтаҗлыктыр», — диде.

Вәзир берзаман тәфәккердән соң мең дирһәм ихсан кыйлмага әмер итте. Ул фәкыйрь кемсәнә алып, хәер-дога кыйлып киткәннән соң, ул кемсәнәне янә үзенә чакырып: «Әй кеше, мин дәхи Аллаһы өчен вә пәйгамбәр хөрмәтенә синнән риҗа итәмен, кайчан ки дошманың катылык белән сиңа килсә, дәрхаль тәзаллем[1] белән миңа кил», — дип, янә ихсан өстенә ихсан кыйлмыштыр.

---

Әгъмәш әйтте: «Бер куем бар иде, сөтен савып, балаларыма эчерер идем. Беркөн бу куем хәстә булып, балаларым ач калды». Бу кыйссаны җумартлардан Хәшмә бин Габдеррахман дигән кемсәнә ишетте. Берничә көнгә чаклы иртә кич килеп: «Куең ни хәл, балаларың ни ашый, куеңа печән ашаттыңмы?» — дип сорашып утырыр иде. Һәр килгәндә намазлыгым астына бер алтын куеп китәр, имеш. Шул кәйфиятчә кулымда өч йөзләп алтын җыелгач, әй кяшки, куемның хәстәлеге озакласа, яхшы буласы икән, дип арзу кыйлыр идем», — димештер.

---

Янә моңар мөнәсәбәт: заманымызда голяма таифәсеннән берәү вафат булып, карья имамларыннан бер имамга яхшы тунын фидия кыйлмышлар икән. Мәзкүр имам, тунны алгач: «Һай, бичара, үлгәнен ишетеп бик кайгырган идем, тунын күргәч сөендем», — димеш.

---

Мәшһүр җумарт Хатәмтайның Сәффанә исемле бер кызы бар иде. Сәффанә кәзалик[2] гарәп җумартларыннан бер җумарт хатын иде. Беркөн атасы: «Әй кызым, бер өйдә ике җумарт булса, мал тәләф булыр. Яки мин җумарт булганда, син саран бул, яки син җумарт булганда, мин саран булаем», — диде. Кызы әйтте: «Әй ата, җумартлыкны мин үзеңнән үгрәндем түгелме?» — дип, атасын илзам кыйлмыштыр[3].

---

Кадим гарәп эчендә мәшһүр булган сараннардан Хәтыйә, вә Әбү әл-Әсүәд, вә Хәмид әл-Әркат, вә Халид бин Сафуан дигән кемсәнәләр булмыштыр. Әмма Хәтыйәнең саранлыгын шөйлә риваять кыйлмышлар ки: беркөн үзенең ишеге төбендә кулына таяк тотып утырыр иде. Бер кеше килеп: «Мин мөсафир-

---

[1] Тәзаллем — хаксызга җәберләнүне белдерү.
[2] Кәзалик — шуның кебек.
[3] Илзам кыйлмыштыр — бәхәстә җиңгән.

мын», — диде. Аңа таягын күрсәтеп: «Мин бу таякны садакачыларның аягына сукмак өчен тотып торырмын», — диде.

---

Зорафадан Хәҗза дигән кемсәнәнең бер саран дусты бар иде. Беркөн Хәҗза дустына барып, янына кермәгә рөхсәт сорады. Әйттеләр: «Ул авырудыр, аны бизгәк тота», — диделәр. Хәҗза әйтте: «Янында утырып тәгам ашаңыз, таки тирләп бизгәге качар», — диде.

Зирәки кеше оялса яки ачигъланса, тирләп китмәк адәмнең мизаҗыннандыр[1]. Вә дустының гаять саранлыгын бәяндыр.

---

Мәшһүр сараннардан бере Гомәр исемле кеше берзаман, үзенә кәуланж[2] зәхмәте пәйда булып, табиб әмере белән бәдәнен майлаганда, тәненнән агып төшкән майны хезмәтчесенә: «Ал шул аккан майны, кандилгә[3] ярар», — диде. Әмма саранлыгына күрә, коймак яки ботка пешерергә ярар, димәгәне гаҗәптер.

---

Мәрван әйтте: «Беркөн хәлифә миңа йөз мең дирһәм бәхеш итте, ул дирһәмнәрне санаганның соңында бер дирһәм артык чыкты, ул бер дирһәмгә ит алып ашадым, гомеремдә бу вакыт сәвенгән кебек сәвенгәнем юк иде», — диде.

---

Мәзкүр Мәрван беркөн бер дирһәмлек ит алып, пешәргә казанына салгач, тәгам ашарга дип, бер дустыннан чакыра килделәр. Мәрван дәрхаль пешә башлаган итне казаныннан алып, яңадан итчегә берничә ноксаны белән чыгарып сатты. Итче зарфадан иде, бу пешәр-пешмәс итне кибет алдына асып: «Әй адәмиләр, бу Мәрван итедер, караңыз», — дип нида кыйлыр иде.

---

Мәрү халкы дәхи саранлык белән мәшһүрләр иде. Хәтта бер-бере белән юлдаш булып юлга чыксалар, юлда бер мәнзилгә туктап, тәгам ашаганда, һәрберсе үзенең юлга алган бер кисәк итен пешереп ашарлар иде. Иттифак белән казан асып, ут ягып, һәр каюсы үзенең итенә җеп тагып, ит пешкәндә як-яктан үзләренең итләрен тотып торырлар иде. Итләре пешкәч, казаннан алып, ялгыз-ялгыз утырып ашарлар иде, шурпасын дәхи бәрабәр тәкъсим кыйлырлар[4] иде.

---

Шагыйрьләрдән Дәгъбаль дигән кемсәнә хикәят кыйлмыштыр ки: «Беркөн Сәһелнең ханәсенә бармыш идем, ни эшләр

---

[1] Мизаҗыннандыр — холкыннандыр.
[2] Кәуланж — авыруның бер төре.
[3] Кандилгә — шәмгә.
[4] Тәкъсим кыйлырлар — бүлерләр.

икән дип, бик озак ачлыгыннан җаны чыгарлык булганга кадәр утырдым, күрдем ки; мин һәнүз китмәймен, начар вә нәгыйлаҗ хезмәтчесенә, әй фәлән, тәгамымызны ник китермәйсең, дип, гүяки зарыгып торган мәнзилендә кычкырды. Хезмәтчесе бер табак эчендә пешкән әтәч китереп, алдына куйды. Сәһел, әтәчкә карап, бераз тәфәккердән соң, әтәчнең башын кая куйдың, диде. Хезмәтче әйтте, башын ташладым. Сәһел әйтте, валлаһи, мин аякларын ташларга да разый түгел икән, башын ташлаганга кайчан разый булаем, тәрбиям бушка китте, әтәчнең башында никадәр хасыять бардыр, аны белмәсмесең, сәгатьсез адәм вакытны кайдан белер, диде. Ягъни әтәч кычкырып, адәмгә вакытны белдерәдер, башы булмаса, ничек кычкырыр вә дәхи тәбәррек[1] булган кикрик баштадыр, әтәчнең күзе белән зарбе мәсәл кыйлырлар, саф шәрабны әтәч күзенә бинзәтеп «шәрабы кәгайнед-дик[2]» диерләр, кәлбә авыруына әтәч миен истигъмаль кыйлырлар, ми дәхи баштадыр, вә башта ничә төрле хасыять бардыр, син мине башын ашамас фараз кыйлып, кайда ташладың, бар алып китер, диде. Хезмәтче әйтте: «Мин ташлаган җиремне оныттым», — дип ямин итте. Сәһел әйтте: «Мин кайда ташлаганыңны беләмен, син аны корсагыңа ташладың», — диде һәм бәддога кыйлды», — диде.

———

Саранңардан бер кемсәнәнең күкрәгенә нәзлә итеп ютәл тотмыш икән. Бадам сөте файда бирер, дип мәслихәт кыйлдылар. Бәһасе кыйммәт булыр, дип, ютәленә сабыр итмәкне тәрҗих кыйлып[3], вә берничә көннәр сабыр итте. Очсыз дару табылмас микән дип торганда, дусларыннан берсе, көрпә суы күкрәккә файдалы, дип, дәляләт кыйлганнан соң, көрпә кайнатып эчте. Күкрәге ачылды, ютәле басылды. Кайчан ки ашамак тәгамын янына китергәндә, хатынына әйтте: «Моны куеп тор, кич ашармыз, син дәхи моннан ары өемездә кибәк пешер, зирәки кибәк суы минем ютәлемне бетерде», — диде.

———

Бер бик хәрис вә ләим[4] кеше бар иде. Бөтен гомере буенча хәрислек белән ашамай-эчмәй күп акча хасыйл итте. Акчасын барын да алтынга әйләндереп, бер җиргә күмеп куйды. Аннан соң һәрбер кулына төшкән алтынны шул алтыннары янына илтеп салыр иде. Вә аның гакыл вә мәгърифәт иясе бер углы бар иде. Егет булып, гыйлем бабыннан өлеш алды, әмма дусларына катышасы килә, акча юк. Акчасыз, фәкыйрь булганга күрә, игътибар кыйлмайлар. Бу угыл хафа булып йөрде: атасының алтыннары бар, ничек кулга төшермәгә кирәк. Беркөн са-

---

[1] Тәбәррек — яхшыга юрау.
[2] Кәгайнед-дик — әтәч күзе кебек.
[3] Тәрҗих кыйлып — өстен күреп.
[4] Хәрис вә ләим — комсыз һәм саран.

галап торды: атасы кулына төшкән алтынны янә шул алтыннар янына салмага китте. Бу егет атасын күрер-күрмәс артыннан барып, кайда куйганын карап торды. Атасы алтыннарны куеп кайткач, бер капчыкка таш тутырды да, шул җиргә барып, алтыннарны ачып алды, урынына таш салып куйды. Кайтты. Бер-бер хөкем булгыйнча, алтыннарны бер җиргә дә сарыф кыйлмады. Берничә заманнан соң атасы янә кулына төшкән алтынны куймага шул җиргә барды. Ачып күрде: алтын урынында ташлар ятыр, хәйран булды. Бераз фикерләп торды да: «Бу һич кем эше түгелдер, мәгәр углым эшедер», — дип, углын чакырып сорады. «Фәлән җирдәге алтыннарны син алдыңмы, углым?» — диде. Углы әйтте: «Әй мәрхәмәтле атам, мин һаман алтыннарың барын да белгәнем юк», — диде. Ахыр, атасы тыгызлагач, икърар кыйлды: «Алдым, әткәй, ләкин мин урынына салып куйдым», — диде. Атасы әйтте: «Бәли, урынына салып куйгансың да, ләкин таш тутырып куйгансың», — диде. Углы әйтте: «Әй җумарт атам, алтын кирәк — ашамак-эчмәк, кимәк, рәхәтләнмәк өчен, әмма җир астында ятмак өчен таш та ярый, балчык та ярый», — диде. Атасы: «Бәрәкаллаһ, углым, Аллаһы Тәгалә һиммәтеңне арттырсын, бу фәһем вә мәгърифәтең өчен гафу кыйлдым, догачы бул», — диде.

———

Көннәрдә бер көн голяма, вә фөкаһә[1], вә заһидлардан күп адәмнәр Рабига Гадәвия янына җыелмышлар иде. Мәҗлестә дөньяны зәм кыйлдылар. Рабига тик тыңлап торды. Алар дөньяны яманлап туктагач, Рабига әйтте: «Берәү бер нәрсәгә мәхәббәт итсә, ул нәрсәне күп зикер кыйлыр, кирәк мәдех белән вә кирәк зәм белән булсын. Әгәр калебеңездә дөнья мәхәббәте булмаса, ник зикер кыйласыз?» — диде.

———

Бер хаким бер кешене гөнаһына күрә җәза бирмәгә әмер кыйлды. Сугарга дип, бер баганага бәйләделәр. Ул гөнаһлы кеше әйтте: «Ходай өчен, мине бу баганадан чишеп, икенче баганага бәйләсәңез лә», — диде. «Ник алай?» — диделәр. Ул кеше әйтте: «Балта суккыйнча, түнгәк ял итәдер, димешләр, шул арада шатлык өмид итәмен», — диде. Аннан чиштеләр, икенче җиргә бәйләделәр. Ул арада, ул хакимне газел кыйлынды[2], дип хәбәр килде. Хәзинә малын аннан моталәбә кыйлдылар[3], тәләф кыйлган, имеш. Бу кеше урынына ул хакимне бәйләделәр.

———

Дауд галәйһиссәлам көннәрдә бер көн тауларда йөргәндә, бер мәгарә күрде. «Бу ничек мәгарә?» — дип, эченә керде. Күрде:

---

[1] Фөкаһә — фикъһедән белемлеләр.
[2] Газел кыйлынды — урыныннан төшерелде.
[3] Моталәбә кыйлдылар — тиешлесен таләп иттеләр.

бер үлгән кеше ятыр. Башы очында бер язылмыш такта бар, укып күрде ки: «Мин фәлән бин фәлән. Дөньяда мең ел гомер сөрдем, мең кала төзедем, мең бакирә кыз алдым. Мең-мең гаскәрне сугышып җиндем, ниһаятьсез мал сарыф кыйлдым, рәхәт булаем дип, хәтеремне хуш тоттым. Бу көн янә кичәгедән рәхәтрәк кичерәем дип, артыграк акча сарыф кыйлдым, һәнүз кичәге эш күңелемнән чыкмады. Тәгам вә шәраб савытларым алтыннан иде. Әнә бар да калды, буш куллай киттем», — дип, табутыннан кулын чыгарып куйдырмыш иде.

---

Кадим заманда бер дәүләтле кеше бар иде. Үзенең гомерен йөз ел фараз кыйлып, һәр көнгә йөз тәнкә хәзерләп куйды, үзенең ризыгы өчен гамьйимәде, бәгъзе вакытта үзенең хисаплап куйганыннан һәм артыграк сарыф кыйлды. Ахыр хисаплаган акчасы бетте. Бик нәфис алтын вә җәваһир белән мөзәйян[1] Коръәннәре вә китаплары бар иде, аларны сата башлады, алар һәр бетте. Ахыр үзе байга керде. Ул белмәде ки, бәндәнең тәдбире Аллаһының тәкъдиреннән узамы.

---

Әбү Мәган әйтте ки: «Мин бер кешегә барып кердем. Бик һәйбәт алтын белән нәкышләгән диванда ятыр, алдында алтын шәмгыданнарда[2] нәфис, хуш исле шәмгылар янып торыр. Астына җәйгән түшәкләре атлас та җефәк. Ничә коллар вә кәнизәкләр хезмәтендә тайяр[3] торырлар... Күп заман һәм үтмәде, ул кешене күрдем, садака соранып йөрер», — диде.

---

Малик бин Динар хәзрәтләре хикәят кыйлмыштыр ки: «Мин бер шәһәргә барып кердем. Табыллар сугылып, мусыйкалар[4] уйнап, бәйрәм итеп гөрләп торырлар. Мәганиләре нәгъмәләрен чалып, гүяндәләре шигырьләрен әйтеп, шаһ бигам тамаша вә тәфәррәждәдер. Шигырьләренең мәзмуны[5] бу иде:

Бибалары таштандыр,
Хәсрәтләре качкандыр.
Килгән кунаклар өчен
Капкаларын ачкандыр.

Аннан узып киттем. Берничә заманнан соң юлым янә шул җиргә тугыры килде. Күрдем: элгәреге сарайлар вә халкы — һичберсе юк. Бу хәбәрне кемнән сораем? дип торганда, бер карчыкны күрдем. Янына бардым, сораштым: «Мондагы һәйбәт бинаһәр вә сарайлар кая китте?» — дидем. Карчык әйтте:

---

[1] Мөзәйян — бизәкләнгән.
[2] Шәмгыданнарда — шәмдәлләрдә.
[3] Тайяр — хәзер, әзер .
[4] Мусыйкалар — музыкалар.
[5] Мәзмуны — эчтәлеге.

«Замана шулай карарсыз нәрсәдер, дәүләтнең зәвале житеп, һәммәсе һәбаән мәнсүра[1] булды», — диде дә китте.

———

Пәйгамбәр галәйһиссәламнең Газаба исемендә бер тәвәсе бар иде, чабышканда һичбер тәвә аннан уза алмас иде. Беркөн бер гарәп кагуд тәвә белән килеп, пәйгамбәр галәйһиссәламнән изен алып чабыштылар. Гарәпнең кагуд тәвәсе узды, моңар сәхабәләр хафа булдылар. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Дөньяда күбрәк Аллаһы Тәгаләнең гадәте вә хикмәте шуның үзәренәдер ки, бервакытны бер нәрсәне күтәреп, бервакытны аны төшерер димәктер ки, дөньядан әгъразга тәнбиһ вә тәвазыйглыкка тәргыйбдер.»[2]

———

Һәмадан шәһәрендә бер дөнья күргән адәмнән хикәят кыйлынмыштыр ки: «Жаһилият заманында шәһәремез әһеле бер хосус өчен мине Хәмир падишаһларыннан Дуәлкәллаг дигән падишаһка һәдияләр белән илче итеп җибәрмешләр иде. Шәһәренә барып, молякат була алмай[3] бер ай үтте, кәмаль горурлыгыннан игътибар кыйлмады. Бер айдан соң мине сараена китерделәр. Мәслихәтемне гарыз кыйлдым, эшемне бетереп кайттым. Бер заманнан соң күрдем ки: дәүләте китеп, Хомыс шәһәренә күчмеш. Бер дирһәмлек кәбаб алып, атының өстендә ашап утырыр вә инкыйлаб заманнан шикаять кыйлып, ошбу бәетләрне укыр иде: «Дөнья ки, бу хәл белән моттәсыйф булып, мин бу дөньядан бәла вә шиддәткә[4] дучар булдым, вә дөньяның тар тереклегенә мөбтәля булдым. Дөньяның хәле шөйләдер ки, бер кешенең иртә белән тереклеге кәеф-сафада булса, ахшам булганда дөнья аңа явызлык касәсен сунар, имеш ки. Мөкаддәмдә дөньяда кемнең дәүләте вә бәхете вә тәхете артыграктыр дисәләр, мисал итеп мине күрсәтерләр иде. Инде мине фәләк[5] бу хәлгә куйды, гыйбрәт ал», — димәктер.

———

Камустан нәкыль кыйлынмыш бер хикәяттер ки: Ямин вилаятендә олуг сил вакыйг булып, силдән соң бер кабер ачылмыш иде, муенында энҗедән тезелмеш жиде хәситәсе вә беләкләрендә вә тубыкларында алтын белән морассаг беләзекләр вә бармакларында кыйммәтле җәваһирдән йөзекләр бер хатын җеназасы зоһур итте. Вә башы очында кыйммәтле затлар тулы бер сандык вә бер такта бар иде, өстенә язылмыш: «Мин

---

[1] Һәбаән мәнсүра — һавага очкан тузан.
[2] Әгъразга тәнбиһ вә тәвазыйглыкка тәргыйбдер — уйларга кисәтү тыйнаклыкка җәлеп итүдер.
[3] Молякат була алмай — очраша алмый.
[4] Шиддәткә — кансызлыкка.
[5] Фәләк — язмыш, тәкъдир.

Хәмир әмирләреннән Зи Шәфәрнең кызы Таҗә идем. Кыхытлык вакыйг булып, малымны җыеп, газиз Мисыр булгучы Йосыф галәйһиссәламгә зәхирәне алмага җибәрдем. Ул кеше кайтмады. Әтбагымнан берен дәхи бер мәд көмеш биреп, урынына бер мәд он алмак өчен, әтрафка күндердем. Он алыр җир тапмай кайтты. Янә бер мәд алтын күндердем, янә, зәхирән, тапмай килделәр. Янә энҗеләремне күндердем, янә өмидсез кайттылар. Мин ул энҗеләремне, он иттереп, камыр ясаттым. Ашадым, ләкин ачлык гыйлләтен китәрмәде. Ахыр, бу кадәр малга малик икән, ачлыктан тәләф булдым. Бу кыйссамны ишеткәннәрдән миңа тәрәххем[1] итмәкләре риҗа кыйлыныр. Гаҗәба, кайсы хатындыр ки, ошбу хөлләләрем[2] вә зиннәтләрем кебек хөлләләр тагынып, минем сурәтем үзә тәләф булмамыштыр».

---

Бер назыйм хикәят кыйлды ки, бер хатын бер карт кешегә (ягъни миңа): «Моның ни хәле бардыр ки, сакалы вә җисеме тәгаййер[3] итмеш, сакалы агармыш вә бәдәненә зәгыйфьлек килмеш?» — диде. Мин дәхи: «Әй хатын, адәмнәрдән миңа берәүне табып китер ки, вакыты даимән сафада булсын, һичбер хәленә вә бәдәненә вә сакалына тәгаййер килмәмеш булсын. Хәлбуки дөньяда һичкемгә бер мосыйбәт[4] ирешмәенчә булмас», — дидем.

---

Бәни Исраилдән бер хатынның бер тавыгы бар иде, бер тавыктан гайре нәрсәгә малик түгел иде. Һәркөн шул тавыкның йомыркасы белән ризыкланыр иде. Беркөн бер угры килеп, ул тавыкны угырлап китте. Ул хатын, бичара, ач калып, кайгы-хәсрәттә икән. Ләкин сабыр вә тәхәммәл кыйлып, угрыга бер сүз димәенчә, Аллаһыга тапшырдым, дип торды. Кайчан ки бу угры тавыкны бугазлап, йонын йолыкканда тавыкның йоннары Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән тәмам угрының йөзенә ябышты. Угры йоннарны йөзеннән төшерергә никадәр иҗтиһад кыйлса да, кодрәте булмаенча, начар бәни Исраилнең голямасыннан бер галимгә барып, үзенең тавык угырлап, бу бәлагә мөбтәля булганын бәян кыйлды вә мәддәд теләде. Ул галим әйтте: «Синең бу дәртеңә ул хатынның бәддогасыннан гайре дәрман белмәймән, инде ул хатынның бәддогасын алмага бер тәдбир кыйл», — дип җибәрде. Угры дәхи филхаль хатынны ачигъландырып бәддога кыйлдырмага бер адәмне күндерде. Ул адәм, хатынга килеп, бер вәҗһе тәгълим[5]: «Әй хатын,

---

[1] Тәрәххем — ачыну, кызгану.
[2] Хөлләләрем — өс киеменең бер төре.
[3] Тәгаййер — үзгәрү.
[4] Мосыйбәт — кайгы, хәсрәт.
[5] Вәҗһе тәгълим — ачыклар өчен.

тавыгыңа ни булды?» — диде. Хатын әйтте: «Тавыгымны угырладылар», — диде. Ул адәм, кайгырган булып: «Һи бәдбәхет угры сиңа җәфа кыйлган, имеш», — диде. Әмма хатын, алай итте ләбаса, дип янә бәддога кыйлмады. Ул адәм янә тәкрар[1]: «Һи, сиңа ни казадыр, һай инсафсыз, синең кебек бичарага зарар итептер, йомыркасы белән тәрбияләнеп торган тавыгыңны тәләф итмеш. Бу ни җәфадыр, сине ачлыкка мөбтәля итмеш», — дип, күп сүзләр әйтә торгач, хатынны ачигъландырды.

Бәс, хатын моңар сабыр вә тәхәммел кыйла алмаенча бәддога кыйлды, хатынның бәддогасы мәкъбуль булып, угрының йөзеннән йоннар коелды. Аннан соң ул галимнән сорадылар: «Моның серен син кайдан белдең, моның хикмәте нидер?» — диделәр. Галим әйтте: «Ул хатын әүвәл башта сабыр итеп, бәддога кыйлмаенча, Аллаһы Тәгаләдән носрәт эстәмеш иде вә Аллаһы Тәгаләгә тапшырдым, димеш иде. Аллаһы Тәгалә ул сурәткә куйды, кайчан ки хатын бәддога кыйлды, Аллаһы Тәгалә ул угрының гокубәтен ахирәткә калдырып, дөньяда бәладән коткарды, йөзеннән йоннар коелды», — диде.

———

Бер кемсәнәне бер хатасы өчен камчы сугалар иде. Ләкин ул кемсәнә, «аһ-ваһ» итмәенчә, сөкүт вә сабыр итеп торыр. Мәшаихтан бер кемсәнә бу хәлне күреп, ул сугылмыш кешегә: «Әй адәм, ошбу камчы сукмак җаныңны ачытмасмы ки, сөкүт вә сабыр итәрсең?» — диде. Ул кеше гайрәтле вә сабырлы кемсәнә иде, әйтте: «Бәли, ачытыр вә авырттырыр. Ләкин ошбунда торган халык арасында бер дустым бардыр ки, мине бәһадир вә куәтле дип игътикад кыйлып торыр иде. Ул хәзер дә мине ни хәлдә икәнемне күреп торыр икән, аның янында фөрьяд итсәм, минем хакымда аның хөсне заны батыйль булып[2], минем дәхи абруем түгелер вә минем хакымда җәбин дип сүи занга китәр дип куркып сабыр вә тәхәммел итәрмен», — диде.

———

Хәсән Бәсри хәзрәтләре әйтте: «Васит шәһәрендә торган заманымда кабердән торып чыккан кебек бер зәгыйфь вә арык кемсәнәгә юлыктым, әйттем: «Әй кемсәнә, ни-нәрсә сине бу бәлагә төшерде?» — дидем. Ул кемсәнә әйтте: «Әман серемне вә хәлемне халыкка фаш итмә. Өч елдыр ки тарлык хәлендә вә кабахәт тереклектә, вә Хәҗҗаҗның кабахәт хибесендә идем, вә мөттасил[3] бу хәлдә сабыр вә тәхәммел итеп бер сүз сөйләмәдем. Кичәге көн минем белән бергә мәхбүс булган кемсәнәләрдән берничәсен хибестән чыгарып, муеннарын ордылар вә зиндан хезмәтчеләреннән иртәгә синең дә муеныңны

---

[1] Тәкрар — кабат.
[2] Хөсне заны батыйль булып — уй-фикере бозылып.
[3] Мөттасил — өзлексез.

орачаклардыр, дип хәбәр ишеткәнемнән соң, миңа шулкадәр каты хәл гарыз булып, алиһи бу катылык галәбә[1] кыйлды вә сабыр булмактан китте дип тәмамин җәнабе Хак Тәгаләгә нияз кыйлдым. Төннең күбрәге үтте, миңа, бер халәт гарыз булып, йоклар-йокламаста бер адәм заһир булды, тор, ике рәкәгать намаз укы, ошбу мин үгрәткән дога белән Аллаһы Тәгаләгә ялвар, дип, ошбу доганы укыды: әй җәмигъ әшяны белгүче вә әй җәмигъ мәхлүкатны гыйлем әзәлисе мохит булгучы пәрвәрдикяр[2], яшерен вә мәстүр булган эшләрнең ниһаятен белгүчесең вә бәндәләренңнең җәмигъ ниятләрен, вә хәтерләрен, вә әхвәлләрен белгүчесең, вә газамәт шаэненең минзил әднадә булгучы бәндәләреңә лотыф вә рәхмәт вә ихсаның хамидыр вә дәрәҗәи кәбир вә голүең белән һәрнәрсәгә галисән, әй заһир вә мөгайян булгучы зөлҗәлал вәлкибрия, йә миңа игасә вә иганә кыйл, вә әсирлек бауларын чиш, зарар вә катылыгымны китәр, зирә сабырым вә тәхәммелем бетте, юк булды, димәктер. Бәс, мин дәхи торып таһарәт алдым, ике рәкәгать намаз кыйлып, мәзкүр ишеткән догамны тәмам укып бетергән заманымда аякларымдагы богаулар чишелеп төште, вә зинданның ишекләренә карадым. Ишек ачык. Торып чыктым. Һичкем миңа мөгарәза кыйлмады вә һичкем мине маныйг булмады. Бу җиргә килдем, инде мин таликы әр-рәхман, ягъни азат кәрдәи милке. Моннан мин ки Хак Тәгалә сабырым сәбәпле миңа шатлык биреп ул тарлыктан хәлас кыйлды», — дип, минем белән исәнләшеп, Хиҗаз тарафына газимәт кыйлды», — диде.

Равиләрдән бер кемсәнә риваять кыйлмыштыр ки: «Бер сәфәремдә Дәфар дигән бер шәһәргә кердем, вәйран вә харап җирләрене гыйбрәт йөзеннән карап йөргән вакытымда бер иске сарайның ишегендә күрдем, язылмыштыр: «Әй өстеңә бер-берсе артыннан кайгылар вә фикерләр ягъмур кебек явып, гыйбрәт алырдай көннәр вә бәлаләр хәленңне тәгаййер иткән мөбтәля кемсәнә! Зарбе мәсәл: мәзкүр булгучы алда зикер кыйлыначак сүзләрне ишетмәдеңме ки, һәрбер катылык соңында сәламәтлек бар, димешләр. Аллаһы Тәгалә кайда вә кодрәте кайдадыр, ягъни фагыйл хәкыйкый Аллаһы Тәгаләдер вә тәкъдир мөбрәм тәхәлләф итмәс, әлбәттә, вакыйг булыр, җәзәгъ-фәзәгъ кыйлмакынның асылы юктыр. Һаман син, катылыклар вә бәлаләр зоһур иткәндә, җәзәгъ-фәзәгъ итмә, Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кыйлып, сабыр ит ки, сабыр иткәннәр тиз заман зафәр таптылар вә сафага ирештеләр. Һәрбер катылык соңында җиңеллек килер вә һәрбер читен күренгән эшнең ахыры зафәрдер» димәктер».

---

[1] Галәбә — җиңү.

[2] Мөхикъ булгучы пәрвәрдикяр — хаклык ягында торучы, тудыручы, яратучы.

Дәүләт Габбасия әмирләреннән Әбү Әюб дигән кемсәнә унбиш ел микъдары хибестә ятып, сабыр вә тәхәммел кыйлмага такате булмаенча, бәгъзе дусларына дөнья хәлләреннән шикаятьнамә язып җибәрмеш иде. Ул кеше Әбү Әюбкә җавабән ошбу кыйтганы язып күндерде ки: «Әй Әбү Әюб, катылыкларга вә бәлаләргә мөбтәля кемсәнә сабыр иткән шикелле, син һәм сабыр ит, синең кебек дөньяны астын өстенә китергән гакыл иясе катылыкларга сабыр итмәсә, гаҗиз булса, инде кем сабыр итәр вә ул бәла вә катылыкларны сиңа биргән Аллаһы Тәгалә дәхи синнән бу бәлаләрне китәрмәгә кадирдыр. Син һаман сабыр ит, зирә тәхкыйк сабырлык рәхәт китерер», — димәктер. Әбү Әюб, бу тәслия бәетләрен алганнан соң, дустына җавабән ошбу кыйтганы язды: «Әй дустым, мине сабыр кыйлдырдың вә миңа вәгазь вә нәсыйхәт кыйлдың. Мин һәм күңелем белән сабыр итмәгә касд кыйлдым, рәхәткә ирешермен, бәла китеп рәхәт килмәкенә якыйным барлык сәбәпле, инде җәзәгъ вә фәзәгъне куйдым, филхәкыйкати мөбтәля кыйлгучы Аллаһы Тәгаләдер, үзенең лотфы белән бәлаләрне кәшеф вә дәфегъ кыйлыр димәктер. Филвакыйг күп заман үтмәде, Әбү Әюб хибестән хәлас булды.

———

Бер галим сазәндә[1] бер галимә наихәне никяхлады. Ул сазәндә наихәнең Аллаһы Тәгаләдән ризык теләп, дога кыйлганын ишетте. Әйтте: «Әй хатын, ризык өчен фикер итмә, кайгырма, чөнки дөнья йә шатлыктыр, йә кайгыдыр, ягъни бу икедән хали булмас. Инде икемез дә дөньяның ике тарафын алдык, ягъни бу ике матдәне җәмгы кыйлдык: сөрүр вә шатлык вакыйг булса, мине чакырырлар; кайгы вә үлем зоһур итсә, сине чакырырлар; дөньяда кайгы булса да, безгә файда, шатлык булса да, безгә файда; безнең һөнәрләремез кәсепсез тормас, бу җәһәттән Аллаһы Тәгалә хәзрәте ризыкымызны мөтәссыйл күндереп торыр», — дип, хәкиманә[2] хитап кыйлмыштыр.

———

Муса галәйһиссәлам заманында тагать вә гыйбадәт белән мәшһүр бер заһид бар иде, бу заһидны Муса галәйһиссәлам белер, имеш. Беркөн Муса галәйһиссәлам бу заһидның мәкаменнән узганда күрде: заһидны ерткычлар парә-парә итеп ботарлап ташламышлар, сөякләре җирдә таркалып ятыр. Муса галәйһиссәлам, моны күреп: «Вә әгъҗәба[3], илаһи бу заһид вә изге бәндәңне бу бәла белән мөбтәля кыйлмышсың, ни хикмәт», — дип, мөнәҗәт кыйлды. Аллаһы Тәгалә тарафыннан вәхи килде ки: «Әй Муса, ул бәндәм, илаһи хәзрәтеңә ирешсәм иде, ләкин изге

---

[1] Сазәндә — саз уйнаучы музыкант.
[2] Хәкиманә — хәкимнәрчә.
[3] Әгъҗәба — гаҗәпнең гаҗәбе.

гамәлем сәбәпле васыйл булмасам[1] иде дип, нияз кыйлмыш иде, ул матлубенә ирешмәк өчен хикмәте алиһия аның бу кәйфияттә ибтилясын икътиза итте», — диде.

---

Вәлид бин Йәзиднең дәргяһенә бер мәслихәт өчен Габәс кабиләсеннән берничә адәм килмешләр иде. Араларында бер әгъма[2] карт кеше бар иде, ул картның хәл-әхвәлен вә гамасыннан[3] сөаль кыйлдылар. Карт әйтте: «Кабиләмездә миннән малдар вә дәүләтле кемсәнә юк иде. Бер кичә сахрада малларым белән төн кичермеш идем, нагяһ бер олуг сил пәйда булып, җәмигъ малларым вә гыялем[4] вә әүладым һәлак булды, мәҗмугысын су басып тәләф кыйлды[5]. Мәгәр бер кечкенә углым тәвә өстендә, имеш, тәвә качып, кечкенә балам котылмыш иде, ләкин тәвәм качып барганда, углым дәхи тәвә өстеннән төшеп калмыш икән. Һич аннан хәбәрем юк иде, тәвәм артыннан барганда, кечкенә баламның тавышын ишеттем. Барып карасам: углымны бер бүре җәрәхәтләмеш, ашап ятыр, ул углым дәхи билә тәләф булды. Аннан дәхи мәэюс булганым хәлдә тәвәм артына төштем, тәвәмне тотаем дип барган идем, аяклары белән тибеп, ике күземне бердән чыгарды. Вәлхасыйл, кичә сәламәт вә малдар вә әһле гыял идем, таң аткыйнча малсыз, әүладсыз, күзсез калдым», — диде.

---

Мәнкульдер ки, Мәһди хәлифә бер кичне йокысыннан бик куркып уянды, филхаль сахибе шортасын[6] чакырып әйтте: «Тиз бар, зинданда мәхбүс булган бер шәриф хөсәини бардыр, аны хибестән чыгарып, ошбу мең алтынны аңа тапшыр вә тәкрим белән сөаль ит ки, монда калмакны ихтыярмы итәр яки үзе теләгән җиргә китмәгәме ихтыяр итәр», — дип, зинданга җибәрде. Сахибе шорта дәрхаль зинданга барып, ул шәрифне күрде: тәмам кибеп, саргаеп бетмеш, хибестән чыгарып, мең алтынны аңа тапшырды вә хәлифә әйткән сүзләрне әйтте. Бәс, шәриф үзенең шәһәренә китмәк тарафын тәрҗих кыйлды. Сахибе шорта ат хәзерләп, ул шәриф атка менгән вакытта: «Әй шәриф, хәлифә хәзрәтләренең азат кыйлмакына сәбәп ни икәнен беләсеңме?» — дип сорады. Шәриф әйтте: «Әй, валлаһи, бу кичтә төшемдә Рәсүл әкрәм саллаллаһу галәйһиссәламне күрдем вә миңа әйтте, әй угланчыгым, сиңа золым кыйлдылармы, диде. Бәли, йә Рәсүлуллаһ, дидем. Рәсүлуллаһ галәйһиссәлам әйтте, тор, ике рәкәгать намаз кыйл вә намаздан соң ошбу дога укы, диде.

---

[1] Васыйл булмасам — ирешмәсәм.
[2] Әгъма — сукыр.
[3] Гамасыннан — сукырлыгыннан.
[4] Гыялем — гаиләм.
[5] Тәләф кыйлды — бетерде, әрәм-шәрәм итте.
[6] Шортасын — бу урында: сакчысын.

Мин дәхи Рәсүлуллаһның фәрманына имтисәлән намаз укып вә дога кыйлып торганда, син килеп мине чакырдың», — диде. Сахибе шорта димештер ки: «Бу эшләрне әда кыйлып, Мәһди хәлифә янына килдем, шәрифнең сүзен нәкыль кыйлганымнан соң, хәлифә әйтте, раст әйтә, зирә мин төшемдә күрдем ки, кулына бер тимер чукмар алып, бер зинҗи зоһур итте. Үзәремә һөҗүм итеп, тиз шәриф хөсәинине хибестән чыгар вә илля сине сугып һәлак итәрмен, диде. Йокымнан куркып уяндым, аннан соң аны хибестән чыгармай торып, күземә йокы кермәде», — диде.

---

Исхак бин Ибраһим хикәят кыйлмыштыр ки: «Бер кичә төшемдә Рәсүлуллаһны күрдем, вә миңа, мәхбүсне азат кыйл, дип боерды. Йокымнан курку белән уянып, хадимнәремне чакырдым, шәмнәрне яндырыңыз, дип әмер кыйлдым. Шәмнәрне яндырдылар вә рәсем үзрә һәркөн зинданнан килгән дәфтәрне карап күрдем: бер кеше кател белән хөкем ителеп, зинданга салынмыш һәм икърары мөҗибенчә[1], кателгә мөстәхак булмыш. Шул сәгать ул адәмне чакыртып, хозурыма китерттем, куркып-тетрәп яныма килде. Тугыры сөйләсәң, сине азат кыйлырмын, тугыры сөйлә, дидем. Ул дәхи, билгайни вәррәэс[2], дип, эшнең хакыйкатен сөйләп әйтте, моннан берничә кич мөкаддәм минем кебек фисык вә фәсад юлында йөрүче берничә яраннарым белән идек, кувваdемез булгучы гаҗүзә[3] иҗраи мәзакымыз өчен безгә бер гүзәл хатын алып килде. Ул хатын безнең, мәканемезгә кергәннән соң, хәйран булып: «Аллаһ, Аллаһ, Аллаһ! — дип, фөрьяд кыйла башлады, — вә бу гаҗүзә хатын мине алдап китерде. — Бу ханәдә изге хатыннардан бераз хатыннар бардыр, зыярәт кыйл вә догаларыны ал, — дип, мине бу җиргә алып килде. — Мин шәрифәмен, бабам Рәсүл әкрам, вә анам Фатыйма, вә атам Хәсән бин Галидер, аларның намусыны хифыз ит», — диде. Мин дәхи, ул хатынның дамин гыйсмәте ертылмасын дип, гайрәт итеп, ул хатынны сакламага касд кыйлдым. Арамыздан бер исерек хәбис торып кабахәт эшкә шөруг[4] кыйлмага ният иткәндә, ул хатынны моннан хәлас кыйлмак өчен ул хәбисне үтермәктән башка чара тапмаенча, чарасыз орып үтердем. Ул мәзкүрә дәхи сәламәтемә дога кыйлды. Ханәмездәге тавыш-гауганы күршеләремез ишетеп, ханәмезгә басып керделәр, һәнүз ул хәбиснең мордар каны агып ятканын вә кулда канлы пычакны күрделәр. Мине тотып хозурыңа китерделәр, инде эшемнең хакыйкате будыр, диде. Бәс, Исхак бин Ибраһим әйт-

---

[1] Икърары мөҗибенчә — гаебен тануы сәбәпле.
[2] Билгайни вәррәэс — баш өсте.
[3] Гаҗүзә — карчык.
[4] Шөруг — керешү.

те: «Әй егет, сине Аллаһы Тәгалә вә Рәсүле Хода өчен багышладым». Ул егет әйтте: «Мин һәм бу багышламакың өчен моннан ары мондаен мәгъсыятьне[1] кыйлмамын», — дип тәүбә кыйлды».

———

Мөгътәмәд хәлифәнең бәгъзе нәдимнәре димештер ки: «Бер кичә хәлифә хәзрәтләренең хозурында идек. «Сез берәр сәгать утырыңыз, мин бераз йоклап алаем», — дип, хәлифә йокламага ятты, бераз йоклаганнан соң уянды. «Зинданга барыңыз, анда Мансур исемле тәвәче бардыр, хозурыма китерегез!» — дип боерды. Дәрхаль китерделәр. Хәлифә әйтте: «Әй Мансур, ни вакыттан бирле хибестәсең?» — диде. Тәвәче әйтте: «Ярты елдыр ки, хибестәмен», — диде. Хәлифә әйтте: «Ни сәбәпле кергән идең?» Мансур әйтте: «Мин бер тәвәче идем, шәһәремдә тормага вәҗһе тапмагач, тәвәмне алып, икенче шәһәргә барганда, юлда күрдем ки: юл кисүчеләрне тәҗәссес[2] кыйлмага Мәүсыйлдан җибәрелмеш ун нәфәр адәм кыйтагыттарикъ төһмәте белән берничә кешене тотып китерерләр иде. Тотылмыш адәмнәрдән бере тәҗәссес кыйлгучыларга ришвәт акча биреп, аның урынына мине тотып китерделәр вә тәвәмне алдылар. Зинһар, Аллаһы өчен, мине азат кыйлыңыз, минем гаебем юктыр, мин кыйтагыттарикъ түгелмен, фәлән шәһәргә барамын, мин бер мөсафирмын, дидем. Сүземә илтифат кыйлмадылар, ул кыйтагыттарикълар белән бергә хибескә салдылар, аларның бәгъзесе чыкты, бәгъзесе вафат булды, мин берьялгыз калмыш идем. Ошбу кичә күз яшемне агызып, хәзрәти Рәсүл әкрам саллаллаһу галәйһиссәламгә нияз кыйлып, дога белән мәшгуль идем, мине алып, хозурыңызга китерделәр», — диде. Хәлифә әйтте: «Раст әйттең», — диде, һәм азат кыйлды, вә биш йөз алтын ихсан кыйлды, вә һәр айга тәгаййеш[3] өчен утыз алтын тәгаен кыйлды вә нәдимнәренә әйтте ки: «Бу фигылемнең сәбәбе нидер, белермесез?» — диде. «Белмәймез, йә әмирел-мөэминин, моның асылын әйтә күрегез», — диделәр. Хәлифә әйтте: «Халән йокымда хәзрәти Рәсүлне күрдем, Мансурны хибестән чыгарып, ингам-ихсан кыйл, дип боерды», — диде.

———

Хикәят кыйлынмыштыр ки: бер шәһәрдә бер ханәгә тагун[4] кереп, халык якын бармага курыкканларыннан ул ханәнең ишеген багламышлар иде. Әмма ул ханә эчендә бер имчәк баласы калмыш вә калганын һич кемсәнә белмәмеш. Бер айдан соң ханәнең ишеген ачып керделәр, ул сабый баланы күрделәр, Алла-

---

[1] **Мәгъсыятьне** — гөнаһны.
[2] **Тәҗәссес** — кеше гаебен тикшерү.
[3] **Тәгаййеш** — яшәү.
[4] **Тагун** — чума авыруы.

һы Тәгалә ул сабыйга тәрәххем кыйлып, анда бер ана эт калган, имеш, ул этнең балалары белән бу сабый бала бергә этнең имчәген имеп тәрбияләнмеш вә сәламәт калмыш.

———

Але Әл-Хәмаданнан мәлик Насыйр әд-дәүләт бер заман кәүләнҗ зәхмәте белән мөбтәля булып, җәмигъ табиблар дәва вә гыйлаҗдан гаҗиз булмыш иделәр; бу арада дошманнары тарафыннан бер адәм Насыйрны кател кыйлмага күндерелмеш иде. Беркөн мәлик Насыйр сараеның бәгъзе бүлмәләрендә утырыр иде. Мәзкүр дошман тарафыннан килгән кеше, форсат табып, килеп Насыйрны хәнҗәр белән сукты, әмма хәнҗәр Насыйрның кәүләнҗ зәхмәте булган җиренә тугыры килеп, җәрәхәт салды, кәүләнҗ зәхмәтеннән хасыйл булган кан вә эрен агып чыкты. Мәликнең зәхмәтенә бу хәнҗәр җәрәхәте файда булып, биизниллаһи кәүләнҗ зәхмәтеннән хәлас булды.

Дәхи моның нәкыйзында бер хикәят Әбү Бәкер әт-Тартусидән нәкыль кыйлынмыштыр ки: «Дания касабәсеннән бер кафилә бер карьягә керделәр. Һава ягъмурлы булганлык сәбәпле, бер харап иске өйгә кереп тораек, дип туктадылар, ут ягып ашамак-эчмәк хәзерләмәгә мәшгуль булдылар. Ләкин ул өйнең бер дивары егылмага мәел, имеш, араларыннан берсе әйтте: «Бак сакланыңыз, монда торманыз, бу дивар тешеп китәргә бик карибтер, һәлак булырсыз, мин монда ятмага куркамын», — дип, тышка чыкты. Юлдашлары ул җимерек өйдә калдылар. Кайчан ки икенче көн булгач, өй эчендә йоклаганнары чыгып атларын хәзерләп, йөкләрен арутып торган арада, ул тышта йоклаган кемсәнә, истибра кыйлмак өчен, ул ханә эченә кереп, хаҗәтемне кыйлаем, дип торганда, дивар җимерелеп төште. Ул бичара дивар астында калып һәлак булды, башкалары сәламәт калды».

———

Янә мәзкүр Тартуси әйтте: «Мәусыйлда Әбүлкасыйм дигән адәм миңа нәкыль кыйлды ки, мин бу диярга килгәч, бу Мәусыйл әһеленнән берәүгә бу ханәдә бер гаҗәп кыйсса вакыйг булды, дип, бер ханәне күрсәтте. Ни кыйссадыр, дип сөаль кыйлганымнан соң әйтте: «Бу мәнзилдә җефәк сәүдәсе белән Күфәгә барып килеп йөри торган бер базаркян[1] торган иде. Беркөн, никадәр малы бар исә һәммәсене әрҗәгә тутырып, ишәгенә йөкләп, кәрван белән Күфәгә барганда, кәрван бер җиргә тәгам ашарга төштеләр. Бу кеше дәхи ишәгеннән әрҗәсен төшереп торган заманда, җәяүле бер ят кеше бар иде. Бу базаркян аннан ярдәм теләде, ул кеше килеп, ишәктән әрҗәсен төшерешеп ярдәм кыйлды. Аннан соң базаркян тәгам хәзерләп ашарга утырганда, ул ят кешене дәхи чакырып, үзе белән бергә ашарга

[1] Базаркян — сәүдәгәр.

утыртты, базаркян ул кешенең әхвәлен сорашып утырды. Ул кеше әйтте: «Мин Күфә шәһәреннән бер кешемен, фәкыйрьлеккә түзә алмаенча, азыксыз, атсыз юлга җәяү чыктым, шулай барамын», — диде. Бу базаркян, аны кызганып: «Сәфәрдә син минем юлдашым бул вә миңа ярдәм кыйлыш, тәрбиян минем өстемдә булсын», — диде. Ул фәкыйрь дәхи миннәт белеп, базаркяннең хезмәтен кыйларак бергә барды.

Янә беркөн кәрван белән Тикрит шәһәренә якын бер җиргә туктадылар, кәрван халкы бәгъзе йомышлары өчен Тикрит шәһәренә керделәр, бу базаркян дәхи, баягы фәкыйрь юлдашына һәммә әсбабын тапшырып, шәһәргә китте. Шәһәргә барып, хаҗәтен бетереп килсә, күрде: кәрван әһеле һәм ул фәкыйрь юлдашы кузгалып китмешләр, базаркян җәяүләп кәрван артыннан йөгереп, мең мәшәкать белән барып җитте. Нәрсәләре вә ул фәкыйрь юлдашы кәрван эчендә юк, кәрван халкыннан сорашты, алар әйттеләр: «Син Тикрит шәһәренә киткәч, юлдашың, ишәгеңне җитәкләп, синең артыңнан китте, без син үзең боергансың дип гөман кыйлдык», — диделәр. Базаркян, бу эшкә хәйран булып, яңадан Тикрит шәһәренә кайтты, сорашты, һич андаен кеше монда күренде, дип әйтүче булмады.

Бу базаркян, мәэюс[1] булып, үзенең Мәусыйл шәһәренә кайтты. Көндез ач, вә ялангач, вә фәкыйрь булып Мәусыйл шәһәренә җиткәч, халыктан оялып, вә, дошман шәматасеннән[2] куркып, вә, дусларым кайгырмасын, дип, көндез кермәгә такате булмаенча, төнләгәчә шәһәрнең бер читендә торды, караңгы булгач, барып ханәсенең ишеген какты. Өе эченнән әһел вә гыяле, анда кем бар, дигәч, мин кайттым, ачыңыз, дип, үзен белдерде. Сөенеп ишек ачтылар: «Әлхәмделиллаһ, бик гаҗиз идек, кайтып җитештең, зирә бу кичә углыңыз дөньяга килде. Бала туена лазем нәрсәләр ала алмадык, инде он кирәк, май кирәк, хосусән караңгыда утырамыз, шәм беткән, кандилләргә май кирәк», — диделәр. Бу базаркян бу хәлне күреп вә бу сүзләрен ишетеп, кайгысы артты: «Әһел вә гыялем кайгырмасыннар, — дип, әхвәлен бер дә сөйләмәде. — Кайда, савытлар бирегез, кирәк нәрсәләрне алып китерәем», — дип, савытлар сорап алды. Каршысында алыш-биреш итә торган бер дөкянче бар иде. Аңа барды, күрде: дөкянче, ут сүндереп, йокларга яткан. Ишеген кагып, дөкянчене уятты, дөкянче дәхи, аның тавышыннан танып, әлхәмделиллаһ, сәламәт йөреп кайттыгыз, дип торып, ут яндырды, ишеген ачып кертте. Базаркян әйтте: «Хәзер лазем нәрсәләрне бир, углым дөньяга килгән, имеш», — диде. Дөкянче, сәмган вә тагатән[3], дип, кирәк нәрсәләрне үлчәп, савытларына сал-

---

[1] Мәэюс — нәүмиз.
[2] Шәматасеннән — (явызларча) сөенүеннән.
[3] Сәмган вә тагатән — тыңлыйм һәм буйсынам.

ганда, базаркяннең күзе баягы угры юлдашы алып качкан үзенең әрҗәсенә төште. Хәйран булып сабырыннан язды, һаман дөкянченең өстенә барып, аяк астына егып ташлады. «Әй Аллаһының дошманы, тиз әйт, минем малларым кайда?» — диде. Дөкянче әйтте: «Әй базаркян, бу ни хәл, Аллаһы белер ки, мин сиңа вә гайре кешеләргә белә торып хыянәт иткәнем бармы?» — диде. Базаркян әйтте: «Бу минем әрҗәмдер, мәрхәмәт кыйлып юлдашлыкка алган бер фәкыйрь юлдашым алып качмыш иде», — диде. Дөкянче әйтте: «Валлаһи, минем аннан хәбәрем юктыр, ләкин ахшамнан соң танымаган бер ят кеше, дөкянемә килеп, миннән кич ашамак өчен тәгам алды, бу әрҗә синдә торсын, мин бер юлчы ят кешемен, иртәгә килеп алырмын дип, монда куйды. Ишәген күршем ханәсенә кертеп баглады, вә үзе мәхәллә мәсҗетенә йокламага китте», — диде. Базаркян әйтте: «Әйдә, алайса, мәсҗеткә бараек», — дип, мәсҗеткә бардылар, күрделәр: ул угры мәсҗеттә йоклап ятыр, һаман базаркян аны аягы белән тибеп уятты. Әйтте: «Һи хаин, кайда минем малым вә ишәгем?» — диде. Ул хаин әйтте: «Малың һаман әрҗәңдәдер, мин бернәрсәңә дә тигәнем юк, әнә ишәгең фәлән кешенең ханәсендәдер, әрҗәң бу кешенең дөкянендәдер», — дип, дөкянчене күрсәтте.

Бәс, базаркян, малын вә ишәген тапканына шөкер итеп, ул хаинны хакимгә хәбәр бирмәде, гафу кыйлды. Максуд мал сәламәтлегедер, дип мәсрүрән[1], малын алып, ханәсенә килде, кыйссаны тәмам әһел вә гыяленә сөйләде. Сөрүр вә шатлыклары зиядә булып, туган балаларының бәхет вә икъбал иясе булачагын моннан истидлал кыйлдылар».

---

Берзаман Гомәр бин Һәбирә Зәкъкадә мәхбүс иде. Хибестән хәлас булгач, кич белән ханәсенә килгәндә, Бәни Сәлим кабиләсеннән бер хатын үзенең җариясе белән сөйләшеп утырганда, бер мөнасәбәт төшеп, җариясенә хитабән: «Әй җария, ул нәрсә син әйткәнчә түгелдер, — Гомәр бин Һәбирәне хибестән коткармакын теләгән, Аллам хакы өчен, дигән сүзен бин Һәбирә ишетеп, филхаль куенында бер капчык белән йөз алтын бар, имеш, чыгарып, — инде Аллаһы Тәгалә бин Һәбирәне хәлас кыйлды, хәтерең хуш булсын», — дип, хатынга ыргытты.

---

Берәү бер кешедән йорт сатулашты, әйтте: «Әгәр сабыр итсәң, мин аршын җиреңне ун дирһәмгә алырмын», — диде. Йорт сатучы әйтте: «Әгәр син сабыр итсәң, мин йөз аршын җиремне бер дирһәмгә бирермен», — диде.

---

Бер җирдә ике кеше дөньядан зарланып торганда, берсе әйтте: «Бәли, шулай шул, замана авыр, бала-чага күп, харәҗәт

[1] Мәсрүрән — шатланып.

зураеп китте, житешеп булмай», — диде. Берсе әйтте: «Баласы бала, чага дигәнең ни-нәрсәдер?» — диде. Яннарында балаларыннан зәхмәт чиккән бер кеше бар иде, әйтте: «Шул балаларның арасында чага торганы буладыр, шуны чага дип әйтәләр», — диде.

———

Әүкатлы яхшы гына бер бай кешенең ике баласы бер хәлфәдә сабак укырлар иде. Беркөн бу балалар ни сәбәпледер сабакка килмәгәч, хәлфәсе аларны алмага бер баланы җибәрде. Ул балаларның анасы әйтте: «Йә, бу көн бармасалар да ярар, укып ни була, аталары иман да белми, һаман көн итә», — диде.

———

Бер падишаһ берәүне зыяфәткә чакырды. Ул кеше әйтте: «Базар кешесемен, падишаһ мәҗлесенә лиякатем юктыр[1], күркәм тарика ашый белмәмен», — диде. Падишаһ әйтте: «Тырнагың кискән булса, җиңнәрең пакь булса, локмәң кечкенә булса, тозны, серкәне майламасаң, ягъни былчыратмасаң, аннан соң теләсәң кем белән аша», — диде.

———

Бер хәким хәлифә мәҗлесендә тәгам ашарга утырды, коры пәйнер[2] сорады, әйтте: «Пәйнер яхшы нәрсәдер, тәгамны һазым кыйлыр, шәрабны ләззәтле кыйлыр, мине пакь кыйлыр вә саф итәр», — диде. «Хәзердә пәйнеремез юктыр», — диделәр. Хәким әйтте: «Кирәкмәс алайса, пәйнер тешне бозар, онытчаклык китерер, телне агыр итәр», — диде. Хәлифә көлде дә әйтте: «Инде кайсы сүзең белән гамәл кыйлаек?» — диде. Хәким әйтте: «Әгәр булса — әүвәлгесе белән, булмаса — соңгысы белән гамәл кыйл», — диде.

———

Солтан Мәхмүд хәзрәтләре бәгъзе нәдимнәре белән бервакытны базинҗан[3] ашады, карыны бик ачкан иде: «Һай, ни яхшы тәгамдыр», — дип мактап ашады, нәдим дәхи: «Раст вакыйган, базинҗан бик яхшы нәрсә», — диде. Ашап туйдылар. Солтан Мәхмүд әйтте: «Бу базинҗан зарарлы тәгамдыр», — диде. Нәдим дәхи: «Бәли, фәлән төрле, фәлән төрле зарарлары бар», — дип, берничә зарарын гәб[1] кыйлды. Солтан әйтте: «Хәзер генә мактадың, янә зарарлы дип әйтәсең», — диде. Нәдим әйтте: «Мин синең нәдимең, базинҗан нәдиме түгел, мин сиңа хуш күренгәнне сиңа муафыйк әйтәмен. Син, зарарлы, дидең, сиңа муафәкатән мин һәм зарарын әйттем, син мактадың, сиңа муафәкатән мин һәм мактадым», — диде.

---

[1] Лиякатем юктыр — лаек түгелмен.
[2] Пәйнер — сыр.
[3] Базинҗан — баклажан.
[4] Гәб — гәп, сөйләшү.

Бер сабый бала, олуглар белән ашарга утыргач, кашыгын куйды да егълый башлады. «Ник егълыйсың?» — диделәр. «Бик кайнар, авызымны пешертә», — диде. «Азрак сабыр ит, суынсын», — диделәр. «Әйе, мин сабыр итәр идем, сез сабыр итмисез анда», — диде.

———

Бер саран кеше хезмәтчесенә әйтте: «Тәгамны китер, ишекне биклә». Хезмәтчесе әйтте: «Әүвәл ишекне бикләмәк лазем иде, аннан соң тәгам китермәк», — диде. Хуҗасы әйтте: «Бәрәкаллаһ, тәдбирең яхшылыгы өчен сине азат кыйлдым», — диде.

———

Бер саран карчыкның мәдрәсәдә укый торган бер галим генә улы бар иде. Көннәрдә бер көн анасы белән күрешергә кайтты. Анасы әйтте: «Әй углым, яхшы кайттың, синең өчен нигъмәтләр хәзерләп куйган идем, яхшы симез каз итем бар, нәфис майлы коймагым бар һәм бик куе каймагым бар, кайсы тәгамны нәфесең теләйдер, ләкин берәм-берәм ашатырмын», — диде. Углы әйтте: «Әй аначыгым, мин каз итен коймакка төреп, каймакка манып ашар идем», — диде.

———

Берничә тофәйли[1] бер туй мәҗлесенә килделәр. Күрделәр: капкасы бикле, имеш. Койма өстенә менделәр, йортның хуҗасы боларны күрде дә койма өстеннән куып төшерде. Әйтте: «Ни өчен безнең хәрәмемезгә вә кызларымызга карыйсыз?» — диде. Болар әйттеләр: «Синең җәмәгатеңдә вә кызларыңда һич хакымыз вә өмидемез юктыр. Мәгәр безнең морадымызны үзең беләсең ки, тамак туйдырмак», — димәктер.

———

Бәни Хәнифә дигән бер кавем үзләренә балавыздан бер пот[2] ясап, аңа табынырлар иде. Берничә еллар табынганнан соң, көннәрдә бер көн бер ачлык пәйда булып, потларын ашадылар.

———

Яхъя бин Әксәм берничә җәмәгатьне кунакка чакырды, бер тар авызлы чүлмәк белән тәгам китерде ки: ике кеше берьюлы кашык тыгып алмак мөмкин түгел иде. Бере кашык белән алганчы, икенчеләре көтеп торырлар иде, аннан соң икенчесе алып капканчы, башкалары дәхи үз нәүбәтен көтеп торырлар иде. Бәс, ашап мәҗлестән чыктылар: «Кайда бардыгыз?» — дип, юлда берәү сорады. «Без салате хәвефтә идек», — дип җавап бирделәр.

———

Берәүгә бер кунак килде. Өй иясе бу кунакны бик кадерхөрмәт итте. Өч көн дә булды, дүрт көн дә булды, бу кунакның

---

[1] Тофәйли — чакырылмаган килеш кунакка йөрүче.
[2] Пот — табына торган сурәт.

китәргә гөманы юк. Өй иясе киная белән: «Тәкъсыйр, арбаңызны майлаекмы, атларыңызга камыт киертәекме»?», — дип әйтеп карый, кунак сөкүт кыйла. Икенче көн дәхи: «Әй кунак, дүрт көн, биш көн кунак иттем, китәргә вакыт иде», — диде. Дәхи әйтте: «Кунак кадере өч көндер, дүртенчесе мөхальдер. Килдекең миһман[1] биш көн улды, бу ни хәлдер?» — диде. Кунак аңар җавап әйтте: «Әй ишәк углы, нә күңел белер син вә нә хәтер, кунакның кәйфиятенчәдер, биш көн дә ятыр, ун көн дә ятыр», — диде.

---

Сараннардан бер адәм угылларына әйтте: «Барыңыз, миңа ит алып пешереп китереңез», — диде. Балалары бу эшне әда кыйлдылар, инде атамыз безгә дә бирер, дип карап торыр иде. Аталары тәмамән итне ашап бетерде, сөякләрен алдына куйды, әйтте: «Әй угланнар, кайсыңыз бу сөякләрне яхшы кимерсә, аңа бирермен», — диде. Олуг углы әйтте: «Әй атачыгым, миңа бир, мин шулкадәр кимерермен, ялармын ки, кырмыска ашарлык нәрсәсе дә калмас», — диде. Атасы әйтте: «Юк, син сөяк кимерергә әһел түгел, имешсең». Уртанчы углы әйтте: «Әй атам, миңа бир, мин шулкадәр ялармын, кимерермән ки, ул сөякне күргән кешеләр ике елгы сөяк дип белерләр», — диде. Атасы моның сүзен һәм тәхсин кыйлмады. Кече углы әйтте: «Атачыгым, миңа бир, мин шулкадәр ялармын ки, ялап беткәч тә, сөяген төеп, он итеп ашармын», — диде. Атасы әйтте: «Бәрәкаллаһ, сөяк кешесе син, имешсең, мәгърифәтең артсын, мә, кимер», — дип, аңа бирде.

---

Әбү әл-Әсвәд дигән бер саран адәм бер җирдә ашап утырганда, бер фәкыйрь гарәп килеп сәлам бирде. Әбү әл-Әсвәд сәламен алды, илтифатсыз һаман ашамакта. Гарәп, бер локмә тәгам өмиде белән, сүз ачып: «Монда килгәндә өеңезгә кереп чыктым», — диде. Әбү әл-Әсвәд әйтте: «Алайдыр, керсәң кергәнсең, чөнки безнең өемез синең юлың өстендә вакыйгдыр», — диде. Әһел вә гыяленнән асла хәбәр сорамай, һаман ашавы белән мәшгуль булып, гарәпкә асла утыр-мутыр димәде. Гарәп әйтте: «Хатының йөкле, имеш.» Әсвәд әйтте: «Беләмен, шулайдыр». Гарәп әйтте: «Хатының баласын тапкан, имеш». Әсвәд әйтте: «Корсаклы булгач, әлбәттә, табар шул». Гарәп әйтте: «Игез бала тудырган, имеш». Әсвәд әйтте: «Хатынымның нәселе шулайдыр, анасы мәрхүмә дә һәркайчан игез бала китерер иде», — диде. Бәс, гарәп, бу рәвешчә сөенеч бирүдән файда булмагач, кайгырту ягын карап: «Балаңның берсе вафат булды», — диде. Әсвәд әйтте: «Яхшы булган икән, анасы ике бала имезә алмас», — иде. Гарәп әйтте: «Икенче көн икенчесе дә

[1] Миһман — кунак.

вафат булды.» Әсвәд әйтте: «Иптәше үлгәч, аның һәм үлгәне яхшы». Гарәп әйтте: «Аналары һәм үлде». Әсвәд әйтте: «Балалар хәсрәте белән үлгәндер», — диде, һич кайгы әсәрен изһар кыйлмады. Гарәп, бу кайгыртудан да файда хасыйл итмәгәч: «Һай, нәфис тәгам вә нәфис нигъмәт ашыйсың, имеш», — диде. Әсвәд әйтте: «Шуның өчен мин ялгыз ашыймын, һай, гарәп, җиһанны башыма ексаң да, бер локмә бирмәмен, бар, кит!» — диде.

———

Хәҗҗаҗ тарафыннан бер шәһәрдә бер гарәп вали нисаб ителмеш иде, озак мөддәт[1] ул шәһәрдә мөтәсарриф булып, көннәрдән бер көн үзенең кабиләсеннән бер гарәп аңа зыярәтән килде. Ул гарәпне хөрмәт вә әкрам кыйлмак өчен тәгам хәзерләп, ул гарәп тәгамга кул сузмас борын хәл-әхвәл сорашып: «Углым Гамир ни хәлдәдер?» — диде. Гарәп әйтте: «Тәмам морадынча рифгатьтәдер[2], дәүләт иясedep, хезмәткәрләре күп, яхшы әукат кичермәктәдер». Вали әйтте: «Гамирнең анасы, ягъни хатыным сәламәтме?» Гарәп әйтте: «Салихәдер, салахта вә төзеклектә киченер». Вали әйтте: «Күршемез ни хәлдә, исәнме?» Гарәп әйтте: «Хуб мәгъмүрдер». Вали әйтте: «Әйкаг атлы этем ни хәлдәдер?» Гарәп әйтте: «Бик яхшы хирасәт кыйладыр, өрмәке белән бөтен шәһәрне яңгыратадыр». Вали әйтте: «Рәүнәкъ атлы тәвәм яхшы йөри микән?» Гарәп әйтте: «Саусәламәттер», — диде. Бәс, бу вали әфәнде, һаман гарәп тәгамны тәнавел кыйлмастан, хадименә: «Тәгамны ал!» — дип кычкырды. Гарәпкә әйтте: «Әй мөбарәк җирдән килгән гарәп, ул сөйләгән хәбәрләреңезне яңа баштан сөйләсәнә, дәхи ишетеп рәхәтләнәем», — диде. Гарәп әйтте: «Янә ни хәбәр сорарсыз — әйтәем». Бәс, вали әфәнде бу дәфга эттән башлап: «Безнең Әйкаг хәле ничек?» — диде. Гарәп әйтте: «Һәлак булды». Вали әйтте: «Ни сәбәпле?» Гарәп әйтте: «Рәүнәкъ дигән тәвәнезнең сөяге тамагына кадалды да үлде». Вали әйтте: «Һай, тәвәм үлдеме, ни сәбәпле үлде?» Гарәп әйтте: «Гамир анасының каберенә су ташып имгәнде». Вали әйтте: «Йә, Гамир анасы да үлдеме, ни сәбәпле үлде?» Гарәп әйтте: «Гамир өчен күп егъламакы сәбәпле кайгыдан үлде». Вали әйтте: «Йә, ул бәгърем пәрәсе дә үлдеме, ни сәбәпле үлде?» Гарәп әйтте: «Бәли, үлде, өстенә диварыңыз җимерелеп төште». Вали әйтте: «Йә, ханәмез һәм егылдымы?» Гарәп әйтте: «Бәли, егылды», — диде.

Бәс, Вали егъларга тотынды. Ул арада гарәп торды да тәгамны тартып алды, дәрхаль ашап та бетерде. «Әлхәмделиллаһ,

---

[1] Мөддәт — ара, вакыт.
[2] Рифгатьтәдер — күтәрелештәдер.

тәһнияңез[1] белән ашый алмадык, ләкин тәгъзиятеңез[2] белән ашадык», — дигәч, вали таягын алып, гарәпне сугарга дигәндә, гарәп чыгып качты.

———

Һарун әр-Рәшит хәзрәтләре зорафат заманыннан Әбелхарискә әйтте: «Фалузәж[3] белән лузинәждән[4] кайсы хушрак, кайсы татлырактыр?» — диде. Әбелхарис әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, гаибкә хөкем ителмәйдер», — диде. Һарун боерды, фалузәж вә лузинәж хәзерләп китерделәр. Әбелхарис һәрбереннән берәр локмә тәнавел кыйлып карады да: «Әй әмирел-мөэминин, берсеннән-берсе артыклыгына хөкем итә алмадым, зирә беренең рәҗханенә хөкем итмәкче булдым, икенчесе хөҗҗәт[5] белән килде», — дип, икесен дә мактады.

———

Янә Һарун әр-Рәшит хәзрәтләре мәзкүр ике тәгамның кайсы яхшырак икәне хакында хатыны Зөбәйдә белән хәремнәрендә бәхәс кыйлышырлар иде. Ул арада имам Әбү Йосыф хәзрәтләре килде. Һарун дәхи имамнан бу бәхәсне ләтыйфа тарикынча[6] сорады. Имам Әбү Йосыф әйтте: «Йә әмир, гаибкә хөкем юк, элгәре ашап караем, аннан ары әйтермен», — дигәч, дәрхаль ул ике тәгамны хәзерләп китерделәр. Имам Әбү Йосыф, ашап караганнан соң: «Әй әмирел-мөэминин, ике хасым[7] бер-бере белән солых кыйлыштылар, хөкем булмады», — дигәч, Һарун әр-Рәшит шулкадәр рәхәтләнеп көлде, имам Әбү Йосыфка мең алтын гатыя[8] кыйлып, бу кыйссаны Зөбәйдәгә сөйләде. Зөбәйдә дәхи, моны ишеткәч, тугыз йөз туксан тугыз алтын имам Әбү Йосыфка гатыя җибәрде. Зөбәйдәнең гатыясе хәлифәнең гатыясеннән бер данә ким булмагында хәйлә, зарафәт[9] вә әдәп бардыр, фәтәәммәл[10].

———

Хәсән бин Сәһел беркөн Маэмүн хәлифә белән тәгам ашаганда, дөге гомерне арттырыр, имеш, дип, дөгене мактап ашар иде. Хәлифә сәбәбеннән сөаль кыйлды. Сәһел әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, һинднең тыйбы дөрестер, ягъни һинд табибларының хәзакать[11] вә тәҗрибәләре мөсәлләмдер. Һинд табиблары

---

[1] Тәһнияңез — котлавыгыз.
[2] Тәгъзиятеңез — кайгы уртаклашуыгыз.
[3] Фалузәж — дөгегә бал-май катыштырып әзерләнгән аш.
[4] Лузинәж — ризыкның бер төре.
[5] Хөҗҗәт — дәлил, ышандыргыч аргумент.
[6] Ләтыйфа тарикынча — көлкеле, ысул белән.
[7] Хасым — дошман.
[8] Гатыя — бүләк.
[9] Зарафәт — ягымлылык.
[10] Фәтәәммәл — шуңа карап үзең бел.
[11] Хәзакать — эштә осталык.

әйттеләр ки, дөге тәгамы ашап йоклагач, һәйбәт вә шатлык төшләре күрсәтер, диделәр.

---

Горафадан берәүнең бер углы падишаһлык хезмәтендә иде. Ул углына әйтте: «Әй углым, ашаганда авызыңны бик ачма, дәстәрхан янында уңга-сулга күп карама вә локмәңне пычак белән кисмә, үзеңнән олуглар барында алардан югары утырма, пакь, нәфис җирләргә төкермә», — дип, тәнбиһ вә васыять итмештер ки. Безгә һәм бу эшләр лаземдер.

---

Хәҗҗаҗның дәстәрханенә бер гарәп кунак булып, гарәп иштиһа белән тәгамны алып ашый башлаганда, Хәҗҗаҗ тәгаррыз кыйлды[1]. Гарәп дәхи: «Әй Хәҗҗаҗ, син дә минем локмәмә карама!» — дип илзам кыйлды.

---

Мәнкульдер ки, бер бәдәви гарәп бәгъзе хәлифәнең дәстәрханенә хәзер булып, гарәпнең алдына бер кәбаб кәҗә бәрәне китереп куйгач та, гарәп хирысланып, тиз үк кул сузып ашый башлаганда, хәлифә әйтте: «Йә гарәп, бу бәрәннең анасы сине сөзгән булмак кирәк ки, ачу белән тотындың», — диде. Гарәп дәхи филхаль: «Бәли, сез бәрәнгә шәфкатән моны әйттегез, галибән[2], бу бәрәннең анасы сезгә сөт имезгән булса кирәк», — дип, гаять көлештеләр.

---

Гомәр бин Гобәйд димештер ки: «Мин Хәсән Бәсри рәхмәтуллаһи галәйһинең кычкырып көлгәнен күргәнем юк иде, мәгәр бер мәртәбә күрдем. Беркөн Хәсән Бәсриның мәҗлесендә булган адәмнәрдән бере, мин бу вакытка кадәр һичбер тәгам миңа зарар биргәнен күрмәдем, диде. Мәҗлестәгеләрдән икенче берәү, йә шулаймы, синең мигъдәң бу кадәр куәтле, имеш ки, әгәр таш ашасаң да, филхаль он итәр, имеш, дигәч, Хәсән Бәсри хәзрәтләре шулкадәр көлде ки, үзен-үзе тыя алмады. Бу ләтыйфәне гаять истихсан кыйлды[3]».

---

Әбү әл-Харис дигән бер адәмнең бер сәүгән хатыны бар иде. Беркөн бу хатынның янына барып, берәр сәгать микъдары мөсахәбәт кыйлганнан соң, Әбү әл-Хариснең карыны ачып: «Кайда, азрак ашарга юкмы?» — дип, хатыннан сорады. Хатын әйтте: «Әй кеше, сине ашамак-эчмәктән оныттыра торган нәрсә миндә юкмы?» — диде. Әбү әл-Харис әйтте: «Әй җаным, җаным, сиңа фида булсын, әгәр Җәмил белән Бәсинә һәм берәр сәгать микъ-

---

[1] Тәгаррыз кыйлды — кеше эшенә тыкшынды.
[2] Галибән — ахрысы.
[3] Истихсан кыйлды — яхшы дип тапты.

дары сохбәт кыйлып, бер-берене тәгам белән хөрмәтләмәсәләр, бер-беренең йөзенә төкереп аерылырлар иде», — дип, хуш мотаябә[1] кыйлмыштыр.

———

Вәһәб бин Җәрир беркөн гарәп арасында күп ашаучылык белән мәшһүр Мәйсәрәт әл-Бәрраштан сорады: «Син күпме ашыйсың?» — диде. Мәйсәрә әйтте: «Бер ашаганда йөз икмәк, ике кадак май ашадым», — диде.

———

Янә мәнкульдер ки: мәзкүр Мәйсәрә беркөн атына атланып барганда күрде, зөрафадан[2] берничә кеше ашарга утырмышлар. «Йә Мәйсәрә, боерыңыз, бергә шурпа ашаек», — дип, Мәйсәрәне чакырдылар. Мәйсәрә, атыннан төшеп, алар янына утырды. Болар Мәйсәрәнең атын хәфиятән бугазладылар, бөтенләен пешереп, Мәйсәрәнең алдына китерделәр. Мәйсәрә бөтен ат итен тәмамән ашап бетерде. Йокларга яттылар, иртәгесен торгач, Мәйсәрә атына атланып китмәкче булды, атын тапмады: «Минем атым кайда?», — диде. «Инде атыңны эзләмә, атың корсагыңдадыр», — диделәр.

———

Күп ашаучылардан мәшһүр Һилал әл-Мазни дигән бер кеше бар иде. Аннан берәү сорады: «Син күпме ашыйсың бер ашаганда?» — диде. Мазни әйтте: «Беркөн карыным ачкан иде, ашарга карадым, атланган тәвәмнән гайре нәрсәм булмагач, бугазлап, тәмамән пешердем. Аз калды, ашап бетермәдем. Кич булгач, җариям белән мөҗәмәгать кыйлмага мәйлем төшеп морад иттем, мөмкин булмады. Җариям әйтте: «Булмас, арамызда бөтен тәвә бар, дип зарафәт кыйлды», — диде.

———

Дәхи мәшһүр күп ашаучылардан бере — Сөләйман бин Габделмәликтер. Сәмәрдәл әт-Таифи риваять кыйлмыштыр ки: «Беркөн Сөләйман Гомәр бин Габделгазиз белән Таифкә килеп, ханәмә нөзүл кыйлдылар. Филхаль Сөләйман: «Әй Сәмәрдәл, безгә ашарга хәзер тәгамың бармы?» — диде. Мин дәхи, халән бер симез кәҗә кәбаб хәзерләмеш идем, дип, алдына китереп куйдым. Гомәрне кил ашарга дип чакырмаенча, дәрхаль үзе генә утырды да ашый башлады. Кәҗәнең бары бер аягы калгач: «Йә Әбү Җәгъфәр, кил, бергә ашаек», — дип, Гомәрне чакырды, Гомәр руза, имеш, ашарга утырмады. Ахыр кәбабны үзе генә ашап бетерде дә: «Әй Сәмәрдәл, моннан башка янә тәгамың бармы? Булса, китер», — диде. Алты данә кәбаб тавыгым бардыр, дидем. «Булса, китер», — диде. Китердем, аны

---

[1] Мотаябә — шаярышу.
[2] Зөрафадан — укымышлы кешеләрдән.

һәм ашап бетерде. Янә: «Тәгамың юкмы?» — диде. Бер зур табак суек бар, дип, алдына китереп куйдым, тәмам эчеп бетерде, янә үзенең аш хәзерләгүче голәменә кычкырды: «Әй фәлән, кич ашамага хәзерләдеңме? Ни микъдар хәзерләдең?» — диде. Голәме әйтте: «Утыз казан аш хәзерләнде», — диде. Аннан соң һәрбер тәгамнан сөлесенә[1] кадәр ашап, кулын сөртеп, аркасы үзрә ятты. Аннан соң: «Хозурыма керәсе кеше керсен», — дип, рөхсәт бирде. Халык кергәч, янә халык белән бергә утырып ашады», — диде.

———

Һилал бин Әшгар дәхи күп ашамак белән мәшһүр иде. Төшендә дәхи кувәт зиядә иде, хәтта коры борчакны авызына тутырып, аның өстенә бер микъдар сөт яки җимеш суы алып, кытыр-кытыр чәйнәп йотар иде. Бер чиләк су эчеп бетерер иде. Бер авыр табигатьле әһел-җәфа вә нәкәс[2] кеше иде.

———

Әһле бәлягатьтән бер гарәп бер симез, калын кешене күреп: «Тышларың суккан комаштан өстеңә нәфис кием кимешсең», — диде, ягъни, күп ашап симерерсең, димәктер.

———

Мәгъруф Хәҗҗаҗ дәхи зиядә әкүл[3], имеш. Мөслим бин Катибә әйтте: «Бервакытны һәрберсенең өстенә берәр балык куеп, сиксән дүрт икмәкне хәзерләп, Хәҗҗаҗны дәгъват кыйлдым, тәмамән ашап бетерде», — диде.

———

Садакат әл-Мазни нәкыль кыйлмыштыр ки: «Өйләнгән вакытымда атам минем туем өчен бер тәвә суеп, ун табак аш хәзерләмеш иде. Мәзкүр Һилал дәхи мәҗлестә иде, халыктан элгәре килеп, бер табак ашны аңа тәкъдим иттек. Ашады, икенче табакны китердек, ашады, вәлхасыйл, ун табаклык ашны тәмам ашады. Туй өчен ашны яңабаштан хәзерләдек. Аның өстенә дәхи бер турсык йөзем суы эчте», — дип, бер гаҗәп хикәят кыйлмыштыр.

———

Өмәвия олугларыннан Гобәйдулла бин Зияд дәхи бик әкүл кеше иде, һәркөн биш мәртәбә тәгам ашар иде. Көннәрдә бер көн бер мәслихәт өчен Күфәгә барганда, юлда бәни Шәйбан кабиләсенә тугыры килеп, мәзкүр кабиләдән берәү Гобәйдулланы тәгамга дәгъвәт кыйлды. Дәрхаль ун тавык пешереп китерде вә берничә чәрек китерде, янә башка тәгамны китереп җиткергәнче, тавыкларны һәммәсен ашады. Аннан соң бер зән-

---

[1] Сөлесенә — өчтән беренә.
[2] Нәкәс — ялкау, яраксыз.
[3] Әкүл — күп ашаучы.

бил[1] коры инҗир вә бер зәнбил йомырка китерде. Гобәйдулламыз аларны дәхи сыпырды, аннан соң: «Һәнүз[2] ачмын», — дип, атына атланды да китте.

———

Мәнкульдер ки, мәзкүр Мәйсәрәнең күп ашаучылыгы хосусында Мәһди хәлифәнең мәҗлесендә сүз булып, алай, имеш, болай, имеш, хәтта йөз икмәк белән бөтен куй ашап бетерә, имеш, дип сөйләделәр. Хәлифә әмер итте, бер фил бугазлатып вә сарайда урын хәзерләтеп, Мәйсәрәне дәгъвәт кыйлды. Йөз икмәк китертте. Бәс, Мәйсәрә туксан тугыз икмәкне фил ите белән ашады, йөзенче икмәкне ашарга хәле булмады.

———

Бер мөсафир адәм бер раһибның саумәгасына килде. Раһиб әйтте: «Мәрхаба, хуш килдең, мин бараем, сезгә тәгам китерәем», — дип, алдына дүрт икмәк китереп куйды, ясмык шурпасы алмага китте. Аны китергәнче бу кеше дүрт икмәкне тәмам итеп куйды, ясмыкны китергәч, дәхи янә икмәк алмага китте. Ул арада бу кеше ясмыкны ашап алды. Хасыйле кәлям, раһиб бу кешегә тәгам китерә-китерә гаҗиз булды. Раһиб әйтте: «Әфәндем, гаеп булмасын, сезне кайдан сорашаек? Кайдан киләсез? Кайда барасыз?» — диде. Бу кеше әйтте: «Мин фәлән шәһәргә барамын, анда бер табиб хазыйк[3] бар, имеш, дип ишеткән идем, табигатем сау түгел, ашарга бер дә иштиһам[4] юк. Ул табибтан бер дәва алып, иштиһам ачылмас микән дип барамын», — диде. Раһиб әйтте: «Әфәндем, алай булса мин сездән бер гозер теләр идем, кабул итсәңез», — диде. Бу кеше әйтте: «Ни гозерең бардыр?» Раһиб әйтте: «Аллаһы теләсә, ул табибка барып, табигатеңезне төзәтсәңез, зинһар, бу юлдан кайта күрмәңез», — диде. Әгәр мигъдәсен төзәтеп кайтса, саумәгамнием белән бергә йотып җибәрер, дип курыкты.

———

Гантар исемле бер кемсәнә беркөн бер балык сатып алды. Хатынына биреп әйтте: «Син бу балыкны бик нәфис итеп пешер, мин бераз ятып торaем. Балык хәзер булгач, уятырсыз», — дип ятты. Хатын хәзрәтләре балыкны яхшылап пешерде, Гантарны уятмады, үзләре балыкны ашап бетерделәр. Хатыны Гантарның авызына, борынына, кулына балык шурпасы сөртте. Бервакытны Гантар уянып: «Кайда, балык пештеме, китереңез», — диде. Хатын әйтте: «Син балык ашап яттың түгелме? Ышанмасаң, кулыңны иснәп кара», — диде. Гантар иснәп карады: «Раст әйтәсең, ләкин ашаганымны тоймадым, йокыда идем», — диде.

---

[1] Зәнбил — камыштан үреп ясалган кәрзин.
[2] Һәнүз — һаман да, әле дә.
[3] Хазыйк — оста.
[4] Иштиһам — ашыйсы килү теләге.

Әсмәгый әйтте: «Гайинәдән, мәкяриме әхлак ни-нәрсәдер, дип сораган идем, Гасыйм бин Ваилнең бәетен ишеткәнең юкмы», — дип җавап бирде. Ягъни тәхкыйк[1], бер мөсафирны вә кунакны килмәстән мөкаддәм зыяфәт кыйлырмыз вә, аларны тәгамландырып, күләр йөздән содур иткән бәшарәт[2] белән туйдырырмыз, ягъни безгә килмәгән кунакларга да өйләренә җибәреп тәгамландырырмыз, өемезгә килгәннәренә бәтарыйкы әүлә димәктер.

---

Бер кемсәнә әйтте: «Исхак әт-Таһири дигән кемсәнә безне бер сәхәр вакытында һәрисә[3] ашамага чакырды. Бардык, һәрисәне китерделәр, ашарга утырдык. Һәрисә эчендә бер кыл кисәге күренде, дәрхаль бер баласын чакырып, безгә сиздермәенчәрәк, баланың колагына бер сүз әйтте. Бала китеп озак вакыт үтмәде, бер егет килде, тәббах, имеш. Күземез алдында һәрисәдән кыл чыкты, ник карамадың, дип, шулкадәр җәза бирде ки, барчамыз мәҗлестән качтык», — диде.

---

Һиммәт вә мөрәүвәт[4] ияләреннән бер адәм үзенең бостанында[5] бер зыяфәт тәртип кыйлып, дусларын зыяфәткә дәгъвәт кыйлмыш иде. Вә ул кешенең бер гүзәл вә әдәпле углы бар иде, мөсафирларга вә кунакларга иртәдән кичкә кадәр хезмәт итеп мунисланды. Бөтен көн кунак хезмәтендә булып арыганлыктан, кич белән өенең югары чарлагына менеп ятканда, каза ирешеп, чарлактан егылды. Филхаль вафат булды. Бу кисәктән булган бәлане атасы, бичара, сизгәч тә, хатынына: «Әгәр кунаклар монда чагында фөрьяд вә фәган итсәнез, фәлән булсын», — дип, сәләсәгә тәгълике итеп вә дәхи башка җариялә-ренә тәнбиһ итеп, кунаклар агяһ булмастан тәҗһиз иттерде, аннан соң кунаклары белән мөсахәбәткә мәшгуль булды. Кунакларның моннан хәбәрләре юк иде: «Баланыз кайда? Мәхдүм кайда?» — дип сорасалар: «Йоклагандыр», — дип җавап бирер иде. Йөзен үзгәртмәде. Иртәсе көн дуслары вә кунаклары өйләренә китмәгә рөхсәт сораганда, бу кеше: «Углымның җеназа намазын укысаңыз», — дип риҗа кыйлды. Кунаклар, хәбәрдар булып, җөмләсе дәфгатән егълаштылар. Ул кеше, бичара, дусларының вә кунакларының күңелләре мөкәддәр[6] булма-

---

[1] Тәхкыйк — һичшиксез.
[2] Бәшарәт — шатлык.
[3] Һәрисә — төйгән бодай белән каклаган иттән хәзерләнгән ашамлык.
[4] Һиммәт вә мөрәүвәт — тырышлык һәм егетлек.
[5] Бостанында — бакчасында.
[6] Мөкәддәр — кайгылы.

сын дип, җегәр парәсенең ифтиракына[1] тәхәммел[2] вә сабыр кыйлды.

———

Әмараи кәрамнан бәгъзеләренә әйттеләр: «Тәгам вакытында әмир танымаган вә әмиргә мәгълүм булмаган кешене мәнгы кыйлмакта зарар булмаса кирәк, зирәки бер явызлык касды белән йөргән адәм тугыры килеп, әмиргә явызлык касд кыйлыр», — дигәч, ул әмир әйтте: «Бер дошман ки тәгамымызга керсә, Аллаһы Тәгалә ул дошманга ирек бирмәс», — диде.

———

Һинд олугларының береннән мәнкульдер ки: бер кунакны кич өендә кундырмак теләсәң, кәндездән аңа хаҗәтханәне белдер. Зирә әүвәлге хәлләремдә мин бер җирдә кунак булып калмыш идем, төнлә хаҗәтханәне таба алмагач, нәгыйлаҗ[3] такыяма тәләввес кыйлдым, димештер.

———

Имам Шәфыйг хәзрәтләре хәдис шәриф укымак өчен Бәгъдадка барган заманында, Зәгъферани дигән кемсәнәнең ханәсенә мөсафир булды. Зәгъфераниның гадәте — һәркөн хәзерләнәсе ашларның исемен кәгазьгә язып, аш хәзерләгүче җариясенә бирер иде. Имам Шәфыйг беркөн бу кәгазьне күрде, Зәгъферани юк вакытта, янә ничә төрле тәгам исемен арттырды. Зәгъферани монхәбәрдар булгач, имам Шәфыйгның дусларча тәкәллефсез мөгамәләсенә кәмаль шатлыгыннан ул пешекче җарияне азат кыйлды.

———

Бер саран кешедән сорадылар: «Катылык вә шиддәттән соң шатлык ни-нәрсәдер?» — дигәч, әйтте: «Бер мөсафир килеп, тәгам гарыз кыйлганда, мин рузамын димәкедер», — диде. Ягъни: бер кунак, мин рузамын, дисә, саран кеше аңа шатлана, имеш.

———

Бер накәс саран кемсәнә үзенең ханәсендә алдына каймак белән бал куеп ашап утырганда, ишеген берәү какты. Ишек ачып, кунакны өйгә керткәнче, углына: «Балларны җыештыр», — дип кушты. Углы, каймакны вә икмәкне җыештырып, балны яшерергә өлгерә алмады, кунак килеп керде, балны күрде. Бу саран кемсәнә, кунак ялгыз балны ашамас диебрәк гөман кыйлып, кунакка әйтте: «Әфәндем, балны икмәксез ашасаң хуш була», — диде. Кунак дәхи тәмам иштиһа белән балны сосып-сосып ашаганда, саранның эче пошып: «Әфәндем, Аллаһы белер, икмәксез, бәлки, мотлака бал мигъдәне[4] яндыра-

---

[1] Ифтиракына — аерылышуына.
[2] Тәхәммел — түзү, чыдау.
[3] Нәгыйлаҗ — чарасызлыктан.
[4] Мигъдәне — ашказанын.

дыр, дип әйтәләр», — диде. Кунак әфәнде зөрафадан бер адәм, имеш: «Бәли, бал мигъдәне яндырыр, дөрес әйтәсең, ләкин синең мигъдәнне яндырадыр», — дип җавап биреп, балны тәмам кыйлды.

---

Бер кемсәнә ачлык галәбә кыйлып: «Тукта, фәлән кешегә бараем, бер-бер нәрсә ашап кайтырмын», — дип, ул кешенең ишегенә барып сугылды. Күрде: капкасы төбендә бер егет торыр. «Хуҗаң өйдәме?» — диде. Ул егет әйтте: «Бер кисәк икмәк бир, әйтермен», — диде. Бу фәкыйрь кемсәнә: «Моның каравылчысы коры икмәккә мохтаҗ, имеш, өендә шурпасы кайчан булыр?» — дип кайтып китте.

---

Бер хәсис вә ләим[1] үзенең бер дустын дәгъвәт итеп, аңа бер микъдар пәйнер белән икмәк утыртты. «Әфәндем, моны аз димә, зирә пәйнернең кадагын өч дирһәмгә алдым», — диде. Кунак әйтте: «Әй әфәндем, кайгырма, мин аны арзан итәрмен, ярты дирхәмгә төшерермен», — диде. Ләим әйтте: «Бу ни кәйфияттә ярты дирһәмгә төшәр». Кунак әйтте: «Әфәндем, мин икмәкнең бер локмәсен пәйнер белән, ике локмәсен пәйнерсез кабармын да, ул арзан төшәр», — диде.

---

Бәгъзе таҗирләрдән[2] мәнкульдер ки: «Кадимге падишаһларның вәзирләреннән Әбү Хәфас әл-Кәрхи дигән кеше мине комаш алмак өчен сараена чакырды. Комашларымны алып бардым. Алдында табак-табак җимешләр бар иде, комашны сатып алды. Эшем беткәч, торып китмәгә теләгән идем, ул вәзир әйтте: «Бу ни гаҗәп надан халык?!» — диде, ягъни китмәкемне мәгъкуль күрмәде. Аннан соң мине икрам кыйлмага тели, имеш, дип утырдым, вә ишарәт кыйлды, җимешләреннән тәнавел кыйлдым. Янә тәгам китерделәр, карыным ач иде, яхшылап ук ашарга тотындым. Тәгам тәмам булгач, рөхсәт алдым, дөкянемә кайттым, һич хәбәрем юк иде.

Иртәсе көн мәзкүр вәзирнең хезмәткәре килеп, мине бергә арбасына утыртып, алып вәзир хозурына илтте. Вәзир, мине күргәч тә, илтифат кыйлып, көлеп: «Әй таҗир, минем ашаганым тиз һәзым кыйлынмайдыр, аз ашыймын. Кичә синең белән бергә ашаганым яхшы булды, моннан соң һәркөн миңа тәгамга хәзер бул», — диде. «Мин һәр көн саен аның тәгамына барыр булдым. Бер сәбәп белән бер көн бара алмасам, хезмәткәрен җибәреп, мине алдырыр иде. Бу вәзиргә билә якынлык хасыйл итеп, аның саясендә күп дәүләткә васыйл булдым», — диде.

---

[1] Хәсис вә ләим — әшәке һәм саран.
[2] Таҗирләрдән — сәүдәгәрләрдән.

———

Бәгъзе мөхазаратта[1] мәнкульдер ки: жумартлык белән, ингам вә ихсан белән могтад[2] вә мәшһүр бер адәм бар иде, ләкин зыяфәт кыйлган вакытта, гарбид иде вә кунакларына яман холык изһар кыйлыр иде. Бәгъзе әзкиядән[3] бер кеше моның шөһрәтен ишетеп, бу кешенең халыкка биргән ингам вә ихсаны вә мөсафирларны икрам кыйлмакы кәримеләхлак булмакына дәләләт кыйлыр[4]. Ләкин халыкның аны яман холыклы дип зәм кыйлмаклары галиба кунакларының үзләренең сүи әдәбеннән садир булган хәл булмакында шөбһә юктыр. Һәрничек аның белән танышлыгым булмаса да, тофәйли тарикынча беркөн зыяфәтенә барып, хакыйкать хәлне тәҗрибә итәем, дип фикерләп барганда, юлда бу кеше үзе миңа раст килеп, тәгъзыймән[5] сәлам бирдем, сәламемне кайтарганнан соң: «Мәйлеңез бармы, рәхим итеңез ханәмезгә, кунак булыңыз», — диде. Мин дәхи, нәгам, дип, бәрабәр ханәсенә киттем. Ханәсенә кергәндә, боерыңыз, дип, мине алдан җибәрде. «Бисмиллаһ» дип кердем. «Югары утыр», — диде, тәкәллефсез генә күрсәткән җиренә барып утырдым. «Таянып торыңыз», — дип, култык мендәре китерде. Мендәренә таяндым. Шатранж[6] тактасы чыгарып: «Уйнарга мәйлеңез бармы?» — диде.

«Һай-һай» дип, берничә уен уйнадык. Тәгам китерелгәч, тәгамның нәфисләрен, йомшакларын алдыма алып-алып, боерыңыз, диде. Һәртөрле нигъмәттән табигатем йөкләрлек кадәр тәкәллефсез ашадым. Тәгамнан бушагач, кул юдырмакчы булып, әкрәмә кулыма су салды, мәныг кыйлмадым, кулымны юдым, аннан соң янымнан чыгарга изен сорады. «Яхшы, мин дәхи рөхсәтеңез булса китәем», — дидем. «Китмә, утыр әле» — димәде. Бу вакытта мин әйттем: «Әфәндем, сезнең белән мөкаддәмдә өлфәтем вә танышлыгым юк булса да, әлхәмделиллаһи, икрам вә илтифат кыйлдыңыз. Бу ни сердер ки, кәрәм итеп сөйләсәңез иде, зирә хакыңызда шулай-болай дип ифтиралар бар», — дип, шөһрәтене хәбәр бирдем. Әйтте: «Валлаһи, әй борадәр, минем андаен әхлакымның зоһурына кунакларымның сүи әдәпләре сәбәптер. Зирә кунакларым килсә, югары утырыңыз, дип әйтәмен, имтинаг[7] кыйлалар, нәфис нигъмәтләремне алларына куямын, бер локмә булсын, ашамастан урынына кайтарып салалар; кулларына суны үзем салып, кулларын юдыр-

---

[1] **Мөхазаратта** — бәхәс итәргә өйрәтә торган фәндә.
[2] **Могтад** — гадәтләнгән.
[3] **Әзкиядән** — сизгерләрдән, зирәкләрдән.
[4] **Дәләләт кыйлыр** — өйрәтеп күрсәтер.
[5] **Тәгъзыймән** — олылап, хөрмәтләп.
[6] **Шатранж** — шахмат.
[7] **Имтинаг** — үзенне тыю, тыйнаклану.

макчы буламын, хаша вә хаша[1], дип, кул юдырудан мәныг кыйлалар; тәгамнан соң озатаем дисәм, якама ябышып, чыкма-чыкма, дип мәныг кыйлалар. Аннан соң ачигым килеп, һи накәс, ханә иясенә икрам булмасмы, кеше үз ханәсендә ни эшләсә дә эшләр, дип, билиҗбар шәтем вә ләгын итәмен, мондаен адәмнәрне сүксәм, бәлки, кыйнасам, гөнаһым бармыдыр», — дип гатзар кыйлды. Мин дәхи мәляхәзәм[2] раст икәнен биттәҗрибә үгрәндем, димештер.

---

Бер кешенең бер саран дусты бар иде. Бервакытны ул дустына әйтте: «Әй дус, халә мин сәфәр кыйлмак теләймен, миңа йөзегеңне бирсәнә. Сине сагынган вакытта бармагымда йөзегеңне күреп, сине исемә төшерер идем», — диде. Ул саран дусты әйтте: «Әгәр мине исеңә төшерәсең килсә, бармагыңа кара, кайчан ки бармагыңда йөзек күрмәсәң, һи фәлән дустымнан йөзеген сораган идем, бирмәде, дип мине исеңә төшерерсең», — диде.

---

Бер галим кемсәнә бер шәһәргә барган вакытында ишетте ки, бу шәһәрдә фәлән исемле җумарт адәм бар, ингам-ихсан кыйладыр вә мөсафирларны зыяфәт кыйладыр, диделәр. Бәс, бу данишмәнд[3], начар гына кием киеп, ул җумартның ханәсенә китте. Ул кеше моңар һич илтифат кыйлмады, утыр, дип, урын бирмәде, бу мөсафир шәрмендә булып кайтты. Икенче көн янә нәфис киемнәр киеп, ул җумартның ханәсенә барды. Бәс, ханә иясе бу мөсафирны тәгъзыйм-тәкрим кыйлып, югары утыртты вә алдына нәфис нигъмәтләр китерде. Бәс, бу мөсафир нәфис нигъмәтләрдән алып-алып, үзенең нәфис киеме өстенә куя башлады. Ханә иясе әйтте: «Әй әфәндем, ни өчен билә кыйласың?» — диде. Мөсафир әйтте: «Кичә начар кием белән килеп һич тәгам тапмаган идем, бу көн өстемдә нәфис кием икән, бу тәгам киемем өчен, имеш, үзем өчен түгел, имеш», — диде. Ханә иясе шәрмендә булып гозер теләде.

---

Фөсахаи нисадан бер хатын дәгъва белән бер казый хозурына килгәч, казый касдан яки хатән: «Шаһидләрең синең белән килде», — диде. Бу хатын асла җавап бирмәенчә тик торды. Дәрхаль казыйның язучысы: «Әй хатын, казый әфәндегә ник җавап бирмәйсең?» — дип, тәркибен җитештереп әйтте. Аннан соң хатын дәхи: «Бәли, шаһидләрем бергә килде, ни буладыр иде, әй казый әфәнде, син һәм кятибың шикелле мөбһәмсез сорасаң, синең яшең күбәймеш, сакалың озаеп, күкрәгеңә

[1] Хаша вә хаша — һич-һич, беркайчан да.
[2] Мөляхәзәм — фикер йөртүем.
[3] Данишмәнд — галим.

таралмыш. Синең кебек терекләр арасында хөкем иткән үлекне күргәнем юк», — дип, казыйны мәсхәрә кыйлды.

———

Мөгътәсыйм биллаһ хәлифәнең хәрәмендә булган бер хәсы[1] хезмәтчесе бер кеше белән дәгъва кыйлышып, казый әл-Козат имам Әбү Йосыф хәзрәтләренә килеп, дәгъва вакытында хәсымы белән бәрабәр тормаенча, азрак алгарак килде. Имамның хаҗибе: «Хәсымың белән бәрабәр тор», — дип, мәныг кыйлса да, һәнүз тыңламады, янә алдарак торды. Имам әйтте: «Шәригать мәҗлесендә хәсымың белән бәрабәр тор, дип, сиңа әмер кыйлдылар, ни өчен бәрабәр тормайсың, барыңыз, фәлән ясерчене[2] алып килеңез, бу колны аңа сатып, акчасын әмирел-мөэмининнгә күндерәем», — дип гыйтап кыйлып, кулыннан тотып, хәсымы белән бәрабәр тордырды. Хөкем тәмам булгач, бу хәлифәнең хезмәтчесе, егълап кайтып, хәлифәгә шикаять кыйлды. Хәлифә дәхи, гыйтап кыйлып: «Әгәр саткан булса иде, сәмәнеңне әбәдән милкемә кертмәс идем. Минем каршымда никадәр кадер хөрмәтең булса да, синең мәртәбәң шәригатьтән олуграк түгелдер, зирә шәригать әсасы солтанәт вә каваме дин вә милләттер», — диде.

———

Беркөн бер җеназа китерделәр. Җеназасына тормастан әүвәл пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Бурычы бармы?» — дип сөаль кыйлганда: «Бәли, йә Рәсүлуллаһ, ике динар бурычы бардыр», — дип җавап бирделәр. Пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Сезләр карендәшеңез намазын әда кыйлыңыз», — дип китеп барганда, Гали разыйаллаһу ганһу: «Йә Рәсүлуллаһ, ул ике динар минем алачагым иде, мин бәхилләдем», — диде. Аннан соң Рәсүлуллаһ ул мәетнең җеназасын әда кыйлып, хәзрәти Галигә хитабән: «Йә Гали, Аллаһы Тәгалә сине хәер белән җәзаландырсын, мәет булган мөэмин карендәшеңнең риһанын фәк кыйлып[3], бурычтан коткарган кебек, синең һәм риһаныңны фәк кыйлсын».

———

Бер мәҗүси вафат булды. Муенында күп бурычы бар иде. Углына әйттеләр: «Йортыңны сат, атаңның бурычларын әда кыйл», — диделәр. Углы әйтте: «Алай итсәм, атам оҗмахка керерме?» — диде. «Юк», — диделәр. Ул әйтте: «Алайса тимәңез, тимә, эти ятсын утта, мин тораем йортта», — диде.

———

Берәү бер кешегә әйтте: «Миңе хосумәткә[4] вә дәгъвага үгрәтсәнә», — диде. Ул кеше әйтте: «Бирәчәгеңне инкяр кыйл,

---

[1] Хәсы — дошман.
[2] Ясерчене — кол сатучыны.
[3] Риһанын фәк кыйлып — закладтан азат итеп.
[4] Хосумәткә — дошманлыкка, явызлыкка.

юкны дәгъва кыйл, үлгән кешене гуаһ кыйл, яминне тәэхир кыйл, шулай итеп үгрәнерсең аны хосуматкә», — диде.

---

Ике кеше бер казыйга хөкемгә килделәр. Берсе-бер тукта-май сөйләшә, икенчесенә сөйләшергә ирек бирмәй. Ул арада сөйләшмәй торганы торды да: «Әй казый әфәнде, гаибкә вә күз артында хөкем итәсең», — диде. Казый әйтте: «Ничек алай?» Ул кеше әйтте: «Мин монда юк, мин гаибмен, ягъни миңа бер кәлимә сүз әйтергә ирек юк икән, мин гаиб мәнзилендәмен», — диде.

---

Беркавым бер казыйга барып дәгъва кыйлыштылар, бер хөрмә агачы хосусында, әмма шаһидләре бар иде. Казый шаһидләрдән сорады: «Ничә хөрмә агачы бар?» — диде. «Белмәй-мез», — диделәр. Казый бу дәгъваны рәд кыйлды. Бер шаһид әйтте: «Әй казый әфәнде, утыз ел бу мәсҗеттә казыйлык кыйла-сың, мәсҗетнең ничә баганасы бар, белмәйсең», — диде.

---

Бер казыйга бер хатын хөкемгә торды, иреннән шикаять кыйлды: «Нәфәка[1] бирмидер», — диде. Ире әйтте: «Мин кодрә-темнән килгән кадәр нәфәка бирәмен, ул минем кодрәтемнән артыкны сорый», — диде. Казый әйтте: «Синең никадәр бирер-гә кодрәтең бар?» Ул кеше әйтте: «Минем су бирергә кодрә-тем бар, әмма ул икмәк тә сорыйдыр», — диде. Казый көлде дә ингам кыйлып җибәрде.

---

Бәгъзе суфиларга әйттеләр: «Җөббәңне[2] сат, акча булыр», — диделәр. Суфи әйтте: «Балыкчы кармагын сатса, ни белән ба-лык тотса кирәк?» — диде.

---

Беркөн Мөхәммәд бин Кәгаб Сөләйман бин Габделмәлик янына керде, күрде: суфилар киеме кебек бер кием торыр. «Бу ниндәен иске кием?» — диде. Сөләйман әйтте: «Әгәр заһид-лык өчен дисәм, үземне мактау була, әгәр фәкыйрьлек өчен дисәм, Аллаһы Тәгаләдән шикаять кыйлу кебек була, бер кием-дер тагы», — диде.

---

Бер адәм, бер мәктәпханә яныннан үтеп барганда, ишетте: бер хәлфә бер балага сабак бирер, шөйлә ки, теле телгә йок-май. Шаять ки ул, бала шул кәйфияттә мәктәп гыйлемен укып тәмам кыйлган булса, тиз сөйләшергә бик оста булгандыр, әм-ма мәгърифәт хасыйл иткәндер, димә.

---

[1] Нәфәка — яшәү өчен бирелгән мал (акча).
[2] Җөббәңне — чапаныңны.

Бер мөәзинне манарада күрделәр: кулында иман шарты бар, азанны иман шартыннан карап әйтә, имеш. Сорадылар: «Ник карап әйтәсең, азан кәлимәләрен күңелеңнән белмәйсеңме?» — диделәр. «Мулладан сораңыз», — диде. Муллага бардылар. Мулла ул вакытта ишегалдында икән, барып: «Әссәламәгаләйкем!» — дип сәлам бирделәр. Мулла, сәлам алмай, өенә кереп китте дә бер китап алып чыкты, актарды-актарды да: «Вәгаләйкемәссәлам!» — диде. Хәер, мулласы да шулай икән, дип киттеләр.

---

Бер мөәзингә әйттеләр: «Син азаныңны кычкырып әйт, без ишетмәймез», — диделәр. Мөәзин әйтте: «Валлаһи, мин үз тавышымны бер чакрымнан ишетәмен», — диде.

---

Бер исерек бер яман тавышлы мөәзингә очрады, мөәзинне тотып, җиргә егып салды да өстенә менеп таптады. Халык җыелды, мөәзинне коткардылар. Исерек әйтте: «Мин мөәзинне болай тавышы начар булган өчен екмадым, ләкин яһүдиләр мөселманнардан мәсхәрә кыйлмасыннар дип ектым», — диде.

---

Берәү бер падишаһка килеп, Аллаһылык дәгъвасы кыйлды. Ул мәҗлестә кечкенә күзле бер бала бар иде. Падишаһ әйтте: «Әгәр тәңрелек дәгъвасында сүзең раст булса, бу баланың күзе кечкенәдер, аның күзен зурайт», — диде. Бу Аллаһыланучы әйтте: «Без ике агай эне: минем агам күктәгеләргә тәдбир кыйладыр, адәмнең билдән югарысына ул хуҗадыр; мин җирдәгеләргә тәдбир кыйламын, адәмнең билдән түбәнге өлешенә мин хөкем итәмен. Әгәр билдән түбән зурайтасы җире булса, әйт, зурайтырмын», — диде.

Болай сүзен мәзахка[1] җибәргәч, падишаһ гафу кыйлды.

---

Берәү: «Мин пәйгамбәр», — дип дәгъва кыйлды. Падишаһка тотып китерделәр вә пәйгамбәрлегенә дәлил, могҗиза сорадылар. Ул пәйгамбәрләнүче әйтте: «Минем бер могҗизам бар ки, суга бер ташны салырмын, шул сәгать таш суда тоз кебек эреп китәр», — диде. Куеныннан чыгарып, бер ташны суга салды, шул сәгать тоз кебек эреде. Әйттеләр: «Син ташны үз куеныңнан чыгарып салдың, анда бер хәйлә бардыр дип беләмез. Без сиңа бер таш бирәек, шул ташны суга сал, тоз кебек эресен, пәйгамбәрлегеңә ышаныпмыз», — диделәр. Ул пәйгамбәрләнүче әйтте: «Бак, сез фиргавеннән олуг түгелсез, миндә һәм Муса пәйгамбәрдәге кадәр хикмәт юктыр. Муса пәйгамбәргә фиргавен әйтмәде ки, мин үзем бер таяк бирәем дә, шул таякны

---

[1] Мәзахка — көлкегә.

аждаһа ит, дип», — диде. Аннан соң падишаһ: «Һи, дивана», — дип көлде дә гафу кыйлды.

---

Бер падишаһка бер кеше килде: «Мин пәйгамбәрмен, мине белмәйсең?» — диде. Падишаһ әйтте: «Аллаһы Тәгалә сине кайсы кавемгә пәйгамбәр күндерде?» — диде. Ул кеше әйтте: «Сиңа вә һәм синең рәгыятеңә пәйгамбәр итеп җибәрде», — диде. Падишаһ әйтте: «Алаймы? Әмма син ахмак пәйгамбәр икәнсең», — диде. Ул кеше әйтте: «Расттыр, һәркайчан пәйгамбәр кайсы кавемгә җибәрелсә, шул кавемнең үзләре кебек буладыр, кавеменә күрә пәйгамбәр җибәреләдер», — диде. Падишаһ көлде дә әмер кыйлды, хәзинәдән ингам кыйлып җибәрделәр.

---

Бер падишаһка бер кеше әйтте: «Мин Ибраһим пәйгамбәр, мине беләсезме?» — диде. Әйттеләр: «Ибраһим пәйгамбәрнең күп могҗизалары бар иде, синең ни могҗизаң бар?» — диделәр. Ул кеше әйтте: «Ибраһим пәйгамбәрнең ни могҗизалары бар иде?» Әйттеләр: «Нәмруд падишаһ олуг ут якты, Ибраһим пәйгамбәрне утка атты, Ибраһим пәйгамбәргә Нәмруд уты гел бакчасы булды, Ибраһим пәйгамбәрне яндырмады, сәламәт котылды. Безләр һәм олуг ут ягып, сине утка ташлаек, ут сине яндырмасын, пәйгамбәрлегеңә ышанырмыз», — диделәр. Ул кеше әйтте: «Һай, зур могҗиза сорадыңыз», — диде. «Алайса, Гайсә, пәйгамбәрнең могҗизасын күрсәт», — диделәр. «Аның могҗизасы ни иде?» — диде. «Үлекне тергезде», — диделәр. Бу кеше әйтте: «Китереңез кылыч, бу падишаһның муенын чабып өзәем, дәрхаль тергезермен», — диде. Падишаһ әйтте: «Дөрес, бар, кит тизрәк, сүзең ялган булса да, ышандым», — диде.

---

Бер кеше, бер падишаһка килеп, пәйгамбәрлек дәгъвасы кыйлды. Падишаһ әйтте: «Син пәйгамбәр булсаң, шул сәгать миңа кавын хәзер ит», — диде. Ул кеше әйтте: «Өч көн миңа миһләт биреңез, мин сезгә өч көннән кавын хәзер итәрмен». Падишаһ әйтте: «Юк, миңа хәзер булсын». Ул кеше әйтте: «Тукта, сабыр ит, Аллаһы Тәгалә җирне-күкне алты көндә яратты, алай булса да кавынны өч айсыз өлгертмәйдер», — диде.

---

Насрулла исемле бер кеше: «Мин пәйгамбәрмен», — дип дәгъва кыйлды. Әйттеләр: «Пәйгамбәрлегеңә дәлилең бармы?» «Бар», — диде. «Ни дәлилең бар?» — диделәр. Әйтте: «Аллаһы Тәгалә минем пәйгамбәр булып килмәгемнән Коръәндә үзе хәбәр бирде», — диде. Әйттеләр: «Могҗизаң бармы?» «Бар», — диде. «Ниндәен могҗиза?» — диделәр. Әйтте: «Миңа китереңез баладан туктаган бер бик карчык хатынны. Мин никяхланырмын, хәзер баласы булыр, тугач та сөйләшә башлар, минем

пәйгамбәрлегемә гуаһлык бирер», — диде. Ул мәҗлестә бер карт вәзир бар иде, аңа әйттеләр: «Китер карчыгыңны, моның могҗизасын күрәек», — диделәр. Ул вәзир әйтте: «Ышанмаган кеше китерсен, мин ялганлыгына ышанамын», — диде.

---

Бер падишаһка, пәйгамбәрлек дәгъвасы кыйладыр, дип, берәүне тотып китерделәр. Падишаһ әйтте: «Пәйгамбәр булсаң, могҗиза булырга лаек, ни галәмәтең бар?» — диде. Бу кеше әйтте: «Мин кешенең күңелендә ни-нәрсә барын беләмен». Падишаһ әйтте: «Хәзер дә минем күңелемдә ни-нәрсә бардыр?» Ул кеше әйтте: «Синең күңелеңдә шул бар ки: син мине хәзер дә ялган әйтә дип уйлап торасын», — диде. Падишаһ әйтте: «Дөрес әйтәсең, ләкин пәйгамбәрлегең янә артсын», — дип, зинданга күндерде. Берничә көннән янә чыгарды. «Нихәл, зинданда вакытта сиңа вәхи килдеме?» — диде. Ул кеше әйтте: «Килмәде ләбаса, зинданга Җәбраил фәрештә кермәй, имеш» — диде.

---

Бер падишаһка, пәйгамбәрлек дәгъвасы кыйладыр, дип, бер хатынны тотып китерделәр. Ул хатынга әйттеләр: «Син Мөхәммәд пәйгамбәргә иман китерәсеңме?» — диделәр. «Бәли, китерәмен», — диде. Әйттеләр: «Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйткән ләбаса, миннән соң пәйгамбәр килмәс, дип. Син аңар ышанмаймысың?» — диделәр. Хатын әйтте: «Бәли, миннән соң пәйгамбәр килмәс, — диде, — ләкин миннән соң хатын пәйгамбәр килмәс дип әйтмәде», — диде. Падишаһ көлде дә гафу кыйлды.

---

Нух исемле бер кеше пәйгамбәрлек дәгъвасы кыйлды. Аның бер дусты бар иде, күп үгет-нәсихәт кыйлды, булмады. Ахыр падишаһка мәгълүм иттеләр, падишаһ бу кешене асмага әмер итте, астылар. Бервакытны дусты узып барганда, күрде Нухны асалар. Әйтте: «Әй Нух, көймәңнең файдасы таган башына менәрлек кенә булыптыр, үзеңне әҗәл туфаныннан да коткармайдыр», — диде.

---

Бәни Исраил эчендә бер габид[1] вә заһид кемсәнә бар иде. Кай тарафка барса да, Аллаһы Тәгаләнең әмере белән өстендә бер кисәк болыт йөрер иде. Көннәрдә бер көн бу габид янына күләгәләнмәк өчен, бер кемсәнә килгәч: «Яныма якынлашма, зирә халык бу болытны синең өстеңдәме, минем өстемдәме икәнен иштибаһ[2] итәрләр», — диде. Ул кеше әйтте: «Вәсвәсәләнмә, зирә халык минем болыт белән күләгәләнмәгә әһел түгел икәнемне беләләр», — диде. Дәрхаль Аллаһы Тәгалә ул

---

[1] Габид — гыйбадәт итүче.
[2] Иштибаһ — шикләнү, шөбһәләнү.

болытны бу кеше өстенә тәхвил кыйлды. Габидның риясы сөкут мәнзиленә багыйс булды[1] вә ул кешенең косурын игътираф кыйлмакы[2] дәрәҗәсе күтәрелүгә сәбәп булды.

---

Сәлми дигән касас, беркөн халыкка хикәят вә кыйсса сөйләп утырганда хитап кыйлып: «Әй җәмәгать, сезләр мине риялы дип игътикад кыйлырсыз, гамәлеңне халыкка фаш итәсең дисрсез, Аллаһы Тәгалә беләдер, кичәге көн руза идем, руза икәнемне бераүгә дә әйтмәдем», — дип, рәҗгать гамма сәҗгать юлынан бер рия сатмыштыр.

---

Бәгъзе голямадан сөаль кыйлдылар ки: «Тәкиядә утырган мөтәсаувифиннарның[3], ягъни риялы суфиларның, хәлләре ни кәйфияттәдер?» Әйтте: «Аларның хәлләре ашамак, эчмәк, рәкыс вә ләгыбдыр»[4], — диде.

---

Бер адәм берничә ел озак сәфәрдә йөреп кайтты. Ишанлык дәгъвасы кыйлып, үзенә ишан исемен чыгарды. Бәгъзе ахмаклар моңар иярделәр. Бара торгач, ахмаклыгы сәбәпле, ишан исеменнән газәл кыйлынды. Халык миңа ихлас куйсыннар, дип, ялган кәрамәтләр изһар кыйлып[5], бәгъзе наданнарны алдаштырды. Бервакытны бу ишан әфәнде үзенең якыннарыннан бер кызга әйтте: «Без фәлән кеше белән йөрергә чыгармыз, шул вакытта син безгә бер савыт җиләк җыеп, юл өстендә ашлык арасына посып тор, без узып барганда, ашлык арасыннан җиләкне суз, үзең күренмә», — дип тәнбиһ кыйлды.

Ахыр бу кыз, ишан әфәнденең әмеренчә, бер мәгълүм көнне бер табак җиләк җыеп, ашлык арасында посып торды. Бу ишан үзенең берәр мөриде белән юлдан барганда, күрделәр: ашлык өстендә бер табак җиләк торыр. Ишан әфәнде: «Бисмиллаһи рәхман ир-рәхим, аллаһуммә салли галә», — дип, җиләкне барып алды, мөриденә әйтте: «Кил фәлән, кәрамәт җиләге ашаек, әмма бу вакыйганы һичкемгә сөйләмә, бу җиләк безгә Аллаһы Тәгаләдән килде фәрештә аркылы», — диде. Җиләкне юлда утырып ашадылар.

---

Бервакытны Гомәр разыйаллаһу ганһу Шамга китәсе булды. Бер кеше әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, Рәсүлуллаһ мәсҗетен

---

[1] **Риясы сөкут мәнзиленә багыйс булды** — икейөзлелеге түбәнгә төшүгә сәбәп булды.

[2] **Косурын игътираф кыйлмакы** — кимчелеген тануы.

[3] **Мөтәсаувифиннарның** — суфиларның.

[4] **Рәкыс вә ләгыбдыр** — бию һәм уен-көлкедер.

[5] **Кәрамәтләр изһар кыйлып** — юмартлыклар күрсәтеп.

калдырып, Шамга китәсеңме?» — диде. Гомәр разыйаллаһу ганһу әйтте: «Рәсүлуллаһның өммәтен ислах өчен Рәсүлуллаһ мәсҗетен калдырамын», — диде. Ул кеше сөкүт кыйлып калды.

---

Бер кеше хәзрәти Галигә берәүне житәкләп килде, әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, бу кеше минем анамны төшендә күреп, синең анаң белән төшемдә ихтилам булдым дип әйтәдер», — диде. Гали разыйаллаһу ганһу әйтте: «Алайса син аны кояшка алып чык та күләгәсен кыйна», — диде.

---

Имам Шәгъбигә әйттеләр: «Иблиснең хатыны ни исемледер?» Шәгъби әйтте: «Хәер, никях мәҗлесендә мин юк идем», — диде.

---

Бер кемсәнә олуглардан бер адәм янына керде. Ул кеше әйтте: «Нихәл, ни бар, ни юк?» — диде. Кыш көне иде. Ул кергән кеше дәрхаль: «Барын сорасаң, тышта суык бар, югын сорасаң — утын юк, утын алырга акча юк», — диде.

---

Берәү бер кеше янына керде. Ул кеше әйтте: «Нихәл, ни бар, ни юк?» — диде. Бу кергән кеше әйтте: «Аллаһы бар, шәриге юк», — диде.

---

Бер кеше бин Габбас разыйаллаһу ганһудан сорады: «Рәсүлуллаһ олугмы яки сез олугмы?» — диде. Ибн Габбас разыйаллаһу ганһу әйтте: «Рәсүлуллаһ олугдыр, мин Рәсүлуллаһтан мөкаддәм тугдым», — дип, хөсне әдәп үзрә җавап бирде.

---

Хәлифәләрдән бер хәлифә Сәгыйд бин Мәрәгә: «Син Сәгыйдмесең?» — диде. Сәгыйд бин Мәрә әйтте: «Сәгыйдлеккә сез сәгыйдсез, мин Мәрә углы», — диде.

---

Маэмүн хәлифә Сәед бин Әнәскә әйтте: «Син Сәедмесең?» — диде, ул дәхи тиз үк зарафәт үзрә[1]: «Әмирел-мөэминин сәедтер, мин Әнәс углымын», — дип җавап бирде.

---

Гарәп әмирләреннән Мәһләб Хәҗҗаҗ хәлифә белән бергә йөргән вакытта, Хәҗҗаҗ сорады: «Синме әтъвал[2] яки минме әтъвал?» — диде. Әмма филвакыйг Мәһләб Хәҗҗаҗдан озынрак иде, әйтте: «Әмир әтъвалдыр, каматтә мин әбсатмын», — диде. Тавылдан миннән вә кәрәм мәгънәсен ирадә кыйлды.

---

[1] Зарафәт үзрә — ягымлылык белән.
[2] Әтъвал — озынрак.

Гали разыйаллаһу ганһудан сорадылар: «Мәшрикъ белән мәгъриб арасы еракмы?» — диделәр. Гали разыйаллаһу ганһу әйтте: «Кояшка бер көнлек юлдыр», — диде.

———

Бер гарәп Мөгавия каршында бернәрсә хосусында гуаһлык бирде, ләкин Мөгавия аның шәһадәтен яратмады: «Ялган әйтәсең», — диде. Гарәп әйтте: «Валлаһи, ялганчы синең киемең эчендәдер», — диде. Мөгавия көлде дә: «Ашыгып җавап әйткәннең җәзасы будыр», — диде.

———

Берәү бер мулладан сорады: «Йә хәзрәт, чыбыркыны билгә кыстырырга кирәкме, сөйрәп барырга кирәкме?» — диде. Мулла әйтте: «Ягъмурлы көн билгә кыстырырсың, коры көн булса, сөйрәп барсаң да ярар», — диде.

———

Бина вә гыймарәткә бик зиһен куйган күп йортлы-җирле кеше бар иде. Бер муллага әйтте: «Йә хәзрәт, Каф тавы артында ниләр бар, әйтсәнә», — диде. Мулла әйтте: «Һи ахмак, инде анда чыгып, гыймарәт кыйлмакчы буламысың?», — диде.

———

Берәү бер имамнан сорады: «Йә хәзрәт, Каф тавы артында бүреләр бар микән?» — диде. Ул имам җавап бирде: «Ул ни эшкә, сарыкларыңны анда чыгарып йөртмәкче буласынмыни?» — диде.

———

Нәсыр бин Сәяр Әби Һиндкә әйтте: «Әби Һинд шәрифләрдән иде, шәраб хур иде, шәрифлекне боздың», — диде. Әби Һинд әйтте: «Мин шәрифлегемне бозмаган булсам, син Хорасанга вәли була алмас идең», — диде.

———

Бер кешегә әйттеләр: «Синең җизнәң вафат, имеш, тутаңа ни мирас калды?» — диделәр. Ул кеше әйтте: «Дүрт ай да ун көн калды да, дүрт кыз бала калды», — диде.

———

Берәүгә үлем сырхавы тиде. Хатыны бар иде, дүрт иргә барып, бу бишенче ире иде. Иренең башы очында утырып егълады: «Инде вафат булсаң, мине кемгә калдырасың?» — диде. Ире әйтте: «Алтынчы иргә калдырамын, явыз иргә», — диде.

———

Әбү Хариска берәү әйтте: «Сиксән яшенә житкәч, кешенең баласы буламы?» — диде. Әбү Харис әйтте: «Күршесендә егерме яшәр егет булса, була», — диде.

———

Берәү бер кешене күрде, углы белән тора. Әйтте: «Углың үзеңә охшамаган икән», — диде. Ул кеше әйтте: «Күршеләремез балаларымызны үземезгә охшарга бирмиләр», — диде.

Бер карчык үзенең иренә әйтте (ире зиначы иде): «Оялмаймысың карт башың белән зина артыннан йөрергә, кайчан кем үзеңнең хуш хәлялең бар», — диде. Ире әйтте: «Хәлял дисәң, бәли, әмма хуш дисәң — юк», — диде.

Бер рәис күрде, ике кеше сөйләшеп тора. «Ни хакында ялганлыйсыз?» — диде. «Синең мәдехең хакында», — диделәр.

Мөгътәсыйм хәлифәнең кулында йөзеге бар иде, бер сабый балага әйтте: «Бу йөзек кашы кебек һәйбәт каш күргәнең бармы?» — диде. Сабый әйтте: «Йөзек эчендәге бармак аннан һәйбәтрәк», — диде.

Пәйгамбәрлек дәгъвасы кыйла дип, Мөгътәсыйм хәлифәгә берәүне тотып китерделәр. Мөгътәсыйм әйтте: «Син кайсы кавемгә пәйгамбәр мәбгус булдың[1]?» — диде. Ул кеше әйтте: «Сиңа вә синең кавемеңә», — диде. Мөгътәсыйм әйтте: «Мин гуаһлык бирәмен ки, син ахмак кешесең», — диде. Ул кеше әйтте: «Дөрес, Аллаһы Тәгалә ахмакларга ахмак пәйгамбәр җибәрде», — диде.

Һарун әр-Рәшиткә берәүне зиндикъ[2] булды дип тотып китерделәр. Һарун әйтте: «Син зиндикъмы?» — диде. Ул кеше әйтте: «Әлхәмделиллаһ, мин намаз укыйм, руза тотам», — диде. Һарун әйтте: «Әмер кыйлырмын, шулай сугарлар, таки зиндикълыгың белән икърар кыйлырсың», — диде. Ул кеше әйтте: «Синең агаларың хәлифә иде, кешене мөселманлык белән икърар кыйлдырыр өчен сугарлар иде, син көфер белән икърар кыйлдырасың, имеш», — диде. Һарун әр-Рәшит оялды да җибәрде.

Гыймран бин Хәттан дигән кешенең бик гүзәл хатыны бар иде, үзе бик тәбәнәк ямьсез адәм иде. Беркөнне хатыны әйтте: «Без икемез дә оҗмахта булсак кирәк», — диде. Ире әйтте: «Нидән әйтәсең?» Хатыны әйтте: «Минем кебек гүзәл хатын сиңа насыйп булды, син шөкер кыйлдың. Аллаһы Тәгалә синең кебек ямьсез кеше белән мине мөбтәля кыйлды, мин сабыр кыйлдым, бәс, сабыр кыйлгучылар вә шөкер кыйлгучылар оҗмахтадыр», — диде.

Маэмүн хәлифәгә берәү килде, әйтте: «Мин гарәп таифәсеннән бер кешемен», — диде. Маэмүн әйтте: «Гаҗәп түгел». Ул кеше әйтте: «Хаҗ бармага ниятем бар иде». Маэмүн әйтте:

---

[1] Мәбгус булдың — җибәрелдең.
[2] Зиндикъ — динсез.

«Юл алдында, Аллаһы Тәгалә сәфәреңне мөбарәк итсен!» — диде. Ул кеше әйтте: «Нәфәкам юк минем», — диде. Маэмүн әйтте: «Синнән фарыз сакыйт[1] алайса», — диде. Ул кеше әйтте: «Мин синнән фәтва[2] сорап килмәдем, синнән бернәрсә ярдәм эстәп килдем», — диде. Маэмүн көлде дә ингам кыйлды.

———

Мансур хәлифә Сөләйман бин Рамилне Мәүсыйлга вали итеп җибәрде, гаҗәм халкыннан мең гаҗәм бирде, әйтте: «Сиңа мең шайтан бирдем, бар алар белән халыкны зәлил кыйлырсың»[3], — диде. Бәс, Сөләйман бу мең кеше белән Мәүсыйл вилаятенә килделәр, Мәүсыйл нәвахисендә күп фәсад[4] кыйлдылар. Мансур аңар хат язды: «Көфране нигъмәт кыйлдың, йә Сөләйман», — диде. Сөләйман Мансурга җавап язды.

Мансур бу җавапны алып укыды да көлде, гаҗемнәрне кайтарып, алар урынына гайреләрне, яхшы адәмнәрне җибәрде.

———

Сакалга мәсих кыйлу хакында Шәгъбидән берәү бер мәсьәлә сорады. Шәгъби әйтте: «Аралаштырмага кирәк». Ул кеше әйтте: «Су тими калыр дип, мин куркамын», — диде. Шәгъби әйтте: «Алайса, сакалыңны кичтән тузанга буяп ят», — диде.

———

Әбү Ягъкубка берәү әйтте: «Әгәр чишенеп госел кыйлыр өчен суга керсәм, йөземне кая таба тәвәҗҗеһ кыйлаем: кыйблагамы, гайре тарафка булса да ярармы?» — диде. Әбү Ягъкуб әйтте: «Йөзеңне киемнәреңә таба кыйлмак артыктыр», — диде.

———

Мөтәвәккил хәлифә мылтык белән бер чыпчыкны атты, тидерә алмады. Ибн Хәмдун әйтте: «Яхшы иттең». Хәлифә әйтте: «Ни-нәрсәгә яхшы иттем?» — диде. Хәмдун әйтте: «Чыпчыкка яхшы иттең дип әйтәм», — диде.

———

Җәриргә берәү әйтте: «Син мохсанатны[5] сүгәсең, имеш», — диде. Җәрир әйтте: «Синең анаңа моннан бер дә зарар юк», — диде.

———

Фәрәздакка берәү әйтте: «Зинадан тәүбә иткәнеңә күптәнме?» — диде. Фәрәздак әйтте: «Синең карчыгың үлгәннән бирле», — диде.

---

[1] Фарыз сакыйт — (өстеннән) фарыз төште.
[2] Фәтва — нинди дә булса эшне дини яктан дөресме-түгелме икәнен күрсәтеп бирү.
[3] Зәлил кыйлырсын — түбәнсетерсен.
[4] Фәсад — бозыклык.
[5] Мохсанатны — әдәпле хатыннарны.

---

Бер хәкимнән сорадылар: «Сөкүт кыйлып сөйләшә торган ни-нәрсә бар!?» — диделәр. Хәким әйтте: «Вәгазь кыйлгучы гыйбрәтләр», — диде. Ягъни: телсез сөйләшә торган нәрсә бармы, дигәндә, гыйбрәт эшләр, дип җавап бирмештер.

---

Бер кешегә әйттеләр: «Син кайчан таяк белән йөрисең, авыру түгел, карт түгелсең», — диделәр. Ул кеше әйтте: «Мин үземне мөсафир дип беләмен», — диде.

---

Һарун әр-Рәшит Бәһлүлгә әйтте: «Син кемне бик яратасың?» Бәһлүл әйтте: «Корсагымны туйдырган кешене», — диде. Рәшит әйтте: «Мин корсагыңны туйдырырмын, мине яратырмысың?» Бәһлүл әйтте: «Мин көтәсегә мәхәббәт итмимен», — диде.

---

Берәү: «Мин фәкыйһ[1]», — дип дәгъва кыйлды. Ишек төбенә палас җәйде, фәтвага утырды, халык фәтвага җыелыр иде. Бер кеше килде, әйтте: «Йә фәкыйһ, ни әйтәсең шул кеше хакында ки; бармагын борынына тыккан иде, кан ияреп чыкты», — диде. Фәкыйһ әйтте: «Ул кеше кан алдырсын». Ул кеше әйтте: «Син монда фәкыйһ булыпмы, табиб булыпмы утырасын?» Фәкыйһ әйтте: «Сиңа табиб, гайреләргә фәкыйһ», — диде.

---

Берәү бер мәҗлестә бер галимнән сорады: «Йә тәкъсыйр, ихтыяте зоһыр[2] хакында ни әйтәсең?» — диде. Бу сөаль ул галимгә имтихан өчен сораган шикелле булып каты тоелды. Бераз сабыр итеп торды да: «Ничек сиңа бу мәсьәлә бу көн генә кирәк булды?» — диде.

---

Бер кеше бер падишаһ ишеге төбендә бер галимнән бер мәсьәлә сорады. Галим әйтте: «Бу мәсьәлә урыны түгелдер». Ул кеше әйтте: «Ник бу галимнәр урынымыни?» — диде.

---

Могтаз хәлифә сабый иде. Бервакытны тәгълим бирергә хәлфәсе килде, әйтте: «Бу көн нидән дәрес башлармыз?» Могтаз әйтте: «Инсирафтан башлармыз», — диде, ягъни бу көн кайтып торсаң да ярар, димәктер.

---

Бер кеше бер рәккасага, ягъни биюче хатынга әйтте: «Ни кул һөнәрең бар?!» — диде. Рәккаса әйтте: «Кул һөнәрем бер дә юк, аяк һөнәрем бар», — диде.

---

[1] Фәкыйһ — дин белгече.
[2] Ихтыяте зоһыр — өйлә намазы вакытына бәйле мәсьәлә.

---

Хəлифə Зияд мəразе мəүт белəн сырхау булды. Шəрих дигəн кемсəнə аның хəлен сорарга килде. Аннан чыккач, Шəрихтəн сорадылар: «Нихəл, Зиядның ни хəле бар?» — диделəр. Шəрих əйтте: «Яхшы, хəзер дə əмарəтен йөртə, əмер кыйла, нəһи кыйла[1]», — диде. Ягъни мөхтəзар булмыш, васыятен йөртмəгə əмер кыйла, миннəн соң нəүхə кыйлмаңыз[2] дип, нəһи кыйла дигəн сүзне ирадə кыйлды.

---

Бер падишаһ үзенең якыннарыннан бер кешене урыныннан газəл кыйлды. Бу кеше бер хəйлə белəн эт кебек өрергə, бүре кебек уларга, ишəк кебек бакырырга, ат кебек кешнəргə үгрəнде. Беркөн падишаһ тəхетендə ялгыз утырып торганда, бу кеше ишек төбенə килеп өрə башлады. Падишаһ əйтте: «Караңыз, эт бар», — диде. Ул арада бу кеше бүре кебек улый башлады. Падишаһ курыкты, тəхетеннəн сикереп төште. Янə ул арада бу кеше ишəк кебек бакыра башлады. Падишаһ тəхетеннəн чыгып качты. Бу ни тавыш икəн, дип чыктылар. Бу кеше ат кебек кешнəде. Моны тотып падишаһка китерделəр. Падишаһ əйтте: «Əй фəлəн, сиңа ни булды, тилерденме?» — диде. Бу кеше əйтте: «Шулай инде, тəкъсыйр, син мине урынымнан төшергəннəн бирле Аллаһы Тəгалə эт сурəтенə кертте, бүре сурəтенə кертте, ишəк сурəтенəə кертте, ат сурəтенə кертте, яңадан элгəреге сурəтемə кертсə дə кадирдыр», — диде. Аннан соң падишаһ, гафу кыйлып, əүвəлге хезмəтен бирде.

---

Беркөн бер падишаһ бəгъзе вəзирлəре белəн сəйранга чыкты, йөри торгач, бер җирдə кешелəреннəн аерылып ялгыз калды. Үзенə бер карт очрады, ул картка əйтте: «Бабай, син кайдагы?» — диде. Карт əйтте: «Мин ошбу шəһəрдəнмен». Падишаһ əйтте: «Бу шəһəрнең хакимнəре ничек?» Карт əйтте: «Хакимнəремез бик залимнар, бик усал кешелəр», — диде. Падишаһ əйтте: «Падишаһ хакында ни əйтəсең?» — диде. Карт əйтте: «Мəмлəкəтемездə моның кебек залим падишаһ булганы юк иде, золымы белəн мəмлəкəтне корытты», — диде. Падишаһ əйтте: «Мине танымайсың, мин кем?» — диде. Карт əйтте: «Юк, танымаймын». Падишаһ əйтте: «Мин шəһəрнең падишаһы булырмын», — диде. Карт əйтте: «Син мине танымаймысың?» Падишаһ əйтте: «Юк». Карт əйтте: «Мин Гажел кабилəсеннəн фəлəн углы фəлəн мəҗнүн, көн саен ике мəртəбə шулай җүлəрлəнеп саташып йөримен», — диде. Падишаһ көлде дə гафу кыйлды вə ингам кыйлды.

---

[1] Нəһи кыйла — тыя.

[2] Нəүхə кыйлманыз — кычкырып еламагыз.

Берәү күрде: бер кешенең өендә матчасы төшеп бара, әйтте: «Бу матчаң төшеп бара, төзәтеп куй», — диде. Ул кеше әйтте: «Тимә-тимә, ул тәсбих әйтә». Бу кеше әйтте: «Мин куркамын, күңеленә йомшаклык килер дә сәждә кыйлыр», — диде.

Бер яшь егет бер карт кешене күрде, бөкрәеп акрын гына бара. «Бабай, ни җуйдың?» — диде. Карт әйтте: «Әй балам, яшьлегемне җуйдым лабаса», — диде.

Берәү бер заманда: «Шикәр харам, шикәр белән чәй эчү дөрес түгел», — дип фәтва бирде. Әмиргә мәгълүм иттеләр. Мөфтиләр: «Бу кеше хәлялне харам дип әйтте, кяфер булды», — дип, үтерергә хөкем иттеләр, сәясәт мәйданына китерделәр. Әмир әйтте: «Сабыр итеңез, бәлки, ул сүзеннән кайтмады микән, сораңыз», — диде. Бу кешедән сорадылар: «Йә, инде шикәр хакында ни әйтәсең?» — диделәр. Бу кеше әйтте: «Шикәр тәмле, тәкъсыйр», — диде. Әмир көлде дә гафу кыйлды.

Берәү бер галимнән сорады: «Коръән өстендә бет үтергәч, ни булыр, тәкъсыйр?» — диде. Галим әйтте: «Шарт итәр», — диде.

Бер кеше бер мулладан сорады: «Баш астына ыштан салып яткач, ни булыр, хәзрәт?» — диде. Мулла әйтте: «Баш астың биегрәк булыр», — диде.

Берәү бер кешедән сорады: «Мәсҗеттә өйлә намазында сәгатьне бормак ничек булыр, килешерме?» — диде. Ул кеше әйтте: «Сәгатеңне борып бетергәч, шарт итеп ябарсың да, кеше синең сәгатең бар икәнен белер», — диде.

Бер карья кешесе бер шәһәр кешесендә кунак булып, өй иясе озата чыккач: «Хуш, сау бул, безгә куна алып кил», — диде. Бу кеше әйтте: «Аллаһы разый булсын!» — диде. Кунарга кил, дип әйтә дип хата фәһемләде.

Берәү бер кешедән пычкы сорады: «Миңа пычкы биреп торсана», — диде. Ул кеше өенә кереп китте дә ышкы алып чыкты. Бу кеше әйтте: «Юк, мин пычкы дип әйтәмен», — диде.

Беркөн бер мәҗнүн өленгесез вә пәрдәсез хәммамга кермеш. Имам Әгъзам хәзрәтләре һәм хәммамда иде, мәҗнүнне өленгесез күреп күзләрен йомды. Имам Әгъзамгә тәгъриза мәҗнүн әйтте: «Йә имам, күзеңез кайчан сукыр булды?» — диде. Имам Әгъзам әйтте: «Син пәрдәңне ерткан заманда», — диде.

Беркөн бер мәҗлестә бер имамнан сорадылар: «Йә тәкъсыйр, ай башы кайчан?» — диделәр. Бу имам бераз торганнан соң җавап бирде: «Айның әүвәл көне», — диде.

———

Берәү бер мәҗлестә бер имамнан сорады: «Йә тәкъсыйр, бу чагында Җидегән йолдыз ник артка каладыр?» — диде. Имам әйтте: «Күп заманнан бирле йөри торгач, арыгандыр, бәлки», — диде.

———

Бер кемсәнә Җәгъфәр бин Мөхәммәд разыйаллаһу ганһуга әйтте: «Аллаһы Тәгаләгә дәлил ни-нәрсә, әмма галәмнән, гарыздан, җәүһәрдән һичнәрсә зикер кыйлма[1]», — диде. Җәгъфәр әйтте: «Син диңгездә йөргәнең бармы?» «Бар», — диде. «Диңгездә каты җил чыгып, гарык буламыз дип курыкканың бармы?» «Бар», — диде. «Анда көймәдән вә көймәчеләрдән безне коткарыр дип өмидең киселдеме?» — диде. «Бәли, киселде», — диде. «Шул вакытта бу һәлакәттән коткарыр кеше булыр дип күңеленә килдеме?» — диде. «Бәли, котылмак өмидем бар иде», — диде. Җәгъфәр әйтте: «Әнә шул Аллаһы Тәгаләдер», — диде.

———

Бер саилгә әйттеләр: «Оялмаймысың, Коръән беләннсаилчелек кыйласын», — диделәр. Саил әйтте: «Сез тик торыңыз, валлаһи, әгәр минем кебек ачыксаңыз вә мохтаҗ вә ялангач булсаңыз, Коръән китерүче Җәбраил фәрештәне үзен сатар идеңез», — диде.

———

Беркөн шәех Сәгъди хәзрәтләре Шираз шәһәрендә гизеп йөргән вакытта бер кыз күрде: гаять томаланып бөркәнгән иде. Кызны шәех Сәгъди шул кадәр күрергә иҗтиһад кыйлды, күрә алмады. Шул вакытта бер шигырь әйтте ки: «Гүзәл вә матур кызлар йөзләрен яшермәенчә йөрсәләр кирәк иде, әмма син йөзеңне өретмешсең, ләкин син матур кыз түгелсең, ахры», — диде. Аңа каршы ул кыз: «Матур вә яшь егетләр тугыруга катып йөрсәләр кирәк иде, ләкин син бөкрәеп барасың, мәгәр нәүҗәван түгелсең, пәштсең[2]», — диде. Бәс, шәех Сәгъди аннан бик күңелсез булып ханәсенә кайтты, һаман күңелсез, ашамай, эчмәй, сөйләмәй берничә көн йөрде. Бу эшкә кызы һәм, хәйран булып: «Әй пәдәр, гаҗәп, кәефеңезгә ни булды? Һич ашамай, эчмәйсез, сөйләшмәйсез», — диде. Шәех Сәгъди әйтте: «Әй кызым, үзем һәм белмәймен, шаять ки әҗәлем якындыр, чөнки бу заманга кадәр сүздә миңа өстен һичкем

———

[1] Зикер кыйлма — искә алма.
[2] Нәүҗәван түгелсең, пәштсең — яшь егет түгелсең, картсың.

чыкканы юк иде, бер жирдә билә вакыйга булды», — дип сөйләде. Кызы әйтте: «Әй ата, мин идем ул», — диде.

---

Бер кеше, бер мөтәсаувиф адәм янына барып, өч мәсьәлә сөаль кыйлды. Әүвәл әйтте: «Ни өчен әйтәсез ки, Аллаһы Тәгалә һәр җирдә хәзердер, әмма һич җирдә Аллаһы Тәгаләне күргәнемез юк, күрсәт. Янә дәхи әйтәсез, һәрни кыйлса, Аллаһы Тәгалә кыйладыр, адәмнең һич кодрәте юк вә Аллаһы Тәгаләнең ирадәсеннән башка бәндә һичнәрсә кыйла алмай, дисез. Алай булса гаепле адәмне ни өчен сәясәт кыйлалар? Янә өченчесе: әйтәсез ки, Аллаһы Тәгалә шайтанны ут белән газап кыйлыр, дисез. Хәлбуки шайтан үзе уттан яратылмыш булса, утны ут белән газап кыйлмакның ни мәгънәсе бар?» — диде. Бәс, ул мөтәсаувиф җирдән бер таш алды да ул кешенең башына орды, ул кеше егълап казый янына китте, әйтте: «Фәлән заһидтан өч мәсьәлә сорадым, мәсьәләмә җавап бирмәде. Башыма таш белән орды, инде башым авыртадыр», — диде. Бәс, казый, ул заһидны чакыртып: «Ни өчен бу адәмнең башына таш белән ордың вә сораган мәсьәләсенә җавап бирмәдең? Сине сәясәт кыйлсам кирәк», — диде. Заһид әйтте: «Әй казый әфәнде, башына таш белән ормакым мәсьәләсенә җаваптыр, инде башының кайсы җире авырта икән, күрсәтсен», — диде. «Мин һәм Ходаны күрсәтермен, янә хозурыңызга килеп ник егълыйдыр, чөнки мин һәрни кыйлсам, Хода ирадәсе белән кыйлдым, Хода ирадәсеннән башка кыйлмадым. Минем ни кодрәтем бар, дәхи ул адәм үзе туфрактан яратылмыш икән, туфрак ник аның башын авырттырсын, юкны сөйли», — диде.

Ул кеше шәрмәндә булып калды[1]. Казый дәхи ул заһидның бу җавабына тәхсин кыйлды.

---

Һарун әр-Рәшиткә сатмак өчен бер җария китерделәр. Һарун җариягә дикъкать белән карап күрде; җария зуррак борынлы, битендә бераз сипкелләре бар. Җарияне сатучыга әйтте: «Әгәр йөзендә сипкел булмаса вә борыны могътәдилрәк булса, алыр идем», — дигәч, җария дәрхаль: «Йә әмирел-мөэминин, рөхсәт боерылыр исә бер сүзем бардыр», — диде. Һарун рөхсәт бирде. Җария әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, киек дәхи бәдәр, ягъни ундүртенче кичә, ай күркәмлек белән мәгъруф икән, киекнең борыны игътидалдан хариҗ бәдәрнең дәхи йөзендә сипкелләр бар», — диде. Бәс, Һарун ул җариянең фәсахәтенә күрә кабул итте.

---

Маэмүн хәлифәгә беркөн сатарга бер җария китерделәр ки, хәсән вә җәмалда бинәзыйр вә һөнәр вә кәмальдә битәкъсыйр,

---

[1] Шәрмәндә булып калды — оятка калды.

ләкин аксак иде. Бәс, Маэмүн жариядә бу ноксанатны күреп: «Юк, кирәк түгел, бар, алып кит», — диде. Жария, бу сүзләрне ишеткәч: «Йә әмирел-мөэминин, миндә булган гаеп вә ноксан хаҗәтеңез вакытында сезгә күренмәс ул», — диде. Аннан соң Маэмүн бу жариянең билә дәрхаль җавап бирүенә хуш вакыт булып әмер кыйлды, бу жарияне әмир өчен сатып алдылар.

---

Тый кабиләсе гарәпнең башка кабиләсеннән бер сабый баланы әсир итеп киткәннәр иде. Ул баланың атасы барып углын хәляс кыйлмак[1] өчен бер микъдар мал бирмәкче булып, мәзкүр кабилә әһеле күбрәк мал сораганлык сәбәпле, бу кешенең ул кадәргә хәле житмәслек булгач, Фәрактан дигән ике кәүкәбне җәбел Тый үзәрендә иртә вә кич дахил кыйлгучы Бари Тәгалә белән касем итәмән ки, шул әйткәнемнән гайре бирергә кодрәтем юктыр дип, мәэюс булып, углыма хәляс тарикын белдердем. Шаять, фәһем итәр, дип тынычлап кайтып китте, ягъни гүяки углына мәзкүр сүз белән җәбел Тый тарафында булган Фәрактангә кич белән кач димәгә ишарәт кыйлды. Углы гаять фәһим вә зирәклеге сәбәпле шул кәйфиятчә качып нәҗат тапты[2].

---

Бер фәкыйрь бер бәкъкальнең дөкяненә[3] бер нәрсә сатып алмага барды, тиз-тиз дип ашыктырды. Бәкъкальнең дөкянендә башка кешеләр һәм нәрсә алырга килгәннәр иде. Житешә алмаганлыктан, фәкыйрь ашыктырган өчен фәкыйрьне сүкте. Бу фәкыйрь аягыннан башмагын салды да башмак белән дөкянченең башына сукты. Бәкъкаль, казыйга барып, шикаять кыйлды. Казый дәрхаль, фәкыйрьне чакыртып: «Әй фәкыйрь, ул бәкъкальнең башына ни өчен суктың? Олуг гаеп эшләдең, мин сине сәясәт кыйлыр идем, фәкыйрьлегең өчен гафу кыйламын. Бар ул бәкъкальгә ярты алтын бир, разый кыйл», — диде. Фәкыйрь дәрхаль кесәсеннән бер алтын чыгарды, казый кулына бирде вә башына башмак белән бер мәртәбә сукты, әйтте: «Әгәр казыйның хөкеме шул булса, яртысын бәкъкальгә бир, яртысы үзенә булсын», — диде.

---

Бер шагыйрь бер бай адәмнең ханәсенә барды, байны мәдехләп, шигырь әйтте. Ул бай адәм монар бик хушнуд булды. Әйтте: «Хәзер дә минем кулымда акчам юк, ләкин ашлыгым бик күп, иртәгә кил, сиңа ашлыктан бернәрсә биреп җибәрермен», — диде. Шагыйрь иртәгесен янә байның ханәсенә килде. Бай әйтте: «Нихәл, ник килдең?» — диде. Шагыйрь әйтте: «Ки-

---

[1] Хәляс кыйлмак — азат итү.
[2] Нәҗат тапты — котылды.
[3] Бәкъкальнен дөкяненә — ашамлык кибете тотучының кибетенә.

чә ашлык бирермен дип вәгъдә кыйлган идең, аның өчен килдем», — диде. Бай әйтте: «Гаҗәп, син ахмак икәнсең, син мине сүзең белән хушнуд кыйлдың, мин һәм сине сүзем белән хушнуд кыйлдым», — диде.

---

Имам Әүзагый хәзрәтләре янында күп адәмнәр бар иде, һәр тугырыдан күп сүзләр сөйләштеләр. Араларында бер әгъраби[1] бар иде, һич тә сөйләшмичә тик утырды. Әйттеләр: «Ник син бер дә сөйләшмәйсең?» — диделәр. Әгъраби әйтте: «Ир кешенең өлеше колагындадыр, телендәге өлеш гайреләр өчендер», — диде. Әүзагый әйтте: «Сөйләштеме сезгә, әмма яхшы сүз әйтте», — диде.

---

Бер хәкимнән сөаль кыйлдылар: «Адәм угланнарында күп гаепләр бардырмы?» — диделәр. Хәким әйтте: «Адәмдә күренгән гаеп вә косурны санап бетерер хәл юк аны, ләкин адәмдә бер сыйфат бардыр ки, әгәр адәм аны истигъмаль кыйлса[2], җәмигъ гаепләрдән сәламәт булыр ки, ул сыйфат телен сакламактыр», — диде.

---

Мәлик Бәһрам бер кичәдә үзенең хәсы бакчасында утырганда, колагына бер кош тавышы килде. «Дәрхаль угын, җәясен алды да телен сакламак ни гүзәл эштер, әгәр телен сакласа иде, ягъни тавыш бирмәсә иде, һәлак булмас иде», — диде.

---

Хәсән Бәсри хәзрәтләренә әйттеләр: «Сине фәлән кеше гайбәт итте», — диделәр. Хәсән дәрхаль ул гайбәт кыйлган кешегә бер табак хөрмә җибәрде. Ул кеше, хөрмәне алган сәгать Хәсән Бәсрига килеп: «Мин сезне гайбәт кыйлмыш икән, миңа һәдия җибәрмәкеңездә ни сәбәп бардыр?» — диде. Хәсән әйтте: «Син миңа изгелегеңне җибәрдең, мин дәхи аның мөкяфәтенә хөрмә җибәрдем», — диде.

Мәгълүм булды ки: гайбәт кыйлган кешенең изгелеге гайбәт кыйлынмыш кешегә бирелер, вә аның гөнаһысы гайбәт кыйлгучыга йөкләтелер, имеш.

---

Мөгавия разыйаллаһу ганһу Әхнәфкә әйтте: «Мин ишеттем ки, син безнең хакымызда шулай-болай дип сөйләмешсең», — дип мөляхәзә кыйлмак булганда, Әхнәф инкяр итте, ягъни: «Сөйләгәнем юк», — диде. Мөгавия янә тәкрар: «Тәхкыйк мин ышанычлы кешедән ишеттем», — диде. Әхнәф әйтте: «Ышанычлы кеше гамазлык кыйлмас», — дип, мәгъкуль җавап белән котылды.

---

[1] Әгъраби — далада яшәүче гарәп.
[2] Истигъмаль кыйлса — кулланса.

Мөхәммәд бин Васигъның уч табанына сызлавык чыкты. Әйттеләр: «Бу зәхмәткә бер дәва итәек», — диделәр. Әйтте: «Тимәңез, тимә, Аллаһы Тәгаләгә шөкер итәмен ки, әле дә күземә чыкмады», — диде.

———

Бервакытны Һарун әр-Рәшит сырхау булып сихәтләнгәч, ибн Сәмәк килде, әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, Аллаһы Тәгалә сине зикер кыйлды, син һәм аңа шөкер кыйл, аны зикер кыйл», — диде.

———

Хикәят кыйлынмыштыр ки: Мәэмүн хәлифә бервакытны Мәрүдә хотбә[1] укыганда, халык бик йөткереште. Маэмүн хәлифә әйтте: «Әй җәмәгать, кемнең ютәле булса, хәмер серкәсе эчсен», — диде. Эчтеләр һәм шифа таптылар.

———

Гасан Рәкъкада вали булып торган заманында сырхау булды, һичбер ашны, хәтта һичбер дәваны кабул итмәде. Әбү Габбад дигән бер табиб бар иде, ул әйтте: «Бу авыруның сәбәбе һавадыр, табигатеңез һаваны үзгәләгәндер», — диде. Әмер кыйлды, Бәгъдадтан ничә җәраб тутыртып һава китертте, көн саен җәрабтан Гасанның йөзенә һава җибәрер иде, ахыр Гасан сәламәтләнде.

———

Бервакытны Маэмүн хәлифә Тарсуста баш авыруы пәйда булып сырхау булды. Кайсар аңа язды: «Мин ишеттем ки, баш авыруы белән мөбтәля икәнсез, ошбу бүрекне башыңызга киеңез, баш авыруыңыз, шаять, тәскин булыр[2]», — дип, бер бүрек җибәрде. Маэмүн бүрекне алды, ләкин мәсмүм[3] булмагай иде, дип кияргә курыкты. Бүрекне китергән кешегә кидерде — һичнәрсә юк, башы авырта торган кешегә кидерде — авыруы туктады, үзенең башына киде — баш авыруы басылды.

———

Бер гарәпкә әйттеләр: «Йә гарәп, ни-нәрсәдән шикаять кыйласың, ягъни сырхавың ни-нәрсәдер?» — диделәр. Гарәп әйтте: «Гөнаһымдыр». Әйттеләр: «Ни-нәрсә иштиһа кыйласың», — диделәр. Гарәп әйтте: «Җәннәтне иштиһа кыйламын». «Табибны чакыраекмы?» — диделәр. Гарәп әйтте: «Табибым мине авыру кыйлды, теләсә, үзе янә дәвасын бирер», — диде.

———

Бервакыт пәйгамбәр галәйһиссәлам бер сырхау егет янына керде, әйтте: «Әй егет, хәлең ни кәйфияттә?» — диде. Егет әйтте: «Аллаһы Тәгаләдән сихәтне өмид итәмен, гөнаһымнан куркамын», — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Алай булса

---

[1] Хотбә — нотык.
[2] Тәскин булыр — тынычланыр.
[3] Мәсмүм — агулы.

бәндәнең калебендә ул икесе дә җыелмас, мәгәр Аллаһы Тәгалә өмид иткәнен бирер, курыкканнан хәлас кыйлыр», — диде.

---

Бер мәдәни Шам шәһәрендә сырхау булды. Күршеләре хәлен сорый килделәр: «Ни хәлең бар, ни иштиһа кыйласың?» — диделәр. Ул мәдәни әйтте: «Иштиһам шулдыр ки: адәмне күрмәсәм икән», — диде.

---

Берничә кеше бер авыруның хәлен сорый бардылар, авыру янында бик озак утырдылар. Ул сырхау кеше әйтте: «Авыру кеше гыядәт кыйлына, сау кеше зыярәт кыйлынадыр», — диде. Ягъни китегез инде дигәнгә ишарәттер.

---

Сәр Сактый хәзрәтләре әйтте: «Бервакытны Тарсус шәһәрендә идем, сырхау булдым, хәлемне сорый килделәр, бик озак утырдылар, үземә мәләләт[1] хасыйл булды, әйттем: «Илаһи, йа Рабби, авыру хәлен ни кәйфияттә сорарга кирәк, гыядәтнең[2] кәйфияте ничектер, безгә үгрәт», — дидем. Ягъни морадым авыру хәлен сорарга барсаң, авыру янында озак торма, димәк иде», — диде.

---

Бер кеше бер табибка шикаять кыйлды: «Эчем авырта», — диде. Табиб әйтте: «Ни-нәрсә ашаган идең?» Ул кеше әйтте: «Балык, сыер ите, йомырка ашаган идем», — диде. Табиб әйтте: «Бак, кара, үләрсең, әгәр моннан үлмәсәң, үзеңне Каф тавыннан ыргыт», — диде. Моннан үлмәй калсаң, Каф тавы башыннан егылсаң, бәтарикъ әүлә булмассың, димәктер.

---

Берәү бер табибка әйтте: «Эчем авырта», — диде. Табиб әйтте: «Ни ашадың?» — диде. Ул кеше әйтте: «Арпа икмәге белән көрпә чылатып ашаган идем», — диде. Табиб әйтте: «Син байтарга[3] бар, мин ишәккә дару итә белмәймен», — диде.

---

Бер кеше бер табибка килде: «Дәва кыйлсана, корсагым авырта», — диде. Табиб әйтте: «Ни-нәрсә ашаган идең?» Ул кеше әйтте: «Күгәргән икмәк ашаган идем». Табиб килде дә күзенә дару бирә башлады. Бу кеше әйтте: «Минем күзем авыртмай», — диде. Табиб әйтте: «Күзең сәламәт булса, көйгән икмәк ашамас идең», — диде.

---

Беркөн Маэмүн хәлифә бер табибка: «Табигатем бозык», — дип шикаять кыйлды. Табиб әйтте: «Салкын су эчмә, юеш нәрсә

[1] Мәләләт — күңелсезлек.
[2] Гыядәтнең — авыру янына хәлен белергә килүнең.
[3] Байтарга — ветеринарга.

ашама», — диде. Маэмүн әйтте: «Алар булмаса, сиңа да хаҗәт төшмәс иде», — диде.

---

Бер гарәп бер кол сатып алды. Бу гарәпкә әйттеләр: «Бу колның авыруы бардыр, түшәккә сиядер», — диделәр. Гарәп әйтте: «Әгәр түшәк тапса, кирәк бер чиләк сисен», — диде.

---

Бер табиб, бер зыярәт тугырысыннан узып барганда, бөркәнеп качып барыр. «Ник алай итәсең?» — диделәр. Әйтте: «Бу мәетләрдән ояламын», — диде. «Ник?» — диделәр. Әйтте: «Бу мәетләрнең күбесе минем даруым белән үлгәннәрдер», — диде.

---

Һишам бин Габделмәликне бер кемсәнә муаҗәһәтән, ягъни үзе алдында мәдех итте. Һишам әйтте: «Әй кемсәнә, бер кешенең йөзенә каршы мәдех итмәк, ягъни үзенең алдында мактамак мәнһи түгелме?» — дип тәгъръйз кыйлды. Ул кеше әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, мин сине мәдех итмәдем, ләкин Аллаһы Тәгаләнең синең үзәреңдә булган нигъмәтен зикер кыйлдым, таки Хак Тәгаләгә шөкерне тәҗдид вә тәкрар иткәйсең», — дип, хакиманә җавап бирде. Һишам әйтте: «Ошбу җавабың әүвәлге мәдехеңнән гүзәлдер», — дип, күп гатыя ихсан кыйлды.

---

Вә дәхи бер балигъ адәм көрамадан бер кешене билә мәдех кыйлды ки: «Ул фәлән кемсәнә шундаен кешедер ки, сөйләшкәндә замана халкының фәсихракыдыр вә, үзенә дәхи берәү сүз сөйләсә, икътизаи дираять үзә аның сүзен тыңламакта заманасының әхсәнедер[1]. Ягъни берәү сүз сөйләгәндә, ул сөйләгүче кеше сүзен бетермәй торып, аннан колагын алмас, әтрафка нәзар салмас[2], ошбу рәвеш сүз тыңламак кәмаль гакылдан килер, вә берәү икенче кеше аңа сүз сөйләшкәндә, әтрафка карар. Ул кеше сүзен бетермәс борын сүз башлар, бу аның хиффәт гакылына[3] вә мөрәвәтенең юклыгына дәляләт кыйлыр», — димәктер.

---

Әбү әл-Гатаһия дигән мәшһүр шагыйрь Гомәр бин әл-Галәне бер касыйдә белән мәдех кыйлгач, Гомәр аңа җитмеш мең дирһәм ихсан кыйлып, өстенә җитмеш кат хилгать кидерде, шөйлә ки, ул хилгатьләрнең авырлыгыннан кыймылдарга кодрәте калмады. Бу ихсанга башка шагыйрьләр хәсед кыйлып, тагнә кыйла башладылар. Гомәр аларның тагнәсен ишеткәннән соң, аларны илзам кыйлмак өчен, һәммә шагыйрьләрне хо-

---

[1] Әхсәнедер — иң яхшысыдыр.
[2] Әтрафка нәзар салмас — тирә-юненә күз салмас.
[3] Хиффәт гакылана — акылының җиңеллелегенә.

зурына чакыртып: «Әй бәлигъләр вә шагыйрьләр гөруһы, бер-береңезгә кыйлган хөседеңезгә тәгажҗеб итәмен ки, араңыздан бәгъзеләреңез безне мәдех өчен касыйдә нәзым итмеш идеңез[1] ки, илле биткә кадәр исемем зикер кыйлынмай бары тәшбиһат булып, илле биттән ары һәм мәдех мәзмуны чыкмас иде». Әмма Әбү әл-Гатаһия, аз гына бәет белән мине мәдехтә билә нәзым итәр дип, мәзкүр Гатаһия шагыйрьчең кыйтгасын укып, шагыйрьләрне мөлзәм кыйлды. Кыйтгаи Гатаһия: тәхкыйк мән әмир Гомәрнең дәргяһенә интисаб риштәсен баглаган вакытымда замананың михнәтләреннән имин вә сәламәт булдым. Әгәр адәмнәр кадир булсалар иде, әмиргә тәгъзыйм вә ижлал[2] өчен йөзләренең тиресеннән башмак тегеп, әмирнең аягына кидерерләр иде. Әй әмир, атланачак атлар сиңа хәлләреннән шикаять итәрләр, зирә синең өчен чүлләрне, вә озак җирләрне, вә комнарны катыгъ итмешләрдер, ягъни кәрәмеңнең шөһрәте галәмгә җәелмәк белән озак җирләрдән халык, синең ихсаныңны тапмак өчен, атларга менеп килерләр вә халык сиңа килгән вакытларында җиңел килерләр, ягъни буш капчык алып килерләр, киткән вакытларында агыр китәрләр, ягъни ихсаның белән капчыкларын тутырып китәрләр, димәктер.

---

Беркөн пәйгамбәр галәйһиссәламнең хозурына Хәбәш мәлик тарафыннан илчеләр килеп, хаке паенә[3] йөз сөргәннәреннән соң хәзрәти Рәсүл үзе ул илче мөсафирларга хезмәткә торды. Әсхаб кирам разыйаллаһу ганһуга әйттеләр: «Йә Рәсүлуллаһ, сезгә зәхмәт булмасын, без хезмәт итәек», — диделәр. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Алар үзләре дә минем сәхабәләремә хезмәт иттеләр иде», — диде.

---

Сәгыйд бин әби Вәкъкас Күфәдә вали иде. Бер кеше килеп: «Әй әмир, синең үзеңдә изгелегем бардыр», — диде. Сәгыйд әйтте: «Ул ни изгелектер?» Ул кеше әйтте: «Бер заманда җәнабыңыз бер тарафка барганда, атланган атыңыз сөртенеп, сезне өстеннән төшергәч, хезмәтчеләреңез яныңызда юк иде, мин барып кулыңыздан тотып, сезне атыңызга атландырдым вә атыңызга су эчергән идем», — диде. Сәгыйд әйтте: «Моңарчы син кайда идең, ягъни ник килмәдең?» — диде. Ул кеше әйтте: «Килгән идем, хадимнәреңез хозурыңызга юл бирмәделәр», — диде. Сәгыйд әйтте: «Әй кеше, ул хадимнең сине мәныг иткәненә мөҗазат[4], сиңа ике йөз мең дирһәм әмер иттек, бирелсен, бу мәкяфәтемез безгә якынлыгыгызга сәбәп булсын», — диде.

---

[1] Касыйдә нәзым итмеш идеңез — шигырь язар идегез.
[2] Тәгъзыйм вә ижлал — бөек итеп күрсәтү.
[3] Хаке паенә — аягына.
[4] Мөҗазат — җәза.

Имам Шәфыйг хәзрәтләре беркөн Мисырда тимерчеләр урамыннан барганда, камчысы кулыннан төшеп китте. Моны күргәч тә дөкяненнән бер кеше чыгып, камчыны алды, туфрагын сөртеп, имамның кулына бирде. Имам Шәфыйг хәзрәтләре янында булган хезмәтчеләреннән берсенә: «Әй фәлән, янында никадәр нәкыд бар?» — диде. Ул хадим әйтте: «Ун алтын бардыр», — диде. Имам әйтте: «Ул алтыннарны камчыны алып биргән адәмгә бир, бу аз булды, гаеп итмәсәнә дип гозер теләә», — диде.

---

Бер рави хикәят кыйлмыштыр ки: «Бер кешенең Сафа белән Мәрвә арасында катырга менеп таваф кыйлганын күрмеш идем. Бер заманнардан соң ул кешене юлда күрдем, җәяүләп барыр. «Бу ни хәл, синең катырың бар иде ләбаса, хәзер дә җәяү барасың», — дидем. Ул кеше әйтте: «Халык Кәгъбәтулланы тәгъзыйм өчен җәяү йөргән вакытта, мин катырга менеп йөрдем. Гадел илаһи икътизасынча халык атланып барганда инде җәяүгә калдырды, вә фәкыйрьгә калдым», — диде».

---

Яхъя бин Әксәм хикәят итмештер ки: «Көннәрдә бер көн Һарун әр-Рәшитнең хозурына бардым. Һарун хәзрәтләре, башын иеп, фикер вә тәәммелдә[1] торыр, мине күргәч: фәлән бәетне әйткән кешене син беләмесең? диде. Мин әйттем: «Әй әмирелмөэминин, бу бәет Габид бин Әбраснындыр ки, ул Габиднең бу бәет белән гаҗәп вакыйгасы бар», — дигәнемнән соң, Габидне китерсеннәр, дип әмер кыйлды. Бәс, Габид килеп әмирнең хаке паенә йөзен сөргәннән соң, хәлифә әйтте: «Әй Габид, ошбу бәетнең кыйссасыннан хәбәр ит». Габид әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, еллардан бер ел хаҗ сәфәренә чыкмыш идем, бер каты эссе көндә чүлнең уртасында хаҗиләр кафиләсендә җәмигъ әтрафны ихата кыйлып, бер олуг сайхә[2] вә фөрьяд белән бер елан зоһур итте. Ни вакыйга бар, дип тәфтиш кыйлып карадым, сораштым. Кафиләнең алдына бар, күрерсең, диделәр. Барып күрдем. Бер кара шәҗаг, ягъни бер олуг кара елан, юлны кисеп юлда аркылы ятыр, үгез кебек фөрьяд кыйлып үкерер. Мин хәйрәт, ни эшләргә белмәдем, икенче тарафтан китәек, дип карадык. Янә кафиләнең алдына барып ятты. Белдем ки: моның сәбәбе бардыр, Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл вә игътимад[3] кыйлып, Аллаһының бәндәләрен бу һәлакәттән хәлас итеп булмас микән, дип, үземне фида кыйлып, бер турсык су алдым, кылычымны суырып аждаһаның янына бардым. Инде өстемә атылыр микән дип торган идем, һаман ятыр. Янә янынарак бардым,

---

[1] Тәәммелдә — тирән уйга чумып.
[2] Сайхә — кычкыру, акыру.
[3] Игътимад — ышану, инану.

мине күргәч, авызын ачты. Миндә су барын хис кыйлса кирәк, дип, суны турсыгымнан кисмәккә салган кебек аударып, авызына салдым. Бер турсык суны тәмамән эчеп бетергәч, комда бераз аунады да, сузылып, бер тарафка таба китте, безгә хәмлә кыйлмыш икән, зарар итмәенчә киткәненә тәгаҗҗеб иттем.

Аннан юлымызга сау-сәламәт киттек. Хаждан соң янә шул юлдан кайткан идек, мөкаддәмдә ул еланга очраган җирдә янә кич кунмак тугыры килде. Караңгы кичәдә юлның читенә чыгып, зикер вә тәсбих белән бераз ятып йокыга китмешмен. Бервакыт күземне ачып карасам, кафилә кузгалып китмеш, бары мин калдым. Хәйран булып ни итәчәгемне белмәенчә торганда, колагыма бер тавыш ишетелде, дикъкать кыйлып тыңладым, бер кеше ошбу бәетне укыды: «Әй атын җуйган кемсәнә ки, янында мәдәд вә ярдәм итүче кешесе юктыр, ошбу кәнеҗ[1] тәвә ки янындадыр. Атлан, үз тәвәңне дәхи алып, кичә караңгылыгын изалә кыйлгач[2], ягъни таң аткач, ул кәнеҗ тәвәдән төш, буш җибәр», — дип бу шигырьне укыгач, күрдем ки: янымда бер кәнеҗ тәвә вә бер тарафымда үз тәвәм торыр. Ул кәнеҗ тәвәгә мендем, үз тәвәмне җитәкләдем, үзем ун мил кадәр киткәч, кафилә күренде, вә атланган тәвәм туктады. Белдем ки: төшәргә вакыт җитте. Дәрхаль төштем, үз тәвәмә атландым, әйттем: «Әй кәнеҗ тәвә, кич караңгы вакытта син юл күрсәтеп, бәла вә михнәттән хәлас булдым, халикымыз булгучы Аллаһы Тәгаләгә касәм[3] итәрмән ки, чүлдә бу изгелекне иткән кем иде, миңа хәбәр бир», — дидем. Ул кәнеҗ тәвә дәхи миңа җавабән шигырь белән җавап бирә ки: «Мин ул еланмын ки, син миңа су эчереп, хәрарәтемне[4] дәфыг кыйлмага сәбәп булдың. Аллаһы Тәгалә сусамактан хәйрәттә калганнарның зарарын дәфыг итәр, су бирмәк белән миңа җумартлык кыйлдың вә туйганчы эчердең. Бу минем сиңа мәдәдкә килгәнем миңа иткән изгелегеңнең җәзасыдыр, ләкин моны мөкяфәт санамам, шөкер иткән хәлеңдә кит, Аллаһы Тәгалә сиңа ихсан кыйлсын» (Тәрҗемә. — *М.Г.*).

———

Берәү бер кешегә әйтте: «Мин сине яратамын», — диде. Ул кеше әйтте: «Бәли, раст әйтәсең». Бу кеше әйтте: «Аны кайдан беләсең?» Ул кеше әйтте: «Аның өчен минем синең белән уртаклыгым юк, алышым-бирешем юк, син минем карендәшем түгел», — диде.

———

Берәү бер кешедән сөаль кыйлды: «Фәлән кеше хакында ни әйтәсең?» — диде. Ул кеше әйтте: «Бик сыер сымак нәрсә

---

[1] Кәнеҗ — яшь.
[2] Изалә кыйлгач — бетергәч.
[3] Касәм — ант.
[4] Хәрарәтемне — эсселегемне.

ул», — диде. Анда икенче кешеләр бар иде, әйттеләр: «Әгәр ул кеше Бәни Исраил каveme эчендә булса, Бәкарә сүрәсе иңгәч, аннан гайрене зәбех кыйлмаслар иде», — диделәр.

———

Сократ хәкимгә әйттеләр: «Адәмиләрдән һичкем гаепсез кеше бармы?». Сократ әйтте: «Әгәр адәм дә булып, гаебе дә булмаса, ул кеше үлмәс иде», — диде.

———

Берәү бер кешене зәм кыйлды[1]: «Билә азгынлыкның гаясенә нәһигә[2] мөхаләфәттә ниһаясенә иреште», — диде.

———

Әбү Тыйб әт-Таһири һәрзаман Бәни Саманны яманлар иде вә гайбәт кыйлыр иде. Бервакытны Насыйр бин Әхмәд дигән кеше аңа әйтте: «Инде кай заманга чаклы адәм ите белән икмәкне бергә катыштырып ашыйсың?» — диде. Аннан соң Әбү Таһир гайбәттән тыелды.

———

Бер түбә өстендә кәҗә бәрәне тора, астыннан бер бүре үтеп бара, кәҗә бәрәне бүрене зәм кыйлды, сүкте. Бүре әйтте: «Юк, син мине сүкмәйсең сүгүен, ләкин син тора торган түбә мине сүгәдер», — диде.

———

Мөтәвәккил хәлифә Әбү әл-Гыйна дигән шагыйрьдән сорады: «Халыктан кемнәрне мәдех итәсең вә кемнәрне һөҗү кыйласың?»[3] — диде. Әбү әл-Гыйна әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, халыктан изгелек иткән гөруһны мәдех, вә сәна, вә явызлык иткән кешене зәм вә һөҗү итәмен», — диде.

———

Гарәп шагыйрьләреннән Хәтыйә дигән шагыйрь кешене яманларга вә һөҗү кыйлырга мөдавәмәт[4] кыйлыр иде. Беркөн һөҗүне касд итеп, ләкин һөҗү кыйлынмыш кемсәнә булмагач, бәет инша кыйлды, ягъни: «Мин бу көн яман сүздән гайре сүз әйтмәскә иреннәрем әба кыйлды[5], ләкин мин яман сүзне кем хакында сөйләгүче булмакымны белә алмадым», — димәктер. Бу бәетне инша иткәннән соң, бер күлгә карап, суда үзенең йөзен күргәч, дәхи инша кыйлды вә бу бәет белән үзен-үзе һөҗү кыйлды: үзем өчен бер йөзне күрәмен ки: Хак Тәгалә аны кабих[6] халык итмештер ки, ул йөзнең хамәиле булгучы мин үзем кабих булырмын, димәктер.

[1] Зәм кыйлды — кимчелекләрен әйтеп орышты.
[2] Нәһигә — тыелган нәрсәгә.
[3] Һөҗү кыйласың — көләсең.
[4] Мөдавәмәт — дәвам.
[5] Әба кыйлды — риза булмады.
[6] Кабих — алама.

———

Бер гакыйль кемсәнә әйтте: «Мине мәдех кыйлсалар да, зәм кыйлсалар да бәйләнмимен, мәдех, зәм миңа бәрабәрдер», — диде. Әхнәф ул кемсәнәгә әйтте: «Алайса халык мәшәкать чиккән җирдә син нәфесеңә рәхәт бирәсең, имеш», — диде.

———

Бәшар дигән шагыйрь һәм һөҗү кыйлучан иде: «Сине һөҗү кыйлырмын», — дисә кирәк. Аңа бер кеше әйтте: «Син мине һөҗү иткән заман кызыммы вафат булыр яки игенлегемме харап булыр», — диде. Бәшар әйтте: «Кызың да вафат булмас, игенлегең дә харап булмас», — диде. Аннан соң ул кеше әйтте: «Инде бу зарарлардан берсе дә булмаса, аягым бугазынача мадәреңнең яшерен әгъзасына булсын», — дип зәм кыйлынудан хәвефе юклыгын бәян кыйлды. Бәшар әйтте: «Ни өчен башыңызны калдырдыңыз[1]?» — диде. Ул кеше әйтте: «Аннан соң ни эшләрсең икән, аны күрмәк өчен калдырдым», — дип, бихәялыкны таэкид итмештер[2].

———

Мәзкүр Бәшар Мәһдине вә Ягъкуб бин Даудны һөҗү кыйлды. Бәс, Ягъкуб бин Дауд Мәһди хәлифәгә аның һөҗүен хәбәр биргәч, хәлифә, ачигъланып; «Бәшар Басрада иде, аның эшен бетермәк өчен Басрага тәвәҗҗеһ кыйлды. Басрага кергәндә зоха вакыты иде, бер азан ишетте: «Караңыз, бу азан әйткән кемдер?» — дип әмер итте. Күрделәр: Бәшар, имеш. Сәрхуш булган хәлдә тотып, хәлифәгә китерделәр. Хәлифә әйтте: «Әй зиндикъ, гаҗәп азан әйттең», — дип, алтмыш камчы сукмага әмер итте. Алтмыш камчы органның бәгъдендә һәлак дәрәҗәсенә җиткәч, бер сәфинәгә[3] куйдырды. Бу Бәшар сәфинәгә кергәндә: «Кяшки мине Әбү Шәмакмак күрсә иде», — дип, тәмәнни кыйлды. Чөнки Әбү Шәмакмак мөкаддәмдә Бәшарны һөҗү итмеш иде, гайне вакыйг булды, димәкне эстәде.

Берничә заманнан соң анда вафат булып, җөссәсен[4] диңгезгә ташладылар. Диңгездән читкә кагылып чыкты, әкърибасы[5] алып юып күмделәр. Һөҗүеннән рәнҗегәннәре өчен һичкем җеназасына бармады, һәлакенә мәсрүр булдылар.

———

Әбү Дәлламә дәхи латаиф белән мәшһүр иде. Бервакытны бер кеше белән дәгъвасы булды, ул вакыт Бәгъдадта Гафия исемле казый иде. Аңа мөрафәга[6] кыйлдылар. Әбү Дәлламә казыйны

---

[1] Калдырдыңыз — күтәрдегез.
[2] Бихәялыкны таэкид итмештер — оятсызлыгын раслады.
[3] Сәфинәгә — зур көймәгә, корабка.
[4] Җөссәсен — гәүдәсен.
[5] Әкърибасы — якыннары.
[6] Мөрафәга — суд эше.

күргәч, бәет нәзым кыйлды: халыкның зиядә гакыйль вә эш күргәннәре, җәдәлгә вә илзамга кадирлары[1] минем белән мөхасамә кыйлдылар. Мин дәхи, алар белән озак заманнар мөхасамә итеп, Хак Тәгалә хөҗҗәтемне вә сәнәдемне[2] батыйль кыйлмады вә мине җаваптан гаҗиз итмәде, аларга галиб[3] килдем, шул казыйлар кем казасында золым кыйлса, ул казыйлардан куркамын, ләкин, әй Гафия, синнән курыкмаймын ки, золым итмәссен, димәктер. Бәс, Гафия бу бәетне ишеткәннән соң: «Әй Әбү Дәлламә, әмирелмөэмининнгә синнән шикаять итәрмен ки, мине бу нәзым белән һөҗү кыйлдың», — диде. Әбү Дәлламә әйтте: «Әгәр шикаять итеп бәетемне дә зикер кыйлсаң, сине газел итәр»[4], — диде. Гафия әйтте: «Ни өчен?» Дәлламә әйтте: «Синең мәдех белән һөҗүне аерып белмәгәнең өчен», — диде. Бәс, Мансур хәлифә Әбү Дәлламәнең Гафиягә биргән ләтыйфә җавабын ишетеп, эче катканча көлде вә Әбү Дәлламәгә күп гатыяләр ихсан кыйлды.

———

Мәзкүр Әбү Дәлламәнең хикәяләреннәндер ки: беркөн Әбү Дәлламә Мәһди хәлифәнең хозурында иде, ул мәҗлестә хәлифәнең әкърибасыннан Исмәгыйль бин Гали, вә Гайса бин Муса, вә Габбас бин Мөхәммәд, вә Бәни Һашимнан дәхи бернichә адәм бар иде. Хәлифә әйтте: «Йә әби Дәлламә, әгәр бу мәҗлестә булганнардан берсене һөҗү итмәсәң, теленне кисәрмен», — дип ямин итте. Әбү Дәлламәгә хәйрәт[5] гарыз булып, мәҗлестәге кешеләрдән һәрберенең гүя ризалыкларын хасыйл итмәк өчен күз салды. Ләкин берәүдә дә ризалык галәмәте сизелмәгәч, чөнки үзе һәм шул мәҗлес әһеленнән булганга күрә үзен һөҗү кыйлды ки. Әбү Дәлламә ошбу һөҗүне тәмам кыйлганнан соң, теле киселүдән үзе котылып, дәхи яминнән хәлифәне коткарган өчен мәҗлес халкы һәммәсе гаять мәсрүрән көлешеп, Әбү Дәлламәгә күп бәхшишләр кыйлдылар.

———

Зорафаның бәгъзеләреннән, фәлән-фәлән кешеләр хакында ни әйтәсең, дип сорадылар. Әйтте: «*һума әл-хәмрү вәл-мәйсир вә исмуһума әкбәру мин нәфгуһума*», — дип битарыйкыл-икътибас һөҗү кыйлды, ягъни алар хәмер белән комар кебектер, ягъни зарарлары файдаларыннан күбрәктер, димәктер.

———

Бәгъзе зөрафага: «Фәлән ниндәен кешедер?» — диделәр. Әйтте: «Бозыклыкта тезгене озын, төзеклектә аршыны кыска, явызлыкта сикерер вә изгелектә утырыр», — диде.

---

[1] Җәдәлгә вә илзамга кадирлары — бәхәстә җиңеп чыгуга көчлеләре.

[2] Хөҗҗәтемне вә сәнәдемне — дәлилләремне

[3] Галиб — өстен чыгучы.

[4] Газел итәр — хезмәтеннән азат итәр.

[5] Хәйрәт — гаҗәпләнү.

———

Берәүгә әйттеләр: «Син фәлән кешене гяһан мактыйсың, гяһан һөҗү кыйласың», — диделәр. Ул әйтте: «Мин аны һөҗү кыйлып, соңыннан мәдех иттем, әшраф һөҗү вә мәдех кыйлынудан хали булмаслар», — диде. Ягъни һөҗү кыйлынмыш булмак, вә мәдехләнмеш булмак әшраф вә яхшы кешеләр шаэнидыр[1], филхәкыйкать, халык мактаса да, яхшы кешене мактай, яманласа — яхшы кешене яманлай, яманны яманламакта ни мәгънә?

———

Бер кемсәнә бар иде, җәмәгате ни-нәрсә хаҗәт сораса, һаман, юк, ди иде. Аңа бер кеше әйтте: «Әй фәлән, син юк дигән сүзеңне бик күп әйтмә, оҗмахта «юк» дигән нәрсә юктыр», — диде.

———

Бер хәсис саран кемсәнә хакында бер кешегә әйттеләр: «Әй фәлән, син фәлән кешенең тәгамын бер-бер ашаганың бармы?» — диделәр. Әйтте: «Юк, ләкин ул ашаганда, аның ишек төбеннән узганым бар», — диде. Әйттеләр: «Аның ашаганын кайдан белдең?» — диделәр. Ул әйтте: «Хезмәтчеләре өе тирәсендәге чебеннәрне куалар иде», — диде.

———

Бер кемсәнәгә әйттеләр: «Мөхәммәд бин Яхъя сиңа берберкием кидергәне бармы?» — диделәр. Ул кеше әйтте: «Әгәр аның бер амбар тулы инәсе булса, Ягъкуб галәйһиссәлам җәмигъ пәйгамбәрләрне үзенә шәфагатьче итеп, фәрештәләрне замин[2] итеп, әүлияларны гуаһ итеп, Йосыф галәйһиссәламнең арттан ертылган күлмәген тегәр өчен гарияткә[3] бер инә сорарга килсә дә, гарияткә бер инә биреп тормас», — диде.

———

Ибн Әхмәд дигән бер шагыйрь бер шәһәрдә Гоммар бин Мәсрук дигән кешенең ханәсенә төште. Аңа әйттеләр: «Кемгә төштең?» — диделәр. Ул шагыйрь әйтте: «Ибн Хәсыйбкә төштем, әмма икмәк үземнән», — диде. «Ник алай», — диделәр. Ул әйтте: «Аның икмәгенә язылган «ля хафиза иллаллаһ[4]» дип түшәк арасына кыстырган, үзе таянып яткан», — диде. Ягъни кунак булып килгәнемдә ханә иясе икмәген сандыкка салып йозак белән бикләмеш, капучыларын вә каравылчыларын, капка төбенә килгән кешене кертмә дип, каравылга куймыш. Аның ханәсендә кунак бер икмәкне күрсә дә: «Бу минем икмәгем түгелдер, берәүнең әманәт куйган икмәгедер», — дип, кунагына ашатмамыштыр, димәктер.

---

[1] Шаэныдыр — үзенчәлегедер.
[2] Замин — кәфил, үз өстенә алучы.
[3] Гарияткә — бурычка, әҗәткә.
[4] Ля хафиза иллаллаһ — Аллаһыдан башка моның сакчысы юк.

Әбү Хәфәсаның ханәсенә әһле Ямамәдән бер кунак килде. Әбү Хәфәса кунакны «мәрхаба» дип утыртты, гаять саранлыгыннан кунакны зыяфәт кыйлмага куркып качты. Кунагы Әбү Хәфәсаның артыннан хат язды: «Әй йортыннан кунакка зыяфәт кыйлмага куркып качкан кеше, кайт, кунагың азык алып килде, бу сурәттә курыкма, кунагыңа кунак бул», — диде.

---

Бер саран кешегә әйттеләр: «Ник син болай ялгыз ашыйсың?» — диделәр. Ул кеше әйтте: «Кеше белән ашаган кешедән ник кеше белән ашыйсың дип сорарга кирәк иде, гаҗәб сөаль кыйлдыңыз», — диде.

---

Һишам бин Габделмәликнең бакчасы бар иде. Беркөн тәвабигъләры[1] белән бакчага керделәр, җимешләрдән ашадылар. Әйттеләр: «Аллаһы Тәгалә бу бакчаның бәрәкәтен арттырсын», — диделәр. Һишам әйтте: «Ни бәрәкәтен арттыру, ашап бетерәсез инде», — диде.

---

Бер бик саран диһкан бар иде, яхшы әүкатлы кеше иде. Көннәрдә бер көн анасы карчык белән борчак җиренә бардылар. Анасының тешләре юк иде, җир өстенә баргач та, бер данә борчак алып капты. Теше юкка күрә һаман шул бер данә борчакны авызында кыймылдатып торды. Углы ничә караса, анасы авызын кыймылдатып ашар күрде. Бу әни җирдәге борчакны ашап бетерә бугай, дип куркып: «Әйдә, әни, инде кайтаек», — диде. Анасы белән кайтырга чыктылар, авылларына килеп җиттеләр. Бер киртә аркылы кичәсе булды, анасы киртә аркылы кичкәндә, авызыннан баягы бер данә борчагы чыгып төште. Анасы, киртә төбендә кармаланып, бернәрсә эзли башлады. Углы әйтте: «Әни, ни эзлисең?» — диде. Анасы әйтте: «Һай углым, җир өстенә баргач та бер борчак капкан идем, авызымнан шул борчак чыгып төште, аны эзлимен», — диде. Углы әйтте: «Әй әни, мин, әни борчакны ашап бетерә, дип, сине алып кайттым, әйдә, алайса яңадан бараек», — диде.

---

Гарәпләрнең сәеде[2] булгучы Кайстан сөаль кыйлдылар: «Син бу олуглыкны вә сәедлекне ни белән таптың?» — диделәр. Кайс әйтте: «Кавемемә күп тәгам бирмәкем вә зыяфәт кыйлмакым белән олуг булдым вә бәхәсләшмәдем, олуг булдым, Аллаһы Тәгалә носрәт[3] бирде, олуг булдым», — диде.

---

[1] Тәвабигъләры — иярүчеләре.
[2] Сәеде — аксөяге.
[3] Носрәт — ярдәм.

———

Хәсрәти Мөгавия заманында Әхнәф белән гарәптән бер таифә бер хаҗәт өчен Шамга килеп, хәлифәнең капусына барган вакытларында, хәлифәнең капучысы боларга әйтте: «Хәлифәгә һәркем үз хаҗәтен үзе ифадә кыйлып, гайре кеше васитасы[1] белән хаҗәт сорамамак хәлифәнең әмере», — дип ихтар кыйлды. Бәс, болар хәлифә хозурына кергәннән соң, хаҗәтләрен хәлифәгә гарыз кыйлдылар. Ләкин Әхнәф әйтте: «Әгәр хәлифәнең әмере билә булмаса иде, бөтен мәмләкәтемездә вакыйг булган бәла вә хәвадисне бәян кыйлып, барча халык хосусында хәлифәдән ихсан эстәр идем», — диде. Мөгавия Әхнәфнең ошбу балиганә ифадәсеннән мәхзуз булып: «Әй Әбү Бәхер, ошбу игъхтизарың хәзерләргә кифая иткәннән соң, гаибләреңезгә дә сираять кыйлды», — дип, шәфагатен кабул кыйлып, барчасына ихсан кыйлды.

———

Бер хикмәтсез кемсәнә Әхнәфкә әйтте: «Йә Әхнәф, нәсәбендә шәрафәт[2] юк, йөзеңдә күркәмлек юк, кыяфәтеңдә хөснең юк икән, сиядәт вә олуглыкны ни белән таптың син?» — диде. Әхнәф әйтте: «Минем олуглыгыма сәбәп синдә булган сыйфатның хилафы белән мөттәссыйф булдым да олуг булдым», — диде. Мәгълүм була ки, бәләнд[3] һиммәтле булмак — олуглыкның вә хөрмәтлелекнең асылыдыр.

Хикәят кыйлынмыштыр ки: бәләнд һиммәтлеләрдән Гаммарә бин Хәмзә дигән кемсәнә беркөн Мансур хәлифәнең мәҗлесенә барып, хәлифә хозурында утырганда, бер кеше килеп: «Әй әмирел-мөэминин, мин бер мәзлуммен[4] ки, хакымны залимнан алып бир», — дип, мәрхәмәт эстәде. Хәлифә әйтте: «Сиңа кем золым кыйлды?» — диде. Ул кеше әйтте: «Хозурыңызда утырган Гаммәрә минем мәдар мәгыйшәтем булган бер кисәк иген җиремне гасыйб кыйлды[5]», — дигәннән соң, хәлифә Гаммарәгә, хитаб кыйлып: «Тор, хәсымың[6] белән бәрабәр тор», — диде. Гаммарә әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, бу кеше миңа хәсым түгелдер, моның белән минем дәгъвам юктыр. Әгәр ул җир аның милке булса, мин низаг итмәймен, китсен, алсын. Хәтта минем милкем булса да, җәнабыңыз хозурында бу кешегә бәхеш кыйлдым, миңа әмирел-мөэминин ихсан кыйлган кадәр хөрмәтне бер кисәк иген җиренә фида кыйлып, әдна вә пәс[7] адәмнәрдән бер

---

[1] Васитасы — арадашчысы.
[2] Шәрафәт — дәрәҗәлелек, затлылык.
[3] Бәләнд — бөек, зур.
[4] Мәзлуммен — җәберсетелгән кешемен.
[5] Гасыйб кыйлды — талап алды.
[6] Хәсымың — каршылык күрсәтүең.
[7] Әдна вә пәс — түбән һәм хурлыклы.

адәм белән хөкемгә торышып, якынлык гыйззәтен ераклык мәзәләтенә алыштыра алмамын», — диде.

Аннан соң Мансур хәлифә Гаммарәнең бәләнд һимматеннән вә егетлегеннән тәгъзыйм вә ригаясеннән мәхзуз[1] булып, Гаммарәнең һимматенә тәхсин кыйлды.

---

Беркөн Мансур хәлифә үзенең хәрәмендәге Өмме Сәлимә белән Гаммарәнең бәләнд һиммәте вә күңеленең пакьлеге хакында мөкяләмә кыйлырлар иде. Өмме Сәлимә Гаммарәне тәҗрибә итмәк өчен, үзенең илле меңгә төшкән энҗе тәсбихын биреп, Гаммарәне чакырып: «Бу тәсбихны аңа һибә кыйл, күрәем, ни мөгамәлә итәр икән, әгәр кабул итсә, зәбун[2] табигать икәнен белермез», — диде. Бәс, хәлифә, Гаммарәне чакырып, сохбәт кыйлып утырганда: «Бу сиңа һәдиядер, ал, сиңа һибә кыйлдым», — дип, тәсбихны алдына салды. Гаммарә дәхи ул тәсбихны кулына тотып, янә алдына куйды, бераз сохбәт кыйлганнан соң, тәсбихны урынында калдырып, рөхсәт сорап чыгып китте. Хәлифә дәхи, Гаммарә бу тәсбихны онытып калдырмыш дип, бер хадим кулына биреп, Гаммарә артыннан җибәрде. Аннан соң Гаммарә, тәсбихны кулына алып: «Инде бу тәсбихны мин һәм сиңа һибә кыйлдым», — дип, хадим кулына бирде. Хадим аннан, Мансур хәлифәгә килеп: «Ул кеше тәсбихны алмады, миңа һибә кыйлды», — дип, кыйссаны бәян кыйлганнан соң, Өмме Сәлимә дәхи ул тәсбихны хадименнән мең алтын биреп кайтарып алды.

---

Хикәят кыйлынмыштыр ки. Һиммәт вә гыйффәт иясеннән дәхи бере Сәгыйд бин Гомру иде ки. Мәрзы мәветендә[3] аңа әйттеләр: «Аһ, вә әнин һәм әйтмәйсез, бу каты сырхавыңызга сабыр итәсез, табибка сырхавыңызны әйтеп дәва эстәмәйсезме?» — диделәр. Сәгыйд әйтте: «Җәзәгъ вә әнин[4] итмәк миңа нәкыстыр, Хак Тәгаләнең миннән җәзәгъ вә әнин тавышымны ишетмәкен эстәмәймен, хәя вә әдәп итәмен, әмма сырхавымны табибка әйтмәк дәхи файдасыздыр. Аллаһы Тәгалә гайреләрнең хөкеме белән хөкем итмәс, теләсә, сәламәтләндерер, теләсә, үтерер», — диде.

---

Хәҗҗаҗ хәлифә беркөн хотбәдә бик озак торды. Җәмәгатьтән бер кеше аяк үзрә торып: «Инде җитәр, намаз укыек, вакыт булды, вакыт сиңа көтмәс, вә Аллаһы Тәгалә сине мәгъзур тотмас», — дип, хитаб кыйлып, күп сүзләр әйткәннән соң,

---

[1] Мәхзуз — шат.
[2] Зәбун — начар, әһәмиятсез.
[3] Мәрзы мәветендә — үлем сырхавында.
[4] Җәзәгъ вә әнин — ыңгырашу, сызлану.

Хәҗҗаж, ачигъланып, ул кешене хәбес кыйлмага әмер итте. Ул кешенең әкърибасы аны хәбестән хәлас кыйлмак хосусында Хәҗҗажга килеп әйттеләр: «Әй әмир, Хода өчен аны гафу итеңез, ул мәҗнүндер», — дип гозер иттеләр. Хәҗҗаж әйтте: «Шулаймы, хозурыма килеп диваналыгын икърар кыйлсын, хәлас кыйлырмын», — диде. Ул кешенең әкърибасы тиз үк барып, хәлифәнең шартын хәбәр бирделәр. «Мин мәҗнүн дип икърар кыйл», — диделәр. Ул кеше әйтте: «Хак Тәгалә мине сыйхәт вә гафияттә кыйлып, мәҗнүнлек белән мөбтәля кыйлмады, ялганны ничек икърар кыйлаем?» — дип, әкърибасын рәд кыйлды. Бу кыйсса Хәҗҗажга ишетелеп, ул кешенең тугрылыкта истикамәте вә сөбаты[1] өчен хәбестән хәлас кыйлды.

———

Ялганчылык белән мәшһүр булган адәмнәрдән берәүгә Әсмәгый әйтте: «Син гомереңдә бер-бер тугыры сөйләшкәнең бармы?» — диде. Ул ялганчы әйтте: «Тугыры сөйләшкәнем юк дип әйтер идем, әгәр бу сүземә ышанмасалар», — диде.

———

Мәшһүрдер ки, Гарәбстанда бер хатынның шикәр камышы бакчасы бар иде. Һәрбер данә камыштан сыгылган шикәр бер олуг савыт тутырыр иде. Шәһәрнең валисе моны белеп, бу хатыннан шикәр бакчасыны җәбран каһран[2] алмага ният итте. Кием алыштырып, танытмастан ул хатынның бакчасына килде, хатынга әйтте: «Мин ишеткән идем, бу бакчаның бер камышыннан бер олуг савыт шикәр чыга, имеш, дип, бу сүз растмы?» — диде. Хатын әйтте: «Бәли, расттыр», — дип, бер камышны алып сыгып күрсәтте, ярты савыт шикәр чыкты. Вали әйтте: «Бер савыт чыкмады ла», — диде. Хатын әйтте: «Бер савыт була торган иде, ләкин валиемез бакчамны гасбан алмага ният итмеш, имеш, бакчамнан бәрәкәт күтәрелде», — диде.

Бәс, ул вали дәрхаль ул бозык ниятеннән кайтып тәүбә итте. Вали әйтте: «Янә берне сыгып кара», — диде. Хатын янә бер камышны сыкты, әүвәлгечә бер савыт чыкты.

———

Мисырда бер бәхетле кешенең ун әрдәб хөрмә бирә торган бер хөрмә агачы бар иде (әрдәб 24 саг керә торган бер савыттыр). Ул мәмләкәттә шулкадәр хөрмә бирә торган агач юклыгыннан, шәһәрнең валисе бакчаны ул кешедән тартып алды. Хикмәте Хода, ул алган елда ул агачның бер данә хөрмәсе булмамыштыр.

———

Әбү Бәкердән риваятьтер ки: бер заманнарда Искәндәриядә балык тотмага вали тарафыннан каршылык тыю булынма-

---

[1] Истикамәте вә сөбаты — намуслылыгы һәм чыдамлылыгы.
[2] Җәбран каһран — рәнҗетеп һәм ачуланып.

енча, халыкка рөхсәт бирелеп, бар халык тотар булды. Бер заман диңгездә балык шулкадәр күбәйде ки, хәтта балалар кул белән тотарлар иде. Аннан соң бу иркенлек вали тарафыннан тартып алынды. Дәүләт кешеләренә генә тотмага әмер булгач, балык Искәндәрия ярлары тирәсендә азаймага башлап, хәтта бу көннәрдә балык үзе күренмәс булды, ягъни бетте. Күренә ки, валиләрнең күңелләрендә яшерен булган ният билә һәр кеше күңеленә кучеп, хисапсыз күбәя, хәер булса, шәр булса, дөньяга заһир булыр, диделәр.

---

Ибн әл-Хатыйб риваять кыйлмыштыр ки: Хәжҗаж хәлифә заманасында Хәжҗаҗның кан түгүче вә залим вә явыз булмаклыгыннан халык, иртә торып, бер-бере белән очрашканда: «Кичә кем үтерелде? Кемне астылар? Кемне суктырдылар?» — дип, моның кебек сүзләр сөйләшеп кенә яши башладылар.

---

Дәхи будыр ки, Гаҗәм падишаһларыннан Яздиҗәрд падишаһның туган бер баласы тормас иде. Бәһрам исемле углы, тугач, бер һавасы нәфис вә мөлаем җирне эзләделәр. Җәзирә Гарәб диңгезе тарафының һавасы бик нәфис дип хәбәр бирделәр. Гарәп падишаһы Ногман Яздиҗәрднең фәрманында иде. Яздежер үзенең углы Бәһрамны тәрбия өчен аңа җибәрде. Ногман дәхи Рум әһеленнән византияле Сөнмар исемле архитектордан хурнак дип мәшһүр булган сарайны Бәһрам өчен бина кыйлдырды. Мәзкүр касрны бина кыйлып тәмам булгач, бу касрның хөсне вә ләтафәтенә Ногман вә гайре халыклар барчасы хәйран калдылар. Сөнмар әйтте: «Әгәр масрәфенә сарыф итәргә хәраҗатенә акчаны артыграк бирерлегеңне белсәм иде, кояш белән бергә әйләнә торган каср бина кыйлган булыр идем», — диде. Ногман әйтте: «Андаен касрны ясарга кодрәтең бар икән, ни өчен эшләмәдең?» — дип, Сөнмарны касрның өстеннән аттырып һәлак итте.

---

Берничә адәм алга чыгып, һичнәрсә тотарга таба алмаенча озак йөргәннән соң, бер чәкалга[1] раст килделәр. Болар чәкалның артыннан куып килгәндә, чәкал, керер җир тапмагач, бер гарәпнең өенә керде. Гарәп бу үзе килеп кергән нәрсә дип, чәкалны тәрбия кыйлыр икән. Беркөн гарәп йоклаган вакытта, чәкал, гарәпнең өстенә килеп, карынын ярып качты. Ул арада гарәпнең карендәше, өйгә кереп, ул гарәпне мәет күргәч, бу чәкал эшедер дип белеп, артыннан барып чәкалны һәлак кыйлды. Аннан соң ошбу мәгънәдә бик хикмәтле кыйтганы нәзым итте.

Бер кемсәнә изгелекне бу изгелеккә лаякатьсез бер кеше-

[1] Чәкалга — шакалга.

гә эшләсә вә сарыф кыйлса, өмме Гамир белән көнияләнмеш өй хуҗасына үзе тәрбияләгән чәкал кыйлган бәлагә төшәр. Күр, ул хуҗа үзенең өенә качып кергән зарарлы хайванны тәрбия кыйлып, үзенең тәвәләреннән сауган сөтен эчертеп симертте. Ахыр симереп, кувәт хасыйл иткәч, тешләре вә тырнаклары белән туендыручысы-сыендыручысы булган хуҗасын ярды.

Әй гыйбрәтшенас, ошбу вакыйганы күрдең. Мөрәүвәт вә ихсан иясенә шөкер кыйла белмәгән кешегә ихсан кыйлып, җиванмәрдлек[1] иткәннең җәзасы ошбудыр моны һаман хәтергә төшер.

---

Әһле сәкаттан берәү нәкыль кыйлмыштыр ки: гарәп сахраларында йөргән вакытымда бер картка раст килдем, янында парәләнмеш бер куй белән бүре баласы торыр. «Әй шәех, моны белермесең?» — диде. Мин әйттем: «Белмәймен». Карт әйтте: «Бу бүре баласын кечкенә вакытта тотып өемә алып кайтып тәрбия кыйлдым, кайчан ки үсеп симерде, куема билә кыйлды ки, күрәсең», — диде. Ошбу нәзымны укыды ки, бик хикмәтле нәзымдыр (мәгънәсе): әй бүре, куемның корсагын тиштең, ягъни үтердең, бу өйдә булганнарны борчулы кыйлдың, хәлбуки син ул куйның үгәй углысың ки, аның сөте белән ризыкланып, безнең ханәмездә тәрбия таптың. Сиңа атаң бүре икәнен кем хәбәр бирде ки, бу ерткычлыкны иттең? Ләкин ни чара, кемнең табигате явыз булса, әдәп тә файда бирмәс, мөгаллим дә файда бирмәс, ягъни табигатьне алыштыра алмас.

---

Гомәр бин Дөвәйрәнен бер карендәше, бер кыз белән араларында гыйшыклык булып, бәгъзе вакытта килеп-китеп, яшеренчә мөсәхәбәт кыйлыр иде. Бер кичә мәзкүр кыз белән сохбәттә икән. Кызның карендәшләре, хәбәрдар булып, Гомәрнең карендәшене бастылар, вә шәһәрләренең валисе Халид бин Габдулла дигән кемсәнә иде, аның капусына барып, һәмширәләре (сеңелләре) мәфтәзәх (хур) булмамак өчен, угры тоттык, дип, вали хозурына китерделәр. Вали, ул егетне сөйләштереп: «Әй егет, син угрымысың?» — дигәч, егет дәхи: «Бәли, кыздан гыйшык угырладым», — дип, икърар кыйлып, дәгъвачыларны тәсдыйк кыйлды. Вали егетнең кулын кисмәгә әмер итте. Ул вакытта мәзкүр Гомәр нәзым әйтеп, Халидкә сонды[2]. Халит, кыйссага моталлига булып, егетне гафу кыйлды. Ул кызны бу егеткә гакыд кыйлып бирделәр. Бәетнең мәгънәсе: әй Халид, Аллаһы Тәгалә белер ки, тәхкыйк бәсыйрәтсезлек кыйлдың; арамызда булган гашыйк мәзлум[3] угры түгелдер. Ул гашыйк мәз-

---

[1] Җиванмәрдлек — юмартлык.
[2] Сонды — тәкъдим итте
[3] Мәзлум — җәберләнгән.

лум кыйлмаган, угрылыкын мәгъшукасының бәднам булмакыннан кулы киселмәкен хәерлерәк күреп икърар кыйлды, димәктер.

———

Бер кәсрага, ягъни фарсы кадим падишаһларыннан бер падишаһка әйттеләр: «Син адәмнең кайсын артыграк сәвәсең?» — диделәр. «Гакыллы дошманны артыграк сәвәмен», — диде. «Дошманны гакыллы булса сәүмәгә ярармыни?» — диделәр. Кәсра[1] әйтте: «Дошманым гакыллы булса, мин аннан имин буламын», — диде.

———

Хәҗҗаҗ бер хариҗига[2] әйтте: «Мин сезгә, ягъни хариҗиларга, бик ачуым килә вә ачу итәмен», — диде. Хариҗи әйтте: «Икемездән кайсымызның ачуы артыграк булса, Аллаһы Тәгалә аны җәннәткә кертсен», — диде.

———

Сүз остасы бер адәмгә әйттеләр: «Фәлән кешегә ни булган, сиңа көнчелек кыйладыр?» — диделәр. Ул кеше әйтте: «Кыйлса кыйлыр, ул кеше минем җан карендәшемдер, шәһәрдә күршемдер, сыйфатта шәригемдер», — дип, көнчесенең үзенә сылтаган гаепләренең һәммәсен аның үзенә сылады.

———

Гарәпнең фәсыйхләреннән бер кешене мөгътәсыйм хәлифә күреп вә бәлягатен тәхсин кыйлып, үзенә нәдим кыйлды. Хәлифә күреп, вә бәлягатен тәхсин кыйлып, үзенә нәдим кыйлды. Хәлифә аңа шулкадәр илтифат кыйлды ки, һичбер рөхсәтсез хәлифә янына кермәгә хокук алып, хәлифәгә гаять якынлык тапты. Хәлифәнең башка нәдимнәреннән бере бу гарәпнең хәлифәгә якынлыгына көнчелек кыйлып, бер мәкер белән ул гарәпкә һәдияләр күндереп, мәхәббәт вә дуслык изһар кыйлды. Ул гарәпне, беркөн үз ханәсенә дәгъвәт кыйлып, сарымсаклы тәгам ашатты. Гарәпне озаткан вакытта: «Әфәндем, син бу көн сарымсаклы тәгам ашадың, хәлифәгә барган вакытыңда хәлифә белән сөйләшкәндә авызыңны тотып сөйләш, таки авызыңнан хәлифәгә яман ис килеп нәфрәтләнмәсен, чөнки хәлифә авызы исле кешене сәүмәс», — дип, хәерхаһлык сурәтен күрсәтте.

Иртәгесен ул көнче нәдим гарәптән элек хәлифәгә барып, аулакта: «Әй әмирел-мөэминин, ул гарәпкә бик илтифат кыйлдыңыз, әмма ул гарәп җәнабеңез хакында, хәлифәнең авызы начар исле икән, дип, гайбәтеңезне сөйләмештер», — диде, хәлифәне ачигъландырып китте. Бервакытны бу гарәп, нәдим хәлифә янына килеп кергәч, авызын кулы белән тотып утырды. Хәлифә әйтте: «Миңа якын кил», — диде. Гарәп дәхи авызын

---

[1] Кәсра — цезарь, кайзер, кайсәр сүзенең фарсыча янгыраш формасы.
[2] Хариҗига — бу урында: сектантка.

яулык белән тотыбрак хәлифәгә якын баргач, хәлифәнең шөбһәсе калмаенча, бу эш раст икән, дип, каләм, кәгазь алып, бу хат һәмаюнымны илтеп биргән кешене дәрхаль кател итәсез, мәзмунында олуг вәзиргә хат язып, мөһерләп, гарәп кулына бирде. Әйтте: «Бар, моны фәлән олуг вәзиремә илтеп бир, бу — бүләк бирү турында язу, илтеп, аннан ихсаныңны ал», — диде.

Бу гарәп хатны алып чыкты. Ул көнче нәдим бу гарәпкә ни булыр икән, дип сагалап торган иде. Бу гарәпкә юлыкты. Гарәп хыянәтсез беркатлы кеше икән: «Әфәндем, сез әйткәнчә, хәлифәгә баргач, авызымны тоттым, исен чыгармадым. Менә хәлифә хәзрәтләре хәзинәдән бүләк алмага хат язды, бүләк аламын», — дип сөенеп хәбәр бирде. Бу хасид нәдимнең башыннан гакылы китә язып: «Сөбханаллаһ, әй борадәр, бу хатны миңа бир, чөнки бу көннәрдә ихтыяҗым бардыр, моннан соң бервакытны миңа да бүләк бирелгәндә, мин сиңа моны кайтарырмын», — диде. Гарәп әйтте: «Бу эш ярамас, моны хәлифә сизәр, ачигъланыр», — дип игътизар кыйлды. Ул хасид әйтте: «Хәлифә аны белмәс, син бер җирдә яшеренеп тор, мин барып киләем, никадәр алганымны әйтермен», — дип, комсызланып бик тә үтенеп хатны алды. Дәрхаль олуг вәзиргә барып хатны тапшырды, вәзир дәхи хатны ачып укыгач, хәлифәнең әмерен бәҗа китерде[1].

Кайчан ки вәзир әгъзам тарафыннан хәлифәгә хаттагы боерык үтәлү җавабы килеп, вәзирнең хатыннан аңлады ки, ул гарәптән башка кеше үтерелгән. Хәлифә, моңар хәйран булып: «Аллаһу әкбар, әлбәттә, монда бер хикмәт бардыр, кайда ул бәдәви гарәп?» — дип ачигъланып кычкырды. Ул бәдәви, моны ишетеп, дәрхаль хәлифә хозурына хәзер булды. Хәлифә әйтте: «Кайда иден, тугырысын әйт!» — диде. Бу бәдәви гарәп, ул нәдимгә ни булганын белмәгәнлектән: «Фәлән нәдим сез җибәргән хатны миннән илтимас белән алып, вәзир әгъзәмгә киткән иде, аны интизар булып көттем, белмим, килмәде», — диде. Хәлифә әйтте: «Син минем хакымда, авызы бәдбуйдыр, дип гайбәт иттеңме?» — диде. Бәдәви нәдим, ул хасидның мәкерен аңлап: «Әй әмирел-мөэминин, белмәгән вә хәбәрем булмаган нәрсәне ничек телемә китерәем?! Беркөн хозурыңызда авыз тотып тормакым аның мәкере белән икән. Хәзер фәһем иттем. Ул мине чакырып, сарымсаклы тәгам ашатып, хәлифә сарымсак исен яратмай, аның алдында авызыңны тотып сөйләш, дип тәгълим итмеш иде», — дип, кыйссаны сөйләде.

Хәлифә хәзрәтләре, бәдәви нәдимгә чиксез күп ихсан кыйлып мәртәбәсен арттырды. Хасид бәласен табып, яман хәл үзрә набуд булды[2].

---

[1] Бәҗа китерде — башкарды.
[2] Набуд булды — юкка чыкты.

———

Әсмагый, йөз егерме дүрт яшенә житкән бер гарәпне күреп: «Әй гарәп, син ничек бу кадәр яшькә життең?» — диде. Гарәп әйтте: «Көнчелекне куйдым, бу кадәр яшькә життем», — диде.

———

Ялганчылар таифәсеннән берәү әйтте: «Мин меңгә дә ялган сөйләмәймен», — диде. Янындагы мөсахибе әйтте: «Бу ялган сүзеңне бер тиенсез дә әйттең түгелме», — диде.

———

Бервакыт Әхнәф Хәжжаж янында бер сүз әйтмәенчә тик торды. Хәжжаж әйтте: «Ник бер дә сөйләшмәйсең?» — диде. Әхнәф әйтте: «Тугыры әйтсәм — синнән куркам, ялган әйтсәм — Аллаһыдан куркам», — диде.

———

Берәү намаз укыды, әйттеләр: «Һай, намазыңны бик яхшы укыдың,» — диделәр. Ул кеше әйтте: «Мин бүген руза да тотамын», — диде.

———

Бәгъзе мораиләрдән[1] сорадылар: «Гыйракка килгәнең күптәнме?» — диделәр. Әйтте: «Егерме елдан бирле мин Гыйракта торамын, утыз елдан бирле руза тотамын», — диде.

———

Вәһәб бин Менбәгә берәү килде, әйтте: «Фәлән кеше сине сүкте», — диде. Вәһәб әйтте: «Шайтан синнән башка илчене тапмадымы?» — диде.

———

Бер гакыйльгә әйттеләр: «Фәлән кеше синең артыңда сине сүкте», — диделәр. Әйтте: «Мин югында мине сукса да, һич чирканмаймын», — диде.

———

Нәүширванга әйттеләр: «Фәләннең эш хакы вакытында билгеләнгәннән артып каладыр», — диделәр. Нәүширван әйтте: «Ашамыйча туйдыра торган тәгамны күргәнегез бармы?» — диде.

———

Һишам бин Габделмәликнең бер хезмәтчесе вафат булды. Һишамга берәү язды: «Фәлән хезмәтчең вафат булды, сәманин әлеф динары калды, әгәр әмир боерса, бәйтелмалга[2] жибәрелсен иде», — диде, гаммазлык кыйлды. Һишам язды: «Бу безгә васыйл булганнарга аздыр, вәрсәсенә тәкъсим кыйлынсын[3]», — диде.

---

[1] Мораиләрдән — алдакчылардан.
[2] Бәйтелмалга — дәүләт байлыгын жыя һәм саклый торган урын.
[3] Вәрсәсенә тәкъсим кыйлынсын— варисларына бүленсен.

———

Могътэсыйм хэлифэгэ бер кеше язды: «Фэлэн вафат булды, күп акчасы калды, бер углыннан башка варисы юктыр», — дип гамазлык кыйлды. «Ялачыларга һэм чагымчыларга булсын», — диде.

———

Бер кеше Сахиб бин Гыйбадка язды: «Фэлэн кеше үлде, ун мең алтыны калды, бер кызы калды», — диде. Сахиб хатның сыртына язды: «Яртысы кызга бирелсен, калганы кызга кайтарылсын, сагыйга[1] мең-мең лэгънэт», — диде.

———

Берэүгэ үлем сырхавы тиде. Мөхтэзар хэлендэ: «Ике ут тавы, ике ут тавы», — дип ята. Җэмэгатеннэн сорадылар: «Моның ни гамэле бар иде?», — диделэр. Җэмэгате эйтте: «Аның ике үлчэве бар иде, берсе белэн алганда, берсе белэн сатканда үлчэр иде», — диде.

———

Мансур хэлифэ бер гамилнең[2] хыянэтен ишетте вэ аны чакырып эйтте: «Әй Аллаһының дошманы вэ эмирнең дошманы, Аллаһы Тэгалэнең малын ашадыңмы?» — диде. Гамил эйтте: «Йэ эмирел-мөэминин, без Аллаһы Тэгалэнең җэмэгате, син Аллаһы Тэгалэнең хэлифэсе, мал Аллаһы Тэгалэнең малы, инде без кемнең малын ашаек?» — диде. Мансур көлде дэ: «Хыянэттэн хали булыңыз, хаклыктан аерылмагыз», — диде.

———

Искэндэр бер угрыны асмага боерды. Угры эйтте: «Йэ мэлик, мин ихтыярым белэн угырламадым», — диде. Искэндэр эйтте: «Син асылсаң да, ихтыярың белэн асылмайсың», — диде.

———

Бер мэдинэи берэүнең күлмэген угырлап углына бирде: «Базарга илтеп сат», — диде. Углыннан ул күлмэкне янэ берэү угырлады. Углы кайтты. Атасы эйтте: «Кыйммэт саттыңмы, улым?» — диде. Углы эйтте: «Үз хакына китте», — диде.

———

Берэүнең ишэген угырлап киттелэр. Хезмэтчесе эйтте: «Йэ хуҗа, безнең бу көн ишэкне угырлап киткэннэр», — диде. Хуҗасы эйтте: «Әлхэмделиллаһ, эле дэ ишэк өстендэ үзем юк идем», — диде.

———

Бер кеше Нэүширванның эчэ торган кэсэсен угырлады, Нэүширван аны күрде. Бервакытны шэраб хэзерлэгүчесе килде, эйтте: «Йэ мэлик, безнең җамны[3] угырламышлар. Валлаһи, тэф-

---

[1] Сагыйга — көнлэшеп яла сөйлэүчегэ.
[2] Гамилнең — хакимият вэкиленен.
[3] Җамны — пыяла савытны.

тиш кыйлмаенча берәүне дә чыгармам», — диде. Нәүширван әйтте: «Берәүгә дә игътираз кыйлма: аны кайтарып бирә торган кеше угырламады, чагымчылык кыйлмай торган кеше аны күрде дә, берәүгә дә әйтмәде», — диде.

———

Мөгавия мәҗлесеннән берәү бер капчык акча угырлады, Мөгавия аны күрде. Хәзинәчесе әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, безнең хәзинәдән бер капчык акча югалды», — диде. Мөгавия әйтте: «Раст әйтәсең, мин аның иясемен, синең өстеңә хисапланыр»,— диде.

———

Берәүнең бер сандыгын угырлап киттеләр. Ул кешегә берәү әйтте: «Син Аятел көрси» укып куйган булсаң, угырламаслар иде», — диде. Ул кеше әйтте: «Валлаһи, эчендә бөтен Коръән дә бар иде», — диде.

———

Бер фәкыйрь кешенең өенә угрылар керде. Берәр нәрсә эзләп йөриләр иде, иясе аны күрде, әйтте: «Әй егетләр, төнлә ни эзләнеп йөрисез? Сез эзләгән нәрсәне без монда көндез эзләп тә таба алмадык», — диде. Угрылар көлештеләр дә чыгып киттеләр.

———

Берәүнең ишәге югалды. Әйттеләр: «Син үзең гаепле, карамагансың», — диделәр. Икенчесе әйтте: «Ишәкне сугарган кеше гаепледер», — диде. Ишәк иясе әйтте: «Алайса угырлаган кешенең генә бер гаебе дә юк икән», — диде.

———

Берәү базарга бара. «Кая барасың?» — диделәр. «Ат базарына барамын, ат аламын», — диде. «Аллаһы теләсә дип әйт», — диделәр. Ул кеше әйтте: «Шарт куярга хаҗәт юк: ат — базарда, акчам — кесәмдә, барырмын да алырмын», — диде. Ат базарына барып җитмәде, кесәсеннән төшереп акчасын җуйды. Кире кайтып килгәндә, янә берәү очрап: «Әй фәлән, кая бардың?» — диде. Ул кеше әйтте: «Ат базарына бардым, Аллаһы теләсә, ат алмакчы идем, Аллаһы акчамны җуйдым Аллаһы теләсә», — диде.

———

Берәү углын сукага җибәрде. Углына әйтте: «Углым, кич кайтканда сука тимеренне яшереп кайт, угырлап китмәсеннәр», — диде. Углы барып, бөтен көн сукалады. Кич кайтканда, сука тимерен бер карама төбенә яшереп куйды. Кайтып килгәндә, атасы берничә адәмнәр белән урамда утырып торыр икән, атасына кычкырды: «Әти, сука тимерен фәлән карама төбенә яшереп калдырдым», — диде. Атасы әйтте: «Әй ахмак, яшергән нәрсәне шулай кычкырып әйтәләрме!» — диде.

Икенче көн угылы сукага барса, күрде: карама төбеннән

сука тимерен угырлап китмешләр. Тиз үк атына атланып, атасы катына чабып кайтты. Атасы печәнлектә йоклаган иде, атасын эзләп тапты, атасының колагына акрын гына: «Әти, әти, сука тимерен угырлаганнар», — диде.

———

Әбү әл-Гыйна әйтте: «Җария сатучыларда бер җария күрдем, хуҗама кайтамын дип ант итте. Ул җариягә әйттем: «Ни өчен алай ант итәсең?» — дидем. Әйтте: «Хуҗам миңа аяк үзрә мөвакага кыйла, намазны утырып укый. Гаебемне изһар кыйлып, мине сүгә. Коръәнне ялгыш укый. Дүшәнбе көн, кече җомга көн руза тота, Рамазанда ашап йөри. Зоха[1] намазын укый, иртә намазын куя», — диде.

———

Әсмәгый әйтте: «Бер әгърабине күрдем, яше йөз егермегә җиткән иде. Сорадым: «Бу кадәр озак гомер итмәкеңә ни сәбәп?» — дидем. Гарәп әйтте: «Хөсед вә көнчелекне куйдым да билә озак гомер иттем», — диде».

———

Фазыйл дигән мөдәрриснең шәкертләре бик күп булып китте, шуның өчен якыннары монар хөсед кыйлдылар. Көнчелекләре белән, бер явыз хатынны табып: «Фазыйл мөдәррис миңа якынлык кыйлды», — дип икърар кыйлдырдылар. Аннан соң Фазыйл үзенең бу тора торган карьясеннән күчте. Ул күчкәч, бу карьянең игенлеге кипте, бәрәкәт бетте. Аннан соң: «Кайтсана», — дип, Фазыйлны чакырдылар. Фазыйл әйтте: «Кайтырмын шул шарт белән ки, минем хакымда кыйлган ялаларыгызны, синең хакында яла кыйлган идек, дип икърар кыйлыңыз», — диде. Ахыр икърар кыйлдылар. Фазыйл әйтте: «Инде ялганчылар карьясендә хаҗәтем юктыр», — дип кайтмады. Карьяләрендә бәрәкәт киселде.

———

Бер йорт сычканы, сахрага чыгып, тәфәрреҗ кыйлып[2] йөргәндә, сахра сычканына очрады. Күрде, ач вә арык вә михнәт эчендә, зәгыйфь кенә йөрер.

Йорт сычканы, аны кызганып: «Әй борадәр, болай нигъмәттән хали җирләрдә ник йөрисең? Әйдә, йортларга бараек. Анда, ашамак-эчмәктән әнваг нигъмәт бардыр», — дип, шәһәргә үзенең оясы булган ханәгә ияртеп килде. Мәгәр ханә иясе эченә май кисәге куеп, тәбе корып куйган, имеш. Шунда ук йорт сычканы ул май кисәгенә барып ябышты, дәрхаль өстенә тәбе төшеп, сычкан тәбе астында яньчелде. Бу вакыйганы сахра сычканы күрде, бераз фикердә торыбрак әйтте: «Юк, болай булмый. Нигъмәт муллыгы дәһшәтле бәла янәшәсендә күрдем. Җан тыныч-

---

[2] Зоха — төш алды вакыты.
[1] Тәфәррреҗ кыйлып — рәхәтләнеп, күңел ачып.

лыгы белән фәкыйрьлектә тереклек кыйлмак миңа үлем якын булган байлыктан сөеклерәктер», — дип, үзенең килгән имин җиренә сахрага качты.

———

Бер зимми[1] үзенең дуңгызын симертеп суймак өчен алдына печән салып, баганага бәйләп куймыш иде. Аның дәхи баласы бер ишәге бар иде. Ишәкнең баласы, ул дуңгыз сачкән печәннәрне җыеп ашаганнан соң, анасына әйтте: «Әй ана, бу печән ни гүзәл, нәфис нигъмәт, имеш», — дип мактады. Ишәк әйтте: «Бак, углым, гафил булма, саклан, алданма, аның аргы ягында — кыямәт дәһшәте вә бәлаи газыймы бардыр», — дип, баласына нәсыйхәт итте. Кайчан ки дуңгыз симереп, зиммигә ит кирәк булгач, дуңгызны яткырып, муенына пычакны куйганда, дуңгыз тиберченә башлаганын ишәк баласы күргәч тә, качып анасы янына килде, авызын ачып: «Әй аначыгым, карасана, тешләрем арасында ул печәннең калганнары юк микән, чыгара күр», — диде. Сәламәтлек өчен канәгать ни гүзәл нәрсәдер.

———

Һарун әр-Рәшит заманында олуг ачлык булып, халык гаҗиз калмышлар иде. Һарун боерды: «Аллаһы Тәгаләгә егълап, тәзаррыг[2] вә дога кыйлыңыз. Уен-көлке коралларын ватыңыз, сындырыңыз», — диде. Шулчак күрделәр: бер егет, кулында уен коралы, уйнап-биеп шатлык кыйлыр. Хәлифәнең әмеренә хилаф булганлык җәһәтеннән аны тотып, хәлифәгә илттеләр. Хәлифә әйтте: «Һәркем ачлыктан гаҗиз калып, егълап дога белән мәшгульләр икән, син ни шатлык таптың, билә уйнарсың», — диде. Ул егет әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, минем хуҗамның амбарлары тулы ашлыгы бар, ул ашлык амбарыннан мин дә тукланам. Әфәндем ул амбарындагы байлыктан мине һәм өлешсез итмәсенә ышанычым вә катнашым барлык җәһәтеннән, ачлык өчен кайгырмаймын, шатлыгымнан уйнармын, биермен», — дип җавап бирде. Хәлифә дәхи, бу җавап итеп уянгандай булып, бу егетнең үзе кебек Алла колы булган берәүгә ышануы вә тәвәккәлле шатлыгына сәбәп булса, Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл вә таяну ни мәртәбә нәтиҗәле булса кирәк? дип, халыкны үз хәлләренә куйды вә Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл[3] белән боерды.

———

Бәлех вилаятендә газизләрдән Хатәм әл-Әсым дигән бер газиз бар иде, әһел әүлады күп ишле гыйлзла вә фәкыйрь адәм иде. Көн үткәрергә бер бөртек икмәккә малик түгел иде. Беркөн әңгәмәдәшләре белән утырып сөйләшкәндә, сүзләре Кәгъбә-

---

[1] Зимми — ислам дәүләтендә яшәүче мөселман булмаган кеше.
[2] Тәзаррыг — түбәнчелек белән ялыну.
[3] Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл — Аллаһыга тапшыру.

туллага зыярәт хакында булганнан соң, күңеленә Кәгъбәтуллага зыярәт кыйлмак шәүкы төшеп, җәмәгате белән мәслихәт кыйлышты: «Бу ел рөхсәт бирсәңез, Кәгъбәтуллага зыярәт кыйлыр идем», — диде. Балалары әйтте: «Әй шәфкатьле атамыз, сезләр бер данә орлыкка малик[1] булмаганлыкыңыздан искә дә алмыйк. Әмма безләр ни дәрәҗәдә фәкыйрьлек вә ачлык белән мөбтәлямез, безне шул хәлдә ташлап китеп, ничек инде ул сәфәрне үзеңезгә лазем итәсез?» — дип разый булмадылар. Әмма бер кечкенә кызы атасына вә башка туганнарына вәгазь вә нәсыйхәт йөзеннән: «Әй ата, вә әй туганнарым, атамызга рөхсәт бирсәңез ни зарар? Тимәңез, барсын, ихласы бардыр, Кәгъбәтуллага таваф кыйлсын. Ул Аллаһы Тәгаләнең бер бәндәсе икән, тәкъдирдә яздырган микъдар ризкын ашагучыдыр, разыйк түгелдер. Безнең ризыкымызны да Аллаһы Тәгалә ирештерер», — диде.

Бу кечкенә кызының нәсыйхәтен аталарына әйтеп, хаҗ сәфәренә рөхсәт бирделәр. Аталары шул сәгать һичбер азыксыз юлга чыгып китте. Иртәгесен күршеләре вә дуслары килеп: «Ни өчен атаңызга рөхсәт бирдеңез? Атаңызның юл азыгы, һичнәрсәсе юк. Сезгә һичнәрсә калдырмай, ничек тереклек кыйлырсыз?» — дип, Әсымның җәмәгатен үкенечкә салдылар. Ул кечкенә кызның туганнары вә аналары: «Әүвәл син мәслихәт иттең, ни өчен тик тормадың?» — дип, баланы орыштылар. Ул кечкенә, бичара, йөзен күккә текәп: «Илаһи бер Ходай, мин гаҗизә бәндәң боларга: безнең ризыкымызны Аллаһы ирештерер дип вәгъдә иттем. Син аларны ризыксыз калдырма, мин гаҗизә бәндәңне алар каршында оятлы итмә», — дип зарилык кыйлды.

Мәгәр шул замананың хәлифәсе ул көндә үзенең кавем кабиләсе белән ауга чыкмыш иде. Юлдашларыннан аерылып ялгыз йөргәндә, юлы бу Хатәм әл-Әсымның ханәсенә тугыры килеп, гаять сусаганлыгыннан Әсымның ханәсенә килеп, бер эчемлек су сорады. Әсымның җәмәгате: «Ул кем?» — дип сорагач: «Хәлифәдер», — дип җавап биргәннәреннән соң, Әсымның хатыны шәхсән үзе бер касә су тотырып алды. «Йа Рабби, безләр бу кичә ач үткәрдек, фазыл вә кәрәмеңнән ишегемезгә хәлифәне китердең», — дип, үзе капка артында торып, хәлифәгә касә белән суны кулы белән сузып бирде. Хәлифә суны алып эчте, рәхәт тапты. «Бу кем йорты?» — дип сорады. Әйттеләр: «Бу Аллаһы Тәгаләнең изге бәндәләреннән Хатәм әл-Әсым дигән бер яхшы адәмнең йортыдыр», — диделәр. Хәлифә әйтте: «Мин ул кешене ишеткәнем бар иде», — дигәч, вәзире әйтте: «Йә әмир, Хатәм хәзрәтләре үзе кичәге көн гаяленә вә әүладына бернәрсә калдырмаенча, хаҗ сәфәренә китте. Җәмәгате бу

[1] Малик — ия һәм тәкъдиргә риза булу.

кич ач уздырдылар дип, мин бу көн ишеттем», — диде. Аннан соң хәлифә: «Бу ханәгә без дәхи мәшәкать ясадык. Безнең кебек кеше бу фәкыйрьләргә мәшәкать чиктермәк лаек түгелдер», — дип, һаман билендәге җәүһәр белән мәрәсыг бизәлгән билбавын чишеп, Хатәмнең ханәсенә ташлады. «Мине сәүгәннәр билә кыйлсын», — дип ишарәт кыйлды. Аннан соң вәзирвөзарасы һәммәсе билләреннән билбауларын чишеп, Хатәмнең җәмәгатенә ташладылар. Вә әйттеләр: «Әссәламәгаләйкем, әй йорт эчендә булган адәмнәр! Сезләрне Аллаһы Тәгаләгә тапшырдык, бу кәмәрләр сездә рәһин кебек торсын, бәһаләрне биреп алырмыз», — дип киттеләр. Һәм тиз заман кәмәрләренең бәһасе өчен күп мал китереп, кәмәрләрен йолып алдылар.

Әлеге кечкенә кыз бала бу хәлне күреп, кычкырып егъламага башлады. Анасы вә туганнары әйттеләр: «Ни өчен егъларсың? Әлхәмделиллаһ, бу кадәр малга малик булдык. Хәзердә шатлык вакытыдыр, егълар вакыт түгелдер», — диделәр. Ул гакыллы кыз бала әйтте: «Егъламакымның сәбәбе будыр ки: бу кичә ач ятмыш идек вә фәкыйрь идек. Ходаның бар иткән җан иярләреннән бер мәхлук безгә, бер мәртәбә карамак белән, безне бу кадәр бай итте. Аллаһы Тәгалә үзе безгә нәзарын салса, ул вакытта бер адәмгә хаҗәтемез булмас дип шөкер итеп егъълармын», — диде. Вә атасы өчен дәхи: «Йа Рабби, атамызга да мәрхәмәт нәзары белән кара», — дип дога кыйлды.

Вә дәхи Хатәм әл-Әсымның хәле билә булды ки, бер акчага мохтаҗ булып, Мәккәгә барып җитте. Ул көн әмирелхаҗ бер авыруга мөбтәля булып, тән дәвасы белән дәва вә гыйлаҗ вә файда кыйлмаганнан соң, рухи дәва өчен: «Хаҗилар арасында Аллаһы Тәгаләнең изге бәндәләреннән бер мөбарәк җан юкмы?» — дип эзләп йөргәндә, Хатәм әл-Әсымны дәляләт кыйлдылар вә Хатәмне дәрхаль табып, әмирелхаҗ янына алып килделәр. Хатәм хәзрәтләре әмирелхаҗга нәфәс биреп, Аллаһы Тәгаләнең изене белән дәрхаль шифа тапты. Аннан соң Хатәмнең бар ихтыяҗы әмир тарафыннан каралмага әмер булды. Ул кичә Хатәм хәзрәтләре җәмәгатенең әхвәлен фикер итеп: «Вә әгъҗәба! Җәмәгатем ни хәлдә икән?» — дип, фикердә торганда, йокы галәбә кыйлып, төшендә Аллаһы Тәгалә тарафыннан хитаб ишетте: «Әй Хатәм, кайсы бәндәм минем өчен мөгамәләсен дөрес вә гүзәл итсә, мин дәхи ул бәндәм белән мөгамәләмне дөрес вә гүзәл итәрмен», — дип, җәмәгатенең хәлен илһам кыйлды. Аннан соң Хатәм әл-Әсым Аллаһы Тәгаләгә шөкер вә сәналәр кыйлып, хаҗны тәмам итеп юлга чыкты вә, кайтып кергәч, кечкенә кызын кочып, егълап дога кыйлды: «Бер кавемнең кечкенәсе дә икенче кавем каршында олугдыр, Аллаһы Тәгалә сезнең яшеңезгә вә дәрәҗәңезгә карамас. Мәгәр кемдә мәгърифәт күп, аңа карар. Барчаңызга васыять кыйламын ки, Аллаһы Тәгаләнең мәгърифәтенә мөла-

язәмәт кыйлып[1], вә Аллаһы Тәгалә үзе аңа кяфи вә вафидыр»[2], — дип, җәмәгатенә нәсыйхәт кыйлды.

———

Мәшһүр Дауд әт-Таи хәзрәтләре бер заманда фәкыйрь хәлгә төшеп, имам Әгъзам углы Хәммад Дауд хәзрәтләренә атасыннан калган мирастан дүрт йөз дирһәм һәдия итеп китерде вә кабул кыйлмакын илтимас итте. Дауд хәзрәтләре: «Әгәр дә бу заманга кадәр берәүдән һәдия кабул иткән булсам иде, мәеткә тәгъзыйм вә хәяттагыларга тәкрим өчен бу дирһәмнәрне кабул итәр идем, ләкин канәгатьтә торып тереклек кыйлмага мәхәббәтем бар, зинһар, гаеп итмәсәнә», — дип кабул итмәде.

———

Габдулла бин Мәрзук олуг газизләрдәндер. Әүвәл хәлләрендә дәүләт иясе адәм булып вә тәмам күңеленнән малга мәхәббәт итеп, һава вә һәвәс, вә исраф белән мәшгуль иде. Беркөн зиядә сәрхуш булып ятыр иде. Икенде намазы үтте. Тәүфикына сәбәп: исерек хәлендә ятыр иде, җариясе кыскыч белән утлы күмер китереп, аягына куйды. Аягы пешкәч, ялт итеп күзен ачты: «Бу ни хәл?» — дип сикереп торды. Җариясе әйтте: «Халән[3] син дөнья утына чыдамадың, ахирәт утына ничек сабыр итәрсең?» — дигәч, җариянең сүзе әсәр итеп, дәрхаль тәүбә вә истигъфар кыйлып, намазын каза кыйлды. Вә бар мал-мөлкәтен Аллаһы Тәгалә юлына сарыф итеп, үзенә ризык өчен үлән вә сәбзә[4] сатып ризыкланыр иде. Вә әүлияи Аллаһыдан булды.

———

Мәнкульдер ки: Гали разыйаллаһу ганһу беркөн мәсҗет шәрифкә кергәндә, атланган ишәген мәсҗет янында торгучы бер адәмгә: «Тотып тор», — дип бирде. Мәзкүр адәм һәман[5] ишәкнең җөгәнен алып, ишәкне урынында калдырып качты. Гали разыйаллаһу ганһу мәсҗеттән чыкканда, ул адәмгә ишәкне тотып торган өчен бирермен, дип, кулына ике дирһәм тотып чыкты, күрде: ул кеше юк, ишәк җөгәнсез торыр. Анда дәхи бер адәмгә ул ике дирһәм акчаны биреп: «Бар, базардан бер җегән алып кил», — дип әмер итте. Ул кеше дәрхаль базарга барып күрде ки, базарда берәү хәзрәте Гали ишәгенең җөгәнен сатар. Ике дирһәмне биреп, ул җөгәнне сатып алды. Хәзрәте Гали хозурына килеп, ишәккә җөгәнне кидерде. Гали разыйаллаһу ганһу әйтте: «Кара, бичара, ни хәлял ризыкны үзенең сабырсызлыгы сәбәпле харам итеп алды, хәлбуки аңа тәкъдир кыйлынган нәрсә сабырсызлыгы белән һич тә артмады», — диде.

---

[1] Мөлаязәмәт кыйлып — турылыклы булып, тапшырылып.
[2] Кяфи вә вафидыр — рәхмәтле һәм ышанычлыдыр.
[3] Халән — әле, хәзер дә.
[4] Сабзә — яшелчә.
[5] Һәман — шунда ук.

———

Бер раһибтан[1] сорадылар: «Кайдан ашыйсың? Ягъни кәсебең ни-нәрсәдер?» — диделәр. Раһиб, тешләренә ишарәт кыйлып: «Ошбу тегермәннәрне ясаган кеше бодай белән килер», — диде. Ягъни тешне яраткан Аллаһы ризыкны да житештерер, димәктер.

———

Бер гарәп хатынынннан сорадылар: «Кайдан тереклек кыйласың», — диделәр. Ягъни кайдан ризыкланасың. Гарәп хатыны әйтте: «Ашаган ризыкымызны беләмез, ләкин кайдан терекләнәмез, сәбәпләрен белмәймез», — диде.

———

Шәкыйк Бәлхи берәүдән сорады: «Тереклегең ничек, ни белән тереклек кыйласың?» — диде. Ул кеше әйтте: «Әлхәмделиллаһ, тапканда — ашыймын, булмаганда — сабыр итәмен», — диде. Шәкыйк әйтте: «Син безнең Бәлех этләре кебек, имешсең, Бәлех этләре һәм шулай: тапсалар — ашыйлар, тапмасалар — сабыр кыйлалар», — диде. Ул кеше әйтте: «Әй Шәкыйк, сезләр ничек итәсез, миңа үгрәтеңез», — диде. Шәкыйк әйтте: «Мин тапсам — исар кыйламын[2], тапмасам — шөкер итәмен», — диде.

———

Хәзрәте Гали разыйаллаһу ганһуга бер гарәп килеп, үзенә ризыклык сөаль кыйлды. Хәзрәте Гали әйтте: «Валлаһи, өемдә ризыкымнан арткан нәрсә юктыр», — диде. Гарәп әйтте: «Мине, болай, хозурына килеп, буш вә мәэюс[3] жибәрмәкеңнән Аллаһы Тәгалә хәзрәте кыямәт көнендә сөаль кыйлыр», — дип мәэюсан киткәндә, Гали разыйаллаһу ганһу мөтәэссир булып егълады. Гарәпне кире кайтарып, үзенең Канбәр исемле хезмәткәренә боерды: «Бар, минем фәлән зәрһемне[4] бу гарәпкә китереп бир», — диде.

Канбәр дәрхаль зәрһне китерде. Хәзрәте Гали гарәпкә биреп әйтте: «Йә гарәп, алданма, моның бәһасен ким сатма, мин ул зәрһне белән күп заман дин өчен сугышта киеп, дошманга галәбә кыйлдым, — бәһасенә сат вә хажәтеңә сарыф кыйл», — диде. Канбәр әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, гарәпкә егерме дирһәм житәр иде, күбрәк бирдеңез», — диде. Гали әйтте: «Әй Канбәр, әгәр Аллаһы Тәгалә бу гарәпнең минем хозурымда хажәтен изһар кыйлып торганыннан сөаль кыйлганда, мин ул гарәпкә дөнья малын биреп, Аллаһы Тәгалә кабул итсә дә, миңа мөсәррәт[5] бирмәс», — дип, Канбәрнең каршы төшүен кире какты.

---

[1] Раһибтан — монахтан.
[2] Исар кыйламын — юмартланам, өләшәм.
[3] Мәэюс — өметсез.
[4] Зәрһемне — металлдан үрелгән өс киememne.
[5] Мөсәррәт — куаныч.

———

Бер малдар вә бай гарәптән бер адәм килеп: «Әй әфәндем, минем җәнабыңызга хаҗәтем — юл адашкан кешенең юл күрсәтүчегә ихтыяҗы кебектер», — дип, купшы сүзләр белән сөаль кыйлып, дәрхаль морадын алмыштыр. Сөальдә күркәм сүзләр тәэсирледер.

———

Хәсән бин Сәһелгә бер кеше бер нәрсә хаҗәт теләп килде. Мәзкүр Хәсән ул кешенең мәгърифәтен имтихан йөзеннән: «Ни мөнәсәбәт белән миннән син хаҗәт теләйсең?» — диде. Ул кеше әйтте: «Мин узган ел хозурыңызга килмеш идем, ул вакыт мине шатландырдыңыз иде», — диде. Хәсән әйтте: «Безгә безнең яхшылык белән тәэсир кыйлган кешегә мәрхаба», — дип, хаҗәтен әда кыйлды.

———

Маэмүн хәлифә Мөхәммәд бин Хазимгә әйтте: «Дәрхаль бик гүзәл ике бәет нәзым әйт», — диде. Ул дәхи дәрхаль бу кыйтганы әйткәннән соң, Маэмүн аңа ун мең дирһәм игъта кыйлды. Шигыренең мәгънәсе: әй хәлифә, син — күксең, күктән ягъмур яуган шикелле синнән ихсан явар. Вә бу бәндәңезнең (ягъни минем) ике кулым синең ихсан күгеңнен җиредер. Ягъмур, әлбәттә, җиргә төшәр, синең ихсаның дәхи минем кулыма ирешер. Бәс, алай булса, әй хәлифә, минем кулыма нигъмәтеңнең орлыгын ик, таки минем телемнең җиреннән мәдех игенен урырсың, димәктер.

———

Хәлифә Мәһди Рәй шәһәреннән Бәгъдадка кайтканда, шагыйрьләр аның кайтмакына шигырь нәзым итеп, югарыда мәзкүр булган Әбү Дәлламә аша кыйтгасыны хәлифәгә гарыз кыйлды. Мәгънәсе: тәхкыйк мин сезнең шат вә сәламәт хәлдә кайтканыңызны күрсәм, сезгә пәйгамбәр галәйһиссәлам үзәренә салават иттермәгә вә куенымны дирһәмнәр белән тутыртмага нәзер әйттем, димәктер.

Кайчан ки хәлифә бу кыйтганы алып укыды, салават әйтте. Әбү Дәлламә әйтте: «Әй хәлифә, әүвәлге хәсәнәгә ашыгычлык күрсәтеп тә, икенче хәсәнәгә сүлпәнлегегез ни сәбәптәндер?» — дигәч, Мәһди бик тә урынлы гарыз дип, бер капчык дирһәм китертеп, әбү Дәлламәнең куенына тутыртты.

———

Һарун әр-Рәшит бервакытны Мәккәи Мөкәррәмәдә бер гарәп хатынының көенечле тавышы белән әйткән бәет ишеткәч, күңеле нечкәреп егълады вә якыннарына катгыйлык белән: «Ошбу гаҗизәгә садакаңыз булса бирегез», — дип әмер итте. Филхаль шулкадәр китереп алтыннан, көмештән, вә гайре заттан, вә кием-салымнан хатынның янына салдылар, хәтта хатын

әйберләр эченә күмелеп калды. Бәетнең мәгънәсе: ачлык вә юклык тегермәннәре безнең вөҗүдемезнең бөртекләрен он итеп тартты. Вә бәхетсезлек безләрне йон кебек итеп тетте. Ошбу гаҗизлегемезгә күрә, дәстәрханнарыңыздан[1] кәрәм вә җомартлык валчыкларыңызны җыярга кулларымызны суздык. Әй Бәйтуллага зыярәт кыйлгучылар, безләргә ихсан кыйлыңыз, әҗер вә савабыңыз безләрдәдер, димәктер.

———

Бер кемсәнә, Мансур хәлифәнең хозурына килеп, бер хаҗәт сөаль кыйлды. Ләкин морады хасыйл булмады. Янә берничә заманнан соң килеп, тагын шул хаҗәтен эстәде. Хәлифә әйтте: «Син аны миңа моннан мөкаддәм дә бер мәртәбә әйттең түгелме?» Хаҗәтен әда кыйлмаслык булгач, ул кемсәнә: «Бәли, әй әмирел-мөэминин, әйткән идем, ләкин вакытларның бәгъзесе бәгъзесеннән изгерәк, бәгъзе урын бәгъзе урыннан шәрафәтлерәк», — дип, килешүчән җавабы белән гозер иткәч, хәлифә: «Дөрес әйтәсең», — дип, аның җавабын хуплап, морадын әда кыйлды.

———

Берзаман Бәгъдад шәһәрендә ачлык вакыйг булып, халык ризык хасыйл итмәк өчен Бәгъдадтан күчмәгә башладылар. Һәркем үзе теләгән тарафка ризык эзләмәгә киттеләр. Әмма бер кеше, хатыны сәфәргә кодрәте булмаганлыктан, хатынын өйдә калдырып китмәк булды. Хатыны моның сәфәргә хәзерләнгәнен күргәч: «Син киткәннән соң, монда безне кем тәрбия кыйлыр?» — дип егълады. Ул кешенең күршесе ибн Гобәйдулла дигән бер икмәкле кемсәнә бар иде. Хатынның ире әйтте: «Минем Гобәйдуллада алачагым бардыр. Хәтта шәргый шаһидем дә бар. Шул алачагым хисабына, мин кайтканчы сине ул тәрбия кыйлыр. Ул шаһидемне илтеп күрсәтерсең», — дип, ошбу бәетне язып, хатынының кулына бирде. Бәетнең эчтәлеге: хатыным минем сәфәр ниятем белән хәзерләнгән тәвәмне вә юл әсбабымны күргәч: «Син сәфәргә киткәннән соң, безне монда кем нәфәкаләндерер?» — диде. Мин әйттем ки: «Сиңа хәкыйкый хуҗа — Аллаһы Тәгаләдер. Вә сури хуҗаң, ягъни Аллаһы Тәгалә биргән ризыкның васитасы булгучы хуҗаң — ибн Гобәйдулла туйдыручыңдыр», — дидем, димәктер.

Бәс, ул кеше сәфәргә киткәннән соң, хатын, ибн Гобәйдуллага барып, ире сәфәргә китеп, шундый эшне аңа йөкләп калдырганын сөйләп, ул кәгазьне ибн Гобәйдулланың кулына бирде. Ибн Гобәйдулла хатны укыганнан соң: «Ирең раст сөйләмеш,

---

[1] Дәстәрханнарыңыздан — ашъяулыкларыгыздан

казыййа[1], шулайдыр», — дип, ул хатынның ире сәфәрдән кайткан замангача нәфәкаләндерде.

———

Мәшһүр шагыйрьләрдән Мотыйг бин Әяс Мәган бин Заидне бер касыйдәи хәсәнә белән мәдех итеп, Мәганның алдында укыды. Мәган гаять мәхзуз[2] булып, Мотыйгның морадын белсә дә, телгә салынып: «Йа Мотыйг, әгәр эстәсәң, Аллаһы Тәгалә сиңа күп әҗерләр вә саваплар бирсен дип дога кыйлаем. Әгәр эстәсәң, син мәдех иткән кебек мин һәм сине шулай мәдех итәем, бу ике нәрсәдән кайсына ихтыярың бар», — диде. Мотыйг ач вә мохтаҗ хәлдә икән, хаҗәтенә берәр нәрсә өмид итеп тә, бу мөгамәләне күргәч: «Аллаһы Тәгаләдән әҗер вә савап эстәмәймен», — дип беркатлыланды. Мохтаҗ икән, Мәганның мәдехенә разый булмак та үзенә көч килеп, бер сүз дәшмәенчә, бары ишектән чыкканда: «Ярар, алайса», — дип, мәдехкә вә дога ризалык күрсәткәндәй булды. Ханәсенә килде дә ошбу кыйтганы язып, дәхи Мәганга күндерде. Мәгънәсе: вакыйган, олуг әмирдән вә нигъмәт вә мал иясеннән, якыннары хакында мәдех — кәсеб вә һөнәрнең хәерлеседер. Ләкин мин ул таифәдән түгелмен. Ачлыктан вә мохтаҗлыктан замана минем сөякләремне нечкәртте. Вә зәгыйфьләндерде — миңа дирһәмнән гайре дәва юктыр, димәктер.

———

Көннәрдән бер көн Искәндәрнең мәҗлесендә күп адәмнәр бар иде. Искәндәр әйтте: «Мин һичкайчан һичкемне мәхрүм итеп җибәргәнем юк, — диде. — Миннән ни хаҗәт эстәсәләр — әда кыйламын», — диде. Шул вакыт мәҗлес әһеленнән берсе әйтте: «Йә падишаһ, хаҗәтем бардыр, миңа бер дирһәм бәхшиш[3] кыйл», — диде. Искәндәр әйтте: «Падишаһлардан аз нәрсәне сорамак әдәпсезлектер», — диде. Ул кеше әйтте: «Әгәр падишаһ бер дирһәм бәхшиш кыйлмактан намусланса, мәмләкәтен бирсен», — диде. Искәндәр әйтте: «Әүвәл мәртәбә сораганың минем мәртәбәмнән ким иде, шуның өчен бәхеш кыйлмадым. Икенче сораганың — үз мәртәбәңнән зиядәдер, ике сөалең дә урынсыз булды», — диде. Ул кеше һич җавапсыз шәрмәндә[4] булып калды.

———

Ибн әл-Хатыйб хәзрәтләре ошбу хикәятне китермештер. Кадим заманда фазыйл вә гөман белән мәшһүр Мәрү шәһәрендә Нух ибн Әбү Мәрьям дигән бер казый бар иде. Кызын берәүгә бирмәгә ният итеп, күршесе булгучы бер мәҗүсигә

---

[1] Казыййа — эш, мәсьәлә.
[2] Мәхзуз — канәгать, шат.
[3] Бәхшиш — бүләк.
[4] Шәрмәндә — оятлы.

киңәш итте. Мәҗүси әйтте: «Сөбханаллаһи, бу гаҗәп эш түгелме, халык мөшкел эшләрен сезгә мәслихәт кыйлышалар. Әмма сез иң кирәкле мәслихәтне, кыз бирмәк хосусында икенче диндә булган кешегә мәслихәт кыйласыз?! Мин, сезнең динездә ни-нәрсә бар, кайдан беләем», — дип гаҗәпләнүен белдерде. Казый әйтте: «Бу хосуста кемгә булса да бер мәшвәрәт кирәк», — диде. Мәҗүси әйтте: «Безнең Гаҗәм падишаһларымыз мал иясенә карый, Кыйсәр падишаһлар хәсәб вә нәсәбен карый. Әмма сезнең рәисеңез булгучы Мөхәммәт галәйһиссәлам диянәт иясен карый, имеш. Үзең кайсы мәзһәбтә булсаң, мәзһәбеңнең рәисләре боерганны тотарсың», — дип, мәҗүси булса да, хак вә мәкъбуль сүзне бәян кыйлды. Казый дәхи, диянәт иясен эзләп, кәримәсен аңа тәзәүвеж[1] итмештер.

———

Шәгъби димештер ки: Әбү Өмәййә дигән бер казый белән мөсахәбәт кыйлып утырганда, сүз уңае килгәч, миңа: «Әй Шәгъби, әгәр тәзәүвеҗ кыйлмага теләсәң, бәни Тәмим кабиләсеннән кыз ал. Зирәки мин аларда гакыл вә дираять[2] күрдем», — диде. «Аны кайдан белдең?» — дип сорадым. Әйтте: «Мин моннан мөкаддәм, егет вакытымда, шәһәрнең тышында булгучы каберстанга бер җеназа белән барып, мәетне күмеп кайтканда, бәни Тәмим кабиләсеннән булган йортларның яныннан узганда күрдем ки: бер йортның капкасы янында бер карчык утырыр, янында кояш кебек балкыган бер яшь кыз торыр иде. Аңа охшаган кызны гомеремдә күрмәдем, эчәсем килмәсә дә, янына бармага сылтау кыйлып бардым. Карчыктан эчмәгә бер касә су сорадым. Хатын әйтте: «Ни эчәсең килә, әйт, китерермез», — диде. Мин әйттем: «Якынрак ни-нәрсәң булса да ярар, эчем бик сусады, азрак хәрарәтем[3] басылсын», — дидем. Хатын әйтте: «Бар, кызым, бу егеткә су китер. Зирә мин бу егетне лаек әлихсан, бер гариб әд-дияр[4] күрәмен», — диде.

Кызы китте, дәрхаль салкын сөт алып килде. Сөтне эчтем, аннан соң әйттем: «Әй хатын, бу яшь кыз кемнең кызы?» — дидем. Хатын әйтте: «Бу кыз Җәрир исемле кешенең кызы Зәйнәптер», — диде. Бу кызның инде ире бармы яки кияүгә китмәгән кызмы?» — дидем. Хатын әйтте: «Бу кыз хәзер генә җиткән кыздыр, һәнүз кияүгә бирелгәне юк», — диде. Янә әйттем: «Алай исә бу кызны миңа бирегез», — дидем. Әгәр кәфү булсаң — булыр, дип «уау» белән «көфу» димәде, кәфү Тәмим лөгатедер. Аннан көндезге ял өчен өемә кайттым. Ләкин күземә йокы кермәде. Торып өйлә намазымны укыдым.

---

[1] Тәзәүвеж — өйләнү, никахлашу.
[2] Дираять — зирәклек.
[3] Хәрарәтем — эсселегем.
[4] Гариб әд-дияр — башка җир кешесе.

Аннан соң каумемнең аксакаллары булгучы кардәшләрем Галькамә вә Әсвәд вә Мөсиб хәзрәтләрене алып, бергә мәзкүрә кызның агасыны күрмәк касды белән ханәсенә бардык. Безне икраман каршы алып, ханәсенә утыртты. Әйтте: «Йә Әбү Өмәййә, ни ирадә белән килдең?» — диде. Мин әйттем: «Карендәшеңнең кызы Зәйнәпне хотбә кыйлмак өчен килдек», — дидем. Дәрхаль юлдашларым хозурында шәрган гакыд кыйлса да, ләкин гакыд соңында бәни Тәмим хатыннары каты күңелле икәнлекләре хәтеремә килеп, нәдамәт кыйлдым. Бу кабиләдән кыз алып ни кыйласың дип, үземә-үзем фикер кыйлдым, талак кыйлаем дип, күңелемә килде.

Янә кайттым, зөфаф кыйлып караем, миңа ярарлык мөгамәләсе булса — тотармын, булмаса — аерырмын дип зөфаф кыйлдым. Кызның мөтәгалликаты[1] булгучы хатыннар кызны зиннәт белән китереп бәйтелгаруска[2] керттеләр. Мәзкүрә кыз иң әүвәл сүз башлап миңа: «Зөфаф кичәсендә зәүҗәне[3] зөфаф бүлмәсенә китергәч, зәвеҗнең торып, ике рәкәгать намаз укып, зәүҗәсенең хәер вә бәрәкәтен Аллаһы Тәгаләдән сорап дога кыйлмагы сөннәттер», — диде. «Мин дәхи, бәли, бәли, шулай», — дип, дәрхаль намаз укыдым вә сәлам бирдем. Күрдем ки: кыз дәхи намаз укып торыр. Аннан соң җарияләре килеп, өстемнән киемне салдырып, миңа зәгъфәран вә мисәк белән буялмыш кичәлек киемен кидерделәр, урынны тәхлия кыйлганнан соң, кызның янына барып, кулымны маңгаена сузганда: «Сабыр кыйл, гаҗәлә боерма, әй Әбү Өмәййә», — дип ошбу хотбәне укыды: «Әй Әбү Өмәййә, мин бер ят хатын, мин синең әхлакыңнан гыйлемем вә хәбәрем юктыр ки, холкың, фигылең вә табигатең ничектер белмәймән, сәүгән вә хуш күргән ни-нәрсәң булса, бәян кыйл, таки җиренә китерәем вә яратмаган вә мәкрүһ күргән нәрсәләреңне әйт. Таки иҗтинаб[4] кыйлаем, гакыд шәргый белән миңа малик булдың, инде Аллаһы Тәгаләнең мөбах[5] кыйлган нәрсәләре белән гамил бул, лотыф вә кәрәм белән мине тот яки тәсрих кыйл, ихтыярыңдыр, инде бу сүзне билә диямен, үзем өчен вә синең өчен Аллаһы Тәгаләдән мәгъфирәт таләп кыйламын», — диде.

---

Харис бин Гауф Әвәс бин Харисның кызларыннан берен хотбә кыйлмак өчен, дусларыннан Харҗә бин Синан дигән кемсәнәне үзенә юлдаш итеп, Әвәснең шәһәре тарафына киттеләр, барып җитеп, Әвәсне күрделәр. Әвәс дәхи: «Мәрхаба, йә Харис,

---

[1] Мөтәгалликаты — туганнары.
[2] Бәйтелгаруска — кызның кияү каршылау бүлмәсенә.
[3] Зәүҗәне — кәләшне.
[4] Иҗтинаб — тыелу.
[5] Мөбах — тыелмаган да, кушылмаган да эш.

ни сәбәп белән килдең?» — дип килмәкнең сәбәбен сорагач, Харис әйтте: «Кызыңны тәзәүвеҗ касды белән килдем, ни боерырсың?» — диде. Әвәс әйтте: «Булмаган эш, ягъни кабул итмәймен», — дип, гайре сүз сөйләшмәенчә зәүҗәсе янына керде. Зәүҗәсе әйтте: «Алар кемнәрдер ки килделәр, сәлам бирделәр исә, син алар белән утырмадың, сөйләшмәдең, ачу белән өйгә кердең», — дип, сәбәбен сорагач, Әвәс әйтте: «Ул кеше гарәпнең сәеде вә олугысы Харис бин Гауфтыр», — диде. Зәүҗәсе әйтте: «Ник өйгә алып кермәдең, кунак итмәдең?» — диде. Әвәс әйтте: «Ул мине ахмакка сайды», — диде. Хатыны әйтте: «Ни кәйфияттә мөгамәлә кыйлды?» — диде. Әвәс әйтте: «Кызымны тәзәүвеҗ касды белән килептер», — диде. Дәхи зәүҗәсе әйтте: «Кызларыңны шулай бер дә бирмәссеңме?» — диде. Әвәс әйтте: «Бәли, бирермен, ләкин Хариска бирмәдем», — диде. Хатыны әйтте: «Бу гарәпнең сәеденә бирмәгәч, кемгә бирерсең?», — диде. Аннан соң Әвәс хафа булып үкенде. Зәүҗәсе әйтте: «Харисны чакырып кайтар, хата кыйлдым дип, гозер ит», — диде. Әвәс әйтте:«Харисны билә наөмид кайтарып җибәрдем, инде ни йөзем белән чакырып кайтараем?», — диде. Хатыны әйтте: «Йортымда бер эш өчен ачуым хәлендә миңа тап булдыңыз, ни әйткәнемне үзем дә белмәдем, хатамны гафу итеңез, фәкыйрь ханәмезгә тәшриф боерыңыз. Һәрни теләк вә мәхәббәтеңез бар исә, әзербез, дип ялвар, чакырып кайтар», — дип, мәслихәтамиз сүзләр белән хатыны, мәгъкульчә үгрәтеп, Харисның артыннан җибәрде.

Харисның юлдашы Хариҗә бин Синан димештер ки: «Без Әвәс өеннән юлга төшеп кайтып барган заманымызда өмидсезлегемезгә кайгырып сөйләшеп барыр идек, артымыздан «йа Харис, ханәмезгә кайт» дигән тавышны ишеттек. Артымызга әйләнеп карадык, Әвәс күренде. Туктадык, Әвәс килеп җитте. «Боерыңыз», — дип, теләгебезне үтәргә ышандырып, безне мөсафирханәсенә китерде. Аннан соң зәүҗәсе янына китеп: «Тиз заман олуг кызымызны китер», — диде. Олуг кызын китерделәр. Әвәс әйтте: «Әй кызым, ошбу Харис бин Гауф гарәп сәедләреннән бер сәедтер, сине аңа кияүгә бирергә касдым бар, разыймысың?» — диде. Кызы әйтте: «Юк, иргә бирмә». Атасы: «Ни өчен кире кагасың?» — дигәч, кызы әйтте: «Әй ата, мин яратылыштан кимчелекле, телемдә тупас сүзле булган җариямен. Ерак җирдер, мине әллә яратыр, әллә яратмас. Харис чит күргән эш миннән садир булса, ни булыр? дип имин түгелмен. Бәс, табигатемдә булган кимчелекләр аркасында Хариска килешмәслек нәрсә садир булганда, мине шунда ук талак итәр. Бу миңа халык арасында намус булыр», — дип, борчылуларын белдергәч, Әвәс дәхи: «Алаймы? Бәрәкаллаһ», — дип, уртанчы кызын чакырып китерде. Аңа дәхи баягы сүзләрне гарыз кыйлды. Ул һәм нәкъ шул олуг кызы кебек җавап бирде. Аннан соң

һәнисә исемле кече кызын чакырды вә Харисның яучылавын белдерде. Кече кызы: «Син вә Харис үзегез белерсез», — дип, үз теләген бәреп әйтмәстән ишарәт белән аңлатып ризалык күрсәтте. Әвәс әйтте: «Әй һәнисә, мин бу яучылауны һәмширәләреңә һәм тәкъдим итмеш идем, кире кактылар, син разый булдың», — дип, сәбәбен сөаль кыйлды. һәнисә гүя һәмширәләренең[1] җавабын ишеткән кебек, хәрефе белән кабатлады: «Ләкин мин ант итәрмен ки, йөзе күркәм, холкы затлы вә фикере хуб мәхбүбмән. Ошбу сыйфатлар белән сыйфатлы булмаклыгым сәбәпле, Харис миңа мәхәббәт итеп, мине куймас. Әгәр талак итсә, үзенең холыксызлыгыннан вә кадер белмәгәнлегеннән талак иткәне халык арасында мәгълүм булмакы мөкаррәрдер. Бу җәһәттән миңа намус булыр дип мин мәлүл булмаймын[2]. Ул чак Харис үзе хур булыр вә Аллаһы Тәгалә аңа гыйваз[3] бирмәс, ягъни минем кебек сәраш таба алмас, пөшиман булыр вә җәзасын табар», — дип, сүзен тәмам кыйлгач, атасы аңа дога кыйлып, янымызга килде. Әйтте: «Әй Харис, һәнисә исемле кызымны сиңа тәзәүвеҗ иттем вә һәнисә дәхи кабул итте, вә шәһадәт кыйлды вә зөфафханә хәзерләп, әнваг зиннәт белән мөзәййән һәнисәне дәхи зөфафханәгә китерделәр». Рәваи әйтте: «Кайчан ки һәнисне чадырында Хариска очраштырдылар, Харис бик аз вакыт торып, кияү келәтеннән минем яныма килде. Мин гаҗәпләнүемне белдергәндә, ул дәхи чәчәк ачылмыйча калып, һаман күңеле хуш булмаганын бәян итте. «Кичектерүгә сәбәп нидер?» — дип сөаль кыйлдым. Әйтте: «Әй борадәр, кайчан ки дәртем дөрләп, мәхәббәт кулымны сузгач, кәләшем: «Мәхәббәт зәүкы — ата каршында һәм кыз туганнар янында була торган эш түгелдер», — дип, минем белән кавышуны кайткач, зөфаф кичәсенә калдыруымны илтәмас итте», — диде. Моны каенатасына дәхи белдереп, һәнисәне килен түшәгенә утыртып, ватанына юл алды.

Бераз киткәннән соң, Харис сабыр итә алмаенча: «Син аз гына монда тор», — дип, мине юлда калдырып, һәнисәнең олавын юлдан күренмәслек җиргә алып китте. Анда да күп тормады, янә килде. «Канәгатьләндеңме?» — дидем. «Юк», — диде. Сәбәбен сорадым. Харис әйтте: «Кавыштыру турында ялварганымнан: «Син миңа әсир җариягә иткән мөгамәлә кебек мөгамәләнеме итәрсең? Бу һәм булыр эш түгелдер! Куйлар суеп, гарәпнең олугларын дәгъвәт кыйлып вә олуг туй уеннары тәртип кыйлып, минем белән синең кебек асыл задәләр гадәте үтәлмәстән торып висал мөхалдер», — дип җавап бирде. Мин дәхи: «Син хак», — дип, һиммәт вә гакылын икърар иттем.

---

[1] һәмширәләреңә — апаларыңа, кыз туганнарыңа.
[2] Мәлүл булмаймын — борчылмыйм.
[3] Гыйваз — тин, алмаш нәрсә.

«Иншаллаһ, син миңа мөбарәк сердәш булырсың, дип дога иттем», — диде.

Аннан соң шәһәремезгә кайтып киттек. Дәрхаль Харис бер олуг бүлмәне бизәтте вә зөфафханәгә керде. Вә янә шунда ук кире чыкты. Янә тиз чыкмакының хикмәтен сорадым. Харис әйтте: «Һәнисәнең янына кереп, син теләгәнне эшләдем — зур мәҗлес ясарга боердым дип, яшерен мөгамәләне ижра кыйлаем, дип рөхсәт сорадым. Янә кәләшем әйтте: «Син тик үзеңдә булмаган шәрәф белән генә мәшгуль имешсең», — диде. Мин әйттем: «Бу сүзне нидән әйтәсең?» — дидем. Әйтте: «Әнә гарәпләр арасында үтерешүләр бара. Вә берен-бере үтереп вә юкка чыгарып торырлар, имеш. Бу фитнәләр вакытында шәрәф белән мәшһүр булган ирләр хатыннар белән мәшгуль булырмы?» — диде. Мин әйттем: «Әй хатыннарның асылы, бу хосуста нинди адым боерырсың?» — дидем. Әйтте: «Аларны килештер. Висал монда торып торыр», — диде. Мин дәхи: «Яхшы, шулай булсын», — дидем. Шул сәгать чыктык, барып мөкатәлә кыйлгучыларны ислах кыйлдык. Дәйиннәрне[1] түләтеп, үтерелгәннең варисларын разый кыйлдырдык. Мәдех вә сәна алып кайттык. Аннан соң Харис висалханәгә саф калеб белән кереп, морадына васыйл булды. Күп заман хуш тереклек белән әүкат кичереп, Һәнисәдән ничә ир бала, ничә кыз бала әүладләре булды».

---

Хәжҗаж урынбасары Хәким бин Әюб дигән кемсәнәгә хат язды: «Габделмәлик бин Хәжҗажга җефетләнмәк өчен ратылышта вә сыйфатта вә холыкта гүзәл йөзле һәм татлы телле бер гүзәл кыз эзләп тап ки, кавеме эчендә кадерле, үзенә хөрмәтле вә зәүҗенә яр муафыйк булгудай кыз булсын. Табып безгә хәбәр күндер», — диде. Бәс, Хәким: «Ул сыйфатта булган бер кызны табып куйдым, ләкин имчәкләре бик зур, кяшки шул җитешсезлеге булмаса, бик әгъля кыз иде», — дип, имчәк зурлыгын гаептән саеп, Хәжҗажга җавап күндерде. Хәжҗаж аңа язды: «Хатыннарның имчәкләре зур булмаенча, хөсне кямил булмас. Зур имчәк һәм фирашны[2] җылытыр, баласын сөткә туйдырыр, бер дә гаеп димәңез. Зур имчәкнең файдасы күп аның», — дип ризалык күрсәтте.

---

Габделмәлик бин Мәрван гатафан кабиләсеннән бер балигъ вә тәҗрибәле адәмгә әйтте: «Хатыннарның әхсәне вә гүзәлрәге ни сыйфаттадыр? Миңа бәян кыйлсана», — диде. Ул кеше җавап бирде: «Әй әмирел-мөэминин, тыңлап тор, мин сиңа хатыннарның мәкъбуль сыйфатларын бәян кыйлаем. Син ал шул

[1] Дәйиннәрне — бирегә: штрафларны, хакын.
[2] Фирашны — урынны, ятакны.

хатынны ки, аяклары итләч булып, мәхруты кәйфиятендә булсын. Тубыклары ит белән өретелмеш булып, сөякләре билгереп тормасын. Вә балтырлары итле булып, йомшак булсын, тез капкачлары итле булсын. Ботлары бер-беренә тоташ кыяфәттә булсын. Беләкләре симез вә юан булсын. Учлары киң булсын. Имчәкләре утырып торсын. Яңаклары ал, кызыл булсын. Күзләре тугмышыннан сөрмәле булсын. Кашлары нечкә булсын. Борынының өсте кәкре булмайрак тигез булсын. Тешләре ак вә рәүшан булсын. Вә авызы татлы булсын. Чәчләре бик кара булсын. Муены мөлаем вә йомшак булсын. Корсак итләре хәдде игътидалда булсын. Иреннәренең кызыллыгы уртача вә ике каш арасы ачык булсын», — диде. Габделмәлик әйтте: «Ай-һай, бу сыйфатта булган хатынны кайдан табарсың? Моның кебек сирәк очрый торган энҗе кем кулына керер?» — диде. Ул кеше әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, бу сыйфатта булган гүзәл хатыннарны халис[1] гарәп эченнән вә халис фарси эченнән тапмак мөмкиндер», — дип, сүзен тәмам кыйлды.

———

Гакыл ияләреннән бер кемсәнә өйләнмәк касдында булып, хатыйбына, ягъни яучысына әйтте: «Минем өчен шундаен бер кыз табып бир ки, күршеләренә кермәй вә күршеләрен үзенә кертмәй торган кыз булсын, ягъни пәрдә эчендә тәрбияләнеп, асла кеше белән катышкан булмасын, вә сәйрангяһ[2] җирләргә чыгып йөри торган булмасын, вә кызлар мәҗлесе дигән мәҗлесләргә дә йөргән кыз булмасын», — дип, ул яучыга тапшырды.

———

Гыймран бин Хәттан исемле кемсәнә үзе кабахәт вә иләмсез сыйфатта бер кеше иде. Әмма гаять гүзәл хатыны бар иде. Көннәрдән бер көн хатыны әйтте: «Иншаллаһ, без икемез дә оҗмахта булырмыз», — диде. Гыймран әйтте: «Бу сүзне нидән әйтәсең?» Хатыны әйтте: «Синең иләмсезлегеңә мин сабыр итәмен. Син минем гүзәллегемә шөкер кыйласың. Шөкер кыйлгучылар вә һәм сабыр кыйлгучылар оҗмахта булырлар», — дип Аллаһы Тәгалә хәбәр бирмештер.

———

Бер кемсәнә Өмме Әяс исемле хатынны тәзәүвеҗ кыйлмак өчен, гакыйлә вә әдәп иясе Гыйзам исемле хатынны яучы итеп күндерде. Ошбу яучы әүвәл Өмме Әяснең анасына барып, үзенең ни мәслихәт белән килгәнен бәян кыйлды. Өмме Әяснең анасы Әмамә исемле иде. Бу Әмамә дәхи кызының янына барып: «Әй кызым, ошбу хатын минем каршымда һәмширәм кебектер вә мөгътәбәр бер хатындыр ки, синең сыйфат вә әхвәлеңә карап, сине сынамак өчен килмештер. Караем дигән жи-

---

[1] Халис — саф, чиста.
[2] Сәйрангяһ — күңел ачу урыны.

реңне һәммәсен карасын, яшермә вә тартынма, күрсәт, сөйләш, оялып торма», — диде.

Бәс, ул яучы Өмме Әяснең янына кереп, тәмам тәфтиш кыйлып белгәннән соң, җиһан күзе күрмәгән җәмигъ камаләтне Өмме Әяста күреп, дәрхаль ул кемсәнәгә хәбәр бирмәк өчен кайтып, Өмме Әясны тәгъриф кыйла башлап әйтте. «Ул Өмме Әяста күргән сыйфатларны, бер дә арттырмай, киметмәй, хак вә тугырысыны сиңа хәбәр бирәем ки: мөҗәллә[1] көзге кебек, маңгай өстендә ялтыраган кара сачы кола атның койрыгы шикелле тулы вә озын, үзенә зиннәт бирмештер. Вә ошбу сыйфат белән мәүсуф маңгаенда дәхи ике кара кашы бардыр ки, бер үлчәүдә вә бер кәйфияттә бер-беренә бәрабәр каләм белән язылмыш, гүяки арысланны атарга корылмыш җәя кебек кәкрәеп төшкән. Кашларының уртасында мөсай[2] кылыч шикелле урта зурлыкта вә тигез борыны бар. Вә дәхи халис ак йөзендә алсу чәчәге шикелле вә җәнәләре ал иннек рәнгендә[3] кызыл вә бу сыйфатта булган ак йөзендә шәкъ ярылган, вә язылмыш йөзек балдагы микъдарында вә арасыннан саф ак энҗе шикелле тешләре зохур итеп көлемсерәп торган авызы бар. Вә авызы эчендә дәхи могътәдил дип кәйфияттә мөнтәзыйм саф энҗе кебек тешләре бар. Вә ул тешләренең арасыннан чыккан сулышы сәхәр вакытында чәчәк тарафыннан искән хуш саба җиле кебек нәфис. Синең борыныңа ирешер. Вә шундаен авыздыр ки, аның эчендә фәсахәт вә бәян иясе тел бардыр ки, ул телне кәмаль гакыл иясе вә җавап хәзер тәкаллеб итәр. Вә ул авызның янында дәхи каймак шикелле мөлаем татлы ике ирен берберенә тиеп торыр, гончә кебек. Алып имсәң, авызыңа бал агар. Вә иреннәре астында көмеш сагыр сыйфатында күкрәктән югары ике иң баш арасында ак вә бәррак[4] муен ки, аңа мөттәсыйл дәхи ике сагыйдләре вә беләкләре. Сөякләре нечкә, тамырлары йомшак вә җефәктән мөлаем бармаклары буыннары батып торыр. Фөсус җәваһир кебек тырнаклары. Вә күкрәгендә ике анар[5] кебек ике имчәк дидекләре утырып торыр. Хакъкәләренең астында нәфис ак җефәктән тукылмыш комаш кебек мөлаем корсактыр. Вә ак фил тешеннән мәснуг[6] гөл мае савыты кебек нафәсе. Янә корсагы артында аркасы бардыр ки, чокыры бер нәһер һәмвар шикелле нечкә биленә ирешер. Аннан түбән талаг нәфидкә охшаган ике сагыйре ки, аңа ике бот тоташмыштыр. Вә аларны ләтыйф ике аяк күтәрер. Аякның билә кечкенәлеге белән ул бәдәнне күтәреп тормакы кодрәтуллаһ-

[1] Мөҗәллә — ялтыр-йолтыр килүче.
[2] Мөсай — ялтыраткан.
[3] Рәнгендә — төсендә.
[4] Бәррак — балкып торучы.
[5] Анар — гранат җимеше.
[6] Мәснуг — ясалган.

тыр. Санаигъ бәдигъ кодрәтуллаһ. Бу мәзкүр әүсафтан башкаларының вәсыйфе бу әдәп җирендә тасрих кыйлыныр нәрсә түгелдер», — дип, ул яучы Өмме Әяснын кыяфәтен бәян кыйлып тәмам иткәннән соң, ул кемсәнә Өмме Әяснын атасына яучы өчен бер могтәбәр адәмне җибәреп, гакыд мәслихәте тәмам булганнан соң, олуг вәлимә[1] тәртип кыйлып зөфаф кыйлды.

———

Бәгъзе шагыйрьләр, хатынынан бизар булып, хатынын зәм[2] кыйлмыштыр, ягъни яман хатынның такатьтән тыш вә газап кибаргә мәхсүб булган әхвәле сәбәпле үлеменә мохтаҗ булып, әҗәлен теләмәкем мөхаккак булса да, үлми ләбаса. Тиз үк үлсә иде дә, мин котылыр идем вә ул, дәхи тиешле булган газабын кабердә күреп, Мөнкир, Нәкир аталган газап фәрештәләре аны газап кыйлсын иде, димәктер.

———

Гарәп эчендә Өмме Хәбиб исемле бер яман хатын бар, имеш. Аның хакында берәү: «Кабергә кермәдән әүвәл терек хәлендә үлемне теләсә, Өмме Хәбибне тәзәүвеж итсен», — димештер.

———

Бер балыкчы, гаҗәп сыйфатта бер балык тотып, Хөсрәү Пәрвизгә китерде. Пәрвиз балыкның хөснен[3] вә сыйфатын яратып, балыкчыга дүрт мең дирһәм биреп, балыкны алды, Ширингә һәдия кыйлды. Ширин дәхи, балыкны мактап, Пәрвизгә әйтте: «Әгәр ул балыкчы икенче мәртәбә балык китерсә, әүвәлге балыгың ата балык идеме, ана балык идеме? дип сөаль кыйлынсын. Ата дисә — ананы, ана дисә — атаны китер, дип әмер кыйлынсын», — диде.

Күп заман үтмәде, балыкчы янә бер нәфис балык китерде. Шириннең әмеренчә, балыкчыдан сөаль кыйлгач, ахырында ни сүз буласын белмәенчә, ул балык ана иде, диде. «Алайса, ата балыгын китер», — диделәр. Балыкчы кыйссаны сизеп, тапкырлыгы белән: «Әй мәлик, гомерең озын булсын, ул балык гәрчә ана балык булса да, һәнүз издиваҗы[4] юк, үзе ата хөкемендәдер», — дигәч, Пәрвиз дәхи балыкчының бу җавабына тәхсин кыйлып, сигез мең дирһәм янә биреп җибәрде. Вә әйтте: «Хатынга итагать кыйлмак алданмакны вә зәхмәтне ирас итәр[5] дип хикмәткә языңыз», — диде.

———

Әмирләрдән бер әмиргә бер кемсәнә мәзәк сүзләр әйтешү тарикынча: «Әй әмир, бервакытны зәүҗемә барып килеп гамәл кыйлганда, үтерден, һай мәдәд, үтерден, дип кычкыра», — дип

---

[1] Вәлимә — туй, мәҗлес.
[2] Зәм — шелтә.
[3] Хөснен — матурлыгын.
[4] Издиваҗы — пары.
[5] Ирас итәр — китереп чыгарыр.

хикәят иткәч, әмир әйтте: «Үтер аны шул үтерү белән, җавабын мин бирермен», — диде.

Хатыныннан хушнуд вә хатыны дәхи разый булган хәлдә, батәкъдире Хода, араларында аерылышу вакыйг булып, хатыны үзенә тиешле нәрсәсен алып киткәндә, ире әйтте: «Әй мине ялгыз калдыргучы хатын, ишет: валлаһи, ир вә хатын булып торган вакытымызда сиңа дәрт белән, ышану вә мәхәббәт белән ышанып яшәп, синнән асла җәфа вә хурлык күрмәгән идем. Вә синең тарафыңнан миңа асла күңел тую килмәгән иде. Ләкин Хак Тәгаләнең тәкъдире вә хөкеме өстендер, тәкъдир буенча гәрчә аерсам да, синнән хушнудмын», — дигәннән соң, хатын дәхи шунда ук: «Бәли, моннан соң Аллаһы Тәгалә сиңа да хәерле бәндәсен тап итсен, мин дәхи тәхте никяхында хатын булган мөддәтемдә, синең лотыф вә ихсаныңны азга саймаган идем. Вә синең җәбереңнән шикаять кыйлмаган идем, ягъни асла җәбереңне күрмәдем. Вә мәхәббәтемне сиңа гына касыр итеп, киметеп, синнән гайрене, һай, минем ирем бу булса, иде дип, күңелемнән теләмәдем. Вә ирләр эчендә сиңа охшаш кеше юк, дип, минем каршымда синнән әгъля ир юк иде. Ләкин Хода тәкъдире билә булгач, бозар хәл юк», — дип, ир хатын бер-береннән шөкер вә ризалык үзрә видаг итмешләрдер.

---

Бер хатын үзенең кызын кияүгә биргәндә, билә нәсыйхәт кыйлмыштыр: «Әй кызым, иреңә кәнизәк бул, ул сиңа кол булыр. Дәхи ошбу ун төрле нәсыйхәтемне ишетеп, хәтереңдә тот: әүвәлан — ирең белән күркәм әңгәмә кыйл, зирә күркәм әңгәмә кыйлмакта күңел тынычлыгы бардыр. Икенчедән — күркәм яшә, итагать белән күркәм яшәүдә Аллаһы Тәгаләнең ризалыгы бардыр. Өченчедән — кабахәт эшеңә иреңнең күзе төшмәсен, саклан. Дүртенчедән — синнән кабахәт ис килмәсен. Бишенчедән — малын сакла, күркәм тәдбир кыйл. Алтынчыдан — хезмәтчеләрен ригая кыйл. Җиденчедән — тәгам вакытын сакла. Чөнки бәгъзе вакытта ачлык хәрарәте ялкынланадыр. Сигезенчедән — ул йоклаган вакытта тавыш итмә, чөнки кешенең йокысы бүленсә, ачуы кабарадыр. Тугызынчыдан — серен фаш итмә. Унынчыдан — әмерендә гыйсъян кыйлма, ягъни бер эш әмер итсә, баш өсте, дип, әда кыйл, чөнки серен фаш кыйлсаң, мәкереннән имин булмассың. Вә әмеренә гыйсъян кыйлсаң, күкрәген кыздырырсың, ягъни ачигъландырырсың», — диде. Кызы әйтте: «Әй аначыгым, бу нәсыйхәтләреңне баш өсте дип, кабул иттем», — диде.

---

Берәү хатынына әйтте: «Аллаһы Тәгалә минем каршымда синнән сәвекле нәрсә яратмады», — диде. Хатыны әйтте: «Аллаһы Тәгалә минем каршымда синнән сөйкемсезне яратмады», — диде. Ире әйтте: «Әлхәмделиллаһ, Аллаһы Тәгалә миңа сәүгәнемне бирде, сине сәүмәгәнең белән мөбтәля кыйлды», — диде.

———

Борынгыларның берсе әшәке хатын алды. Хатынына әйтте: «Үз морадымча, сине нәфис киемнәр белән киендерәемме? Яки үз морадыңча, чыгып йөримесең?» — диде. Хатыны киемгә разый булмады, чыгып йөрмәкне ихтыяр кыйлды. Ире бик начар кием алып бирде. Хатын әйтте: «Бәрәкаллаһ, мине бу фаҗирәлектән коткардың», — дип, ире алдында тәүбә итте.

———

Искәндәргә әйттелләр: «Мәмләкәтеңне киңәйт. Хатынны күп ал, балаларың күп булыр», — диделәр. Искәндәр әйтте: «Ирләргә галиб була торган кешегә хатыннарга мәгълүб булмак күркәм эш түгелдер», — диде.

———

Бервакытны Һарун әр-Рәшит Зөбәйдә яныннан көлеп чыкты. Әйттеләр: «Йә әмирел-мөэминин, ни-нәрсәгә көлдеңез?» — диделәр. Әйтте: «Мисырдан өч йөз мең алтын килде. Һәммәсен Зөбәйдәгә бүләк кыйлдым, яныннан да китмәгән идем, синнән ни хәер күргәнем бар, дип, мине орышадыр», — диде.

———

Һарун әр-Рәшит Сорур исемле җариясенә әйтте: «Йә Сорур, хатыннар ярата торган нәрсә ирләрдә ни-нәрсәдер?» — диде. Сорур әйтте: «Суының кайнарлыгы, баһның[1] кувәте, авыз исенең хушлыгы», — диде.

———

Бер җариягә әйттеләр: «Йә фәләнә, син бакирәме[2]?» — диделәр. Әйтте: «Булганым бар иде, Аллаһы Тәгалә коткарды»,— диде.

———

Бер кеше Хәсән бин Гали разыйаллаһу ганһуга килеп киңәш итте: «Бер кызым бар, кемгә бирәем икән?», — диде. Хәсән әйтте: «Берәүгә бир, әмма Аллаһы Тәгаләдән курыккан изге кешегә бир. Изге кеше мәхәббәт итсә — хөрмәт итәр, мәхәббәте булмаса — золым итмәс», — диде.

———

Бер хатын иренә әйтте: «Әй дәйюс[3], әй мөфлис[4]», — диде. Ул кеше әйтте: «Әлхәмделиллаһ, минем гөнаһым юк, имеш. Әүвәлгесе — синнән. Икенчесе — Аллаһы Тәгаләдән», — диде.

———

Берәү бер кешенең углына бөти яза: «Анасы ни исемле?» — диде. Ул кеше әйтте: «Гаҗәп, атасының исемен сорамадың», — диде. Ул әйтте: «Чөнки анасында шөбһә юк», — диде. Ул кеше

---

[1] Баһның — шаһвәтнең, җенси дәртнең.
[2] Бакирәме — гыйффәтле кызмы.
[3] Дәйюс — намуссыз, түбән.
[4] Мөфлис — бөлгән.

әйтте: «Яз, әгәр минем углым булса — шифа булсын, булмаса — булмасын», — диде.

———

Имам Кәсаига: «Ник өйләнмәйсең?» — дип шелтә кыйлдылар. Әйтте: «Шул гыйффәтем белән мәшәкать чигеп тормакым хатын алып хатын мәслихәте артыннан йөрмәкемнән ансатрактыр», — диде.

———

Шәгъбидән сорадылар: «Иблиснең хатыны ни атлы?» — диделәр. Шәгъби әйтте: «Белмим, мин никях мәҗлесендә юк идем», — диде.

———

Бер мөгаллим бер хатынга яучы җибәрде. Хатынның углы мөгаллим янында иде, хатын кабул итмәде. Бервакытны мөгаллим бу хатынның баласын сукты. «Ник әйтмәдең анаңа, хәлфәнең аләте бик зур дип?!» — диде. Бәс, ул бала анасына килеп: «Хәлфә шулай дип әйтә, — диде, — мине кыйнады», — дип егълады. Аннан соң хатын, бу сүзне күңеленә салып йөреп, бер заманнан соң ул хәлфәгә никяхланды.

———

Берәү бер хатынга яучы җибәрде. Хатын әйтте: «Яхшы, ләкин минем күп шартым бар: мең алтын мәһәр, һәр көнгә нәфәка фәлән кадәр, кием фәләнчә булыр», — диде. Ул кеше әйтте: «Бәли, кабул иттем, ләкин минем гаебем бардыр», — диде. Хатын әйтте: «Ни гаептер?» Ул кеше әйтте: «Мин җимагка бик хирыс, әүвәлгесеннән бушап бетмәс борын, икенчесенә хәзерләнә башлыймын», — диде. Хатын әйтте: «Йа җария, диванадыр бу кеше! Хәзерлә тизрәк туй әсбабын», — дип, җариясенә әмер кыйлды.

———

Ибн Сәбабә карт ак сакаллы кемсәнә иде, аңа әйттеләр: «Хатының сине мәкруһ күрәдер, ак сакаллы карт дип әйтәдер», — диделәр. Ибн Сәбабә әйтте: «Ул мал азлыгыннандыр, сакал аклыгыннан түгелдер, валлаһи. Әгәр дә миндә Нухның картлыгы, иблиснең аклыгы, Мөнкир вә Нәкирнең кыяфәте булып та, байлыгым булса иде. Ул хатын мине җәмалы — Йосыфтан, холкы — Даудтан, сыны — Гайсәдән, юмартлыгы — Хатәмнән, йомшаклыгы — Асафтан артыграк күреп сөяр иде», — диде.

———

Бер кемсәнә бер тәҗрибә әһеленнән кыз-хатынның яшен сорашты. Ул кеше әйтте: «Ун яшәр кыз — кабыгын әрчегән бадамдыр[1], унбиш яшәр кыз — уенчан егетләргә уенчыктыр,

[1] Бадамдыр — миндальдер.

егерме яшәр кыз — ите-тине тулган тыгынчыктыр, утыз яшәр хатын — бала-чага анасы. Кырык яшәр хатын — гаҗүзә карчык, кемгә барасы. Илле яшәр хатынга пычак керсен, алтмыш яшәр хатынга ләгънәт булсын», — диде.

———

Берәү бер хатынны никяхланды. Хатынына әйтте: «Мин явыз холыклымын», — диде. Хатыны әйтте: «Син алган кешенең холкы синнән явыз булмаса, ким булмас, мин шул явыз холыкка мохтаҗ», — диде. Һәм үлгәнче араларында вәхшәт булмады.

———

Әсмәгый әйтте: «Бер кешене күрдем, Бәйтуллаһта бер карт кешене күтәреп, таваф кыйлдыра. Әйттем, бәрәкаллаһ, яхшы эш кыйласың, бу кеше синең атаңмы, бабаңмы, дидем. Ул кеше әйтте, бу минем углымдыр, диде. Әйттем, сөбханаллаһи, бу углың ни сәбәпле билә картлар сыйфатына кермеш, дидем. Ул кеше әйтте: «Явыз холыклы хатыны бардыр, ошбу дәрәҗәгә житкерде, — диде».

———

Берәү бер хатынны никяхлады. Ул хатын никяхтан соң бишенче көнендә бер ир бала тапты. Бу кеше базарга барды, кәгазь, каләм, кара сатып алды. «Бу ни эшкә?» — диделәр. Әйтте: «Биш көннән туган бала, әлбәттә, өч көннән мәктәпкә йөри башлар, углым өчен алдым», — диде.

———

Бер кеше иблисне күрде: дүрт ишәккә зур йөк төяп бара. Ул кеше иблистән сорады: «Кая барасың?» Иблис әйтте: «Сатуга барам». Бу кеше әйтте: «Йөкләреңдә ни-нәрсә бар?» Иблис әйтте: «Берсендә золымлык». «Аны кемгә сатасың?» «Түрәләргә сатам». «Икенче йөгеңдә ни-нәрсә бар?» «Көнчелек». «Аны кемгә сатасың?» «Галимнәргә сатам». «Өченче йөгеңдә ни-нәрсә бар?» «Хыянәт». «Аны кемгә сатасың?» «Байларга сатам». «Дүртенче йөгеңдә ни-нәрсә бар?» «Хәйлә». «Аны кемгә сатасың?» «Хатыннарга сатам», — диде.

———

Бер заманда бер бай кеше бар иде, әмма хатыны бик яман иде. Иренең сүзенә асла колак салмас иде. Һәрни хосуста ире белән кычкырышып торыр иде. Ире һәрни әйтсә, каршы килер иде. Ире һәрни алып бирсә, яратмаенча ыргытып ташлар иде. Бервакытны ире үлеп китте. Акча бетте. Байлык китте. Беркөн бу хатын яланаяк, күлмәкләре ертык, башы ялангач, сачларын туздырып барганда, кадимгә дусларыннан берсе очрады, әйтте: «Әй фәлән, ни хәлең бар?» — диде. Бу хатын әйтте: «Минем ник хәлемне сорыйсың? Башмак кимәс наз идем, чабата тапмай бәрамән», — диде.

———

Бер кеше әйтте: «Әлхәмделиллаһ, минем ишегемнән шайтан кергәне юктыр», — диде. «Алай булса син хатыныңны морҗадан керттеңмени?» — диделәр.

———

Әсфаһан шәһәрендә кызыл мал белән сату итүче Гантәр исемле бер кеше бар иде. Аның гадәте шул иде: ел саен иң әүвәл җиләк җимеш чыккач та, алып кайтып җәмәгатенә авыз иттерә иде. Көннәрдән бер көн яңа карбыз чыккач та: «Карбыз сатып алып, өйгә илтеп бир!» — дип, хезмәтчесенә биреп җибәрде. Кич булгач, Гантәр өенә кайтты, җәмәгате белән утырды. «Кайда, карбызны китерегез, ашаек», — диде. Җәмәгате әйтте: «Без инде ашап бетердек аны», — диде. Гантәр әйтте: «Ашасаңыз зарар юк, кайда, миңа калдыргансыз, китерегез», — диде. Җәмәгате әйтте: «Сиңа калдырырга онытканмыз, юк, бетте», — диде. Гантәр әйтте: «Көн саен бергә ашыймыз, бергә эчәмез, бергә торамыз — мине оныттыңыз! Мин үлгәч ничек булырсыз икән? Минем хәлем ничек булыр икән», — дип, күңеленә үлем куркуы төште. Күңеленнән әйтте: «Мин аларны ашатамын, эчертәмен. Алар өчен, хәлялне-харамны карамаймын, ант итәмен, ялган сөйләшмәймен. Алар мине үлмәс борын оныттылар! Ах, минем хәлем үлгәч ни булыр?!» — диде.

Икенче көн иртә булды. Гантәр базарга чыкты. Бер карбыз сатып алды. Аны үзе өенә алып кайтты, җәмәгате белән карбыз ашарга утырдылар. Гантәр җәмәгате белән ачык йөз белән көлә-көлә сөйләшә: «Менә гаҗәп, кичә сез мине карбызсыз калдырдыңыз. Базарда карбыз бетмәгән, менә бу көн рәхәтләнеп бергә ашыймыз», — диде, әмма күңелендә ни ният барын бер дә белдермәде. Аннан соң хатынына әйтте: «Җаным, сиңа мәхәббәтем бик зур. Көн дә кибеттә, көн дә кибеттә. Һичбер рәхәтләнеп бергә утырып булмай. Шөгылем бик күп. Мин бу көн ишеттем: фәлән кеше җимеш бакчасы сата, имеш. Бакчасы бик зур, бик әйбәт. Әгәр син миңа бар акчаңны бирсәң, вә һәм, алтын-көмештән ни җиһазың булса, сатып, миңа карыз бирсәң[1], аннан соң кибетемне сатармын. Барын бергә кушып, шул акчага ул бакчаны алыр идем. Шул бакчадан килгән файда белән тереклек итәр идек», — диде. Хатын бу хәбәрне ишеткәч, ягъни ашамак, эчмәк вә гыйш-гыйшрәт сүзләрен ишетеп, бик шат булды, әйтте: «Мин карыз бирмим, барча җиһазымны сиңа бүләк кыйлаем», — диде, һәм болар казый хозурына барып язылыштылар.

Бәс, Гантәр кабыз шәргый[2] белән хатыннан җиһазны үзләштерде. Ул җимеш бакчасын егерме меңгә сатып алды. Ан-

---

[1] Карыз бирсәң — әҗәткә бирсәң.

[2] Кабыз шәргый — шәригать хөкеме белән алу.

нан соң базарга чыгып нида кыйлды: «Җимеш агачы кирәк булса, минем бакчамнан һәркем барып кубарып алсын! Мин аны мөселманнарга вәкыф кыйлдым», — диде. Һәммәсе, җимеш агачы кирәк кешеләр барып, агачларны төпләре вә тамырлары белән кубарып алдылар, бары коры җире генә калды. Аннан соң Гантәр казыйга барып әйтте: «Ул бакча урынын мин мөселманнарга каберлеккә һибә кыйлдым, ул җир каберстан булсын», — диде. Һәнүз бу көндә дә «Гантәр мәкъбәрәсе» дип мәгълүмдер. Хатын, бу хәбәрне ишеткәч, шикаять кыйлды, егълады, иренә әйтте: «Нигә миңа золымлык кыйлдың?» — диде. Гантәр әйтте: «Мин сиңа золымлык кыйлмадым, ләкин син үлгәч мине онытырсың дип курыктым. Чөнки мин терек вакытта, карбыз ашаганда оныттың. Мин үлгәч, кайчан син мине искә төшерерсең?» — диде.

Аннан соң бер ел үтмәде, Гантәр вафат булды. Бәгъзе дуслары Гантәрне төшендә күрде: оҗмахта, киңлеге мең фәрсәх бер сарай эчендә, сөттән, балдан, зәнҗәбилдән, сәлсәбилдән[1] чишмәләре агып торыр. «Ни сәбәпле бу кадәр дәрәҗәгә ирештең?» — дип сорады. Гантәр әйтте: «Дөньядагы бакчамны каберлеккә вәкыф кыйлмыш идем, шул сәбәпле Аллаһы Тәгалә бу дәрәҗәләрне миңа рузи кыйлды», — диде.

---

Габделмәлик бин Мәрван Әхтылга әйтте: «Син ни кыйласың хәмер белән? Эчүнең әүвәлгесе авыру, ахыры махмырлык», — диде. Ул әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, бу икесе арасында бер халәт бар, синең бөтен мәмләкәтеңә бирмәймен», — диде.

---

Берәү бер кешене күрде: бик эче катып көлә. «Ник көләсең?» — диде. Әйтте: «Бер исерек узып китте. Безгә сәлам бирде, сәламен алмадык. Утырды да безнең уртамызда бәвел кыйла башлады. «Ни эшлисең?», — дидек. «Бак, әле монда кеше бармыни, мин кеше юк дип торамын», — диде».

---

Берәү исереп егылган, косып ята. Бер эт килде дә авызын ялый башлады. Исерек әйтте: «Бәрәкаллаһ, авызымны яулык белән сөртәсең, имеш», — диде. Моннан соң эт битенә бәвел итә башлады. Исерек әйтте: «Аллаһының рәхмәте төшсен сиңа, яулык белән авызымны сөрттең, инде йөземне җылы су белән юасың, имеш», — диде.

---

Берәү бер җиргә барган икән, анда эчеп исереп кайтканда, атыннан егылып, бер чокырга тугыры килеп, чокырга тәгәрәп төшкән, имеш. Юлдагы кешеләр: «Бу ат иясе кайда икән?» — дип килеп карасалар, күрделәр: бу кеше чокырда ята. Ул исе-

[1] Сәлсәбилдән — бик тәмле судан.

рек, боларны күргәч, башын күтәреп карады да: «Йа Аллаһы, сөбханаллаһи, чокыр», — диде.

Бервакытны Мәһди хәлифә ауга чыкты. Бер җирдә юлдашларыннан аерылып калды. Бер әгърабиның йортына керде. Әгъраби аны ашатты, эчертте. Бер җам хәмер китерде. Мәһди эчте, әйтте: «Мин кем, мине таныймысың?» — диде. Әгъраби әйтте: «Юк, танымаймын». Әйтте: «Мин хасларның хезмәтчесемен», — диде. Әгъраби әйтте: «Бәрәкаллаһ, яхшы урында икәнсең», — диде. Янә бер җам хәмер эчертте. Мәһди әйтте: «Мин кем, мине таныймысың?» — диде. Әгъраби әйтте: «Кем икәнеңне әүвәл дә әйткән идең», — диде. Мәһди әйтте: «Юк, мин ул кеше түгел, бәлки мин гаскәрләр башлыгы», — диде. Әгъраби әйтте: «Бәрәкаллаһ, гаскәрең тыныч булсын, морадың хасыйл булсын!» — диде. Янә бер җам эчертте. Мәһди әйтте: «Мин кем?» Әгъраби әйтте: «Әйткән идең», — диде. Мәһди әйтте: «Юк, валлаһи, мин әмирел-мөэминин», — диде. Аннан соң әгъраби хәмер савытының бөкесен тыкты, әйтте: «Әгәр сиңа тагын дүртенчене эчертсәм, мин — Рәсүлуллаһ, дип әйтерсең», — диде. Мәһди көлде. Ул арада Мәһдинең вәзир-вөзарасы да килеп җитте. Әгъраби бик курыкты. Мәһди әйтте: «Зарар юк, бер дә курыкма», — дип, күп бүләкләр биреп китте.

---

Бер кеше хәзрәти Галинең савытыннан хәмер эчте. Исерде. Хәзрәте Гали аны җәзалап суктырды. Ул кеше әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, мин синең эчемлегеңне эчтем», — диде. Хәзрәте Гали әйтте: «Мин сине эчемлек өчен сукмадым, исергәнең өчен суктым», — диде.

---

Берәүгә әйттеләр: «Нихәл? Син эчәсеңме?» — диделәр. Ул кеше әйтте: «Юк, мин хәмернең янында торсам да, бер ай исерек булып йөримен», — диде.

---

Беркөн бер гарәп бер таифә төркем изгеләр мәҗлесенә керде. Ул кавем кич уяу торып, төнлә кыйлган намазның савабына кагылышлы сүзләр сөйләшеп утырырлар иде. Берсе бу гарәпкә әйтте: «Әй гарәп, син һәм кичәләрдә уяу торамысың?» — диде. Гарәп әйтте: «Бәли, һәр кичне ике-өч мәртәбә бәвел итәргә чыгамын да кереп ятамын», — диде.

---

Бер хатын бер мулладан ишетте, мулла вәгазь әйтә: «Берәү гашүрә көнендә руза тотса, бер еллык гөнаһына кәффарәт булыр», — диде. Бу хатын әйтте: «Тукта, бу бик яхшы эш икән, бер көн руза тотаемчы дип ният итте, сәхәр ашады, ярты көн руза тотты да карыны ачты. — Әйтте: — Инде миңа алты айлык гөнаһыма кәффарәт булса да җитәр», — диде, ашады.

———

Берәү үзенең бер дустына кашсыз йөзек бүләк җибәрде. Ул кеше йөзекне алды, әйтте: «Рәхмәт, Аллаһы Тәгалә аңа оҗмахта түбәсен япмаган сарайлар бирсен», — диде.

———

Берәүнең кызына яучы килде. Кызның атасы бирмәкче булды. Никях мәҗлесендә кызның атасыннан сорадылар: «Әй фәлән, кызың ничә яшьтә, кайчан туган иде?» — диделәр. Ул кеше әйтте: «Мин белмим, анасы әйтә торган иде, урак беткән көнне туды, дип», — диде.

———

Бер кеше рамазан аенда рузасын ачты: он базына төште дә икмәк ашый башлады. Аны углы күрде дә кычкырды: «Анда кем бар?» — диде. Атасы әйтте: «Кычкырма, кычкырма, атаң фасыйк үз икмәген үзе угырлап ашап утыра, Ходайдан курыкмай, адәмнән курка», — диде.

———

Берәү әйтте: «Бервакытны атым чыгып киткән иде, атымны эзләргә чыктым. Бик суык көн иде. Бер өйгә барып кердем. Җәмәгать белән намаз укып торалар. Араларында бер карт бар, күлмәкчән, аяклары ялангач, үзе туңган, дер-дер калтырый, әйтә: «Йа Рабби, бу суык үзәгемә үтте, намаз укырга кушасың, кием бирмәйсең. Әгәр мин тәмуглык булсам, хәзер керт мине тәмугка, ичмасам, җылыныр идем», — диде. Берәү әйтте: «Әй баба, намазың бозылды, намаз эчендә сөйләштең», — диде. Карт һаман әйтә: «Йа Рабби, кием бирсәң, бөтен гомер буе намаз укыр идем», — диде. Өстенә берәү кием китереп кидерде, ләкин кыска, картның гаүрәтен дә капламады. Утырып укый башлады. Һаман әйтә: «Йа Рабби, бу утырып укыган намазым өчен гозерем бар, кыйблага карап укыйм — таһарәтсез, салкын су белән таһарәт алыр хәлем юк, үзең кабул ит», — диде.

———

Ибн әл-Хатыйб димештер ки: «Җаһилият заманында хәмернең хөрмәтенә нәсс[1] килмәстән мөкаддәм хәмернең кабахәтеннән бизар булып, хәмер эчүне соңыннан ташлаган кемсәнәләрдән бере — Корәеш олугларыннан Габдулла бин Җәдган Әмия бин әс-Салат әс-Сакфи белән мәҗлес ясап, хәмернең көче күңеленә ашкач, бер ачу белән Әмиянең күзенә сукты. Күзеннән кан китеп: «Ахры, күзсез каламын», — дип, хәвефе белән һаман күзен сөртеп утырды. Иртәсе көн ибн Җәдган Әмияне күргәч, кичәдә үзенең исереклек белән ни кыйлганын белмәгәнлектән: «Күзеңә ни булды?» — дип сорады. Әмия сөкүт кыйлды, әйтмәде. Янә сорады. Ахыр бик үтенгәч: «Кичә син суккан идең түгелме?» — диде. Бин Җәдган әйтте:

---

[1] Нәсс — хөкем, анык дәлил (хәдистә).

«Әстәгъфируллаһи, мин шул дәрәҗәгә кадәр эчеп исердемме? Моннан соң хәмер эчмәмен, хәмер миңа харам булсын», — дип тәкъвалык кыйлды вә Әмиягә ун мең дирһәм бүләк кыйлды.

———

Вә дәхи бере Кайс бин Гасыймдыр. Аның сәбәбе шөйлә булмыштыр. Бер кичә зиядә исерек булмак белән, үзенең кызына мәвакыйга эстәп, кызы моны сизгәч, качты. Иртәсе көн айнып кызын күрмәгәч: «Кызым кайда?» — дип сорады. Әйттеләр: «Син кичә ни эшләгәнеңне беләсеңме?» — дип, вакыйганы сөйләделәр. Аннан соң: «Бу хәмерне эчмәмен!» — дип, гаһед кыйлды.

———

Дәхи Габбас бин Мәрдас дигән кемсәнә, бер кичә ай яктысында нөзһәтгяһкә[1] чыгып, кәеф-сафада сәрхуш булмак белән ямин[2] итте. «Айны җиргә кертмәенчә, моннан кайтмасмын», — дип, эчеп, сәрхуш булып биемәгә башлады. Беләсез, исерекнең егылмакы бик җиңел. Бии торгач йөзтүбән егылды. Торырга хәле булмагач, таң атканчы үләксә кебек шул урында ятты. Иртә белән торып, азрак айныгач, үзенең бу кабахәтен күреп: «Миңа ни булды болай?» — дип сорашкач, вакыйганы хәбәр биргәннәреннән соң, гаять оялып, ант итеп тәүбә кыйлмыштыр.

———

Дәхи мәшһүр шагыйрьләрдән Насыйп исемле кемсәнә беркөн Шам олугларыннан берenең хозурына барып, ул олуг адәм: «Шигырь әйт», — дип, Насыйпка әмер итте. Шагыйрь дәхи, гадәттән тыш күп шигырьләр әйтеп, ул олуг кемсәнә гаять мәхфуз булды. Насыйпны күп ингам-ихсан белән шат кыйлганнан соң, тәгам хәзер булып, бергә тәнавел кыйла башладылар. Ул кемсәнә әйтте: «Йә Насыйп, синең азрак күңел ача торган нәрсәне эчмәгә мәйлең бармы?» — дип, шәраб эчмәгә тәклиф кыйлгач, Насыйп дәхи: «Әй әмир, бәдәнемнең тиресе кара, бер зәнҗимен[3]. Вә яратылуым вә йөзем бер ямьсез сыйфаттадыр. Бу нәфрәтле хәлем белән, дәүләтеңез мәҗлесендә зат галиеңез белән бергә утырып, тәгам тәнавел итмәгә мөстәхак булдым. Гыйлемем вә гакылым мине бу дәрәҗәгә васыйл кыйлды. Мин бу дәүләткә сәбәп булган гакылымны киметә торган нәрсәне сәүмәймен вә эстәмәймен, зинһар, тәклиф кыйлмасаңыз ла», — дип игътизар кыйлгач, кәмаль истихсан белән янә гата[4] өстенә гата кыйлды.

---

[1] Нөзһәтгяһкә — күңел ачу урынына.
[2] Ямин — ант.
[3] Зәнҗимен — негрмын, кара тәнлемен.
[4] Гата — бүләк.

———

Хәҗҗаҗ бин Йосыф Гыйрак әяләтендә вали чагында Вәлид хәлифә хозурына бер мәслихәт өчен килгәндә, Вәлид тәгам ашап утырыр иде. Хәҗҗаҗга әйтте: «Шәрабка мәйлең бармы?» — дип тәклиф кыйлды. Хәҗҗаҗ әйтте: «Әй әмирелмөэминин, әмереңә карыша алмаймын. Ләкин мин Гыйрак илендә халыкны эчүчелектән тыйган идем. Үзем тыелмаган эштән халыкны, эшләмәңез, дип тыймакны кәриһ[1] күрәмен».

———

Захак бин Мөзахим бер шәрабхурга[2] «Шәраб эчеп ни эшлисең, аның ни файдасы бар?» — диде. Ул эчкече әйтте: «Ашказанында ашаганымны сендерә, кәефемне хушландырадыр», — диде. Захак әйтте: «Тәгамыңны сеңдергәннән артыграк дәхи динеңне вә гакылыңны һәзым кыйлмайдырмы?» — дип, исерткечнең тыюга хаклы вә гакылның кимчелегенә сәбәп булмакын сәнгатьчә сөйләмештер.

———

Ибн Әбү әл-Вафа кавемен шәрабхурлыктан нәһи кыйлып: «Әй кавем, әгяһ булыныз ки, хәмердә рәфгать юктыр, ягъни хәмер кешене алга таба илтмәйдер. Вә адәмгә дәрәҗә бирмәйдер, бәлки хур вә зәлил итәдер. Сакланыңыз, якын бармаңыз. Күрәсез, мин хәмерне эчмәймен. Зирә мин хәмерне шөйлә күрдем. Вә карарым, ышануым шөйләдер. Шәрабка вә хәмергә мөлазем, вә даимчылык кыйлгучылар явызлар мәнзиленә керерләр. Вә кабакханәләрдә булырлар, яхшы урыннарда булмаслар. Яхшы хезмәт тапмагач, гаҗизанә кярханәләргә керерләр, зиядә кабахәт җирләрдә булырлар, даим хурлыкта булырлар», — димештер.

———

Бер кичә бер гарәп үзенең чатырыннан чыгып, сахрада йөргән вакытта, бер яшь кыз раст килеп, бу гарәп кабахәт эшне касд кыйлганда, кыз гафифә булмак җәһәтеннән вә әһел бәлягать булмак җәһәтеннән гарәпнең бу харам эшкә мәйлен рәд кыйлып: «Әй кемсәнә, синең, филхәкыйкать, динеңнән вагыйз вә насыйхың[3] юктыр!» Ягъни әгәр дә динең булса иде, гыйльме эзәлисе белән һәрнәрсәне мөхыйт[4] булгучы Аллаһы Тәгалә хәзрәтенең колларына булган әмер вә нәһиен тыюын белеп бу мөгамәләгә җөрьәт итмәс идең. Гакылың юк икән. Әгәр дә гакылың булса иде, бу хәясызлыкны итмә дип гакылың сине тыяр иде», — дип, бу бәлягатьле сүзләрен сөйләде. Гөманы үзрә кызны җавапсыз калдырырмын дип: «Безне йолдызлар-

---

[1] Кәриһ — чиркану.
[2] Шәрабхурга — эчкечегә.
[3] Вагыйз вә насыйхың — вагазьчең һәм нәсихәтчең.
[4] Мөхыйт — колачлаучы.

дан гайре кемсәнә күрмәс, монда аулактыр», — диде. Вакыйган белмәклеге зарур булгучы Аллаһы Тәгаләнең сыйфат әзәлиясеннән галим сыйфатын белмәгәнен кызның занына муафыйк күрсәтте. Аннан соң ул: «Әй кеше, аларның йолдызландыручысы кайда? Вә халикы булгучы Аллаһы Тәгалә кайда? Һәр ниНәрсәне белеп, күреп тормайдырмы? Вә ул Аллаһы Тәгаләдән курыкмаймысың?» — диде. Гарәп бу җәваһир кебек сүзләрне ишеткәннән соң, оятка калып, бу сүз мәзах[1] җөмләсеннән булмаса да, ни әйтергә белмәгәч: «Мин сиңа мәзахлап кенә әйткән идем», — диде.

———

Пәйгамбәр галәйһиссәламнең сәхабәләреннән Нәгыйман дигән кемсәнә бик мәзахчан кеше иде. Вә ләтыйфәгә гаять мәел иде. Бер сугышта шәһид булды. Пәйгамбәр галәйһиссәламгә аның шәһид булган хәбәрен китерделәр. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Бичара, ул оҗмахка да көлә-көлә керер лә», — диде.

———

Сәгыйд бин Җабир хәзрәтләре вәгазь вә нәсыйхәт мәкамендә газап вә гыйкаб[2] хәлләрен сөйләшеп, кәмаль тәэсиреннән халыкны егълатыр иде, аның соңында мәтаибә вә мәзах кыйлып, дәхи халыкны көлдерер иде.

———

Бер шатранҗбаз[3] бар иде. Үлем сырхавы тиеп, мөхтәзыйр[4] хәлендә шәһадәт кәлимәсе китерәчәк җирдә, «шаһ!» «мат!» дип җан тәслим кыйлмыштыр.

———

Бер фәкыйрь үлем сырхавы хәлендә әкърибасыннан янына җыелган адәмнәр: «Әй фәлән, хәлең начар, иманыңны әйт», — дигәч, ул бичара: «Һай, шул үлем хәлендә дә имана белән аптыраталар ла!» — димеш.

———

Мәнкульдер ки, бер гарәп үзе һәм ашый һәм ишә, ягъни киеменнән бетләрен чүпләп-чүпләп ата. Бу хәленә тәгаҗҗеб кыйлып, бер кеше: «Әй карендәш, синең бу ни эшеңдер?» — дип сорады. Гарәп әйтте: «Йә минем бу эшем яхшы тәдбир түгелмедер, тәгаҗҗеб итәрсең? Искене чыгарып, яңаны кертеп, дошманнарымны бетерәмен», — диде.

———

Бер гарәпкә әйттеләр: «Инде Рамазан шәриф килде», — диделәр. Гарәп әйтте: «Валлаһи, тимә, килсен, мин аның җәмгыятен сәфәр белән, әлбәттә, таркатырмын», — диде.

---

[1] Мәзах — көлке.
[2] Гыйкаб — җәза, авырлык.
[3] Шатранҗбаз — шахматчы.
[4] Мөхтәзыйр — җан бирү.

---

Бер жаһил гарәп бер карый Коръән укыганда, аятен ишетеп, гәрчә Коръән аяте икәнен белмәсә дә вә ишеткәне булмаса да, үзе гарәп булмак җәһәтеннән ләфызның мәгънәсен фәһем итеп: «Бу карый безне һөҗү[1] кыйлды», — диде. Аннан соң аятен ишеткәч: «Зарар юк икән, һөҗүдән соң гарәпләрне мактап та куйды, безнең шагыйрьләремез кебек», — диде.

---

Бер гарәп әһел гыйбадәттән берничә кемсәнә утырып гыйбадәт белән төнге уяулык фазыйләтен сөйләшеп утырганда яннарына барды. Бу гарәпкә әйттеләр: «Йә гарәп, син дәхи кичәләр уяу торамысың? Төнлә укый торган вирдләрең[2] бармы?» — дигәч: «Бәли, бар», — диде. «Ни эшлисең?» — диделәр. Гарәп әйтте: «Торамын. Истибрага чыгамын, йомышларымны йомышлыймын», — дип, зикри мөстәһҗән булган фигыльләрне фәлән итәмен, янә ятып йоклыймын, дип мәсхәрәлек итмештер.

---

Дәхи гарәпләрдән бер гарәп җария сатып алмак өчен бер шәһәргә барды. Җария базарына чыгып, бер җария сатулашып торганда, дәллял[3] ул гарәпкә дуслык гарызы белән колагына: «Әй карендәш, бу җариянең өч төрле гаебе бардыр, әгәр разый булсаң ал, югыйсә алма», — диде. Гарәп әйтте: «Ни гаепләре бар?» Дәллял әйтте: «Бер гаебе будыр ки, ничә көннәр гаиб булып тора, эзләп табып кайталар», — диде. Гарәп әйтте: «Бу сүзеңнән морадың кача димәкчесең?» — диде. Дәллял әйтте: «Бәли». Гарәп әйтте: «Мин кечкенә кырмысканы да комда эзе белән табамын, бу җарияне дә эзеннән табармын», — диде. «Икенче гаебе нидер?» — диде. Дәллял әйтте: «Йоклаганда күп тамчылар тамызадыр», — диде. Гарәп әйтте: «Астына бәвел итә димәкендер?». Дәллял әйтте: «Бәли». Гарәп әйтте: «Итсә итсен, түшәгемә бәвел итәр дип куркар идем, миндә түшәк юктыр, хәймәмдә[4] туфрак тулы, теләгәнчә бәвел итсен», — диде. «Өченче гаебе ни-нәрсә?» — диде. Дәллял әйтте: «Күп вакыт бер нәрсә белән уйный», — диде. Гарәп әйтте: «Бәлки, угры дигән сүзеңдер?» — диде. Дәллял әйтте: «Бәли». Гарәп әйтте: «Миндә авызына кабарга да нәрсә тапмас, угырлар нәрсә кайда калды», — дип, җарияне алып китте.

---

Бер гарәп үзенең бер хаҗәте өчен Хәҗҗаҗ хозурына килде. Тәгам вакыты иде. Хәҗҗаҗ бу гарәпне дәхи тәгам ашамага дәстәрханга дәгъвәт кыйлды. Берничә төрле тәгам аша-

[1] Һөҗү — мәзәк, көлке.
[2] Вирдләрең — аятьләрең.
[3] Дәллял — маклер.
[4] Хәймәмдә — чатырымда.

ганнан соң, хәлвә китерелде. Гарәп хәлвәдән бер локмә[1] алып тәнавел кыйлгач, Хәҗҗаҗ әйтте: «Кемдә кем бу хәлвәдән бер дәхи локмә алса, муенын ордырырмын», — диде.

Хәҗҗаҗның үтерү бабында мәзахы да чынга китмәге сыналган иде. Мәзах икәне заһир булса да, куркып, бу мәҗлестәге барча ашаучылар кашыкларын куйдылар. Гарәп дәхи кашыгын куеп, гяһ Хәҗҗаҗның йөзенә, гяһ хәлвәгә карап торганнан соң: «Әй әмирел-мөэминин, ятим булып балаларым кала, балаларымны ташлама, Аллаһы өчен, күз-колак бул», — дип, җаныннан өмид өзеп, нәфсе белән кулын хәлвә табагына сузып, хәлвәне ашый башлагач, Хәҗҗаҗ вә гайреләре дәхи эчләре катканчы көлеп, бу гарәпнең хаҗәтен эда кыйлудан башка күп салә кыйлып, гарәпне куанычка васыйл кыйлмыштыр.

———

Гали разыйаллаһу ганһу бер гарәпнең намазны җиңелчә укыганын күреп, камчысы кулында иде, гарәпнең янына барып: «Әй гарәп, намазыңны яңадан кыйл!» — дип, дөрес нигезгә китереп тәкрар намаз укытты. Гарәп намаздан бушагач, Гали разыйаллаһу ганһу сорады: «Әүвәл укыган намазың яхшы идеме, соңыннан укыган намазың яхшы булдымы?» — диде. Гарәп әйтте: «Әүвәлгесе яхшырактыр вә хәерлерәктер». Хәзрәти Гали әйтте: «Нидән әүвәлгесе хәерлерәк дип әйтәсең?» — диде. Гарәп әйтте: «Әүвәлге намазым Хак Тәгалә ризасы өчен иде. Соңгы намазымны камчыдан куркып укыдым», — дигәч, Гали разыйаллаһу ганһу гарәпнең җавабын тәхсин кыйлып, көлемсерәп куйды.

———

Муса исемле бер җаһил гарәп берәүнең бер кесә акчасын угырлап, бер мәсҗеттән үтеп барганда, намаз вакыты, имеш, мәсҗеткә керде. Имам ахшам намазын укыганда аять укыды. Ул гарәп үзенә хитаб кыяс кыйлып, имамга: «Әлбәттә, син сахирсең, мә, менә!» — дип, имамның алдына ул янчык белән акчаны атып, мәсҗеттән чыгып качмыштыр.

———

Дәхи Әсмәгыйдан мәнкульдер. Гыйрак гарәп әһалисеннән берничә яшь мөсафирлар бер мәнзилдә туктап ашап-эчеп утырганда, яннарына гарәптән бер зәгыйфә карчык хатын килеп туктады. Болар бу карчыкны мәрхаба кыйлып, бераз тәгам биреп ашарга утырттылар. Вә дәхи нәбизаттан бер касә хәмер эчерделәр. Карчыкның бераз башына китеп, көлә башлады. Икенче бер кадәхне бирделәр. Карчык аны дәхи эчте. Кызарып вә кызып янә артыграк көлмәгә башлады. Өченче кадәхне дәхи тоттырдылар. Карчык яхшырак сөйләшә башлады. Егет-

[1] Локмә — бер катым.

ләрнең уен көлкесенә катышып: «Әй егетләр, Гыйракта сезнең хатыннарыңыз нәбизаттан эчәләрме?» — диде. «Бәли, эчәләр», — диделәр. Ул аларга: «Таэкид өчен касәм итәрмен ки, ул сезнең хатыннарыңыз, әлбәттә, зина кыйлырлар. Әгәр бу сүзегез хак булса, араңызда атасы мәгълүм кемсәнә юктыр», — дип, егетләрдән мәсхәрә кыйлып көлеп китте.

———

Мөхәммәд бин Габдулла исемле фазыйл нәкыль кыйлмыштыр. Беркөн Госман бин Әбү Шәйбә дигән карый янына бәгъзе зөрафа белән бармыш идек. Мәзкүр карый хәрәменнән чыгып, янымызга килгәч: «Нун вәлкаләм кайсы сүрәдә?» — дип, бездән сөаль кыйлып, гаять көлдерде. «Нун вәлкаләм» сүрә башы булып, сүрәнең исеме икән, кайсы сүрәдә дип сорамакы тәгаҗҗеб кыйлачак урындыр.

———

Мәнкульдер ки, Әбү әл-Гыйна исемле бер әмирнең ханәсендә бераз әһел гыйлем вә бәлагә вә зөрафа җыелып, гыйлем вә шигырь бабыннан сохбәт кыйлып утырырлар иде. Ләкин бодай башаклары арасында бакра шикелле алҗыган, асла сүз катмаенча утырыр бер кемсәнә бар иде. Мәҗлестәге яраннар моның ахмак вә наданлыгын бу кәйфиятеннән аңлап: «Әй барадәр, Коръән тәфсиреннән вә хифызыннан өлешең бармыдыр?», — дип сорадылар. Бәс, ул кемсәнә мөтәкәббиранә «һай-һай, «Коръәнне беләмен» дип, наданлыгын белдергәч, зөрафаның берсе, имтихан өчен бер гарәби кәлям тезеп укыды: «Йә сәмдәна, бу укыганым кайсы сүрәдәдер?» — диде. Ул кемсәнә бераз фикерләп торды да: «Бу сүз — Хөммедөхандәдер», — дигәч, мәҗлес әһеле һәммәсе каһкаһә көлештеләр.

———

Бер надан фәкыйһләрдән[1] бер кемсәнәгә берәү килеп: «Йә сәйидәна, Рамазанда беркөн гозер шәргыйсез рузамны боздым. Моның хөкеме нидер?» — диде. Мәзкүр фәкыйһ әйтте: «Урынына янә бер көн руза тот, каза кыйл», — дип җавап бирде. Ул саил дәхи беркөн килеп әйтте: «Йә фәкыйһ, каза нияте белән бер көн руза тотмыш идем, ләкин ул көн базарга чыгып йөреп өемә кайтсам, җәмәгатем маэмүния дигән хәлвә пешергән, имеш, алдыма китерде. Мин дәхи тыела алмаенча, ул хәлвәдән тәнавел кыйлдым», — диде. Бу фәкыйһ әйтте: «Аны дәхи ахырдан каза кыйл», — диде. Ул кемсәнә, янә килеп: «Йә фәкыйһ, беркөнне каза нияте белән руза булмыш идем, җәмәгатем мешмеш хәлвәсе пешереп алдыма китергәч, ашамаенча хәлем булмады», — дигәннән сон, ул фәкыйһ: «Күбесенчә, бәлки, бу каршылыклар яртысы иң башта фикерем синең кулың бугазына

[1] Фәкыйһләрдән — юристлардан.

багланмактыр», — дип, соңыннан кечкенә генә зарафәт[1] күрсәтмеш булса да, наданлык йөзеннән зарафәт итмеш, димәктер.

---

Холәфаи Габбасия заманында ләтыйфә сөйләүчеләрдән бер Сәлим дигән кемсәнә бар иде. Аңа берәү: «Тәкъсыйр, дога кыйлыңыз», — дип, кашсыз йөзек бирде. Сәлим дәхи кул күтәрде дә: «Илаһи, бу кемсәнәгә оҗмахта түбәсен япмаган сарайлар рузи кыйл», — дип дога кыйлмыштыр.

---

Мөхазаратта[2] мәзкүр хомакадан[3] бер кемсәнә бер кеше белән уртак бер йорт сатып алмышлар иде. Бер көн ул ахмак үзенең яраннарына әйтте: «Шул йортта булган ярты үземә тиешле өлешен сатмакчы булдым. Таки акчасы белән шәрикемә тигән өлешне дә алып, бөтен йортлы булыр идем», — дип, халык арасында көлке булмактыр.

---

Һарун әр-Рәшит хәзрәтләре бер кичә бер эш хосусында фикердә калып, хафачылыгыннан күзенә йокы кермәенчә, бер тәсәлли юаныч табылмас микән, дип, вәзир әгъзам булгучы Җәгъфәр бин Яхъя әл-Бәрмәкине чакыртып: «Әй Җәгъфәр, бер эшне фикерләп торганнан соң йокым качты, ни эшләем?» — диде. Җәгъфәр, күңел ача торган бәгъзе сүзләрне сөйләп, Һарунга бернәрсә белән юаныч бирмәк теләсә дә, хәлифәгә тулы җиңеллек хасыйл булмады. Хәйран булып торганда, Мәсрүр исемле хас могтәбәр хадим алдында торыр иде, көлеп җибәрде. Хәлифә ошбу хафачылыкта икән, Мәсрүрнең көлгәненә тарланып: «Һи, әдәпсез, мине көлкегә калдырыргамы касд итәрсең», — дип шелтә кыйлгач, Мәсрүрнең шатлыклы исеме затына киресенә мөнкалиб булып, алмашының җаны башына сачрады. Куркуыннан төсе китеп: «Әй әмирел-мөэминин, Рәсүлуллаһка якынлыгыңыз хакы өчен, бу көлмәк миннән касдан садыр булмады. Бәлки, үткән көн чыгып Диҗлә тарафына бармыш идем. Хисапсыз халык тамашага җыелмышлар иде. Бу халык нигә җыелган дип барсам, ибн әл-Мәгазли исемле бер мәзәкче төрле мәсхәрәлекләр сөйләшеп, халыкны көлдермәктәдер. Халән аның сүзләреннән бере хәтеремә килеп, көлеп җибәрдем. Вәлгафу, йә әмирел-мөэминин, дип, аягына баш куйды. Хәлифә гафу белән мөнкаләб исемен кайтарды вә әйтте: «Әй Мәсрүр, тиз бар, ул мәзәкчене монда алып кил», — диде.

Мәсрүр дәрхаль торып китте. Ул бу мәзәкченең ханәсен сорашып тапты. Әйтте: «Йә Мәгазли, әйдә, сине әмир чакырыр», — дигәч, ибн әл-Мәгазли дәхи: «Баш өсте!» — дип юлга

---

[1] Зарафәт — сүздә үткенлек, ягымлылык.
[2] Мөхазаратта — әдәби әңгәмәдә.
[3] Хомакадан — ахмаклардан.

чыктылар. Мәсрүр әйтте: «Әй ибн әл-Мәгазли, сине хәлифә хозурына шул шарт белән алып барамын, әгәр дә сиңа әмир гатыя бирсә, салисание миңа булыр, салисы[1] — сиңа булыр», — дип килештеләр. Хәлифә хозурына килделәр. Әдәп вә тәгъзыйм белән хәлифә хозурында тордылар. Хәлифә әйтте: «Әй мөзахик, әгәр мине көлдерә белсәң, сиңа биш йөз алтын гатыя. Әгәр көлдермәсәң, ошбу капчык белән өч мәртәбә сугармын», — дип, яннарында дирһәм тулы бер капчык бар иде, аңа ишарәт кыйлды. Мәзәкче ул капчыкны буш капчык хыял кыйлып, гатыя тамгысы белән, өч мәртәбә түгел, ун мәртәбәгә разый булмакчы булып, телдә вә эштә хәлифәне көлдермәгә иҗтиһад кыйлып, төрле мәзәкләр кыйлды. Әмма Һарун әр-Рәшит хәзрәтләре захик түгел, тәбәссем дә кыйлмады[2].

Бәс мәзәкче, бу хәлне күргәч, курку алып калтырап, аркасын куеп, суктырырга хәзер торды. Хәлифә әйтте: «Инде сугуга мөстәхак булдың», — дип, ул капчыкта мең дирһәм микъдары акча булып, мәзәкчене бер мәртәбә сукты. Кайчан ки, мәзәкченең җилкәсенә бер суккач, зәхмәтенә такать тота алмаенча кычкырды. Мәсрүр белән кыйлган шарты күңеленә килеп: «Әман боер, йә әмирел-мөэминин, ике генә сүзем бар, ишет», — диде. Хәлифә әйтте: «Ни сүзең бар?» Мәзәкче әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, Мәсрүр белән шарт куймыш идек: әгәр дә әмир нигъмәт бирсә дә, зәхмәт бирсә дә, күбрәге Мәсрүргә, азрагы миңа булмак иде, ягъни салисы миңа, салисание аңа иде. Өч мәртәбә сукмага шарт кыйлмыш иденез. Мин үземә тиешле бер зарбәне[3] алдым. Калган ике зарбә Мәсрүр хиссасыдыр», — дигәч, хәлифә сабырга мәҗале калмаенча тәгаҗҗеб кыйлып, каһкаһә белән көлде, бу һибә сиңа тиеш, имеш, дип, шул капчык белән Мәсрүргә берне бирде. Мәсрүр дәхи такатьсез кычкырып: «Валлаһи, әй әмир, калган өлешемне ризалыгым белән ибн әл-Мәгазлигә һибә кыйлдым. Калганын дәхи аңа бир», — дигәч, бу сүзгә дәхи хәлифә рәхәтләнеп көлде. Күңеле ачылып, һәр икесенә бишәр йөз алтын ихсан кыйлды вә Җәгъфәргә дәхи кыйммәтле хилгать кидерде.

---

Холәфаи Өмәвиядән нәүбәт Гомәр бин Габделгазизгә[4] килгәч, ягъни хәлифә булгач, хәлифәлеген котламак өчен һәр әтрафтан килгән халык арасында бер сабый бала бар иде. Бу бала хәлифә мәҗлесендә сүз сөйләшә башлаганда, хәлифә аңа гыйтаб[5] тарикынча: «Әй бала, бу мәҗлестә синнән олуграк вә

[1] Салисы — өченче өлеше.
[2] Захик түгел, тәбәссем дә кыйлмады — көлү түгел, елмаймады да.
[3] Зарбә — кыйнауны, сугуны.
[4] Әмәвиләр династиясеннән 8 нче хәлифә, 717 елда тәхеткә утыра.
[5] Гыйтаб — шелтә.

синнән лаеграк адәмнәр бардыр. Син кечкенә кеше, сабыр ит, олуглар сөйләшсен», — диде. Сабый әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, үзеңез дигәнчә, кадер вә шәрафәт ихтыяр белән, ягъни картлык белән булса иде, бу мәҗлестә хәлифә булырга һәм синнән лаеграк кемсәнәләр бар иде, сез хәлифә булдыңыз», — диде. Аннан соң хәлифә: «Вакыйган, кадер вә шәрафәт ихтыяр белән түгелдер», — дип, сабыйга сөйләргә рөхсәт бирде. Сабый әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, безләр һәркайсымыз шәһәрләремездән сезләрне Хак Тәгалә безләргә хәлифә кыйлганының хәмед вә шөкере өчен килдек. Вә сездән ярдәм өмид итеп яки җәзагыздан куркып килмәдек. Сезнең гадаләтеңез аркасында җәр[1] вә золымлыктан иминнәрмез», — диде. Бу сабый: «Шөкер вә синең өчен килгән илчеләрмез», — дигәч, Гомәр бин Габделгазиз әйтте: «Әй сабый, миңа вәгазь вә нәсыйхәт кыйл», — диде. Сабый әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, адәмиләрдән бер фирка бардыр ки, Аллаһы Тәгаләнең йомшаклыгына вә адәмнәрнең мәдехенә мәгърур булганнар җөмләсеннән булыр исәң, аягың сөртенер, ягъни хурлыкка төшеп, ул фирка җөмләсеннән булырсың». Аннан соң Гомәр бин Габделгазиз ул сабыйдан сорады: «Әй сабый, син ничә яшьтәсең?» — диде. Сабый әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, яшем унике белән барадыр», — дигәч, Гомәр бин Габделгазиз бу нәзымны укыды. Мәгънәсе: син гыйлем үгрән. Зирә кеше атасыннан галим булып тумайдыр, гыйлемгә ия булган кеше, әлбәттә, җаһил кемсәнә кебек түгелдер. Гыйлеме булмаган кеше, кавеменең олугы булса да, галимнәр мәҗлесендә кечкенә вә хәкыйрь күренер.

———

Мәнкульдер ки, Һишам[2] бин Габделмәликнең хәлифәлеген заманында берничә ел гаять ачлык булып, халык барчасы Һишамның алдына җыелып килделәр. Ләкин Һишамның мәһабәтеннән куркып, бу мәҗлестә сүз башларга берәү дә җөрьәт кыйлмады. Ул халык арасында нәфис телле Дәрвас бин Хәбиб дигән унике яшәр бала бар иде. Бу балага Һишамның күзе төшеп, капка сакчыларына әмер кыйлды: «Минем дәргяһемә гарыз белән килгән кешегә кем булса да рөхсәт бир, хәтта сабыйлар булса да керсен», — диде. Ул сабый бу рөхсәтне ишеткән заман сачрәп керде, Һишам алдында аяк үзрә торып, алдына гына карап, Һишамга аслан күзе белән нәзар салмаенча: «Йә әмирел-мөэминин, рөхсәт булса, бераз сүз сөйләем», — дип рөхсәт сораганнан соң, Һишам, бу сабыйның бу бәһадирлыгына тәгаҗҗеб итеп: «Әй сабый, атаңа рәхмәт, ни сүзең бар, сөйлә», — диде. Бәс, сабый бәлягать вә фәсахәт белән: «Әй

---

[1] Җәр — өстерәү, тарту.
[2] Әмәвиләрдән унынчы хәлифә, 724 елда тәхеткә утыра.

әмирел-мөэминин, өч елдыр ки безләргә кахт[1] вә ачлык иреште. Әүвәлге ел җанымызны эретте. Икенче ел вөҗүдемезнең итләрен ашады. Өченче ел сөякләремезне нечкәртте. Дәүләтеңез хәзинәсе мал белән тулыдыр. Әгәр ул маллар Аллаһы Тәгаләнең исә Аллаһының бәндәләренә игъта бүләк кыйлыңыз. Вә әгәр бәндәләрнең исә, ни өчен алардан мәныг кыйласыз? Вә әгәр хассатән үз милкеңез исә, Аллаһы Тәгаләнең мөселман бәндәләренә садака боерыңыз. Зирә Аллаһы Тәгалә, садака биргүчеләргә рәхмәт итеп, әҗерен бирер», — дип сүзен тәмам кыйлды.

Кайчан ки Һишам ул сабыйның бу кадәр бәлигъ кәлямен ишеткәч, кыр-далаларда яшәүчеләргә ризык өчен йөз мең дирһәм тәгаен кыйлды. Аннан соң сабыйга әйтте: «Әй сабый, хассатән үзең өчен бер морадың бармы? Үтимен», — диде. Сабый әйтте: «Бу мөселман җәмәгате эчендә фәкать үзем өчен морадым юктыр», — дигәннән соң, Һишам дәхи бу сабыйга гаять илтифатыннан: «Әй сабый, инде син бу кавемнең хуҗасы булдың», — диде.

---

Хәҗҗаҗ беркөн татлы теллеләрдән Газбан дигән кемсәнәне күп җәһәтеннән тәҗрибә вә имтихан кыйлды. Җөмләдән берсе ошбудыр ки, Газбаннан сорады: «Йә Газбан, галим кемдер вә гакыйль кемдер? Җаһил вә надан кемдер?» — диде. Газбан әйтте: «Гакыйль шул кемсәнәдер ки, диненә вә дөньясына файдасы булмаган сүзне сөйләмәс. Вә һәркемгә йомшаклык вә шәфкать белән нәзар кыйлыр. Вә бирәүгә дә ачигъланмас. Хыянәтне яшермәс. Вә халыктан гозер эстәмәс, ягъни берәү аның каршында гаепле булып, аның гозер теләгәнен көтмәс, гозереннән мөкаддәм гафу кыйлыр. Ләкин җаһил шул кешедер ки, сүзендә күп ялган вә буш сүзләр. Вә тәгамында миннәт. Вә сәламендә саранлык. Вә олы әл-әмиргә итагатендә ялкаулык вә итагатьсезлек булыр. Халыкка фахиш сүзләр белән хитаб кыйлып, золым вә җәбер кыйлган кешедер», — диде. Хәҗҗаҗ әйтте: «Хатыннарның вә җарияләрнең хәлләреннән вә мәзахларыннан миңа хәбәр бир?» — диде. Газбан әйтте: «Хатыннарның табигате кәкре кабырга сөякләре кебектер: әгәр төзәтә башласаң, сынып китәдер, һаман кәкре көенчә истигъмаль кыйлмак лазем. Аларның җәүһәрләре вә затлары бары алар белән мөдарә[2] кыйла белеп тезгә килер. Карышулары вакыйг булганда, ә килешүчәнлек эзләп табу йомшаклык белән. Максатка ирешүдә тырышлык кирәктер. Вә алар белән йорт тышындагы эшләрдә мәшвәрәт кыйлган кешенең хәле вә

---

[1] Кахт — корылык.
[2] Мөдарә — яхшы, куркәм мөгаләмә.

хәяты мәкәддәр булыр. Вә аларның иң газизрәк вә кадерлерәк булганнары гафифә вә пәрһизләредер[1]. Әгәр хатыннар гыйффәттән төшсә, үләксә исеннән яманрак вә кәриһрәктер», — диде.

Бәс, Хәҗҗаҗ, бу җаваплардан Газбанның гакылын вә фәһемен тәҗрибә кыйлганнан соң, әйтте: «Әй Газбан, Кирман шаһы ибн Әшгаскә сине илче итеп җибәрәчәкмен. Анда ни сөйләрсең?» — диде. Газбан әйтте: «Йә әмир, аның һәлакенә дәлил сүзләр вә сезнең галәбәңезгә хәвефле кәлимәләр әйтеп куркытырмын», — диде. Хәҗҗаҗ әйтте: «Мин гөман кыйламын ки, минем янымда мактанганың шикелле аның янында, яки нәрсәдер өмет итү белән, яки куркып, билә мактана алмассың», — диде. Газбан әйтте: «Ни өчен сөйләмәсмен, йә әмир, бәлки, синең янында сөйләшкәнемнән һәм артыграк, Аллаһы Тәгалә тел ачкычы бирсә, сүз мәйданында киңлекне иҗра кыйлсам кирәк», — диде. Бәс, Хәҗҗаҗ әмер итте, Газбан илчелек сәфәренә чыгып китте.

Хәҗҗаҗның гадәте бу иде ки, бер җиргә илче җибәрсә, яшерен күзәтү кыйлмак өчен артыннан шымчы күндерер иде. Шул гадәте буенча Газбан артыннан һәм яшерен бер җасус күндерде. Кайчан ки Газбан кирман шаһы Әшгаскә васыйл булып, илчелеген әда кыйлганда, үзенең табигатендә булган әшәкелек вә хыянәт таләбенчә вәгъдәсенә хилаф итеп, үзенең Хәҗҗаҗ тарафыннан илче булып килгәнен ифадә кыйлды. «Хәҗҗаҗдан мөкаддәм, син үз мәслихәтеңне кара, ул үтерүдән кыйлмастан элгәре син үтерелү вә үтерелүгә каршы торуга хәзер бул», — дип, Хәҗҗаҗның ниятен белдерде. Ибн Әшгас, дәхи әсбаб мөкатәләгә кайгыртучанлык иһтимам итеп, Газбанга хилгать кидереп, күп һәдия вә гатыяләр бирде.

Бәс, Газбан әдаи сәфарәтне тәмам кыйлып, юлга чыкты. Кирманның комлык вә каты эссе сахрасында көннең эссе вакытында чатыр корып ятканда, вә кояшның бик кыздырган вакытында Бәкер бин Васыйл кабиләсеннән тәвәсенә атланган хәлдә бер гарәп, сусап, Газбанның чатырына килде вә чатыр алдына туктады. Газбан ул гарәпнең сәламен алып, сәлам бирмәк сөннәт вә кайтармак фарыздыр, сәлам алган кеше һадаяттәдер, алмаган кеше зәляләттәдер, дип, гарәпкә хитап кыйлып: «Әй гарәп, ни мәслихәт белән килдең?» — диде. Гарәп исә яланаяк, җирнең хәрарәтеннән бер аягын күтәреп, бер аягын басып торган хәлдә: «Морадым вә мәслихәтем бу каты эсселектән сезнең күләгәңездә икрамыңызны вә чатырыңызның бәрәкәтене истәрмен вә өмидем химаятеңездер», — диде. Газбан әйтте: «Минем чатырымнан вә минем күләгәмнән олуграк чатыр вә күләгә бардыр, аны ни өчен касд кыйлмадың?» — диде. Гарәп әйтте: «Ул чатыр вә ул күләгә ни рәвешле күләгә вә химаядер

[1] Пәрһизләредер — тыелучанларыдыр.

вә кайдадыр?» — диде. Газбан әйтте: «Ибн Әшгаснең коббәсе вә күләгәседер», — диде. Гарәп әйтте: «Ул күләгәгә ирешмәк мөшкелдер, бәлки, ирешер мөмкин булмаган нәрсәдер. Ләкин бу чатырга кермәк җинел вә аннан кинрәктер, тату булсак, сыярмыз», — диде. Газбан әйтте: «Бу чатырга Әшгас чатырына кермәктән кыенрактыр», — дип, каты-каты сөйләгәненнән гарәп ачигъланды. «Әй Аллаһының колы, син кемсең, ни исемлесең?» — диде. Гарәп әйтте: «Минем исемем Ахиздер, ягъни алгучыдыр, ни бирерсең? Ике исемем булмакны мәкруһ күрәмен», — диде. Гарәп әйтте: «Аллаһы өчен әйт, син кайдан булырсың?» — диде. Газбан әйтте: «Руи зәминнән, ягъни Җир йөзеннән булырмын». Гарәп әйтте: «Кайда барасың?». Газбан әйтте: «Җирнең нахияләрендә гизеп йөримен», — диде. Әмма гарәп җирнең гаять эсселегеннән һаман бер аягыннан бер аягына торып: «Әй егет, карыз шигырь итәрмесең, ягъни шагыйрьмесең?» — диде. Газбан әйтте: «Карыз шигырьне күселәр итәрләр — күсе түгелмен», — диде. (Чөнки карыз шигырь лөгаттә изафә белән шигырь сөйләмәк мәгънәсенә вә карыз бернәрсәне кисмәк вә кырмак мәгънәсенәдер. Вә шигырь шинның[1] асты белән назымлы сүз вә җыр мәгънәсенә, әмма шинның өсте белән арпа мәгънәсенәдер. Бәс, Газбан, икенче мәгънәсен ирадә кыйлып, арпа кырмак мәгънәсен алды. Әмма гарәпнең морады әүвәлге мәгънәсе иде.) Янә гарәп әйтте: «Мәсҗәгъ кәлям[2] белермесең?» — диде. Газбан әйтте: «Сәҗыгъне күгәрченнәр әйтер, мин күгәрчен имәсмен», — диде. (Чөнки сәҗыгъның бер мәгънәсе күгәрчен гөрләмәк мәгънәсенәдер, Газбан шул мәгънәне ирадә кыйлды.) Гарәп, кояшның эсселегеннән гаҗиз булып: «Әй адәм, рөхсәт бир, чатырың эченә керәем», — диде. Газбан әйтте: «Менә сахра сиңа минем саямнан киңрәктер», — диде. Гарәп әйтте: «Монда һәр җирдә кояш эссесе әсәр итмеш, басар хәл юк», — диде. Газбан әйтте: «Мин кояшка хуҗа түгелмен, кыздырса кыздырыр», — диде. Гарәп әйтте: «Зинһар, синең тәгамың, ашамак-эчмәкең миңа кирәк түгел, бары күләгәдә генә утыраем», — диде. Газбан әйтте: «Минем чатырыма үлсәң дә керә алмассың, булмаган эшкә тәгаррыз кыйлма», — диде. Бәс, гарәп, моңар бик гаҗәпләнеп: «Сөбханаллаһи», — диде. Газбан әйтте: «Хак Сөбханә вә Тәгалә, син дөньяга килмәстән, мөкаддәм дә һәм тәсбих вә тәкъдис кыйлыныр иде», — диде. Гарәп, гаять ачигъланып: «Әй егет, бу үртәү сүзләрдән башка синдә нәрсә юк, имеш», — диде. Газбан әйтте: «Юк. Дәхи бер олуг таягым бар, таягым белән башыңа орырмын», — диде. Гарәп кәмаль гаҗизлегеннән: «Әй җар бәни кәгаб», — дип, кабилә халкыннан мәдәд эстәп, фөрьяд кыйла

---

[1] Шин — «Ш» хәрефенең исеме.
[2] Мәсҗәгъ кәлям — ритмлы сөйләм.

башлагач, Газбан әйтте: «Һи карт, син ниндәен зәбун[1] адәм икәнсең. Ант итәмен ки, сиңа кем тиде? Һичбер кем сиңа золым вә дошманлык кыйлмады ки. Кабиләңнән мәдәд эстәр идең?» — диде. Гарәп әйтте: «Синнән зиядә каты күңелле, мәрхәмәтсез кеше күрмәдем. Мәдәд вә ярдәм эстәп килдем, мине сөрдең. Чатырыңа кертеп, бәлиганә ягымлы сүзләр сөйләп сохбәт итсәң, ни булыр иде?» Газбан әйтте: «Синең белән сохбәт итмәгә бер мәслихәтем вә хаҗәтем дә юктыр, бар, кадал, кит», — диде. Гарәп әйтте: «Аллаһыны сәвәр исәң, әйт, исемең нидер? Һич булмаганда, исемеңне белеп китәем, бәян кыйл, валлаһи», — дип ант эчте. Газбан әйтте: «Минем исемем Газбан бин Кабгасридыр». Гарәп әйтте: «Исемең ниндәен начар исем, имеш, газаптан мәхлук булганыңа дәлаләт итәр. Бу исемнең иясендә хәер юктыр», — диде. Газбан әйтте: «Шул тупас, кабахәт, хәерсез аягыңны ишегемә таба куйма», — диде. Гарәп әйтте: «Әгәр синең аягыңнан хәерле булмаса, Аллаһы хәзрәте аягымны сындырсын», — диде. Газбан әйтте: «Әгәр хаким булсаң, хөкемеңдә золым итәр идең. Чөнки минем аягым чатыр эчендә күләгәдә торадыр, синең аягың эссе ком өстендә тора, баһерхәл, хәйрият вә мәнфәгать минем аягым җанибендәдер», — диде. Гарәп ачигъланып: «Мин гөман кыйламын ки, син хәрүри, ягъни харҗи таифәсеннәнсең», — диде. Газбан, янә үзенә дога кыйлыбрак: «Илаһи Хак Сөбханә вә Тәгалә мине изгелек эстәгәннәр җөмләсеннән кыйлгай иде», — диде. Гарәп әйтте: «Белдем ки, синең ганасыйрың[2] бозыктыр». Газбан әйтте: «Бозык булса булыр. Минем аны төзәтер хәлем юктыр», — дип җавап биргәннән соң, гарәп, наөмид булып, Аллаһы Тәгалә сиңа разый булмасын, дип дога кыйлып, шигырь юлына салган бәетне укыды.

Гарәп Газбанга хитабан: «Син аларга сәед вә вали булган кавемне Хак Тәгалә хәер вә бәрәкәт белән мәгъмүр итмәсен. Ант вә ямин итәрмен ки, син — шайтан икәнсең! Зыяфәт вә икрамыңны өмид итеп, саяңә килдем, мине мәхрүм җибәрдең», — диде.

Хасыйле кәлям, Газбан сафарәтне әда кыйлып гәрчә кайтса да, ләкин аннан мөкаддәм мәзкүр җасүс Газбанның Әшгас белән булган әңгәмәсен вә гарәп белән булган маҗарасын кайтып хәбәр бирмеш иде. Әмма Газбан моннан гафил булыбрак, Хәҗҗаҗ янына кайтып керде. Хәҗҗаҗ Газбанга хитап кыйлып: «Йә Газбан, Кирман җирендә гаскәр торгызмак кирәкле дип табылган тәкъдирдә, ни рәвеш белән булыр?» — дип җавап сорагач, Газбан Хәҗҗаҗны ниятеннән дүндермәк касды белән вә Әшгаскә иганәт ярдәм, Хәҗҗаҗны гафил калдырмак өчен: «Йә әмирел-мөэминин, Кирман җирләре сулардан вә җылга-

---

[1] Зәбун — загыйфь, куәтсез.
[2] Ганасыйрың — асылыңның элементлары.

лардан халн, урманнан вә нәбататтан ялангач. Вә угрылары вә юлбасарлары күп бер җирдер. Әгәр анда җибәрәсе гаскәрегез күбрәк булса, ашамак-эчмәк нәрсәсе җитмәс. Әгәр аз гаскәр җибәрсәгез, аларның гаскәренә тиңләшергә кадир булмаенча, заигъ булырлар», — диде. Хәҗҗаҗ әйтте: «Вакыйган дөрестән дә синең гөманың расттыр». Ибн Әшгаскә: «Хәҗҗаҗ газел итәчәктер бәйләнер, аннан мөкаддәм, син мөкавәмәткә каршылык күрсәтергә әзер бул, икъдам кыйл, дип әйтмәдеңме» — дигәч, Газбан, Хәҗҗаҗның вакыйгадән хәбәрдар булганын фәһем итеп, үтенү ягына тартылып: «Әл-эман, йә әмир, аларга тамыг йөзеннән сөйләшкәнем сезнең дәүләтегезгә зарарлы түгелдер, гафу кыйл», — диде. Хәҗҗаҗ әйтте: «Ант итәмен ки, сине, хурлык паласына утыртып, хурлау атына атландырып, шәһәр гиздерермен!» — дип, бәйләп, богаулап зинданга җибәрде.

Бер заманнан соң Хәҗҗаҗ, Васат дигән җирдә бина кыйлынмыш хазара исемле сарайны тамаша кыйлырга барып, үзенең сохбәттәшләреннән сорады: «Бу сарай хакында ни әйтәсез?» — диде. Алар дәхи: «Әй әмир, бу бина кыйлынмыш коббәи[1] Хазара нык вә хуш гыймарәттер, нәзар кыйлган адәмгә шатлык бирер вә торгучыларына куаныч китерер», — дип мәдех кыйлгач, Хәҗҗаҗ әйтте: «Сез тугырысын сөйләмәдегез! Тиз Газбанны китерсеннәр, аннан сорармыз», — диде.

Дәрхаль зинданнан чыгарып, Газбанны китерделәр. Газбан, бу сөальне сораганнан соң: «Ул коббәне ки үз шәһәреңнән гайре җирдә вә балаңнан гайре кеше өчен бина кыйлдың, сиңа даим булмас вә варисың дәхи анда тормас. Һәм сарай, һәм син бакый калмассың», — димәктер. Бәс, Хәҗҗаҗ инсаф итеп: «Газбанның сүзе растыр. Ләкин янә зинданга җибәрелсен», — дип әмер кыйлды.

Газбан зинданга барган вакытта аять укыды. Зинданга барып җитеп, зинданга кергән вакытта дәхи аять укыды. Аннан соң Хәҗҗаҗ, ачигъланып: «Салыңыз шуны җир астындагы зинданга!» — дигәч, Газбан янә аять укыды. Мәгънәсе будыр: без, олы шанлылар, сезләрне җирдән вә туфрактан халык иттек. Янә мәүтегездән соң туфракка кайтарырмыз. Туфрак булган тәннәрегезне җыеп, җаныгызны янә биреп, туфрактан чыгарырмыз, димәктер. Хәҗҗаҗ дәхи катырак ачигъланып: «Сүрәп илтегез аны зинданга!» — дип кычкырды. Газбан дәхи аять укыды. Аннан соң Хәҗҗаҗ әйтте: «Җибәрегез шуны үз юлына, безләргә күп галәбә кыйлды», — дип, бәлягать вә фәсахәтенә бинаән, гөнаһын гафу кыйлып, күп гатыяләр биреп, шәфкать кыйлды. (Менә сүзне урынына күрә килештереп сөйләгәннең файдасы! Бер кеше булыр: бер кәлимә белән зинданга төшәр, мең кәлимә белән чыга алмас. Вә бер кеше булыр ки:

---

[1] Коббәи — гөмбәзле.

бер кәлимә белән зинданга төшәр, бер кәлимә белән зинданнан котылыр.)

---

Бер имамның улы, ерак җиргә барып, озак көннәр мәдрәсәдә гыйлем хасыйл итеп вә гаять галим булып, атасы белән күрешергә кайткан, имеш. Атасы моның белән күрешкән заман шатлыгыннан вафат булмыш. Заманамызда булган вакыйгадыр.

---

Әбү Бәкер бин Әхмәд әйтте: «Шәех Шиблине күрдем, бер мәсҗеттә халык бик күп иде, Шибли әйтте: «Малын җуйган кеше өчен дога кыйлган бәндәгә Аллаһы Тәгалә рәхмәт итсен», — диде. Бер егет халык арасыннан ертып чыкты да: «Малын җуйган кеше кемдер?» — диде. Шибли әйтте: «Ул кеше минмен». Ул егет әйтте: «Малың ни-нәрсә иде?» Шибли әйтте: «Малым — сабырдыр. Сабырымны җуйдым», — диде. Халык һәммәсе гаять елаштылар».

---

Бер кешенең аты һәлак булды. Бу кеше бик кайгырып елады. Әйттеләр: «Кайгырма, шаять, шул хәерледер. Хәерле каза булсын», — диделәр. Ул кеше әйтте: «Әгәр хәерле булса, һәлак тә булмас иде, янында бер качыры да булыр иде», — диде.

---

Берәү бер кешегә әйтте: «Аллаһы Тәгалә сиңа кайгы хәсрәт вә мәкруһ эшләрне күрсәтмәсен. Вә барча мәкруһ эшләреңнән имин итсен», — диде. Ул кеше әйтте: «Гүяки син миңа үлем белән дога кыйласың! Чөнки берәү, терек булып торган мөддәттә, мәкруһ эшләрне вә казаны күрмәй хәле юктыр. Кайгы-хәсрәт күрмәсә, адәм дә түгелдер», — диде.

---

Сафиян разыйаллаһу ганһуның бер мөхәннәс[1] күршесе бар иде. Беркөн сырхау булды, Сафиян хәзрәтләре берничә кеше белән аның хәлен сорамага керделәр. Сафиян әйтте: «Әй күрше, ни хәлең бар?» — диде. Ул мөхәннәс әйтте: «Ни хәлем булсын, авырулар вә афәтләр кочак белән керә, чеметемләп чыга», — диде. Сафиян әйтте: «Бакчы, монда кермәкемездән бер файда булды», — диде, ягъни бер хикмәтле сүз белдек, диде.

---

Бер әгърабигә әйттеләр: «Ни хәл, ни хәлең бар?» — диделәр. Әгъраби әйтте: «Хәлем Аллаһы теләгәнчә дә түгел, шайтан теләгәнчә дә түгел, үзем теләгәнчә дә түгел. Чөнки Аллаһы Тәгалә минем мөэмин вә габид булмагымны тели. Шайтан минем кяфер булмагымны тели. Мин үзем бай булмагымны телимын. Хәлбуки берсе дә шулай түгел», — диде.

---

[1] Мөхәннәс — куркак.

---

Шәех Шиблигә әйттеләр: «Дөньяда шөгыль бар. Ахирәттә курку бар. Инде котылу кайдадыр?» — диделәр. Шәех Шибли әйтте: «Шөгылеңне куй, ахирәттә куркудан имин булырсың», — диде.

---

Муса галәйһиссәлам заманында бер изге кеше бар иде, Мотыйгулла дип мәгъруф иде. Муса галәйһиссәлам күрде: бер җирдә гәүдәсе ята, ерткыч хайван җаралап ташлаган. Муса галәйһиссәлам бик гаҗәпкә калып туктады, әйтте: «Йа Рабби, бу яхшы бәндәңне билә бер бәла белән мөбтәля кыйлдың, ни сәбәптер», — диде. Аллаһы Тәгаләдән вәхи килде: «Ул бәндәм дога кыйлды, догасын кабул иттем: гамәле сәбәпле ирешмәй торган дәрәҗәне миннән сорады, шул дәрәҗәгә ирештермәк өчен аны бу михнәт белән мөбтәля кыйлмакны ихтыяр иттем», — диде.

---

Хәҗҗаҗ хәлифә заманында бер егетнең бик гүзәл җариясе бар иде. Бервакытны бу бик фәкыйрьлеккә төште. Акчага мохтаҗ булып, Бәгъдад шәһәренә җариясен сатмага алып барды. Ул шәһәрнең хәлифәсенә сатты. Хәлифәнең бер карендәше бар иде. Бервакытны бу җария ул егет белән күзләшеп торыр! Хәлифә моны күрде, җарияне шул егеткә һибә кыйлды. Егет дәхи җарияне кабул итеп алды, йортына китерде. Кич яттылар. Егет эшкә шөруг кыйлды. Ул арада өй эчендә бер тавыш булды, егет куркып китте, әгъзасы калтырап, эшеннән мәхрүм калды. Җария таң атмас борын егетнең яныннан чыгып качты. Җария кая китте, һич белгән кеше юк.

Иртә белән хәлифәгә хәбәр бирделәр. Тиз заман җарияне эзләп табып, хәлифәгә китерделәр. Хәлифә әйтте: «Һи бәдбәхет, наинсаф, мин сине кыйммәт бәһа биреп сатып алдым. Агамның углына мәхәббәтең төште, аны сиздем, сине аңа һибә кыйлдым. Хәзер сине астырырмын! Башыңны кистерермен!» — дип куркытты. Җария әйтте: «Әфәндем, ихтыярың бар, теләсәң ни кыйл. Ләкин бераз сабыр ит, бер сүзем бардыр», — диде. Хәлифә әйтте: «Ни сүзең бар?» Җария әйтте: «Мин мөкаддәмдә фәлән авылның фәлән кешесенең кулында идем. Тормышыбыз яхшы иде. Көннәрдән бер көн ул егет фәкыйрьлеккә төште. Акча кирәк булгач, мине, бу шәһәргә китереп сезгә сатты. Юлда килгән вакытта уйнадык, көлдек. Бу егет кызышып китте, бер камышлыкка кердек, егет эшкә шөруг кыйлгач та, камыш арасыннан бер елан килеп чыкты, егет шундук биленнән кылычын суырып алды да еланны чабып өзде. Күңелендә вә әгъзасында һичбер курку галәмәте беленмәде. Эшен кямилән әда кыйлды. Әмма бу синең карендәшең эшкә шөруг кыйлгач та, өй эчендә бер тавыш булды. Бу егет аннан куркып, сеңгерләре йомшап, әгъзалары калтырап, һушсыз булды. Үлде дип куркып

качтым», — диде. Хәлифә көлде дә әйтте: «Ул егетнең бу кадәр йөрәкле булмакына сәбәп нидер, беләмесең?» — диде. Җария әйтте: «Зан галибем[1] шулдыр ки, ул егет гомерендә бер авызына кайнар тәгам капмады, кайнар нәрсә эчмәде эчемлектән. Дәхи гомерендә бер эчемлек эчкәне юк иде», — диде. Хәлифә әйтте: «Бәрәкаллаһ! Бәрәзауллаһ! Сине азат кыйлдым, бар, ул әүвәлге хуҗаңа кайт», — дип җибәрде.

---

Нәмири исемле бер куркак кемсәнә бар иде. Аның күршесе хикәят кыйлмыштыр ки: бер кичә ханәмнән Нәмиринең хәленә карап торыр идем. Күрдем, ханәсенең эчендә бер тавыш ишетеп, куркуыннан калтырап, кылычын алып: «Һи, өемезгә кергән карак, башыңа киләсе бәлане белмәдеңме? Ошбу ялк-йолк итүче ләгаб мәния ышанычлы, атлы мөсайкал ялтыратылган кылычым мәшһүр галәмдер, кулымда хәзердер. Сине гафу кыйлдым, яхшылык белән чык», — дип дер-дер калтырап, ханәсенең ишеген ачты. Күрдем ки, өеннән бер эт чыгып киткәннән соң: «Аллаһыга шөкер, әй харамзадә, эткә әверелдең, без һәм котылдык», — диде.

---

Могътәсим хәлифә беркөн ауга чыкмыш иде. Нагяһ бер арыслан заһир булып, хадимнәреннән берсенә әйтте: «Әй фәлән, синдә шул арысланны тотмага бәһадирлык бармы?» — диде. Ул хадим: «Әй әмирел-мөэминин, миннән булмас», — дигәч, хәлифә әйтте: «Һи, тавык йөрәк», — диде.

---

Искәндәрнең вәзирләреннән Искәндәр исемле бер вәзире бар иде. Ләкин җитәкче булган сугышларында һәркайсында җиңелеп кайтыр иде. Искәндәр әйтте: «Һи йөрәксез, яки бу эшеңне алыштыр, яки исемеңне алыштыр», — диде.

---

Әсләм бин Әбү Зәрга дигән бер куркак хәварижләр фитнәсендә сугышка чыкмыш иде. Хәварижләр таифәсеннән бәһадирлары Әбү Һилал дигән кемсәнә иде. Әмма Әбү Һилал тарафында бары кырык кеше, Әсләм тарафында ике меңләп гаскәр бар иде. Әсләм җиңелгәч, халык Әсләмне шелтәләделәр: «Һи, җөбен[2]», — дип зәм иттеләр. Әсләм әйтте: «Әйдә зәм итсәләр итсеннәр, хәятымда мине зәм итмәкләре мин үлгәч, мине мәдех итмәкләреннән миңа сөеклерәктер», — дип ләтыйфәгә алыштырды. Аннан соң әгәр Әсләм базарга чыкса, халык вә балалар артыннан: «Әбү Һилал килә!» — дип кычкырыр булдылар.

[1] Зан галибем — өстенлек иткән уем.
[2] Җөбен — куркак.

———

Бер сугышта җиңелгән бер куркак хорасани кемсәнә бар иде. Гаять курыкканлыгыннан, атына атланганда каушап кире атланып, ягъни атның башын койрык вә коерыгын баш санап, коерыгына җөгән киертә алмаенча: «Һи, ат түгел икәнсең, бу ни булды, маңгаең киң, ялың озын булмыш», — дип, атына хитап кыйлып, күргән адәмнәрне көлдереп, эчләрен катырмыштыр.

———

Риваять кыйлынмыштыр ки: бер кеше мөрәүвәт вә изгелек иясе бер адәмгә үзенең бер зарур хаҗәте өчен килеп, хаҗәт сорарга оялып, берәр сәгать хаҗәтен әйтмәй торды. Ул мөрәүвәт иясе зат шәриф, хаҗәт теләп килгән кешегә: «Әй син, йокладыңмыни, ни өчен хаҗәтеңне сорамайсың?» — дигәч, бу кеше дәхи: «Әй сахиб мөрәүвәт, сине уяндырган хаҗәт иясе йокламайдыр вә, кичә-көндез үзенең хаҗәтен күрмәк өчен, онытмаенча синнән хаҗәт касд итеп килгәндер. Морадына ирешмәй китмәс. Хаҗәтемне телем сиңа бәян кыйлмаса да, хәрәкәтемнән морадымны фәһем итәрсең», — дип, хаҗәтемне өмид иттем. «Мөрәүвәтең бар, шаять, мөрәүвәт вә ихсан кыйлырсың», — дип, татлы сүзләр белән җавап биргәннән соң, ул мөрәүвәт иясе аның морадыннан артык дәхи мең динар биреп, разый кыйлды.

———

Берәү бер мөрәүвәт иясенең ишеге төбенә туктап, хаҗәтен әйтмәй торганда, ул мөнгыйм[1] әйтте: «Ни хаҗәтең бар, сора?» — диде. Бу хаҗәт иясе дәрхаль: «Синең бирүче җумарт кулың минем сораучы телемнән киңрәктер вә озынрактыр», — диде. Ул мөрәүвәт иясе ул мохтаҗга мең динар ихсан белән хаҗәтен әда кыйлды.

———

Беркөн але Габбас вәзирләреннән Зүәррәясәтыйнның капкасына хаҗәт өчен күп халык җыелган вакытта: «Йә, хаҗәт белән килгән халык бик күп икән, белмәймен, мин ни эшләрмен?» — дип шикаять изһар кыйлды. Анда Ләсамә бин Әшрәс дигән кемсәнә дәрхаль: «Төш урыныңнан, мин гаһед кыйламын ки, ишегеңә берәү дә килмәс, тыныч булырсың», — диде. Ягъни вәзирлек вә рәислек бары халыкның хаҗәтен күрмәк өчендер, юкса ялгыз үзләренең файдасы вә бәхете өчен генә түгелдер.

Мәгънәсен ифадә кыйлганнан соң, инсаф белән Зүәррәясәтыйн дәхи: «Раст әйттең», — дип, ихлас күңеле белән һәрбер кешенең хаҗәтен әда кыйлып җибәрде.

———

Хәсән вә Хөсәен разыйаллаһу ганһу араларында вәҗеһсез азрак сүз вакыйг булып, хәзрәти Хөсәенгә әйттеләр: «Олуг ка-

[1] Мөнгыйм — ашатучы, аш бирүче.

рендәшенне барып разый кыйл», — диделәр. Хөсәен разыйаллаһу ганһу әйтте: «Мин бабам Рәсүлуллаһтан ишеттем ки, ике кемсәнә арасында тәмсез сүз вакыйг булып, кайсы әүвәл барып ризалык эстәсә, ул җәннәткә элгәре керер, — диде. — Шуның өчен яшьтә олуг булган карендәшемнән җәннәткә мөкаддәм кермәкне лаек түгел хисаплаганымнан, аның әүвәл килмәкене арзу кыйламын», — диде. Хәсән разыйаллаһу ганһу бу сүзне ишеткәч тә, ашыгыч хәзрәти Хөсәеннең ханәсенә килде, ризалык эстәштеләр.

---

Җәгъфәр бин Сөләйманның хадимнәреннән бере бер нәфис вә кыйммәтле җәүһәрен сиздертмичә алып, күп акчага сатмыш. Җәгъфәр ул җәүһәрнең югалганын белгәч, һәммә көмешчеләрне вә җәваһир сатучыларны тәфтиш иттереп, бер көмешчедән ул сиркаләнмеш[1] җәүһәрне таптылар. Кыяфәтенә карап, саткан кешене тәгъриф кыйлып, шул хадим саткан, имеш, дип, хадимне Җәгъфәр хозурына китерделәр. Җәгъфәр, ул хадимнең гаять курыкканын күреп, кәмаль шәфкатеннән вә хөсне холкыннан ул хадимгә: «Әй фәлән, син ни өчен куркасың? Ул җәүһәрне фәлән вакытта син миннән сораган идең, мин һәм аны сиңа һибә кыйлган идем. Ләкин хәзердә онытып, сиркаләнде, дип хыял кыйлып эзләттердем», — дип, көмешченең хадимгә биргән сәмәнен биреп, җәүһәрне хадимгә һибә кыйлды. «Ал, синең хәлял малыңдыр. Теләсәң, көмешчегә сат», — дип, хөсне холык итәгенә кыйммәтле җәүһәрне такты.

---

Хикәят кыйлынмыштыр ки: Бәһрам беркөн ау касды белән сахрага чыгып гизеп йөргәндә, бер хайван күреп, тотмак өчен артыннан китте. Хадимнәреннән аерылып, ул хайванны тота алмады. Истибра тәказасы белән[2] атыннан төшеп, бер агач астына туктады. Бер көтүчене күреп: «Мин истибра кыйлганчы, атымны тотып тор», — дип бирде.

Бәһрам истибра кыйлган вакытта, ул көтүче атның җөгәненнән алтын-көмешләрне кисеп алмага касд кыйлды. Пычак алып кисә башлады. Бәһрам, аны күрмәгәнгә салышып, көтүчене куркытмас өчен, озак истибра кыйлды. Аннан соң күзен тотып: «Әй чупан, атымны китер, күземә тузан керде», — дип, күзен тотып, атына атланып китте. Хадимнәре янына җиткәч: «Әй хадимнәр, янымда акчам юк, имеш, җөгәнемнең көмешләрен фәкыйрьләргә бирдем. Әгәр берәүдә күрсәңез, җинаятьче итмәңез», — дип тәнбиһ кыйлды.

---

Нәүширван падишаһ, үзләренең гадәтләренчә, нәүруз көнендә диванханәдә тәхет үзрә утырып, әркан дәүләт вә әгъян мәм-

---

[1] Сиркаләнмеш — урланган.
[2] Истибра тәказасы — кече йомышны үтәү өчен.

ләкәтне җыеп, алтын-көмеш савытлар вә табаклар эчендә тәгамнар, вә шәраблар, вә әнваг җимеш белән тулы алтын-көмеш белән бизәлгән ашъяулыклар җәеп, икрам вә зыяфәт кыйлганнан соң, мең мыскал алтынга торырлык бер табакны мәҗлестәге адәмнәрдән берәү, алып, киеме астына яшерде. Нәүширван моны күреп торды, һичбер дәшмәде. Зыяфәт тәмам булып, кунаклар китәр вакытта савыт-сабаны сакларга җаваплы булган бер хезмәтче, савытларны санап караса, бер савыт юк булганын белеп, олуг тавыш белән: «Бер савыт югалды, тәфтиш кыйлмаенча, диванханәдән берәү дә чыкмасын!» — дип нида кыйлды. Нәүширван, моны ишетеп, ул хадимгә әйтте: «Ул савытны оятыннан кайтарып бирә алмай торган кеше алды, алганын күргән кеше дәхи әләкче түгелдер, тентемә», — диде.

Ул савытны алган кеше, сатып, бәһасенә кәмәр алды, вә нәфис киемнәр тектерде, вә кылычын зиннәтләде. Бервакыт Нәүширван, бу кәйфияттә күргәннән соң, аны чакыртып: «Бу зиннәтләр шул җөмләдәнмедер?» — дип, киная белән ишарәт кыйлды. Ул кеше, йөзен җиргә сөреп: «Йә мәлик, синең саяңдә», — дип дога кыйла башлады. Нәүширван гаять җумарт вә гаделлегеннән вә хөсне холкыннан аны гафу кыйлды.

---

Габдулла бин Таһир димештер ки: «Беркөн Мәэмүн хәлифәнең хозурында идем. Хәлифә хадимнәренең берсенә «әй голям[1]» дип кычкырганда, бер төрки егет килеп, чытык йөз белән: «Һәркайчан яныңнан китсәк, тышка чыксак, «әй голям, әй голям» дип кычкырасың, голямнарың ашамасынмы, эчмәсенме? Нигә чаклы «әй голям» дип кычкырасың?» — дип, әдәпсезлек кыйлганда, хәлифә, бер сүз димәенчә, башын түбән салып, бераз фикергә барды. Мин, бу хәлне күреп: «Инде бу голямның башын киселсен», — дип әмер итмәкендә шөбһәм калмады. Шул вакыт хәлифә, миңа хитап кыйлып: «Әй Габдулла, әхлак хәсәнә ияләренең хезмәтчеләре әхлак сүийә[2] белән мөтәссыйф булырлар. Явыз холыклы булган әфәнденең йомышчылары әхлак хәсәнә иясе булырлар. Мин, хезмәтчеләремнең холыклары күркәм булсын дип, үземнең явыз холыклы булмавымны теләмәймен», — дип, голямны гафу кыйлды», — димештер.

---

Әхлак Хәмидә белән мәшһүр Әхнәф бин Кайстан сөаль кыйлдылар: «Бу кадәр күркәм холыкны кемнән үгрәндең?» — диделәр. Әхнәф әйтте: «Кайс бин Гасыймнан үгрәндем. Беркөн ханәсенә бармыш идем. Бергә утырыр идек, ашчы кәбаб китергәндә, кәбабның шеше бер имчәк баласы өстенә төшеп, дәрхаль бала җан-тәслим кыйлды. Бу ашчыга гаять курку төшеп,

---

[1] Голям — йомышчы малай.
[2] Әхлак сүийә — начар әхлак.

калтырап хәйран булып торганда: «Курыкма, эш Алла хөкеменнән башка булмай. Сине бу көн азат иттем», — дип, ул колның хатасы дәрәҗәсендә ихсан белән мәҗазат кыйлды», — диде.

———

Ибн Гомәр разыйаллаһу ганһу колларыннан берәвенең тәгъдил әркан белән намаз укыганын күрсә, дәрхаль азат итәр, имеш. Бәс, коллары бу хәлне белгәч, намаз укымай торганнары да рияланып, ибн Гомәр күрердәй җирдә намаз укырлар вә азат кыйлыныйрлар, имеш.

Беркөн ибн Гомәр разыйаллаһу ганһуга әйттеләр: «Әфәндем, ихлас белән укыганнарын азат кыйлсаң да, җирендәдер. Әмма мөраиларын[1] азат кыйлмавынызга сәбәп нидер?» — диделәр. Ибн Гомәр әйтте: «Бер кемсәнә Аллаһы Тәгаләгә итагатьтә вә гыйбадәттә миңа хәйлә кыйлса, ул кемсәнәгә алдатмакта ни зарар бардыр, бәлки, фәкать файдадыр», — диде.

———

Әбү Госман дигән бер заһид бер эссе көндә шәһәр эчендә урамнардан барганда, өстенә бер өйдән тулы бер ләгән көл түктеләр. Янындагы адәмнәр ул кешегә тел озатып орыша башлаганда, Әбү Госман аларны мәныг итеп: «Тимәңез, өстенә ут түкмәгә мөстәхак булган кемсәнәнең өстенә көл түксәләр, орышмак җаиз түгелдер», — диде.

———

Гали разыйаллаһу ганһу беркөн бер колына өч мәртәбә: «Йә голям», — дип кычкырды. Голям җавап бирмәгәч, торып, голямның янына барды. Голям ятып торыр иде, әйтте: «Әй голям, кычкырганымны ишетмәденме?» Голям әйтте: «Бәли, ишеттем». Гали разыйаллаһу ганһу әйтте: «Ишеткән булсаң, иҗабәт[2] лазем түгелме?» — диде. Голям әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, җәнабыңызның йомшаклыгы вә хөсне холкы сәбәпле, шелтәләвегездән имин булганым өчен, ялкаулык кыйлып җавап бирмәдем», — диде. Гали разыйаллаһу ганһу ул колның әдәпсезлегенә каршы: «Сине ливәҗһиллаһи, азат кыйлдым», — дип икрам кыйлып, азат кыйлды.

———

Мәзкүр Әбү Госман заһидны бер кеше ханәсенә зыяфәткә дәгъвәт кыйлды. Ханәсенең капкасына җиткәч, Әбү Госманга әйтте: «Йә остаз, ханәмә кермәкеңдә минем өчен файда юктыр, кайтып кит!» — диде. Әбү Госман кайтып, үзенең мәкаменә якын җиткәндә, янә артыннан барып: «Йә остаз, бу ярамаган эшемә үкендем. Әйдә кайт, сине зыяфәт кыйлаем», — дип, Әбү Госманны янә ханәсенә китерде. Капкасына җиткәч, янә әү-

[1] **Мөраиларын** — күз буяучыларын, яхшылыкны кешегә күрсәтү өчен генә эшләүчеләрен.

[2] **Иҗабәт** — колак салу.

вәлге кебек әйтте. Хасыйле кәлям, дүрт мәртәбә шөйлә алдады. Әбү Госман асла рәнҗемәенчә килде, китте. Ахыр ул кемсәнә Әбү Госманның кулын үбеп, меңнәрчә тәкрим вә тәгъзыйм белән: «Максудым җәнабеңезнең әхлак хәсәнәсен тәҗрибә кыйлмак иде», — дип, мәдех вә сәна кыйлды. Әбү Госман әйтте: «Әй кеше, эттә булган табигать белән вә эттә булган холык белән адәм мәдехкә лаек булмас. Бу сыйфат эттә дә бардыр. Зирә эт, ничә мәртәбә чакырылса да, килер, кугач — китәр», — диде.

---

Ошбу хикәят дәхи мәхасин әхлактандыр ки, Яхъя бин Әксәм риваять кыйлмыштыр. «Бер кичә Мәэмүн хәлифәнең өендә идек. Мин яткан идем, ләкин йокым килмәгәнлектән, йоклаган сыйфатта булып ятыр идем. Хәлифәнең су эчмәгә теләге булып, мине уяныр дип, хадимнәренә кычкырмаенча, үзе, акрын гына урыныннан торып, су савыты янына өч йөз адым микъдар җиргә барып су эчте. Су эчеп килгәндә, мин яткан җирдән аякларының очы белән генә басып, урынына килеп, берничә мөддәт утыргач, кичәнең ахырында тормак гадәт хәсәнәсе булмак җәһәтеннән хезмәтчеләренә кычкырмаенча, минем уянуымны бер заман көтеп торды.

Инде болай булгач, мин һәм урынымда йокымнан уянган кебек булып кыймылдадым. Аннан соң Мәэмүн, урыныннан торып, хадимнәрен чакырып, таһарәт алырга су сорады, таһарәт алды. Бәгъдә[1] яныма килеп, миңа көньям[2] белән: «Йә Әбү Мөхәммәд, яхшы йокладыңмы, ял иттеңме?» — дип сорады. Мин дәхи: «Әй әмирел-мөэминин, вөҗүдем сиңа фида булсын, саяңдә ял иттем, Аллаһы разый булсын», — дип тәшәккер иттем. Аннан соң Мәэмүн әйтте: «Әй Әбү Мөхәммәд, торыр вакытым булса да, син уяныр дип, хадимнәремә кычкырмадым, сабыр иттем», — диде. Мин әйттем: «Әй әмирел-мөэминин, Аллаһы Тәгалә сезләргә пәйгамбәрләр холкын вә пәйгамбәрләр сирәтен[3] ихсан кыйлмыш. Вә бу нигъмәт белән сине махсус шундый холыклы итмеш, Хак Тәгалә бу нигъмәтеңезне мөбарәк итеп, сәгадәт дарәенләреңезгә ике дөнья бәхетләрегезгә васыйл иткәй иде», — дип, дога кыйлганымнан соң, мең данә алтын ихсан кыйлды. Күңел сафлыгы белән алып кайттым», — димештер.

Вә янә мәзкүр Яхъя бин Әксәм хикәят кыйлмыштыр: «Беркөн Мәэмүн хәлифәнең ханәсендә кич йоклаган заманымда, хәлифәгә ютәл гарыз булып, мин уянмасын дип, җиңе белән

---

[1] Бәгъдә — шуннан соң.

[2] Көньям — кушаматым. Әбү, ибн сүзләренең берсен кушып ясалган ялгызлык исеме кушаматлары янсә атасының исеме белән әйтү.

[3] Сирәтен — табигатен.

авызын тотып йөткерер. Алай да ютәлен тыя алмагач, тавышым чыкмасын дип, авызын җиргә куеп йөткерер иде.

Мәэмүн хәлифә беркөн Хәсән бин Сәһелгә әйтте: «Йә Хәсән, мин дөнья ләззәтләренең һәрберсен күрдем, җиде нәрсәдән гайрене ялыктыргыч дан таптым», — диде. Хәсән әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, ул ни-нәрсәләрдер?» Мәэмүн әйтте: «Бодай икмәге, куй ите, салкын су, йомшак вә мөлаем кием, хуш ис, йомшак түшәк», — диде. Хәсән бин Сәһел әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, дуслык вә җан дуслыкны санамадыңыз. Янә ләззәтлерәк булыр иде», — диде. Хәлифә әйтте: «Әй Хәсән, бик яхшы сүз әйттең, вакыйган, бу барчасыннан артыграктыр», — диде.

———

Ибн Сәмәктән сөаль кыйлдылар: «Кай кемсәнәнең дуслыгы вә мәхәббәте садыйк вә даимдер?» — диделәр. Ибн Сәмәк әйтте: «Шундаен кеше дуслыкка ярар ки, диянәтендә тугрылыклыкта булыр. Гакылында кәмаль булыр. Сиңа якын булганда, борчу китермәс. Синнән ерак булганда, сине онытмас. Якын булсаң, ул дәхи якын булыр, ерак булсаң да, сиңа ригая кыйлыр. Ярдәм эстәгән заманыңда сиңа ярдәм кыйлыр. Мохтаҗ булганда, хаҗәтеңне әда кыйлыр. Вә фигыльендә булган дуслыгыннан күңелендә булган дуслыгы күбрәк булыр», — диде.

———

Бер кеше пәйгамбәр галәйһиссәламгә килеп, пәйгамбәр галәйһиссәламнең мәһабәт нөбүвәтеннән тезләре калтырап торыр иде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Әй кеше, курыкма, мин падишаһ түгелмен. Бары коры-сары гына ашаучы Корәеш кабиләсеннән бер хатынның углымын», — дип, тәвазыйг бабында энҗеләр ыргытмыштыр.

———

Гарәп кабиләләреннән Мотарраф бин Габдулла, йоннан тукылмыш хәшен вә тупас кием киеп, фәкыйрьләр вә мескиннәр белән аралашыр, иде. «Ник бу эшкә тырышлык кыйласың?» — дисәләр, «Атам мөтәкәббир вә җәбир иде, Аллаһы Тәгалә өчен тәвазыйглык кыйламын. Фазылы вә рәхмәте белән атамның тәкәбберлеге вә тәҗәбберлеге сәбәпле, лаек вә мөстәхак булган газабы җиңеләйсен дип», — диер иде.

Ошбу Гали кәрәмәллаһу вәҗһенең кәляменнәндер ки: әй егет, һәр мәртәбәдә вә һәрвакытта, ягъни сөрүр вә шатлык вакытларында вә мөкаддәр вакытларында олыга-кечегә тәвазыйглык кыйл. Зирәки туфракның туфрактан артыклыгы юктыр. Филхәкыйкать, бай-фәкыйрь, олуг-кечек асылда бер-беренә бәрабәрләрдер. Мин — бай, син — фәкыйрь, мин — олуг, син — кече, дип, фәхерләнмәгә вә һаваланмага урын юктыр, димәктер.

———

Мәһләбнең әүладыннан бере мөтәкәббирләр сыйфатында йөрер иде. Малик бин Динар бу егеткә очрап, нәсыйхәт йөзен-

нән: «Әй углым, бу тәкәбберлек сыйфатын куйсаң, үзеңә гүзәл эш итмеш булыр идең», — диде. Ул егет Малик бин Динарга, рыйзасызланып: «Син мине танымаймысың?» — диде. Малик әйтте: «Һай-һай матур егет, бик беләмен: әүвәлең бер катрә нәҗес мәни суыдыр, ахырың нәҗес үләксәдер. Син ошбу ике халәт арасында өч көнлек дөньяда тизәк савыты күтәреп йөргүчесең», — диде.

Дәрхаль бу егет, ибн Динарның җәүһәр белән бәрабәр хас нәсыйхәте әсәр итеп, явыз холыклардан тыелды.

———

Гарәп арасында, җәзимә таифәсе диерләр, бер таифә бар иде, зиядә мөтәкәббирләр иде. Гарәпләр бер мөтәкәббир кешене күрсәләр, «җәзимә кебек», диерләр иде.

———

Вә дәхи гарәпнең олугларыннан ибн Сәвабә дигән кемсәнә зиядә мөтәкәббир икән, хезмәтчесенә: «Су китер», — дип хитап кыйлганда, хезмәтчесе: «Аш булсын», — дип, су китереп бирде. «Син кем буласың, миңа аш булсын, дип әйтәсең? Зирә «әйе» дип миңа «юк» дип әйтмәгә кадир булган кеше генә әйтә белер», — дип, хезмәтчесен суктырды.

Мәзкүр ибн Сәвабә дәхи бервакытны бер кемсәнә белән мөсахәбәт вә мөкяләмә кыйлды. «Һи, шул дәни адәм белән сөйләшеп, авызымны былчыраттым», — дип, су китертеп, авызын чайкады.

———

Бәни Габдеддар кабиләсеннән бер кемсәнәгә: «Ни өчен хәлифә хозурына бармайсың?» — диделәр. Ул кемсәнә әйтте: «Куркамын ки, юлдагы күпер минем шәрәфемне күтәрә алмас», — диде.

———

Мөтәкәббирләрдән Хәҗҗаҗ бин Әртат дигән кемсәнәгә әйттеләр: «Ни өчен җәмәгать намазына бармайсың?» Хәҗҗаҗ әйтте: «Вак-төяк халык миңа тыгызлык итәр дип куркып бармаймын», — диде.

———

Мөсавир бин Һинд дигән кеше тәкәбберлек белән мәшһүр иде. Бер мөнәсәбәт белән бер кешегә әйтте: «Мине танымаймысың?» — диде. Ул кеше әйтте: «Юк, танымаймын», — диде. Ул мөтәкәббир: «Мин Мөсавир бин Һинд ләбаса», — дигәч тә, бу кеше вакыйган, белмәенчә яки аңсыздан: «Юк танымаймын сине», — диде. Әмма бу ул мөтәкәббирнең тәкәбберлегенә тиеп: «Күктә мәшһүр булган айны белмәгән кешенең муены астына килсен! Йөзтүбән төшсен!» — дип, үзенең олуглыгын дәгъва кыйлмыштыр.

———

Әсмәгый димештер ки: «Бер кичә бәйт Кәгъбәне таваф иткәндә, бер егет күрдем, эстәр, Кәгъбәгә ябышып мөнәҗәт әй-

теп. Аннан соң ошбу мөнәҗәтне инша кыйлып, тетрәнү зоһуры белән һушы китеп егылды. Мин дәхи дәрхаль янына бардым. Күрдем ки, Зәйнелгабидин Гали бин Хөсәен бин Гали разыйаллаһу ганһу пәйгамбәр правнугы, имеш. Дәрхаль мөбарәк башын җирдән күтәреп кочагыма алдым. Еглададым, мөбарәк йөзенә бер тамчы яшем тамды. Һушына килеп, күзен ачып карап: «Бу кемдер? Бу кешене кем кушты ки, безгә билә кыйлды?» — димеш иде. Мин әйттем: «Йә сәедем вә әфәндем, мин Әсмәгый колындыр. Бу егъламакың нидер ки, сезләр әһел бәйтсез вә мәгъдән рисаләтеннән бер парә пакь гәүһәрсез, хакыңызда Аллаһы Тәгалә боермыштыр», — дидем. Зәйнелгабидин хәзрәтләре кәмаль тәвазыйгыннан: «Һәйһат, йә Әсмәгый, Аллаһы Тәгалә җәннәтне итагать вә инкыяд баш иючеләре кыйлганнар өчен яратты. Буйсынучы вә мохтаҗ булганнар, нәсәб иясе булмасалар да, хәтта хәбәши кол булсалар да, җәннәткә керерләр. Алла сакласын, Хак Тәгалә җәһәннәмне ялгыш юлдагылар вә гөнаһлылар өчен халк итте. Фәхер вә мактану фәкать тәкъвалык белән генә булмагына ишарәттер. Мәзкүр мөнәҗәтнең эчтәлеге, мәгънәсе ошбудыр: кичә караңгылыгында кыен хәлдәгеләр догасын кабул итүче, зарар вә бәлаларне чишүче вә авыруларга шифа бирүче, әй Бар Ходая, бәйт Кәгъбәнең әтрафына килгән бәндәләр йоклап уяндылар. Хәлбуки син, әй Хәйй вә Каюм, йокыдан ерак, йа Рабби, мин хәйран вә көенечле булганым хәлдә, синнән йомшаклык өмид итәмен ки, бәйт Кәгъбә хөрмәтенә егъламакым өчен мина мәрхәмәт ит. Әгәр әшәкеләр вә гөнаһлылар синең юмартлыгыңны вә кәрәмеңне риҗа итмәсәләр, гөнаһлыларга кем кәрәм белән җумартлык итәр? Вә дәхи, әй һәр хаҗәттә максуд булгучы Аллаһы Тәгалә, сиңа нәфес вә шайтанның зарарыннан шикаять итәмен: минем ниязыма мәрхәмәт кыйл, вә якынлыгымны дәфыг аклап вә гөнаһымны багышлап, хаҗәтемне кабул кыйл. Мин дәргяһыңа яман вә кабахәт гамәлләр белән килдем. Вә халык эчендә минем җинаятем кебек вә минем кабахәтем кебек җинаять вә кабахәт иткән кеше юктыр. Әй соңгы максудым, ут белән мине яндырырмысың? Әгәр яндырсаң, хәвефем вә өмидем кайда калыр?». Ягъни: вәгъдәң икътизасынча[1] гафу итәрсең, димәктер.

---

Шагыйрьләрдән Җәрир белән Фәрәздак Сөләйман бин Габделмәлик хозурында мактаныштылар. Фәрәздак әйтте: «Мин үлекләрне тергезә торган кешенең углымын», — диде. Бу сүзнең ачык инкяр ителерлек булмак җәһәтеннән Сөләйман Фәрәздакны кире какты. Фәрәздак әйтте: «Минем атам дәхи ничә һәлак булачак кемсәнәләрне һәлаклектән хәлас вә котыл-

[1] Вәгъдәң икътизасынча — вәгъдәң кушуынча.

макларына сәбәп булмыштыр», — дип, берәүне бәян кыйлды. Вакыйга Фәрәздакның атасы бу сыйфат белән гарәп арасында мәшһүр, имеш. Аннан соң Сөләйман: «Әй Фәрәздак, син шагыйрь һәм галим, имешсең», — дип тәхсин кыйлды.

---

Хәким бин Габдерахман Әндәлестән Мисыр валисенә мактанып язды. Мәгънәсе: без шундаен бәни Мәрван түгелме ки, дәвер вә заманаларны вә илләрне кулымызда буйсындырып, яулап, бер хәлдән икенче хәлгә алмаштырдык. Кабиләмездән бер бала дөньяга килсә, җир үкерәдер вә манаралар селкенәдер, димәктер.

---

Холәфаи Габбасиядән Әбү әл-Габбас хәлифәнең, нәфис сүз осталарын вә шагыйрьләрне җыеп, шигырь әйттермәк вә бәхәс кыйлыштырмак гадәте бар иде. Бер кичә мәҗлесендә Ибраһим бин Мәхзәмә белән Халид бин Сафуан кыйсса вә тәварихтан мөкаләмә кыйлып утырганда, сүзләре Мисыр кабиләсенә вә Ямән әһеленә барып җитте. Мәзкүр Ибраһим үзе ямәни булмак җәһәтеннән Ямән әһелен мактап: «Әй әмирел-мөэминин, әһле Ямән-гарәптән бер шәриф таифәдер. Дөнья аларга буйсынып, атадан-бабадан падишаһлык аларга мирас кала килгәндер. Һаман алардан падишаһлык юкка чыкканы юктыр. Мәсәлән, Ногман бин Мөнзәр вә Гаяз вә гайреләре мәлик Ямәннәндер. Никадәр өстенлек вә шан бар булса, Ямән әһелендә барчасы мәүҗүддер. Ингам-ихсан кыйлырлар. Мөсафирларны кунак итәрләр. Алар асыл гарәплә рдер, башка гарәпләр гарәп мөтәгарәбәләрдер, ягъни асыл гарәп түгелләрдер», — дип, Ямәнне мактады. Аннан соң аларны бер-бере белән бәйләндермәк өчен: «Әй Ибраһим, алай булса, син бу сүзең белән Халидне ирадә кыйлдың», — дип, Халидкә ишарәт кыйлды. Халид әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, сүзгә изен вә рөхсәт бирсәнез, мин һәм үз тарафымнан сөйләшәем», — диде. Хәлифә әйтте: «Рөхсәт, сөйләш», — диде. Бәс, Халид әйтте: «Иптәшем, ягъни Ибраһим, җәһелгә мөкарин булмак җәһәтеннән ялгыш сөйләде. Аларда Коръәнне вә хәдисне белгән фәсыйх тел вә сахих лөгать булмаса, аның бәян иткән мәдехе ничек аларга гына дәлилсез булыр. Әгәр алар Ногман белән вә Мөнзәр белән мактансалар, безләр дәхи хәйреләнам Мөхәммәд галәйһиссәлам белән мактана белермез. Аллаһы Тәгалә рәхмәтелгаләмин булгучы зат әшрәфне пәйгамбәр вәкил итмәк белән безләргә вә аларга ингам вә ихсанны төгәлләде, ул пәйгамбәр — бездәндер. Бәйт мәгъмүр, зәмзәм шәриф, хәтим, күрсәтмә бирүче зат, мәкам Ибраһим, Мәккәдә хәҗәр әсвад бәтаха, ягъни Мәккә безләрдәдер. Әбү Бәкер, Гомәр, Госман, Гали вә шәһид киткән Хөсәен, вә Хәсән, вә Хәмзә разыйаллаһу ганһу безләрдәндер. Әй ямәниләр вә барча халык, сезләр динне безләрдән үгрәнденез! Без-

ләргә мәхәббәт вә шәфкать иткәннәргә безләр һәм мәрхәмәт вә шәфкать итәмез. Вә дошманлык изһар кыйлганнарның асылын корытырмыз», — дип, Ибраһимга тәвәҗҗеһ юнәлтеп кыйлып: «Әй Ибраһим, кавеменнең лөгатен белермесен?» — диде. Ибраһим әйтте: «Бәли, белермен». Халид әйтте: «Ямән лөгатендә гайннең, ягъни күзнең, исеме нидер?» Ибраһим әйтте: «Җәмҗәмәдер». Халид әйтте: «Синнең, ягъни тешнең, исеме нидер?» Ибраһим әйтте: «Мөбдәндер». Халид әйтте: «Өзен, ягъни колакның, исеме нидер?» Ибраһим әйтте: «Санарәдер». Халид әйтте: «Әсабигъның, ягъни бармакларның, исеме нидер?» Ибраһим әйтте: «Шөнабирдер». Халид әйтте: «Зиәбнен, ягъни бүренең, исеме нидер?» Ибраһим әйтте: «Кәныгдыр», — диде. «Йә Ибраһим, Аллаһы Тәгаләнең иңдергән китабын белермесең?» — диде. Ибраһим әйтте: «Бәли, белермен ки, Коръәндер».

Янә Ибраһимны артыграк җавапсыз калдыру касды белән: «Әй Ибраһим, янә дүрт нәрсә сөаль кыйлырмын, игътираф вә икърар кыйлсаң, җавапсыз булырсың. Инкяр кыйлсаң, кяфер булырсың», — диде. Ибраһим әйтте: «Сөаль кыйл». Халид әйтте: «Әфза Рәсүл булучы пәйгамбәремез галәйһи әссалате вәссәлам сездәнме, юкса бездәнме?» Ибраһим әйтте: «Сездәндер». Халид әйтте: «Коръән газыйм сезнең телеңез үзрәме, юкса безнең телемез үзрәме иңдерелде?» Ибраһим әйтте: «Сезнең лөгатенезчә иңдерелде?» Халид әйтте: «Мөнбәр Рәсүл вә бәйт Мөкәррәм бездәме, юкса сездәме?» Ибраһим әйтте: «Сездәдер», — диде. Аннан соң Халид әйтте: «Әй Ибраһим, безгә шулар җитәр. Бар, кит, торма. Болардан башка никадәр нәрсә бар исә — ал, сезгә булсын. Сезгә бары калды: маймун тәрбия кыйлмак, тире иләмәк, бүз тукымак, тау казымак», — дип, Ибраһимны өнсез кыйлды. Хәлифә дәхи, канәгать вә шат булып вә гаять көлеп, икесенә дәхи икрам там кыйлды.

———

Риваять кыйлынмыштыр ки: Хөсәен разыйаллаһу ганһу беркөн Язид белән очрашып, Язид, без алай, без болай, дип мактанып торганда, Хөсәен разыйаллаһу ганһу колак салып тыңлап торды. Ул хәлдә азан вакыты булып, азанда Хөсәен әйтте: «Әй Язид, бу зат кемнең бабасыдыр?» — диде. Язид, һичбер сүз димәенчә, аптырап калды.

———

Бер фәкыйрь хәлдә бик мактанчык кемсәнә бар иде. Һәркөн авызын, мыегын майлап, халык арасына чыгып, мактанып: «Әлхәмделлилаһ, өс-баш ул кадәр төзек булмаса да, ашау-эчүемез яхшы: һәркөн кәбаб та мәбаб, тавык ите. Күп вакытны пылау ашыймыз», — дип, мыекларын сыпырып, тешен казып утырганда, бер кечкенә кызы килеп: «Әти, кашыктагы авызмыек майлый торган маеңны мәче ашады», — диде.

Шәгъбине бер ахмак хурлады. Шәгъби сабыр кыйлып торды да әйтте: «Әгәр син бу хосуста ялганчы булсаң, Аллаһы Тәгалә гафу кыйлсын. Әгәр мин тугыры булсам, Аллаһы Тәгалә мине гафу кыйлсын», — диде.

Искәндәргә әйттеләр: «Фәлән кеше синең кызыңны сәвәдер, аны үтермәк лазем», — диделәр. Искәндәр әйтте: «Әгәр без сәүгән кешене дә үтерсәк, дошманны да үтерсәк, җир йөзендә берәү дә калмас», — диде.

Берәү бер оятсыз вә хәясыз кешегә әйтте: «Әгәр йөзеңнең тиресе миндә бер кисәк булса иде, аннан атыма тояк ясап куяр идем», — диде.

Беркөн Һарун әр-Рәшитнең хатыны Зөбәйдә Мәэмүнгә әйтте: «Атаңа карышканым мине бу көн болай кыйлды», — диде. Ягъни: беркөн Һарун әр-Рәшит Зәбәйдәгә мөҗамәгать кыйлмакчы булды. Зөбәйдә карышты, мәныг кыйлды. Аннан китеп, бер кара җариясенә мөҗамәгать кыйлды. Ул җариядән Мәэмүн тугды. Ягъни Зәбәйдә ошбу кыйссага ишарәт кыйлды.

Нәүширванга әйттеләр: «Кеше көче җиткән авыр нәрсәне күтәрә, никадәр авыр булса да. Әмма авыр холыклы кешенең мәҗлесен кеше күтәралмый. Бу нидән болай?» — диделәр. Нәүширван әйтте: «Кеше авыр нәрсәне бөтен әгъзасы белән күтәрә. Әмма авыр мәҗлесне җаны гына күтәрәдер», — диде.
Бер авыр кеше Шәгъбигә авыруның хәлен белергә килде. Бик озак утырды, әйтте: «Бу авыруың эчендә ни катылыклар күрдең?» — диде. Шәгъби әйтте: «Синең утыруыңнан авыр нәрсә күрмәдем», — диде.

Бер кеше өй түбәсеннән егылды. Ике аягы да сынды. Гыядәткә килгән халык бик күп булды. Бу кеше тарыкты да, бу кыйссаны бер кәгазьгә язды. Берәү килеп хәлен сораса, шул кәгазьне күрсәтер булды.

Бер авыр кеше бер авыруга әйтте: «Нәфесең ни тели?» — диде. Авыру әйтте: «Сине күрмәмәкне тели», — диде.

Әмир Исмәгыйль Саманига бер галим килеп, Исмәгыйль ул галимне гаять икрам кыйлды вә галим алдында тәвазыйглык вә әдәп белән торды. Вә киткәндә, җиде адым озатып калды.
Бәгъзеләр бу эшенә шелтә ишеп кыйлдылар: «Бик кечелек кыйлдың», — диделәр. Самани әйтте: «Галимнәрне икрам кыйлмак — безләргә важиб эштер», — диде. Самани шул кичәдә

пәйгамбәр галәйһиссәламне төшендә күрде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Йә Исмәгыйль, Аллаһы Тәгалә ул җиде адымың белән җиде углына җиде мәмләкәт бирде», — диде.

———

Мөхәммәд бин Хәсән әл-Шәйбани хәзрәтләре беркөн Һарун әр-Рәшиткә килде. Һарун гаять тәгъзыйм вә тәкрим кыйлды. Һарунның зур дәрәҗәле ишләре үзара сөйләштеләр: «Һарун болай булса, мәһабәте калмас, берәү дә курыкмас булыр», — диделәр. Һарун әйтте: «Голямага тәвазыйглык сәбәпле киткән мәһабәт китәргә тиеш», — диде.

———

Гайшә разыйаллаһу ганһага бер кеше әйтте: «Кайчан мин изге булырмын икән?» — диде. Гайшә разыйаллаһу ганһа әйтте: «Кайчан үзеңне мин явыз дип танысаң, шул вакыт син изге», — диде. Янә ул кеше әйтте: «Кайчан мин явыз булырмын?» — диде. Гайшә разыйаллаһу ганһа әйтте: «Мин изге дип үзеңә соклануың булса, шул вакытта син явыз», — диде.

———

Бер хәкимнән сорадылар: «Картларның хәле ничектер? Яшьләрдән бигрәк дөньяга хирыслык итәрләр». Хәким җавап бирде: «Картлар егетләрнең һаман татымаган дөнья ләззәтләрен алардан элек татыганнары өчен хирыс булырлар», — диде.

———

Бер хирыс димештер ки: «Башымда сачым агарды, замана һәнүз картаймаган икән, мин картайдым, максудыма ирешә алмадым. Тәхкыйк белдем ки, дөньяга хирыс булган кеше даим мәшәкатьтәдер», — димештер.

Искәндәрдән сөаль кыйлдылар: «Дөньяның шатлыгы ни-нәрсәдер?» — диделәр. Искәндәр әйтте: «Тапкан ризыгыңа канәгать кыйлмак», — диде. «Дөньяның кайгысы вә хәсрәте ни-нәрсәдер?» — диделәр. Искәндәр әйтте: «Хирыстыр вә тамыгдыр».

———

Әмма вәгъдәгә вафа кыйлмак хосусында гаҗәиб вә гарәиб хикәятләрдән берсе — Хәлми кабиләсеннән бер кеше белән Ногман бин Мөнзәрнең нәдимнәреннән Шәрик исемле кешенең арасында булган хикәяттер. Ул хикәятнең кыскасы будыр: мәзкүр Ногман гарәп падишаһларыннан бер мәгъруф падишаһ иде. Бер көнне габүс, бер көнне нигъмәт көне, берсенә — бәхетсезлек, бәла көнен, берсенә — муллык, киң тормыш көне, дип ат куймыш иде. Бәхетсезлек көнендә раст килгән кешене үтертер иде. Вә муллык көнендә раст килгән кешегә ингам-ихсан кыйлыр иде. Мәзкүр хәлми кабиләсеннән Таи дигән кеше, берзаман фәкыйрьлеккә төшеп, әһел вә әүладының нәфәкасе өчен чыгып, юлда саилчелек кыйлыбрак, Ногманның дәргяһенә килде.

Шәһәргә кергәч, Ногманның үзенә раст килеп, мәгәр бәхетсезлек көне, имеш, бичара Таи үзенен мәкътүл булачагын җәз-

ман белеп: «Әй мәлик, берничә ач вә ялангач вак балаларым вә әһел гыялем бардыр, аларга нәфәкалек хасыйл итмәк өчен, йөз суымны түгеп, чарасыз саилчелек кыйлып, бу тарафка килдем. Кара бәхетем мине мәликнең бу чытык көнендә дәргяһенә сөрде. Әһел гыялем дәхи бу тарафтан ерак түгелдер. Һәлаккә кариб булмышлар. Мине кател кыйлдырмакта көннең әүвәле белән ахыры бәрабәрдер: мәлик хәзрәтләре рөхсәт боерсын ки, бу хасыйл иткән нәфәкалекне аларга илтеп бирәем. Кабиләмә барып, Аллаһы өчен, җәмәгатемне ташламаңыз, дип васыять әйтәем. Аннан соң килеп, падишаһка, әмерен үтәү өчен, үземне тапшырырмын», — диде.

Бәс, ул Ногманның күңеленә йомшаклык килеп, бераз фикердә торса да, үзенең батыйль гадәтенә үзрә сабит[1] булмакыннан: «Әгәр бу Таи качса, аның урынына кател кыйлынмак өчен Хәлми кабиләсеннән бер кәфил[2] өстәде. Ногманның нәдиме мәзкүр Шәрик дәхи мәлик янында иде, бәс, Таи Шәриккә карап шигырь укыды. Мәгънәсе: әй Шәрик бин Гади, мин кателдән качмыйм, курыкмыйм. Ләкин ничә көннәр тәгам татымактан мәхрүм калган гыялем бар. Вә, ачлык дәртенә төшеп, мине көтеп торучы зәгыйфь гыялемә вә балаларыма миннәт вә ихсан кыйл. Әй нәдим, син кәримнәр нәселеннәнсең. Миңа заман вә ышану белән кәрәм юмартлык кыйл. Аллаһы Тәгалә гуаһ булсын: ахшамнан әүвәл кайтып килермен, ягъни бу көн кояш баеганчы килеп җитәрмен, димәктер.

Кайчан ки мәзкүр Шәрик бу шигырьне ишеткәннән соң: «Йә мәлик, мин зиммә[3] вә кәфилмен: бу бичара җәмәгате белән ризалашып килсен», — дигәч, Ногман, кабул итеп, Таига изен бирде. Таи дәхи дәрхаль гыяле тарафына ашыкты. Бәс, Таи китеп, бераз заман кичкәннән соң, Ногман әйтте: «Йә Шәрик, инде көн үтте, Таи килмәде», — диде. Шәрик әйтте: «Тәмам ахшам җитмәенчә, мәликнең минем үзәремә хөкеме йөремәс», — дип, вакыт сорады. Бәс, ахшам якын килде, Таи һаман юк. Ногман әйтте: «Йә Шәрик, вакыт җитте, үлемгә хәзер бул», — диде. Шәрик һәм ахыр: «Мөкаддәр язылган килә», — дип, үлемгә хәзерләнмәктә икән, ерактан бер кеше күренде. Шәрик әйтте: «Өмидтер ки, бу килгән кеше Таи булырга кирәк. Ул кеше килеп житкәнче мөһләт боерыңыз», — дип торганда, Таи килеп җитте. Әйтте: «Ахшамгача барып җитә алмам дип курыккан идем, хәзер кояш баемаган әле», — дип, вафа мәйданында каим булып[4] кателгә мөнтәзыйр булып торды. Ногман, бу әхвәлне күреп, гаҗәпләнү дәрьясына талды. Күп уйдан соң

---

[1] Сабит — тотрыклы, шиксез.
[2] Кәфил — берәү өчен җаваплылыкны үз өстенә алучы.
[3] Зиммә — бер эшне үз өстенә алу.
[4] Каим булып — сүздә нык торып.

башын күтәреп: «Аллаһ белер ки, сезләрдән гаҗәбрәк нәрсә күрмәдем. Әмма син, әй Таи, дөньяда берәүгә дә вафа мәйданында торачак җир куймадың. Вә әмма син, әй Шәрик, бер кәримгә дә кәрәмлек белән зикер кыйлыначак әсәр калдырмадыгыз. Вафада — Таи, кәрәмдә Шәриктән гайре адәм зикер кыйлынмаса кирәк. Хәйф ки, мин сезгә өченчегез була алмай, бары мин һәм Таиның вафасыны вә Шәрикнең кәрәмене тәкриман, «бәхетсезлек» көнен халыктан күтәреп, гадәтемне бетердем», — дигәч, Таи нәзым әйтте. Мәгънәсе: әй мәлик, хозурыңнан гаһедләшеп киткәнемнән соң, кабиләм мәие хилафка[1] дәгъвәт кыйлып, китмә, диделәр исә дә, мин аларның сүзләрен юлдан язу әйтеме гад итеп санап, сүзләрен тыңламадым, килдем. Мин бер кемсәнәмен ки, миндә вафа — холыктыр, аны куя алмам. Мәкярим әхлак иясе булган адәмнең һәрбер фигылефазыйләттер», — диде. Аннан соң Ногман әйтте: «Әй Таи, шул вәгъдәгә ки вафа кыйлмагы нәфсене бетерүдән гыйбарәт икән, бу эшкә батырчылык кыйлмакыңа сәбәп ни иде?» — диде. Таи әйтте: «Вафа кыйлмакыма сәбәп — динемдер, зирә вафасы булмаган кешенең дине һәм булмас», — диде.

Бәс, Ногман Таиның мөрәүвәт вә диянәтенә, вә Таиның вәгъдә кыйлып вәгъдәсенә вафа кыйлмакы үзенең гадәт батыйләсен бетермәгә сәбәп булмакына шат куанычлы булып, тәмам ихсан белән тәкриман гаиләсенә җибәрде.

———

Беркөн Мансур Һишамның якыннарыннан бер кемсәнәне чакырып: «Һишамның җиһад вакытында ни тәдбирләре бар иде?» — дип сорагандa, ул кемсәнә дәхи: «Йә әмирел-мөэминин, Һишам рәхмәтуллаһи галәйһи алай итәр иде, болай итәр иде», — дип әйтә башлагач, Мансур хәлифә, Һишамны рәхмәт белән яд иткәнгә күрә, ул кемсәнәгә ачигъланып: «Галәйһи ләгънәтуллаһи һи, надан! Һәм паласым өстендә утырасың, һәм дошманыма рәхмәт укыйсың», — дип орышты. Ул кемсәнә әйтте: «Әфәндем, Һишамның нигъмәте минем муенымда бер муенчактыр, үлгән тәнемне юган кеше генә муенымнан салдырыр (ягъни үлгәнчә онытмамын вә исемен изгелек белән яд итәрмен)», — диде. Моны ишеткәннән соң, Мансур хәлифә илтифат кыйлып: «Әй дөнья күргән шәех, бар, кайт. Гаһеденә вафа кыйлган вә изгелекне онытмаган адәм икәнеңне белдем», — дип, күп бүләк бирде. Ул кемсәнә әйтте: «Аллаһы белер: әгәр Мансур хәлифәнең дә тагате өстемә ваҗиб булмаса, Һишамнан соң бу кемсәнәнең ихсаныи алмас идем» — дигәннән соң, Мансур хәлифә әйтте: «Әгәр кавемең эчендә синнән гайре вафадар кемсәнә булмаса, ялгыз син аларга иләл-әбәд мәңгегә бу шәрәфне калдырыр иден», — дип мактады.

---

[1] Мәие хилафка — сүзне тотмаска.

———

Холәфаи Өмәййәдән Сөләйман бин Габделмәлик Язид бин Мәһләб белән Димәшкъ шәһәренең тышында тамаша вә күңел ачып йөргәндә, күрделәр: бер кабернең янында — бер хатын, нурлы йөзе толымнары эчендә болыт арасыннан күренгән кояш кебек балкып торыр; хөсен вә җәмал иясе бер хатын аһваһ итеп егълар. Болар хәйран булып, Сөләйман әйтте: «Йә Язид, бар, ул хатынны яучыла, кабул итмәсме?» — диде. Язид, Сөләйманның әмере белән: «Йа Алла, әгәр ирең булмаса, әмирел-мөэминингә, ягъни Сөләйманга, иш булмакны эстәрмесең?» — дип хотбә әйтте. Ул хатын аларга инкяр күзе белән карап, нәзым белән, ул морадыгыз булмаса, димәкне белдерде. Ягъни: әгәр минем гыйшык вә мәхәббәтемнән сөаль кыйлсагыз, әй егетләр, минем мәхәббәтем шул кабернең иясенәдер. Мин аннан, арамызда туфрак хаил[1] булган хәлдә дә, терек вакытында хәя иткән кебек хәя итәмен, ягъни: бу кабер иясе минем сәүгән зәүҗем иде. Ул терек вакытта мин нәфесемне гайреләргә күрсәтмәктән хәя иткән булсам, туфрак эчендә булган вакытта да хәя итәмен, ягъни һичкемгә бармамын, диде.

———

Хәзрәти Госман разыйаллаһу ганһу шәһид булганнан соң, хатыны Наилә бин Фирафәгателкәлбине Шам тарафыннан бер олуг вә урын иясе адәм яучылап, ягъни никяхланып алмакны ирадә кыйлып хәбәр күндерде. Наилә разыйаллаһу ганһа: «Ул кеше минем кай җиремне ярата?» — дип сөаль кыйлганнан соң: «Синең тешләреңне ярата», — дип җавап бирделәр. Бәс, Наилә: «Тешләремне ярата торган булса, менә тешләрем», — дип, тешләрен суырып, ул кешегә җибәрде.

Мәзкүрә Наиләнең бу эшеннән Корәеш егетләре ул кабиләнең хатыннарын алмага рәгъбәт итәр булдылар.

———

Вафадар хатыннардан дәхи бере Мәрван бин әл-Хәким хәлифәнең мөхалифәләреннән[2] Һәдия бин Хәшрәмнең хатыны. Аның ирен хәлифә Мәрван бин әл-Хәким мәйдан сәясәттә җәзалап үтерергә әмер кыйлганда, Һәдиянең хатыны килеп: «Миндә ирем Һәдиянең бер әманәте бардыр, кичектереп торыгыз, китереп тапшыраем», — диде. Мәрван дәхи: «Бар, тизрәк китер», — дип, вакыт бирде.

Ул хатын бер кассабның[3] дөкяненә[4] барды. Кайтарып китермәк шарты белән ике дирһәмгә бер пычак алды. Бер диварның артына керде, борынын вә иренен пычак белән кисте. Пы-

[1] Хаил — пәрдә.
[2] Мөхалифәләреннән — көндәшләреннән.
[3] Кассабның — ит сатучының.
[4] Дөкяненә — кибетенә.

чакны янә кассабка кайтарып китерде. Аннан сәясәт мәйданына килеп, зәүҗенә: «Әй Һәдия, инде кара, мине моннан соң бер-бер кеше алмага рәгъбәт итәрме?» — диде. Һәдия әйтте: «Инде үлемгә үзем тапшырдым, үлеменә гамем юк», — дип, дога кыйлды.

———

Мисырда хөкүмәт иткән падишаһлардан Әхмәд бин Тулунның яшерен серләрен бүлешүче вә якыннарының иң сәвеклесе Габдулла исемле кеше хикәят кыйлмыштыр.

Әхмәд бин Тулун мөкаддәмдә бер чишмә янында ташланмыш бер нарасидә бала табып вә исемене Әхмәд куеп, үзенең тәрбиясендә һөнәр вә мәгърифәт тәгълим итте. Бу бала үсеп «Әхмәд ятим» димәк белән мәшһүр иде. Кайчан ки Әхмәд бин Тулун үлем сырхавы белән сырхау булганда, үзенең углы Әбелхәсән Хәмарвиягә: «Әхмәд ятимне үзеңә мөсахиб кыйл», — дип, васыять әйтмеш иде. Ибн Тулун вафат булып, углы әмир булгач, Әхмәд ятимгә: «Синең кадерең минем каршымда ригаять кыйлынмактадыр. Ләкин минем гадәтем: һәрбер эшне башлаган вакытымда, миңа хыянәт итмәскә ант кыйлдырырмын. Син һәм гаһед кыйл», — диде.

Әхмәд ятим дәхи ямин итеп вәгъдә кыйлгач, Әбелхәсән үзенең даирәсендә булган хадимнәрне вә гаммәтән сарай эшләрен һәммәсен «ятим»гә тапшырып, «ятим»нең икъбалын бәләнд кыйлды. «Ятим» дәхи Әбелхәсәннең тәмам ризасы үзрә истикамәткә мөлязим булып, тугрылыклык бабында олуг мәртәбәдә иде. Көннәрдән бер көн Әбелхәсән Әхмәд ятимгә әйтте: «Әй Әхмәд, фәлән бүлмәдә утырган җиремдә бер энҗе тәсбихым бардыр, алып кил», — диде. Әхмәд ятим барып, бүлмәгә кереп күрде, бүлмәсендә җарияләрнең бере бер хезмәтче белән кочаклашып торыр, Әхмәд ятимне күргәч, ул хаин хезмәтче качты. Мәлгунә җария: «Ул хадим белән һич башка мөгамәләмез булмады. Әман! Мине әмиргә сөйләмә!» — дип ялварып, мине әмиргә әйтмәс, дип гөман кыйлып, үзенең висалын Әхмәдкә тәкъдим кыйлды. Әхмәд әйтте: «Әлгаязе билляһ, мине ихсанына гарык итеп, мин дәхи хыянәт итмәскә гаһед иткән вәли нигъмәтем булучы әмирнең намусына ничек хыянәт итәем? Чөнки ул хадим белән чамасын белеп булгучы бер эш араңызда вакыйг булып, һәнүз эш хөкемгә җитәкләгән. Тәүбә вә үкенү кыйл. Моннан ары билә кабахәт кыйлма», — дип, нәсыйхәт кыйлып, тәсбихны Әбелхәсәнгә китерде. Вакыйганы Әбелхәсәнгә сөйләмәде.

Әмма мәзкүрә җария, әмирдән үзенең кабахәте хосусында бернәрсә сизмәсә дә, куркып йөргәндә, әмир беркөн үзенең янына икенче җариясен алып, бу мәлгунә җарияне янына чакырмаганлыгыннан: «Минем кабахәтемне Әхмәд ятим әмиргә ирештергәндер», — дип гөман кыйлып, үзенең котылуы өчен мәкер тарикына китмәке сәбәпле, бервакытны ялгыз утырганда егълап, әмир хозурына кереп: «Әфәндем, сез Әхмәд ятимне имин

хисапламаңыз: ул миңа якынлашмакчы булды», — дип шикаять итте.

Әмир, ышанып, дәрхаль Әхмәд ятимне үтермәгә касд кыйлды. Ләкин гакылына салып фикерләгәннән соң: «Тукта, икенче бәһанә табып, хөкемне иҗра кыйлаем. Зирә бу сурәттә сабыр кирәктер», — дип, ышанычлы забитларыннан[1] берсен чакырып әйтте: «Мин сиңа бер буш табак белән берәүне җибәрермен. Әмир бу табакка мисек[2] тутырып җибәрмәгә боерды, дип, сиңа табак күтәреп барган адәмне шундук кызганусыз башын кисеп, табакка салып, өстен ябып китер!» — диде. Моңа биш-ун көн узганнан соң, әмир үзенең ярдәмчеләре белән тәгам тәнавел кыйлганда, Әхмәд ятим дәхи хезмәтендә тора иде. Әмир, дәстәрханда булган бер буш табакны күрсәтеп, Әхмәдкә әйтте: «Шул табакны ал, фәлән забитка илт, мисек тутырып китерсен», — диде. Әхмәд ятим әмирнең бу хәйләсеннән гафил вә күңеле саф булган хәлдә, баш өсте, дип, табакны алып тиз заман барганда, әмирнең хас хадимнәреннән берничә хадим сый мәҗлесе кыйлып утырган җирләрендә Әхмәд ятимне күреп: «Әфәндем, бераз гына безнең сый мәҗлесемезгә рәхим итсәңез лә!» — дип гозер иттеләр. Әхмәд ятим әйтте: «Мин әмирнең фәрманы белән фәлән забитка барамын. Әмир боерды — бу табакны мисек белән тутырып алып әмиргә илтсәм кирәк. Гаеп итмәсәңез лә», — диде. Әйттеләр: «Безнең белән бераз утыр! Арамыздан бер хадимне җибәрәек, ул алып китерер, кем барып китерсә дә, зарар юк», — дип игътизар кыйлып, мәҗлесләренә утырттылар. Мәзкүрә җария белән маҗарасы булган хадим һәм анда иде: «Бир, мин барып алып киләем», — дип, табакны Әхмәд ятимнең кулыннан алып, ул забит тарафына китте. Барып: «Бу табакны әмир мисек белән тутырып җибәрмәгә боерды», — дип, табакны забит кулына бирде. Бәс, ул забит, әмирнең әмере бу булмак кирәк дип, ул хадимнең башын кисеп, ул табак эченә салды. Капкачын ябып, забит үзе ул табакны әмиргә китергәндә, хадимнәрнең мәҗлесенә очрап, Әхмәд ятимгә бирде. Әхмәд дәхи, табак эчендә ни барын карамастан, әмир хозурына китерде. Әмир ул Әхмәд ятимнең сәламәт кайтмакына дәхи табакны ачып, табак эчендә гайре кешенең башы булмакына тәфәккер белән хәйран булып: «Бу ни хәлдер? Монда ни хикмәт бардыр, йә Әхмәд, сөйлә?» — дигәч, Әхмәд әйтте: «Мин белмимен. Мәгәр мин бу табакны забитка алып барганда, хас хадимнәрнең бәземенә[3] очрап, мәҗлесемезгә утыр, дип илтимас кыйлганнарыннан соң, мин аларның сый мәҗлесендә

---

[1] Забитларыннан — офицерларыннан.

[2] Мисек — кабарга исемле хайванның аерым бизләреннән алынган гаять хуш исле бер матдә.

[3] Бәземенә — мәҗлесенә.

калдым. Фәлән хадим, мин барып китерәем, дип, миннән табакны алды. Забит янына китте. Бер заманнан соң күрдек: забит үзе килеп, табакны кулымызга бирде. Мин башкасын белмимен», — диде. Әбелхәсән әмир басыйрәт[1] әһеле иде, әйтте: «Әй Әхмәд, бу мәкътүлнең бу җәзага мөстәхак булырлык ни маҗарасы бар иде, белмәймесең? Сөйлә, зирә монда бер хикмәт Илания бардыр», — диде. Әхмәд ятим әйтте: «Бу хәбиснең бер хыянәте бар иде. Мин хозур дәүләтеңезгә гарыз кыйлмага оялып, көннәрдән бер көн аның бәласе башына киләчәген көтеп торыр идем», — дип, җария белән хадимнең булган маҗарасын тәмам сөйләде. Әбелхәсән бу сүзләрне ишеткәннән соң, ул җарияне чакырып, Әхмәд ятим алдында сөйләштерде. Җария дәхи Әхмәд ятим әйткән рәвешчә хәбәр биреп икърар кыйлды. Аннан соң Әбелхәсән әйтте: «Ал бу фасиканы, үз кулың белән кател ит», — дип, Әхмәд ятимгә әмер кыйлды.

Әхмәд ятим әмирнең әмерен җиренә китерде. Ул хаиннәр бәр вәҗһе мөхәррәр[2] бәлаләрен таптылар. Вә Әхмәд ятим дәхи, тугрылык вә вәгъдәлелек бәрәкәтендә чиктән тыш олуг дәрәҗәгә иреште.

———

Бер дана[3] димештер ки: «Үземнән теләнче кешене күрмәдем. Мәгәр этне күрдем. Бервакыт сагыз чәйнәп барганда, бер эт артымнан бер чакырым ияреп барды», — димештер.

———

Бер кешедән сорадылар: «Ни хәл, ни эшең бар?» — диделәр. Әйтте: «Әле өмидкә хезмәт итәмен, тамигъка[4] кол булдым», — димештер.

———

Тамигъ белән мәшһүр Әшгас дигән бер адәм бар иде. Аннан сорадылар: «Син тамигъда кайсы дәрәҗәгә җиттең?» — диделәр. Әшгас әйтте: «Күршемнең морҗасыннан төтен чыкканын күрсәм, аш пешерәләр, имеш, ашарга бараем дип, ниятемә киләдер», — диде.

———

Бер тамигъ әйтте: «Бер җеназа[га] хәзер булганда, ике кеше бер-бере белән яшеренчә сөйләшкәнен күрсәм, бәлки, бу мәет минем өчен бер-бер нәрсә васыять әйткәндер дә, аны сөйләшә торганнардыр, дип фараз кыйламын», — диде.

———

Бер хәкимнән сорадылар: «Картлар яшьләрдән артыграк дөньяга хирыс буладыр, ни гаҗәп?» — диделәр. Хәким әйтте:

---

[1] Басыйрәт — аңлы, алдан күрүчән.
[2] Бәр вәҗһе мөхәррәр — шул рәвешле.
[3] Дана — акыл иясе.
[4] Тамигъ — кешедән өмет итүче.

«Картлар дөньяның тәгамын күп беләләр. Әмма яшьләр дөньяның, күп тугырыда, тәгамын татып бетергәннәре юк», — диде.

---

Әмирләрдән бер әмиргә бер кеше әйтте: «Син миңа фәлән нәрсә вәгъдә кыйлган идең», — диде. Әмир әйтте: «Хәтеремдә юк», — диде. Ул кеше әйтте: «Хәтереңдә юклыгы шулдыр: син күп кешегә вәгъдә кыйлгансың, кайсыберсе хәтереңдә торсын? Минем хәтеремнән чыкканы юк, чөнки мин синнән гайре кешедән сораганым юк. Булса да, бик аз», — диде.

Әмир аның җавабына да тәхсин кыйлды, ингам-ихсан кыйлды.

---

Бер үзеннән дә кызганучы берәүгә бер нәрсә вәгъдә кыйлды, сүзендә тормады. Бу кеше әйтте: «Син миңа фәлән вәгъдә кыйлган идең, вәгъдәңә хилафлык кыйлдың», — диде. Ул әйтте: «Мин хилафлык кыйлмадым, ләкин малым хилафлык кыйлды», — диде.

---

Бер әгърабидән сорадылар: «Матурлык ни-нәрсә, беләмесең?» — диделәр. Әгъраби әйтте: «Һай, шул булса!» — диде. «Ул ни-нәрсә?» — диделәр. Әйтте: «Авызы зур булсын. Борыны зур булсын. Аяклары, тубыклары симез булсын», — диде.

Әсмәгый әйтте: «Бер гүзәл бәдәви гарәп хатынын күрдем. Ире белән, әмма ире бик ямьсез. Әйттем: «Әй фәләнә, син бу ямьсез кеше белән ятырга ничек разый буласың?» — дидем. Бәдәвия әйтте: «Әй Әсмәгый, аның белән Аллаһы Тәгалә арасы бик гүзәлдер; Аллаһы Тәгалә мине аңар шунын өчен, савап итеп бирде. Минем белән Аллаһы Тәгалә арасы ямьсездер; шуның өчен Аллаһы Тәгалә аны миңа газап итеп бирде. Аллаһы Тәгалә разый булгач, мин ник разый булмамын?» — диде. Хыйлькате[1] кебек холыклы һәм гүзәл, имеш».

---

Бер хәким бик күркәм холыклы, әдәпле, бик ямьсез егетне күрде, әйтте: «Әй егет, әдәбеңнең күркәмлеге йөзеңнең ямьсезлеген җуеп җибәрде», — диде.

---

Мансур Хәллаҗны күреп, бер кеше әйтте: «Әгәр син дәгъваңда тугрылыклы булсаң, мине маймыл сурәтенә керт», — диде. Мансур әйтте: «Әгәр касд кыйлсам, яртысы артып та калыр», — диде. Ягъни маймылдан кабахәт сурәткә кертермен, диде.

---

Җахыйз әйтте: «Бер мәртәбә мине бер хатын бик оялтты. Мине бер нәкъкашкә алып барды, әйтте: «Менә моның төсле», — диде. Һични әйтергә белмәдем, Нәкъкаштан сорадым: «Моның сәбәбе нидер?» — дидем. Нәкъкаш әйтте: «Ул хатын

---

[1] **Хыйлькате** — тумышыннан бирелгән сыйфаты.

миннән шайтан сурәтен ясап бир, дип сорады. Мин әйттем, мин шайтанны күргәнем юк, күрмәгән нәрсәнең сурәтен мин ясый белмим, дидем. Сине алып килде дә, менә моның төсле, диде», — диде. Җахыйз ямьсез кеше иде.

———

Берәү Кәгъбәдә тавафта бер бик ямьсез кешене күрде. Һаман егълый, истигъфар кыйла. Ул кешегә әйтте: «Әй дус, синең бу ямьсезлегеңә караганда, җәһәннәмнән курка торган эшең юк. Җәһәннәм сине кабул итмәс», — диде.

———

Бервакыт Зәид ибн Әбиянең мәҗлесендә бер бик ямьсез кеше бар иде. Зәидның табынында бик күп ашады. Дәстәрханда һичнәрсә калдырмады, һәммәсен ашап бетерде. Зәид әйтте: «Әй фәлән, синең балаларың бармы?» — диде. Ул кеше әйтте: «Тугыз кызым бар», — диде. Зәид әйтте: «Бар да үзеңә охшаганнармы?» — диде. Ул кеше әйтте: «Мин үзем кызларымнан матуррак. Әле дә алар миннән дә күбрәк ашыйлар», — диде.

Бөтен мәҗлестәге халык көлеште.

———

Бер бик зур борынлы кеше бер хатынга яучы җибәрде, әйтте: «Мин бик сабыр вә түземле, кеше ни әйтсә — күтәрәмен, ачигъланмаймын. Нәселем-нәсәбем яхшы», — диде. Хатын әйтте: «Бик ышанамын, дөрес әйтә: кырык ел шулкадәр борынны күтәреп йөргән кеше бер кечкенә сүзне күтәрмәсме?!» — диде.

———

Имам Шәфыйг әйтте: «Мөхәммәд ибн әл-Хәсәннән гайре симез кешенең бу кадәр гакыллы булганын күргәнем юк иде», — диде. Чөнки имам Мөхәммәд бик симез кеше иде.

———

Берәүгә әйттеләр: «Син ник сакалыңны йолкасың?» Ул кеше әйтте: «Син ник йолыкмайсың?» — диде.

———

Локман хакимгә әйттеләр: «Бер куйны бугазла, иң тәмле җиреннән ике кисәк ит пешереп китер», — диделәр. Локман хәким куйны бугазлады, телен вә һәм йөрәген алып пешереп китерде. Янә әйттеләр: «Бер куйны бугазла, иң яман, тәмсез җиреннән ике кисәк безгә китер», — диделәр. Локман хәким барды, бер куйны бугазлады, теле белән йөрәген алып китерде, әйтте: «Шул икесеннән татлы нәрсә юк, әгәр татлы булсаң. Шул икесеннән әшәке вә тәмсез нәрсә юк, әгәр яман булсаң», — диде.

———

Матурлык вә җәмал иясе адәмнәрдән бере — Мәсгаб бин Зөбәер зиядә матур вә гүзәл кеше иде. Беркөн Бәсрада дарел әмәрасе йортында утырып торганда, бер хатын, килеп вә Мәсгабка каршы басып, дикъкать белән карап торыр иде. Мәсгаб әйтте: «Әй хатын, бу җиргә килеп тормакыңа сәбәп нидер?» —

диде. Ул хатын дәхи оста телле, имеш, болай дип җавап бирде: «Ханәмездә кандилемез сүнгән иде, йөзеңнән кандилемезне яндырып алаек дип килгән идек. Ягъни, нурлы йөзеңнән күземезнең шәмгына нур алаек», — дип, нәзакәтлелек белән җавап биреп, Мәсгабның җәмалын мәдех кыйлды.

———

Бер ягымлы гарәп хатыныннан сорадылар: «Әй абыстай, иреңә ни булды, иреннәрең ярылган ла?» — дигәч, ул: «Инҗир, пешеп вә татлыланып җиткәч, ярыладыр», — дип, инҗирдән татлырак җавап китермештер.

———

Вә дәхи гаять гүзәл вә матурлар җөмләсеннән Габдулла бин Мөбарәкнең кызы Ләбибә, имеш. Ул Вәлид бин Гатбәнең хатыны иде. Ләбибә әйтте: «Ялгыз көзгегә караганда, миннән гүзәл бармы, диер идем. Вәлид белән бергә караган вакытымда алай әйтеп булмады», — дип, Вәлиднең үзеннән дәхи гүзәл икәнен тәгъриф итмештер.

———

Хәбәшә белән Румия, ике хатын, әгъзаларының матурлыгыннан мактанышып, Румия хатын әйтте: «Мин ак кафурдан[1] бер бөртекмен, син бер күмер кисәгесең», — диде. Хәбәшә хатын әйтте: «Мин мисек бөртегемен, син исә тоз капчыгысың», — дип, гүзәллек белән җавап бирмештер.

———

Язид бин Мәзид сакалы күкрәгенә чаклы салынган озын сакаллы бер кешене сакалын буяп торганда күреп: «Әй фәлән, син сакалың өчен байтак хәреҗ[2] тота торгансың?» — диде. Ул кемсәнә әйтте: «Һай-һай, сакалыма һәр җомгада ике дирһәм лазем булып, берсен — майга, берсен кынага хәреҗ итәмен! Әгәр Язид бин Мәзиднең миңа өлеше вә бүләге булмаса иде, сакалым тигрәсендә ак энҗеләр заһир булыр иде», — диде.

———

Кайс Мисырда вали булып торган заманда бер карчык хатын, килеп: «Әй әмир, өемдә сычканнар азайды ла», — диде. Кайс: «Монда бер гүзәл киная булса кирәк, — дип, — хатынның ханәсен икмәк, ит, май белән тутырыңыз», — дип ихсан кыйлмыштыр.

———

Сәлимә бин Мәрә дигән бик тәбәнәк кеше Әмрәәлкайсны әсир кыйлды. Әмрәәлкайс бик озын, юан кеше иде. Әмрәәлкайсның кызы Сәлимәгә килеп: «Әй касыйр, ягъни, әй кәрлә, атамны җибәр», — диде. Сәлимә әйтте: «Агаһ булыңыз, әй халык, Әмрәәлкайсның кызы, мин тәбәнәк кеше булганыма күрә, мине гаҗиз, дип гөман кыйлды. Хәлбуки аның атасын мин гаҗиз

[1] Кафур — Һиндстанда үсә торган бик матур гөл.
[2] Хәреҗ — чыгым, акча тоту.

кыйлдым. Касыйр булсам да, күп озыннар бардыр ки, мин аның киемен суеп, атын дөпәләп, канын агыздым», — диде.

———

Әбүләсүәд әд-Дәэли бер аз егетләр мәҗлесенә барып керде. Әбүләсүәд гаҗибелхыйлькать бер адәм иде. Ул егетләрнең берсе торып ләтыйфә кыйлды. Мәгънәсе: Әбүләсүәднең йөзе иреннән талак алып кайткан карчыкның йөзенә охшар, димәктер.

———

Җахыйз хикәят итмештер ки: «Мине һич кем оялтканы юк иде, мәгәр бер хатын миннән мәсхәрә кыйлып оятлы булдым», — диде.

Җахыйз гаять чирканыч йөзле иде. Аны хурлап, берәү әйтте: «Әгәр дуңгызге янә икенче мәртәбә ямьсез сурәт кертелсә иде, алай да дуңгызның кабихлеге Җахыйзның кабихлегеннән ким булмас иде, ягъни Җахыйзның сурәтеннән күркәмрәк булыр иде».

———

Бер ямьсез вә кабихелмәнзар кемсәнә, Ямәнгә барып кайтканда, көймәдә нәзым әйтмештер. Мәгънәсе: мин Ямәнгә кергән көнемнән бирле бер гүзәл йөз күрмәдем. Әй адәмнәр, Ямәннең катылык вә мәшәкатенә караңыз! Мин Ямәндә чагында, Ямәндә миннән гүзәл кеше юк иде, димәктер.

———

Дәү борынлы бер адәм хакында бер шагыйрь димештер: «Синең йөзеңдә дивар шикелле бер борын кисәге бардыр. Аны ишәк баглар өчен багана итмешләрдер. Вә ул борын иясе, мисалда, кабер вә борыны — зыярәт ташы кебек. Ләкин ул ташны кыйбла тарафына муафыйк куелмамыштыр», — димәктер.

———

Әмирләрдән бер әмир үзенең хадименә боерды: «Бар, миңа бер гакыллы кешене табып китер», — диде.

Хадим урамга чыкты. Берәүне алып керде. Әмир әйтте: «Бу кешенең гакыллы икәнен кайдан белдең?» — диде. Хадим әйтте: «Бу кеше җәй көне китән кия, кыш көне котын[1] кия. Әлбәттә, вакытына карап, кием кигән кешедә гакыл бардыр, дип уйладым да алып кердем», — диде.

———

Бер кеше хатынына яңа кием алып кидерде. Хатыны: «Бу фәләнрәк», — дип, яратмаганын изһар кыйлды. Ул кеше әйтте: «Бу кием фәләнрәкме яки талак фәләнрәкме?» — диде. Хатыны: «Билгаен вә баш өсте», — дип кабул итте вә разый булды.

———

Вәлид бин Язид Һишам бин Габделмәлик янына керде. Вәлиднең башында бик нәфис кыйммәтле чалма иде. Һишам

---

[1] Котын — мамыктан тегелгән кием.

әйтте: «Кыйммәт алдыңмы бу чалманы?» — диде. Вәлид әйтте: «Бәһасе мең дирһәмлектер», — диде. Һишам әйтте: «Кыйммәт икән. Исраф булмасмы?» — диде. Вәлид әйтте: «Мин газиз вә кадерле әгъзам өчен мең дирһәмгә моны алдым. Әмма син кабахәт әгъзаң өчен ун мең дирһәмгә җария сатып алдың, исраф кайсымыздадыр?» — диде.

———

Ибраһим бин Мәһди белән Исхак әл-Мәүсыйли көйләү хосусында бәхәс вә мөхасамә кыйлыштылар. Исхак әйтте: «Хөкемләшик дисәң, синең белән минем арада хаким булырга хайван җитәр». Ягъни, җырның хайванга тәэсире булса, адәмгә тәэсире битарыйк улә[1] булмак кирәк, диде.

———

Гаҗәм падишаһларыннан бер падишаһ вафат булды. Варисы — бары бер кечкенә баласы калды. Вә аның бер гакыллы вәзире бар иде. Баланы имтихан өчен аның янына уенчыларны вә мөганниләрне[2] китертеп көйләр уйнатты. Бу тавышлар баланың колагына кергәч, бала бишектә аяклары белән тибенеп хозурланып ятканнан соң, падишаһ иттеләр.

———

Габдулла бин Мөбарәк разыйаллаһу ганһу әйтте: «Беркөн егет вакытымда, бер бакчада юлдашларым белән ашадык-эчтек. Мин шәштар[3] уйнамага бик хирыс идем. Кич булгач, шәштарны, уйнаем дип, кулыма алдым. Уйный башладым. Әүвәл чиерткәнемдә, шәштар телгә килеп аваз чыгарды. Филхаль шәштарны тоттым да җиргә ордым. Аннан соң Аллаһы Тәгаләнең зикереннән ишгаль кыйла торган нәрсәне эшләмәдем», — диде.

———

Беркөн Һарун әр-Рәшит Әбелгыйнадан көй хакында сөаль кыйлды. Әбелгыйна әйтте: «Бу көйнең шәрхе бик озындыр вә шарты бик күптер. Әмма көйнең лазем шартлары өчтер: әүвәл, көйләүче гүзәл булсын; шигыре вә сүзе татлы булсын; хуш холыклы вә хуш фигыльле булсын; вә янә мөганни белән тыңлаучы якын вә кара-каршы булсын. Шигырьләренең әлфазы гарәиб вә гаҗәиб вә мәгънәләре ләтыйф булсын», — диде.

———

Мансур хәлифәнең Бәгальбәк дигән бер хас мөәззине бар иде. Беркөн хәлифә таһарәт алганда, бер җария хәлифәнең аягына-кулына су салып торыр икән, мәзкүр мөәззин, хуш авазы белән тәрҗигъ кыйлып, азан әйтә башлады.

Бу җария азан тавышын ишеткәч, үзеннән китеп, су салмакны онытты. Кулыннан комганы төште. Хәлифә намазга ке-

---

[1] Битарыйк улә — тагы да шәбрәк.
[2] Мөганниләрне — җырчыларны, музыкантларны.
[3] Шәштар — алты кыллы музыка коралы.

реп, намаздан соң мөәззингә әйтте: «Кил йә Бәгальбәк, сиңа бер җария һибә кыйлаем», — дип, ул җарияне мөәззингә һибә кыйлып бирде. Мөәззиннең тавышына җария гашыйк булмакын бәяндыр.

———

Хәсән бин Гали разыйаллаһу ганһу хикәят кыйлмыштыр ки: бер мөганнигә әйттем: «Йә мөганни, минем өчен бер тәганни[1] кыйл». Мөганни әйтте: «Бу — әмердер», — диде. Мин әйттем: «Бер тәганни кыйлмакыңны эстәймен». Мөганни әйтте: «Бу үтенүдер». Мин әйттем: «Әгәр мәгъкуль күрсәң, тәганни кыйлсана». Мөганни әйтте: «Бу ибрамдыр, ягъни кыстаудыр». «Алайса, тәганни кыйлма!» — дидем. Мөганни әйтте: «Бу сугыштыр», — диде.

Бәс, мөганниләргә, әүвәл, салә хуш иттең, әһла вә сәһла димәктер, чөнки уенчының вә җырчының үзләренең күңеле ябышмаса, уйнатып та булмай, җырлатып та булмай.

———

Хикәят Исхак әл-Мәүсыйли әйтте: «Атам янында бер мөганни тәгам ашап бетергәннән соң, атам әйтте: «Йә Әбү Хәфәса, инде колакларымызны тәгамландыр», — диде».

———

Иң әүвәл исламда тәганни кыйлган кеше Тауис исемле иде. Хала бу Тауис шомлыкта зарб мәсәлдер ки, «Тауистан шомрак» диерләр. Тауис әйтте: «Минем анам әнсар хатыннары арасында иде. Рәсүлуллаһ вафат булган кич мине тудырды. Әбү Бәкер разыйаллаһу ганһу вафат булган көн мине сөннәткә утыртты. Гомәр разыйаллаһу ганһу үлгән көн балигъ булдым, Госман разыйаллаһу ганһу үлгән көн өйләндем. Гали разыйаллаһу ганһу мәкътүл булган көн бер балам дөньяга килде. Минем кебек шом кем бар?» — диде.

———

Язид бин Мәһләб үзенең әһел вә гыяленә әйтте: «Ганадан сакланыңыз ки, көй мөрәүвәтне туктатыр, хаяны киметер, шәһвәтне арттырыр, гаурәтне ачар. Чөнки көй хәмернең каим урынбасары. Исерткеч гакылга ни кыйлса, көй дәхи аны кыйлыр», — диде.

———

Нафигъ әйтте: «Бервакыт Гомәр разыйаллаһу ганһу белән идем. Юлда курай тавышыны ишеттек». Гомәр разыйаллаһу ганһу әйтте: «Йә Нафигъ, мин бервакытны пәйгамбәр галәйһиссәлам белән идем, курай тавышын ишеткәч, колагына бармагын тыкты», — диде.

———

Бер фәйләсуф бер мөганнинең тәганни кыйлганын ишетте. Карар күзгә сөйкемсез вә кабахәт тавышлы мөганни, имеш.

---

[1] Тәганни — көйләү, җырлау.

Фәйләсуф әйтте: «Каһиннәр[1] бер кешенең өе түбәсендә ябалак кычкырса, ул кешенең үлмәкенә дәлаләт кыйла, дип заннары хак булса, бу мөганнинең тавышы ябалакның үлмәкенә дәләләт кыйлыр иде», — димештер.

---

Беркөн Хәжжаж үзенең мәжлестәшләреннән сөаль кыйлды: «Сезнең каршыңызда ниндәен тавыш нечкәрәктер, ягъни күңелне нечкәртә торганрактыр?» — диде. Мәжлестәшләренең берсе әйтте: «Мин һич күңел нечкәртә торган тавыш ишетмәдем. Мәгәр төн уртасында матур аваз белән Коръән укыган тавыш күңелләрне нечкәртәдер», — диде. Хәжжаж әйтте: «Раст әйттең, бик гүзәл нәрсәдер», — диде. Икенче берсе әйтте: «Бала табарга тулгак тоткан хатынымны өйдә калдырып, иртә белән мәсҗеткә баргач, артымнан: «Балаң булды вә әхсәнаһ», — дип әйткән тавыштан минем каршымда сөеклерәк тавыш юктыр», — диде.

---

Габдулла бин Җәгъфәргә бер кеше әйтте: «Фәлән кеше миңа, сине сәвәмен, дидер, мин аның сөйгәнен кайдан беләем?» — диде. Габдулла әйтте: «Күңелеңнән сора: әгәр күңелең аны сәүсә, ул сине сәвәдер булыр», — диде.

---

Бер кемсәнә Йосыф галәйһиссәламгә әйтте: «Йә Йосыф, мин сине сәвәмен», — диде. Йосыф галәйһиссәлам әйтте: «Мин мәхәббәттән хәер күрмәдем: атам мине сөйде — мине коега ташладылар. Газиз хатыны мине сөйде — мине зинданга салдылар. Син мине гафу кыйл, Аллаһ сине гафу кыйлсын», — диде.

---

Гали бин әл-Җәһем димештер ки: «Бервакытны бер хуҗада хезмәттә идем. Хуҗама Хорасан валисе тарафыннан күп гүзәл һәдияләр күндерелмеш иде. Ул һәдияләр эчендә Таифтә тәрбия кыйлынмыш җәмал вә кәмаль иясе, вә шигырь әйтмәктә, вә мусикида, вә тәганнидә барча мөганниялардән өстен Мәхбүбә исемле бер җария дәхи күндерелмеш иде. Ул хуҗам, ошбу җариягә тәмам гашыйк булып, яныннан бер дә аермас иде. Ләкин берзаман араларында бер эш вакыйг булып, хуҗам мәзкүр җарияне ялгыз бер бүлмәгә куеп, берничә заманнар аерым калдырды.

Кичләрдән бер кич мин хуҗам бүлмәсендә йокламыш идем. Төн уртасында хуҗам, яныма килеп: «Гали, Гали, тор әле», — дип, мине уятты. «Ләббәйкә, әй хуҗам», — дип сикереп тордым. Хуҗам әйтте: «Әй Гали, мин бу кич төшемдә Мәхбүбә белән барышып[2], аннан разый булганымны күрдем», — диде.

---

[1] Каһиннәр — шаманнар.
[2] Барышып — татулашып.

Мин әйттем: «Әй әфәндем, хәерле булсын. Разый булсаң да, җәфа кыйлсаң да, дәүләтең кулыңдадыр. Разый булганыңны белдереп, ул мәһҗүрә җарияңезне шатландырыгыз», — дидем.

Без бу сүзне сөйләшеп торганда, нәүбәтчеләрдән бер хадим, килеп: «Йә әмир, ул надир җарияңездән тәганни вә шәштар авазы ишеттем», — дип хәбәр бирде. Хуҗам әйтте: «Әй Гали, әйдә, бараек», — дип, мине янына алып, җария бүлмәсенең ишегенә бардык. Пәрдә артыннан карап күрдек ки, җария, кулына шәштарне алып, бәет көйләр. Хәсрәт белән тәганни кыйлганын ишетеп фәһем иттек ки: ул җария һәм төшендә очрашуыгызны искәртәдер. Кайчан ки, хуҗам хәлял гыйшык белән гашыйк булып, ничә заман мәһҗүр куелмыш мәгъшукасыннан ошбу хәсрәтен аңлатучы җан көйдергеч шигырьләрне ишеткәннән соң, чарасыз аһ вә фөрьяд итте. Вә Мәхбүбә дәхи, аһ! дип фөрьяд итеп, әмирнең аягына сарылды. Әмир әйтте: «Ма һәза», ягъни: «Ни булды? Ни булды?» — дип, бу хәсрәтнең сәбәбен сорады. Җария әйтте: «Әй хуҗам, бу кичә гафу вә ризаңны төшемдә күреп уяндым. Мәзкүр шигырьне инша кыйлып, сез бу үлгән җарияңезне килеп терелтерсез дип көтеп торыр идем», — диде. Әмир әйтте: «Мин дәхи билә күрмеш идем. Әй Гали, ошбу уртак төшләрдән бер гаҗәбрәк нәрсә күрдеңме?» — дип, кәмаль сөрур вә шатлык белән җариясенең кулыннан тотып, хилвәт сараена китереп, висаләт шәрабын нуш иттерде», — димештер.

———

Гарәпнең кадимге падишаһларыннан бер падишаһ нәдимнәре белән сохбәт кыйлганда, йокысы килсә, чишенмәенчә, шул мәҗлестә йоклар иде. Нәдимнәре вә мөганниләре вә сазәндәләре[1] шунда йокларлар иде. Аларны яныннан җибәрмәс иде. Кичләрдән бер кич ашап-эчеп тәмам булгач, гадәтенчә, шул мәҗлестә йоклады. Вә мөганни егетләр вә мөганния җарияләр дәхи йокладылар. Мәҗлестә йокламаган кеше калмады. Ләкин мөганни егетләрдән берсенең йокысы килмәенчә, йоклаган кебек булып ятыр иде. Чөнки мөганния җарияләрнең берсенә гашыйк иде. Халык йоклап беткәч, торып, мәгъшукасы булган җариянең янына барып, гүзәллегенә карап, кара савыт, каләм алды: «Әй фәлānә, төшемдә күрдем ки, синең белән икемез бер ястыкта ятып, авызымны авызыңа куеп ятамын, имеш», — дигән мәзмунны бәян кыйлып, күрешү теләге белән, ошбу бәетне нәзым итте. Кәгазь битенә язып, вәрәкъне[2] төреп, мәзкүрә җария уянсын өчен, мәхсус катырак ыргытты.

Мәгәр ул җариянең дәхи бу мөганнигә мәхәббәте булганга күрә, җария дәхи йоклар-йокламас ятыр икән. Ул, вәрәкъне

[1] Сазәндәләре — саз уйнаучы музыкантлар.
[2] Вәрәкъне — язылган кәгазь битен.

алып, вәрәкънең аркасына, сәнгатьчәләп: «Хәерле булсын. Көнләшүчеләрнең борыны төшсен: якында висалемә ирешерсең», — дигән сүзне бәян кыйлгучы бәетне язып, мөганнигә атмага торган заманда, падишаһ, уянып, бу хәлне күрде. «Бу ни-нәрсә? — дип, вәрәкъне җариянең кулыннан алып: — Бу ни эшегез? Мин сезне фәлән итәрмен!» — дип ачигъланган, ул мөганни белән җария, икесе дә, падишаһның аягына егылдылар. Вәгъдә вә ант итеп: «Моңарчы арамызда һичбер сүз юк иде, һичбер хәбәрләшү юк иде. Мәгәр эчләремездән гыйшык тотып, бәгырьләремез кәбаб булганлыктан, сабырымыз калмаенча, бары бу шигырь әйтешү язуы белән хәлемез изһар кыйлынды. Юк исә васита белән фахиш мөгамәләмез һичбер вакыйг булмады», — дип егълашып, үтенеч кыйлдылар.

Аннан соң падишаһ хәлне фәһем итеп гафу кыйлды. Ул, җарияне азат кыйлып, мәзкүр мөганнигә гакыд вә никях кыйлды. Вә күп ихсан вә җиһаз биреп: «Инде барыгыз, сараема килмәгез», — дип һәм ихсан һәм хөсне сәясәт кыйлды.

———

Холәфаи бәни Өмәййә заманында өдәбадан Әбү Язид Әсәди дигән бер кемсәнә бар иде. Ул хикәят кыйлып димештер ки: «Бер көн, холәфаи Өмәййәдән Габделмәлик бин Мәрванның углы Сөләйманның хозурына бармыш идем. Күрдем ки, бер һәйбәт вә нәфис җимешләре пешеп торган бер бакчаның уртасында, диварлары кызыл рөхам[1] ташыннан булучы бер касыр эчендә яшел дибаждан[2] түшәк вә юрган үзрә утырыр. Вә янында берсеннән-бере гүзәл җарияләр торыр. Вә кояш мәгъриб җамә хабенә кереп, ягъни һаваның кайнарлыгы бер тарафка китеп, кич сайраучы кошлар, гүя бер-беренә каршы җаваплашып, тәрәннемдә. Ләтыйф вә мөлаем җилләр агач кярханәсендә көмаш тукып, ягъни нәфис җефәк көмаш кебек җилфердәп исеп, агачлар бер яктан бер якка мәел кыйлып торыр иде. Барып шунда ук сәлам сөннәтелисламны әда кыйлдым. Сөләйман ул вакытта, башын алдына салып, хәйран булып уйланып утыра. Сәламемне ишеткәч, башын күтәреп әйтте: «Әй Әбү Язид, моның кебек кәеф-сафа урынында булсам да, гыйшык вә мәхәббәт белән мөбтәля булдым.

Аһ, кем, әйләсәм дә сәйре гүзәллек,
Бер яшерен газап вар күңелемдә, —

дип бәгырем кәбаб вә тәмуг, күзем төстәш шәраб вә ярымның аерымлыгыннан күңелем бер интегү мәгънәсен фәһемләтте. Мин әйттем: «Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә әмир хәзрәтләрен ислахта итсен. Гыйшык вә мәхәббәттән соң гашыйкның өстенә кыямәт кубармы вә гашыйкны һәлак итәрме?» — дидем.

---

[1] Рөхам — мәрмәр.
[2] Дибаждан — чәчәкле бизәк төшерелгән ефәк тукымадан.

Сөләйман әйтте: «Бәли, бәли, әһле гыйшык өстенә кыямәт кубар», — диде. Янә башын күтәребрәк: «Әй Әбү Язид, ошбу көнемездә инде ни гүзәл эш бардыр, ни эшләрмез?» — дигәч, мин әйттем: «Әй әмирел-мөэминин, ошбу җәгәр сүз гыйшык бәласе белән мөбтәля булган көнгә мөнасиб нәрсә мин булсам, ак биллүр эченә әһле гыйшыкның дәвасы булгучы кызыл мәйне ак, җәсмин төсле назлы, күңелле вә зифа гәүдәле, вә хуш аваз бер җырчы кыз салып бирсә, җаным, дип, дәрхаль ул шәрабкосы бирәче гүзәлнең кулыннан алып авыз итеп, бер-бер артлы авызымны авызына сөреп, ул халәттә ничә көн тарткан гыйшык җәфасын онытыр итәр идем», — дидем.

Бу сүземне сөйләп, мәгъшукасын исенә төшергәнемнән соң, Сөләйман һичбер җавап бирмәенчә, янә башын түбән салып, тәфәккер дәрьясына талып, ике күзеннән яшь акмага башлады. Сөләйманның бу хәлен күргәч, янында торган җарияләр бер тарафка киттеләр, Сөләйман берзаманнан соң башын күтәреп, кәмаль гыйшыкыннан акыл җыя алмый әйтте: «Әй Әбү Язид, син шундаен көндә яныма килдең ки, әҗәленнең инкыйзасы[1] вә хәятыңның мөнтәһасы[2] ошбу көндәдер. Валлаһи, әгәр минем дәртемнең дәвасына бер чара тапмас исәң, муенынны ордырырмын, әлбәттә», — диде. Мин дәхи: «Бәли, бәли, шаять, бер чара табармын, юану бирүче булырмын. Һаман Аллаһы Тәгалә әмиремезне сәламәт итсен. Кичәге көн борадәрең Сәгыйднең ишеге төбендә утырып торыр идем. Нагяһ касыр эченнән бер җария чыкты. Гүяки аучының җәтмәсеннән ычкынган аһу баласы иде, ягъни курыккан кеше кебек борчылулы иде, өстендә искәндәрани нечкә күлмәк иде. Аның аркылы бәдәненең аклыгы вә күкрәгенең сафлыгы күренер иде. Вә аягында ике биек башмагы бар иде. Аягының аклыгы, башмагының кызыллыгына ишрак биреп, алмас кебек төсләр күрсәтер иде. Вә йөзенең кәйфияте шөйлә иде ки, ике яңагы ике кояш кебек. Ике күзе өстендә ике кашы ике җәя кебек. Күзләре гүя сихри төкәлү иде ки, тәэсир көче белән гашыйкны дулкынландыра иде. Гүяки борыны биллүрдән төзелмеш. Вә ал, кызыл булучы ике иреннән гүяки кан тамып торыр. Вә ул җария бу кәйфияттә нәфис икән, шунда билә тәкәллем кыйлыр: «Әй Аллаһның коллары, шикаять кыйлынмастыр, димәңез ки, исеме зикер кыйлынмай торган гыйшыкыма минем өчен дәва вә чара итмәгә кем бардыр ки? Килеп миңа гыйлаҗ кылыр иде! Зирәки аерылу озакка китте. Вә җавап кичекте. Шул җәһәттән күңелем хәйран вә гакылым пәришан булып, калебем пәрдәләнде. Йокым багланды. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте һәй шул таифәгә булсын ки, гыйшык юлында михнәт чигеп, мәгъшукаләремә ви-

---

[1] Инкыйзасы — бетүе.
[2] Мөнтәһасы — чиге, ахыры.

сал тапмаенча, һижран аерымлык уты белән көеп һәлак булдылар. Әй, кяшки минем өчен әгәр бу гыйшыклык сабырын йөкләмәгә бер чара булса иде, ни гүзәл эш булыр иде. Ләкин бавырым вә бәгырем белән сабырым бергә көеп китте. Сабырга көчем калмады, гыйшык уты сөягемә керде!» — дип, бик озак башын түбән салып торды. Янә башын күтәрде. Бәс, бу хәлне күргәннән соң, мин әйттем: «Әй гүзәлләр солтаны булучы гәүһәр парәсе җария, адәм җенесеннәнмесең, җен җенесеннәнмесең? Яки оҗмахтан чыккан хур кызымысың? Яки җир йөзендә бер могҗизамысың? Зирәки гакылыңның зирәклеге вә сүзеңнең гүзәллеге гакылымны хәйран кыйлды», — дидем.

Бәс, минем бу сүземне ишеткәч, йөзен җиң белән өретте, гүяки мине күрмәгәнгә салышты. Ягъни сарай эченнән бәгыре кәбаб булган хәлдә чыгып, мине күрмәенчә, чит кешеләрдән хали җирдер дип гөман кыйлып, күңелендә булган хәсрәт вә көенечләрен теленә китереп, хәлен үзенә үзе бәян кыйлганда, мине күргәч оялып китте. Аннан соң миңа хитаб кыйлып: «Әй меңлем, бу гыйшык бабында мин акланырлык булмакым җәһәтеннән гозеремне кабул ит. Аяучысы вә ярдәмчесе булмаган гашыйкның вә юлын адашмыш сагынучының хәле ямандыр», — дип, сараена кереп китте.

Валлаһи, әй әмирел-мөэминин, ул җария шулкадәр гүзәл вә сүзе шулкадәр ширин иде ки, ләззәтле тәгам ашаганда, ул җария хәтеремә килсә, бугазымнан ләззәтле тәгам да үтмәс. Хаһ, ниндәен гүзәлләр булсын, аның янында күземә чиркин күренерләр, дигәнемнән соң, Сөләйман әйтте: «Әй Әбү Язид, синең ошбу сыйфатлар белән зикер кыйлган җариянең җәмалыннан минем мөштак күңелемә ирешкән дәрт вә михнәтләр барчасы ул җариядәндер. Хилем вә вәкар[1] миннән китте вә сабыйлык хәлләре миңа кайтты. Әй Әбү Язид, белгел ки, ул җария турында гарәп шагыйрьләре димешләрдер: Дәлика бер якут кисәгедер ки, диһкан[2] кисәсеннән чыкты димәктер. Дәлика гәрчә падишаһлар нәсәбеннән булмаса да, бер якуттыр вә җарияләр арасындадыр, ятимдер. Ул җарияне борадәрем мең дирһәмгә сатып алмыш иде. Ул җария саткан егетнең үзенә дә гашыйк, имеш. Валлаһи, үлгән кеше үлмәс, мәгәр аның хәсрәтеннән үләр; вә кабергә кермәс, мәгәр аның кайгысы белән керер. Хәлбуки сабырда шатлык бар, үлемне көтмәктә таланмак бар, дип, җариянең хәл сөзешеннән хәбәр биреп әйтте: «Әй Әбү Язид, бар, Аллаһ сәламәтлек бирсен, кит», — диде. Вә бер бидрә дирһәм китереп, Әбү Язидкә бир, дип, голаменә әмер кыйлды. Мин дәхи ун мең дирһәмне алып хозурыннан чыктым, диде.

Вә дәхи Әбү Язид риваять кыйлмыштыр, кайчан ки Сөләй-

---

[1] Хилем вә вәкар — йомшаклык һәм горурлык.
[2] Диһкан — крестьян.

ман дәүләт Өмәвиядә бәйгать кыйлынып хәлифәлек тәхетенә җөлүс иткәч, мәзкүрә вә мәгъшукасы булган Дәликага малик булды. Яз фасылында гаутаи Шамның күңел ачу урынында чатырлар хәзерләтеп, мәкам әйтмеш иде.

Риваять кыйлынмыштыр ки: Сөләйманның Синан исемле мөганнисе вә хас нәдиме бар иде. Синан бер көн бер ай яктысы кичәдә кичнең бер өлешенә кадәр, сөрүр вә шатлык белән нәдимлек итеп чатырына йокларга килгән заманда, дусларыннан бәгъзе кемсәнәләр Синанга зиярәткә килеп, сәлам вә дога соңында «тәганни кыйлсана» дип илтимас иттеләр. Синан дәхи, тәгам хәзерләп, дуслары белән бәзем кыйлырга хәзерләнде. Вә әйтте: «Сез әмирнең холкын беләсез: аның мәҗлесеннән башка җирдә тәганни кыйлмага миңа фәрманы юктыр», — диде. Алар әйттеләр: «Безгә тәганни кыйлып, рухымызның азыгын бирмәс исәң, синең эчмәкеңә безнең ихтыяҗымыз юктыр», — дип, илтимас вә гозер кыйлдылар. Ахыр чарасыз Синан әйтте: «Кайсы көй белән тәганни итәем, бер көйне тәганни кыйлыңыз?» — дип, дусларының хәтере өчен алар теләгән мәкамны, ягъни мәһтаб Дәлика вә хөсне ликаны вә аның гыйшкын вә хөсне саутын фәһемләтеп, бәетне көйләде.

Дәлика, Синанның тавышын вә нәгъмәсен ишеткәч, чатыр пәрдәсе артына чыгып, Синанның ән көен тыңлап, Синанда булган матур аваз вә ләтыйфәтен күреп, нәзымында әхвәп гыйшык аның хосусында икәнен фәһемләп, Дәликаның күңелендә яшерен булган гыйшык уты хәрәкәткә килеп, битакатьлегеннән ике күзе яшь белән тулы булган хәлдә буылып-буылып егълаган тавышына Сөләйман уянды. Уянып, янында Дәлика булмагач: «Бу кайда китте?» — дип, чатырның алдына чыгып, Дәликаны бу кәйфияттә күргәч: «Әй Дәлика, бу ни хәлдер?» — дигәннән соң, Дәлика дәхи: «Ул үзе вә йөзе чиркин, ата-анасы дүн Синанның хәсән авазы әсәр итеп болай булдым», — дип хәйлә кыйлды. Сөләйман, Дәликаның күңеле бозылып, гакылы чуалган булганлыктан: «Синанны тотып монда китерерңез!» — дип, хадимнәренә әмер кыйлды. Дәлика дәхи Синанны оршыр өчен чакырганын фәһемләп хафа булды, үзенең хадимнәреннән берсенә әмер кыйлып әйтте: «Әгәр әмирнең хадименнән элгәрерәк Синанга барып хәбәр биреп качырсаңыз, ун мең дирһәм биреп азат кыйлырмын», — диде.

Әмма ул булмады. Сөләйманның җибәргән хадиме аннан элгәрерәк барып, Синанны әмир хозурына китерде. Сөләйман әйтте: «Әй Синан, мин сине моның кебек эштән мәныг вә нәһи кыйлмадыммы», — дип шелтә кыйлганнан соң, Синан әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, мине ошбу кәйфияттә гыйсъянга китерүче нәшвәи гакардыр, ягъни әче эчемлектер. Мин әфәндемнең тәрбияле колы вә гарес нигъмәтемен. Әгәр әмир колның гөнаһын гафу боерса, ижра кыйлсын», — дип гафу эстәде. Сө-

ләйман әйтте: «Бу мәртәбә гөнаһыңны гафу кыйлдым. Ләкин белмәсмесең ки, айгыр ат кешнәсә, бия аңа якын килер. Вә иркәк тәвә гөрләсә, ана тәвә висал тарафына сузылыр. Вә ир кеше тәганни итсә, хатыннар, ирләрнең морадын җан колагы белән тыңлап , рам[1] булырлар. Саклан ки, моннан соң мондаен саз чәлеп тәганни кыйлма. Зирә михнәт вә газабың озакка китәр, үлгәнче зинданда калдырырмын», — диде.

———

Гарәбстанда бер падишаһның Рәша вә Җәүзәр исемле ике мөганнияи зарифа вә әдибә җарияләре бар иде. Ул шәһәрдә дәхи Мәзид исемле бер мәзәкче вә көлдерүче кемсәнә булып, атаклылар мәҗлесеннән чыкмас иде. Вә кайда сый мәҗлесе булса, әлбәттә, ул мәзәкче анда булыр иде. Кичләрдән бер кич ул падишаһ бер хас мәҗлес ясады. Ул олуглар мәҗлесенә могтәбәр булгучы мәзкүр мәркин уен көлке вә мәзәк белән тәсәлли кыйлмак өчен мәҗлескә чакырды. Ул мәзәкче килеп, дәхи сый мәҗлесенә утырып, мәзкүр мөганнияләрнең фасылын тыңлап, үзенең сүз керештерү вә мәзәге белән халыкны көлдермәгә башлады. Мәгәр падишаһ мөкаддәмдә ул мөганнияләргә әйтеп куймыш иде ки, ул мәзәкче эчәсе шәрабка эч йомшартучы дару кушып бирегез, димеш иде.

Бәс, бу мәзәкче ул дару катышмыш пияләны тәкрар тәнавел кыйлып, бераздан соң тышка чыгасы килә башлады. Падишаһ моны сизеп тәнавем кыйлып, ягъни йоклаган булып ятты, мөганнияләр: «Әмиремез йоклый», — дип, килеп өстенә яптылар. Мөкаддәмдәге тәнбиһ үзрә мөганниләр вә җарияләр һаман тәганни вә тәрәннем кыйлып һич туктамаслар иде. Ул мәзәкче: «Тукта, бу бәетне генә әйтеп бетерсеннәр», — ди-ди, байтак заман вакыт кичте. Бик тышка чыгасы килеп: «Тукта, бу кызлар Ямәндә тәрбияләнгәннәрдер. Ямән лөгатенчә хаҗәтханәне мәрхас тәсмия кыйлыныр», — дип, кызларга: «Әй кызлар, мәрхасыңыз кайдадыр, күрсәтегез», — диде. Ул мөганнияләр, бер-беренә карап, белмәгәнгә салышып: «Бу әфәндемез ни әйтә?» — диештеләр. Берсе әйтте: «Янә тәганни кыйлсаңыз» дип илтимас кыйлыр», — дип, берсе бәет көйләп, мәзәкчене алдадылар. Аннан соң мәзәкче күңеленнән: «Ахыр, болар Мәккәдә тәрбияләнгән булсалар кирәк, сүземне фәһемләмәделәр. Мәккә истыйляхынча[2] әйтеп караем, — дип, — Мәхрәҗ кайда?» — диде. Янә мөганнияләр, бер-беренә карашып, икенче төрле шигырьне теләй дип, тәрәннем кыйлып сүзсез калдылар. Бу мәзәкченең янә морады булмады. Бәс, мәзәкче: «Янә сүземне фәһем итмәделәр. Гөманыма күрә болар Шамда үскән булмак кирәк, Шам лөгатенчә сораем, — диде. — Әй сәвекле-

---

[1] Рам — буйсынучы.

[2] Истыйляхынча — термин, атама белән.

ләрем, хаҗәтханәнез кайдадыр?» — диде. Кызлар дәхи икенче төрле бәетне тели, дип нәзым кыйлдылар, янә мәзәкченең морады булмады. Аннан соң мәзәкче ачигъланып: «Ля хәүлә, янә морадымны аңламадылар. Гөман итәмен ки, бу кызлар Мәдинәлек булсалар кирәк. Мәдинә лөгатенчә сораем, — дип: «Әй сәвекле гүзәлләрем, бәйтелхола кайдадыр?» — диде. Янә бу кызлар: «Әфәндемез янә башка шигырьне эстәр», — дип, тан көйләп, янә мәзәкченең морадын итмәделәр.

Бу мәртәбәдә мәзәкченең пошынуы инфигале артып: «Һи, болар сүземне фәһемләмәделәр. Мисыр хатыннарына, бәлки, якынлыклары бар микән? Мисырча сораем, — дип, — Бәйтелхаш кайда?» — диде. Тагы ул мөганнияләр: «Әфәндемез янә икенче мәкамны эстәр», — дип тәрәннем кыйлдылар. Мәзәкче янә: «Ахыр, болар Куфәдә тәрбияләнгән булмагайлары, куфәчә сорамак кирәк, — дип, — Кәниф кайда?» — диде. Бу мөганниyaләр дәхи: «Һай-һай, бу мөсафир әфәндемез һич шигырь тыңламактан туймас икән, бу мөсафир әфәндемез кебек бер дәртле кеше күрмәдек», — дип мактап, җан азыгы булган тәганни үзәренә фөтур[1] килмәс. Һаман хуш аваз эстәр, инде ул эстәгән саен шигырь табып җиткермәк тә мөшкел булды», — дип, көй белән шигырьне әйтә башлагач, мәзәкченең сүзеннән чыгарып алынган сүз белән шигырь әйтеп, мөганниyaләрнең белмәүгә салынуларыннан мәзәкченең чыдамы калмаенча, фөрьяд кыйла башлады.

Юрган астыннан әмир, бу вакыйганы күреп, көлмәенчә көчкә чыдап ятыр иде, каһкаһә белән кычкырып көлеп җибәрде. Аннан соң бу мәзәкче торып: «Һи уйнашчы хатыннар, әгәр минем максудымны белмәгән булсаныз, инде сезгә белдерәем!» — дип, шулчак итәген күтәреп, шул утырган җирендә мөганниyaләр өстенә бәвел вә тизәк кыйлып пычратты. Әмир һаман юрган астында көлеп ятыр иде. Юрганын ачып: «Һи хәясыз вә әдәпсез, сараемны кабахәт иттең», — дигәч, мәзәкче әйтте: «Минем сәламәтлегем синең касырыңнан газизрәктер. Һи ахмаклар», — дип кычкырды. Әмир моңар дәхи эче катканчы көлеп, ахырыннан мәзәкче күп бүләкләр белән разый кыйлып җибәрде.

---

Мәҗнүн шикелле мәшһүр гашыйклардан Җәмилнең мәгъшукасы Бәсинә бер киңәш өчен Габделмәлик бин Мәрван хозурына килмеш иде, Габделмәлик әйтте: «Әй Бәсинә, синең гашыйкың Җәмил шагыйрь синең хакында нәзым кыйлган сыйфатларны мин синдә берсен дә күрмәдем», — диде. Бәсинә әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, ул Җәмил мине шундаен күз белән карыйдыр ки, ул күз синдә юктыр. Ягъни синең карамакың

[1] **Фөтур** — ару, йончыгу.

гыйшык белән түгелдер», — диде. Мәхәббәт җәмал теләмәс димәктер.

---

Ибраһим бин әл-Мәһди Маэмүн хәлифәдән качкан заманында Зәйнәп бинте Әбү Җәгъфәр ханәсенә качып яшеренгән иде. Мәзкүрә Зәйнәп аны үзенең хәрәмендә бер бүлмәсендә саклап, хезмәтенә төс вә әдәптә заманында тиңе юк Мәликә исемле җариясен тәгаен итмеш иде. Вә бу җарияне биш йөз мең дирһәмгә сораганда да сатмамыш иде. Бу арада Ибраһим ошбу җариянең гашыйк хәйраны булды.

Беркөн ошбу җария Ибраһимның хезмәтендә иде, Ибраһим, дәрхаль җырлап, үзенең гашыйк икәнен белдереп, кавышу чарасын таләп кыйлды. Җария дәхи, тыштан Ибраһимның теләген фәһемләп, Зәйнәпкә барып, бу шигырьне әйтеп, вакыйганы хикәят кыйлды, Зәйнәп дәрхаль җариягә әйтте: «Сине һибә кыйлдым, бар, Ибраһимга бар, минем һибә кыйлганымны белдер», — диде. Җария дәрхаль кавышу белән сөенеч бирмәгә Ибраһим янына барды. Ибраһим янә баягы шигырьне җырлап тәкрар кыйлгач, бу җария һибә хәбәрен сөйләмәстән Ибраһимны дәрагуш[1] кыйлмак теләгәндә, Ибраһим әйтте: «Әй җария, кит моннан, мин хыянәт кыйлмасмын», — дип, кавышуны кире какты. Аннан соң җария әйтте: «Әй әфәндем, сәидәм мине сезгә һибә кыйлганын белдермәк өчен күндермеш иде», — диде. Ибраһим әйтте: «Алаймы, кил алай исә, кавышу бакчасының җимешләрен җыештыраек», — дип, хилвәтханәи хәлялдә зәвык кавышу белән морадларына ирешмешләрдер.

---

Холәфаи Өмәвийә заманында төстә вә әдәптә кәмаль вә хафизаи Коръән вә голум гарәбияне тәгълим итмеш бер җарияи мөмтаз[2] бар иде. Ошбу җарияне ишетеп, Язид бин Габделмәлик сатып алып висаленә наил булмыш иде. Җария дәхи Язидкә бик ярап, Язид аңа гашыйк иде.

Беркөн сохбәт кыйлып утырганда, Язид әйтте: «Әй җария, синең әкърибаң яки әүвәлге хуҗаңның әкърибасы юкмыдыр, таки аларны синең хәтерең өчен ригая вә ихсан вә икрам итәр идем», — диде. Җария, җир үбеп: «Әй әмирел-мөэминин, минем әкърибам юктыр, ятимәмен. Ләкин әүвәлге хуҗамның Мәдинәи Мөнәвввәрәдә өч дусты бар иде. Алар булса, сезнең саяңыздә бер зыяфәт күрсәләр ярар иде», — диде. Аннан соң Мәдинәнең валисенә ул өч кешегә һәр кайсына юл хәреҗе өчен унар мең дирһәм җибәреп: «Фәлән кемсәнәләрне Шамга җибәрегез», — дип язып әмер күндерде.

Тиз заман ул өч кеше, унар мең мәзкүр юл хәреҗен алып

---

[1] Дәрагуш — кочакка алу.
[2] Мөмтаз — берәр як белән башкалардан аерылган.

юлга чыктылар вә башкалага васыйл булып, изен белән Язид хозурына керделәр. Язид, аларны зиядә икрам вә зыяфәт кыйлып: «Мин бәгъд морадыңызны, һәрни булса, әйтеңез, әда кыйлыныр», — дип ихсан там кыйлды. Икесе, хаҗәтләрен гарыз кыйлып, Язидтан хаҗәтләренә наил булдылар. Әмма өченчесе әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, минем һич хаҗәтем юктыр», — дип, мохтаҗ булмау күрсәтте. Язид әйтте: «Сөбханаллаһ, һич хаҗәтсез кеше булырмы? Әгәр хаҗәтең булса, мин аны әда кыйлмага кадир түгелме», — диде. Ул кеше әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, бәли, әда кыйлмага кадирсыз. Ләкин куркамын ки, минем морадымны әда кыйлмассыз», — дип шик белдерде. Язид янә әйтте: «Әйт хаҗәтеңне, урынлы булмаган эшне әда кыйлмаска тырышырмын», — диде. Ул егет дәхи: «Әй әмирел-мөэминин, җәзалатмаска вәгъдә алмастан сөйләмәгә куркамын». Язид әйтте: «Һич вакыйга юк, әман бирдем, сөйлә», — диде. Аннан соң мәҗлесне хәлвәт кыйлдырып әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, бу колларыңызны тәрбия кыйлып, ингам-ихсан боердыңыз. Җариянезнең өч көй белән укыла торган тәганнисен ишетәсем киләдер», — дип нәзар бәркадәм булып, хая вә әдәп белән торды. Әмирнең гәрчә бу хосуста йөзе үзгәрсә дә, гаһед итеп әман биргәненә күрә, гаһелкә вафа дәхи мәҗбүр булып, дәрхаль торды да, хәрәменә барып, вакыйганы җариясенә сөйләде. Җария дәхи бу егеткә гашыйк, имеш. Күңеленең морады мәгъшукын күрмәк булганга күрә: «Әй вәли нигъмәтем, бу хосуста ярдәм итсәңез, зат дәүләтеңезгә зарары юктыр», — дип нияз кыйлды.

Аннан соң Язид бер эчкәреге бүлмәдә, халыкка тавыш ишетелмәслек җирдә, җарияне бер җиргә пәрдә артына утыртып, ул егетне дәхи бер почмакка утыртып, вә үзе тәхет өстенә утырып, егеткә әйтте: «Инде, әй егет, морадыңны әйт», — диде. Егет әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, җарияңезгә әмер кыйлып, бер тәганни кыйлдырсаңыз иде», — диде. Язид ул җариягә боерды. Җария дәхи гашыйканә хәсрәт итеп дәмсаз булды: «Мәгъшукымның гыйшыкы хәсрәтеннән чиккән зәхмәтем бәрабәренә юаныч тапмага кадир була алмамын. Инде бу гыйшкың миңа иткән зәхмәтеннән дәхи артык зәхмәт итәрме? Хәсрәтемнең ниһаяте булды. Ярымның аерымлыгына күңелемне дәгъвәт кыйлсам, миңа итагать итәр вә, әлбәттә, аерылган булырмын. Ләкин, әй күңелем, синең ошбу итагатең чынмы? Ихлас белән чын күңелдән һиҗран вә ифтиракны эстәрмесең, дисәм, сиңа вәгъдәләшүле кыйлырмын, дип сидкын исбат итәр. Син, үлмәй торып, бу гыйшыктан хәлас булмассың», — димәктер. Моннан соң янә ошбу бәетне тәганни кыйлды: «Һавасы нәфис вә сәйрангяһ булгучы Ногман тавының җирендә үскән өрек агачыннан мәгъшукам өчен бер нәфис ботак эзләдем вә таптым. Ләкин ул нәфис, зифа чыбыкны Һиндстанга илтүче кем булыр? Агяһ булыңыз вә кәрәм итеңез, әй ике тау, Аллаһы

Тәгалә сезне даим мөбарәк итсен: мине өстенезгә мендеренез, мәгъшукым булучы һинд сезне күрмәк өчен килмәк касдында булмаса да, җиренез борын-борыннан кәсеб сәгадәт иткәнлегеннән, мин аны күргән кебек булып, бу сурәттә күңел ачыла, димәктер». Бәетендәге икенче Һинд-Һиндстан булмак ихтималдыр, чөнки шуңа ишарәли. Һинд Газра, Ләйлә, Сәгад, Сәлми — гарәпләрнең мәшһүр гашыйкларыннандыр, әмма, һәрбер урынына күрә, тик мотлакан мәгъшука мәгънәсендә кулланыладыр.

Бу тәганнидән соң дәхи тәганни кыйлды. Бу бәетләрне тәганни кыйлып, гашыйкларның бәгырен яндыра торган сүзләрне әйтеп, тәмам булмастан әүвәл ул гашыйк садыйкның һушы китеп сандалидан егылды, һушсыз булды, янып китте. Әмир, бу хәлне күргәч, әйтте: «Әй җария, кара, ни булды?» — диде. Җария барып кыймылдатып карады, вафат булмыш күрде. Бәс, әмир, бу кәйфиятне күргәч, гаять хафаланып: «Әй җария, бу бичара өчен егъла», — диде. Җария әйтте: «Әй әмир, син хәятта вакытта, мин аның өчен егъламам» — диде. Моның үзәренә әмир аяучы янә: «Әй җария, егъла! Чынлап егъла! Әгәр ул егет вафат булмаса, чынлап сине һибә кыйлыр идем», — дип, әмир һәм егълады, җария һәм егълады.

Әмир әмер кыйлды, ул егетне кәфеннән җиһазлап, бер зыярәткяһтә дәфен кыйлдылар. Әмма ул җария дәхи, берничә көннәр үткәч, гыйшык дәртеннән вафат булып, ул егетнең янында дәфен кыйлдылар.

———

Габдулла бин Җәгъфәр, Мәдинәи Мөнәввәрәдән бер эш хосусында Габделмәлик бин Мәрванны күрмәк касды белән, Шамга килмеш иде, Габделмәликнең кунакханәсендә хөрмәтле кунак. Бер кичә сохбәт кыйлып утырганда, Габделмәлик әйтте: «Әй ибн Җәгъфәр, гашыйклар кыйссасыннан күргән гаҗәиб кыйссаларың булса, хикәят кыйл ки, ләззәтләник», — диде. Ибн Җәгъфәр әйтте: «Бу бабта күргән ят вакыйгам будыр ки, әй әмирел-мөэминин, минем ун мең дирһәмгә сатып алган бер җариям бар иде. Гаять оста вә әдибә иде. Хәтта Язид бин Мөгавия җариянең гүзәллеген, матурлыгын ишетеп: «Яки миңа ул җарияңне һибә кыйл, яки сатып бир!» — дип язмыш иде. «Милкемнән чыгармаска вәгъдә иткән идем», — дип җавап язмакым белән сөкүт туктаган итмеш иде.

Үземнең көннән-көн җариямә мәхәббәтем вә гыйшкым артып торган хәлдә, беркөн күршемнең хатыны, яныма килеп: «Йә сәед, хәбәрең бармыдыр ки, синең сәвекле җарияң белән бер Мәдинә гарәбе арасында бәйләнеш җебе вә мәхәббәт булып, берен-бере күрмәктән туктаганнары юк. Мәзкүр гарәп, һәр кич йөзенә пәрдә ябып вә киемен үзгәртеп, гайре табигый сурәттәрәк җария тора торган бүлмәнең тәрәзәсенә якын килеп, җария дәхи тәрәзә ярыкларыннан карар вә пәрдә артыннан

тәганни итәр. Гарәп тыңлап егълар да кайтып китәр. Үштә хәлләре будыр», — диде. Мин, дәхи җариямә белдермәенчә, бер хәйлә белән ахшамнан соң бер дустымның янына барамын, дип чыктым. Бер яшерен җирдә качып тордым. Филхәкыйкать, гарәп башын пәрдәләгән хәлендә килде. Вә җариям дәхи, тәрәзәгә барып, бер-беренә хитабан гыйшык вә мәхәббәт сүзләре белән сөйләшеп, таңга кадәр сөйләштеләр. Ләкин фәхшиятка дәляләт кыйла торган сүзләрен ишетмәдем.

Аннан соң бер җирдән кайткан кәйфияттә булып ханәмә кердем. Җарияләремнән баш җариямне чакырып: «Бар, фәлән җариямне, ягъни ул гашыйка җариямне тиз заман, һичкем күрмәсен, киендереп, зиннәтләп, яныма алып кил», — дип җибәрдем. Дәрхаль киендереп китерделәр. Илтифат белән кулыннан тотып, хәрәмем капусыннан бергә чыгып, ул гарәпнең янына бардык. Күрдем ки, гарәп һушы китеп ятыр. «Әй углым, тор», — дип уяттым. Калтырап, каушап торды. «Зарар юк, курыкма, курыкма», — дип юаттым. «Ошбу җариямне сиңа һибә кыйлдым», — дидем. Бер аһ чигеп, янә куркуга калды. Асла җавап бирмәде. Колагына иелеп: «Әй егет, Аллаһы Тәгалә сине морадыңа гали вәҗһел хәлял ирештерде, шөкер ит, бу жарияне ал», — дидем. Җавап бирмәде. Кулым белән кыймылдатып карадым, күрдем ки: җан-тәслим кыйлмыш иде. «Әй әмирелмөэминин, гыйшык хосусында моннан гаҗәп нәрсә күрмәдем», — дидем. Габделмәлик әйтте: «Чыннан да, гаҗәп нәрсә сөйләдегез. Егет вафат булгач, җариягә ни булды?» — диде. Әйттем: «Әй әмирел-мөэминин, җария, дәхи егетнең фиракыннан хәстәләнеп, тиз заман вафат булды» — дидем».

———

Мөхәммәд бин Васигъ әл-Әзди риваять кыйлмыштыр ки, Габделмәлик бәйсезлек белән Гыйрак валисе булгучы мәгъруф Хәҗҗаҗга бер әмернамә күндерде. Мәзмуны бу иде: «Әмма бәгъдә, бу әмернамәмне алып укыгач, минем өчен кара тәнле затлы булып тугмыш вә шәһәр тәрбиясе белән тәрбияләнмеш гаять гүзәл өч җария табып, бәһаләрен вә сыйфатларын язып, ул җарияләрне хөрмәтләп вә кадерләп, тарафыма күндерәсең...» дигән. Кайчан ки бу әмернамә Хәҗҗаҗга васыйл булды, Хәҗҗаҗ әмернамәне укып, мазмунын фәһемләгәч, нәххасларны[1] чакырып, күп бәһа биреп, шәһәрләрдән вә карьялардән мондаен җарияләрне тапмага боерды. Вә бу хосуста һәр әтрафка махсус намәләр күндерде.

Нәххаслар шәһәр гизеп, Габделмәлик теләгенә яраклы тиңсез өч данә җария табып, Хәҗҗаҗ хозурына китерделәр. Хәҗҗаҗ кан түкмәктә никадәр үткен булса, сәнгатьтә дәхи ул кадәр үткен иде. Хәрәмендә булган ханымнар васитасы белән

[1] Нәххасларны — кол белән сәүдә итүчеләрне.

мәзкүр җарияләрнең сыйфатын сорап белеп, Габделмәликкә намә яздырды: «Әмма бәгъдә, Аллаһы Тәгалә әмирнең гомерен озын итсен, фәрманы миңа васыйл булды. Намәдә зат галиләре өчен өч бәкер җария табып, бәһаләрен вә сыйфатларын бәян кыйлып, миңа ирсал җибәр, димеш иде. Әй әмирел-мөэминин, әмер галиеңезгә имтисалән ошбу җарияләрне тапмак хезмәтендә булдым. Вә сыйфатлары ошбу бәндәңезнең белүенчә биләдер. Әүвәлге җария — тамак асты озынча мөдәввәр[1], арты симезчә, күзләре тумыштан сөрмәле, бит алмалары татлы, ягъни гүзәл, имиләре хәзер генә чыга башламыш, тезләре бер-беренә янәшә, гүяки алтын белән көмеш катышмыш тубы булып, шагыйрьнең мәзкүр бәетендәге васыфы расланадыр, бәһасе утыз мең дирһәмдер. Икенче җария — матурлык бик әгъля, камил урта буйлы, мөлаем сүзле, хәстәгә шифа бирер бакирә җария булып, әй әмирел-мөэминин, бәһасе алтмыш мең дирһәмдер. Өченче җария — күз тибрәтмәке зәгыйфьрәк,ләтыйф вә йомшак куллы, күндәмлеге тулы, азга шөкер кыйлгучы, зәүҗенә ярдәмче, гүзәллеге гаҗәеп, гүяки аһу баласы бер җария булып, йә әмирел-мөэминин, бәһасе сиксән мең дирһәмдер» дип, җарияләрнең сыйфатларын вә бәһасен белдереп, намәсене язып вә мөһер орып, юл кирәкләрен хәзерләмәгә әмер кыйлды. Вә бу җарияләрне саклап вә тәрбияләп, башкалага илтеңез, дип тәнбиһ кыйлып, хезмәткәрләр белән Шамга җибәрде. Ләкин бу җарияләрне китергән нәххаслардан бере карт кеше булганлыктан, әүвәлге сәфәрдә зәгыйфьлек килеп: «Мин бара алмаймын. Минем урыныма икенче кешене җибәрсәңез иде», — дип гозер иткәч, аның урынына бер егетне җибәрделәр.

Кәрван юлга чыгып китте. Бер мәнзия баргач, бер һәйбәт күләгәле җирдә туктап, мәзкүр җарияләр шәмсияләре[2] астында истирахәт кыйлып йоклаган хәлләрендә, Мәкътүм исемле җарияи куфиянең күкрәген җил ачып җибәрмеш. Бу җарияләрнең чатырлары яныннан очраклы мәзкүр егет, узып барганда, нагяһ Мәкътүмнең ай кебек балкыган күкрәген күреп, шул сәгатьтә Мәкътүмгә гашыйк хәл булып вә ихтыяры кулдан китеп, янына барды. Ошбу бәетне Мәкътүмнең башы очында укып торганнан соң, кыз дәхи, уянып, дәрхаль егеткә гашыйк булып, ошбу бәетне нәзым кыйлды: «Әй егет, әгәр әйткән сүзең раст булса вә гыйшыкың чын исә, кич эчендә безгә зыярәт кыйл», — дип, вәгъдә вә ризасын мөшгыйрь җавап бирде.

Кич булгач, егет гыйшык юлында җанын фида кыйлып, муены киселәсе кылычын муенына баглап, ягъни җаныннан өмид өзеп, Мәкътүмнең янына барды. Күрде ки: җария дәхи, көтеп карап, аяк үзрә торыр. Шунда ук егетнең кулы тотып, бергә

[1] Мөдәввәр — йомры, түгәрәк.
[2] Шәмсияләре — зонтлары.

качмак ирадәсендә икәннәр, саклап вә хадимнәр моны сизеп, егетне тотып багладылар. Шул рәвешчә, аягы-кулы баглы хәлдә, җарияләр атлары белән, Шамга васыйл булып, ирекле ымсындыручы патша бортына хөр, Мисраи дареләмарәгә керделәр. Вә җарияләр Габделмәлик хозурына китерелеп, һәркайсы аяк үзрә хәлифә хозурында тордылар. Хәҗҗаҗның намәсе укылды.

Җарияләрнең икесе намәдә язылганга муафыйк сыйфатта булып, өченчесе, ягъни Мәкътүмнең йөзе бернечә сары вә бәдәнендә үзгәрешләр барлыктан, нәххасларны вә хадимнәрне чакырып: «Өченче җариянезгә ни булды? Хәҗҗаҗның намәсендәге сыйфатка мөтабыйк түгелдер», — дигәч, җавапларында: «Әй әмирел-мөэминин, әман боерсаңыз, сөйләрмез», — дип әман алдылар. Габделмәлик: «Тугыры сөйләнез — юкса һәлак итәрмен», — дип, сөйләмәгә дәстүр бирде. Алар дәхи Мәкътүмнең егет белән булган вакыйгасын кәма һүә нәкыль кыйлдылар. Габделмәлик әмер кыйлды, егетне чылбырлары белән чалтыратып китерделәр. Бу егет, шиксез җаныннан өмид өзеп, каты аваз белән егълап гафу үтенеп, бу нәзымны әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, мин, мәрхәмәтеңез хозурына кулларым муеныма багланмыш булган хәлдә, йөземне түбәнсетелү, хурлык туфрагына сөреп китерелдем. Бу әдәпсезлек белән кыйлган кабахәт эшемне таныймын: алар хәбәр биргән гөнаһ һәммәсе миндә бардыр. Әгәр җәзага әмер итсәң, җирендәдер. Гөнаһыма караганда, миңа җәзел генә аздыр, ягъни хөкем белән үтерсәң дә, шуңа хаклымын. Әмма, әгәр гафу итсәң, миңа җумартлык вә ихсаныңдыр», — диде.

Бәс, Габделмәлик моны ишеткәннән соң, егетнең табигатен яратып, вә раст әйткәнлегенә егетне кызганып: «Әй егет, безне мыскыл кыйлып, бу эшеңә ни сәбәп булды, әллә җариягә гашыйк булдыңмы?» — дип шелтә кыйлып, егетне сөйләштереп, бәлки, аңа җавап юлын күрсәткәннән соң, ул матур сөйләм иясе егет: «Бәли, әй әмирел-мөэминин, сезнең дәүләтеңезнең вә олуг кодрәтеңезнең хакы өчен мине бу һәлаклек чокырына салган вә гыйшык тозагын күңелемә аткан җариядер», — диде. Габделмәлик, янә егетне кызганып: «Әй егет, алайса ул җарияне сиңа һибә кыйлдым», — дип, чыннан да, җумартлык кыйлды. Вә ул егет дәхи, җаныннан өмид кискән хәлдә, тугрысын сөйләп, бу куркынычтан хәлас булгач, ул ләгыль вә җәваһир белән бизәлгән хәзер җарияне алып, шат бәхетле, үзенең шәһәре тарафына китүче кәрван белән рәван булды. Кәрван барып, әүвәл мәнзилгә туктадылар. Кич белән кәрван халкы һәркайсы чатырларына кереп ял иткәндә, бу егет дәхи җария белән үзләренең чатырында бер-беренә сарылып яттылар.

Иртә булгач, кәрван халкы хәзерләнеп кузгалып киткәндә, боларның чатырында бер дә кыймылдаган кеше күренмәгәч:

«Тукта, боларны уятыйк, аерылып калмасыннар», — дип, чатырларына барып күрделәр. Икесе бер җирдә кочаклашып вафат булмышлар. Барлык кәрван халкы, еглашып, бичараларны кәфенләп вә намазларын укып, ул ике гашыйк, бер тәнне юлның бер читенә дәфен кыйлып калдырдылар. Бу хәбәрне Габделмәлик дәхи, ишетеп, тәгаҗҗеб кыйлып еглады.

———

Мәшһүр сәнгатьче Әсмәгый хикәят кыйлмыштыр: «Беркөн сахрада гизеп йөргән вакытында бер таш күрдем ки, өстендә язылмыш иде: «Әй гашыйклар гөруһы, әгәр бер егетнең башына гыйшык төшсә, ул егет ни эшләсә кирәк? Ягъни гыйшык дәртенә ни белән дәва итсен, хәбәр бирегез?» димәктер. Әсмәгый дәхи ул язуның астына бәет язып куйды. Бәетнең мәгънәсе: ул гашыйк булган егет, гыйшыкка сабыр итеп, хәлен яшерсен вә һәрбер эштә мәгъшукы тарафыннан ләтыйфмы, золыммы зоһур итсә, күндәм аек түбәнчелек белән кабул итсен.

Янә икенче көндә Әсмәгый ул таш янына барып күрде ки, Әсмәгыйның җавабын астына янә бәет язылмыштыр: «Ялгыз, тик ул гашыйк егетне үтерүче гыйшыкка сабыр кыйлынырмы? Ни кәйфияттә сабыр итмәк кирәк?». Ягъни: синең сабырына чаклы ул сине үтереп ташлый.

Әсмәгый янә өченче мәртәбә ул таш янына килеп күрде, мәзкүр бәет язылмыш иде. Аның астына дәхи Әсмәгый язып куйды: «Сабыр итеп серен яшерергә кадир булмаган гашыйкка үлем артыктыр, кайгысы бетәр», — дип язып киткәннән соң, бервакыт янә килеп караса, күрде: таш янында бер егет вафат булып ятыр.

———

Бәрмаки сөләләсенең[1] бәгъзе әмирләреннән сорадылар: «Ни сәбәпле дәүләтегез китте вә хәлифәлегегез мөнкарыйз егылды?» — диделәр. Ул әмир әйтте: «Иртә күп йокладык, кич күп эчтек, гафил үткәрдек, ялкау булдык, мәмләкәтне карамадык», — диде.

Хәкимнәр димешләрдер ки: «Тәкъдиргә күп сылтау кыйлмак гаҗизлеккә дәлаләт кыйлгучыдыр». Ягъни берәү үзе ялкау буладыр да, «безгә инде тәкъдир шулай» дип, тәкъдиргә сылтау кыйла башлыйдыр; әүвәл иҗтиһадыңны сарыф кыйлып кара, аннан соң, булмаса, тәкъдир шулайдыр! дип әйтсәң әйтерсең.

———

Нәүширван Гадел падишаһ булмастан мөкаддәм гыйлем вә фәннәр укыганда, остазы беркөн Нәүширванны берничә мәртәбә сугып рәнҗетте. Нәүширван падишаһ булгач, остазының тәкълим вакытында сукканы күңеленнән чыкмаенча, беркөн остазына: «Әй остаз, фәлән вакытта һичбер гөнаһсыз мине суктың, ни сәбәп иде?» — дип шелтә кыйлып сораганда, ул хәким

[1] Сөләләсенең — ыруының, династиясенең.

остаз әйтте: «Әй мәлик, һәр фәнне тәхсил кыйлдың, золымлык фәненнән дә сиңа дәрес бирәем, дип, золымны сиңа татыттым. Вә, золым ачы нәрсә икәнен белеп, падишаһ булгач, Аллаһы Тәгаләнең бәндәләренә золымлык итмәгәйсең», — дип җавап бирде. Бәс, Нәүширван моны хуплап, остазының гафуын эстәп, тәгъзыйм вә тәкрим кыйлды.

---

Муса галәйһиссәлам заманында бәни Исраилдән ишле гаиләле бер фәкыйрь кеше, балык тотып, аны сатып, акчасы белән балаларын вә җәмәгатен нәфәкаләндерер иде. Беркөн бу фәкыйрь балык тотканда, ятьмәсенә бер олуг балык керде. Мәзкүр фәкыйрь зиядә шат булып, ул балыкны сатарга барганда, забит мәкуләсеннән[1] бер кемсәнә очрап, ул фәкыйрьнең кулыннан балыкны көчләп тартып алмак касдында икән, балыкчы бирмәгәч, балыкчының башына кулындагы таягы белән сугып башын ярды. Балыкчы фәкыйрь, моңар бик рәнҗеп: «Илаһи, мин бәндәңне зәгыйфь вә ул залимны куәтле итеп яраттың. Миңа золым иткәне үзеңә мәгълүмдер. Илаһи йа Рабби, хакымны бу дөнья йортында ал, ахирәткә калдырма», — дип бәддога кыйлды.

Кайчан ки ул залим бу фәкыйрьнең кулыннан балыкны көчләп алып өенә кайтты, җәмәгатенә пешерергә бирде. Балык пешеп, ашарга утыргач, бу залим балыкка кул сузганда, балык, Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән авызын ачып, моның кулын шулкадәр каты тешләде, хәтта авыртканына сабыры калмаенча, табибка дәва кыйлдырмага китте. Табиб күреп әйтте: «Бармагыңны кистермәсәң, моңар дәва юктыр. Әгәр кисмәсәң, бөтен бәдәнеңә үтеп китәр», — диде. Бәс, бу залим бармагын кистерергә разый булды. Бармагын кистереп өенә кайткач та, һаман авыртуы бөтен кулына үтте. Янә шул табибка барды, табиб әйтте: «Кулыңны беләгеңә кадәр кистермәсәң, төзәлмәс», — дигәч, янә беләгенә кадәр кулын кистерде.

Ахыр, һәрбер кистергәндә, югары үтеп, кулын, беләген, хәтта әгъзасын билә турамак лазем килеп, бу залим, бичара, җаныннан өмид кисеп, егълап сахрага чыкты. Бер агач төбенә ятты. Йокыга китте. Төшендә әйттеләр: «Әй бичара, дәва вә чара касд кыйлып, әгъзаңны ничә мәртәбә кистердең, чара тапмадың. Бар, кит, ул рәнҗетелгәннән ризалык сора вә аны разый кыйл», — дигән аваз ишетеп, йокысыннан уянды. Дәрхаль тәүбә кыйлып, шәһәргә кайтты. Ул рәнҗетелгән балыкчыны эзләп тапты. Көчләп талап алган балыкның хакын түләп вә ул аның кичерелүен теләп егълады. Аннан соң балыкчы разый булып дога кыйлды. Бу залимның бераз авыруы басылып, рәхәтләнеп йоклады. Йокысыннан уяның күрсә, кулы тәмам сәламәт булмыш. Бу хосуста Муса галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләдән вәхи килде:

[1] Забит мәкуләсеннән — забит (иминлек хезмәткәре) төркеменнән.

«Әй Муса, гыйззәтемгә вә җәлалем белән ант итәмен ки, әгәр дә ул залим шул фәкыйрьне разый кыйлмаган булса, гомере барынча билә газапта калдырыр идем», — диде. Мәгълүм булды ки, рәнҗетелгәннәрнең догасы дөньяда вакытта орып егадыр, имеш.

---

Дәфгы мәзалим[1] өчен Нәүширван мәҗлескә утырганда, хозурына бер тәбәнәк кеше килеп: «Йә әмир, мин тәбәнәк кешемен, рәнҗетелгән кешемен. Миңа золымлык кыйлдылар», — диде. Нәүширван әйтте: «Юк, тәбәнәк кешегә берәү дә золым итмәс», — диде. Ул кеше әйтте: «Йә әмир, ул миңа золым иткән кеше миннән дә тәбәнәк иде», — диде. Нәүширван көлде дә, шикаятен кабул кыйлды.

---

Әбү Ямән әйтте: «Безнең бер шәехемез бар иде. Аны халык Исме Әгъзам догасын белер дип гөман кыйлырлар иде. Ул шәехемез миңа әйтте: «Әй карендәш, син калебеңне таныйсыңмы?» — диде. «Бәли, таныймын», — дидем. Шәех әйтте: «Кайчан ки калебең нечкәрсә, кыйблага каршы утыр, Аллаһы Тәгаләдән хаҗәтеңне сора — Исме Әгъзам ошбудыр», — диде.

---

Бер карый бер хәлфәнең исеме белән хитаб кыйлды. Хәлфә ачигъланды, әйтте: «Көнья кайда?» — диде. Карый әйтте: «Аллаһы Тәгалә сөйгән бәндәсен исеме белән әйтте, сөймәгән бәндәсен көньясе белән әйтте», — диде.

---

Гомәр бин Габиднең ишеген берәү какты. Гомәр: «Кем бар анда?» — диде. Ул кеше әйтте: «Мин». Гомәр әйтте: «Безнең нәселемездә Мин исемле кеше юк», — диде.

---

Берәү бер кешедән сорады: «Син ни исемле?» — диде. Ул кеше әйтте: «Бәхер (ягъни диңгез)». «Кем атасы?» — диде. Ул кеше әйтте: «Әбү Фаез (ягъни ташу атасы)». «Кем углы?» — диде. Ул кеше әйтте: «Ибн Әлфөрат (ягъни Фөрат[2] углы)». «Алайса синең белән утырыш кыйлырга көймә кирәк», — диде.

---

Бәшәрнең ишеген берәү какты. Бәшәр әйтте: «Анда кем бар?» Ул кеше әйтте: «Мин». Бәшәр: «Әйдә, Мин, кер алайса», — дип, ишек ачып кертте.

---

Гомәр разыйаллаһу ганһу бер кешегә әйтте: «Синең исемең ничек?» — диде. Ул кеше әйтте: «Җәмрә (ягъни утлы күмер)», — диде. Гомәр әйтте: «Кем углы?» Ул кеше әйтте: «Ибн Шиһаб (ягъни Ялкын углы)». Гомәр әйтте: «Кайдан килдең?» Ул кеше

[1] Дәфгы мәзалим — золым күренешләрен хөкем итү.
[2] Фөрат — Евфрат елгасы.

әйтте: «Хәркадән (ягъни Җаныктан)». Гомәр әйтте: «Кайда торасың?» Ул кеше әйтте: «Хәраттә торамын (ягъни ташлыкта)». Гомәр әйтте: «Бар, алайса җәмәгатең янып бетте», — диде. Бу кеше өенә кайтты, күрсә, җәмәгате янып бетмеш.

---

Гомәр разыйаллаһу ганһу бер кешедән ярдәм таләп итмәкче булды да исемен сорады. Ул кеше әйтте: «Минем исемем Залим бин Сәррак[1]», — диде. Хәзрәти Гомәр әйтте: «Ярый, бар, син залим бул, атаң угырласын», — диде, һичбер ярдәм эстәмәде. Ягъни аның исеменнән шомланды.

---

Гарәпнең бер кечкенә баласына әйттеләр: «Син кем углы?» — диделәр. Ул бала әйтте: «Уау, уау», — диде, чөнки атасы Кәлеб (эт) исемле, имеш.

---

Бер кеше Фәрәздак дигән мәшһүр шагыйрьгә әйтте: «Син кем?» — диде. «Мин — Фәрәздак (ягъни камыр кисәге)», — диде. Ул кеше әйтте: «Мин сине белмимен, ләкин фәрәздакны (камыр кисәген) безнең хатыннарымыз ашый», — диде. Фәрәздак әйтте: «Аллаһка шөкер, мине Аллаһы Тәгалә хатыннарыгыз корсагына керткән, имеш».

---

Берәү риваять кыйлмыштыр: «Юлдашларым белән бер сәфәремездә сәкаттан бер колның тирмәкенә кереп күрдек. Бер почмакта баглап куелмыш бер мәҗнүн шигырь укыр. Янына барып тыңлап: «Һи, бәрәкаллаһ», — дип тәхсин кыйлганымыздан соң, «Безгә атмага касд итеп кулына бер таш алып, минем кебек мәҗнүнгә ниндәен тәхсин булсын», — диде. Безгә таш белән атар дип куркып киттек. Ләкин артымыздан: «Әй, кайтыгыз, сезгә янә бер шигырь әйтәем, әгәр яхшы сөйләсәм — әхсин вә яман сөйләсәм, тәкъбих әйтеңез», — дип ант итеп, ялвармага башлады.

Янә янына килдек. Берничә шигырь укыды. Ошбу бәетләр, филхәкыйкать, гашыйкның ут тоташмыш күңеленең учагыннан сачылмыш очкыннардыр. Гашыйкларның бәгырен көйдерүче бер сүздер. Шигырьнең мәзмуны ошбудыр: кайчан ки таңнан әүвәл, ягъни сәхәр вакытында килгән илчеләр ак төсле тәвәләрен мәгъшукамның ханәсе капусына чүктереп, мәгъшукамны вә аның белән китәчәк рәсем кебек гүзәл кызларны тәвәгә мендереп киткән заманда, мәгъшукам, күзене беркәнчеге арасыннан читләр күрмәсен диебрәк, аз гына күрсәтеп, аерылу уты белән хәсрәт чигүче ошбу гашыйкына (ягъни миңа), кыналы бармакларының очлары белән хушлашканда, шөйлә фөрьяд итеп гыйшык вә җинүемне ватып: «Әй мәгъшукамны

---

[1] Сәррак — карак.

утыртып, аны миннән аерып алып китүче тәвә, синең аякларың йөкне тарта алмасын, ягъни һәлак булгайсың. Вә, әй тәвә, син, җыр белән тизләтүче тәвәче, тәвәңне кайтар, таки мәгъшукам белән вә бергә киткән сөекләләрем белән хушлашып, исәнләшеп калаем. Зирә, әй тәвә, сине әйдәтеп, минем мәгъшукамны алып киткән тәвәче, синең китмәкендә әҗәл бардыр! Инде мин икенче мәртәбә аны күрәчәк түгелмен! Вә мин шул мәхәббәт гаһедендә шулкадәр нык торам ки, гыйшык вә мәхәббәтемне сындырмам, гашыйк бичара ул озак фиракълыкта ни эшләр?» — димәктер».

Ошбу хикәятне нәкыль кылучы димештер ки: «Ул мәҗнүн, бичара, мәзкүр шигырьне әйтеп, аһ корып, егъламага башлады һәм вафат булды. Шигыренең таләбенчә, ул мәҗнүннең сылтавы җен түгел, имеш, бәлки гыйшык чамадан тыш, имеш ки, барлыгы юкка чыгуга сәбәптер.

———

Бер гарәп сәфәрдән кайтты. «Файда иттеңме?» — диделәр. Гарәп әйтте: «Сәфәрдән файда итмәдем, мәгәр намазны кыска укыдым», — диде.

———

Бер гарәптән сорадылар: «Шатлык ни-нәрсәдер?» — диделәр. Гарәп әйтте: «Сәфәрдән зарарсыз кайтмак, гайбәтсез мәҗлес кыйлмак», — диде. Бәгъзеләр үз шәһәрендә мәшәкать тартмак — сәфәрдә рәхәт чикмәктән артыктыр, димешләрдер.

———

Бер гарәп әйтте: «Сәфәр кыйлмак ният итеп күңелемнән әйттем: әгәр сәфәр аенда сәфәр кыйлсам, кулым буш кайтмакым ихтималдыр. Әгәр мөхәррәмдә сәфәр кыйлсам, мәхрүм кайтмагым ихтималдыр, дип рәбигыл-әүвәлдә сәфәр кыйлдым. Сәфәрдә авырдым. Уйлаган идем, рәбигъ ашау-эчүдә чикләнү дип, баксаң, рабигъ чир икән», — диде.

———

Беркөн Язид бин Мәһләб янында Сөләйман бин Габделмәлик кунак булган. Аннан чыккач, сорадылар: «Язид мәҗлесендә ни яхшы нәрсә күрдең?» — диделәр. Сөләйман әйтте: «Хезмәтчеләре, әмер кыйлмастан, ишарәт белән хезмәт итәләр икән», — диде.

———

Мәдрәсәдә бер шәкерт үзенең энесен куа: «Бар, фәлән, су алып кер, минем эчәсем килә», — диде. Энесе бармады. Кабат әйтте. Бармады, чөнки энесе яткан иде. Боларның хәлфәләре бар иде, ул әйтте: «Бар, син фәлән, үзең миңа су алып кер, минем эчәсем килә», — диде. Ул шәкерт торды. Су алып керде. Хәлфәсенә бирде. Хәлфә әйтте: «Ярар, рәхмәт, үзең эч инде, мин эчмәймен», — диде.

---

Мәэмүн хәлифәдә хезмәт итеп чыккан бер кеше бар иде. Мәэмүн аңа беркөн бер эш хосусында бик ачигъланып җәзаны касд кыйлды. Ул кеше әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, иске хезмәт, яңа тәүбә — икесе арасында булган хата вә гөнаһны җуядыр», — диде. Аннан соң Мәэмүн ул колның гөнаһын гафу кыйлды.

---

Вә дәхи Мәэмүн берәүгә әйтте: «Валлаһи, сине үтертермен», — диде. Ул кеше әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, сабыр ит, гафу кыйл», — диде. Мәэмүн әйтте: «Мин ант иттем, антын бозган кеше буламын», — диде. Ул кеше әйтте: «Үтерүче булып күренүеңнән Аллаһы Тәгаләгә хәнис булып күренүең артыктыр», — диде. Аны һәм гафу кыйлды.

---

Габдулла бин Заһир әйтте: «Беркөн Мәэмүн хәлифә янында идем, бер хезмәтчесенә «малай-малай» дип, бик каты тавыш белән кычкырды. Бер төрки хезмәтчесе керде, әйтте: «Хезмәтчегә ашарга, яки эчәргә, яки таһарәт алырга, яки намаз укырга тиеш түгелмени? Яныңнан киткәч тә, малай-малай, дип кычкырасың, нигә чаклы малай-малай?» — диде. Мәэмүн башын салып торды. Бу колны үтерергә әмер итә инде, дип торсам, башын күтәрде дә әйтте: «Йә Габдулла, кеше үзенең холкын күркәм кыйлса, хезмәтчесенең холкы яман була, үзенең холкын яман итсә, хезмәтчесенең холкы күркәм буладыр. Хезмәтченең холкы күркәм булсын дип, үземнең холкымны бозарга кодрәтем юк», — диде».

---

Яхъя бин әл-Бәрмәкигә әйттеләр: «Ник хезмәтчеләреңә әдәб бирмәйсең?» — диделәр. Яхъя әйтте: «Хәзер дә без алардан иминнәрмез. Әгәр аларны куркытсаң, алардан без ничек имин булырмыз?» — диде.

---

Бер кешенең бик ялкау бер хезмәтчесе бар иде. Аңар акча бирде, боерды: «Бар, базардан йөзем вә инҗир алып кил», — диде. Малай базарга китте. Бик озак торып, йөзем алып кайтты. Янә икенче мәртәбә инҗир алырга китте, төнлә кайтты. Аннан соң бае орышты, кыйнады: «Бер йомышка баргач, ике йомышны бетереп кайтыр кеше!» — диде.

Бервакыт бу бай сырхау булды. Баягы малайны табибка җибәрде. Хезмәтче китте. Табибны алып килде, аның белән янә бер кеше ияртеп килде. Бае әйтте: «Бу кешене нигә алып килдең?» — диде. Малай әйтте: «Фәлән вакыт үзең мине кыйнадың, бер йомышка барганда, ике йомышны бетереп кил, дидең. Инде, менә сиңа табиб. Әгәр үлсәң, менә сиңа кабер казучы, икенче мәртәбә мине йөртмә», — диде.

---

Берәү бер кеше үзенең хезмәтче малаеннан шикаять кыйлды, әйтте: «Мин малайлардан гаҗиз булдым. Яхшы малай табып булмай», — диде. Ул кеше әйтте: «Малаең ашый-эчәме? Угырлыймы? Ялкаумы?» — диде. Бу кеше әйтте: «Ашаган-эчкәне дә күренми, угырлаганы да беленми. Ләкин эшкә ялкау, бик акрын эшли. Озак йоклый. Күп ашый, әйтмәенчә эшли белми, әйтсәң — карыша», — диде. Ул кеше әйтте: «Инде әфәндем, шул малайга канәгать кыйл: төн-көн яныңда ята. Ул түгел, хатыныңны да үзеңчә итеп булмай. Кайчагында калыплап та карыйсың, алай да булмай», — диде.

---

Хөсәен бин Фазыйл бала вакытта хәлифәләр вә олуглар мәҗлесенә керде. Олуг голямадан күп адәмнәр бар иде. Олуглар арасына кереп сөйләшә башлады. Әйттеләр: «Бу — сабый балалар сөйләшә торган җир түгелдер, син тик тор», — диделәр. Хөсәен әйтте: «Мин сабый булсам да, Сөләйман галәйһиссәламнең һөдһеденнән[1] кечкенә түгел, сез дә Сөләйманнан олуг түгел», — диде.

---

Бер сиксән яшендәге карттан берәү сорады: «Син ничә яшеңдә инде, тәкъсыйр?» — диде. Ул карт: «Мин алтмыш өчтә», — дип җавап бирде. Ул кеше әйтте: «Алай гына булмасаң кирәк, бик карт күренәсең», — диде. Ул карт әйтте: «Үземне пәйгамбәр галәйһиссәламнән карт күрсәтүне әдәпсезлеккә санадым», — диде.

---

Хәҗҗаҗ бер карттан сорады: «Тәгамың вә кәефең ничектер?» — диде. Карт әйтте: «Ашасам — авыраям, ашамасам — дәрманым бетә», — диде. Хәҗҗаҗ әйтте: «Никяхың ничек?» Карт әйтте: «Әгәр тотынсам — гаҗиз булам. Тыелсам — хирысым арта», — диде. Хәҗҗаҗ әйтте: «Йокың ничек?» Карт әйтте: «Халык йоклаганда, йокым килә, ятсам — йоклап булмый», — диде. Хәҗҗаҗ әйтте: «Утырмакың-тормакың ничек?» — диде. Карт әйтте: «Утыраем дисәм, җир ерак күренә; тораем дисәм, җирдән аерылып булмай», — диде. Хәҗҗаҗ әйтте: «Йөрмәкең ничек?» Карт әйтте: «Җирдә киндерә ятса, күземә бүрәнә кебек күренә, атлап үтә алмыйм, ат тизәге булса, абынам», — диде. Картлыкның кәйфиятен тәмам әйтеп бетерде.

---

Бер картка әйттеләр: «Бабай, картайдың, фани булдың. Явызлыкта гомер үткәрдең, инде бар, хаҗга кит», — диделәр. «Акчам юк», — диде. «Йортыңны сат», — диделәр. «Хаҗдан кайткач, кайда торырмын?» — диде. «Мәккәдә тор», — диделәр. «Әгәр Мәккәдә мөҗавир булсам, һи картабан, йортын сатты да монда торырга килде, дип әйтерләр», — диде.

[1] Һөдһед — һөдһөд кошы.

———

Пәйгамбәр галәйһиссәламгә ике кеше килде. Берсе — яшь, берсе карт кеше иде. Карттан элек ул яшь кеше сүзгә керешеп сөйләшә башлады. Пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Янында карт кеше барында, аннан элек ни өчен сүз башлап сөйләшәсең? Картка юл куй, аңа тәгъзыйм кыйл», — дип, тәгълимән тәнбиһ боермыштыр.

———

Бер кеше, бер җәмал иясе вә гүзәл хатынга юлыгып: «Әй дөньяның гүзәле. Әгәр зәвеҗеңез булса, Аллаһы Тәгалә сезгә мөбарәк итсен, әгәр зәвеҗеңез булмаса, миңа белдереңез», — дип, үзенең нияте барын ишарәт кыйлды. Ул хатын әйтте: «Фәһем иттем ки, мине тәзәввеҗ итмәгә ниятеңез бардыр». Ул кеше әйтте: «Бәли, бардыр». Хатын әйтте: «Заһирән, миндә хөсен вә җәмал күрәсең, ләкин сачларымда ак бардыр», — диде. Ул кеше моны ишеткәч тә, шунда ук атының җөгәнен тартып китеп барган вакытта, хатын янә әйтте: «Юк, ак чәчем юктыр, ләкин ниятем сиңа белдермәктер иде ки, синең миндә чит күргән нәрсәң бар булган шикелле, мин һәм синдә аны күреп чиркәнечемне сиңа белдермәк өчен, биләдимеш идем», — дип, ошбу бәетне укыды: ирләр пакь итәкле хатыннарның сачы аклыгын чит күргән шикелле, хатыннар дәхи ирләрнең сачы вә сакалы аклыгын чит күрерләр, димәктер.

———

Зәмга бин Салих озын төннәрдә намаз вә гыйбадәт белән мәшгуль булып, сәхәр вакыты житсә, әһел вә гаиләсен нида кыйлып уятыр иде. Әһел вә гаиләсе дәхи урыннарыннан сикерешеп торырлар иде. Дәрхаль таһарәт алып, барчасы гыйбадәт белән мәшгуль булырлар иде. Вә дәхи бер бәет нида кыйлыр иде. Мәгънәсе ошбудыр: кич вакытында сәер вә хәрәкәт кыйлучы юлчылар, иртә белән максуд мәкаммәренә житеп, рәхәт хасыйл булгач, кич сәер кыйлып, мәшәкать чиккәннәрен онытып, мәдех кыйлынырлар. Әй мәгърисләр, бөтен кич буенча сәфәрдә йөреп, кичнең ахырында, ял өчен туктап, янә иртә белән торып китүчеләр, ягъни: әй гомернең озын юлын үтеп ахирәткә баручы кемсәнәләр, кичтән таң атканчы ятып, фани дөнья гыйбадәтенә чуммакыңыз сезгә лаекмыдыр? Бәлки, шаэнеңез зарурлык кушуы белән чикләнеп, гыйбадәт Хакка дәвам булмактыр, димәктер.

———

Габуд исемле күп йоклаучан бер кара кол, имеш, хәтта тоташ бер атна йоклаганы мәгълүмдер. Ул кара кол беркөн әһел вә гаиләсенә: «Мин тәмавет итәем, ягъни үлгән булып ятаем, миңа елау авазы күтәрегез, ягъни ни хәсрәт, дип фөрьяд кыйлыңыз, ни кәйфияттә була икән, беләем», — дип сузылып ятты. Дәрвакыйг, шулай иттеләр, күрделәр һич кузгалмас ки, хәкыйкать вафат булмыш, имеш.

———

Бәгъдадта сөаль вә таләп ишеген бикләп, тәвәккәлгә бил багламыш бер дәрвиш бар иде. Шулай, беркөн бер локмә тәгамга мохтаҗ булып, биззарур сөальгә ният итте. Пөшиман булып, янә монча заман Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кыйлып гыйбадәт иттем, янә ул гаһедемне боздым, дип сабыр итте вә йокыга барды. Йокысында күктән бер тавыш, «фәлән җирдә бер сары бүз парчасында фәлән кадәр алтын бардыр, барып ал, хаҗәтеңә сарыф кыйл» дип ишетеп уянды. Ул җиргә барып, мәзкүр сыйфат үзрә тапты.

———

Мәккәи Мөкәррәмәдә каберлек каравыллаучы бер дәрвиш Бәгъдадта торучы бер дустының вафатын ишетеп, зикер белән мәшгуль икән, вакыйган да ул дустын Бәгъдад урамында күрде, Бәгъдадта хәтта тимерченең чүкеч тавышларын ишетте. Бу вакыйгасыннан айныгач, көне-сәгате белән дусларына хәбәр биреп һәм тимерченең чүкеч авазын ишеткәнен әйтеп тикшертте. Тәфтиш кыйлганның соңында кәма һүә Бәгъдадта шундый хәл булмыш, ягъни дусты вафат булмаган, ул чакта тимерчеләр урамында гизгәне аңа күренмеш, имеш.

———

Кадим гарәп падишаһларыннан Рәбига бин Нәсыр Ләхми бер куркулы төш күреп, төш юраучыларны җыеп, төшен юраучы сорады. Дәүләтнең олылары әйтте: «Бар төшнең тәэвилен Сәтыйх белер», — диделәр. Бәс, Сәтыйхны китертеп: «Мин бер төш күрдем, мине бик куркытты. Әгәр ни төш күргәнемне белсәң, тәэвилен дәхи белерсең», — диде. Сәтыйх әйтте: «Син бер ат күрдең. Ул ат мәгъриб тарафыннан чыкты вә нигъмәт җиренә төште. Ягъни бәрәкәтле җиргә, Ямәнгә вә Җәзирәтелгарәбкә килде. Шунда ук баш сөякле нәрсәләрне ашап бетерде», — дигәч, мәлик әйтте: «Һичбер хата әйтмәдең, төшемнең нәкъ үзен сөйләдең, тәэвиле нидер?» — диде. Сәтыйх әйтте: «Моның тәгъбире шулдыр ки: мәмләкәтеңезгә хәбәш кавеме һөҗүм итеп, Әбин вә Җәреш белән чиге билгеләнгән мәмләкәтеңезгә хуҗа булырлар», — диде. Мәлик әйтте: «Бу вакыйга кай заман булыр? Минем патшалыгымдамы яки соңмы булыр?» — диде. Сәтыйх әйтте: «Патшалыгыгыз заманыннан соң алтмыш-җитмеш ел үткәч килер. Вә анда бәрелеш вакыйг булып, мәмләкәттән әһалисе качып чыгарлар», — диде. Мәлик әйтте: «Алардан соң Ямән мәмләкәтенә кем ия булыр?» — диде. Сәтыйх әйтте: «Әрем зи Язән исемле мәлик Гадән тарафыннан зоһур итеп гаскәр белән килер, Ямәндә берәүне дә калдырмас», — диде. Мәлик әйтте: «Ахыр Ямәндә патшалык калырмы, юкмы?» Сәтыйх әйтте: «Патшалык мөнкатыйг булыр». Аннан соң мәлик әйтте: «Патшалыкны кем катыйг кыйлыр?» Сәтыйх әйтте: «Ягъни Аллаһы Тәгалә җанибеннән вәхи белән килгән пәй-

гамбәр катыйг кыйлыр». Мәлик әйтте: «Ул пәйгамбәр кайсы нәселдәндер?» Сәтыйх әйтте: «Гаднан гүзәл буыннарыннандыр вә ахыр заманга кадәр мәлик үзе вә өммәте булыр». Мәлик әйтте: «Замананың ахыры вә гаяте бармыдыр?» Сәтыйх әйтте: «Һай-һай, ник булмасын. Заманның ахыры бер көндер, ягъни кыяматтер ки, анда мәхлукат җыелып вә терелтелеп кыйлынып, дөньяда изге булганнар анда сәгадәттә вә явыз булганнар газапта булырлар», — диде. Аннан соң мәлик әйтте: «Бу хәбәр биргәнең хакмыдыр? Вә кыямәт дигәнең хакмыдыр?» — диде. Сәтыйх әйтте: «Шәфәкъ вә камәр белән ант итәрмен ки, тәхкыйк сиңа хәбәр биргәнем хактыр», — диде. Аннан соң мәлик, Сәтыйхның тәэвилен ишеткәч, янә Шык дигән бер кәһанны чакыртып сорады, ул дәхи Сәтыйх кебек тәэвил кыйлды.

———

Өмәййә[1] бин Габдешшәмес белән Һашим[2] бин Габдемәннаф гадәтләре буенча шәрәфтә, макталуда ярышып, бу дәгъвада кайсымыз өскә чыкса, Мәккәдә кара күзле илле тәвә бугазлап, фәкыйрьләрне итгам итмәк үзрә сүз куешып, Хазагый дигән кәһангә барып, хөкемгә торышмакчы булдылар. Ләкин «Бу шартымызны кәһангә белдермәмез», — дип, яннарына дәхи бераз адәмнәр алып, кәһан Хазагыйга барып сөйләделәр вә әйттеләр: «Без бер мәсьәлә өчен үз арамызда сүз куешып, ләкин синнән яшермәк шарты белән килдек. Әгәр яшерен эшемезне белсәң — сине, әгәр белмәсәң, гайре кешене хаким итәрмез», — диделәр. Кәһан әйтте: «Сез шулай-болай шарт итмешсез», — дип, тәмам аларның күңелләрендәге яшеренне әйтеп бирде. Алар әйтте: «Инде кайсымыз әшрәфмез», — диделәр. Кәһан әйтте: «Ошбулар белән ямин итәрмен ки, хөрмәттә мәкяримдә әүвәл вә ахыр Һашим бин Габдемәннафтыр ки, Өмәййә бин Габдешшәмесне мәйдан шәрәфтә сәбкат итмештер[3]», диде. Аннан соң Габдемәннаф, ул тәвәләрне алып вә суеп, Мәккә халкын туйдырды. Өмәййә хурлыктан Шамга китеп, ун ел микъдары анда тормыштыр. Бәни Һашим кабиләсе белән бәни Өмәййә кабиләсе арасында вакыйг булган дошманлашу сәбәбе ошбудыр, дип мәнкульдер.

———

Моннан соң дәхи бер хикәят: Гатбә бин Рәбиганең кызы Һинд Факә бин Мөгайрәнең никяхында иде. Ошбу Факә Корәешнең байларыннан булып, ханәсеннән аерым, халык өчен бер зыяфәтханәсе бар иде. Халык рөхсәт сорамастан, хәзер тәгамны кереп ашарлар иде.

Беркөн ошбу зыяфәтханәсендә берәү дә юк иде, Факә зәүҗәсе Һинд белән барып утырган вакытта, җиңеләер өчен, Факә

---

[1] Әмәвиләр династиясе аның исемендә.
[2] Һашим — пәйгамбәр бабасының әтисе.
[3] Сәбкат итмештер — узмыштыр.

тышка чыккан арада, бер кеше тәгам ашамак касды белән ханәгә керде. Күрде: Һинд ялгыз утырыр. Монда хатын кыз бар икән, дип чыгып барган вакытта, Факә тыштан килеп кергәндә, күрде бер кеше ханәсеннән чыгып барыр. Һинд яткан иде, аягы белән тибеп уятты. «Моннан кем чыгып китте?» — дип ачигъланып сорады. Һинд әйтте: «Мин монда кешене күрмәдем, йоклаган имешмен, син уяттың», — диде. Әмма Факә, яманга юрап: «Бар, атаң өенә кайт», — тәгъбире белән талак кыйлды. Халык арасында Һинд хакында сүзләр булып, атасы Гатбә әйтте: «Әй кызым, халык синең хакында сүзне күбәйтте. Әгәр Факәнең гөманы раст булса, бер хәйлә белән аны үтертәем, таки халыкның сүзе киселсен. Әгәр ялгыш гөман кыйлган булса, ямән кәһаннәреннән беренең янына китеп, хөкемгә тораек, таки ул гөман кыйлган эштән синең пакь булмакың мәйданга чыгып, яманаттан хәлас булаек», — диде. Һинд әйтте: «Валлаһи, Факә сүзендә раст түгелдер», — диде. Гатбә әйтте: «Әй Факә, кызымны бер олуг кабахәт белән яла иттең, Ямән кәһаннәреннән берен хаким итәек», — диде. Факә разый булып, бәни Мәхзүм кабиләсеннән берничә кеше дәхи бәни Габдемәннафтан бераз җәмәгать алып вә Һинд дәхи берничә хатын белән Ямән юлына рәван булдылар. Ямәнгә барып җиткәннәрендә, Гатбә әйтте: «Инде күрерсез, ни булыр», — дигәч, һинднең хәле үзгәрде. Бәс, Гатбә моны күреп: «Әй кызым, мин синең хәлеңне хәзердә мөтәгайййр күрәмен. Синең бу төсең үзгәрү кабахәт эшеңә дәлаләт кыйладыр», — диде. Һинд әйтте: «Валлаһи, Ходай беләдер, бу кабахәт фигылемнән түгелдер. Ләкин белермән ки: сез кәһангә барачаксыз. Кәһан дәхи бер адәмдер ки, хата вә савап аның шаэненнәндер[1]. Һаман шөбһәдән хали түгелмен ки, бихәсәбил бәшәрият[2] хата кыйлыр, яки кәһанәттә, кәмале шаигъ булса да, бер максат өчен ялганны ихтыяр итеп, яман нәфсенә муафыйк, миңа файдалы сүз сөйләмәс дип куркамын», — диде. Гатбә әйтте: «Әй кызым, курыкма. Бу эштә мин кәһанне имтихан кыйлырмын», — дип, дәрхаль атының рәвесләгәнен карап торып, зирәклеге белән бер данә бодай алды да атның зекеренә кертеп баглады.

Иртә белән бу ике таифә кәһан янына керделәр. Кәһан боларга тәвә суеп икрам кыйлды. Тәгамнан соң Гатбә кәһангә әйтте: «Без сиңа бер йомышымызны тәхкыйк кыйлдырмага килдек. Вә синнән мин эчемдә бернәрсә яшердем, шуны бел», — диде. Кәһан әйтте: «Сез бер сәмәрәне кәмәрәгә яшердеңез, ягъни бер данәне зекергә яшердеңез», — диде. Гатбә әйтте: «Мин теләр идем ки, моны янә ачык тәгъбир кыйлсаңыз икән», — диде. Кәһан әйтте: «Бер бодай данәсен атыңызның камышына

---

[1] Шаэненнәндер — биредә: карамагындадыр.
[2] Бихәсәбил бәшәрият — бәндәчелек белән.

керттенез», — дип ачык җавап бирде. Аннан соң Гатбә әйтте: «Шул хатыннарның эшенә дикъкать белән караңыз», — диде. Кәһан дәхи ул хатын таифәсенең яннарына барып, һәрберенең иңнәренә кулы белән сугып, нәүбәт Һиндка килгәч, янә кулы белән Һиндның иң башына сугып: «Син дәхи кабихә вә зания булмаганың хәлдә хәрәкәт ит: тиз заман синнән бер падишаһ тугачактыр ки, исеме Мөгавиядер[1]», — диде.

Бәс, Һиндның зинадан бәри[2] булганын кәһаннең хәбәреннән күргәч, Факә Һиндның кулыннан тотты, ләкин Һинд, разый булмаенча, кулын кулыннан тартып алды. «Кит моннан, ул падишаһ синнән гайредән тугмакыны күңелем эстәр, сиңа бармасмын», — диде. Аннан соң Һиндны Әбү Суфьян тәзвеш итеп, аннан Мөгавия разыйаллаһу ганһу тугмыштыр.

———

Бер кемсәнәдән мәнкульдер: «Беркөн тәвәм качмыш иде, фалаху фәнене беләторган Хәрраш исемле кемсәнәгә барып: «Тәвәмне табармынмы?» — дип сорадым. Кызына минем өчен җиргә сызык сызмага әмер кыйлды. Кыз, шунда ук сызык сызып гамәлен бетергәннән соң, аягына калыкты. Вә Хәрраш, көлеп, миңа әйтте: «Кызым ни өчен торды, белдеңме?» — диде. «Юк, белмәймен», — дидем. Хәрраш әйтте: «Тәвәңне табарсың дип белеп, дәхи үзен син өйләнүеңне куйган сызыкларыннан нәтиҗә чыгаргач оялып калыкты», — диде. Бәс, мин аннан торып киттем, тәвәмне таптым. Вә Хәррашның кызына өйләндем», — димештер.

———

Мәнкульдер ки, гарәптән Гамру бин Габдулла белән Малик бин Хәрраш дигән кемсәнәләр юлдаш булып, дини сугыш белән чыкмышлар иде. Юлда сызык сызып, киләчәк вакыйгаларны истиразҗ кыйла белүче бер хатынга очрадылар. Малик ул хатынның бу гамәленә көлеп, мәсхәрә кыйлыр иде, шунда ул хатын, Маликкә карап: «Сиңа барган җиреңнән кайтмак юктыр. Вә хатыныңны ошбу юлдашың Гамру алыр», — диде. Вакыйган шулай булмыштыр.

———

Янә мәнкульдер ки, Рәсүл саллаллаһу галәйһиссәлам хәзрәтләренә мәлик Кайсәр[3] бер илче күндереп, илчегә тәнбиһ кыйлды ки: «Ул затның кәтеф сәгадәтләрендә булучы пәйгамбәрлек мөһере булган хәлен күзең белән карап күреп кайт», — дип әмер кыйлды. Кайчан ки ул илче килеп хәзрәти Рәсүлне күрде: биек урында, аягын юып, хәзрәти Гали янында аягын сөртеп торыр. Пәйгамбәр галәйһиссәлам, ул илчегә таба әйләнеп: «Кил, боерылган булган нәрсәңә кара», — диде. Мәзкүр илче мөһерне карап

---

[1] **Мөгавия** — 661 елда Әмәвиләр династиясенә нигез салучы хәлифә. 680 елда вафат.

[2] **Бәри** — чиста, ару.

[3] **Мәлик Кайсәр** — Византия патшасы.

күрде. Илчелеген тәмам кыйлып, Кайсәргә кайтты. Күргән нәрсәләрен Кайсәргә хәбәр бирде. Кайсәр күрәзәлек белән, ягъни аңлап белү юлы белән: «Әлбәттә, минем тәхетем аның тәхет аяк астында булыр вә мәмләкәтемә мәлик булып, үз идарәсенә алыр», — дип, пәйгамбәр җиңәсен биек урында булмакыннан вә аяклары суда булмакыннан аңлап белү юлы белән дәлилләде.

———

Хәлифә Мәрван бин Мөхәммәд беркөн киңәш бүлмәсендә утырып, илне идарә эшләре белән мәшгуль чагында, алгы бүлмә пыялаларыннан бере уалып, ярыгыннан Мәрванның иң башына кояш төште. Анда бер аңлап белүче бар иде, шунда ук торып китте. Мәрванның егетләреннән Сәүбән исемле бер кеше: «Гарафнең бу торып китмәкендә бер ишарә бардыр», — дип, артыннан китте вә сөаль кыйлды. Гараф дәхи җавап бирде: «Шешәнең ярылмагы — солтанәтнең ярылмагыдыр. Тиз заман кояш аннан китеп, яки төректән, яки Хорасаннан бер кавем килер. Зирә мәзкүр иншикак[1] минем каршымда ачык дәлилдер», — диде. Вә ике ай үтмәде, Мәрванның дәүләте егылды. Мәрван холәфаи Өмәвиянең ахыргысыдыр.

———

Гали разыйаллаһу ганһу Сыйффин вакыйгасында Мәгъкыйль бин Ясарны ун мең кадәре гаскәр белән Рәкадә яшәргә җибәрмеш иде. Мәгъкыйль дәхи, юнәлеп, Хәдибиягә төшеп, берничә көн тормакта икән. Мәзкүр мәрхәләдә күрер ки: ике кәҗә бер-бере белән сөзешсәләр иде, ике кеше килеп, икесе ике кәҗәне аерып алып киттеләр. Гаскәрендә Шәддад бин Әбү Рәбига дигән киләчәктән хәбәр бирүче, алдан күрүче бар иде, Мәгъкыйльгә килеп: «Сез бара торган сәфәрегездән галиб тә, мәгълүб тә булмаенча кайтырсыз, — диде. — Зирә, күрмәдеңезме ки, кәҗәләр бер-бере белән сөзешеп, галиб вә мәгълүб булмастан аердылар», — диде.

———

Искәндәр, бәгъзе илләрне яулап, эченә кергәч күрде: бер хатын бүз тукыр. Искәндәрне күргәч: «Әй мәлик, сиңа озынлык вә яссылык иясе бер милек бирелде», — дип, күрәзәлек кыйлды. Янә Искәндәр ул хатынны икенче мәртәбә күргәндә, хатын әйтте: «Әй мәлик, син мәлик вә солтанәттән тиз читләтелерсең», — диде. Искәндәр бу сүзгә гаять ачигъланды. Хатын әйтте: «Әй мәлик, ачигъланма, чөнки бәгъзе күңел бәгъзе галәмәт белән эшне вакыйгаләр ишарә кыйлыр. Зирә әүвәл мәртәбә күргәнемдә мин бүзнең озынлыгын, вә киңлеген, вә микъдарын тәдбир кыйладыр идем. Әмма бу мәртәбәдә миңа бүзнең сугылып бетеп кисәргә касд кыйлган вакытымда очрадың», — диде. Филвакыйг, хатын әйткәненчә булды: Искәндәр ул шәһәрдән чыкты.

---

[1] Иншикак — ярылу.

---

Сәйф бин Язән Ямән өлкәсенең мәлиге иде. Бервакыт Ямәнне Хәбәшә мәлиге Мәсрук бин Әбрәһә басып алды. Бәс, Сәйф Мәсрукны Ямәннән чыкармакны касд кыйлып, Кәсрәдән[1] мәдәд вә ярдәм эстәп, Кәсрә тарафыннан күп гаскәр җибәрелгәннән соң, Сәйфкә куәт килмәк белән, Мәсрук өстенә һөҗүм кыйлды. Мәлик Хәбәшә дәхи йөз мең микъдары гаскәр белән Сәйф өстенә чыкты. Хәлбуки Хәбәшә мәлигенең маңгаенда алтын чылбыр белән асылмыш ут шикелле балкыш бирә торган әгъля бер кызыл якут булып, бер олуг фил өстенә менмеш иде.

Вә Сәйфнең гаскәрендә Заһир исемле бер зәҗир[2] бар иде. Мәлик, Хәбәшәнең кыяфәтен таэмил итеп, Сәйфкә килеп әйтте: «Сабыр ит, мәлик Хәбәшәнең гакылына вә хәленә караек», — дип сабыр итте. Ул арада мәлик Хәбәшә, филдән төшеп, тәвәгә, бәгъдә тәвәдән төшеп, атка вә аннан дәхи төшеп, ишәккә менде. Әмма ишәккә атланмакыннан максуды Сәйфне кечерәйтү вә мыскылы иде. Кайчан ки мәзкүр зәҗир мәлик Хәбәшәнең әгълядән әднага төшүеннән юкка чыгуын аңлап, Сәйфкә әйтте: «Инде һөҗүм вә сугыш кыйл, Хәбәшәнең бу арада солтанәте китте, зира олуг аттан төшеп, кечкенә ишәккә менде», — диде. Вә Сәйф дәхи Мәсрук өстенә һөҗмә салып вә тар-мар итеп, мәлик Хәбәшәне үтерде. Аннан соң Ямәндә мәлик — Сәйфнең углы Мәгъдикрәб булмыштыр.

---

Бәгъдадта урамнарда гизеп, сөаль кыйлгучыларга җавап биреп, җавабы раст килә торган бер гариф[3] бар иде. Бер кемсәнә юлыгып: «Фәлән кемсәнә кулга алынган. Вә әгъҗәба! Хәлас булыр микән?» — дип сорады. Бу гариф уңга-сулга карады да, дәрхаль җавап бирде: «Ул кемсәнә хибестән котылыр һәм хилгать кияр», — диде. «Моны кайдан белдең?» — диделәр. Гариф әйтте: «Син сөаль иткәч, уныма-сулыма карадым: җилкәсенә су тулы көянтә-чиләк күтәргән бер кешене күрдем. Ул кеше һаман шунда ук суны бушатты. Буш чиләкне җилкәсенә күтәрде. Бәс, суны — мәхбүс белән, бушатмакын — мәхбүснең хәласы белән вә буш чиләкне күтәрмәкен хилгать кимәке дип юрадым», — диде. Дәрвакыйг, ул юраганча булмыштыр.

---

Мәнкульдер ки, мәшһүр олуглардан Мәхмүд вә Һимамеддин — ике кемсәнә — бер бәйрәм көнендә тамаша вә күңел ачу өчен сахрага чыкмышлар иде. Бер-бере белән рәхәтләнеп вә шатлык үзрә сохбәт кыйлып утырганда, Мәхмүд әйтте: «Әй борадәр, билә икенче бәйрәмгә кадәр сау-сәламәт җитмәкемезне беләсен-

[1] Кәсрәдән — Иран патшасыннан.
[2] Зәҗир — килгән хәлләрне хәбәр итүче.
[3] Гариф — алдан белүче.

ме?» — диде. Һимамеддин әйтте: «Бер ел кайда, хәтта бу айның ахырына кадәр барып җитәрмезме?» — диде. Сөбханаллаһи, Хак Тәгаләнең лотыфы үзрә, әзәлдә язмыш булганны каза боерып, бере — ай тулмастан вә бере ел тулмастан вафат итмешләрдер.

———

Бер падишаһ бер мөнәҗҗимнән сорады: «Минем ничә ел гомерем калгандыр, әйт!» — диде. Мөнәҗҗим әйтте: «Йә падишаһым, ун ел гомерең бардыр», — диде. Бәс, падишаһ бик фикергә калды. Хәтта авыруга сабышты, түшәк җәйдереп ятты. Падишаһның бер гакыллы вә дана вәзире бар иде, ул мөнәҗҗимне падишаһ хозурына чакыртып, падишаһ күзе алдында сорады, әйтте: «Йә мөнәҗҗим, синең ничә ел гомерең бар?» — диде. Мөнәҗҗим әйтте: «Минем халән егерме ел гомерем бар», — диде. Вәзир кылычын суырды, мөнәҗҗимнең башын чабып өзде. Аннан соң падишаһның күңеле тынычланды. Вәзирнең хикмәтен бик мактады. Аннан соң һичбер мөнәҗҗимнең сүзен колагына алмады.

———

Бәлигадан бер кемсәнә үзенең бер дустына хат язып күндермештер ки, белә: «Бәгъдә әд-дога, әй дустым, халыкка фигылең белән, гамәлең белән вәгазь вә нәсыйхәт кыйл. Юкса сүзең белән вә кәлямең белән вәгазь кыйлма, ягъни барча гамәлләрең, вә фигыльләрең, вә җөмлә хәрәкәтең шәригатькә гакылга муафыйк вә буйсындырылган булсын да, һәр кеше сиңа охшарга теләсен, нәсыйхәтләнүче булсыннар. Вә дәхи Аллаһы Тәгаләнең сиңа якынлыгы кадәр Аллаһы Тәгаләдән оял ки, Аллаһы Тәгалә һәр хәлдә сине белеп торыр. Вә сиңа Аллаһы Тәгаләнең кодрәте никадәрдер, ул кадәр хәвеф ит, даим хәвеф үзрә бул, вәссәлам», — димештер.

———

Һарун әр-Рәшит хәлифә Мансур бин Гоммарга әйтте: «Йә Мансур, кыскалык белән генә миңа файдалы бер вәгазь вә нәсыйхәт әйтсәнә», — диде. Мансур әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, нәфесеңездән зиядә сәвекле нәрсәңез бармы?» — диде. Һарун әйтте: «Юктыр». Мансур әйтте: «Кеше үзенең сәүгәненә яманлык кыйлып, аның һәлак булмакын эстәмәс. Бу тәкъдирчә җәнабыңыз һәм ике дөньяда нәфесеңезгә газап бирә торган эшне эшләмәсен», — диде. Ягъни нәфесең вә җаның үзеңә газиз булса, газапка хаклы булырдай эшне эшләмә, димәктер.

———

Әмирләрдән Мәэмүн бин Мәһран бервакыт Хәсән Бәсрига юлыккан вакытта: «Тәкъсыйр, сезнең белән юлыкмакны күптән тели идем, рәхим итеп, миңа вәгазь вә нәсыйхәт әйтсәнә», — дип үтенде. Хәсән Бәсри ошбу аятьне укыды. Мәгънәсе: һәрни кадәр динсезләр ничә заманнар дөнья нигъмәтләре белән туендыручылары файда бирмәс, димәктер.

Аннан соң бин Мәһран Хәсән Бәсрины тәгъзыймән: «Йә Әбү Сәгыйд, Аллаһы Тәгалә синнән разый булсын, безгә яхшы вә күркәм вәгазь белән вәгазь иттең», — диде.

———

Риваять кыйлынмыштыр ки: хәзрәти Гали разыйаллаһу ганһуны ибн Мөлҗәм һәлак иткәндә, мәлгунь кылыч белән орып өенә китерелгәч, һәнүз җаны мөбарәк бәдәнендә иде. Җәрәхәте катылыгыннан бер мөддәт һушы китеп, янә һушына килгәннән соң, угланнары Хәсән, Хөсәенне янына китертеп, ошбу нәсыйхәтне әйтте: «Әй угыллар, Аллаһы Тәгаләдән куркыңыз. Вә ахирәткә күңел биреп, дөньядан йөз чәвереңез. Дөнья нәрсәсеннән әрәм булган нәрсәнез өчен үкенеп кәефсезләнмәгез. Вә даим хәер эштә булыңыз, залимгә хосумәт вә мәзлумга иганәт кыйлыныз», — диде. Аннан соң Мөхәммәд Хәнәфине дәхи чакыртып: «Әй углым, карендәшләреңә әйткән нәсыйхәтемне ишеттеңме?» — диде. Мөхәммәд Хәнәфи әйтте: «Бәли, ишеттем». Аннан соң Гали разыйаллаһу ганһу әйтте: «Әй углым, син дәхи ул васыять үзрә бул. Вә карендәшләреңне олугла вә кадерләрене бел. Вә аларның нияте вә тәдбире булмаенча бер эшне эшләмә», — диде. Янә Хәсән вәХөсәенгә мөрәҗәгать итеп әйтте: «Әй угланнар, Мөхәммәдне сезгә тапшырдым. Карендәшеңездер вә атаңызның углыдыр. Белерсез ки, атаңыз Мөхәммәдне сәвәр иде, сезләр һәм аңар мәхәббәт итеңез, — дигәннән соң, янә: — Әй угылларым, һәр җирдә, өйдә вә сәфәрдә Аллаһы Тәгаләдән куркыңыз: риза хәлеңездә вә газап, вә ачу вакытыңызда хаклыктан читләшмәгез. Тугыры юлда булыңыз. Вә дустыңызга вә дошманыңызга гаделлек кыйлыңыз. Шатлык вә кайгы хәлләрендә, тагатьтә вә изге гамәлдә булыңыз. Катылык вә рәхәтлек вакытында шатлыкта вә хәсрәттә Аллаһы Тәгаләдән разый булыңыз. Әй угылларым, бер эш булыр ки, күренүе явыз вә әшәке эш күренеп, ләкин аны эшләмәк белән җәннәтне табылыр. Ул эш — явыз эш түгелдер, аны эшләңез, әмма гүзәл вә күркәм күренеп, ул эшне кыйлмак сәбәпле, тәмуг газабына мөстәхак булыныр, ул эшне эшләмәңез. Җәннәт нигъмәтеннән башка булган һәрбер нигъмәтләр һәммәсе хурдыр. Вә һәрбер тәмуг газабыннан башка булган мәшәкать вә газаплар һәммәсе яхшыдыр. Әй угылларым, бер кемсәнә үзенең гаебен күрсә вә үзенең гаебен белсә, ул кеше гайреләрнең гаебе белән мәшгуль булмактан гафил калыр, ягъни үз гаебен күргән кеше кеше гаебен күрмәс. Вә әгәр бер кеше Аллаһы Тәгаләнең тәкъдиренә вә биргән өлешенә разый булса, беткән вә загыйгъ булган нәрсәләр өчен көенмәс. Вә дәхи бер кеше золымлык вә азгынлык кылычын чыгарса, ахырында ул кылыч белән үзе үтерелер. Вә берәү мөэмин карендәшен төшермәк өчен кое казыса, ул коега үзе төшәр. Вә гайре кешенең хатасын вә гөнаһысын олугка сайган кеше үзенең хатасын вә гөнаһысын

онытмыш булыр. Вә бер кеше үзенең ниятенә вә үзенең тәдбиренә масайса вә мәгърур булса, хата вә зәляләткә төшәр. Вә үзенең гакылы белән генә эш кыйлган кеше хурлыкка төшәр. Вә гайренең ниятеннән вә мәшвәрәтеннән читләшкән кеше хур булыр. Вә халыкка тәкәбберлек кыйлганнар дәхи хур булыр. Төһмәтле җирләргә, ягъни явызлар арасына вә харам эшләр белән мәшгуль була торган җирләргә кергән кеше һәрни кадәр анда гөнаһ вә харам эш эшләмәгән булса да, гаепләнүдән хали булмас. Вә дәхи ахмаклар вә түбән адәмнәр белән катышкан кеше нәтиҗәдә хур-хәкыйрь булыр. Вә галимнәр белән мөҗәләсә[1] вә мөсахәбә иткән кеше олуглык вә кадер вә гыйззәт табар. Вә күп уен-көлке вә мәзәк вә ләтыйфә кыйлган кешенең кадер вә хөрмәте җуелыр. Вә күп сөйләшкән кешенең хатасы вә гөнаһысы күп булыр. Хатасы күп булган кешенең әдәп вә хәясы аз булыр. Әдәп вә хәясы аз булганның пәрһизлеге вә тәкъвалыгы[2] аз булыр. Вә пәрһизлеге аз булганның күңеле үләр. Вә күңеле үлгәннәрнең урыны җәһәннәмдер. Әлгаязе биллаһи. Әй угылларым, әдәп мизандыр. Вә күркәм холык сиңа якын булган нәрсәләрнең изгерәгедер. Әй угылларым, гафият вә сәламәтлек ун өлештер, тугыз өлеше Аллаһы Тәгаләнең зикерендәдер. Әй угылларым, фәкыйрьлек зиннәте — сабыр, байлыкның зиннәте — шөкердер. Әй угылларым, исламнан олы шәрәф, вә тәкъвалыктан олы кәрамәт, тәүбә вә истигъфардан шәфагатьлерәк нәрсә юктыр. Тән сәламәтлегеннән артыграк кием юктыр. Әй угылларым, хирыслык вә комсызлану вә зәхмәтнең ачкычыдыр», — диде. Һәрбер сүзе — тәдбир, нәфестә вә дәрәҗәдә, Коръән вә хәдис сүзләренә тиң рухи авыруга имдер, разыйаллаһу ганһу.

———

Холәфаи Өмәвиядән Һишам бин Габделмәликнең вафаты якынлашып, үлем түшәгендә янына җыелган халыкның елагъланын күреп: «Әй җәмәгать, Һишам сезгә дөнья белән җумартлык кыйлды, ягъни сезгә мал-мөлкәт калдырды. Сез аңа күз яше белән җумартлык кыйласыз. Ул җыйган нәрсәләрен һәммәсен сезгә куйды. Сез аңа бары менәчәк нәрсәсен, ягъни җеназаны куйдыгыз. Әгәр Хак Тәгалә хәзрәте аны гафу итмәсә, вә ни хәсрәт, барачак җире ни олуг җирдер ки, җәһәннәмдер», — дип, мөнәҗәт кыйлды.

———

Малик бин Әнәс әйтте: «Беркөн ибн Тавис белән Әбү Җәгъфәрнең мәҗлесенә кергән вакытымызда күрдек ки: Әбү Җәгъфәр үзенең күзе алдында берничә адәмнәрнең башын кистерер иде. Безгә «утырыгыз» дип ишарәт кыйлды. Бәс, утырдык. Хөкем итү тәмам булгач, Әбү Җәгъфәр безнең янымызга килеп торды.

---

[1] Мөҗәләсә — утырышу.

[2] Пәрһизлеге вә тәкъвалыгы — саклануы һәм диндарлыгы.

Башын иеп, һичбер кәлимә сүз әйтмәенчә, берничә мөддәт торганнан соң, башын күтәреп ибн Тависка эндәшеп: «Әй ибн Тавис, синең атаң Рәсүлуллаһтан ниндәен хәдис риваять кыйлмыш исә, сөйлә, ишетәем», — диде. Ибн Тавис әйтте: «Атамның Рәсүлуллаһтан риваять кыйлмыш бер хәдисе ошбудыр», — диде. Мәгънәсе: кыямәт көнендә газап вә гыйкаб җәзасы зиядә булган кеше шул кемсәнәдер ки, Аллаһы Тәгалә аны дөньяда үз милкенә шәрик итте, ягъни милекне тотуны аңа бирде. Бәс, ул кемсәнә ул милеккә карата хөкемендә җәүр вә золымлык кыйлды, димәктер.

Бәс, ибн Тавис бу хәдисне зикер кыйлганнан соң, Әбү Җәгъфәр берничә заман сөкүт кыйлды вә гаять күңеле кырылды. Мин дәхи күңелемнән, ибн Тависка моннан котылмак җиңәр хәлдә түгелдер, Әбү Җәгъфәр ибн Тависны үтергәнче кыйнар яки муенын кисәр, миңа каны сачрамасен, дип, киемемне җыебрак торыр идем. Аннан соң Әбү Җәгъфәр әйтте: «Йә ибн Тавис, шул каләм вә кара савытымны алып китерче», — диде. Әмма ибн Тавис китермәде. Әбү Җәгъфәр әйтте: «Ни-нәрсә мәныг булды ки, кара савытымны алып китермәдең?» — диде. Ибн Тавис әйтте: «Әй Әбү Җәгъфәр, кара белән бер мәгъсыять вә гөнаһ була торган нәрсәне язарсың да, мин һәм ул мәгъсыятьтә сиңа шәрик булырмын дип куркып китермәдем», — диде. Аннан соң Әбү Җәгъфәр, ачигъланып: «Бар, моннан чык», — дип, безне мәҗлестән куып чыгарды. Ибн Тавис әйтте: «Безнең дә максудымыз бу иде», — диде. Бергә чыктык. Ибн Тависның вәгазь вә нәсыйхәттә бу кадәр ныклыгын белгәнем юк иде, ул көн белдем», — диде.

---

«Мөстәтраф» иясе димештер ки: «Шәехем Әбү Бәкер әт-Тартуши «Сираҗелмөлүк» дигән китабында: «Язар заманымда булган Мисыр мәлиге Әфзал бин Әмир әл-Җөюшның мәҗлесенә кереп, әссәламегаләйкем вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатүһ, дидем. Ул дәхи, вәгаләйкемәссәлам вә рәхмәтуллаһи вә бәрәкатүһ, дип, сәламемне кайтарды. Хөрмәт олылау кыйлып, мине хас мәҗлесенә утыртты. Мин дәхи сәламнән соң сүз дип әйттем: «Әй мәлик, Аллаһы Тәгалә җәнабыңызны бу кадәр олы мәртәбәгә мендереп, олуг урын бирде. Вә үзенең милегеннән бер бүлеген сезгә ингам вә ихсан кыйлды вә сезне халыкка әмир кыйлды. Сезгә буйсынучыларны сезгә табыйг кыйлды. Вә үзенең хөкемен вә әмерен иҗра кыйлмага сезне җаваплы кыйлды. Вә синең әмерең үзәренә янә берәүнең әмере йөрмәкенә разый булмады. Ягъни Аллаһы Тәгалә халыкның сиңа итагать кыйлмакларына разый булмаган кебек, сез дәхи Аллаһы Тәгаләгә шөкер йөзеннән, бер кеше дә синнән артык булмакына разый булма. Хакның шөкерен лаекынча җиренә китереп, бу бабта барчалардан өстен бул. Аллаһы Тәгалә сиңа халык итагать кыйлмак белән сине икрам кыйлды, син дәхи иҗ-

тиһад кыйл: итагать җәһәтеннән Аллаһы Тәгаләгә синнән буйсынганрак адәм булмасын. Ләкин шөкер-тел белән генә шөкер имәстер, изге гамәл белән вә ихсан белән булыр. Хак Тәгалә боермыштыр: «Әй але Дауд, сезләр гамәл вә тагать белән вә төрле гыйбадәт белән Аллаһы Тәгаләгә шөкер өчен гамәл кыйлыңыз», — димештер. Әй мәлик, белгел ки, сезнең бу мәлик вә солтанәткә ия булмакыңыз сездән әүвәл килгән мәликләрнең үлеме сәбәпледер. Бу милек сезгә килгән кебек, сездән дәхи китәр. Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә падишаһларның һәммә эшләреннән сөаль кыйлыр. Вә дәхи әй мәлик: Хак Тәгалә Сөләйман галәйһиссәламга дөнья милеген бирде, адәмиләрне, җеннәрне, шайтаннарны, кошларны вә җәмигъ җанварны аңа буйсындырылган сүз тыңлаучы кыйлды. Аннан соң һаваны вә җилне дәхи аңа буйсындырды. Шөйлә ки аның әмеренә мөнкад булып, ул теләгән җиргә исәр иде. Бу кадәр милек вә солтанәт аңа бүләк кыйлынганнан соң да, кыямәт көнендә нам мәнкуленчә хисап алу кыйлынмамак дәхи җәнаб Хактан вәгъдә икән, моны нигъмәт санамыйча аңлау вә мәкер булмакыннан хәвеф кыйлыбрак, димеш иде, ягъни бу нигъмәтләр Раббымның фазыл вә кәрәменнәндер. Тәфәззыл вә ихсан кыйлмагы тәҗрибә вә имтихан өчендер ки, бу нигъмәткә шөкерме итәрмен яки инкярме итәрмен, дип куркыр иде. Әй мәлик, гаделлек ишеген ач вә ярдәм эстәгәннәрне читләмә, мәзлумга ярдәм вә иганәт бир, таки Аллаһы Тәгалә сиңа да ярдәм итәр. Мәшрикъта, мәгърибтә мәмләкәтләрне гиздем, сезнең идарәдә булган җирдән гайрене ихтыяр итмәдем, монда яшәүне касд кыйлдым», — дип, вәгаземне тәмам кыйлып, ошбу бәетне инша кыйлдым. Мәгънәсе: халык бары ингам вә ихсан күргән кешене генә мәдех итәрләр.

---

Һарун әр-Рәшит заманында Мәккәи Мөкәррәмәдә Фазыйл бин Рәбигъ дигән газизләрдән бер газиз бар иде. Ул газиз хикәят кыйлмыштыр ки: «Һарун әр-Рәшит хәзрәтләре хаҗга килгән елда Мәккәи Мөкәррәмәдә идем. Бер кичәдә, бүлмәмә килеп, Һарун әр-Рәшит ишекне какты. Һәркем йоклаган иде. «Ишектә кем бар?» — дип, барып ишекне ачтым. «Бу вакытсыз килгән кеше кемдер?» — дидем. Әмирел-мөэминин: «Һарун әр-Рәшит хәзрәтләредер, кабул боерыңыз», — диде. Дәрхаль йөземне сөртеп: «Йә әмирел-мөэминин, әмер иткән булсаңыз, яныңызга мин барыр идем, бу тәкәллефне ихтыяр иттегез?» — дидем. Һарун әйтте: «Хәлемне сорама, күңелемә аптырау вә көенеч вакыйг булды. Күңелемнән бу көенечне һичкем читләмәс. Мәгәр миңа тиз бер галим вә гариф адәмне табып бир», — дигәч, Суфьян бин Гайинә хәтеремә килеп, Һарун белән Суфьянның ханәсенә китеп, ишеген кактык. «Ишектә кем бар?» — диде. «Әмирел-мөэминин Һарун хәзрәтләредер», — дидем. Дәрхаль ишеккә килеп, ишекне ачты вә: «Әй

әмирел-мөэминин, фәкыйреңезгә бер адәм күндерсәңез, аяк туфрагыгызга килер идем», — дип, мөлаямәтле[1] сүзләр белән ханәсенә алып керде. Берәр сәгать сохбәт кыйлганнан соң, Һарун әйтте: «Йә Суфьян, ихтыяҗыңыз бармы?» — диде. Суфьян әйтте: «Бәли, бардыр», — диде. Һарун аның хаҗәтен әда кыйлып, Суфьянның ханәсенән чыктык. Һарун әйтте: «Әй Фазыйл, моның белән мөкаләмә миңа файда итмәде, башка бер газизне табып бир, таки нәсыйхәте белән мөтәнәсыйх булаем», — дигәч, «Монда Габдерәззак бин Һимам дигән зат бардыр, аңа бараек», — дип, ханәсенә киттек. Ишегенә кактык. Ул дәхи истикъбальдә вә сохбәттә нәкъ Суфьян кебек җавап бирде. Һарун әр-Рәшитнең күңел җәрәхәтенә шифа бирмәде. Вә аның дәхи хаҗәтен әда кыйлды. Аннан чыккач: «Әй Фазыйл, минем морадыма тугыры килгән бер галимне тапмадың, мин тәкъва вә пирһәз вә саф күңелле бер галимне эстәймен ки, диндә нык булсын, дөньядан читләшеп, асла дөньяви түбәнлекләргә мәел вә дәрте булмасын», — диде. Мин әйттем: «Йә әмир, ул син эстәгән галим Фазыйл бин Гаяздыр», — дидем. Һарун дәхи: «Әйдә, бергә бараек», — дип, Фазыйл бин Гаязның ханәсенә бардык.

Ул вакыт Фазыйл озын аятьләр белән намаз укыр иде, көтеп тордык. Намазын тәмам иткәч, ишекне кактык. «Кем бар?» — диде. Мин дәхи: «Кабул итеңез, әмирел-мөэминин Һарун әр-Рәшит килде», — дидем. Фазыйл әйтте: «Минем кебек фәкыйрь белән әмирнең ни мөнәсәбәте бардыр?» — дип, ишекне ачмады. Мин янә: «Сөбханаллаһи, хәлифәгә итагать кыйлмак сиңа важиб түгелмедер?» — дидем. Аннан соң ишеген ачты. Кандилен сүндереп, ханәсенең бер почмагына гизләнде[2].

Бәс, Һарун әр-Рәшит, Фазыйл кайда утырыр икән дип, кармалап йөргәндә, Һарунның кулы Фазыйлның кулына тигәч, Фазыйл, Һарунның кулын тотып: «Әй, ваһ, гаҗәба, бу ниндәен йомшак кул, имеш. Яхшы ла, әгәр дә кыямәт көнендә Аллаһы Тәгаләнең газабыннан котылса», — диде. Һарун әйтте: «Йә шәех, нәсыйхәтеңне телим вә өмид итәрмен ки, миңа вәгазь вә нәсыйхәт иткәйсең», — диде. Фазыйл әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, син ашаучыларыңның вә үзеңә буйсынган шәфкатьсезләрнең бар гөнаһларын үзеңә йөкләмешсең. Әгәр кыямәт көнендә тәвабигъ хитамларыңа; минем гөнаһымның бер азын гына йөкләңез, дип гозер итсәң дә, йөкләмәсләр.

Ул көн шундаен көндер ки, сиңа никадәр зиядә мәхәббәт итүчеләр шулкадәр зиядә синнән качарлар. Гомәр бин Габделгазиз хәзрәтләре хәлифәлеккә җөлүс иткәч, Сәлим бин Габдулла вә Мөхәммәд бин Кәгаб вә Рижа бин Хәят хәзрәтләрене мәҗлесенә дәгъвәт итеп: «Әй гыйлемнәре белән гамәл кыйлу-

---

[1] Мөлаямәтле — ягымлы, илтифатлы.
[2] Гизләнде — посты.

чы газизләр, мин бу хәлифәлек йөге белән мөбтәля булдым. Сезләрдән морадым булыр ки, даим мине хәер эшкә дәлаләт вә дөнья-ахирәт сәламәтлегенә ишарәт иткәйсез», — дип, нигъмәт сайган әмирлеген вә хәлифәтен йөк санады. Әүвәл Сәлим бин Габдулла нәсыйхәт башлап: «Әй әмирел-мөэминин, әгәр кыямәт көнендә Аллаһы Тәгаләнең газабыннан котылмак морадың булса, ураза бул, авыз ачуың — әҗәлең булсын, ягъни дөньядан тыел, кабергә барып кергәнче зөһед вә тәкъвалыгыңны бозма», — диде. Аннан соң Мөхәммәд бин Кәгаб әйтте: «Әй хәлифә, кыямәт көнендә Аллаһы Тәгаләнең газабыннан сәламәт булып, нигъмәт йортына кереп, мәңге ләззәтне тапмак эстәсәң, каршыңдагы мөселманнарның карт вә олуг яшьлеләре — атаң булсын; вә урта яшьлеләре — карендәшләрең булсын; вә кече яшьлеләре — балаларың булсын ки, аталарыңны икрам вә тәгъзыйм кыйлып ихсан ит; вә карендәшләреңә мәрхәмәт ит; вә балаларыңа шәфкать ит», — диде. Аннан соң Рижа бин Хәят дәхи: «Әй хәлифә, үзеңә ни рәвеш белән мөгамәлә итсәң, вә ни изге эш итсәң, мөселманнарга ул изге эшне эшлә. Үзеңә ни-нәрсәне кәриһ күрсәң вә зарар дип хисапласаң, мөселманнарга дәхи аны кәриһ күреп, үзеңне ул зарардан саклаган шикелле, Аллаһның бәндәләрен дәхи шөйлә сакла. Аннан соң теләсәң кайчан ул ахирәткә куч, диде», — дип, Фазыйл бу хикәятне китергәннән соң, Һарун әр-Рәшиткә эндәшеп: «Әй хәлифә, мин дәхи ул газизләрнең Гомәргә әйткән сүзләрен вә нәсыйхәтләрен әйтәмен: аяклар тая торган кыямәт көнендә булачак хәлләр өчен сиңа зиядә хәвеф итәмен», — диде. Һарун әр-Рәшит шулкадәр егълады ки, һушы китте.

Һарун әр-Рәшитне кызганып: «Әй Фазыйл, әмирел-мөэминингә бик каты әйттең», — дидем. Фазыйл әйтте: «Синең кебекләр хәлифәгә мәрхәмәт итмәенчә, аның хәтерен саклап, мактау белән аны һәлакәткә җибәрмәктәсез, һай, бичаралар», — дип, миңа дәхи шелтә кыйлды. Аннан соң дәхи хәлифә: «Әй Фазыйл, лотыф итеп нәсыйхәтеңне дәхи зиядә кыйл», — диде. Фазыйл әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, Гомәр бин Габделгазизнең валиләреннән бере, йокысызлык авыруына мөбтәля булып, Гомәр бин Габделгазизгә гарыз вә шикаять кыйлды. Гомәр бин Габделгазиз дәхи: «Әй карендәшем, кичәләрдә йокым юк, дип тәхрир кыйлмышсың. Әй карендәш, әлгаязе биллаһи, җәһәннәм әһеленең җәһәннәмдә йокысызлыкларын вә тәннәренең ут эчендә янмагын исеңә төшер. Кирәк йокыда, кирәк уяулыкта даим җәһәннәмне исеңдә тотмакың сине Хак Тәгаләгә тоташтырыр. Ошбу тугъры юлда аягың таймакыңнан саклан, сиңа кисәтүем будыр», — дип мәктүб күндерде.

Ул вали, Гомәрнең мәктүбен алып укыганнан соң, төнне көнгә катып, ашыгыч ватанын ташлап, Гомәр бин Габделгазиз хозурына килде. Гомәр әйтте: «Йә вали, килмәкеңә сәбәп нидер?» —

диде. Вали әйтте: «Әй хәлифә, мәктүбтә язылмыш вәгазең белән күңелемнән дөнья омтылышларын чыгардың. Аллаһ белән йөзгә-йөз очрашканчы, хаким булуны эстәмәсмен», — диде».

Бәс, Һарун әр-Рәшит, Фазыйлдан бу хикәятне ишеткәч, каты егълап, янә: «Әй Фазыйл, вәгазеңне дәхи зиядә кыйл», — диде. Фазыйл әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, ибн Габбас разыйаллаһу ганһу беркөн Рәсүл саллаллаһу галәйһивәсәлләмгә әйтте: «Йә Рәсүлуллаһ, бәндәңне бер шәһәргә вали итеп куйсаңыз», — дип риа кыйлды. Рәсүл галәйһиәссәлам: «Бер нәфес ки, аны син тыелу вә канәгать белән терелтү шартларын җиткерә алмаслык әмарәтеңнән вә валилегеңнән хәерледер. Зирә кыямәт көнендә әмирлегең хәсрәт вә үкенүдер. Әгәр, әй хәлифә, кодрәтең булса, әмир булма», — диде. Һарун әр-Рәшит дәхи каты егълады. Янә әйтте: «Йә Фазыйл, нәсыйхәтеңне дәхи зиядә кыйл, рәхимәкаллаһе Тәгалә», — диде. Фазыйл әйтте: «Әй хәлифә, тәхет хөкүмәтеңдә никадәр халык вә рәгыять[1] бар исә, дөньяда аларның әхвәлен тоту вә сакламак җәнабыңызга йөкләнгәнлектән, кыямәт көнендә Хак Тәгалә һәрбереннән сөаль кыйлыр. Әгәр бу назнин[2] бәдәнеңне җәһәннәмнән хәлас кыйлмага кодрәтең булырлык булса, әмир бул. Вә саклан ки, рәгыятьтән вә барча халыктан бер кемсәнәгә хыянәт вә дошманлык булмагай. Нахак бер кешене рәнҗетеп, үзеңә дошман итмә», — диде. Һарун әр-Рәшит дәхи егълап: «Әй Фазыйл, хаҗәтең вә бурычың бармы, түлим», — диде. Фазыйл әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, Раббыма бурычым бардыр. Ләкин хәзердә хисабы беленмәмештер. Әгәр Хак Тәгалә ул дәйнне эстәп мөнакашә боерыр исә, вә хаҗәтемне кабул итмәс исә, газап вә гыйкап минем өчендер», — диде. Һарун әйтте: «Минем морадым — бәндәләргә дәйнең бармы димәк иде?» — диде. Фазыйл әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, Аллаһы Тәгалә миңа дәйн вә бурыч әйт, дип боермады, ләкин вәгъдәсенә тасдыйк[3] вә әмеренә итагать белән боерды. Минем вазыйфаи дәйянәтем гыйрфан вә гыйбадәткә чалышмактыр».

---

Кайчан ки Фазыйл бин Гаяз, аятьләрне укып, вәгазен тәмам кыйлды, Һарун әйтте: «Әй мәүлана, ошбу мең алтындыр, ал, нәфәкаи әһел вә гыялеңә сарыф ит. Вә Аллаһы Тәгаләнең гыйбадәтендә моның белән куәт тап», — дип, мең алтын гарыз кыйлды. Фазыйл әйтте: «Сөбханаллаһи, йә әмирел-мөэминин, мин җәнабыңызны ошбу нәсыйхәтем белән хәергә вә хәлас тарикына боерырмын. Әмма сезләр бу фәкыйрьгә моның кебек фани нәрсә белән бүләк кыйласыз», — дип игътизар кыйлды вә мең алтынны кабул итмәде. Дога белән сүзен тәмам итеп, артык сүз сөйләмәде.

---

[1] Рәгыять — подданныйлар.
[2] Назнин — нәфис, йомшак.
[3] Тасдыйк — раслау, дөресен әйтү.

Изгеләрдән бер адәм һәркөн анасының аягын үбәр иде. Беркөн сыйланып вә сохбәт кыйлып утыра торган дусларының янына кичегеп килде. Сохбәттәшләре: «Ник сонга калдың?» — дип сорадылар. Аларга: «Җәннәт бакчаларында йөрдем», — диде. Ягъни: анамның аягына йөземне сөрмәк белән мәшгуль идем, зира хәдис шәриф безгә ирешмештер, диде.

---

Гомәр бин Габделгазиз Мәймүн бин Мәһранга васыятендә әйтте: «Әй Мәймүн, падишаһлар ишегеннән аерылмаслык булма. Һәр никадәр яхшылыкка өндәр вә яманлыктан тыяр булсаң да. Вә намәхрәм хатыннар белән хәлвәт итмә, һәр никадәр тәгълим Коръән итәр булсаң да. Вә ата-анасына буйсынмас вә гөнаһлы булганнар белән мөсахәбәт кыйлма, зирә ата-анасына изгелек итмәгән кеше сиңа һәм изгелек вә мәхәббәт итмәс», — диде.

---

Мәэмүн хәлифә димештер ки: «Атасына изгелек иткәннәрдән Фазыйл Бәрмәкидән артыгын күрмәдем. Зирә ишеттем ки, ата-угыл зинданда ябылганнар икән. Бер суык кичәдә зинданчылар аларны ут якмактан мәныг итмеш булып, Яхъяның атасының җылы су белән таһарәт алмага гадәте булмак җәһәтеннән, иртә намазга атасы торганчы, аяк үзрә кандил өстенә тотып, атасына су җылытып куймыш», — димәктер.

---

Мәнкульдер ки, бер кемсәнә дәхи җамә йокысында ятканда, углыннан эчмәгә су бир, дип сорап, янә йокыга китмеш. Углы суны китергәч, атасы йокыга киткәнен күреп: «Тукта, бәлки, тагы уянып сорар», — дип, атасының башы очында таң атканчы көтеп тормыш, имеш.

---

Бер кеше хәзрәти Гомәр разыйаллаһу ганһуга әйтте: «Әй әмирел-мөэминин, анам картлык көненә житеп хәрәкәткә кадир булмагач, даим аркама күтәреп йөрермен. Моның белән ана хакын жиренә житкерә белерменме?» — диде. Гомәр разыйаллаһу ганһу әйтте: «Юк, житкерә алмассың. Зирә синең анаң, син кечкенә вакытта синең хәятта калмакынны тәмәнна итеп, күтәреп йөрде вә хезмәтеңне кыйлды. Әммә син моны анаңның аерылышуын ният кыйлыбрак, ягъни анам үлеп-нитеп китсә, миннән бәхил булсын, дип әйткәнгәрәк охшыйсың», — диде. Бер ахмак бала бу сүзне ишетте дә: «Минем анам да, үсеп житкәч бер файда күрермән дип тәмәнна кыйлып, мине күтәреп йөргәндер», — диде.

---

Мөхәммәд бин Әлмөнәкдәр хәзрәтләре әйтте: «Бер кичә атамның аякларын уып кич үткәрдем. Борадәрем ул кичә тәһәжжед намазын кыйлды, мин кыйла алмадым. Ләкин карендәшемнең ошбу кичәсе минем кичәм янында мине мәсрүр кыйл-

мас», — диде, ягъни: атамны риза кыйлганыма шулкадәр сөендем, тәһәҗҗед намазының савабы күземә күренмәс, димәктер.

———

Мөхәммәд бин Сирин хәзрәтләре анасына, каты тавыш белән асла сөйләшмәенчә, бик усал түрәләр белән сөйләшкән кебек, тәгъзыйм белән сөйләшеп, анасының догасын бу юл белән тәхсыйл итәр иде.

———

Гали бин Хөсәен разыйаллаһу ганһу хәзрәтләре халыкның да изгерәге икән, аңа әйттеләр: «Ни өчен аның белән бергә утырып ашамайсың?» — диделәр. Гали әйтте: «Бәлки, анамның күзе төшкән локмәне белмәстән алып ашармын да, буйсынмаучы гөнаһлы булырмын, дип куркып, бергә ашаймамын», — диде.

———

Ибн Гамирның хатыны Әмамәт бинте Харис йөкле булган мөддәттә, ибн Гамир әйтте: «Әгәр дә ир бала тапсаң, хөкем синеңдер, ягъни син ни теләсәң, ул булыр», — дип вәгъдә кыйлды. Качан ки мөддәте тәмам булып, дөньяга ир бала китергәннән соң, Әмамәт әйтте: «Җиде көн микъдары нәфис нигъмәтләр тәртип кыйлып, мең табын халык тәгамландырмак вә мең куй гакыйка корбан зәбех кыйлмак эстәрмен», — диде. Ибн Гамир тәмамән иҗра кыйлмыштыр.

———

Корәеш әмирләреннән бер әмир, углына ачигъланып, яныннан куып чыгармыш иде. Әхнәф бин Кайс әйтте: «Әй әмир, балаларымыз — күңелләремезнең җимеше вә таянчы терәгемездер. Безләр балаларымызның зәхмәтләрен вә мәшәкатьләрен күтәрергә кирәкмез. Үпкәләсәләр, разый кыйлмак кирәкмез. Аларга хурлау, шелтә күзе белән карамаңыз. Эстәсәләр дә, эстәмәсәләр дә, бүләк кыйлыңыз ки, хәятыңыздан туеп, үлеменезне тәмәнна кыйлмасыннар», — диде.

Әмир Корәеш, Әхнәфнең бу фәсыйх сүзен ишеткәч, кабул итеп, колларыннан бер колына: «Әй кол, бар углыма ике йөз мең дирһәм вә ике йөз кат кием илтеп бир вә миннән сәлам әйт», — дип җибәрде. Әмирнең бу углы, атасыннан, каты ачу өстенә бу ихсанны күргәч, ул илткән колга әйтте: «Йә, атамның янында кем бар иде?» Кол: «Әхнәф бар иде», — дигәннән соң, Әхнәфне чакырып: «Йә Әбү Бәкер, кыйсса ни кәйфияттә булды?» — диде. Әхнәф дәхи вакыйганы тәфсыйлән хикәят кыйлды. Әхнәфнең бу лотыфына тәшәккәрән, атасы җибәргән нәрсәнең яртысын Әхнәфкә багышлады.

———

Голәмаи нәхүдән[1] имам Кәсаи риваять кыйлмыштыр ки: «Беркөн Һарун әр-Рәшит хәлифәнең хозурына кердем иде, угыл-

---

[1] Голәмаи нәхүдән — грамматика галимнәреннән.

лары Мөхәммәд Әминнең вә Мәәмүннең минем яныма килмәкләрен эстәп әмер кыйлды. Бәс, угыллары, дәрхаль үзләрен тезеп вә зиннәтләп йолдызлар кебек балкып вә зоһур итеп тәгъзыйм белән сәлам биреп, догаларын тәмам кыйлганнан соң, аяк астына гына карап, кәмаль әдәп үзрә аталарының хозурында тордылар. Хәлифә хәзрәтләре Әминне — уңында, Мәәмүнне — сулында утырмага боерганнан соң, миңа карап: «Әй Кәсаи, боларга дәкыйк гыйлем нәхүдән[1] берәр мәсьәлә имтихан кыйл», — дип боерды. Мин дәхи мәсаил нәхүдән дәкыйк мәсьәләләрне сөаль кыйлган вакытында, һәрбер мәсьәләмә күркәм җавап бирделәр. Хәлифә хәзрәтләре, шатланып, «Әй Кәсаи, боларның гыйлемдә чамалары ни дәрәҗәдәдер», — диде. «Әгъля дәрәҗәдер, дидем», — димештер.

———

Бәдәви гарәп хатыннарыннан бер хатын, баласын кочагына алып уйнатканда, бәет тәрәннем итеп әйтер, имеш. Эчтәлеге: баламның исе, шәһәрдә булган хәзами исе кебек, ни хуш истер. Әйа, һәрбер бала моның кебек рәгънәмедер яки моның кебек баланы минем кебек берәү дә тудырмадымы?

Халән үз җенесемездән бер хатын баласын бишеккә салып тирбәткәндә ишеттем:

Әлли-бәлли итәр бу,
Бохарага китәр бу.
Бохарадан кайткачтын,
Мулла булып житәр бу, —

дип,назнин, нечкә тавыш белән тәрәннем кыйлыр. Хуп, яхшы сүздер. Ләкин мәзкүр бәдәви хатынның баласы шул сыйфатка лаекмы, түгелме, бу вәсыф. Ялгыз баланың нәфселәмердә шул сыйфатта булмакы чыннан муафыйк төшмәс.

———

Бер кеше углына: «Озынлыгы егерме аршын кадәр бер кое бавы ал», — дип, базарга җибәрде. Углы, ярты юлга җиткәч, кире кайтып: «Әй эткәй, озынлыгы егерме аршын кадәр, дип әйттеңез, җуанлыгы никадәр булсын», — дип, ахмаклар кебек сораганга күрә, атасы әйтте: «Әй углым, синең белән мөбтәля булганым микъдарда булсын», — диде.

———

Гайса галәйһиссәламнән сорадылар: «Кайсы адәм вә кайсы нәсел әфзальдер?» — диделәр. Бәс, ике кулына җирдән туфрак алды да: «Моның кайсы әфзальдер?» — диде. Аннан соң ике кулындагын бергә кушты, җиргә ташлады. «Адәмнең һәркайсысы туфрактыр, бер-береннән әфзалияте юктыр. Аллаһы Тәгалә каршында кем тәкъва, ул артыктыр», — дип җавап бирде.

---

[1] Дәкыйк гыйлем нәхүдән — грамматика фәне нечкәлекләреннән.

Мәнкульдер ки, бер гарәпкә әйттеләр: «Син вафат булырсың», — диделәр. Гарәп әйтте: «Мин вафат булганнан соң, кайда булырмын?» — диде. «Аллаһы Тәгаләнең мәгънәви тарафына китәрсең», — диделәр. Гарәп әйтте: «Андаен хәер вә изгелек фәкать аннан гына булган изге затның тараф мәгънәвисенә китмәктән курыкмыйм мин», — диде.

Үзе бер надан гарәп икән, гарәп табигате үзрә хикмәткә мөтабыйк сүз сөйләмештер.

---

Хәсән бин Сабит разыйаллаһу ганһу беркөн бер сабый баласын кочагына алып, каймак белән бал ашатып торганда, баласы сау-сәламәт икән, кинәт вафат булгач, нәзыйм әйтте. Мәгънәсе: әй мәгърур мөддәт, хәятында аз гына миһләт бар икән, кайчанга чаклы гафләттә каласың? Әй, ни үкенечтер сиңа ки. Һаман сыйхәт мәйданында икәнсең, изге гамәлгә чалышмакың лаземдер. Зиар син сау-сәламәт хәлеңдә һаман шулай хәяттә булырмын дип өмид итәрсең, ләкин каймак белән бал арасында яшерен булган әҗәл, бердән килеп, бугазыңны тотса, ул вакытта каймак һәм бал сиңа агу булыр, димәктер.

---

Һарун әр-Рәшитнең берзаман бик сөя торган бер җариясе вафат булып, бик хәсрәтләнде, күп сабырсызлану кыйлды. Һарун әр-Рәшитнең бәгъзе вакытта күңел юатыр өчен бер мәзәкчесе бар иде. Ул Һарун әр-Рәшитне юату касды белән: «Йә әмирелмөэминин, бу хәсрәт белән үзеңезне үзеңез бетерәсез. Бу кадәр хәсрәтләнү кирәкмәс иде», — диде. Һарун әйтте: «Һи ахмак, минем нигә мөбтәля булганымны күрмәдеңме? Хәфа ки, мин кемне генә сөйсәм, вафат булды», — дигәч, мәзкүр мәзәкче: «Әй вәли нигъмәтем, мине һәм сөйсәнә, таки үләр идем», — диде. Һарун әйтте: «Мәхәббәт вә сөймәк ихтыяри нәрсә түгелдер, бәлки чарасыздыр, мин сине сөямен, дип әйтү генә мәхәббәт түгелдер», — диде. Мәзәкче әйтте: «Әфәндем, миңа сине сөямен, дип теленнән генә әйтсәң дә ярар иде», — дип, мәзәкчелек тарикынча: «Йә, сине сөямен, дип, бер генә мәртәбә әйтсәнә?» — дип интектергәч, Һарун әр-Рәшит дәхи: «Мин сине сөямен», — дигән иде, мәзәкче бичара филхаль мәхмүм булып егылды, мәрхүм булды.

---

Габдеррахман бин Мәһдинең углы вафат булып, бик егълап-куркып калганын ишетеп, имам Шәфыйг хәзрәтләре язып җибәрде. Мәфһүме будыр: «Әй җаным белән бәрабәр булучы борадәрем, гайреләргә кайгы уртаклашып нәсыйхәт биргәнең шикелле, үзеңә үзең нәсыйхәт кыйл. Җәзәгъ-фәзәгъ кыйлганны гайреләрдән күргән вакытта, мәкруһка сайганың шикелле, үзеңә дә мәкруһ күр».

Бер кемсәнә дусларыннан берсенең углы вафат булгач, ошбу бәлигъ тәгъзиятнамәне язып күндермеш: «Әмма бәгъдә, бисмиллаһи хәмд салават соңында хәятта булып торган мөддәттә, бала — атага фитнә вә көенеч маддәседер. Атасыннан мөкаддәм ахирәткә китсә, аның бу атасыннан мөкаддәм вафат булмакы Аллаһы Тәгалә җанибеннән[1] ул баланың атасына ихсан мәгъфирәт вә рәхмәттер. Бу сурәттә киткән фитнә өчен җәзәгъ-фәзәгъ итеп Аллаһы Тәгалә җәнибеннән киләчәк савап вә рәхмәтене заигъ итмә», — димештер.

———

Берәү бервакыт өендә утырып торганда, ишектән берәү килеп керде. Бу аны танымады, «Син кем?» — диде. Ул кеше әйтте: «Мин шундаен кешемен, падишаһлардан курыкмаймын; бикле сарайларга, таш пулатларга керәмен; акча алмаймын; ришвәт алмаймын; һичкемгә әман бирмәймен», — диде. Ул кеше әйтте: «Алайса, син җан алучы фәрештәсең, минем җанымны алырга килдеңме? Мин әле үлемгә хәзерләнгәнем юк, сабыр ит», — диде. Ул кеше әйтте: «Атаң кая китте? Фәлән дустың кая китте? Аларның үлеменнән гыйбрәт алмадыңмы?» — диде.

———

Нәсыйб исемле бер шагыйрьгә әйттеләр: «Һи син шагыйрь. Шигырең картайды», — диделәр. Нәсыйб әйтте: «Юк, минем шигырем картаймады, ләкин кәрәм вә җумартлык картайды. Хәким бин Моталлабны бер касыйдә белән мәдех кыйлдым, дүрт мең куй, дүрт мең динар, йөз тәвә бәхеш кыйлды», — диде.

———

Берничә шагыйрьләр җәмагать булып бер хәлифәгә бардылар. Аларга дәхи бер тофәйли[2] ияреп барды. Хәлифә янына керделәр. Бере артыннан бере касыйдәләрен укыдылар. Хәлифәдән бәхшишләр алдылар. Тофәйли хәйран булып калды. Аңар әйттеләр: «Инде син дә шигыреңне укы», — диделәр. Тофәйли әйтте: «Мин шагыйрь түгел, — диде. — Мин азган бер кешемен, нитәкки Аллаһы Тәгалә әйтте: шагыйрьләргә азгыннар ияр». Хәлифә көлде дә аңа да ингам кыйлмага боерды.

———

Мәнкульдер ки, Шәгъбә хәдистән дәрес биргәндә бик арыды, ялыкты. Ул вакытта Әбү Язид әл-Әнсари бер шигырь укып торыр иде. Шәгъбә әйтте: «Әй, килче монда, Әбү Язид», — диде. Әбү Язид аның янына килде дә бераз шигырь әйтештеләр. Дәрес тыңлаучыларның берсе әйтте: «Сиңа без, ерак җирдән тәвәләремезне ардырып, хәдис тыңларга киләмез. Син шигырьгә тотындың», — диделәр. Шәгъбә шулкадәр ачигъланды: «Һи, мин үземә нәрсә кирәкне белмәйменме?» — диде.

---

[1] Җанибеннән — тарафыннан.
[2] Тофәйли — чакырылмаган кунак.

## ҖӘВАҺИРЕЛ ХИКӘЯТ

Ошбу китап остазларның остазы имам Сүюти разыйаллаһу ганһуның «Әнисел җәлис» китабыннан тасниф кыйлынды. Мөхиб вә мөхлисләремезгә тәзкирә өчен тасниф кыйлып, «Җәваһирел хикәят» тәсмия кыйлдым. Габделкаюм мелла Габденнасыйр углы әш-Шырдани әр-Рәззакый 1299 (1882) елда. Таки дусларымыз өчен ялгызлыкта якын дус вә сохбәттәш булгай. Укып файда алучыларның күкрәге нур илә тулгай. Аллаһы Тәбарәкә вә Тәгалә җәмигъ мөэмин вә мөселманнар белән бергә барчамызны мәгърифәт кыйлгай. Амин, би хөрмәти сәйидилмөрсәлин. Әмма бер дә колакка ишетелмәгән ят сүзләр гакыйлга муафыйк күренмәгәндәй булса, имам Сүютинең «Әнисел җәлис» китабына нәзар салгайлар. Әгәр хата фәһемләп, хата тәрҗемә кыйлмыш булсам, носканыма икърарым[1] бар, гафу пәрдәсе пәрдәләсеннәр.

Инде, әй угыл! Аллаһы Тәгалә үзенең бәндәләренә кичәкөндез 24 сәгать эчендә биш вакыт намаз фарыз кыйлды ки, ул намаз — җәмигъ гыйбадәтләрнең башыдыр. Намаз белән җәмигъ хаҗәтләр үтәлер. Бәндәдән Аллаһы Тәгаләгә мөнәҗәттер. Караңгы кабердә якты чырадыр. Биш намазын тәрк кыйлгучы бу файдалардан мәхрүмдер вә ике дөньяда хур вә зәбундыр[2]. Берәү, башка изге гамәлләрне кыйлып, намазны тәрк кыйлса, ул гамәлләренең намаздан башка зәррә[3] кадәр файдасы юктыр. Намаз — баш мәнзилендәдер. Бәс, намазсыз башка гамәлләр башсыз тәнгә охшашлыдыр. Аллаһы Тәгалә үзенең Кәлямендә әйтте: әүвәл нәбиләрдән соң килгән кавем фарыз намазны ташладылар. Вә нәфсе арзуларына табигъ булдылар. Тиздер, кем, алар җәзага мөләкый булырлар. Мәфһүм тыйбъян.

Пәйгамбәр галәйһиссәламнән риваять кыйлынды ки: берәү, намазны сәһел нәрсәгә хисаплап, җәмәгать белән укырга ялкаулык кыйлса, Аллаһы Тәгалә аны 12 төрле җәза белән гый-

---

[1] Носканыма икърарым — кимчелекле булуын тануым.
[2] Зәбундыр — куәтсездер.
[3] Зәррә — бөртек.

каб кыйлыр. Өчесе — дөньяда, өчесе — үлгән вакытта, өчесе — кабердә, өчесе — кыямәт көнендә. Инде дөньяда Аллаһы Тәгалә аның кәсебеннән бәрәкәтне алыр; йөзеннән изгеләр нуры китәр — мөселманнар күзенә мәхәббәтсез күренер. Янә үлгән вакытында гаять сусап үләр: бөтен дөньядагы суны эчеп бетерсә дә туймас. Җаны бик катылык белән алыныр. Дәхи дөньядан имансыз китмәгендә хәвеф бардыр. Әлгаязе биллаһ. Дәхи кабердә катылык белән сөаль кыйлыныр. Кабере гаять караңгы булыр. Кабере тар булыр. Кабыргалары аралашыр. Вә һәм кыямәт көнендә сөаль вә хисап каты булыр. Аллаһы Тәгалә газап кыйлыр. Ут белән мәгъзаб булыр.

«Хөласател фәтави» («Фәтвалар җыентыгы») китабында мәзкүрдер ки: берәү азан әйткәнне ишетсә, аңа җәмәгать намазын куймага рөхсәт юктыр. Чөнки җәмәгать намазы расланган сөннәттер. Шөйлә ки: әгәр бер төбәк әһеле яки бер карья әһеле җәмәгатьне тәрк кылсалар, алар белән сугыш важибтыр. Әгәр бер кавемнән берәү җәмәгатьне тәрк кыйлса, җәза важибтыр. Тәрикес салятның[1] шәһадәте мәкъбуль түгелдер. Тәрикес салятның күршеләре — имам вә мәзин дәхи, әгәр сөкүт кылсалар, бергә гөнаһлы булырлар вә тәрикес салятның кәсафәте күршеләренә дә әсәр итәр. Тәрикес салят өчен тәгъзирнең иң азы — өч камчы сукмактыр. «Хөласател фәтави» иясе әйтте: «Мин бер шәригать галименнән ишеттем ки, тәрикес салятның малыннан җәримә[2] алып тәгъзир кыйлыныр. Чөнки адәмгә мал җәримәсе тән җәзасыннан читенрәктер. Бу җәзалар намазны җәмәгать белән укымаган кешегәдер. Әмма билкөллия намазны тәрк кыйлган кешегә ни җәза булыр, Аллаһы Тәгалә үзе белер».

———

Риваятьләрдә килмештер ки: бер адәм сахрада шайтан белән юлдаш булды. Беркөн йөрделәр. Бу кеше биш вакыт намазны укымады. Кич булды. Бер җирдә ятып йокламакчы булдылар. Бу кеше йокларга яткач, шайтан бу кешедән качып китте. Бу кеше әйтте: «Ник миннән качтың?» — диде. Шайтан әйтте: «Ник качмаска: мин гомеремдә бер мәртәбә Аллаһы Тәгаләгә гасый булдым, моның өчен Аллаһы Тәгалә мине мәрхәмәтеннән сөрде — мәлгунь булдым. Син беркөн Аллаһы Тәгаләгә биш мәртәбә гасый булдың! Инде куркамын ки, Аллаһы Тәгалә сиңа газап кыйлса, синең гыйсъяның сәбәпле миңа да каһәре

---

[1] Тәрикес салятның — намаздан читләшүченең.
[2] Җәримә — штраф.

тияр», — диде. Инде, әй угыл, тәүбә кыйл: тәрикес саляттан шайтан да курка, имеш!

———

Риваять кыйлынмыштыр ки: пәйгамбәр галәйһиссәлам сәхабәләре белән утырып торганда, бер гарәп мәсҗет капусына килеп егълады. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Әй егет, ни өчен егъларсың?». Егет әйтте: «Йә Рәсүлуллаһ, атам вафат булды. Кәфенлегем юк. Юарга кешем юк, фәкыйрьмен», — диде.

Пәйгамбәр галәйһиссәлам Әбү Бәкер вә Гомәр разыйаллаһу ганһу хәзрәтләренә боерды. Мәет янына бардылар, мәетне күрделәр: кара дуңгыз сурәтендә булмыш ятыр. Кайтып пәйгамбәр галәйһиссәламгә хәбәр бирделәр: «Йә Рәсүлуллаһ, без анда мәетне күрмәдек, мәгәр бер кара дуңгыз ятыр күрдек», — диделәр.

Бәс, җеназасына пәйгамбәр галәйһиссәлам чыкты. Җеназа укыды. Күрделәр: мәет үз сурәтендәдер. Аннан соң, дәфен кыйлмага, мәетне ләхет авызына китерделәр. Мәет янә дуңгыз сурәтенә дүнмеш. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Әй егет, атаң дөньяда ни явыз гамәл кыйлган иде?». Егет әйтте: «Йә Рәсүлуллаһ, атам дөньяда һич намаз укымады, җәмәгать намазына бармады», — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Йә сәхабәләрем, күрегез, кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә тәрикес салятны дуңгыз сурәтендә кубарса кирәктер», — диде.

———

Әбү Бәкер Ситдыйк разыйаллаһу ганһу заманында бер адәм вафат булып, халык моның җеназасына җыелдылар. Мәетнең кәфене кыймылдап-селкенеп торыр. «Бу ни хәл?!» — дип, кәфенне ачып карап күрделәр: бер елан мәетнең муенына чорналмыш. Мәетнең итен ашап, канын суырып ятыр. Бәс, бу еланны тотып үтермәгә касд кыйлдылар. Елан әйтте: «Лә иләһә иллә Аллаһү, Мүхәммәдүр рәсүлуллаһ, ни гөнаһым бар? Аллаһы Тәгалә миңа боерды: кыямәткәчә шөйлә бу мәетне газап кыйлсам кирәк», — диде. Әйттеләр: «Бу кешенең ни гөнаһысы бардыр?» Елан әйтте: «Бу кешенең өч төрле олуг гөнаһысы бардыр: әүвәл — азан ишетте, җәмәгать намазына бармады; икенче — малының зәкятен чыгармады; өченчесе — галимнәр вә вагыйзлар сүзен тыңламады. Бәс, ошбу аның җәзасыдыр», — диде.

Инде, әй угыл, Аллаһы Тәгаләнең әмерен тотмаганнарга кыямәт көнендә күп куркынычлар бардыр. Әл-хәзәр, әл-хәзәр![1].

———

Мөҗәһид разыйаллаһу ганһудан риваять кыйлынды ки: «Ибн Габбас разыйаллаһу ганһу янына бер кеше килде, әйтте:

---

[1] Әл-хәзәр, әл-хәзәр! — сак бул!

«Йә Ибне Габбас, бер кеше кичләре уяу торды, көндезләре руза тотты. Әмма җомга намазына бармады, намазны җәмәгать белән эда кыйлмады. Шул хәл үзрә вафат булды. Инде бу кеше хакында ни әйтәсең?» — диде. Ибне Габбас әйтте: «Ул кеше шиксез тәмуглыктыр», — диде».

———

Олуг мәшаихлардан бер адәм сәфәр нияте белән чыгып, юлы дәрьяга тугыры килде. Дәрья сәфәре өчен көймәгә утырганда күрде: су хайваннары бер-берене тотып ашадылар. Бу шәехнен күнеленә килде ки: «Сөбханаллаһи, дәрьяда һәм ачлык була, имеш», — дип хәйран булды. Мәллахтан сорады: «Йә мәллах, бу ни хикмәт? Монда сер ни-нәрсәдер ки, су хайваннары бер-берсене ашадылар?» — диде. Мәллах әйтте: «Инде ун елдыр күрәмез: су хайваннары шөйләдер, бер-берсене ашарлар. Әмма ни хикмәт, ни сер бардыр, белмәдек», — диде.

Бәс, бу шәех, мөнәҗәт кыйлып, Аллаһы Тәгаләдән сорады. Һатифтән бер аваз ишетелде ки: «Көннәрдән бер көн бер бинамаз, ошбу дәрьядан узганда, сусап, дәрья якасына килде. Дәрьядан су алып, авызына капты. Дәрья суы ачы, имеш, авызындагы суны янадан дәрьяга түгеп ташлады. Бәс, бинамазның кәсафәте әсәр итеп, дәрьяда ачлык вакыйг булды. Хәтта балыклар бер-берсене ашамага башладылар», — диде.

———

Көннәрдән бер көн Гайсә галәйһиссәлам бер карьядән узганда күрде: гыймарәтләре төзек, агар сулары вә җимешләре күп вә нигъмәтләре мул. Вә карья әһле барчасы тагать вә гыйбадәт белән мәшгульләрдер. Маллары вә хайваннары күп. Әнваг нигъмәт белән мөнәгъгыймнәр. Гайсә галәйһиссәламне китереп, гыйззәт вә хөрмәт кыйлдылар. Вә малларын Гайсә галәйһиссәламгә гарыз кыйлдылар, әмма Гайсә галәйһиссәлам кабул итмәде, юлына китте. Аннан соң янә өч ел үткәч, Гайсә галәйһиссәлам ошбу карьягә килде, күрде: элгәреге бакчалары вә гыймарәтләре харап булмыш. Елгалары вә агар сулары корымыш. Маллары вә хайваннары юкка чыкмыш. Тагать вә гыйбадәт кыйлгучылары мәсҗетләреннән китмешләр. Йортларында һичкем юк. Бөтен карьяне гизде, һичберәүне күрмәде. Бу әхвәлне сорашырга кеше тапмагач, гаҗәпләнеп, Аллаһы Тәгаләгә мөнәҗәт кыйлды. Әйтте: «Илаһи Бер Ходая, әгәр синең каршыңда бу бәндәнең аз гына кадер вә гыйззәте булса да, бәян кыйлгыл: бу карья әһеленә ни булды? Гыймарәтләре вә бакчалары, вә халыклары кая китте? Агар сулары вә чишмәләре кая китте? Бер сахир юкка чыгардымы? Күз тидеме? Яки дошманнары һәлак кыйлдымы? Яки тагать вә гыйбадәтләрен ташладылармы?» — диде. Дәрхаль Җәбраил галәйһиссәлам инде, әйт-

те: «Йә Гайсә, Аллаһы Тәгалә сиңа сәлам укыды. Вә дәхи әйтер ки, бу карья сихер сәбәпле, күз тию сәбәпле, вә тагать-гыйбадәтне кую сәбәпле харап булмады, бәлки харап булды намазсыз кеше шомлыгыннан. Көннәрдән бер көн бу карьядән бер намазсыз кеше узып китте. Чишмә-суларында кулын юды вә суларын эчте. Бәс, шул намазсызның кәсафәте тиеп, бу карья һәлак булды», — диде.

Инде, әй угыл, кайчан ки намазсызларның кәсафәте дөнья гыймарәтләрен харап итсә, үзенең дин гыймарәте харап булып, кыямәт көнендә аңа булачак газап вә гокабаны Ходай Тәгаләдән гайре кем белер?

---

Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: һәрбер булачак эшләр Ләүхелмәхфүздә язылды. Каләм кипте. Кемнең гасый буласы, кемнең мотыйг буласы әзәлдә язылды. Бәс, әмер вә нәһинең вә ирсалның[1] ни файдасы бардыр, дисәң, әй угыл, бу мәсьәләдә күп вәҗеһләр вә күп гыйлемнәр бардыр. Кем белде, һидаять тапты. Вә кем белмәде, зәляләткә төште. Әгәр дә берәү «каләм кипте» дигән сүздән: «Аллаһы Тәгалә һәрбер нәрсәне яратып бушады», — дигән сүзне ирадә кыйлса, ул кеше яһүдиләр мәзһәбенә китте. Чөнки алар диләр ки: «Аллаһы Тәгалә дөньяны вә дөньяда булган нәрсәне — һәммәсен алты көндә яратты, җиденче көндә бушады», — диләр. Бу сүз — көфердер. Инде безнең җавабымыз будыр ки: бер заманда бер гамәл белән мәшгуль булып, бер заманда гамәлдән читтә булган һәрбер зат мәңге жумарт булмас. Аның өчен, әгәр дә шулай булса, ягъни бер заманда гамәлендә булып, бер заманда эштән бушаган булса, бәс, ул башка булды вә аның гамәленә башкалык керде ки, ул тәгъйиргамәл вә фәрәгатьтер вә замандыр. Бәс, Аллаһы Тәгалә тәгъйирдән вә тәбдилдән[2] ерактыр. Каләмне халк итмәседән элек ничек иде, кипкәч тә, һаман шулайдыр. Аллаһы Тәгаләнең сыйфатында һич тәгъйир булмас. Аллаһы Тәгалә әбәдән[3] эштән фаригъ булганы юк. *«Куллү яумин һүвә фи шәэн»* — Корьән аяте моңа дәлилдер.

Бәс, белгел ки, әй угыл, һәрбер нәрсә Аллаһы Тәгаләнең ирадәсе белән вә теләмәке беләндер. Һичбер нәрсә, һичбер хөкем, һичбер әмер, һичбер гамәл Аллаһы Тәгаләнең ирадәсеннән вә сангыннан тыш булмас. Вә дәхи нитәкки Аллаһы Тәгаләнең заты һичбер мәхлук затына охшамас, эше-сәнгате, һичбер гамәле дәхи мәхлук эшенә вә мәхлук гамәленә охшамас. Мәхлук ни-нәрсә кыйлса, Аллаһы Тәгаләнең һәм эш-сәнгате аның га-

---

[1] Ирсалның — язу җибәрүнең.
[2] Тәгъйирдән вә тәбдилдән — үзгәртүдән вә алмашынудан.
[3] Әбәдән — мәңге.

мәленә бәйледер. Ягъни бер нәрсәне эшләп, бәндәнең ул гамәленә вә ул фигаленә[1] мокабил вә мокарин икенче бер нәрсә иҗат кыйлыр. Хәлбуки ул нәрсәне эшләмәктән бәндә гаҗиздер. Аны эшләмәгән бәндә әбәдән кадир түгелдер. Мәсәлән, бәндә бер локмәне алып, авызына капмага вә чәйнәмәгә кадир. Әмма локмәгә ләззәт бирмәгә кадир түгелдер. Ягъни бәндәнең чәйнәмәгенә мокарин ләззәт бирмәк — Аллаһы Тәгаләнең эшедер. Вә дәхи бәндә үзенең хезмәтчесен сукмага кадир. Ләкин оялуны, үкенүне иҗат кыйлмак бәндә эше түгелдер. Бәндәнең сугуына үкенүне Аллаһы Тәгалә халк итәдер. Бәндә иген икмәккә, җиргә орлык сачмага кадирдыр. Әмма ул орлыкны тишелдермәгә вә үстермәгә кадир түгелдер. Вә дәхи бәндә җимаг кыйлмага кадирдыр. Әмма җимагда ләззәтне иҗат кыйлмага вә бала булдырмага кадир түгелдер. Бәс, бәндәнең һәрбер сангында Аллаһы Тәгалә сангының дәхеле бардыр. Хәлбуки бәндә андан гаҗиз иде.

Инде, әй угыл, бу бабта сүз күптер. Бу кадәресе кифая[2]. Вә дәхи Аллаһы Тәгаләнең сангы бәндә сангына охшамагынлыкы Нәмруд утында, вә дәхи корбан Исмәгыйльдә, вә гассаэ Мусада бик заһирдыр. Ягъни Нәмруд Ибраһим галәйһиссәламне утка аткач, Аллаһы Тәгалә утның эсселеген алды, бакча кыйлды. Вә Ибраһим галәйһиссәлам углы Исмәгыйльне зәбех кыйлганда, Аллаһы Тәгалә пычакны кисмәс итте, кыйссасы мәшһүрдер. Вә дәхи Аллаһы Тәгаләнең сангыннандыр: тагатьтә — мәгъсыять вә мәгъсыятьтә мәгърифәт зоһур итәдер. Мәсәлән, иблис тагатьтә иде, тагате гыйсъянга монкалиб булды. Вә сихерчеләр Фиргавен гыйсъянда иделәр, Аллаһы. Тәгалә аларда бер мәгърифәт иҗат кыйлды: хаклыкны белделәр — Муса галәйһиссәламгә иман китерделәр.

---

Кайчан ки Муса галәйһиссәламгә «Тәүрат» инде. Муса галәйһиссәлам «Тәүрат»ны укыр иде вә «Тәүрат» белән мөшәррәф булыр иде. Бәс, көннәрдән бер көн Җәбраил галәйһиссәлам әйтте: «Йә Муса, Аллаһы Тәгалә сиңа сәлам укыды вә дәхи әмер кыйлды ки: Бәни Исраилне җыйгайсың вә минбәргә менгәйсең вә кауменне вәгазь кыйлгайсың. Кауменнән кем дә кем һидаятькә әһел булса, һидаять кыйлынып, рәхмәткә васыл булсыннар», — диде.

Бәс, Муса галәйһиссәлам минбәр куйды: Бәни Исраилны җәмгы калды. Менә берзаман сәясәт вә тәкәбберлек белән зиннәтле нәфис вә бизәлгән киемнәр киеп, вә хәзинә ачкычларын кырык тәвәгә йөкләп, вә дәхи алтын-көмеш белән мөзәййән атларга

[1] Фигаленә — фигыльләренә, эшенә.
[2] Кифая — җитәр.

атланган өч мең коллары белән Муса галәйһиссәламнең вәгазь мәҗлесенә Карун килде. Нитәкки *фәхраҗә галя каумиhи фи зиннәти* — Корьәндә мәзкүрдер.

Инде, әй угыл, әгәр голяма мәҗлесенә бармак теләсәң, сиңа важибтыр ки, тыйнаклык вә түбәнчелек белән вә инкисаре калеб белән барырсың. Кем дә кем голяма мәҗлесенә бу сыйфатта барса, Аллаһы Тәгаләдән мәгъфирәт[1] табар. Әгәр Карун сыйфатында тәкәбберлек өчен зиннәтләнеп барса, Аллаһы Тәгаләдән киселеп, җәзага улашыр. Нитәкки күрдеңме, Карун сәясәт, вә тәкәбберлек, вә зиннәт белән килде. Фәкать дөнья тереклеген ирадә кыйлгучылар аңа аяк үзрә тордылар вә аны тәгъзыйм вә тәкрим кыйлдылар. Бәс, Муса галәйһиссәлам аларны бу эштән мәныг кыйлды: «Бу ярамас гыйлем вә вәгазь мәҗлесендә шөйлә тәкәллафләнмәңез», — диде. Кемдер, Муса галәйһиссәламнең сүзен кабул итеп, Карунга аяк үзрә тормады, Муса белән бергә нәҗат тапты[2]. Карунга тәвазыйглык кыйлып, тәгъзыйм вә тәкрим кыйлганнар Карун белән бергә карангы булдылар, ягъни Карун белән бергә барчасын җир йотты.

---

Кайчан ки Муса галәйһиссәлам Карунның зиннәтен вә байлыгын күрде, зәкят чыгармага әмер кыйлды. Бәс, Карун хисап кыйлып карады, мең бер дә мең алтын зәкят чыгачак булды. Бу кадәр зәкятне чыгармак күңеленә авыр килде: «Юк, мин бу кадәр зәкятне чыгара алмамын», — диде. Муса галәйһиссәлам әйтте: «Берәү үзенең малыннан хаккы Аллаһыны чыгармаса — кяфердер», — диде. Аннан соң Карун Муса галәйһиссәламнән бу сүзне ишеткәч, күңелендә кинә тотты. Дәхи көннәрдән бер көн Муса галәйһиссәлам, халыкка вәгазь итмәгә, минбәргә ашты. Карун галәйһиләгънә Бәни Исраил арасында Муса галәйһиссәламне төһмәт кыйлып оятлы итмәк өчен, бер йөкле хатынны табып китереңез, дип боерды. Бер дә йөкле хатынны таба алмадылар. Мәгәр бер көтүче белән зина кыйлып йөкле булган хатынны табып китерделәр. Карун ул хатынга кырык ука, алтын вәгъдә кыйлды. Вә ул хатынны үгрәтте вә әйтте: «Әй хатын, Бәни Исраил арасына чыгып: «Муса минем белән зина кыйлды, аннан йөкле булдым, дип дәгъва кыйл», — диде. Аннан соң Карун дәхи Муса галәйһиссәлам мәҗлесенә килде. Муса галәйһиссәлам белән моназарага торды. Муса галәйһиссәлам минбәрдә иде. Әйтте: «Йә Муса, золымлык белән кеше үтергән кеше хакында ни әйтәсең?» — диде. Муса галәйһиссәлам әйтте: «Үтерү — важибтыр». Карун әйтте: «Алай булса, золмән кеше үтермәк зәкят бирмәгәннән олуграктыр ки, син үзең —

---

[1] Мәгъфирәт — ярлыкау.
[2] Нәҗат тапты — котылды.

золмән, бер кеше үтердең, сине кател важибтыр», — диде. Муса галәйһиссәлам әйтте: «Мин, золмән, берәүне дә үтергәнем юк, мәгәр дошман кяферне үтереп, бер хак мөселманны коткардым. Бу золмән кател имәстер, мәгәр дошман белән газадыр», — диде. Карун әйтте: «Минем дәхи бер мәсьәләм бар: бер хатын белән зина кыйлып, ул хатын андан йөкле булса, бу кеше хакында ни әйтәсең?» — диде. Муса галәйһиссәлам әйтте: «Әгәр мохсинә[1] булса, ташлар бәреп үтерелер яисә куылыр. Әгәр гайре мохсинә булса, йөз камчы сугылыр», — диде. Карун әйтте: «Алай булса, сине рәҗем важиб, чөнки син бер хатын белән зина кыйлып, ул хатын синнән йөкле булмыштыр», — диде. Муса галәйһиссәлам әйтте: «Һич мин бу эшне кыйлганым юк. Мин — бу эштән бизгүчемен», — диде. Аннан соң шул хатын, аяк үзрә торып: «Муса минем белән зина кыйлды, бу йөгем аннандыр!» — дип, Бәни Исраил арасында гауга чыгарды. Муса галәйһиссәлам бик оялып, башын түбән салып тик торды. Хәлбуки Муса галәйһиссәлам бу эштән азат иде.

———

Муса галәйһиссәлам бу кадәр гыйсмәте вә бәраәте[2] белән кяфер арасында зина төһмәтеннән хәҗил булды. Инде, әй угыл, дөньяда ачык зина кыйлып йөргән адәмнәрнең хәле кыяммәттә җәмигъ халаиклар вә пәйгамбәрләр арасында ничек булса кирәк? Бәс, бу кадәр кавем арасында Муса галәйһиссәлам мөтәхәйир[3] булып калды. Вә мөнәҗәт кыйлды: «Илаһи, бу кавем зинадан саф икәнемне белмәсәләр дә, хәлемне син беләсең», — дип, Аллаһы Тәгаләгә тәзарры кыйлды. Бәс, Аллаһы Тәгаләдән нида килде: «Йә Муса, әгәр эшеңне миңа тапшырсаң вә миннән хаҗәт теләсәң, анасы корсагындагы баланы сөйләштермәгә кадирмын. Таки синең зинадан мөбәррә икәнеңә шәһадәт бирсен», — диде. Муса галәйһиссәлам Карунга әйтте: «Йә Карун, әгәр дә анасы корсагындагы бала минем зинадан пакь икәнемә гуаһлык бирсә, ни әйтерсең?» Карун әйтте: «Әлбәттә, синең тугырылыгың заһир булыр, ялган төһмәт икәне беленер», — диде.

Бәс, бала Аллаһы Тәгаләнең изене белән анасы корсагында сөйләште. Барча Исраил кауме ишеттеләр, бала фәсих теле белән әйтте: «Фәлән җирдә, фәлән вади эчендә фәлән көтүче белән анам зина кыйлды. Анам аннан хамилә булды. Муса галәйһиссәлам зинадан пакьтер вә пәйгамбәрдер. Сезләргә Рәсүл итеп җибәрелде. Аның сүзе хактыр вә заты гөнаһтан бәридер», — диде. Кайчан ки бу бала шәһадәт бирде, Муса галәй-

---

[1] Мохсинә — ирле хатын, намуслы хатын.
[2] Гыйсмәте вә бәраәте — сафлыгы һәм гаепсезлеге.
[3] Мөтәхәйир — гаҗәпләнүче, хәйран калучы.

һиссәлам шат булды. Карун хәҗил булды. Инде белгел ки, әй угыл, шәригатьтә сабыйның шәһадәте җаиз түгелдер. Шулай була торып, ягъни шәһадәте җаиз булмаган кешенең шәһадәте белән, Аллаһы Тәгалә Муса пәйгамбәрне төһмәттән вә бөһтаннан коткарды. Үзенең өммәтеннән булган кяферләр арасында хәҗил вә оятлы кыйлмады. Инде ни әйтерсең ки, Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд галәйһиссәлам өммәтенә: *«Кунтум хайра уммәтин ухърижәт линнәс»* — дип, үзе гуаһлык бирде. Бәс, кыямәт көнендә тәмугтан вә кыямәт хәҗаләтеннән хәлас кыйлып, фазлы вә кәрәме белән оҗмахка кертсә, ни сүзең бардыр?!

Бәс, ул фәхишә вә зания[1] хатын Муса галәйһиссәлам хакында ялган гуаһлык бирде. Аның ялган шәһадәте сәбәпле, йортлар харап булды; Карунны мал-милкене вә сарайлары белән җир йотты. Вә ул хатын үзенең денен фәсад кыйлды, һәлак булды. Әй угыл, һәрбер ялган гуаһлык биргән кеше — үзенең динен харап итәр вә гайреләрнең йортын харап итәр. Ул кеше зания хатыннан да дүндер[2].

Кайчан ки ул зания хатын Муса галәйһиссәлам хакында ялган гуаһлык биреп хәҗил булды, халык арасыннан качты. Мөэминнәрдән ике кеше ул хатынның артыннан киттеләр. Хатынның йортына керделәр, күрделәр: бу йортында ашамак-эчмәктән, кием-салымнан һичнәрсә юк, гаять фәкыйрә хатын, имеш. Чөнки зина фәкыйрьлекне ирас кыйлыр: *«Лиәннәз-зина йурәсул-фәкра»*, — диделәр. Дәхи пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: *«Иннә әһләз-зина мәкъһурату бил-фәкри»*. Һәрбер йорт зина белән мәшһүр булса, ул йорттан бәрәкәт качар. Аннан соң ул ике кеше хатынны тотып, Муса галәйһиссәламгә китерделәр. Муса галәйһиссәлам әйтте: «Таки баласын ташламай торып, бу хатынга җәза тиеш түгелдер. Чөнки хатын гөнаһлы булса да, корсагындагы баласы мәгъсумдыр», — диде.

Инде, әй угыл, күрдеңмә, ул зания хатын хәтта зинадан булган баласы сәбәпле җәза кыйлынудан мөһләт тапты. Бәс, Аллаһы Тәгаләгә гасый бәндә үзенең мәгърифәте вә иманы сәбәпле Аллаһы Тәгаләнең лотфы вә гыйнаяте белән гокубәттән вә тәмуг газабыннан иминлек тапса гаҗәпме? *Иннә Аллаһ ягъфируз-зөнүбә җәмига.*

Янә баягы сүзгә кайттык. Кайчан ки Бәни Исраил баланың анасы корсагыннан шәһадәт биргәнен ишеттеләр, иман әһленнән булганнары Аллаһы Тәгаләдән тәүфыйк таптылар, Муса галәйһиссәламгә өммәт булдылар. Күңелләрендә нифак булганнары мәхзүл булдылар: «Мусаның дәлиле сихридер», — диделәр. Әй угыл, бу кыйссадан хисса будыр ки: Аллаһы Тәгаләдән

---

[1] Зания — зиначы хатын.
[2] Дүндер — түбәнрәктер.

тәүфыйкъ вә һидаять ирешкән кеше гыйлем вә вәгазь мәҗлесеннән тәүбә вә истигъфар белән кайтадыр. Мәрдүд вә мәхзүл булганнарга гыйлем вә вәгазь әсәр итмәйдер. Алар гөнаһларында ныклардыр. *Нәгүзү билләһи мин зәлик.*

———

Муса галәйһиссәламнең бу мәҗлесендә Бәни Исраил арасында бер кыбтия хатын бар иде, күңеленнән ният итте: «Әгәр Муса галәйһиссәламнән могҗиза изһар итсә яки минем ниятемә муафыйк нәсыйхәт сөйләсә, Мусага иярермен — мөселман булырмын» — диде. Әмма ул җөзам[1] зәхмәтле хатын иде. Бәс, тынлап торды. Муса галәйһиссәлам һәрни әйтә, тәсдыйк кыйлды. Кайчан ки Муса галәйһиссәламнән могҗиза күрде, кулын югары күтәреп: *«Әшһәдү ән ля иләһә иллә Аллаһ вә әннә Муса Рәсүлуллаһ»*, — дип иман китерде. Шул сәгать җөзам зәхмәте һәм китте, биизниллләһи Тәгалә. Инде, әй угыл, хатын бер мәртәбә гыйлем мәҗлесенә кермәке белән бу кадәр мәгърифәт вә иман белән мөшәррәф булып, җөзам зәхмәтеннән хәлас тапты. Ушандак[2] гыйлем вә вәгазь мәҗлесендә булган адәмнәр, мәгърифәт вә мәгъфирәт табып, Аллаһы Тәгаләнең лотфы берлән мәгъсыят зәхмәтеннән хәлас булса, һич гаҗәп юк. *Вә зәккир фәиннәз-зикра тәнфәгул-мөэминин.*

Кайчан ки Карун Муса галәйһиссәламгә гасый булды, аның сүзен тыңламады — зәкят бирмәде. Бәс, Муса галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә мөнәҗәт кыйлды. Аннан соң Җәбраил галәйһиссәлам иңеп, Аллаһы Тәгаләнең әмерен тапшырды, әйтте: «Йә Муса, Аллаһы Тәгалә өч көнгәчә җирне сиңа буйсындырды. Җиргә әмер кыйл: Карунны йотсын», — диде. Бәс, Муса галәйһиссәлам җиргә әмер кыйлды. Аннан соң, зилзилә кубып, Карунны мал-мөлкәте белән, һәм сарайлары белән, вә 700 кешесе белән җир йотты. Мәзкүрә иман китергән кыбтия хатынның ирен дәхи биленә чаклы җир тотты. Шул хәлдә хатын әйтте: «Илаһи, иманым вә исламым хөрмәтенә иремне бу хәвефтән хәлас кыйл!» — диде. Шул сәгать хәлас булды. Ул яңа мөселман булган хатын иренең хәласенә ике нәрсәне шәфыйг китерде: әүвәл Муса галәйһиссәлам мәҗлесен вәсилә[3] кыйлды. Икенче, үзенең иманын вә мәгърифәтен вәсилә кыйлып сорады. Бәс, ире хәлас тапты.

Инде, әй әһле ислам, ошбу гасый бәндә биш нәрсәне шәфыйг тотып дога кыйладыр ки, амин диеңез: «Илаһи мөэминнәрнең гыйбадәт мәүзигы булгучы мәсҗет хөрмәтенә! Вә китабың Коръән мөбин хөрмәтенә! Хатимен нәбийин мәүзигы

---

[1] Җөзам — махау, проказа.
[2] Ушандак — шулай ук.
[3] Вәсилә — чара.

булгучы минбәр хөрмәтенә! Вә Коръән газыйм иңгән Рамазан шәриф ае хөрмәтенә! Вә гөнаһлы мөэминнәрнең күзеннән аккан яшь тамчыларының хөрмәтенә: ошбу, хазер-м-мәҗлес булган җәмәгать мөслиминне мәгъфирәт кыйл. Амин. Кыямәт михнәтләреннән хәлас кыйл. Амин. Вә газаб кабердән имин кыйл. Амин. Вә тәмугтан азат кыйл, оҗмахың белән мөшәррәф кыйл. Амин. Вә йөзеңне күрү белән мөшәррәф кыйл. Амин, *бирахмәтикә йа әрхәмәр-рахимин*.

---

Сөләйман галәйһиссәлам пәйгамбәр икән, ни өчен Аллаһы Тәгаләдән дөнья милкен вә дөнья нигъмәтен сорады: *«Рабби һәб ли мулкә»*, — диде. Монда ни хикмәт бар иде? Әй угыл, җавап будыр ки: Сөләйман галәйһиссәлам фәкать дөньяны гына сорамады. Ул аятьнең алдында әүвәл мәгърифәт сорады: *«Раббигъфирли вә һәбли мулкә»*, — диде. Әгәр фәкать дөньяны сораса, *«Раббигъфирли»* димәс иде. Монда күп сәбәп бардыр. Җөмләдән бере будыр ки: Сөләйман галәйһиссәлам фәкыйрь кемсәнә иде.

Беркөн Җәбраил галәйһиссәлам килде, әйтте: «Йә Сөләйман, Аллаһы Тәгалә сиңа сәлам укыды вә әмер кыйлды ки: фәлән җирдә ярлы, ялгыз бер хатын бардыр. Аллаһы Тәгалә каршында аның дәрәҗәсе олугдыр. Ул хатынга ихсан кыйлгайсың — дөнья хаҗәтләрен андин күтәргәйсең», — диде. Сөләйман галәйһиссәлам әйтте: «Илаһи, үзеңә мәгълүмдер ки, мин фәкыйрьмен: дөньялыктан нәрсәм юктыр, *фәһәб ли мулкә, хәтта әһәб ләһә*». Ягъни: илаһи, миңа дөньялыкны бирсәң, таки ул хатынга ихсан кыйлыр идем, дип мөнәҗәт кыйлды. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Йә Сөләйман, ни максудың бар, сора. Биргүче мин!» — диде. Сөләйман галәйһиссәлам әйтте: «Дөнья — ахирәт максудым бар. Инде сорамага изен булды: *«Раббигъфирли вә һәбли мулкә ля янбәгый лиәхәдин мин бәгъди иннәкә әнтәл вәһһәб»*, — дип дога кыйлды. Бәс, Аллаһы Тәгалә Сөләйман галәйһиссәламгә җилне, адәмнәрне, вә җен вә шайтаннарны мөсәххәр кыйлды. *Фәсәххарнә ләһүр-рихә тәҗри би әмриһ*.

Кыйссаларда мәзкүрдер ки, Сөләйманның гаувас[1] шайтаннары бар иде. Дәрьяга чумып, энҗе вә җәваһирләр китереп, Сөләйман галәйһиссәламгә тәкъдим кыйлырлар иде, *вә минәшшәятыйни мин ягусүнә ләһү*.

Аннан соң Сөләйман галәйһиссәлам Җәбраил галәйһиссәламгә әйтте: «Ул хатынның урыны кайдадыр?» Җәбраил галәйһиссәлам: «Фәлән җирдәдер», — дип тәгъриф кыйлды. Бәс, Сөләйман галәйһиссәлам сәхәрдән торды, шул хатынның мәкаменә килде. Күрде: бер караңгы җирдә торыр. Күрде: өендә ашамак-эчмәктән, кеймәк-салмактан һич нәрсәсе юк. Ха-

---

[1] Гаувас — водолаз.

тынның ике кызы бар, имеш. Уң кулын — олуг кызының баш астына, вә сул кулын кече кызының башы астына куеп, кызларын йоклатмыш. Кызлары ялангач, коры җирдә яталар. Җирнең катылыгыннан тәннәренә чыбта бизәге төшмеш. Аналарының куллары җәрәхәтләнмеш. Балаларына шәфкать йөзеннән сабыр итеп торыр. Шул заман бер кызы, уянып: «Һай, атам булса, тәгам китерер иде, ашар идем». Вә икенчесе дәхи: «Ваһ, атам булса, кием бирер иде, кияр идем», — дип, тавыш белән егъларлар. Боларның хәсрәтеннән аналары дәхи егълар, хәсрәт яше күзләреннән агар иде, Сөләйман галәйһиссәлам әйтте: «Йә мескинә хатын, ирең кайчан вафат булды?» Хатын әйтте: «Йә Рәсүлуллаһ, инде үлгәненә ел ярым булды. Бу ике ятим бала белән фәкыйрьлектә мөбтәлямен», — дип. Бәс, Сөләйман галәйһиссәламнең рәхеме килеп: *«Рабби һәбли мулкә»*, — диде.

Берничә көннән Сөләйман галәйһиссәлам әмер кыйлды: бу хатынга биш тәвә йөге җиһаз — алтын, көмеш вә җәүһәрдән төяп илттеләр. Сөләйман галәйһиссәлам дәхи килде, әйтте: «Йә хатын, сиңа сөенеч булсын: сабыр кыйлдың, Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кыйлдың. Сабырың вә тәвәккәлең өчен Аллаһы Тәгалә сиңа биш йөк җәваһир һибә кыйлды», — диде. Әй угыл, белгел ки, Аллаһы Тәгалә сабыр вә тәвәккәл кыйлганнарны заигъ кыйлмас. Берәү Аллаһы Тәгаләгә тәвәккәл кыйлса, ятимнәргә вә мескиннәргә шәфкать вә хезмәт кыйлса, һичкайчан аның әҗере заигъ булмас. *Вә мин йәтәвәккәл галәллаһи кәфәһ.*

---

Авызына сөяк капкан бер эт, күпердән узып барганда, суда үзенең сурәтен күрде: авызына сөяк капкан да йөгереп бара. Бу үзенең сурәтен хакыйкый эт дип гөман кыйлып, судагы этнең авызыннан сөякне алмага касд кыйлды: сурәтнең авызындагы сөяк зуррак күренде. Аны алмакчы булып, авызындагы сөякне ташлады. Судагы этнең авызындагы сөяк һәм төшеп китте, эт ике сөяктән һәм мәхрүм калды.

Инде, әй угыл, бу хикәятне бер буш кыйссага хисаплама. Кыйссадан хисса будыр ки: нәфсе әммара адәмнең тәнендә шул эт кебектер. Адәмнең авызында гамәл сөяге бардыр. Дөнья тереклеге су шикелледер. *Иннәмә мәсәлул хәйәтил-дунья кәмәин әнзәлнәһү минәс сәмәи.* Нәфсе әгәр дөньяга караса, үзенең сурәтендә халыкны күрәдер ки, авызларында мал сөяге вә байлык сөяге бар. Алмага тәмыг кыйлып, авызындагы гамәл сөяген ташлыйдыр. Малга да васыйл булмай каладыр. *Вә зәликә һүәл хүсранул-мубин.*

---

Солтан Мәхмүд Газнәви заманында бер зөҗаҗ, ягъни пыялачы бар иде. Пыяла дөкяне солтан сараена якын иде. Көннәрдән бер көн бу дөкянгә килеп, берәү бер динарлык пыяла

алды. Солтан Мәхмүд үзенең сараеннан карап торыр иде. Вә солтанның Аяс исемле бик сөекле вәзире сарай өстеннән ук атар иде. Ук шул кешенең пыяласына килеп тиде. Пыяласы уалды. Солтан моны күреп торды. Бу кеше, солтан капусына килеп, шикаять кыйлды, егълады: «Йә солтан, вәзирең пыяламны ватты, хакымны алып бир», — диде. Солтан әйтте: «Пыялаңның бәһасе кыйммәтме иде?» — диде. Ул кеше әйтте: «Мең тәңкәлек иде». Солтан әйтте: «Һай, ялганчы, оялмаймысың? Мин үзем күреп тордым: бер алтынга сатып алдың лабаса, — диде. — Хәзер дә мең тәңкәлек иде, дип әйтәсең!» — диде. Пыяла иясе әйтте: «Солтанның гомере озын булсын! Пыяла, уалмаган чагында, бер алтыннан артык түгел иде. Ләкин солтанның сөекле кешесе ваткан өчен, мең тәңкәдән ким хисапламаймын», — диде. Андан соң солтан әмер итте, мең тәңкә биреп җибәрделәр.

Инде, әй угыл, ушандак мөэмин бәндәнең калебе пыяла шикелледер: кайчан ки Аллаһы Тәгалә сүзенең угы вә Рәсүлуллаһ сүзенең угы белән мәнсез булганнан соң, мөэмин бәндә, тәзәррыг кыйлып, Аллаһы Тәгаләнең йортына *«вә иннәл мәсәҗид лилләһ»* килсә, Аллаһы Тәгалә әйтер: «Әй бәндәм, ни сорарсың, ни хаҗәтең бар?» Мөэмин бәндә әйтер: «Илаһи, мәнсез булмыш вә сынык күңелемнең кыйммәтен сорармын», — дияр. Аллаһы Тәгалә әйтер: «Синең калебең бер тамчы кандыр, аның ни кыйммәте булсын?» Бәндә әйтер: «Илаһи, растыр, ләкин дустыңның сүзе күңелемне сындырды. Инде солтан Мәхмүд заманыннан ким аласым килмәйдер» — дияр. Бәс, Аллаһы Тәгалә әйтер: «Әй бәндәм, калебеңнең инде кыйммәтен әйттең, сынык күңелләләрне мин яратамын».

———

Кыш суыклары үтте. Яз булды. Аллаһы Тәгалә яз көнендә галәмгә рәхмәт нәзары белән нәзар кыйлды. Аллаһы Тәгаләнең рәхмәт әсәрләре белән, җир йөзе мөзәйян[1] булды. *Фәнзуру илә әсәри рахмәтилләһи кәйфә юхъйил әрза бәгъдә мәүтиһә.* Әүвәл сары гөл чыкты. Карадык: хуш исе юк. Аннан соң ак гөл чыкты. Аның да хуш исе бик аз. Аннан соң нәфис кызыл гөл чыкты. Кямил хуш исле булып чыкты, халык моның белән мөзәйян булды; бакча мөзәйян булды. Һәркем, кулына алып, борынына куеп иснәделәр. Ул әнваг чәчәк вә гөлләр белән бөтен җир йөзе мөзәйян булып, хуш исле гөлләр бакчаларны, сахраларны вә күңелләрне хуш исле кыйлды. Әнваг сайрар кошлар вә былбыллар, вә җәмигъ мәхлукат вә адәми зат тамаша вә шатлыкта иделәр. Кайчан ки ул хуш исле гөлләрнең кибү вакыты җитте, бәс, ул гөлләрдән бәни адәмгә мирас хуш исле сулар вә хуш исле майлары гына калды.

---

[1] **Мөзәйян** — зиннәтле.

Аннан соң адәм углы-кызы, көз көнендә, кыш көнендә яз галәмәте тапмак өчен, гөлнең мирасын истигъмаль кыйлдылар, ягъни хушбуй иснәделәр вә киемнәрен вә йортларын хушбуй белән мөгаттар кыйлдылар. Инде, әй угыл, син бу хосуста яз көне кыйссасына игътибар кыйлма, — бу бер мәсәлдер. Ләкин яз көнен иҗат кыйлгучы Аллаһы Тәгаләнең сангына вә кодрәтенә игътибар кыйл. Ягъни яз көнен бәян кыйлудан хисса будыр ки: сары гөл Муса галәйһиссәламнең иде. Күрмәймесең ки: яһүд таифәсенең галәмәте сарыдыр. Ак гөл Гайсә галәйһиссәламнең иде. Күрмәймесең ки, хәвариюн таифәсе китән агартучылар иде. Аннан соң шәригате исламның кызыл гөле зоһур итте ки, Мөхәммәд галәйһиссәламдер: бәс, бөтен дөнья ул шәригать гөле белән рәушан булды. Вә аның бәрәкәте белән галәм мөгаттар булды. Шәрыккә вә Гаребкә күчү вакыты иреште, мәңге үзеннән соң киләчәк өммәтенә кыяматкәчә зиннәтләнмәк вә шәрәфәтләнмәк өчен, Коръән Кәрим вә хәдис шәрифләр мирас калдырды. *Суммә әураснәл-ләзинәстафәйнәһү мин гыйбәдинә. Бәллигу ганна вә ләү бикәлимәтин*, диде.

---

Көннәрдән бер көн бер падишаһ, сараеның чардагыннан мәйданга җыелган халыкны карап, тамаша вә тәфәррең кыйлып торыр иде. Вә халкы дәхи — олуг вә кечек, бай вә фәкыйрь — һәммәсе җыелып, падишаһны карап торырлар иде. Бәс, падишаһ, ул халыкка җәваһир нисяр итмәгә арзу кыйлып, бер капчык җәваһир китереп, халык өстенә сачты. Җефәк вә атлас кигән адәмнәр өстенә җәваһир иреште. Ләкин җефәк вә атласлар өстендә карарланмады, шуып төште. Ертык һәм садә вә тупас киемнәр өстенә һәм җәваһир иреште. Киемнәре җуан вә ертыклыгы өчен, төрлесенә төрле санда җәваһир ябышып калды.

Инде, әй угыл, монда максуд улдыр ки: Адәм галәйһиссәламнең кыйссасы һәм ошбу кыйссага охшар. Ушандак, Аллаһы Тәгалә галәм хосуста нәзар кылучылар өстенә ирештермәк өчен, үзенә кодрәте мәңгелек сарае өстеннән хәлифәлек җәүһәрен сачты, *нәхну нусәббиху бихәмдикә вә нукаддису ләк* хөлләләрен кимешләр иде. Киемнәре тагать ыруы белән ялтыраткан вә ялтырамыш иде. Алар өстенә хәлифәлек җәүһәре иреште. Әмма ябышмады, шуып төште. Әмма Адәм галәйһиссәлам золым, наданлык киеме кимеш иде. Киеменең тупаслыгы сәбәпле, күнеле сынык иде. Бәс, Адәм галәйһиссәламгә хәлифәлек җәүһәре иреште. Вә золумән-җәһүлән киеменә ябышты. Аны *«җәгалә фил әрзый хәлифә»* таҗы белән таҗлады.

---

Вә дәхи әй угыл, ушандак минбәрдә вәгазь әйтүче галимнәр вә вагыйзлар ошбу мәшһүр падишаһ охшашлыдыр: ул падишаһ сарай өстенә ашкан шикелле, вагыйзә һәм минбәргә аш-

ты. Капчыгыннан энҗеләрне вә җәүһәрләрне өстегезгә сачты. Тәкәбберлек белән, монафикълык белән, хыянәт белән вә кинә белән мәшгуль булганнарның калебләренә ул хикмәт энҗеләре вә вәгазь җәүһәрләре ирешге. Әмма карарланмады[1], шуып китте. Ягъни калебләрегезгә иблис үрмәкүче оялаганлык сәбәпле, вәгазь әсәр итмәде. Әмма төзеклек вә тәвазыйглык белән сынык күңелләрегезгә ул энҗеләр карарланыр булды. *Фәзәккир фәиннәз-зикри тәнфәгуль-мөэминин.*

———

Адәм галәйһиссәлам һәм гөнаһ эшләде, иблис һәм гөнаһ эшләде. Адәм галәйһиссәламнең тәүбәсе кабул булды, иблиснең тәүбәсе ни өчен кабул булмады? Җавап: инде, әй угыл, бу сөаленә җавап булырга лаек хикәят бар иде. Син ул хикәятне ишеткәнең юк булса кирәк.

Көннәрдән бер көн бер падишаһка сатарга ике кол китерделәр. Ул колларның берсе нәфис җефәк-атлас киемнәр кигән иде, мөзәйян иде. Икенчесе начар гына иске ертык кием кигән иде. Бу колларны падишаһка гарыз кыйлдылар. Бәс, падишаһ ул иске киемле колны сатып алды. Җефәк кием кигәнен кайтарып җибәрде: «Бу кол кирәкмәс», — диде. Падишаһның вәзире әйтте: «Әй падишаһ, бу колларның нәфис кигәнен кабул итмәдең, иске, алама кигәнен кабул иттең, аның ни күркәмлеге бар? Бер кыяфәтсез нәрсәдер», — диде. Падишаһ әйтте: «Әй вәзир, син бу колларның икесен дә чишендер. Киемнәрен салдыр: ялангач булсыннар. Мин сиңа күрсәтермен һәм әйтермен, ни өчен кабул итмәгәнмен», — диде. Бәс, вәзир икесен дә чишендерде. Күрде ки: нәфис җефәк кием кигән колның тәне кутыр да чакыр; тәне сасы, якын барыр хәл юк. Әмма иске кием кигәненең тәне — шалкан кебек: пакь, ләтыйф, хушбуй чыгып торыр. Бәс, падишаһ әйтте: «Мин бу колны кабул иттем: тәне саф, ләтыйф вә табигатькә мәкрүһ нәрсәсе юктыр. Ул нәфис кигәненең тәне зәхмәтле вә сасыдыр», — диде.

Инде, әй угыл, бу кыйссадан хисса шулдыр ки: Адәмнең вә иблиснең хәле һәм ушандактыр ки, Адәм белән иблис — икесе ике галәм иделәр. Хак Тәгалә хәзрәтенә гарыз кыйлындылар. Иблис — тагать кыйлгучылар җөмләсеннән булып, фәрештәләр белән бергә, «*нәхи нәсбәх вә хамдикә*» дип, тәкәбберлек киемен кигән иде. Вә Адәм тәвазыйглык габәсен кимеш иде. Тәвазыйглык өчен Аллаһы Тәгалә аның тәүбәсен кабул итте. Тәкәбберлек киемен кигән өчен, иблиснең тәүбәсен рәд кыйлды. Аллаһы Тәгалә калебе пакьне сайлады. *Иннә Аллаһәсътафә Адәм.* Кайчан ки иблистән тәкәбберлек кияме салдырылды, күкрәгендә көнчелек кутырлары заһир булды. Авызын-

———

[1] Карарланмады — ябышып калмады.

нан, *«әнә хайрун минһә»* дип, тәкәбберлек исе килә башлады. Шул сәбәпле кыяматкәчә Адәм угланларының дошманыдыр. Адәм галәйһиссәлам *«Раббәнә заләмнә әнфусинә»* дигәч, тыныннан тәвазыйглык гатыры зоһүр итеп, авызыннан тәүбә исе чыкты. Шуның өчен, шиксез, Аллаһы Тәгалә аның тәүбәсен кабул итте. Вә һидаять киеме кидерде. Вә иблиснең муенына *вә иннә галәйкәл ләгънәту илә йәүмиддин* камытын кидерде.

———

Әгәр дә йомырканы инә белән тишеп, эчендәге агын вә сарысын агызып, йомырканы чык суы белән тутырып, тишеген балавыз белән нык ябыштырсаң, кояш чыкмас борын биек җиргә, мәшрикъка таба каратып бер тас өстенә куйсаң, кояш чыккач, ул йомырка акрын-акрын һавага күтәрелеп китәр. Әй угыл, син һәм шуның шикелле, нәфесеңне тиш риазәт инәсе белән; бәдәнеңнән акны, сарыны чыгар ки, ул — рия вә нифактыр[1]. Күз яшеңне тутыр. Сәхәрдән тор. Тәһәҗҗед намазыңны укы. Мәсҗет тасына куй. Кайчан ки өстеңә гыйнаять әзәлия кояшы чыгып, мәләкүт кодсия түбәсенә күтәрелсә, һич гаҗәп юк. *Иләйһи йәсъгадүл кәлимүт-тайиби вәл гамәлүс-салиху йәрфәгуһ.*

Белгел ки, әй угыл, кайчы дигән нәрсә икейөзледер вә ике ирене бар. Шуның өчен аның бугазына кадак сугалар. Кайчының һөнәре кисмәк вә киметмәктер. Әгәр киеменне кайчы авызына бөтене белән куйсаң да, киемеңне тәмам кисеп чыгарыр. Әмма кайчының бугазыннан һичнәрсә килмәс.

Инде, әй угыл, бу хикәяттә максуд түгелдер ки, кайчының гамәлен бәян кыйлмак; мәгәр кяферләр хәлен бәяндыр. Мәсәлән, ул моганидлар[2] авызларына кяфер кайчысын каптылар. Бугазларына һәм, әлбәттә, кяфер кадагы кагылмыштыр. *Суммүм букмун гумйүн фәһүм ля ягъкыйлүн.* Кайчан ки авызларына дәгъват Раббания атласын куйдылар, *мә һәзә иллә әсәтыйрул-әүвәлин* кайчысы белән кистеләр. Бугазларыннан һичнәрсә чыкмады. Бәс, игътибар ит, и угыл.

———

Әй угыл! Һиндстанда бер үлән бардыр ки, фарсыча нәбат миһер кияһ, диләр. Ягъни мәхәббәт үләне, гавам халкын сөйдергеч үләне, диләр. Әмма бу үләнне көндез һичкем эзләп таба алмай. Мәгәр төнлә генә эзләп табалар, имеш. Бу үләннең хасияте шулдыр ки: кем дә кем бу үләнне үзе белән асыраса, ул кешене кем күрсә дә, сөйми калмас. Инде, әй угыл, һәрбер күргән кеше мине яратсын, дип, ул үләнне хасыйл итмәк өчен, Һиндстанга сәфәр кыйлмакчы булсаң, юк, бара алмассың: бик ерак. Инде кич Һиндстанына сәфәр кыйл. Ике рәкәгать намаз

---

[1] Нифактыр — икейөзлелектер, әшәкелектер.
[2] Моганидлар — үзсүзләләр, дошманлык күрсәтүчеләр.

васитасы белән *фәтәҗзибү нәфиләтүн ләкә* үләнен хуҗаңнан сора. Шуның иртәгесен, һәрбер күргән кеше сине сәвә башлар. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: *«Мин кәссәрас-саләтә билләйл хәсүнә вәҗһүһү бин-нәһәр»*.

———

Көннәрдән бер көн хәзрәти Гомәр разыйаллаһу ганһу Мәдинәнең әтрафында бер егеткә каршы очрады. Егетнең итәге астында бер нәрсә бар иде. Гомәр разыйаллаһу ганһу әйтте: «Әй егет, итәгең астында ни-нәрсә бар?» — диде. Әмма итәге астында бер шешә белән хәмер иде. Бу егет хәмер дип әйтмәгә бик оялды. Күңелдән әйтте: «Йа Аллаһ, әгәр Гомәрнең каршында мине оялтмасаң, вә фазыйхәткә төшермәсәң, вә аның каршында гаебемне капласаң, әбәдән хәмер эчмәс идем», — диде. «Йә әмирел мөэминин, итәгем астында серкәдер», — диде. Гомәр әйтте: «Кайда, күрсәтче, серкә микән?» — диде. Егет итәге астыннан хәмер шешәсен чыгарды, хәзрәти Гомәргә бирде. Хәзрәти Гомәр күрде: чыннан да, серкә, имеш. Ягъни шул хәлдә хәмер серкәгә монкалиб булды. Бу кыйссадан хисса будыр ки, әй угыл: Аллаһы Тәгаләдән курык. Күрмәдеңме, бер мәхлук Гомәр разыйаллаһу ганһу алдында тәүбә кыйлды. Гомәр үзе дә мәхлуктыр. Гомәрдән курку белән, Аллаһы Тәгалә ул кешенең хәмерен серкәгә әверде. Инде бер гөнаһлы, әшәке, гөнаһ шешәсен калебеннән чыгарып, үзенең явыз гамәлләреннән носух тәүбәсе белән тәүбә итсә, вә кыйлган гөнаһысына үкенеп тәзаррегъ кыйлса, Аллаһы Тәгаләгә һич тә мөшкел эш түгелдер. *Фәуләикә бәддәләллаһү сәййи-әтиһим хәсинәһ.*

———

Йосыф галәйһиссәламгә гашыйк булып, Зөләйха күп егълады. Озак заман кавышуга ирешмәде, алданды. Мисыр хатыннары Зөләйхадан көлделәр. Кайчан ки үзләре Йосыф галәйһиссәламнең җәмалын күрделәр, үзләрен оныттылар. Йосыф галәйһиссәламнең җәмалына хәйран булдылар. Алманы турыймыз дип, пычак белән кулларын турадылар, сизмәделәр. Зөләйха ул заман алардан көлеп торды.

Моннан хисса будыр ки, әй угыл: ушандак дөньяда мөэминнәр Аллаһы Тәгаләдән куркып егъларлар, дивана вә мәҗнүн сыйфат булырлар. Кяферлар һәм мөшрикләр мөэминнәрне бу сыйфатта күреп, тәгълимсез дип, көлеп торырлар. Һичшиксез, алар дәхи кыямәт көнендә тәмуг газабыннан куркып егъларлар. Мөэминнәр оҗмахта алардан көлеп торырлар. *Фәл яумел зин әманда минәл көффар язхикун.*

———

Белгел ки, әй угыл, Аллаһы Тәгаләдән пәйгамбәрләрдән өч пәйгамбәргә күлмәк кидерелде, шул күлмәкләр эчендә иминлек таптылар.

Берсе Ибраһимга иде. Кайчан ки Нәмруд ләгыйнь Ибраһим галәйһиссәламне караңгы зинданга салмага әмер кыйлды, һәм салдылар, Ибраһим галәйһиссәламгә һич зарар ирешмәде. Нәмрудка хәбәр бирделәр, Нәмруд әйтте: «Алай булса, утка атыңыз», — диде. Бәс, ут ягып, Ибраһим галәйһиссәламне мөнҗәникъка[1] куйдылар, утка аттылар. Утка житмәс борын дәрхаль Җәбраил галәйһиссәлам килеп иреште, әйтте: «Йә Ибраһим, ни хажәтең бардыр, сора», — диде. Ибраһим галәйһиссәлам әйтте: «Миндә ни хажәтең бар, дисең, синдә бер хажәтем дә юк», — диде. Шул сәгатьтә Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәлам өстенә күлмәк кидерде. Бәс, Ибраһим галәйһиссәлам утка барып төште, мәзкүр күлмәктән бер ис чыгып, бу күлмәк шәрәфәтендә утның эсселеген сүндерде. *Йә нәру, куни бәрдән вә сәләмән галя Ибраһим.*

Инде, әй угыл, кыямәт көнендә мөэминнәрнең хәле һәм ушандактыр. Кайчан кем, *вә әннә минкүм иллә вәридүһә,* моктазасынча, мөэминнәрне тәмугка сөрсәләр, өсләрендә тәүхид киеме вә тәкъва күлмәге булса, тәүхид киеменнән бер ис чыгып, утка ирешкән заман ут сүнәр, салкынланыр, мөэминнән качар, әйтер: «Йә мөэмин, үт тизрәк, утымны сүндерден», — дияр.

Икенче — Һарун галәйһиссәламгә Аллаһы Тәгалә ушандак күлмәк кидерде. Кыйссасы ошбудыр: кайчан ки Муса галәйһиссәлам Фиргавенне исламга дәгъвәт кыйлды, карендәше Һарун белән бергә иде. Фиргавен сорады: «Йә Муса, бу кемендер?» — диде. Муса галәйһиссәлам әйтте: «Бу — бер тугма карендәшемдер», — диде. Һарун — хәсән вә җәмал иясе, күркәм кеше иде. Бәс, Фиргавен әмер кыйлды: Һарун өстеннән киемен салдырдылар. Муса галәйһиссәламнең таягын кулыннан алдылар. Боларны сукмага әмер булды. Шул заман Җәбраил галәйһиссәлам иреште, оҗмахтан бер күлмәк китерде. Һарун өстенә кидерде. Бу күлмәкнең унике әдәбе бар иде. Һәрбер әдәпкә Бәни Исраилның унике сабтыннан[2] бер сабтның исеме язылмыш иде. Фиргавен бу күлмәкне күргәч әйтте: «Йә Һарун, бу күлмәк сиңа кайдан килде?» Һарун әйтте: «Аллаһы Тәгалә оҗмахтан китерде», — диде. Аннан соң куркудан Фиргавеннең әгъзасын калтыравык тотты. Бәс, ошбу күлмәк Мусаның вә Һарунның хәласына сәбәп булды. Моннан соң Фиргавен Муса вә Һарун үзәренә галәбә кыла алмады.

Инде, әй угыл, бу кыйссадан фәһем ит: «Муса вә Һарун галәйһиссәлам, хәзрәти Җәбраил оҗмахтан китергән күлмәк сәбәпле, Фиргавеннән имин булдылар. Вә Фиргавеннең вә кауменең күңелләренә курку төште. Инде, мөэминнәр, тәкъва кие-

---

[1] Мөнҗәникъ — борынгы заман сугыш коралы.
[2] Сабтыннан — өлешеннән.

ме сәбәпле вә иман күлмәге сәбәпле, тәмугтан имин булып, ут алардан качса, ут: «Йә мөэмин, тизрәк үт, утымны сүндерден», — дисә, һич гаҗәпләнмә.

Өченче — пәйгамбәр галәйһиссәлам күлмәгедер. Монын кыйссасы будыр ки: бер мөшрикә хатын үзенең углын пәйгамбәр галәйһиссәламгә җибәрде вә әйтте: «Бар, Мөхәммәдкә әйт, анам фәкыйрә вә ялангачтыр, синнән күлмәк сорады, диген. Әгәр Мөхәммәд, күлмәгем юк, дип әйтсә, син әйт, өстендәге күлмәгеңне салып бир, дип әйт», — диде.

Бәс, углан пәйгамбәр галәйһиссәламгә килде. Анасы өйрәтүе буенча пәйгамбәр галәйһиссәламнән күлмәк сорады. Бәс, пәйгамбәр галәйһиссәлам үзенең мөбарәк тәненнән күлмәген салып, бу угланга биреп җибәрде, ялангач калды. Михрабта[1] торып мөнәҗәт кыйлды. Ул углан пәйгамбәр галәйһиссәлам яныннан китмәгән иде. Дәрхаль, Җәбраил галәйһиссәлам инде, оҗмахтан бер күлмәк китереп, пәйгамбәр галәйһиссәлам тәненә кидерде. *«Вә лә тәҗгаль ядәкә мәгълүләтән илә гунукыйкә вә лә тәбсутъ фәтәкъгудә мәлумән мәхсура»* аяте бу вакытта назил булды. Аннан соң бу углан анасы янына кайтып вакыйганы сөйләде. Ул хатын барча кавем вә кабиләсе белән мөселман булдылар, пәйгамбәр галәйһиссәламнең күлмәге бәрәкәтендә.

Инде, әй угыл, Аллаһы Тәгалә әйтсә кирәк ки: «Әй Мөхәммәд өммәте! Мин сезләргә иман күлмәге бирдем. Вә тәкъва вә мәгърифәт киеме кидердем. Хәлбуки сез аларны һәва вә шәһвәт былчырагы белән былчыраттыгыз. Вә гөнаһ нәҗесе белән нәҗесләдегез. Әгәр гафу сорасаңыз, мин аларны, сезнең күз яшегез белән юып, пакьләмәгә кадирмын», — дисә кирәк. *Иннәллаһә ягъфируз зунубә җәмиган иннәһү һувәл гафурур-рахим.*

---

Көннәрдән бер көн Муса галәйһиссәламнең кауме Муса галәйһиссәламнән ягъмур сорадылар. Муса галәйһиссәлам әйтте: «Яхшы. Әйдәгез минем белән истиска намазына[2] чыгыгыз», — диде. Аларның бәгъзеләре — нифаклык чыктылар. Ягъни ихлас белән түгел иде. Дога кыйлдылар. Аллаһы Тәгалә аларга ягъмур бирде. Сачкән игеннәре яхшы үсте, ләкин игеннәренең башагы булмады. Коры салам гына үсте. Муса галәйһиссәлам мөнәҗәт кыйлды: «Илаһи, монда ни хикмәт бардыр?» — диде.

Бәс, Аллаһы Тәгаләдән нида килде, әйтте: «Йә Муса! Аларның догасы ихлас белән булмады. Шуның өчен игеннәренә бәрәкәт индермәдем», — диде.

---

[1] Михрабта — мәчетләрнең мулла намаз укыр өчен аерым эшләнгән урынында.

[2] Истиска намазы — янгыр намазы вә догасы.

Инде, әй угыл, моннан мәгълүм булды ки: мөэминнәр Аллаһы Тәгаләдән ихлас белән дога кыйлып сорасыннар.

---

Көннәрдән бер көн бер шәһәрнең олуг хуҗаларыннан бер адәм караңгы кич ут яндырып, фонарь белән бер мәхәллә арасыннан узды. Бу мәхәлләдә бер карчык хатын бар иде. Шул вакытта намазга торды. Ләкин кыйбла кайда таба икәнен белмәде, чөнки караңгы иде. Шул вакыт мәзкүр хуҗаның алдан фонарь күтәреп баручы кешесе килеп җитте. Карчыкның өенә тәрәзәсеннән якты төште. Карчык өеннән йөгереп чыкты: «Тукта, сабыр итә күреңез: ут яндырып алыйм!» — диде. Туктадылар. Карчык, ут алып, өенә керде. Намазын укыды. Хуҗасының фонаре сәбәпле, ут яндырып, киемен ямады.

Инде бу кыйссадан максуд ни-нәрсәдер? Әй угыл, мин сиңа бәян кыйлаем: галимнәр — шул фонарь күтәреп баручы кеше кебидер. Пәйгамбәр алдыннан шәригать фонарен күтәреп бардылар. Алар синең гомереңмәхәлләсеннән узадыр. Син, шул карчык хатын шикелле, шәһвәт караңгылыгында калып, гамәл кыйблаңны җуйдың. Инде сәгадәт кыйбласын тапмак теләсәң, сөннәт фонареннан калебеңнең чырагын яндырып ал, күңелең өе яктырып, тәүбә кыйбласын табарсың. Вә ул чыраг яктысында дөньяның ертыгын ямарсың вә ким җирләрен тутырырсың. *Тәзкиратүл голәмәә һидәятүл-җөһаләә.*

---

Әгәр сәфәрдән килүче адәмнәрдән хак сүзле бер адәм әйтсә ки: «Ошбу юлда куркынычлар бар: бик хәвефле ерткыч хайваннар, бүреләр бар», — дисә, син ул юлдан китмәссең, син ул һәлакәттән куркырсың. Вә ул юлны куеп, иминрәк юлны карарсың. Янә аннан соң икенче бер ялганчы кеше килеп әйтсә: «Бу юл — бик имин: һич тә хәвеф-хәтәр юк дисә, син әйтерсең, бер кеше бик хәвефле, дип хәбәр биргән иде лә», — дип әйтерсең. Ул кеше янә әйтсә: «Юк, ул кеше сиңа ялган хәбәр биргәндер. Бу юлда һич хәвеф-хәтәр юк. Ерткыч хайваннар юк. Бик имин юл», — дисә, син, бу ялганчының сүзенә ышанып, ул юлдан китсәң һәм анда һәлак булсаң, моның гөнаһысы шул имин, дип хәбәр биргән кешегә булыр.

Инде бу мәсәлдән максуд budyр ки, әй угыл, пәйгамбәрләр, вә әүлиялар, вә галимнәр сиңа хәбәр бирделәр ки: «Мәгыйшәт юлы һәлакледер: күп хәтәрләр бар, ерткычлар бар», — диделәр. Аннан соң шайтан мәлгунь килде дә, нәфсеңә муафыйк нәрсәләр күрсәтеп: «Сиңа бу гөнаһ юлы — бик имин, бик рәхәт, һичнәрсә юк» — дип, сине алдады. *Зүйинә лин-нәси хүббүш-шәһәвәти минән-нисаэи вәл-бәнин.* Шайтан сүзен ишеткәч, син шайтанга ышанып, гөнаһ юлына сәфәр кыйлдың. Гамәлең комашлары анда заигъ булды, һәлаккә төштең. *Вә кадимен илә мә гамилу мин гамәлин фәҗәгальнәһү һәбәәәм-мәнсура.*

Көннәрдән бер көн бер адәм Госманлы мәмләкәтеннән Һиндстанга сәфәр кыйлды. Һиндстан шәһәрләреннән бер шәһәргә барып керде. Мөсафирлар гадәтенчә, сәфәрдән килгәч, хәммамга кермәкне ирадә кыйлып, хәммамнардан бер хәммамга килде. Күрде: хәммамчы — бер яхшы гына кеше, имеш, ишек нәүбәтендә утырыр. Бәс, бу мөсафир хәммамчыга акча бирде, юынырга тас сорады. Хәммамчы бу кешенең алдына ике агач башмак куйды, өстенә киздән тегелмеш кием кидерде. Башына киез бүрек кидерде. Йөзен сөртергә бер тастымал бирде. Кулына бagларга бер беләзек бирде. Ике башлы сөңге бирде. Бу мөсафир әйтте: «Бу эш гадәткә хилафтыр. Монда ни хикмәт бар?» — диде. Хәммамчы әйтте: «Хәммамның урта ишегендә балчыклыдыр, былчырактыр, бу башмакны аягың балчыкка батмасын өчен киярсең. Дәхи хәммамның түшәме тигәнәкле безнең. Башына тигәнәк кадалмасын өчен, киез бүрекне башыңа киярсең. Дәхи безнең хәммамда чебен, озынборын, черки күп. Алардан имин булыр өчен тастымал бирдем, йөзеңә бөркәнерсең. Дәхи хәммамда бер олуг ерткыч бардыр. Әгәр сиңа хамлә кыйлса, бу сөңге белән үзеңне химая кыйлырсың», — диде. Мөсафир әйтте: «Сөбханаллаһи, бу — җәһәннәм галәмәтедер, хәммам түгелдер», — диде. Инде бу кыйссадан хисса ни-нәрсәдер, әй угыл, беләмсең?

Мондан хисса будыр ки: әй угыл, син — бер мөсафирсың, әрвахлар гаскәре белән бергә җыелып, Төркстан вилаятеннән бу дөнья мазаргяһына сәфәр кыйлдың. Сиңа да *минһә халәкънәкүм, вә фиһә нүгыйдүкүм вә минһә нүхъриҗүкүм* хәммамына кермәгә хаҗәт булыр. Бу хәммамның иясе Мөхәммәд галәйһиссәламдер. Инде бу кабер хаммамында һәлакәттән имин булмакны теләсәң, ул сиңа *вәмсәху бируъусикүм* бүреген бирде. Аны башыңа киярсең. *Фагъсилү вүҗүһәкүм* тастымалын бирде. Аның белән йөзеңне сөртерсең. Вә кулыңа, баглар өчен, таһарәт беләзеке ки, *вә әйдикүм иләл мәрафикъ* беләзекен бирде, аны кулыңа бagларсың. Вә госел вә мәсих башмагы ки, *вә әрҗүләкүм иләл кәгъбәин* дер, аягыңа аны киярсең. Вә өстеңә дәхи *вә ришән вә либәсүт-тәкъва* чикмәне бирде, аны киярсең. Вә дәхи ике башлы сөңге ки, *лә хауля вә ля куәтә иллә биллаһил галийел газыйм* сөңгеседер, аны кулыңа тотарсың.

Кайчан кем кабер хәммамына барып керсәң, бәхетсезлек төкәнлеге башыңны чәнечмәс. Газап балчыгына аягың батмас. Кабер чебеннәре тәнеңне ашамас. Ике башлы *ля хәүля вә ля куәтә* сөңгесе белән, әшәдд[1] дошманың ки, иблис мәлгуньдер, үтерерсең. Мәгъсыять сәфәрендә керләнгән вә нәҗәсәтләнгән

[1] Әшәдд — иң көчле.

тәненне шул өч тастан ки, Аллаһы Раббы, Мөхәммәд нәбиәлисламдине тасларыдыр, жуарсың. Вә кабер хәммамыннан чыккан вакытында, җефәк вә хөллә киеп, Аллаһы Тәгаләнең мәгъфирәтенә вә дидарга салахиятле булырсың. *Фәтубәләк әййүһәл* угыл.

———

Көннәрдән бер көн Шам вилаятеннән бер адәм сәфәр кыйлды. Бер сахрада барганда, күп тәвә көтүе күрде. Көтү арасыннан бер котырган тәвә бу кешегә касд кыйлды. Бу кеше качар җир тапмагач, анда бер кое бар иде, үзен шул коега атты. Коеда бер агач үскән, имеш, ул агачның ботагына тотынды. Кое бик тирән иде. Коеның төбенә карады. Коеның төбендә бер олуг аждаһа ятыр! Дәхи күрде: ике сычкан агачның тамырына ябышып кыралар. Бу кеше агач ботагына ябышып карап тора. Һич хәлас мөмкин түгел.

Мәгәр бу кешенең бер шәехе бар, имеш, аны зикер кыйлып, мәдәт сорады. Шәех кәрамәт иясе бер адәм иде. Дәрхаль ул шәех хәзер булып, кое төбендәге аждаһаны дәфгы кыйлды. Вә ул шәехнең догасы бәрәкәтендә әнваг чәчәк вә нәбатат зоһур итте. Ахыр ул ике сычкан агачның тамырларын кырдылар: агач егылды. Бу кеше һәм агач ботагыннан ычкынып китте: «Йа Аллаһы, аждаһа авызына төштем!» — дип торганда, күзен ачып карады, күрде: кое төбе әнваг нәбатат вә чәчәк белән тулыдыр. Инде монда бу кеше хикәяте максуд түгелдер.

Бәлки, моннан хисса шулдыр ки, әй угыл: синең хәлең, минем хәлем һәм ушандактыр. Инде котырган тәвә дигәнемез — үлемдер. Дөнья сахрасында синең артыңнан ияреп йөрер. Син ул үлемнән гомерең коесына качтың, горурлык агачына ябыштың. Ике сычкан дигәнемез хирыслык белән түл әмәлеңдер, ул горурлык агачының тамырын кыралар. Бу гомерең коесында мәгъсыять аждаһасы бар. Син һавада асылынып торасың. Бер кулың белән хәвеф агачының ботагына ябышкансың. Икенче кулың белән рижа[1] агачының ботагын тоткансың. Кулың кайсыннан ычкынып, кайсы якта каласың, мәгълүм түгел. Бик хәтәрдә торасың. Инде бу куркынычлардан хәлас өмет итсәң, әлбәттә, үзеңнең хуҗаңны ки, Аллаһы Тәгаләдер, зикер итсәң кирәк; *Раббәнә гъфирләнә зүнубәнә вә кәффир ганнә сәййи-этинә вә тәвәффәнә мәгал-әбрар*, дип, гозер итеп мөнәҗәт кылсаң кирәк. Аннан соң Аллаһы Тәгалә сиңа рәхмәтен дә җибәрер, мәгъсыять аждаһасын һәм дәфгы кыйлыр. Вә кабереңне нур чәчәге белән тутырып, оҗмах бакчаларыннан бер бакча итәр.

———

Дөнья сараенда бер шәһәр бардыр. Ул шәһәрнең гадәте будыр ки: кайчан падишаһларының кызы бәлягатькә җитсә,

---

[1] Рижа — өмет.

бер хәбәрче нида кыйлыр, шәһәр халкы һәммәсе — олугысы вә кечесе сахрага чыгарлар; падишаһның кызын һәм чыгарырлар. Кызның атасы-анасы кызның кулына бер алтын алма бирерләр. Ул кызның кемгә күңеле төшсә, алтын алма белән шул кешегә атар. Аннан соң кызны шул кешегә никяхланырлар иде.

Бәс, бу шәһәрдә бер олуг падишаһ бар иде. Күршесендә бер фәкыйрь генә гүзәл егет бар иде. Көннәрдән бер көн падишаһның кызы кәмаләткә җитеп, шул егеткә мәхәббәте төште. Гыйшкыннан йөзе саргайды. Әмма һичкемгә бу серен әйтмәде. Бәс, падишаһ кызына кияү сайламак нияте белән нида кыйлдырды: «Фәлән көн шәһәрдә берәү дә калмасын: сахрага чыксыннар! Мәликә үзенә лаек кешене сайласын», — диделәр. Падишаһ балалары, әмирләр, вә олуглар, вә байлар, нәфис киемнәр киеп, зиннәтләнеп чыктылар. Падишаһ балалары, әмирләр вә байлар — һәркайсы: «Бу кыз алтын алманы минем өстемә ташлый микән?» — дип көтеп тордылар.

Падишаһның кызы һәр тарафтан карап йөрде, баягы фәкыйрь егетне күрмәде, һичкем өстенә алтын алманы ташламады, шәһәргә кайтты. Халык үзара: «Бу көн падишаһ кызы берәүне дә ошатмады», — дип сөйләнеп торырлар иде. Икенче көн янә чыктылар. Кыз егетне күрмәде. Янә кайтты. Шәһәр халкы: «Бу падишаһ кызының кияүгә бармага ирадәсе юк, имеш», — дип сөйләшә башладылар.

Өченче көн янә сахрага җыелмага әмер булды. Шәһәр халкы барчасы чыктылар. Ул фәкыйрь егет һәм чыкты. Күңеленнән әйтте: «Бәли, беләмен: падишаһ кызы миңа илтифат кыйлмас. Ләкин бер мәртәбә чыгып караем. Халыкны тамаша кыйлаем», — диде. Өстенә тапканын киеп чыкты. Халыктан ерак бер җиргә барып утырды. Бәс, падишаһ кызы чыгып, халыкның әтрафыннан әйләнеп йөрде, һаман егетне күрмәде. Халык арасыннан чыкты. Кайтып китмәгә ният итте. Ул арада егетне күрде. Халыктан ерак бер җиргә нәүмиз булып утырыр иде. Падишаһ кызы килде, алтын алманы аның өстенә ташлады. Әмирләр, байлар вә түрәләр оятка калып кайттылар. Кызның ата-анасы әйтте: «Ник болай иттең? Әмирләрнең вә олугларның балаларын калдырдың, бер фәкыйрь егет өстенә ташладың. Ул фәкыйрьнең һичнәрсәсе юктыр», — диделәр. Кыз әйтте: «Ул егет фәкыйрь булса, мин баймын. Мин аның өстенә алтын алма ташладым. Әмма ул минем өстемә хәсрәт алмасы ташлады», — диде.

Аннан соң кызны шул егеткә никяхландырдылар.

---

Аллаһы Тәгалә әйтте: «*Вәсигат рахмәти куллә шәйин* — Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте киндер, һәрнәрсәгә ирешәдер». Кайчан ки Аллаһы Тәгалә үзенең сангы[1] белән бөтен галәмне юк-

[1] Сангы — кодрәте, осталыгы.

тан бар итте вә һәрбер мәхлукатны үзенең хикмәте вә ирадәсе белән халык итте. Вә үзенең ирадәсенчә, җәмигъ мәхлукатка бер тәртип бирде. Җәмигъ барлык Аллаһы Тәгаләнең сәнгать сахрасында Аллаһы Тәгалә хозурында тәмәддех кыйлдылар». Кайсысы рәхмәт бәрәкәтендә Аллаһы Тәгаләгә якынлыкны истәделәр. Фәрештәләр: «Безгә нә рәхмәт булыр? *Нәхну нәсәббиху бихәмдикә вә нукаддису ләк»*, — дип тордылар. Кояш, дәхи Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен өмид итеп, үзенең нурын галәмгә сачты. Ай, үзенең икътидарынча бу рәхмәтне өмид итеп, галәмгә яктылык чыгарды. Күкләр, дәхи бу рәхмәтне өмид итеп, җир йөзенә ягъмур тамчыларын җибәрде вә игеннәр үстерде. Таглар, дәхи бу рәхмәткә мөштак булып, әнваг җәваһирларын индерде. Җир дәхи, бу рәхмәтне өмид итеп, әнваг нәбатат вә агачлар изһар кыйлдылар. Дәрьялар, дәхи бу рәхмәтне өмид итеп, сәдәфләрен, әнҗүләр изһар кыйлдылар. Хасыйле кәлям, һәрбер мәхлук «Иннә гаразнәл-әманәт алмасы, мина бирелмәенчә, кемгә бирелсен? Мин мөстәхакмын!» — дип дәгъва кыйлдылар. Адәм галәйһиссәлам, мәзкүр фәкыйрь егет кебек, золүмә-җәһүлә дивары артында башын тезенә куеп, ерактан нәүмиз булып карап торыр иде. Бәс, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте бөтен галәмне тәваф кыйлды, әмма әманәт алмасын мәхлукаттан һич берәү өстенә ташламага мәгъкуль күрмәде.

Ул рәхмәт, мәйдан мәләкүттән йөреп кайтканда күрде ки: Адәм галәйһиссәлам гаҗизлек дивары артында утырыр. «Мә, бу сиңа тиеш икән» — дип, әманәт алмасын Адәмгә бирде. Адәм кабул итте. Әманәт алмасыннан морад — намаздыр. Аннан соң мәхлукат арасында гауга чыкты. Фәрештәләр, күкләр, кояш, ай вә йолдызлар, таулар кычкырдылар. Вә фәрештәләр әйттеләр: «Йа Рабби! Һай, шул бер башы, аягы ялангач Адәмне бездән артык күрдең. *Вә нәхну нусәббиху бихәмдикә вә нукаддису ләк»*, — диделәр.

Бәс, Аллаһы Тәгаләдән нида иреште: «Әй фәрештәләрем! Мин аңа әманәт бирсәм, ул мина мәхәббәт бирер. Ул фәкыйрь булса, мин баймын, милексез падишаһмын. Аның өстендә тукылмыш кием булса да, аның эчендә миннән рух бардыр. *Фәизә истәвәйнә вә нәфәхту фиһә мин рухи.* Вә аның калебе вә ихласы миндәдер. Вә иманы бардыр. Бәс, сезнең араңыздан аны ихтыяр кыйлдым. Вә сездән аны әфзаль кыйлдым. Вә аның байрагын күтәрдем. Җәмигъ әсаманы аңа үгрәттем. Вә гөнаһсың ярлыкадым. Кыяматкәчә туачак балаларының һәм гөнаһларын ярлыкармын. *«Әнә иннәл-гафурур-рахим.* Вә кыямәт көнендә аны вә аның балаларын үземнең живаремдә кыйлырмын. *Фи мәкъгади сыйдкыйн гыйндә мәликин мөкътәдир»*, — диде.

———

Берәүгә суык тисә, томау зәхмәте пәйда буладыр. Аннан соң ул кешенең борыны һичбер исне сизмидер. Хуш истән

мәхрүм калыр. Ни эшләргә белмәй, ахыр бер табибка килеп, үзенең хәлен сөйләп, дару истәйдер. Аннан соң табиб, аны бер караңгы җиргә кереп, бераүгә әмер кыйладыр. Ул кеше бу томау зәхмәтле кешене егълаганчы орыша, сүгә, ачуланадыр. Егълагач вә ачулангач, ул кешенең тәнендә хәрәкәт хасыйл булып, тәненнән тир чыгадыр. Аннан соң ул кеше томау зәхмәтеннән хәлас буладыр.

Син ошбу томау зәхмәтле кеше кебексең, әй угыл! Мәгъсыять салкынлыгы сиңа әсәр итеп, мидә мәгъсыять томавы заһир булды. Гыйлем вә хикмәт исен сизмәйсең. Ул сәбәпле саваттан вә гыйлем ләззәтеннән мәхрүмсең. Мәгъсыять томавы белән мөбтәля булып, ни эшләргә белмәйсең. Инде бу зәхмәтне үзеңнән китәрәсең килсә, шәһвәт караңгылыгыннан чык. Дөнья гамәлен куй. Мәсҗеткә кил. Вагыйз табиб минбәргә чыкканчы, көтеп утыр. Аллаһы Тәгалә сүзләренең исе вә Рәсүлуллаһ сүзләренең исе борыныңа керсен, җисмеңдә эсселек пәйда булып, күз яшең белән калебең тирләсен. *Вә изә сәмигу мә үнзилә галәр-рәсули тәра агъюнәһүм тәфиду минәд-дәмгый.* Мәгъсыять томавы синдән заил булып, тагать исе борыныңа керер. Вә җәннәт әһеле булырсың. *Сәламүн галәйкүм тубтүм фәдхулүһә халидин.*

———

Бер йөкле хатын бер бай кешенең капкасы төбеннән узганда, борынына байның ашханәсеннән ит исе вә ләззәтле тәгамнар исе керсә, ул бай моннан хәбәрдар булса, аны чакырып, бер нәрсә тәгамыннан тәнавел кыйлдырадыр, таки ул хатынның йөгендәге баласына зәхмәт ирешмәсен өчен. Әй угыл, мөэмин бәндә һәм ушандактыр. Аллаһы Тәгаләнең әманәте белән, ягъни иман вә намаз белән йөкле. Аллаһы Тәгаләнең капкасы төбеннән үткәндә, ягъни мәсҗеткә кергәндә, Аллаһы Тәгаләнең миннәте вә кәраме ашханәсеннән борынына тагать исе керде. Инде Аллаһы Тәгаләнең фазлына лаек имәсме, үзенең мөэмин бәндәләренә оҗмах нигъмәтләрен тәнавел кыйлдырса? Бәли, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте киңдер, рузи кыйлыр, мөэмин бәндәләрдән моны кызганмас. *Иннәлләзинә әмәну вә гамилүс-салихәти кәнәтләһүм җәннәтүл фирдәүси нүзүлә.*

———

Бер хатын үзенең бер сабый баласына: «Бар, фәлән җирдән су алып кил», — дип, кулына бер чүлмәк бирде. Бу бала, чүлмәкне алып, суга китте. Юлда күрде: үзе шикелле берничә кечкенә балалар уен уйнарлар. Бу бала чүлмәген куйды да, балалар янына килеп, уеннарына катнашты. Суга баруны онытты. Кич булгач, янә буш булган чүлмәген күтәреп, анасы янына кайтты. Анасы әйтте: «Кайда, су алып килдеңме?» — дип. Чүлмәкне карады: чүлмәк буш. Аннан соң баласын орышырга тотынды. Баласы әйтте: «Әй ана! Су алып кайтмасам да, чүлмәк-

не бөтен алып кайттым. Ваткан булсам, нишләр идең? Аңар да шөкер ит әле», — диде. Анасы күңеленнән әйтте: «Углым раст әйтә: сабый баладыр», — дип гафу кыйлды.

Инде, әй угыл, син һәм бу бала шикеллесең. Аллаһы Тәгалә синең кулыңа иман чүлмәген тоттырды: «Әй бәндә, бу чүлмәкне гамәл суы белән тутыр», — дип әмер кыйлды. Син, баягы бала шикелле, дөнья уены белән мәшгуль булып *вә мә һәзәл хәятуд-дөнья иллә ләһвун вә ләгыйбун*. Кайда барганлыгыңны оныттың. Гыйбадәт чүлмәген гамәл суы белән тутырмадың. Кайчан кем гомереңнең көнә кичкә әйләнсә, әҗәл сәгате сукса, сиңа Аллаһы Тәгалә әйтер: «Йә бәндәм, гамәл суың кайда?». Мөэмин бәндә әйтер: «Илаһи, үземә үзем шөкер итәмен: әле дә иман чүлмәген сиңа бөтен китердем». Аллаһы Тәгалә гыйнаять нәзаре белән карар, күрер: бәндә — зәгыйфь, аннан ни алмак кирәк? Әйтер: «Бәндәм раст әйтә: *гуфирәт ләкум каблә эн тәстәгъфируни*», — дип гафу кыйлып, диванына мәгъфирәт язар.

———

Заман кадимдә бер вилаятьтә бер олуг күл бар иде. Ул күлдә ике каз, бер бака бик озак заманнар тереклек кыйлдылар. Өчесенең арасында дуслык пәйда булып, берберенә мөнис булдылар. Аннан соң, күп заманнар үтү сәбәпле, бу күлнең суы кими башлады. Суы аз калды. Ахыр күл тәмам кипмәгә кариб булды. Бу ике каз бака янына исәнләшергә килделәр вә бакадан бәхиллек үтенделәр. Әйттеләр: «Әй дус, бу зәбун дөньяның ахыры — фирактыр. Инде мәхлукатның тереклегенә сәбәп булган нәрсә — судыр. Күлнең суы кипте. «Сүрәэ Әнбия»-да: *«Вәҗәгальнә минәл мәъи күллә шәйэин хәй*. Судан башка безнең торыр хәлемез юктыр. Инде без икенче күлгә күчәмез. Ният иттек. Бәхил бул», — диделәр.

Бәс, бака бу казларның сүзен ишеткәч, егълады, кайгылы булды вә әйтте: «Әй шәфкатьле дусларым, мин һәм сезнең белән икенче күлгә сәфәр кыйлыр идем. Ни хәйлә кирәк? Вә сезнең белән булмага ни сәбәп кирәк?» — диде. Казлар әйттеләр: «Сине һәм үземез белән алып китәрмез. Ләкин куркамыз ки, син сөйләшерсең, чөнки бака җәмәгате телләренә малик түгелләрдер, ягъни бакылдамый тора алмыйлар». Бака әйтте: «Инде гаһед кыйлдым: аслан сөйләшмәсмен», — диде. Казлар әйттеләр: «Кайчан кем без синең белән очсак, адәмнәр күреп бик гаҗәпләнерләр, бер-берenә чакырып, безнең очмакымызны тамаша кыйлырлар. Инде хәкимнәрнең *минәс-самти нәҗаун* дигән сүзләрен вә дәхи *әл-бәла мөвәккәл бән нотык* дигән сүзләрен хәтереңнән чыгарма. Сабыр ит, сөйләшмә. Әгәр сабыр итмәсәң, бер-бер сүз әйтсәң, безгә үпкәләмә, үзеңә үпкәлә. *Вә ля түлку биәйдикум иләт-тәһликәәт*. Үз гөнаһың үзеңә булыр. Бу сүзне хәтереңдә тот!» — диделәр.

Бәс, бака бу сүзләрне ишетте. Аллаһы Тәгаләнең *«Инни нәзарту лир-рахмәни саумән фәлән үкәллимәл-ямә инсия»* дигән сүзенә тәмәссек кыйлып, асла бер сүз әйтмәмен, дип гаһед кыйлды. Бәс, бу ике каз, баканы шөйлә гаһед кыйлдырып, бер камышлыкка килделәр. Бакага әйттеләр: «Син бу камышны уртың белән тешлә, ирененне бик каты кыс!» — диделәр. Бака камышның уртасыннан, алар әйткәнчә, тешләде. Ике каз икесе дә камышның ике башын муеннарына куйдылар, бака белән бергә һавага очтылар.

Бәгъзе адәмнәр, бу тамашаны күреп, бәгъзеләренә хәбәр бирделәр. Җыелышып: «Вә гаҗәба! Ике каз бер баканы ничек күтәреп очадыр!» — дип, араларында гауга купты. Бака, бу гауганы ишетеп, бераз сабыр кыйлды. Ахыр халыкның тәгаҗҗебенә сабыр итә алмады, аларга җавабән: «Ник гаҗәпләнәсез? Күрмәймесез, ничек очадыр, бакакак!» — дип кычкырган иде, авызы ачылгач, камыштан ычкынып китте, җиргә төшеп, һәлак булды.

Инде, әй угыл, бу сүземдә максуд сиңа каз хикәяте түгелдер. Син һәм ушандак ошбу бака шикелле унбер ай нәфсиният вә шәһвәт күлендә тереклек кыйлдың. Уен һәм шуклык белән. Анда дуслык таптың. Кайчан кем Рамазан ае килде, руза эсселеге белән шәһвәт күлендә мәгъсыять суы кипте. Әүвәле — рәхмәт, уртасы — мәгъфирәт, ахыры — уттан азат була торган Рамазан аенда рәхмәт вә рәэфәт[1] казлары сиңа килде, *үзкуруллаһә фи әйямин мәгъдүдәт* камышын авызыңа куйдылар. Явыз сүз сөйләшмә! Гайбәт сөйләшмә — рузаны ачадыр!» — дип, сиңа әйттеләр. *Вә түбү иләллаһи җәмиган*, дип, сиңа тәүбә илка кыйлдылар. Кайчан ки син тәүбә кыйлдың вә гаһед кыйлдың, алар, ягъни рәэфит вә рәхмәт казлары, сине һавага рәфегъ кыйлдылар. Инде явыз вә яман сүзне вә гайбәтне сөйләсәң, вә нәфсеңә иярсәң, бозыклар бозыклыгына төшәрсең. Сиңа Газраил бакага шикелле килер, тереклек камышын авызыңнан алып, хәят тәүбәсеннән үлем иделенә төшәрсең. *Раббәнә әхриҗна минһа фәин гуднә фәиннә залимун*, дип ятарсың. Аннан соң тәүбәгә вә гамәл салихка әфәнделәрең булмас. Тәхкыйк, үзеңне үз кулың белән һәлак кыйлдың.

---

Аллаһы Тәгалә башка мәхлукат арасыннан адәмне ихтыяр кыйлды. Вә җәмигъ мәхлукат үзрә бәни адәмне фазыйләтле кыйлды. Вә ләкад кәррамнә бәни адәм, диде. Аллаһы Тәгалә бәни адәмне шөйлә хөрмәтле кыйлса, ул бәни адәмне үлем фәрештәсе кулына тапшырмакында, вә әманәтендә вә кыямәт көнендә терелтеп хисап кыйлмакында, аннан соң оҗмахка керт-

[1] Рәэфәт — кызгану, кайгыртучанлык.

мәкендә ни хикмәт бар? Вә халән ки җәмигъ мәхлукат вә җәмигъ мәүҗүдат арасында адәмнән хөрмәтлерәк нәрсә юк иде. Аллаһы Тәгалә адәмне халк иткәч, башына кәрамәт таҗы кидерде. Вә әүладына дәхи кидерер. Вә колагына мәхәббәт алкасы кидерде. Вә биленә тәүхид кәмәре баглады. Вә бармагына тәсхир балдагы кидерде. Ошбу кәрамәтләр вә ошбу дәрәҗәләр була торып, бәни адәм ничә-ничә мәшәкатьләр күрәдер. Аталар аркасыннан вә аналарның карангы рәхменнән чыгарыладыр. Төрле михнәтләр һәм төрле авырулар күрәдер. Кайгылар белән мөбтәля буладыр. Үлем ачысын күрәдер. Кабер газабын вә кабер тарлыгын күрәдер. Хәшер вә нәшер[1] соңында соруг сөальгә ба тарикъ нас җавап бирделәр вә дәхи би тарикъ гакыл җавап бирделәр. Ба тарикъ нас будыр ки, пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «*Изә әхәббәллаһү габдән ибтәләһү фәин сабәра иҗтәбәһү вә ин разыя истафәһ*», — диде.

Әмма ба тарикъ гакыл җавап будыр ки, мәсәлән, ягъмур болытлардан сыгылып чыгадыр, һава аркылы тартылып, болыт арасыннан үтеп, бәгъзе тамчылары — дәрьяга, вә бәгъзе тамчылары — җир өстенә, вә бәгъзе тамчылары, тимсах[2] кебек, хут балык кебек хайваннар авызына төшеп, ничә-ничә миллион тамчылары юк буладыр. Гайре мөтәнәһи тамчылардан бер генә данәсе — шәрәфәтле урынга, ки сәдәф авызыдыр, ана төшәдер. Аннан сәдәф диңгез төбенә төшеп, ничә заманнар анда сәдәф эчендә энҗе булып үсәдер. Вакыты җиткәч, гауваслар аны чыгарып, эчен яралар; сәдәф эченнән энҗене чыгаралар. Кадерләп, падишаһларның таҗларына тезәләр. Вә халән ки ул энҗе бер данә ягъмур тамчысы иде. *Фәтәбарәкәллаһү әхсәнул-халикыйн*. Әгәр дә ул ягъмур тамчысы бу согубәтләрне күрмәсә иде, падишаһларның таҗына урнашырга салахиятле вә мөстәхак булмас иде.

Инде, әй угыл, син һәм бу ягъмур тамчысы шикелле. Әгәр дә синең бер тамчы нотфәң атаң сәлбендә вә анаң рәхмендә ятмаса, вә михнәтләргә вә куркуларга төшмәсә, үлем ачысыны татымаса, мәхәл корбәт булырга салахиятле булмас идең.

Янә бер гакыйль җавап будыр ки: гөл чәчәге ләтыйф вә кыйммәтле була торып, әгәр дә агачыннан йолкып алынмаса, эскәнҗәгә кыстырып, мае чыгарылмаса, голяма вә фозала кемнәрен, вә падишаһларның, вә әмирләрнең киемнәрен хушбуйлы кыйлырга салахиятле булмас иде. Бәни адәм һәм ушандак. Әгәр дә мәләкелмәүт аны хәят агачыннан йолкып алмаса, кабер каруръәсенә салып кысмаса, сөаль уты белән кыздырылмаса, аның

---

[1] Хәшер вә нәшер — хыянәт көнендә мәетләрнең туплануы һәм таралуы.

[2] Тимсах — крокодил.

калебе рух чәчәгенең суына гарык булмас иде. Хурелгаен хөлләләре белән мөгаттар булмас иде.

Дәхи бер гакыйль җавап будыр ки: әгәр алтынны җирдән, туфрак астыннан казып алмасалар, утка салып кыздырмасалар, чүкеч астына салып сукмасалар, адәмиләр каршында һич кадерле булмас иде. Адәм угылы һәм ушандак: төрле михнәтләр күрмәсә, картлык ачысын күрмәсә, вә үлем ачысын вә кабер газабын күрмәсә, җәннәткә салахиятле булмас иде. Аллаһы Тәгалә гүя әзәлдә әйтте: «Тукта, әгәр дә бәндәм михнәт вә мәшәкать ачысын татымаса, нигъмәт вә гата кадерен белмәс. Таки нигъмәт кадерен белсен: михнәт чиктерәем», — диде. Әйтте: «Әй бәндәм, сине бар иттем, кодрәтемне күрмәк өчен. Ризык бирермен, рәхмәтемне белмәк өчен. Сине үтерермен, хикмәтемне күрмәк өчен. Сине хәшер кыйлырмын, гыйнаятемне күрмәк өчен. Китабыңны укытырмын, савап вә гыйкабеңне күрмәк өчен. Утка сөрермен. *Вә иннә минкум иллә вәридүһә* шифа күрмәк өчен. Оҗмахка кертермен, гатамны күрмәк өчен. Кәүсәр шәрабын эчертермен, сафа күрмәк өчен. Руэият бирермен, лика күрмәк өчен», — диде.

Вә дәхи Аллаһы Тәгалә мәхлукат эченнән Мөхәммәд галәйһиссәламне пәйгамбәр итеп сайлады. Әмма пәйгамбәрлекне яшь вакытта бирмәде. Әйтте: «Әгәр дә яшь вакытында пәйгамбәрлек бирсәм, кыйммәтен белмәс», — диде. Бәс, 40 яшендә пәйгамбәрлек бирде. Вә төрле михнәтләр белән михнәтләндерде. Авырулар, мәшәкатьләр белән мөбтәля кыйлды. Хәтта бәгъзе кяферләр, ул — сихерчедер, диделәр. Бәгъзеләре, шагыйрьдер, диделәр. Вә бәгъзеләре, мәҗнүндер, диделәр. Аннан соң: «*Йә әййүһәр-Рәсүл бәллигъ мә унзилә иләйкә*» — дип, рисаләт белән бәшарәт кыйлдылар. Вә Мөхәммәд галәйһиссәлам, рисаләтнең кадерен белеп, *әфәлә әкунә габдән шәкүра*, дип шөкер кыйлды.

Инде мөэмин бәндә һәм ушандактыр. Дөнья сахрасында хәйран булып, Аллаһы Тәгалә ул мөэмин бәндәне төрле бәлаләр белән вә авырулар белән мөбтәля кыйлды. Хатын вә балалар белән фитнәләндерде. *Иннәмә әмвәлүкүм вә әүләдүкүм фитнә*. Вә аның гайбәтенә керделәр. Бәгъзеләр, әшәке, вә бәгъзеләр, түбән зат, диделәр. Вә ул бәндәнең өстенә дөнья мәшәкатен йөкләп вә мәгазалик фәраизны бәндә әда кыйлды. Таки *үдхүлүл-җәннәтә әнтүм вә әзвәҗүкүм тәхбирун* бәшарәтен ишетмәк өчен. Бәс, бәндә бу вакытта бәндәлек кадерен белеп, *әлхәмдү лилләһил-ләзи әҗәләнә дәраль-мәкамәт*, дип шөкер әда кыйлыр.

---

Вә дәхи Аллаһы Тәгалә Йосыф галәйһиссәламне беләсез. Вә мәшәкатьсез вә михнәтсез дә Мисырга падишаһ кыйлмага кадир иде. Падишаһлык вә олуглыкның кадерен белсен өчен,

бу кадәр бәлаләр бирде. Карендәшләре сәбәпче булды. Атасыннан аердылар. Коега салдылар. Аз бәһагә кол итеп саттылар. Вә Аллаһы Тәгалә аны михнәт, вә мәшәкать, вә горбәт белән мөбтәля кыйлды. Фөркать уты белән бәгърен кәбаб кыйлды. Зиндан михнәтен тартты. Йосыф галәйһиссәлам, бу михнәтләрне тартканнан соң, Мисырга падишаһ булды. Инде, әй угыл, мөэмин бәндә һәм ушандактыр. Әгәр дә авырулар ачысын татымаса, үлем ачысын татымаса, кабер зинданының тарлыгын күрмәсә, вафат булып сөекле хатыныннан вә баласыннан-чагасыннан аерылмаса, гарасат мәйданында михнәтләр күрмәсә вә тәмугта сугарылмаса, миннәт вә нигъмәт кадерен белмәс иде.

Вә дәхи, әй угыл, каләмнән гыйбрәт алмаймысың?! Әгәр ул каләмне камышлыктан кисеп алынмаса, үскән җиреннән аерылып, горбәткә төшмәсә вә, ул каләмне юнып, башын кисеп, бугазын ярылмаса, кара савыт зинданына куелмаса, вә карага манылмаса, вә кәгазь өстендә Аллаһы Тәгаләнең исемен яза алмас иде. Бәс, каләм бу мәшәкатьләрне тарткач, кәгазь өстендә Аллаһы Тәгаләнең исемен күреп, шөкер кыйлыр вә әйтер: «Әлхәмделиллаһ, бу кадәр мәшәкатьләрне күрсәм күрдем, телемнән дә Аллаһы Тәгаләнең исеме заһир булды», — дияр.

Әй угыл, мөэмин бәндә һәм ушандактыр. Дөньяда авырлыклар, мәшәкатьләр күрәдер: үлем ачысын татыйдыр. Үлде, дип, кабер зинданына куялар. Аннан соң кыямәт куркуларын күрәдер. Җәһәннәм төтене белән йөзе карала, аннан соң нигъмәт вә җәннәт кадерен белер! Оҗмахка кергәндә әйтер: «Авырулар, мәшәкатьләр күрдем, үлем ачысын татыдым. Күп хәтәрләргә вә куркуларга төштем. Аллаһының йөзен күрергә әһел булдым», — дияр.

———

Адәм галәйһиссәлам җәннәткә гыйззәт вә хөрмәт белән керде, хурлык вә гаҗизлек белән чыкты. Монда ни хикмәт бар иде? Аллаһы Тәгалә Коръәндә һәммәсеннән хәбәр бирде ки: Аллаһы Тәгаләнең *вә галләмә адәмәл-әсмаәә күлләһә тәгълиме* белән Адәм галим иде. Адәм галәйһиссәламнең: *«Әнбәэәһүм би әсмаэиһим»*, — дип, гыйльменнән хәбәр бирде. Вә Адәм галәйһиссәламнең: *«Раббәна, заләмнә әнфүсинә»,* — дигән сүзе белән хәвефеннән хәбәр бирде. Вә шәҗәрәдән ашаганына. *«Вә нәсия әдәмү, вә ләм нәҗидләһү газма»,* — дип, гозереннән хәбәр бирде. Вә Адәм галәйһиссәламне җәмигъ мәхлукат эченнән сайлаганына: *«Фәҗтәбәһү Раббүһү»*, — дип хәбәр бирде. *«Әнә җәгыйлүн фил әрзый халифәһ»*, — дип. Адәм галәйһиссәламнең җир йөзенә хәлифә булуыннан хәбәр бирде. *«Үскүн әнтә вә зәүҗүкәл җәннәте»*, — дип, җәннәттә тормакыннан хәбәр бирде. *«Фәкүлү минһа рагъдән хәйсү шиътүмә»* — дип, оҗмахта һәр нигъмәтне ашамак мөбах булуыннан

хәбәр бирде. *«Фәнфәхтү фиһи мин рухи»*, — дип, Адәм галәйһиссәламгә җан нәфех кыйлуыннан хәбәр бирде. *«Вә ләкад кәрамнә Бәни Адәмә»*, — дип, Адәм җәмигъ мәхлукаттан әфзаль булмакка хәбәр бирде. Адәм галәйһиссәламгә сәҗдә кыйлмакка: *«Үсҗүдү лиәдәмә»*, — дип, фәрештәләргә әмер кыйлуыннан хәбәр бирде. Вә һәм пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Аллаһы Тәгалә Адәмнең балчыгын кырык көн хамыр кыйлдым, дип әйтте», — дип хәбәр бирде. Бу кадәр кәрамәтләр вә бу кадәр дәрәҗәләр соңында: *«Вәкальнәһбиту минһә җәмига»*, — дип, оҗмахтан чыгаруыннан хәбәр бирде. *«Вә гаса адәму раббәһү фәгувә»*, — дип, оҗмахтан мәгъсыять вә гыйвая сәбәпле чыкмакыннан хәбәр бирде. Инде Адәм галәйһиссәламгә бу кадәр михнәтләр, бу кадәр зилләт йөкләнмәктә, вә бу кадәр әгъля дәрәҗәгә күтәргәннән соң төшермәктә ни хикмәт бар иде? Инде, әй угыл, бу сөальгә ба тарикъ нас вә һәм ба тарикъ гакыл бик күптөрле җавап бирделәр. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: *«Каддәраллаһүл-мүкаддир каблә халкыйс-сәмәвәти вәл әрзый»*. Ягъни Аллаһы Тәгалә, җирне-күкне яратмастан, мөкатдәм һәрнәрсәне тәкъдир кыйлды. Бәс, хикмәте әзәлиясенең икътизасы шөйлә булды. Әмма ба тарикъ гакыл җавап будыр ки: бәгъзе кяферлар гоман кыйлдылар ки: «Халән, оҗмах-тәмуг яратылмагандыр», — диделәр. Бәс, Аллаһы Тәгалә оҗмах-тәмугның халән барлыгына шаһид булсын өчен, үзенең кодрәтен изһар кыйлды.

Вә дәхи бер гакыйль җавап будыр ки: Адәм галәйһиссәлам оҗмахка кергәч, фәрештәләр әйттеләр: «Бу, безнең мәкамымызда, зилләтне моктиза булгудай гөнаһ кыйлмак юк. Без тагать өчен яратылдык. Аслымыз сөгуддыр[1], тагатьне икътиза кыйлыр. Йә Адәм, синең асылың нидер ки? — Туфрактыр, мәгъсиятне икътиза кыйлыр», — диделәр. Бәс, Адәм галәйһиссәлам шайтанның: *«Һәза шәҗәрәтүл хульди вәл-мүлки лә юблә»*, — дип әйткән вәсвәсәсе белән шәҗәрәтел тәнавел кыйлды. Гасый булды. *Вә гаса Адәму — Раббәһү фәгавә.* Фәрештәләр баягы сүзләреннән хәҗил булдылар[2]. Ягъни, Адәм галәйһиссәламнән гыйсъян садыр булгач: «Бу — тагать урыныдыр. Монда гөнаһ кыйлмак юктыр», — дигән сүзләреннән оятлы булдылар. Аллаһы Тәгаләнең һәйбәтеннән курыктылар. Бәс, Аллаһы Тәгаләдән нида килде: «Йә Адәм, фәрештәләр синең асылыңны зәм кыйлдылар, туфрактан яратылмыш, дип, сиңа чиркәнү белән карадылар. Инде чык оҗмахтан», — диде.

Кайчан ки Адәм галәйһиссәлам җир йөзенә инде, Аллаһы Тәгаләгә тагать изһар кыйлды. Гөнаһлы булганына егълады, тәүбә кыйлды. Тәүбәсен Аллаһы Тәгалә кабул итте. Ошбу фә-

---

[1] Сөгуддыр — югары менүдер.
[2] Хәҗил булдылар — йөзләре кызарды, оялдылар.

рештәләрне, ягъни шул әһанәт кыйлган фәрештәләрне, үзләрен Адәм галәйһиссәламгә бәшарәт белән җибәрде. Бәс, Адәм галәйһиссәлам оҗмахта вә гасый Адәм «раббиһи» нидасын ишетте, вә җир йөзендә «*Фәтәбә галәйһи вәһәдәһү*» нидасын ишетте. Фәрештәләр «Синең асылың — туфрак. Монда гөнаһ кыйлмак юк» дигән сүзләреннән хәҗил булдылар. Бәс, Аллаһы Тәгалә алар әйткәннең хилафына үзенең кодрәтен изһар кыйлды. Адәм галәйһиссәлам дәллял мәнзилендә булды. Ягъни, бер дәллял — йорт саттырмага, бакча саттырмага яки җир саттырмага теләсә, мөштәригә[1] хәбәр кыйлмак өчен, әүвәл эченә кереп карап, кәйфиятләрен тикшерәдер. Адәм галәйһиссәлам һәм ушандак.

Кайчан ки Адәм галәйһиссәламне Аллаһы Тәгалә яратты, мәхлукат эченнән сайлады. Җәннәтне аңа мөбах кыйлды. Ягъни Адәм галәйһиссәлам оҗмахка керде. Кәйфиятен тикшерде. Оҗмахның һәр әтрафын сәер кыйлды. Тиз чыкты. Дөньяга килде. Мөштәриләргә, ягъни үзенең изге вә явыз балаларына барчасына белдерде. Вә оҗмахның бәясен бәян кыйлды. Таки аның балалары — оҗмах орлыгыннан. Оҗмахның бәясен хасыйл итсәләр, оҗмахка керерләр. Вә дәхи Адәм галәйһиссәлам Мөхәммәд өммәтенә бәшарәт өчен сөенче мәнзилендә булды. Гүя Аллаһы Тәгалә әйтте: «Әй Мөхәммәд өммәте, минем рәхмәтемә, гыйнаятемә нәзар кылыңыз ки, атаңыз Адәм бер локмә тәнавел кыйлды, бу локмә сәбәпле рәхмәт җиреннән михнәт җиренә чыкты. Сезнең фәкыйрьләргә бер локмә бирмәкеңезне оҗмахка кергәнеңезгә сәбәп кыйлдым. Бәс, минем өчен бер локмә саранлык кыйлмаңыз. Бу минем өчен биргән локмәңез сәбәпле, атаңыз чыккан рәхәт урынны сезгә бирермен», — дисә кирәк. Ягъни зәкят, гошер вә садака кебек важибәтне әда кыйлмакта саранлык кыйлмаңыз, димәктер.

———

Адәм галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә гасый булды. Вә иблис дәхи Аллаһы Тәгаләгә гасый булды. Аллаһы Тәгалә, Адәмнең тәүбәсен кабул итеп, һидаять кыйлды. Вә иблиснең тәүбәсен рәд кыйлып, ләгънәт итте, дәргәһыннан сөрде. Моның хикмәте ни иде?

Адәм галәйһиссәлам дәүләтнең кыйммәте, вә милләтнең юлбашчысы, вә хикмәтнең чыганагы, вә җәннәт әһеленең рәисе иде. Кодес сафасында мөҗавирләрнең мәсҗүде вә инс саумәгасында мөлазимнәрнең максуды иде. Вә дәрәҗәсе әгъләә галәйингә чыкты. Оҗмах вә хурелгаен аңа мөбах булды. Таҗ әсфия башына куелды. Моннан соң ошбу кәрамәтләре була торып, Аллаһы Тәгалә аны шайтан вәсвәсәсе белән мөбтәля

---

[1] Мөштәригә — сатып алучыга.

кыйлды. Шайтан вәсвәсә кыйлып, аны оҗмахтан чыгарды. Вә дөнья сахрасында хәйран вә сәргәрдан кыйлды. Аннан соң Адәм галәйһиссәлам ике йөз ел егълады. Аннан соң Аллаһы Тәгалә тәүбәсен кабул итте. Башына гафу вә мәгъфирәт кидерде. Монда ни хикмәт бар иде?

Вә дәхи ушандак иблисне Аллаһы Тәгалә якын фәрештәләренә мөгаллим кыйлды. Вә аларга рәис кыйлды. Вә әмин кыйлды. Вә Гаршегә янәшәдә кыйлды. Аннан соң, *үхъруҗ минһә фәиннәкә раҗим* дип, аны дәргяһтан сөрде. Муенына ләгънәт камыты кидерде. Әгәр дә Адәмнең вә иблиснең мәгъсыятьләренә карасаң? Иблис фәрманны куйды. Вә Адәм нәһигә гөнаһлы булды. Бәс, икесе дә гөнаһлы булдылар. Аллаһы Тәгалә аларның берсен кабул итте, берсен сөрде. Монда ни хикмәт бар иде? Инде, әй угыл! Бу сөальгә дәхи ике юл белән җавап бирделәр.

Бере нас[1] белән ки пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «*Кабилә мин кабилә лилгыйлләт вә раддә мин раддә лилләззәти*». Вә дәхи гакыйль җавап будыр ки: Адәм галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә гасый булды. Аннан соң гыйсъяннан кайтты: «*Раббәнә заләмнә әнфусәнә*», — дип истигъфар кыйлды. Бәс, Аллаһы Тәгалә аны мәгъфирәт кыйлды. Әмма иблис Аллаһы Тәгаләгә гасый булды. Гасый була торып, тәкәбберлек кыйлды. Бәс, тәүбә кыйлган мәкъбуль булды вә тәкәбберлек кыйлган мәрдүд булды[2].

Вә дәхи икенче бер җавап будыр ки, иблис үзенең тагатенә шатланып көлде. Әмма Адәм галәйһиссәлам мәгъсияте вә хатасы өчен егълады. Инде иблиснең көлмәге утка әверелеп, тагатен көйдерде, тагате туздырылган тузан булды. Вә Адәм галәйһиссәламнең егъламакыннан сил пәйда булып, гөнаһысын юды. Вә дәхи иблис, мәгъсыять сәбәпле, кяфер булды. Нитәкки шәригатьтә бер кемсәнә, гөнаһ кәбирә сәбәпле, кяфер булмайдыр. Ләкин иблис кяфер булды, чөнки Аллаһы Тәгаләгә җәһел нисбәт бирде. Ягъни Аллаһы Тәгалә иблискә әйтте: «Йә Газазил, Адәм синнән яхшырактыр, аңа сәҗдә кыйл!» — диде. Иблис әйтте: «Юк, Адәм яхшырак түгелдер, мин яхшыракмын. Чөнки мине уттан яраттың, аны балчыктан яраттың. *Халәкътәни мин нәри вә халәкътәһү мин тыйн*», — диде. Иблис гөман кыйлды ки, ут балчыктан хәерледер. Бәс, бу сәбәпле кяфер булды вә мәрдүд булды. Вә Адәм галәйһиссәлам һидаять вә мәгъфирәт тапты.

Инде, әй угыл, максуд будыр ки: тәүбә кыйлмак вә истигъфар кыйлмак —Адәм галәйһиссәлам һөнәредер. *Гаҗҗилү биттәүбәти каблəл-мәүт*. Вә горурлык вә истикъбар — иблис

---

[1] Нас — цитата.
[2] Мәрдүд булды — кире кагылды.

һөнәредер. Әй угыл, син Адәм хикәятенә гаҗәпләнәсең: «Адәм галәйһиссәлам ник үлде? Иблис ник үлмәде?» — дисең. Ишетмәденме син бер падишаһ этенең хикәясен?

Кадим заманда бер падишаһ бар иде. Вә аның дәхи сөекле вә тәгълим бирелеш эте бар иде. Тәмам алтын вә җәваһир белән мөзәйян иде. Бу эт бик картайды. Зәгыйфьләнде. Гакылынданоксан заһир булды. Вә падишаһны тешләмәгә касд кыйлды. Падишаһ әйтте: «Сөбханаллаһи, бу эт иясен танымас булды. Моңар ни хәйлә кирәк?» — дип, егетләренә боерды: «Бар, бу этне сахрага илтеп җибәреңез, ләкин муеныннан җәваһир вә алтыннарын алмаңыз», — диде. Егетләре әйттеләр: «Йә падишаһ, ни өчен шөйлә боерырсызлар?» Падишаһ әйтте: «Мин, бу эт беләнауга йөреп, тамаша вә куаныч кыйлдым. Аның белән мәшгуль булдым. Инде бу — этнең ахыргы дәүләтедер. Вә миннән аңа тигән өлешедер. Моннан соң бу дәүләт аңа янадан килмәс, вә моннан соң бу эт элгәрege рәхәтне тапмас», — диде.

Бәс, егетләр падишаһның фәрманын әда кыйлдылар. Этне алтын вә җәваһирләре белән сахрага илтеп җибәрделәр.

Әй угыл, иблиснең хәле һәм ушандактыр. Иблис мөкатдәмдә Аллаһы Тәгаләнең якыннарыннан иде. Гыйззәт вә дәүләт эчендә иде. *Иннә һайрун минһү*, дип, инаниятне изһар кыйлды. Бәс, Аллаһы Тәгалә әйтте: «Бу этем сөббух кодес сәйдендә берничә иманнар мәшгуль иде. Халән гакылында ноксан заһир булды. Дөнья сахрасына илтеп, аны җибәреңез. Мин аның муенына *«иннәкә минәл-мүнзарин»* муенчагын кидердем. Бу муенчакны муеныннан алмаңыз. Аның бер ахыргы дәүләтедер. Вә миннән тигән өлешедер, кайчан кем, инзар мөддәте узып рәхәтне кыйлса да, әбәдән тапмас. Ул вакытта: *«Йә ләйтәни күнтү тураба»*, — дип әйтер», — диде.

———

Кайчан ки Аллаһы Тәгалә Адәм галәйһиссәламне гадәм[1] чишмәсеннән вөҗүд[2] сахрасына китерде, башына кәрамәт таҗы кидерде. Аллаһы Тәгалә әкрәмел әкриминдер. Берәүгә бер нәрсә бирсә, мәнге кайтарып алмас. Әмма Адәм галәйһиссәламне оҗмахтан ялангач вә ачык гаурәт чыкармакында ни хикмәт бардыр? Хәлбуки Аллаһы Тәгалә Адәмне туфрактан яратты. Вә нотфәсеннән балалар китерде. Вә кодрәте белән юктан бар кыйлды. Вә аңарга, *халәка ләкүм мә фил әрзый җәмига*, дип, үзенең миннәтен белдерде. Вә аларга сигез оҗмах, җиде күк, алты җәннәт, биш хәвас, дүрт гасыр бар итте. Җәмигъ мәхлукат эчендә Адәмне сайлады. Аллаһы Тәгаләнең сәнгать сандыгы

[1] Гадәм — юклык.
[2] Вөҗүд — барлык.

гында хикмәттән, нигъмәттән һичнәрсә калмады, һәммәсе Адәмгә һибә кыйлынды. Хөллә кидерде. Вә кәрамәт тажын кидерде. Нур белән зиннәтләде. Ожмахына кергезде. Бәс, ошбу гатая соңында бодайдан бер ярты локмә өчен ярты көндә ожмахтан чыгарды. Өстендә хөлләләрене суйды. Камчысы белән сурды. Дөнья сахрасына ялангач җибәрде. Вә Адәмне хәлифәлек исеме белән күтәрде. Мәгъсият исеме белән төшерде. Вә өстенә михнәт вә мәшәкатьне йөкләде.

Монда ни хикмәт бар иде? Бу сөальгә җавап будыр: әй угыл, белгел ки, Аллаһы Тәгалә кәмаль хакимдер. Аның сангының хакыйкатенә вә хикмәтенең маһиятенә гарифләрнең дә фәһеме ирешмәс. Әй угыл, важибтыр ки, гакылынны вә фикереңне жыеп, Аллаһы Тәгалә мәхлукатының гаҗәибатен фикерләгәйсең. Инде белгел ки, гыйтабтан вә мозилләттән һәрни Адәмгә ирешкән ирсә сиңа мисалдыр. Вә сиңа хөҗҗәттер. Вә сиңа нәсыйхәттер.

Кайчан ки Адәм галәйһиссәлам, ошбу кәрамәтләре була торып, бер Ходайдан бер данә орлык тәнавел кылганы өчен ожмахтан сөрелде. Вә мәгъсыяте өчен гыйтаб кыйлынды. Әй мескин! Синең дә хәлең ничек булыр: зәвекъләнеп вә хозурланып харам ашыйсың. Гөнаһка мөртәкиб буласың. Гафләт хәмере белән үзең махмырсың. Дөнья нигъмәтләре белән мәгъруррсың. Дөнья нигъмәте исә торганы — гокубәттер. Эчең-тышың — түл әмәл. Әйтерлек юк синдә гамәл. Хәлялне-харамны карамадың, ашадың. Үлемне, каберне, сөальне вә кыямәт куркуларын оныттың. Һәйһәт! Һәйһәт! Ничек котылырсың?! Адәм галәйһиссәлам, бер данә бодай тәнавел кыйлып, бер кечкенә гөнаһы сәбәпле, ожмахтан чыкты. Мең-мең гөнаһ кыйлып, ожмахка ни белән керерсең?

Кайчан ки Адәм галәйһиссәлам, бодай җимешен тәнавел кыйлып, шайтан вәсвәсәсе белән зилләткә төште, Аллаһы Тәгаләгә гасый булды, өстеннән хөлләләре салдырылды. Башыннан таҗ очты. Ялангач калды. Гаурәтен өртмәк өчен, яфрак сорап, агачтан агачка йөгерде. Бәс, бодай агачына килде, әйтте: «Әй агач, миңа гаурәтем өртерлек яфрагың бирә күр, синең сәбәпле ялангач калдым», — диде. Бодай агачы әйтте: «Кяшки яфракларым булса бирер идем, яфрагым юктыр», — диде. Аннан рәман агачына килде, күрде: мөзәйян, нәфис агач, башын югары күтәрмеш. Яшел зөмред кебек нәфис яфраклар белән өртелмеш, гүяки горус зөфаф өчен хәзерләнмеш. Бәс, Адәм галәйһиссәлам бу агачка үзенең хәлен гарыз кыйлды, көенеп, егълап яфрак сорады. Агачтан асла җавап килмәде. Аллаһы Тәгаләдән нида килде: «Йә Адәм, куй ул агачны. Хатыннарның тавышы да гаурәттер. Сиңа җавап бирмәс», — диде.

Аннан алма агачына килде. Күрде: кайгылы, хәсрәтел агач-

тыр. Күз каны белән йөзләре кызармыш. Адәм галәйһиссәлам әйтте: «Мәҗрух кешедән дару сорамак мәкрүһтер», — дип, аннан китте. Кәмсяри агачына килде. Күрде: бу агач һәм үз хәле белән мәшгуль.

Аннан китте. Хух агачына китте. Күрде: бу агач һәм үзе дә сусамыш, йөзләре каралмыш, ботакларында яфраклары сирәкләнгән, газап чигәр. Үз хәле белән мәшгуль, үзенә-үзе нәсыйхәт кыйлыр. Бәс, Адәм галәйһиссәлам нәсыйхтан нәсыйхәт тыңламак; әмма киемен сорамак мәгъкуль имәстер, дип, аннан сорамыйча китте.

Йөзем агачына килде. Күрде: оҗмах сахрасында утырыр. Күләгәсен җиргә түшәмеш. Яшел яфраклары белән бизәнмеш. Зөлфләрен яңакларына салындырмыш. Адәм галәйһиссәлам әйтте: «Бу агачның яфраклары вә күләгәсе күп, имеш. Әмма агачы вә ботагы да күптер. Бәлки, яфрагы үзенә дә азлык кыйлса кирәк. Моннан сорамак җаиз түгел», — дип, чикләвек агачына килде. Күрде: ишексез-тәрәзәсез караңгы өйдә утырыр. Әйтте: «Әгәр бу агач мөрәүвәтле булса иде, өенең ишеге булыр иде. Яки йортында чырагасы булыр иде, мөрәүвәтсездер», — дип, бадәм агачына килде. Күрде: уенчы җария кебек утырмыш. Алдына чәңг куймыш. Чәңгне сукмага кулын сузмыш Адәм галәйһиссәлам әйтте: «Бу мотрибә җариянең киеме белән файдаланмак җаиз түгелдер», — дип, аннан китте.

Инҗир агачына килде. Хәлбуки инҗир — суфи агачтыр. Адәм галәйһиссәламне кабул итте, аның белән тарикы тәсавыфны тәмам итте. Адәм галәйһиссәлам тарлыкка вә мәшәкатькә төшкән мөсафир кебек иде. Бәс, инҗир Адәм галәйһиссәламгә каршы килде. «Мәрхабә! Хуш киләсез!» — дип, үзенең ханакасына дәгъвәт кыйлды. Үзенең мәнзиленә алып килде. Икрам вә игъзаз белән хезмәтләренә торды. Рәхәт тынлык белән сыйлады. Адәм вә Хаваның алларына ике хөллә китереп куйды. «Йә Адәм вә Хава, боерыңыз: бу хөлләләрне киегез», — диде.

Бу сәбәпле Аллаһы Тәгалә инҗирне хөрмәтле кыйлды. Хәтта *вә тыйни вәз зәйтуни*, дип, инҗир белән ант итте. Белсеннәр ки: Аллаһы Тәгалә каршында җумартлык вә сәхавәт — олуг нәрсәдер. Вә дәхи белсеннәр ки: җумартлык — монафикътан садир булмас. Чөнки сәхавәт вә җумартлык — заһир вә батыйн сафлыгын тәказа кыйладыр. Вә галән ки монафикъның заһиры батыйнына хилафтыр. Аннан нәтәк сәхавәт садыр булыр? Монафикъның мисалы — мәрдүд иблис мисалындадыр. Нитәкки иблиснең заһиры батыйнына хилаф иде. Хикмәтләре мәзкурдер, инҗир агачын ут белән яндырмак җаиз түгелдер, фәкыйрьлек китерер, диделәр. Инде, әй угыл, һәммә эшләрнең яхшырагы — җумартлыктыр, оҗмахка кермәккә сәбәптер, нитәкки бодай хакында мисалы мәзкүр булды.

Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламгә әүвәл мәртәбәдә: «Углың Исмәгыйльне корбан кыйл!» — дип әмер кыйлды. Аннан соң аның фидасына кучкар җибәрде: «*Вә фәдәйнәһу бизәбхин газыйм*», — диде. Монда ни хикмәт бар иде? Аллаһы Тәгалә — кәмаль хакимдер. «Углыңны корбан кыйл!» — дип, Ибраһим галәйһиссәламгә әмер кыйлды. Әгәр бу әмердән хәлилен тәҗрибә кыйлмак булса, Аллаһы Тәгалә — галәм-с-сәр вәл хафияттер. Аннан һич яшерен нәрсә юктыр, аны тәҗрибәсез дә белде. Әгәр дә бу әмердән морады Ибраһимнан зилләт садыр булды да шуның өчен углын зәбих кыйлмага боерды, дисәң, Аллаһы Тәгалә үзе, *вә ля тәзиру вәзиратун визра ухъра,* дип хәбәр бирде. Ибраһим галәйһиссәламнең зилләте өчен углын зәбих кыйлмага вәҗеһ юктыр. Дәхи моннан һәм гаҗәбрәк, Аллаһы Тәгалә Ибраһим углын зәбех итмәгә әмер кыйлды. Вә пычакны нәһи кыйлды: «Исмәгыйльне кисмә!» — диде. Углын зәбех кыйлмакны кучкар зәбех кылмак белән икътисас кыйлды.

Бу нәрсәләрне Аллаһы Тәгаләнең ирадәсенә хамил кыйлмакта нә вәҗеһ бардыр? Ибраһим галәйһиссәлам үзе Хәлилулла була торып, бер мәртәбә дошманнар кулында әсир итте. Бер мәртәбә Нәмруд утына төште. Бер мәртәбә: «Углыңны корбан кыйлма. Аның урынына кучкар зәбех кыйл», — диде. Аллаһы Тәгаләнең кәраменнән бу эшләрнең кирәге ничек ихтималдыр? Моның ни вәҗһесе бар иде? Монда ни хикмәт бар?

Инде моның җавабы будыр ки: әй угыл, нитәкки Аллаһы Тәгаләнең әзәлдә, гадәте шөйлә җари булды. Әгәр үзенең бәндәләреннән бер бәндәсен үзенең мәхәббәтенә хәзерләсә, вә үзенә дуслыкка әһел кыйлса, ул бәндәне башкалардан аерадыр, вә гайреләр белән өлфәтләндерәдер. Үзенең дусларына үзеннән гайреләргә карамакыны теләмидер. Бәс, Ибраһим галәйһиссәлам үзенең углы Исмәгыйльгә мәхәббәт итте. Аннан соң Аллаһы Тәгалә әйтте: «Йә Ибраһим, углың Исмәгыйльне зәбех кыйл», — диде. Вә әйтте: «Йә Ибраһим, минем дустым вә Хәлилем булган кеше миннән гайрегә карамасын, миннән гайре белән мәшгуль булмасын», — диде. Шул җәһәттән пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «*Әли бәлә-у мувәккәлүн бил әнбия-и сүммә бил әүлия-и, сүммәл-әмсәл фәл-әмсәл*», — диде. Кайчан минем өчен корбан кыйл, дип әмер булды, Ибраһим галәйһиссәлам әйтте: «Әй угыл, Аллаһы Тәгалә әмер кыйлды. Сине аның өчен корбан кыйлсам кирәк», — диде. Исмәгыйль галәйһиссәлам әйтте: «Әй ата, фәрман ни булса, җиренә житкезгәйсең: Аллаһы Тәгалә фәрманына имтисал[1] важибтыр», — диде. Әм-

[1] Имтисал — буйсыну.

ма Исмәгыйль галәйһиссәламнең бу кадәр инкыяд[1] вә имтисалын һич берәү белмәде. Исмәгыйль, һич чирканмастан, үзенең җанын Аллаһы Тәгалә юлына фида кыйлды. Аллаһы Тәгалә җир вә күк әһеленә Исмәгыйльнең инкыядын гарыз кыйлмага вә күрсәтмәгә теләде. Бәс: «Углыңны корбан кыйл», — дип әмер кыйлды.

Таки җир-күк әһеле белсеннәр ки, Исмәгыйль галәйһиссәлам һич хәвефләнмәй Аллаһы юлына җанын фида кыйлыр, һич шикаять кыйлмас. Аллаһы Тәгалә Исмәгыйльгә фида өчен кучкар җибәрде, башка хайванны җибәрмәде. Монда ни хикмәт бар иде? Әй угыл, монда ике вәҗеһ бардыр, әүвәл кучкар — Һабил корбаны иде. Һабил корбаны мәкъбульләрдән булганын белдермәк өчен, кучкар җибәрде. Икенче вәҗеһ будыр ки, кучкар оҗмахта утлар иде. Сыгыр вә тәвә гайре хайваннар оҗмахта утламадылар. Бәс, бу кучкар оҗмахка керер, гайреләре бу кәрамәтне тапмаслар. Нитәкки кяферләр дөнья бакчаларын утларлар, мөтәнәгъгыйм[2] булырлар. Әмма мөэминнәр Хода юлына җаннарын сарыф вә фида кыйлырлар. Бәс, кыямәт көнендә алар мөселманнарга фида булырлар: зобанилар җәһәннәмгә һәрбер кяферне атканда: «Әй фәлән мөэмин, синең фидаһдыр!» — дисә кирәк.

Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламне утка ташламаенча да Нәмруд кулыннан хәлас кыйлса кадир иде. Әгәр берәү берәүне үзенә дус иттихаз әйләсә, ул дусты хатирәсенә нигъмәтен вә малын кызганмаенча, дусты юлына сарыф кыйладыр. Дусты өчен рәхәт вә иминлектән башканы теләмәйдер. Әгәр дустына Аллаһы Тәгалә Ибраһимны Хәлил иттихаз итте: *«Вә иттәхазә Аллаһу Ибраһиме халилән»*. Ни өчен үзенең дустын Нәмруд кулына бирде вә кяферләр каршында әсир итте? Нәмруд галәбә кыйлды. Мәнҗәникъка[3] куйды. Утка атты. Җәмигъ пәйгамбәрләрнең вә әүлияларның җаннары егълаштылар. Вә фәрештәләр егълаштылар. Оҗмах, тәмуг, җир, күк егълады. Хурлар вә гыйльманнар егълады. Галәм галиядә гауга купты. Моның мәгънәсе нидер вә ни хикмәте бардыр.

Инде, әй угыл, Нәмрудның Ибраһимны утка атмакында хикмәт шулдыр ки: Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламне карибиюн[4] фәрештәләргә гарыз кыйлмак теләде. Таки алар күрсеннәр: Ибраһим галәйһиссәлам Аллаһы Тәгалә юлына ни кәйфияттә җанын сарыф кыйладыр. Вә дәхи бәгъзе китапларында мәзкүрдер: кайчан ки кяферләр Ибраһим галәйһиссә-

---

[1] Инкыяд — буйсыну, сүз тыңлау.
[2] Мөтәнәгъгыйм — иркен яшәүче, тукланучы.
[3] Мәнҗәникъка — зур таш ата торган коралга.
[4] Карибиюн — Аллаһы Тәгаләнең иң якын фәрештәләре.

ламне хурлык белән мөнҗаникъка куймага теләделәр, Ибраһим галәйһиссәлам әйтте: «Мине ихтыярыма куеңыз: үз ихтыярым белән мәнҗаникъка аягымны куяем. Мине утка атмага кодрәтеңез юктыр. Мин уттан хәвеф итмәймен. Мин — якутмын, таки якут уттан курыкмай. Ут анда зарар итмәй. Бәлки, никадәр утка салсаң, шулкадәр күркәмлеге артадыр, ләтыйфәте вә кызыллыгы артадыр», — диде.

Бәс, шул җәһәттән Аллаһы Тәгалә утка ташламакны ирадә кыйлды. Таки бар күк әһеле белсеннәр ки, Ибраһим галәйһиссәлам уттан мәгъсумдыр. Нитәкки якут уттан мәгъсумдыр. Ушандак якут шикелле Ибраһим галәйһиссәлам уттан чыкканда, йөзе якут кебек вә яңаклары кызыл гөл кебек иде. Вә дәхи бер хикмәт шулдыр ки: Җәбраил галәйһиссәлам мең елдан бирле әйтер иде: «Илаһи, миңа бу кадәр кувәт бирдең, җирне-күкне бармагым очы белән әйләндереп ташламага вә тауларны парә-парә итмәгә кадирмен», — ди иде. Аллаһы Тәгаләдән нида килде: «Йә Җәбраил, нигә чаклы бу дәгъваны кыйласың? Бер сарраф[1] алтын танымакны дәгъва кыйлса, алтынны беләүгә сызып карар; син һәм шул сарраф кебек кувәтне дәгъва кыйлдың. Бар, минем дустым Ибраһимга аның дуслык беләвенә кувәт алтыныңны сызып кара, сайкалын белерсең», — диде.

Аннан соң Җәбраил галәйһиссәлам Хәлилгә килде. Күрде, Ибраһим Хәлил мәнҗәникъта иде. Әйтте: «Йә Ибраһим, бер хаҗәтең бармы?» Ибраһим галәйһиссәлам әйтте: «Миндә хаҗәтең бармы, дисәң, синдә хаҗәтем юктыр». Җәбраил әйтте: «Йә Ибраһим, уттан курыкмаймысың?» — диде. Ибраһим галәйһиссәлам әйтте: «Йә Җәбраил, миндә эшең юктыр. Мине Аллаһы Тәгалә эшенә тапшыр. Мин дә Аллаһы Тәгаләнең ригаясе астында вә дуслар аның химаясе астындадыр. Ни гөманың бардыр, йә Җәбраил? Берәү хөллә киемен киде, аннан куркармы?» Нитәкки Аллаһы Тәгалә әйтте: *«Мин ләм йусыйрра галя дарбинә фәл-иртихәлү мин курбинә»*. Җәбраил әйтте: «Йә Ибраһим, миңа изен бир, таки катибең булаем, сиңа вакыйг булган хәдисне язаем». Ибраһим әйтте: «Йә Җәбраил, хәдисләр кәгазьгә каләм белән язылыр. Минем шаукымның хәдисләрен ташка вә тимергә ясасаң да, ташлар-тимерләр эрер. Кайчан ки таш вә тимер минем шәүкымны йөкләмәсә, кәгазьләр-каләмнәр нитәк йөкләр? Йә Җәбраил, мине куркытыргамы килдең? Якут утта янармы? Сәмәндәр уттан куркармы? Якуттан, сәмәндәрдән мине ким күрдеңме? Шәвекъның маһиятен белмәймесең? Йә Җәбраил, күп заманнан бирле кувәт дәгъвасын кыласаң. Әйдә, минем белән бергә Нәмруд утына кер. Таки

---

[1] Сарраф — процент белән акча ваклаучы.

Аллаһы Тәгаләнең шәүкы белән утны сүндергәйсең», — диде. Җәбраил әйтте, синең шикелле минем утка сабырым юк. Йә Ибраһим, утка кермәсмен». Ибраһим әйтте: «Бу кыйлган дәгъваңның ни мәгънәсе бар? Минем белән утка кермәдең. Йосыф белән коега кермәдең. Юныс белән балык корсагына кермәдең. Мөхәммәд белән гарга кермәдең. Кит минем янымнан, йә Җәбраил. Тәүхид нуры белән Нәмруд утын басаем. Көне барда, хитабы килсен, таки Нәмруд уты ялынсын. Бер дә вә сәламен мөнкалиб улып, утыннарыннан чәчәк үсәр. Уттан йобусат китәр, дымлылану килер. Агачлары җимешләр белән мөзәйян булыр. Ут арасыннан сулар агар», — диде.

Кайчан ки Җәбраил галәйһиссәлам Ибраһим галәйһиссәлам сүзен ишетте, хаҗилән Аллаһы Тәгалә хозурына кайтты. Сәҗдә кыйлды, әйтте: «Илаһи, мин — зәгыйфьмен. Дустың белән моназара кыйлырга такатем булмады. Дустыңның аяк туфрагын күземә сөрмә кыйлдым», — диде. Моннан соң янар көне: «Бердән вә сәламен галя Ибраһим», — дип, Аллаһы Тәгаләдән нида кыйлды.

Бәс, Ибраһим галәйһиссәламнең утка атылмакында хикмәт бардыр. Хикәяттән янә бер хикмәт вә хисса будыр ки, әй угыл, Мөхәммәд өммәтеннән гасый бәндәләрнең калебләре тынычландыру өчен, Аллаһы Тәгалә Ибраһим галәйһиссәламнең утка атылмакын тәкъдир кыйлды. Кайчан кем Хәлил галәйһиссәлам утка төште, ут әйтте: «Илаһи, шәригать белән гамәл кылаеммы яки табигать белән гамәл кылаеммы?» — диде. Аллаһы Тәгаләдән хитаб килде: «Йа ут, икесе белән һәм гамәл кыйл! Ягъни табигатең белән күлмәген яндыр. Чөнки күлмәк — минем дошманымның күлмәгедер. Вә шәригать йөзеннән, җисемен яндырма! Чөнки җисеме — минем милкемдер. Ушандак Мөхәммәд өммәтеннән гасый бәндәләр кыямәт көнендә җәһәннәм утына ирешсәләр, ут әйтер: «Илаһи, бу гасый бәндәләрне яндыраеммы, юкмы?» Аллаһы Тәгаләдән нида килер: «Әй ут! Гөнаһларын яндыр, чөнки гөнаһлары минем дошманымның вәсвәсәсе белән булды. Тәннәрен яндырма, чөнки тәннәре — минем бәндәләрем вә кәнизәкләремдер», — диер.

Инде, әй угыл, белгел ки, безгә ни сөенечләр бардыр: Нәмруд утыны яндыручы дошманнар вә кяферләр иде. Җәһәннәм утыны яндыручы — Аллаһы Тәгаләдер. Кяферләр вә дошманнар яндырган ут Ибраһим Хәлилнең җисемен яндырмады. Аллаһы Тәгалә яндырган ут ник үзенең дустының өммәтләрен яндырсын? Шул сөенеч җитмәсме безгә.

---

Йосыф галәйһиссәламнең җәмалына вә хөсненә, гакылына вә кыйммәтенә җитәрлек сәмән дөньяда юк иде. Әмма дирһәм, мәгъдүдәгә сатылмакка ни хикмәт бардыр? Йосыф Садыйк

галәйһиссәлам хөсен вә җәмалда, дәрәҗәсе кәмальдә иде. Хәтта кояш, ай вә йолдызлар аңа сәҗдә кыйлдылар. Йосыф галәйһиссәламне һәрбер күргән кешеләр, *ма һәзә иллә мәләкүн кәрим,* диләр иде. Вә Ягъкуб галәйһиссәлам аны, *лә-әҗәду рихә Юсуф,* дип, өч көнлек арадан Йосыфның исен хис кыйлды. Әгәр аның холкыннан вә җумартлыгыннан сөаль кыйлсаң, карендәшләренә, *лятәсъриб галәйкем әл-яум,* дип, әйтте дип, Аллаһы Тәгалә Коръәндә хәбәр бирде. Әгәр гыйльменнән сорасаң, аның хакында Аллаһы Тәгалә Коръәндә, *вәләммә бәләга әшүддәһү әтәйнәһү хүкмән вә гыйльмән,* дип яд кыйлды.

Бәс, ошбу сыйфатлар белән тасвирлы булган кешенең аз бәһагә сатылмакында ни хикмәт бардыр? Инде, әй угыл, моның җавабы будыр ки. Көннәрдән бер көн Йосыф галәйһиссәлам көзгегә карады. Үзенең хөсен вә җәмалын көзгедә күрде, күңеленә бу килде ки: «Әгәр мин кол булып сатылсам, минем бәһамне җиткерергә кемнең кодрәте булыр?» Бәс, күңеленә бер төр тәкәбберлек килгән сәбәпле, Аллаһы Тәгалә аны коллык белән мөбтәля кыйлды. Карендәшләрен мосалләт кыйлды, таки сәмән бәхәс тәкабиленә саттылар. «Сәмән бәхәс» дигәне 17 дирһәм иде. Инде, әй угыл, бәндәгә важибтыр ки, Тәнресе өчен тәвәзыйглык кыйлган, тәҗҗәббер[1] кыйлмаган. Һәрхәлдә үзенең гаҗизлеген белгән, таки фәүзен-нәҗат[2] тапкан. Нитәкки пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: *«Мин тәкәббәра вәдагаллаһү вә мин тәвәдага рафәгаллаһ».* Бәс, һичбер бәндә үзенә бәһа куя алмас. Вә гайреләргә дәһи бәһа куя алмас.

---

Йосыф галәйһиссәлам 17 дирһәмгә сатылып, Мисырга илттеләр. Дәллял кулына сатарга бирделәр. Дәллял базарга чыгарды. Халык җыелды. Җәмалына хәйран калдылар. Һәркем: «Мин алсам икән!» — дип, арзу кыйлды. Бәһасен арттырдылар. Бәгъзеләре үзе авырлыгы алтын бирмәкче булды. Бәгъзеләре — үзе авырлыгы көмеш. Бәгъзеләре үзе авырлыгы җефәк. Бәгъзеләре — үзе авырлыгы җәүһәр бирмәкче булдылар. Малик бин Зәгыр әйтте: «Кем дә кем алтыннан, көмештән, җефәктән, җәүһәрдән — һәркайсыннан Йосыф авырлыгы нәрсә бирер, ул кешегә сатамын», — диде. Зөләйха әйтте: «Һәртөрле нәүгътан үзе авырлыгы зат мин бирәмен, аның голына тәнемне-җанымны сарыф кыйламын», — диде. Малик Зәгыр әйтте: «Хатыннар хакында *«нәкыйсатүл гакъли вәд-дин»* дигән сүзләр булса да, моның хосусында бу хатын шулкадәр җумартлык

---

[1] Тәҗҗәббер — олылану.
[2] Фәүзен-нәҗат — котылу.

изһар кыйлды, инде ул хатыннан да ким булмак мөрәүвәт түгелдер. Ирлекне вә җумартлыкны изһар кыйлмак кирәк: бер мәртәбә үзе авырлыгы нәрсәдән артык алмаймын», — диде.

Инде, әй угыл, бу кыйссадан хисса будыр: белгел ки, Аллаһы Тәгалә оҗмахны шул сыйфатта яратты ки, тәүсыйф мөмкин түгел. Анда төрле нигъмәттән вә җимештән хәзерләде. Вә анда колак ишетмәгән, вә күз күрмәгән, вә адәмнең күңеленә кермәгән *мә лә гайнүн раәт вә лә үзүнүн сәмигат вә лә хатара галя кальби бәшәр* нәрсәләрне тәртип кыйлды. Вә анда хур вә гыйльман иҗат кыйлды. Мөзәйян вә мөрәссаг касырлар вә тәхетләр анда хәзер кыйлды. Вә анда балдан, вә сөттән, вә хәмердән чишмәләр агызды. Аннан соң Аллаһы Тәгалә: «Оҗмах сатыладыр. Бәндәләремнән кем дә кем бәһасен арттырса, ул алыр дип, дәллялларга нида кыйлдырды. Аннан соң һәр бәндә, үзенең такате кадәренчә, оҗмахны сатып алырга сәмән алып килде. Бәгъзеләре намаз алып килде, зәкяте юк, имеш! Ул ала алмады. Вә бәгъзеләре намаз алып килде, көче җитә торып, хаҗ кыйлмаган, имеш. Ул ала алмады. Инде оҗмахның бәһасен кем белде? Әйт ки, әй угыл? Аллаһы Тәгалә оҗмахның бәһасен пәйгамбәрләр аркылы белдерде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Оҗмахның бәһасе — исламдыр!»

Бәс, ул биш бинаны камилән әда кыйлган кеше оҗмахны сатып алды. Аннан соң гарифләр вә тәкъвалар бәһа арттырдылар: биш вакыт намазны җәмәгать арасында әда кыйлдылар. Хәлвәттә вә яшерендә нәфел укыдылар. Малларыннан зәкятләрен әда кыйлдылар вә яшерен садакалар бирделәр. Хода юлында газа кыйлдылар, Аллаһы Тәгалә юлына җаннарын-тәннәрен фида кыйлдылар вә яшерендә нәфесләре белән вә шайтан белән газа кыйлдылар. Вә фарыз хаҗны әда кыйлдылар вә яшерендә гомер хаҗыны әда кыйлдылар. Вә халык белән рамазан аен руза тоттылар вә яшерендә нәфел руза тоттылар. Аннан соң Аллаһы Тәгалә әйтте: «Әй бәндәләрем, Йосыфны сатучы Малик Догар ни әйтте. Инде оҗмахны сатучы мин, падишаһларның падишаһы —Аллаһмын, Малик Догар бәндәдер. Мохтаҗ була торып, Зөләйха арттырган сәмәнне алмады, мөрәүвәт кыйлып, сәмән әүвәлгә сатты ки, ул Йосыфның үз авырлыгы алтын иде. Мин бәндәләремнең тагатенә имәсмен. Сәхавәт вә җумартлыкны мин үзем яраттым. Бәндәләрем белән сатулашмай, мин сәмән әүвәлгә оҗмахны бирәмен. Нитәкки оҗмахны ике хәреф белән яраттым. Ушандак һәм бәндәләремә ике кәлимәгә оҗмахны сатамын. Ягъни Аллаһы Тәгалә «күн» дигән сүз белән оҗмахны яратты ки, ике хәрефтер. *«Ля иләһә иллаллаһү Мухәммәдүр-расүлуллаһ»* — оҗмахның бәһаседер ике кәлимәдер. Инде, әй угыл, бу байтак татлы сүзләр булып китте, хәтереңдә тот.

Муса галәйһиссәлам әүвәл утка салынды. Аннан соң суга салынды. Вә аның сәбәпле ничә балалар кател кыйлынды. Монда ни хикмәт бар иде?

Муса галәйһиссәлам — Кәлимуллаһ вә мәхбубел Халикъ, хикмәт вә нәваль белән мөзәйян, кәрамәт вә фазиләт белән махсус *«инни истафәйнәкә галән-нәс бәррус-саляти вә бикәлами»* таҗы белән *«мәтәвәҗид»* биза белән *мөәййәд фа хаккый гасаһ фазаһи сугъбән мөбин»* таягы белән мөбәрһән. Вә кырык ир кувәте үзенә бирелмәш була торып, мондаен җәфаларын тартты. Хикмәт ни иде?

Җавап будыр ки: Муса галәйһиссәлам сәбәпле, балалар кател кылынмакта олуг сер бардыр. Ул заманда Муса галәйһиссәлам кауме мөнәҗҗимнәр иде. Нөҗүм гыйльме белән гамәл кыйлырлар иде. Мөнәҗҗимнәр хөрмәтле иде. Мөнәҗҗим ни әйтсә, аңа игътикад кыйлып, мөнәҗҗим сүзе белән гамәл кыйлырлар иде. Вә нөҗүм гыйльме белән күренмәгәнне хөкем кыйлырлар иде. Бәс, Аллаһы Тәгалә гаибкә хөкем итмәкләре сәбәпле, аларга газап кыйлды. Чөнки гыйльме гаиб — Аллаһы Тәгалә сыйфатларыннан бер сыйфаттыр. Шул сәбәптән Аллаһы Тәгалә аларга бер пәйгамбәр күндермәк теләде. Бәс, ул мөнәҗҗимнәр, үзләренең гыйльме буенча, Мусаның тууын белделәр. Ләкин Муса сәбәпле, балаларының һәлак буласын белмәделәр. «Муса булмагай иде», — дип, һәрбер туган баланы кател кыйлдылар. Аллаһы Тәгалә Мусаны сәламәт калдырды. Хәлбуки алар нөҗүм гыйльме белән Мусаның хәлас буласын белмәделәр. Һәрбер мөнәҗҗим хәле шөйләдер!

Көннәрдән бер көн Гали разыйаллаһу ганһу Бәгъдад шәһәрендә бер мөнәҗҗимне күрде. Үзенең гыйльмендә дәгъвасы олуг. Вә мөбаләгә[1] ялган сөйләшер. Гали разыйаллаһу ганһу бу мөнәҗҗимнең янына килде. Күреште. Әйтте: «Йә мөнәҗҗим, сиңа бер йомышым бар — бераз синең белән сөйләшәсе сүзем бар. Фәләкияттән[2], табигатьтән, әкалимнан[3] вә җирдән хәбәр бирәсең, имеш. Мөнәҗҗимнәрнең син рәисе, имеш. Син бераз тоткарлан, мин тәгам алып киләем. Синең белән бергә ашаек. Бу кавем арасында синең фазыйләтеңне белдерәем, шөһрәтең чыксын», — диде.

Тәгам алмага китте. Бер савыт кайнаган сөт, ике күмәч алып килде. Мөнәҗҗим янында өч меңләп кеше бар иде. Мөнәҗҗим алдына сөтне куйды. Ике күмәчнең берсен мөнәҗ-

---

[1] Мөбаләгә — арттыру.
[2] Фәләкияттән — космостан.
[3] Әкалимнан — климаттан.

жимгә бирде, берсен үзенә алды. Әйтте: «Йә мөнәҗҗим, син бу күмәчеңне сөткә тура, мин һәм үз күмәчемне сөткә тураем». Бәс, икесе дә турадылар. Аннан соң Гали разыйаллаһу ганһу сөткә тураган күмәчләрне һәммәсен бергә катыштырды. Әйтте: «Хуш ула, ашаек», — диде. Бәс, мөнәҗҗим кулын суза башлаган иде, Гали разыйаллаһу ганһу әйтте: «Сабыр ит, әүвәл гыйльмеңне куллан», — диде. Мөнәҗҗим әйтте: «Голүме нөҗүмне монда ни кәйфияттә кулланыйм?» Гали разыйаллаһу ганһу әйтте: «Шул сөт эченнән үзең тураган күмәчне сайлап ал», — диде. Мөнәҗҗим әйтте: «Мин аларны хәзер дә кайдан беләем?» Гали разыйаллаһу ганһу әйтте: «Нөҗүм гыйльменә кара да үзең тураганны танып ал», — диде. Мөнәҗҗим әйтте: «Нөҗүм гыйльмендә моны үгрәтмәйде», — диде. Гали разыйаллаһу ганһу әйтте: «Һи, ялганчы. Хәзер, бу сәгатьтә, үзең тураган күмәчне белмәйсең. Җирдә-күктә булган гыйльме гаибне ничек беләсең?» Мөнәҗҗим әйтте: «Йә Гали, алай булса, син үзең тураган күмәчне сайлап ал», — диде. Гали разыйаллаһу ганһу әйтте: «Мин гыйльме гаибне белмәймен. Һәм беләмен, дип дәгъва да кыйлмаймын. Гыйльме гаиб — Аллаһы Тәгаләгә хастыр». Мөнәҗҗим әйтте: «Кяшки күзем белән күрсәм ки, син тураган күмәчтән мин тураган күмәчне Аллаһы Тәгалә ничек аерыр, бу гыйлемнән тәүбә итәр идем», — диде.

Бәс, хәзрәти Гали Аллаһы Тәгаләдән дога кыйлып сорады. Шул сәгать савытта сөт кайнап, мөнәҗҗим тураган күмәч һәммәсе өскә чыкты. Коры иде. Аслан сөт сеңмәгән иде. Гали разыйаллаһу ганһу тураган күмәч һәммәсе савытта калды. Бәс, мөнәҗҗим тәүбә кыйлды. Аннан соң хәзрәти Гали күмәч тураган сөтне савыты белән алды, ул мәҗлестәге халыкка ашатты. Никадәр кеше бар иде, һәммәсе ашап туйды, артып та калды.

Инде, әй угыл, бу кыйссадан хисса будыр ки: бер күмәч тураган бер савыт сөт хәзрәти Гали бәрәкәтендә, никадәр халыкны туйдырды, кимемәде. Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә гасый мөэминнәрне хәзрәти Рәсүл бәрәкәтендә үзенең рәхмәтенә туйдырса, ни гөманың бар? Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте кимерме? Әлбәттә, кимемәс!

---

Вә дәхи Муса галәйһиссәлам әүвәл утка, аннан суга кермәкендә хикмәт будыр ки: Муса галәйһиссәлам, кяферләргә, *вә әнәр бәкем иллә галә,* дип, тәңрелек дәгъвасы кыйлучыларга кылыч гадәт кылыч ясаганда, тимерне әүвәл утка кыздырып сугалар, аннан соң, үткен булсын өчен, суга салып катыралар. Таки максуд хасыйл булыр ки, максуд үткен булмактыр. Вә дәхи фиргавеннең тәҗрибә өчен Муса алдына ут куймакыны вә Муса галәйһиссәламнең дәрьядан үтмәкене Аллаһы Тәгалә-

нең гыйльме әзәлисендә мәгълүм иде. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Йә Муса, сине утка гадәтләндерермен, таки алдыңа ут куйсалар, алып авызыңа капсаң, авызың көйдермәс. Вә суга гадәтләндерермен, таки су сине гарык итмәс».

Вә дәхи Муса галәйһиссәлам сәбәпле, балалар кател кылынмакының вәҗһе будыр ки: Аллаһы Тәгалә әзәлдә белде ки, әгәр бу кател кылынмыш балалар үсеп, олыгаеп тереклек кылсалар, фиргавен шикелле һәрберсе тәңрелек дәгъвасы кылачаклардыр. Шул җәһәттән Аллаһы Тәгалә, Мусага зарар ирештермәсеннәр өчен, аларның мәкътүл булмаклыгын ирадә кыйлды.

Муса галәйһиссәлам, *Рабби әрини әнзур иләйкә,* дип, Аллаһы Тәгаләдән руэять таләб кыйлды. Бәс, Аллаһы Тәгаләдән: «Йә Муса, мине дөньяда күрә алмассың», — җавабын ишетте. Монда ни хикмәт бар иде? Вә халән ки, Муса-Кәлимуллаһ иде. Вә Аллаһы Тәгаләнең мөкятибе иде. Шөгаеб галәйһиссәламнең кияве иде. Вә мөкәшәфәте гаибнең мөттәлигы иде. Җирдә вә суда мәхфуз иде. *Вәл куммәлү вәд-дафадигу вәд-дәм,* дип, аять могҗизат сахибе иде. Ут яндырмады. Су батырмады. Анасынан аерылып, фирак михнәтен татыды. Ерткычлар арасында куй көтте. Дәрья аерылды, юл булды. Пәйгамбәрләр арасында олы-әлгазыйм аталды. *Вә мәга зәликә лән тәрани* нидасын ишетте. Хикмәт ни иде?

Инде, әй угыл, Муса галәйһиссәламнең руэятьтән мәныг кылынуына җавап: Аллаһы Тәгаләнең *«нәхну касәмнә бәйнәһем мәгыйшәтәһем фил хәятид-дөнья вә рәфәгнә бәгъдүһүм фәука бәгъд дәрәҗәт»* дип әйткән сүзедер. «Әнисел җәлис» китабында шөйлә тәфсир итмештер ки: *«Нәхну касәмнәл әшьяә кабләл бәдъи вә иннәл хыйлләтә ли-Ибраһимә вәл-кәламү ли-Мүсә вәр-руъйәтү ли-Мухәммәд. Кәнә каләә Аллаһү Тәгалә: йә Мүсә әр-руъйәтү фид-дөнья нәсыйбү ли Мүхәммәдин вә иннәкә лән тәрани».*

Вә дәхи белгел ки, әй угыл, кайчан кем бер авыру кеше үзенең авыруыннан шикаять кыйлып, бер табиб янына килсә, табиб авыруның кулын тотып карый — нәбзын[1] тотып карый. Ниндәен авыру икәнен фәһемләп, авыру кешегә әйтә: «Сиңа фәлән даруны истигъмаль кыйлмак кирәк». Аннан соң авыру кеше әйтә: «Алайса, шул даруыңны бир. Истигъмаль кыйлып караем», — ди. Табиб: «Бүген синең кәефең саф түгелдер. Иртәгә чаклы сабыр ит. Иртәгә сиңа дару бирермен, таки бүген дару эчеп, кәефенне бозмагайсың», — ди.

Муса галәйһиссәлам ушандак шәвекъ чире белән хаста иде. *Руэять вә лика* белән дәва таләп кыйлды. Бәс, Аллаһы Тәгаләдән *лән тәрани* нидасы килде. Ягъни: бүген таңдагача сабыр

---

[1] Нәбзын — тамыры тибүен.

ит, таки кәефенә зарар итмәгәй. Кайчан ки сабах булса, руәять шәрабы эчертермен. Ягъни Аллаһы Тәгалә әйтте: «Йә Муса, синең җисемең бүген дөньяда руәять шәрабы эчмәгә салахиятле түгелдер. Ягъни дөньяда сиңа руәять насыйп түгелдер. Кыяматкәчә сабыр ит, мине тәзәррыгсыз вә таләпсез күрерсең», — диде.

Дәхи дә бер хикмәт будыр ки: кайчан кем Муса галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә мөнәҗәт кыйлды вә Аллаһы Тәгаләнең Кәлямен ишетте, моннан соң мәхлукат сүзен яратмас булды. Берәү белән сөйләшмәс булды. Адәм сүзен сөймәс булды. Әгәр дөньяда дәхи дә руәять рузи кылынса иде, Аллаһы Тәгаләне күрсә иде, мәхлукатны дошман тотар иде, мәхлукатны күрәсе килмәс иде. Вә халән ки тәблигъ рисаләткә бу эшләр мәслихәт булмады. Шул сәбәпле Аллаһы Тәгалә Муса галәйһиссәламгә дөньяда руәять рузи кыйлмады, *«лән тәрани»*, диде.

———

Әй угыл, хәбәрдә килмештер ки: мәшһүр Мәҗнүн Ләйләне сөйде вә Ләйләгә гашыйк булды. Хәтта димешләрдер ки: Мәҗнүн белән Ләйләнең кыйссасы кыямәт көнендә гашыйкларга хөҗҗәт[1] булыр, имеш. Мәҗнүннең исеме мөкатдәмдә Кайс иде.

Көннәрдән бер көн бер сәйядны[2] күрде. Бу сәйяд бер киек тотмыш иде. Бәс, Кайсның күзе бу киекнең күзенә төште. Күнеленә бу килде ки: «Бакчы, бу киекнең күзе Ләйлә күзенә охшаган, имеш», — дип, Ләйләне исенә төшерде. Дәхи һушы китте, һушына килгәч, әйттеләр: «Йә Кайс, сиңа ни булды?» Кайс әйтте: «Бу киекнең күзен Ләйлә күзенә охшаттым», — диде. Моннан соң Кайс исеме китте, Мәҗнүн атадылар. Чөнки киекнең күзен мәгъшукының күзенә тәшбиһ кыйлды. Бәс, һәрбер гашыйк үзенең мәгъшукын гайрегә тәшбиһ кыйлса, ул дәхи мәҗнүндер.

Вә димешләр ки: беркөн Мәҗнүннең атасы Ләйлә янына килде, әйтте: «Йә Ләйлә, угылым мәҗнүндер: аңа җәмалыңны күрсәтүдән мәныг кыйлмасаңа, гакылына килер иде», — диде. Ләйлә әйтте: «Мәныг юк, килсен», — диде.

Бәс, Мәҗнүн килеп, Ләйләгә якын булды. Ләйлә тарафыннан бер җил исеп, Мәҗнүнгә тиде. Дәрхаль Мәҗнүн һушы китеп егылды. Ләйләгә нәзар салырга такате булмады. Бәс, Ләйлә Мәҗнүннең атасына әйтте: «Мин сиңа әйтмәдемме ки, мин Мәҗнүннән җәмалым мәныг кыйлдыгым саранлыгым җәһәтеннән түгел иде, бәлки Мәҗнүнгә шәфкать кыйлып иде», — диде.

Инде, әй угыл, Муса галәйһиссәламнең кыйссасы һәм ушандактыр. Ягъни Аллаһы Тәгаләнең *«лән тәрани»* димәке Муса

---

[1] Хөҗҗәт — дәлил.
[2] Сәйядны — аучыны.

галәйһиссәламгә шәфкать өчен иде. Чөнки Мәҗнүн дөнья йортында Ләйләи фаниянең җәмалына нәзар салмага такать тотмады; Муса галәйһиссәлам бу фәна йортында Бакый, вә Кадим, вә Әзәли булгучы Аллаһы Тәгаләгә нәзар кыйлмага ничек такать тотар иде?

---

Пәйгамбәрләрнең вә салихларның җаннарын кабыз кыйлгучы Аллаһы Тәгаләдер. Дәлил будыр ки: Аллаһы Тәгалә «Зөмәр» сүрәсендә: *«Аллаһү ятәвәффәл әнфүсә хинә мәутиһә»*, — диде. Ягъни Аллаһы Тәгалә бәдәннәрдән җаннарны кабыз кыйлыр. Заһирән вә батыйнән җаннарның бәдәннәргә тәгаллекын[1] вә бәдәннәр эчендә тәсаррыфын[2] бетерер. Моны мәүт вә үлем, диләр. Дәхи җаннарның бәдәннәргә тәгаллекы заһирән бетер вә батыйнән бетмәс. Моны нәүм вә йокы, диләр.

Инде Газраил Муса галәйһиссәламнең җанын кабыз кыйлмага килгәндә, Муса галәйһиссәлам Газраилне ни өчен сукты? Хәтта Газраилнең күзе чыга язды. Газраил белән низаг кылышты. Газраилгә буйсынмады. Хәлбуки Муса галәйһиссәлам Газраилнең Аллаһы Тәгалә тарафыннан әмер белән килгәнен беләдер иде. Бәс, моның мәгънәсе нидер? Монда ни хикмәт бар иде? Дәхи дә, рух галәм, бер ләтиф әгъҗубә иде. Ягъни гаять тәгаҗҗеб итәрлек нәрсәдер. Рухның хакыйкатен белмәктән акыл иләре гаҗизләрдер. Вә мәгънәсен белмәктән гаҗизләрдер. Вә тәхкыйк Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд галәйһиссәламгә әсрар әйтте вә әзәлине гарыз кыйлды. Ике дөньяда ләтафәттән вә кәсафәттән ни-нәрсә бардыр, барчасыны Аллаһы Тәгалә аның өчен халк итте. Гыйльме әүвәлин вә ахиринне аңа гата кыйлды. Вә дәхи, *баллигъ мә үнзил иләйкә мин раббикә*, диде. Вә шәригатендә ни-нәрсә бардыр, барчасын бәян кыйлды. *Литүбәйинә ләһүмүл-ләзинә яхтәлифунә фиһи*.

Вә ул Мөхәммәд галәйһиссәламнән һичнәрсә яшерен булмады. Вә аннан һичнәрсә яшерен калмады. Нитәкки пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: *«Бүгыйсту биҗәвамигыль кәлим»*. Хәлбуки рух һәм Аллаһы Тәгаләнең мәхлукларыннан бер мәхлукыдыр. *Сүммә иншаәнәһ халькан ахар фә тәбәракәллаһү әхсинүл халикыйн.* Рух гаять ләтыйфтер. Хәтта бер ләхзәдә Гарше вә Көрсине үтәр. Адәмиләргә вә җинниләргә мөттәлигъ булыр. Һичнәрсәгә төртелеп тәвакъкыф[3] кыйлмас. Бәс, Мөхәммәд галәйһиссәлам рухның маһиятен[4] белдеме вә рухны күрдеме-юкмы? Әгәр рухның маһиятен белмәгән булса вә

---

[1] Тәгаллекын — бәйләнешен.
[2] Тәсаррыфын — идарә итүен.
[3] Тәвакъкыф — туктау.
[4] Маһиятен — асылын, үзлеген.

күрмәгән булса, бу аңа нәкыстыр. Хашә аның хакында нәкыс мотасаввырмы? Әгәр дә мәһиятен белгән вә кәйфиятен күргән булса, рухтан сөаль кыйлганда, *каляр-рух мин әмри Рабби*, дип, ни өчен әхбәрдән тыелды?

Дәхи дә Муса-Кәлимуллаһ, Мөхәммәд-Хәбибуллаһдырлар. Хәбибуллаһ кайда, Кәлимуллаһ кайда? Вә халән ки Муса: *«Аллаһүммәҗгальнә мин үммәти Мухәммәд»*, — дип, Аллаһы Тәгаләдән дога кыйлды. Вә Газраилне сукты. Газраил белән низаглашты. Вә Газраилгә тәслим вә монкад булмады. Әмма Мөхәммәд галәйһиссәлам Газраил белән асла низаг кыйлмады, мөсәлләм булды. Моннан соң Муса галәйһиссәлам килде дә тәфахкә монкад вә туфахны иснәде, җаны кабыз кыйлынды. Вә мәгълүмдер ки, Газраил тәфах җәмадтан хәердер. Бәс, Муса галәйһиссәлам Газраилне сукмагында, ахырында тәфахка мөсәлләм булмакында ни хикмәт бардыр? Инде, әй угыл, моның җавабы будыр ки: рухның кабыз кылынуы вә тәннән чыгуы филхәкыйкать Аллаһы Тәгалә кулы белән, ягъни Аллаһы Тәгалә кодрәте беләндер. Газраилнең тәненнән суырып тартып чыгаруы белән имәстер. Әгәр дә Аллаһы Тәгаләнең әмере белән рух монкад булмаса, Газраилнең рухны кабыз кыйлырга кодрәте юктыр.

Бәс, җаннарны кабыз кыйлгучы филхәкыйкать Аллаһы Тәгаләдер. Чөнки терек булгучыларга җанны Аллаһы Тәгалә үзе игъта кыйлды, һәрбер җан иясенә җанын Аллаһы Тәгалә һибә кыйлды. Моның дәлиле: кайчан кем Аллаһы Тәгалә адәмне халк итте, Адәм тәненә җанны өрде. Бу эштә һичнәрсә сәбәп булмады. Вә һич нәрсә халь булмады. Газраил дә сәбәп булмады. Гарше дә сәбәп булмады. Ләүх тә сәбәп булмады. Каләм дә сәбәп булмады. Җан кайдан килде, һичкем белмәде. Бәс, кайчан кем рух галәм гаибтән Адәм җәсәденә газем кыйлды, әүвәлдән Гаршедән узды, аннан соң Көрсидән узды. Оҗмахларга илтифат кыйлмады. Күкләргә илтифат кыйлмады. Газраилгә игътибар кыйлмады. Мәккә белән Таиф арасында иңде.

Җәсәдне күрде: сахрада ташланмыш ятыр. Рух әйтте: «Бу хәрабәгә ни кәйфияттә кердем? Бу караңгы вә куркыныч урында миңа ничек мәслихәт булыр? Бу караңгы җиргә кермәк? Халән ки мин үзем — Газраилдән килгән бер нәү грус булсам? Бу минем шаэнемә лаек түгелдер. Ашханәдә падишаһлар урыны булырга мәслихәтмедер! Әгәр падишаһ урыны ашханә булса, ашханәнең төтене падишаһның җәмал бәһҗәтен китәрер! Вә гыйсмәт вә пакьлек киемен каралтыр! Юк! Аслан мин бу караңгы җиргә керәсем юк!» — диде. Бәс, Аллаһы Тәгаләдән нида килде: «Әй рух! Әмерем белән кер! Син кергәч, бу караңгы җәсәд якты булыр, нурлы булыр», — диде.

Кайчан ки рух бу ниданы ишетте, бу хитабны хуш күрде. Бу хитабның хәлавәтеннән сөкран булып тыйнга дәхил булды.

Бәс, рухның җәсәдкә кермәке Аллаһы Тәгалә «әдхали» дигән сүзе васитәсе белән булды. Инде җәсәдтән чыкмас, мәгәр Аллаһы Тәгаләнең «әхрәҗи» дигән сүзе васитасы белән чыгар. Фәрештәләр җанны кендеккә чаклы назыг кыйлырлар. Чөнки Адәм галәйһиссәламнең тыйнәсен алар тәгъҗин кыйлдылар. Аларның кендеккә чаклы суырмаклары тәгъҗин әҗрәсе хисабынча булыр.

Аннан соң Аллаһы Тәгалә Газраилгә әмер кыйлып, җанны бугазга чаклы Газраил тартып китерер. Моның соңында Аллаһы Тәгаләдән хитаб килер: «Әй Газраил, имди синең эшең бетте. Син мәгъзүл булдың. Туфрак күтәреп килгәннең әҗрәсен алдың». Чөнки җир йөзеннән туфракны Газраил алып китермеш иде. Инде бугаздан югары — баш, йөз — сәҗдә урнысыдыр вә шөһүд мөхаледер. Йөзен, кодрәтем белән мин тасвир кыйлдым. Бәс, миннән гайре зат кабыз кыйла алмас, дип әйтер. *«Ликаулиһи Тәгалә вә иннә илә Раббикә лә раҗигун»*. Бәс, ошбуның өчен Мөхәммәд галәйһиссәлам мөбарәге рухын кабыз кыйлганда, мөсәлләм вә монкад булды. Чөнки ул бу мәгънәне белде. «Эф» дип тә әйтмәде. Чөнки аның җанын кабыз кыйлгучы Аллаһы Тәгалә иде. Әмма кайчан ки Муса галәйһиссәламгә Газраил килде, Муса галәйһиссәлам әйтте: «Йә Газраил, ник килдең?» Газраил әйтте: «Җаныңны кабыз кыйлмага килдем». Муса галәйһиссәлам әйтте: «Йә Газраил, җан тәндә кай җирдәдер, урынын беләмесең?» Газраил әйтте: «Юк, белмәймен». Муса әйтте: «Йә Газраил, әгәр җанның урынын белмәсәң, минем җанымны алмага нә кәйфияттә кодрәтең җитәр?» Газраил әйтте: «Йә Муса, хөҗҗәт кыйлма, мөсәлләм бул, җаныңны кабыз кыйлырмын». Муса итте: «Җанымның каны җирдән алырсың?» Газраил әйтте: «Авызыңнан алырмын». Муса әйтте: «Авызым белән Аллаһы Тәгаләгә мөнәҗәт кыйлдым». Газраил әйтте: «Телеңнән алырмын». Муса әйтте: «Телем белән «Тәурат»ны укыдым». Газраил әйтте: «Кулыңнан алырмын». Муса әйтте: «Кулым белән әлуахны тоттым, ничек алырсың?» Газраил әйтте: «Аягыңнан алырмын». Муса әйтте: «Аягым белән Тур тагына бардым». Газраил әйтте: «Колагыңнан алырмын». Муса әйтте: «Йә Газраил, колагымнан ни кәйфияттә алырсың: халәнки колагым белән Раббым Кәлямен ишеттем», — диде. Шөйлә моназага кыйлыша торгач, Муса галәйһиссәлам ачигъланды, Газраилне бер мәртәбә сукты. Хәтта бәгъзеләр: «Күзен чыгарды», — диделәр.

---

Димешләрдер ки: Аллаһы Тәгалә Гарше астында бер агач яратты. Яфраклары адәм сурәтендәдер. Әгәр Газраил берәүнең җанын алырга килсә, ошбу агачның бер яфрагын алып килер. Ошбу адәм сурәтендә булып килер иде. Аннан соң Газраил әйтте: «Йа Рабби, Мусаң мине сукты, җанын кабыз кыйл-

мага мөсәлләм вә монкад булмады». Нида килде: «Йә Газраил! Муса миңа итагать кыйлды. *«Лән тәрани»* нидасын ишетте. Син аның рухын низаглашып алмага кодрәтең юктыр. Инде син Җәбраилгә бар, әйт, җәннәтнең ризваннарына барсын, җәннәттә фәлән бакчага керсен. Анда Әхмәд сурәте нәкыш кылынмыш алма бардыр. Шул алма агачыннан бер алманы Мусага алып кил. Муса ул алманы иснәр. Вә җанын кабыз кыйлмага монкад булыр», — диде.

Бәс, Газраил ошбу әмерне иҗра кыйлды. Муса галәйһиссәламгә бер алма алып килде. Муса галәйһиссәлам алманы иснәде. Алмада Мөхәммәд галәйһиссәлам исен тапты. Бәс, монкад булды: Газраил җанын кабыз кыйлды.

Инде, әй угыл, күрдеңме, Хәбиб белән Кәлимуллаһ арасында никадәр аерма бар? Хәбиб үзе рухын Әхмәдкә фида кыйлды. Кәлим Әхмәдкә фида кыйлды. Кәлим кайда? Хәбиб кайда?

———

Дауд галәйһиссәлам гөнаһы кәбирәдән мәгъсум иде. Тәкый, зәки, вафи иде. 99 хатыны бар иде. Ни өчен үзенең карендәше Урия хатынына нәзары төште. Дауд галәйһиссәламнән мондаен эш садыр булмак ничек ихтимал иде? Дауд галәйһиссәлам шундаен дәрәҗәдә иде ки, хәтта тавышының күркәмлеге җәһәтеннән, вәхши кошлар, ул «Зәбур» укымакында, кыйраәтен тыңламага җыелдылар. Хәлифә ләкабы белән мәләкъкаб иде. Вә гыйлем белән мәүсуф иде. Вә калебе нур белән мөншәрих иде. Җәлүтны кател кыйлды. Тимерне утсыз йомшак кыйлды. «Зәбур» укыганда, кошлар саф тотып тордылар. «Зәбур» укып, Аллаһы Тәгаләнең шәүкыннан егълады. Күз яше төшкән җирдән яфрак вә үләннәр үсте. Вә бу үләннәр вә бу нәбататлар авыруларга шифа булды. Шөйлә адәмгә кошлар белән шөгыльләнеп, «Зәбур» кыйраәтеннән калмак нә кәйфияттә күркәм эш булсын? Үзенең әһеленнән вә мәхрәменнән гайрегә нәзар салмак ничек җаиз булсын?

Үзенең карендәше Урияне бер хезмәткә җибәреп, ул анда мәкътүл булгач, аның хатынын никяхланмак пәйгамбәр хакында ни кәйфияттә җаиз булсын? Әгәр Урия хатынына шәһвәт белән караган булса, бу эш пәйгамбәргә бер дә тугыры килмәй. Чөнки харамга шәһвәт белән карамак күз зинасыдыр. Хәлбуки пәйгамбәрләр андан мәгъсумнардыр. Әгәр дә гафләт белән нәзары төшсә, бу дәхи пәйгамбәрләр хакында тугыры килмәй. Чөнки пәйгамбәрләр гафил түгелләрдер.

Монда ни хикмәт бар иде? Әй угыл, инде, күп нәрсә сөаль кыйлдың, иншааллаһ, моның җавабы ошбудыр. Дауд галәйһиссәламнең зилләткә[1] төшмәкендә хикмәт бу иде: Дауд галәй-

---

[1] **Зилләткә** — түбәнлеккә, хурлыкка.

һиссәлам һәрбер гөнаһлы кешене вә хата кыйлган кешене күргән саен, *«Аллаһүммә әлганил гусат»* дип дога кыйлыр иде. Шул сәбәпле зилләткә мөәахазә кыйлынды. Вә дәхи бәндәнең һәркайчан күңеле мәгъмүм вә нәзары мәхфуз булмак важибтыр. Кайчан ки Дауд галәйһиссәлам мөзәйян кошка нәзар кыйлды, гыйсмәттән чыкты. Вә кайчан кем Урия хатынына нәзар кыйлды, зилләткә төште. Бу зилләттән мөкатдәм: *«Аллаһүммә лә тәгъфирил хаттайин»,* — дип дога кыйлыр иде. Зилләттән соң: *«Аллаһүммәгъфирил хатыйинил-мөэминин»,* — дип дога кыйлыр булды.

Ул кош күгәрчен иде. Кыйссасы мәгъруфтер. Тәфсыйль хаҗәт исә, «Кыйсасы Рабгузи»га мөрәҗәгать кыйл. Бәс, Дауд галәйһиссәламнең зилләтенә ошбу кош сәбәп булды.

Моннан соң Дауд галәйһиссәлам гасыйларга мәгъфирәт белән дога кыйлыр булды. Әмма Дауд галәйһиссәламнең калебе кош белән мәшгуль булмакының хикмәте бу иде. Дауд галәйһиссәлам һәрзаман гасыйларга һәлаклек белән дога кыйлыр иде.

Кичләрдән бер кич Дауд галәйһиссәлам михрабында каимән намазда иде. Күрде: бер адәм зина кыйлыр. *«Аллаһүммә әһләке»,* — дип дога кыйлды. Бәс, Аллаһы Тәгалә аны бу сәбәпле кош белән мөбтәля кыйлды, таки гасыйларга һәлаклек белән дога кыйлмагай, бәлки тәүбә вә истигъфар белән дога кыйлгай. Чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте: «Гасыйларның инкяр ашканы миңа мосабихләрнең риҗәсеннән ахәбтер», — диде.

Инде мәсьәләнең җавабы будыр ки: зикер кыйлынды, әгәр, Дауд галәйһиссәлам гайре кешенең хатынына зина касд кыйлды, дисәң, бу — хата сүздер.

---

Хәзрәти Әбү Бәкер разыйаллаһу ганһуның вафатыннан соң, Гомәр разыйаллаһу ганһу холәфәткә җөлүс итте. Аның гадәте бу иде ки: кичләрдән бер кичне торды. Мәсҗеткә килде. Чыраг яндырды. Мәсҗетне тикшереп карады. Мәсҗетнең бер почмагында бер төргән төенчек күрде. Караса — эчендә бер имчәк баласы. Янында бер кәгазьгә төргән ун динар. Кәгазенә язылмыш ки, бу баланың атасы юк. Ошбу алтыннар аның нәфәкасыдыр. «Кем дә кем бу баланы алып, рәхим вә шәфкатьле ата мәнзиләндә булып тәрбия кыйлса, Аллаһы Тәгалә ул адәмгә рәхмәт кыйлгай» дип язылмыш иде.

Бәс, намазга халык җыелды. Намазны әда кыйлдылар. Гомәр разыйаллаһу ганһу бала кыйссасын халыкка сөйләде. Вә әйтте: «Бу баланы алып тәрбия кыйлмага миннән әхак кемсә юктыр. Мин алаем вә тәрбия кыйлаем», — диде. «Яхшы. Мәгъкуль», — диделәр. Аннан соң Гомәр разыйаллаһу ганһу бу баланы ханәсенә алып килде. Гобәйдулла әл-Мәсҗети дип исем кушты. Бәс, бала аягына йөри башлагач, Коръән тәгълим кыйлды. Җи-

де яшенә житкәч, Коръән хафиз кыйлдырды. Ундүрт яшенә житте — гыйльме хәдис укытты. Вә гайре фәннәрне күп тәгъ-лим кыйлды. Бу баласы вә җәмал иясе вә сахибе куәт булып үсте. Тәмам егет булды. Үзенең күңеленнән: «Мин Гомәр разыйаллаһу ганһуның углымы?» — дип уйлап йөрер иде. Егетләр белән көрәшер иде. Һичкем моңар чыкмады.

Көннәрдән беркөн янә көрәшкә чыкты. Бер егетне көрәшеп екты. Бу егет, ачуланып, Гобәйдулланы сәб[1] кыйлды: «Һи, харам баласы!» — диде. Гобәйдулла, моның өчен мәгъмүм булып, хәзрәти Гомәр янына кайтты. Әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, фәлән кеше мине сәб кыйлды, һи, харам баласы, дип әйтте. Минем атам син түгелмесең?» — диде. Гомәр разыйаллаһу ганһу әйтте: «Мин синең атаң имәсмен. Мәгәр мин сине биләгән көенчә мәсжеттән таптым. Ләкин мин синең атаңны вә анаңны белмәймен», — дип, кыйссаны бәян кыйлды. Гобәйдулла әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, мин синнән илтимас кыйламын ки, минем атамны вә анамны тәфәххес[2] кыйлып, тапкайсың, вә иллә үземне һәлак кылсам кирәк», — диде. Гомәр разыйаллаһу ганһу әйтте: «Бүген мөһләт бир, мин тәфәххес кыйлып атаң-анаң кем икәнен белеп хәбәр бирермен», — диде.

Бәс, кич булды. Гомәр разыйаллаһу ганһу таһарәт алды. Ике рәкәгать намаз укыды вә әйтте: «Илаһи, әгәр дә каршыңда бу Гомәрнең аз гына мәнзәләсе булса да, бу егетнең ата-анасын белдергәйсен», — диде. Ятып йоклады. Төшендә Рәсүлуллаһны күрде. Рәсүлуллаһ әйтте: «Көенмә, йә Гомәр разыйаллаһу ганһу, сабах булып бу йокыңнан торгач, әмер кыйл ки: бөтен Мәдинә хатыннары бер мәйданга чыксыннар. Вә Гобәйдулла ул хатыннарның юлында утырып торсын. Һәрбер хатынның йөзенә карасын. Әгәр дә кайсы бер хатынны күргән бәгъдендә йөрәге мөтәхәррик булып, каны хәрәкәткә килсә, вә калебеннән бер теләк кубып, ул хатынга тәгаллек тотса, егетнең анасы — улдыр. Ул хатыннан аерылмасын. Ул хатынны сиңа алып килсен», — диде.

Бәс, Гомәр разыйаллаһу ганһу йокысыннан уянып әмер кыйлды. Мәдинә хатыннары барчасы мәйданга чыктылар. Гобәйдулла һәм чыкты, һәрбер хатынның йөзенә карады. Күңелендә бер дә галәмәт тапмады. Бәс, бер гүзәл җариянең йөзенә карады. Дәрхаль үзеннән бер теләк кубып, йөрәге хәрәкәткә килде. Вә күңелендә бер галәмәт сизде. «Әлбәттә, син — минем анамсың», — дип, ул хатынны тотты. Хатыннар әйттеләр: «Ник синең анаң булсын ул? Ул — бакирә[3] кыздыр. Һәнүз ир күргәне

[1] Сәб — сүгү, ачулану.
[2] Тәфәххес — эзләп.
[3] Бакирә — гыйффәтле.

юктыр», — диделәр. Гобәйдулла әйтте: «Мин бу жария белән хәзрәти Гомәр янына бармай торып, әлбәттә, аннан аерылмасмын», — диде.

Бәс, Гомәр разыйаллаһу ганһу янына килделәр. Вакыйганы хәбәр бирделәр. Гомәр разыйаллаһу ганһу әйтте: «Йә жария, хәлеңнән безгә хәбәр бир: бу эшнең хакыйкатен кәшеф кыйл. Сиңа моннан хәлас юктыр. Мәгәр тугрылык белән хәлас буларсың», — диде. Жария әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, белгел ки, тәхкыйк мин зинадан бәримен. Һәнүз ир күргәнем юктыр. Хәлял йөзеннән, харам йөзеннән һичбер ир женесе мине мәс кыйлмады.

Ләкин миңа бер гажәп вакыйга булды ки, мөраһәкә идем, бәлягатькә ирешкән заманымда көннәрдә бер көн жәмал иясе бер егетне күрдем. Ул вакытта миңа шәһвәт галиб булып, инзал вакыйг булды. Үземнән мәни[1] юешлеген сөртмәк өчен, берберг нәрсә юкмы икән, дип, дивар янына килдем. Диварда бер ярыкта юешрәк мамык кисәге күрдем. Шул мамыкны алып, сөртмәгә дип, фәржемә куйдым. Моннан нәфсемә шулкадәр ләззәт вә шәһвәт хасыйл булды ки, тәгъбир мөмкин түгел. Мамыкны ташладым да аннан ханәмезгә кайттым, һәрбер ай узган саен, корсагым зурайды. Йөкле булдым. Бу хәлгә үзем бик курыктым. Хәлемне анама сөйләдем. Мәдинәнең тышында бакчамыз бар иде. Анама әйттем: «Әй ана! Мине шул бакчабызга чыгарып куй. Мәдинәдә халыкка бәднам булганчы[2] гына торам», — дидем. Бәс, бакчага чыктык. Мөтдәте хәмел[3] мөнказа булганчы, бакчада тордык. Хәмел мөтдәте бетеп, бер ир бала китердем. Аннан соң ул баланы биләүгә төрдем. Янына, кәгазьгә төреп, ун динар куйдым. Бала вакыйгасын кәгазьгә яздым. Барысын бергә төреп куйдым. Бу вакыйга булганына ундүрт елдыр», — диде.

Аннан соң Гомәр разыйаллаһу ганһу әйтте: «Әй егет, сөенеч сиңа булсын: тәхкыйк, синең анаң зоһур итте», — диде. Бәс, тордылар. Берсе: «Анам!» — дип, берсе: «Углым!» — дип кочаклаштылар. Газыйм шат булдылар. Аннан соң Гомәр разыйаллаһу ганһу бу жариягә әйтте: «Йә жария, шул үзең мамык алган ярыкны хәзер дә барып табармысың?» Жария әйтте: «Бәли, йә әмирел-мөэминин, шаять, тапсам кирәк», — диде. Гомәр разыйаллаһу ганһу бармагыннан йөзеген салды, жариягә бирде, әйтте: «Бар, алай булса, бу йөзекне шул ярыкка илтеп куй», — диде. Жария йөзекне алды. Тугыры шул ярыкка илтеп кыстырды.

---

[1] Мәни — нәсел орлыгы.

[2] Бәднам булганчы — начар исем чыкканчы.

[3] Мөтдәте хәмел — йөкле булу вакыты.

Гомәр разыйаллаһу ганһу аннан соң әмер кыйлды: баягы тарикъча, Мәдинә ирләре берәү дә калмады, һәммәсе мәйданга чыктылар. Егеткә әйтте: «Һәрбер узган кешене күзеңнән кичер, йөзенә кара. Кайсы ирнең йөзенә караганда, калебең кузгалса вә күңелеңдә атаңны күргәндәге кәйфияттә бер галәмәт тапсаң, ул кешене барып тот, аннан аерылма. Ул кешене монда алып кил», — диде.

Бәс, ул егет һәрбер кешене күздән карап уздырды. Аннан соң җәмал вә кәмаль иясе бер егет узганда, йөзе йөзгә тугыры килеп, бу егетнең калебендә бер хәрәкәт купты. «Әлбәттә, минем атам — будыр!» — дип, такать булмаенча, ул егеткә һөҗүм кыйлды. Ул егет әйтте: «Әй углан, сиңа ни булды?»— диде. Бу егет әйтте: «Әссәламегаләйкүм, йә ата», — диде. Ул егет әйтте: «Мин атаң булырга һәнүз өйләнгәнем юк. Хатыным юк. Һичбер хатын белән зина кыйлганым юк», — диде.

Бәс, болар низаглашып, хәзрәти Гомәр янына килделәр. Гомәр разыйаллаһу ганһу әйтте: «Әй егет, син гомереңдә өйләнгәнең бармы? Хатының бармы?» — диде. Егет әйтте: «Һәнүз өйләнгәнем юктыр», — диде. Гомәр разыйаллаһу ганһу әйтте: «Тугырысын сөйлә! Зина кылганың да юкмы?» — диде. Егет әйтте: «Валлаһи, йә әмирел-мөэминин, зина кыйлмадым һәнүз. Ләкин миңа бервакытны бер эш вакыйг булды. Үзем кебек егетләр белән сәйран кыйлган вакытымда хатыннар җәмәгате күрдек. Алар арасында бер гүзәл кыз бар иде. Ул вакытта мин мөраһикъ[1] идем. Күңелем ул кызга мәел кыйлып, миңа шәһвәт галиб булды. Иһтилам булган шикелле, миндән дәфак вә шәһвәт белән мәни назил булды. Бер дивар янына килдем дә киемемнән мамык йолкып алдым. Аләтемне сөрттем. Бәгъдә ул мамыкны бер ярыкка кыстырып куйдым», — диде. Гомәр әйтте: «Ул ярыкны хәзер дә белермесең?» — диде. «Бәли, белермен, йә әмирелмөэминин», — диде. «Инде, син бар. Шул ярыкта минем бер галәмәтем бер нәрсә бардыр, аны алып кил», — диде.

Егет ул дивар янына китте. Йөзекне алды. Гомәргә китерде. Аннан соң Гомәр разыйаллаһу ганһу әйтте: «Йә Гобәйдулла, атаң да заһир булды. Хәзер дә сиңа *«вәләд әз зина»*, яки *«вәләдел харам»* дип әйтергә ярамас. Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән бу икесеннән дөньяга килдең» — дип, бу хатынны бу иргә гакыд кыйлды, никях укыды. Ир вә хатын булдылар.

———

Нәбиләр вә вәлиләр дөньяга мәхәббәт итмәсләр вә мал эстәмәсләр. Чөнки дөнья сөймәк вә мал эстәмәк Аллаһы Тәгалә каршында мәзмүмдер. Әмма Сөләйман галәйһиссәлам. *«Рабби һәбли мүлкән ля янбәгый ли әхәдин мин бәгъди»*, — диде.

---

[1] Мөраһикъ — яшүсмер.

Гүяки нәфсен бөхелләргә охшаткан кәйфияттә булып, дөньяны таләп кыйлды. Ягъни: «Миннән сонгыларга лаек булмаган мөлкәтне миңа бир», — дип, саранлык кыйлган шикелле итте. Ул нәбувәт белән моттасыйф булган зат, Аллаһы Тәгалә каршында хөббе дөнья мәзмүм икәнен, әлбәттә, белде.

Инде, әй угыл, бу мәсьәләгә җавап будыр: белгел, Сөләйман галәйһиссәлам күңелендә дөнья мәхәббәте тотып, мал-мөлкәтне фәкать үзенең рәхәте өчен таләп кыйлмады. Бәлки үзенең кадәрәтендә булган сәясәтен игълан итәр өчен таләп кыйлды. Күңелендә дөнья мәхәббәте барлык җәһәтеннән сорамады. Берәүнең кулында дәүләт булып та, дөньяга мәхәббәт итмәсә, зарар юктыр. Вә берәүнең дәүләте булып, дәүләткә мәхәббәт итсә, калебен караңгылык басадыр. Аллаһы Тәгаләне онытадыр. Ошбу эш — мәзмүмдер. Хәдиснең мәгънәсе һәм ошбудыр. Әмма малдан — нәүгъ карангылык калеб булмаенча чара юктыр. Нитәкки ак яулыкка көмеш тәңкәләр төреп куйсаң, яулыкка каралыгы әсәр итәдер. Әмма кешенең кулында дәүләте булып, күңелендә дөнья мәхәббәте булган өчен, саран буладыр. Саранлык дигән нәрсә дөнья мәхәббәтеннән киләдер.

Нитәкки Әбү Бәкер разыйаллаһу ганһу бай иде, әмма күңелендә дөнья мәхәббәте юк иде. Күнендә Аллаһы Тәгалә юлына кырыгышар мең динар сарыф кыйлды. Вә Әбуҗаһил бай иде вә күңелендә дөнья мәхәббәте бар иде. Аллаһы Тәгалә юлына гомерендә бер данә тәсаддык кыйлмады. Кыйссасы мәшһүрдер. Сөләйман галәйһиссәлам үз кулы белән зәнбил эшләп, аның табышы белән ризыкланды. Аны мескиннәр белән бергә утырып ашады. Вә дәхи Сөләйман галәйһиссәлам: *«Лә янбәгый ли әхәдин бәгъди»*, — диде. Бу сүзе саранлык җәһәтеннән түгел иде. Вә бөхелгә дә дәлаләт кыйлмайдыр. Бәлки, Сөләйман галәйһиссәламнең бу сүзе халыкка гаять шәфкатеннәндер. Чөнки адәм дәүләткә вә рәхәткә чыдамайдыр. Һәлакәткә төшәдер, хәтта бәгъзеләр дөньяда вакытта һәлак буладыр. Бәс, Сөләйман галәйһиссәлам: «Миннән гайре кеше дәүләткә чыдамас», — дип белеп, шөйлә дога кыйлды.

Әй угыл, белгел ки, Аллаһы Тәгалә Сөләйман галәйһиссәламгә илһам кыйлды һәм таләп дөньяны күңеленә салды, бу эштә хикмәт бардыр. Вә Аллаһы Тәгаләдән ишарәт бардыр. Шөйлә ки Бәлкыйс каршыннан Бәлкыйснең илчеләре Сөләйман галәйһиссәламгә килделәр. Нәдилләр, вә хәзинәләр, вә җәваһир китерделәр. Сөләйман галәйһиссәлам: *«Әт-тәкәббуру галәт-тәкәббүру садакать»*, — дип, берсенә дә илтифат кыйлмады. Сөләйман галәйһиссәлам пәйгамбәр һәм падишаһ иде. Аллаһы Тәгалә аңа милек бирде, таки башка падишаһларның милкегә илтифат кылмагай. Ходадан гайрегә вә дөнья мәхәббәтенә күңеле мәел кылмагай. Вә дәхи Аллаһы Тәгалә пади-

шаһларга күрсәтмәкне вә падишаһларга тәгълимне ирадә кыйлды. Таки гайре падишаһлар вә дәүләт ияләре Сөләйман галәйһиссәламнән сабак алсыннар. Бөтен дөнья Сөләйман галәйһиссәламнең фәрманында иде. Адәмиләр, пәриләр вә җәмигъ җан иясе аңа мотыйг вә монкад иделәр. Вә мәгазалик Сөләйман галәйһиссәлам зәнбил ясап, аның белән ризыкланды. Зәгыйфә вә мескиннәр белән бергә ашады — тәвазыйглык кыйлды.

———

Мәшаихы суфиядән бер шәех бар иде. Көннәрдән бер көн ул шәехнең ханәкасенә мөсафирлардан бер җәмәгать килде. Шәех аларны гадәтләренчә икрам кыйлды. Бер көн бу шәех мөсафирлар белән вә яраннары белән утырганда: «Фарсы теле белән әгъләмеңез кайсыңыз булыр?» — диде. Мөсафирлардан берсе янә фарсыча: «Мин», — диде. Ягъни гарәпчә «ана». Шәех әйтте: «Мин» дигән сүзнең мәгънәсе авырлыкка дәлаләт кыйладыр. «Мин» диләр, таштан бер рат үлчәү таштыр», — диде. Аннан соң шәех торды. Һавага күтәрелде. Дәвер вә рәкыс кыйлды[1]. Ягъни, гавам истилахынча, «биеде» дигән сүздер.

Ерак түгел бер олуг күл бар иде. Күлгә сикерде. Күлдә су өстендә биеде, суга батмады. Хәтта аягы да чыланмады. Аннан соң шәех «мин галим торам» дигән мөсафирга ишарәт кыйлды. Ул мөсафир һәм күлдә рәкыс кыйлмага керде. Батты. Гарык була язды, шәех тартып чыгарды, әйтте: «Кайчан ки син «мин» дидең, мин белдем ки, син — авырсың. Мин булмас, фәкать таш булыр. Инде син «мин» булма, ләкин иҗтиһад кыйл. Салам бул. Таки сине су гарык кыйла алмас. *Вәл мураду мин ишәратиш-шәйх һәһүнә әннәһү лә яҗүзү ән ятәкәббәра әхәдүн лә фихәл вә лә фил-мәкаль*».

———

Көннәрдән бер көн шәех Хәсән Бәсри разыйаллаһу ганһу үзенең шәкертләре белән Рабига Гадәвияне зиярәт кыйлмага ирадә кыйлды. Аралары байтак ерак җир иде. Бераз мәсафәт баргач, шәех әйтте: «Әй яраннар, Рабига Гадәвия адәмнәрдән читләшкән бер хатындыр. Бәлки, хакаикъ тәҗридне белмәй торгандыр. Хатыннар нәкъ сател гакыйль була торган. Без аны зиярәт кыйлмага вә нәсыйхәт кыйлмага телимез. Ничек булыр икән?» — диде. Хәлбуки Рабига Гадәвия кәрамәт вә мөкәшәфәт иясе вәлиәтуллаһ бер хатын иде. Бәс, шәех әйткән сүз аңа мөнкәшиф[2] булды. Рабига Гадәвия торды. Зур капчык алды, үзенең капкасына асып куйды.

Аннан соң шәех килеп житте. Моны күрде. Рабига Гадәвия янына кермәде. Борылып кайтты. Яраннары әйттеләр: «Йә

---

[1] Рәкыс кыйлды — биеде.
[2] Мөнкәшиф — ачылган.

шәех, сиңа ни булды? Рабига янына кермәдең, капкасыннан кире кайттың?» — диделәр. Шәех әйтте: «Имди сөкүт кыйлыгыз. Без хата гөман кыйлдык. Хата сөйләштек. Сахибәтел кәрамәт, имеш: безгә бу капчык белән җавап бирде. Капчыкның мәгънәсе улдыр: гүяки Рабига әйтте: Һәркем үзенең капчыгын тикшермәк тиеш, үз хәлен белмәк тиеш», — диде.

Инде, әй угыл, бу кыйссадан хисса шулдыр ки: кешенең хәлен тикшермәгәйсең, үз хәлең белән булышкайсың.

---

Кайчан ки *«вә иннә минкүм иллә вәридуһә»* дигән аять назил булды, пәйгамбәр галәйһиссәлам: «Өммәтем утка керәчәк, имеш», — дип, гаять курку белән курыкты. Бизгәкле кебек булды. Бик каты елады, хәтта һушы китте. Сәхабәләре бу еламакның сәбәбен белмәделәр. «Йә Рәсүлуллаһ, бу еламакның сәбәбе нидер?» — диделәр. Пәйгамбәр галәйһиссәлам, кайгы вә хәсрәте күплек сәбәпле, һичбер җавапка кадир булмады.

Бу вакыйганы хәзрәти Фатыйма разыйаллаһу ганһуга хәбәр ирделәр. Хәзрәти Фатыйма разыйаллаһу ганһу дәрхаль торды. Киенеп, елап, Рәсүлуллаһ катына килде. Күрде: Рәсүлуллаһның һушы китеп ятыр. Гаять каты елады. Йөзе саргайды, атасының хәлен белмәде. Кайчан ки пәйгамбәр галәйһиссәлам күтәрелде, Фатыйма разыйаллаһу ганһу галәйһиссәлам әйтте: «Әй күземнең нуры атам, ник болай еларсан? Сиңа ни мосибәт иреште ки, шөйлә һушың китеп ятарсың, Рәсүлуллаһ?» — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Бүген дустым Җәбраил *«вә иллә минкүм вәридуһә»* дип, бер аять индерде. Йә Фатыйма, еламакымның сәбәбе будыр. Вә хасрәтәһ өммәтемә ки, азмы шәехләр ут эчендә *«вә әшбабәтәһ»* дип тәфәҗҗагъ кыйлырлар. Азмы егетләр тәмугта *«вә әшбабәтәһ»* дип нида кыйлырлар. Азмы хатыннар тәмугта *«вә әфзыйхәтәһ»* дип кычкырдылар. Өммәтләремнең йөзе каралды, аркалары бөгелде. Тәннәренә ут тоташты. Кечеләре олугларын хөрмәтләмәделәр. Олуглары кечеләренә рәхим-шәфкать итмәделәр. Хатыннарын яшермәделәр», — диде.

Бәс, Фатыйма разыйаллаһу ганһу бу сүзне ишетте, каты елады. Аяк үзрә торды. Әбү Бәкер разыйаллаһу ганһуга әйтте: «Әй күрше! Сиңа хаҗәтем бардыр ки, кыямәт көнендә атам өммәтенең картларына җаныңны фида кыйлгайсың». Гали разыйаллаһу ганһуга әйтте: «Йә Гали, сиңа хаҗәтем бардыр ки, кыямәт көнендә атам өммәтенең егетләренә җаныңны фида кыйлгайсың». Вә Хәсән, Хөсәен разыйаллаһу ганһуга әйтте: «Әй нур дидаларым, сезгә хаҗәтем бардыр ки, кыямәт көнендә атам өммәтенең балаларына нәфәсеңезне фида кыйлгайсыз. Вә кыямәт көнендә мин дәхи атам өммәтенең хатыннарына җанымны

фида кыйламын. Таки Мөхәммәд галәйһиссәламнең өммәте ул көндә җәмигъ куркулардан сәламәт булсалар икән», — диде.

Вә шул хәлдә Җәбраил галәйһиссәлам назил булды, әйтте: «Йә Мөхәммәд, сиңа сөенеч китердем. Аллаһы Тәгалә сиңа сәлам укыды. Көенмәсен! Вә Фатыймага дәхи әйт ки: көенмәсен!» — диде. Вә Аллаһы Тәгалә әйтте: «Кыямәт көнендә мин Фатыйма сөйгән эшне кыйлырмын. Вә Фатыйма ихтыяр иткән эшне кыйлырмын. Барчасын Фатыймага багышлармын», — диде.

Бәс, әй гөнаһлы шәехләр! Әй нәфсеңезгә золымлык кыйлучы егетләр! Вай, явыз вә залимә хатыннар! Бу гыйсъяныңыз белән мөселман исемен күтәрәсез. Мөхәммәд галәйһиссәламнән оялмайсызмы? Вә бу тыйгъяныңыз белән Аллаһы Тәгаләдән курыкмайсызмы? Тәхкыйк, Рәсүлуллаһтан оялыңыз! Вә Аллаһы Тәгаләдән куркыңыз! Вә нәсух тәүбәсене кыйлыңыз. Шаять ки, фәләх табарсызлар. Һич шик вә шөбһәсез берәү Аллаһы Тәгаләдән курыкмаса, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән һәм насыйбы юктыр.

Нитәкки Дауд галәйһиссәлам бер нәвыг зилләт белән мөбтәля булды ки, ул зилләт, сезнең каршыңызда иң кечкенә зилләттер. Каты вә озак егълады. Хәтта күз яше төшкән җирдән үләннәр вә яфраклар үсте. Сусаганда да бер эчемлек су эчмәде, күз яшеннән кадәхләр тутырды. Әй гасый бәндә! Чиләкләп-чиләкләп хәмер эчәсең, күзеңнән бер тамчы яшь чыкмас. Кыйлган гөнаһыңа нәдамәт тартмайсың. Нәфеседә кыйлган золымлыгыңдай аһ димәйсең. Гөнаһың башыңнан ашты. Күрмәймесең, Дауд галәйһиссәлам, пәйгамбәр, вә мәгъсум вә гөнаһыннан пакь була торып, зилләте исенә төшкән саен, һушы китеп йөзе белән җиргә егылыр иде. Йөзе белән җиргә озак ятып, йөзенең тиресе җиргә ябышыр иде. Башын күтәрсә, йөзенең тиресе җиргә ябышып кубып калыр иде. Күзеннән яшь, йөзеннән кан агар иде. Әй гасый вә җафи мөэмин! Бу кадәр гыйсъянга чумдың, күзеңнән катрә яшь чыкмай: күңелең таштан каты, имеш! Бу гыйбрәтләр ташка тисә, таш та кургашын булып өрер иде. Вә күңелең агачтан каты, имеш! Бу нәсыйхәтләр агачка әйтелсә, агач та, бөгелеп, яңадан җиргә керер иде.

---

Әй угыл, белгел ки, кем дә кем дөньяда «мин» дип сөйләшсә, вә галим вә белекле адәмнәрдән алда сөйләшсә, кыямәт көнендә ул кеше самитлардан вә сакитлардан[1] булыр. Ягъни сөйләшергә теле булмас. Әгәр дә берәү дөньяда сакиннардан булса, кеше сөйләшкәндә тыңлап торучылардан булса, әлбәттә, кыямәт көнендә фәсыйхлардан вә натыйклардан[2] булса кирәк.

[1] **Самитлардан вә сакитлардан** — телсезләрдән һәм дәшмәүчеләрдән.

[2] **Фәсыйхлардан вә натыйклардан** — бик матур, ягымлы сөйләүчеләрдән.

Мөхәммәд галәйһиссәлам дөньяда 40 яшькә кадәр һич сөйләшмәде. Даимел фикер вә даимел сөкүт иде. Иң зур кайгы килгән көндә: «Өммәти! Өммәти! Аллаһүммәгъфирли өммәти би әсриһә», — дисә кирәк. Вә башка пәйгамбәрләр, башларын бөгеп самит булганнары хәлдә, үзләренең нәҗатен теләсәләр кирәк.

Әй угыл, монда хикмәт шулдыр ки: дөнья эшләре һәммәсе ахирәт эшләренә мөнакыйздыр. Дөнья эшләре ахирәттә һәммәсе мәгъкус булып табылыр. Күрмәсмесең, габидлар вә заһидларның хәлләре дөньяда Аллаһы Тәгаләнең хәвефеннән егъламак, көенмәк вә әнваг бәла белән мөбтәля булмак. Вә фәкыйрьлек зинданында мәхбүсләр иде. Әмма җәннәттә эшләре вә шөгыльләре җәннәт нигъмәтләреннән вә шәрабларыннан әкел вә шәреб. Вә кулларында алтын кадәхләр. Гыйльман вә вилдан хезмәтләрендә. Әнваг сәмгъ колакларында булып, касырларына мөшарәфә вә хур кызларына мөбашәрәдә булсалар кирәк. Ушандак фасикларның вә фаҗирларның хәлләре дөньяда башәр табәкале йортларында ашамак, эчмәк, уйнамак, көлмәк, хәмер касәләре кулларында, рәкыс вә сәмгъ кыйлмакта. Вә күп әүкатлары — әкел, шәреб, җимаг иде. Әлбәттә, кыямәт көнендә тәмугта төрле газапта: *«Вавайлә! Вахәсрәтә!»* — дип, утта яна. *«Әхриҗнә минһа!»* — дип кычкырып янырлар. *«Зиднәһүм газабән фәүкаль газаб»*, — дип нида ишетә торырлар. *Нәгузе биллаһ мин залик.*

———

Пәйгамбәр галәйһиссәлам бер җирдә: «Фәкыйрьлек — горурлыгым» вә икенче бер җирдә: «Фәкыйрьлек кяферлеккә якын», — диде. Монда ни хикмәт бар иде?

Җавап. Белгел ки, әй угыл, фәкыйрьлек бик хур, хакыйрь нәрсә түгелдер. Бәлки газиз вә олуг вә мөфтәхир нәрсәдер. Фәкыйрьнең хәлен вә маһиятен бәян кыйлаем. Таки колагыңны ачып, зиһенеңне җыеп тыңлап торгайсын. Кайчан ки Аллаһы Тәгалә күкләрне вә җирләрне яратты, аннан соң әхсән сурәт үзрә вә әгъля һиммәт үзрә бер кош яратты. Вә ул кошны «Фәкырь» дип тәсмия кыйлды. Аннан соң ул кошка әйтте: «Бар, барча галәмне тәваф кыйл! Үзеңә торырга урын эзлә. Вә үзеңә карин эзлә. Гыйззәтем вә җәлялем белән касәм кыйламын ки, бер җирдә дә сине тотмамын, мәгәр минем мәхлукатымнан кемне яратсаң, анда торырсың. Син кемгә иптәш булсаң, вә кем сиңа мәскән булса, ул кеше миңа җәмигъ мәхлукаттан сәвекледер», — диде. Кайчан ки Фәкырь очмага теләде, Гарше нида кыйлды: «Әй Фәкырь, миндә тор!» — диде. Фәкырь әйтте: «Син — мөшәбәһәнең шөбһәсе белән мәнһамсың. Ягъни мөшәбәһә таифәсе *«әррахману галә гаршистәвә»*дә шик тоттылар. Шул сәбәпле син мөттәһәмсең, минем синдә кара-

рым булмас», — диде. Көрсигә тәваф кыйлды. Көрси әйтте: «Миндә тор.» Фәкырь әйтте: *«Вәсигә курсийүһүс-сәмавәти вәл-әрз»* дигән сүз белән син мөфтәхир вә мөтәккәбирсең. Син моның белән җәмигъ мәхлукат каршында тәфәххер кыйласың. Синең белән тормамын».

Аннан соң оҗмахка китте. Оҗмах нида кыйлды: «Әй Фәкырь! Мин — әүлияуллаһлар мәсканемен! Бездә берәр сәгать кунак бул. Әлван нигъмәт белән зыяфәт кыйлаек». Фәкырь әйтте: «Син һәм үзеңнең хурларың, вилдан-гыйльманнарың белән, мәсрур вә касырларың, вә әлван хөлләләрең, вә җимешләрең белән мәгърурсың. Минем мәсрурлар вә мәгърурлар белән карарым юктыр». Кояш нида кыйлды: «Миндә тор!» Фәкырь әйтте: «Синең дә бер урында карарың юк. Үз нәфесең белән мәшрикътан мәгърибкә сәерең белән мәшгульсең, синең белән тормаймын».

Аннан җиргә иңде, җир әйтте: «Миндә тор!» Фәкырь әйтте: «Син — хәсрәт урыны вә михнәт сарае вә мәетләр бишегесең. Синдә тормам». Аннан Адәм галәйһиссәламгә килде. Адәм әйтте: «Син миңа рәфикъ булырга муафыйксың. Миннән яхшы мәскән булмас сиңа». Фәкырь әйтте: «Йә Аллаһ! Син *«Иннә Аллаһәстафә адәм»* таҗы белән мөтавиҗсың. *«Сөммәҗтәбиһи Раббә фәһди»* ридасе белән мөтәрридсең. Син болар белән ифтихар кыйласың. Синең белән дә карарым булмас.

Нух галәйһиссәламгә килде, Нух әйтте: «Мәсканең миндә булсын». Фәкырь әйтте: «Син мәхлукатка рәхим кыйлсаң, *рабби ля тәзәр галәл әрзый минәл-кяфиринә дәйәра*, дип, Аллаһы Тәгаләнең мәхлукатына һәлаклек белән дога кыйлмас идең. Синең догаң сәбәпле, кяферләрдән башка ничә хайваннар һәлак булды. Синдә тормам».

Ибраһим галәйһиссәламгә килде. Ибраһим галәйһиссәлам әйтте: «Миндә тор». Фәкырь әйтте: «Син һәм йолдызга *һәзә Рабби* дип әйтмәкең белән мөтәшәкиккләргә охшадың». Муса галәйһиссәламгә килде. Муса галәйһиссәлам әйтте: «Йә Фәкырь, минем белән тор. Мин кечкенә вакытымда фиргавеннең янагына суктым. Олуг хәлдә терек һава кыйлдым. Габага вә гасага разый булдым». Фәкырь әйтте: «Син *Рабби әрини әнзур илэйкә*, диден. Руэять таләп кыйлдың», — диде.

Аннан Мөхәммәд галәйһиссәламгә килде. Җәмалын күрде. Яратты. Тормага разый булды. Күрде: җисеме — мөтәвазигъ[1]. Калебе — кибр вә гоҗебтән саф. Теле — закир. Рухы — мәхәббәт вә мүәддәт, могҗиза вә кәрамәт белән мөзәйян. Кулы — сәхи. Теле — фәсих. Күкрәге кинә вә шиктән пакь. Рәфт вә рәхмәт белән мәмлүдер. Фәкырь әйтте: «Шаять, миңа

[1] Мөтәвазигъ — түбәнчелекле, эреләнмәүче.

мәскән бу булгай», — диде. Синең хакында *«ләү ләкә ләү ләк мә халәкътул әфләк»* дип әйтелгән иде. Син шул кешеме?» — диде. Мөхәммәд галәйһиссәлам әйтте: «Бәли, мин шул кешемен», — диде. Бәс, Фәкырь Рәсүлуллаһ алдына төште, әйтте: «Йә Рәсүлуллаһ, миңа ни мәслихәт? Таки башкалардан хәлас булып, синдә торыр идем».

---

Исфаһан шәһәрендә кызыл мал белән сату итүче Гантәр исемле бер кеше бар иде. Аның гадәте шул иде ки: ел саен иң әүвәл җиләк-җимеш чыккач та, алып кайтып, җәмәгатенә тәнавел кыйлдырыр иде. Көннәрдән бер көн яңа карбыз чыкканда, карбыз сатып алды. «Өйгә илтеп бир», — дип, хезмәтчесенә биреп җибәрде. Бәс, кич булгач, Гантәр кайтты. Җәмәгате белән утырды: «Кайда, карбызны китерегез, ашаек», — диде. Җәмәгате әйтте: «Без инде ашап бетердек аны», — диде. Гантәр әйтте: «Ашасаңыз, ярар юк. Кайда, миңа өлеш калдыргансыз, китерегез», — диде. Җәмәгате әйтте: «Калдырырга оныттык. Инде юк, бетте», — диде. Гантәр әйтте: «Көн саен бергә ашыймыз, бергә эчәмез, бергә торамыз, мине оныттыгызмы?! Үлгәч ничек булырсыз икән?» — дип, күңеленә үлем куркуы төште. Күңеленнән әйтте: «Мин аларны ашатамын-эчертәмен. Алар өчен хәлялне-харамны карамаймын, ант итәмен, ялган сөйләшәмен. Алар мине үлмәс борын оныттылар. Ах, минем хәлем үлгәч ни булыр?» — диде.

Икенче көн булды. Гантәр базарга чыкты. Бер карбыз сатып алды. Өйгә үзе алып кайтты. Җәмәгате белән карбыз ашамага утырдылар. Бәс, Гантәр җәмәгате белән ачык йөз, көләкөлә сөйләшер. «Менә гаҗәп! Кичә сез мине карбызсыз калдырдыңыз. Менә бүген рәхәтләнеп бергә ашыймыз», — диде. Әмма күңелендә ни ният барын белдермәде. Аннан соң хатынына әйтте: «Җаным, синә мәхәббәтем бик зур. Көн дә кибеттә. Көн дә кибеттә. Һичбер рәхәтләнеп бергә утырып булмай. Шөгылем бик күп. Мин бүген ишеттем: фәлән кеше җимеш бакчасы сата, имеш. Бакчасы бик олуг, бик һәйбәт. Син, бар акчаңны җыеп, вә һәм алтын-көмештән ни җиһазың бардыр, сатып, миңа карыз бир. Аннан соң кибетемне дә сатармын. Барын бергә кушып, шул бакчаны алырмыз. Бакчадан килгән файда белән рәхәт тереклек итәр идек», — диде. Хатын бу хәрәкәтне ишеткәч, ягъни ашамак-эчмәк вә гыйш-гыйшрәт сүзләрен ишетеп, бик шат булды. Әйтте: «Мин карыз бирмим сиңа, бәлки барча җиһазымны сиңа һибә кыйлаем», — диде.

Бәс, болар кабз-и-шәргый белән хатыннан җиһазыны кабз кыйлды. Вә ул бакчаны 20 меңгә сатып алды. Аннан соң базарга чыгып нида кыйлды: «Җимеш агачы кирәк булса, минем бакчамнан һәркем барып төпләп алсын: мин аны мөселман-

нарга вакыф кыйлдым», — диде. Җимеш агачы кирәк кешеләр, барып, һәммәсен төпләп алдылар. Бары коры җире генә калды. Аннан соң Гантәр казыйга барып әйтте: «Ул бакча урынын мин мөселманнарга каберлеккә һибә кыйлдым, ул бер каберстан булсын», — диде. Халән Исфаһанда «Гантәр мәкъбәрәсе» дип мәгълүмдер. Аннан соң хатын бу хәбәрне ишеткәч, шикаять кыйлды, егълады. Иренә әйтте: «Ник болай миңа золымлык кыйлдың?» — диде. Гантәр әйтте: «Мин сиңа һичбер золымлык кыйлмадым. Ләкин син мине, үлгәч, онытырсың дип курыктым. Чөнки мин терек вакытта, карбыз ашаганда оныттың. Мин үлгәч, кайчан син мине искә төшерерсең? Хосусән гайре иргә барсаң», — диде.

Аннан соң бер ел үтмәде, Гантәр вафат булды. Бәгъзе дуслары Гантәрне төшендә күрде ки: Гантәр оҗмахта киңлеге мең фәрсах бер сарай эчендә утырыр. Сөттән, балдан, зәнҗәбилдән, сәлсәбилдән[1] чишмәләре агып торыр.

Дусты сорады: «Ни сәбәпле бу кадәр дәрәҗәгә ирештең, йә Гантәр?» — диде. Гантәр әйтте: «Дөньядагы бакчамны каберлеккә вакыф кыйлмыш идем. Шул сәбәпле Аллаһы Тәгалә бу дәрәҗәне бирде», — диде. Инде, әй угыл, һәркем, тугыры гакылы булса, Гантәр кебек үзенә изгелек хәзерләсен! Һәркем, гафил вә җаһил булса, гайреләр өчен мал хәзерләп калдырсын! Бәшәр табәкале[2] таш уеп калдырсын! Үзе вәбалын[3] күрсен. *Фәнәкви биһә җибәһәһүм вә җунүбәһүм вә зуһураһүм һәзә мә кәнәзтүм ли әнфүсикүм фәзуку мә күнтүм тәкнизүн.*

Аллаһы Тәгалә — Вахид, Әхәд, Самат, Фәрд вә бәрдер. Әмма *«фарикъ фил җәннәт вә фарикъ фис-сәгыйрь»* дип, ике юл күрсәтте, хикмәт нидер?

Әй угыл, җавап будыр ки, мәсәлән, берәү Кәгъбәгә бармак теләсә, кайдан якынрак, аннан барадыр. Аннан соң Кәгъбәгә бара торган дүрт юл бар. Дүртесе Кәгъбәнең дүрт тарафында. Мәдинәдән бара торган юл «Зөлхалифә» атала; Шамнан — «Хаҗифә»; Ямәннән — «Ялмәләм»; Гыйрактан «Затгарк» аталадыр. Ушандак Рәсүлуллаһка ки ул шәригать сахибедер, бармак теләсәң, дүрт юлның берсе белән бармак лаземдер. Ул дүрт юл: имам Әгъзам юлы; имам Шәфигый юлы; имам Мәлик юлы; имам Әхмәд бин Хәнбәл юлыдыр.

Бәс, берәү ошбу дүрт юлның берсенә тәмәссек кыйлса, шул юл белән барса, бер юлдан икенче юлга күчмәсә, әлбәттә, ул кеше Рәсүлуллаһка васыйл булыр. Әгәр дә ошбу дүрт имамны хак дип игътикад кыйлмаса, ул кеше Рәсүлуллаһка васыйл бул-

---

[1] Сәлсәбилдән — оҗмах чишмәләреннән.
[2] Бәшәр табәкале — халык катлауларыныкы.
[3] Вәбалын — нәтиҗәсен, гөнаһын.

мас. Бәс, *«фарикъ фис сәгыйр»* җөмләсеннәндер. Инде берәү мөэмин мөхлис булса, аңа лаземдер ки, мөтәгассыйб вә мөхалифә[1] булмагай. Мөттәфикъ вә муафыйк булгай. Чөнки иттифак иҗтимагны мөстәлзәмдер. Вә ихтилаф — ифтиракны мөстәлзәмдер вә мүристер. Күрмәсмесең, «шәҗәрәтел хилаф» дигән бер агач — сәмәрәсе юктыр; исеме хилаф булган өчен, сәмәрәсе булмады. Бәс, ошбу ишарәттер. Гүяки Аллаһы Тәгалә әйтте: «Әй бәндәм, хилаф булма! Таки рәхмәтемнең сәмәрәсеннән мәхрүм булмагайсың. Дүрт имамны тәсдыйк кыйл. Таки пәйгамбәрем Мөхәммәдкә васыйл булгайсың. Вә фарикъ фил җәннәт зөмрәсеннән булгайсың», — диде.

---

Инде, әй угыл, мәзһәбтән мәзһәбкә күчкән кешенең мисале[2] «Кәлилә, Димнә» китабында зикер кыйлынган эт мисалендәдер ки. Бер шәһәрдә бер эт бар иде. Ул этнең гадәте бу иде: бер җирдә тобыл, ягъни барабан сугылса, барабан тавышын ишетеп, анда барыр иде. Уйлар иде ки: анда туй мәҗлесе бардыр. Халык моны белде дә бу эткә бер хәйлә төзеделәр: шарт иттеләр ки, бер карьядә дә барабан сукмакчы булдылар.

Бәс, ул эт тобыл сугылган карьягә килсә, янә әүвәлге карьядә сукмакка шарт иттеләр. Шулай итеп, эт ике карья арасында тик йөрде. Тобыл сугылган карьягә килсә, монда туктыйлар, икенче карьядә тобыл суга башлыйлар. Эт ул карьягә китә. Эт анда барып җитсә, бу карьядә суга башлыйлар. Эт монда килә. Шулай итә-торгач, бу эт тәгамга ачлыктан вә суга сусаудан һәлак булды.

Бәс, ушандактыр ки, әй угыл, бер кеше мәзһәбтән мәзһәбкә күчсә, хәле шөйләдер. Вә дәхи үз мәзһәбенең сәхтенә игътикад кыйлмаган кешенең вә пәйгамбәр сөннәтен вә Рәсүлуллаһ шәригатен мөхафәзә[3] кыйлмаенча, низам шәригатен тоткан кешеләрнең хәле һәм ушандактыр. Әлгаязе билләһ, ул кемсәнә ислам нигъмәтенә ач вә рәхмәт суына сусап митәләсә кирәктер. Мәзһәбтән мәзһәбкә күчкән кемсәләрнең хәле шөйләдер, бәян кыйлынды. Ислам шәригатенннән низам шәригатенә күчкән адәмнәрнең хәле ничек булыр?

---

Әй угыл, белгел ки, дүрт имам — дүрт рөкендер. Ягъни пәйгамбәр галәйһиссәлам — гыйлем шәһәредер. Гали разыйаллаһу ганһу — капкасыдыр. *«Инна мәдинәтул гыйльмун, Галийун бабуһә»* диде пәйгамбәр галәйһиссәлам. Вә бу дүрт имам — ул шәһәрнең дүрт почмагы мәнзилендәдер. Кайчан ки

---

[1] Мөтәгассыйб вә мөхалифә — фанатик һәм каршы торучы.
[2] Мисале — үрнәге.
[3] Мөхафәзә — яклау, саклау.

пәйгамбәр галәйһиссәлам ахирәт мәзрагасына, ягъни ахирәт игелеген игә торган җиргә, ки дөньядыр, гыйлем вә хикмәт орлыгын китерде, анда үзенең дүрт вәрасәсен күрде ки, әл-голяма — вәрасәил әнбиядер. Аларда хикмәтнең сәмәрәсен *«ли тәфкаһу фид дин»* кыйсмәте буенча, дүрткә тәкъсим кыйлып бирде. Бер кыйсме имам Әгъзамга тиде. Бер кыйсме имам Шәфигыйга тиде. Бер кыйсме — имам Маликкә. Вә бер кыйсме имам Әхмәд бин Хәнбәлгә тиде. Бәс, кем дә кем ошбу дүрт почмакның берсенә, ягъни дүрт мәзһәбнең берсенә тәмәссек кыйлса, Рәсүлуллаһка васыйл булыр. Дүрт тарик дүртесе дә Коръәннән ахаз кылынмыштыр. Аллаһы Тәгалә Коръәннән үзе васыйф кыйлды, *вә ля ратбун вә лә ябисун иллә фи китабин мүбин*, диде.

———

Көннәрдән бер көн Рәсүлуллаһ галәйһиссәлам сәхабәләренә бу аятьнең мәгънәсен тәфсир кыйлганда, Әбүҗаһил ишетте. Әйтте: «Йә Мөхәммәд, *вә ля ратбун вә лә ябисун иллә фи китабин мүбин*, дип дәгъва кыйласың. Коръәнендә минем мөхсиннәрем вә синең мөхсиннәрең мәзкүрме соң?» — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Бәли, йә Әбүҗаһил, Аллаһы Тәгалә синең хакында, *кәшәҗәрәтин хабисәтин мин фәукыйль әрз*, диде. Вә минем мөхсиннәрем хакында, *кәшәҗәрәтин тайибәтин әсълүһә сябитүн вә фәргуһә фис-сәмаэи түвәти укүләһә күллә хинин биизни Раббиһә вә ядрибүллаһүл әмсәлә линнәс*, диде.

*Вә әммәт тарику иләллаһи Тәгалә кәсиран вә габидүн гаҗизүн ган имсәкит тарикый бишәрәитыйһә фәйәҗүзү ән ясыйлә иләллаһи би тарикыйн вәхидин вә би тарикайни әү әксәри мин зәликәт турукый вәлләзи лә йүхса гадәдүһә кәс-саләти вәз-зәкәти вәс-сауми вәл-хаҗҗи вәл-җиһәди вә кыйраъәтил Коръәни вәт-тәсбихи вәс сәхаэи вәл вафаъи вә гайра зәликә мин әнвәгыйль хайрати фә йәҗүзү ән йәгъфируллаһү Тәгалә ләһү би сәбәбин мин зәликәл әсбәби* («Әнисел җәлис»). Мәгънәсе: әмма Аллаһы Тәгаләгә юл күптер, ә бәндә юлның шартларына туры килгән рәвештә барудан гаҗиз. Шул сәбәпле Аллаһы Тәгаләгә бер юлдан, ике юлдан, яки күбрәк юллардан ирешү җаиз. Бу юллар сансыз күптер, мәсәлән, намаз, зәкят, ураза, хаҗ, җиһад, кыйраәти Коръән, тәсбих, юмартлык, вәгъдәдә тору һәм башка изгелекләр. Шушы сәбәпләрнең берсе аркасында, Аллаһы Тәгалә аның гөнаһларын мәгъфирәте белән гафу итүе җаиз.

———

Шәех Әхмәд Газали разыйаллаһу ганһу бер заһид вә мөттәкый адәм иде. Утыз ел ахшам таһарәте белән иртә намазын укыды. Кичләрендә каим булып, көндезләре руза тотып, 70 ел

Аллаhы Тәгаләгә гыйбадәт кыйлды. 360 мөриде бар иде. hәрбер мөриде сахиб кәрамәт иде. Ахыр гомерендә адәмиләрдән гозләт[1] кыйлып, бер мөриде белән бер тауда саумәгада торыр иде.

Көннәрдән бер көн шәех Әхмәд Газалигә сырхау тиде. Җиде көн авырды. Көннән-көн сырхавы артты, хәле зәгыйфьләнде. Бу авырган заманда көн саен саумәгасының почмагыннан: *«Әлвәйлу сүммәл вәйлү ләкә, йә Әхмәд»*, — дип тавыш ишетеләр иде. Беркөнне бу шәех мөриденә әйтте: «Шәhәрдә минем күршем бер яhүд бар иде. Бар, шул яhүдне монда алып кил, миндә хакы калган булса кирәк. Бәхиллек сораем. Вә илләмин hәлак булсам кирәк», — диде. Бу сүзне әйтеп бетерде, теле hәм тотылды. Артык сөйләшергә кодрәте булмады.

Шул хәлдә мөрид күрде: шәехнең йөзендә ике кара нокта пәйда булды. Бу ике кара нокта hаман җәелде. Хәтта шәехнең йөзе кап-кара булды. Аннан соң мөрид кычкырып еглады. «Вә вәйлә вә мөсибәтүh, шәехнең хәле шөйлә булды. Мөриднең хәле нитәк булса кирәк?» — дип, киемен ертып еглады. Хәтта куркуыннан каберстанга качты. Йөзен анасының кабеpенә куеп: «Вә әмаh, Аллаhы Тәгаләнең газабыннан кайда качаем?! Вә әбаh, Аллаhы Тәгаләнең гокубәтеннән нитәк хәлас булаем?» — дип озак еглады. Моннан соң үзенә-үзе әйтте: «Инде болай еглап эш булмас. Кайтып, халык күрмәстән элек вә халыкка рисвай булмастай элгәре шәехемне дәфен кылаем», — дип, шәех янына кайтты. Күрде: шәех өстеннән hавага нур чыгып торыр. Якынрак килеп күрде: бу нур шәехнең йөзеннән чыгар, имеш.

Бәс, мөрид Аллаhы Тәгаләгә хәмед итте. Шөкер кыйлды вә шәехне госел кыйлды. Кәфенләде. Дәфенләде. Вә дәфен кыйлган вакытта, ләхет эчендә шәехнең йөзен ачып карады. Шәех мөриднең йөзенә карап көлде, әйтте: «Әй углым! Мин үлмәдем, бәлки дөньядан ахирәткә күчтем», — диде.

Бәс, мөрид хикәятен кыйлды ки: «Беркөн шәехемезне төшемдә күрдем. Холәфаи рәшидиннәр белән утырыр. Әйттем, йә шәех, йөзеңнең каралуына ни сәбәп иде? Халән әсхаб Рәсүлуллаh белән утырасың. Дәхи дә ләхеткә куйганда, йөзеңдә нур балкып торыр иде. Анда ни хикмәт бар иде? Шәех әйтте, йә угыл, кайчан ки әҗәлем якын булды, гамәл дәфтәремне гарыз кыйлдылар. Дәфтәрдә күрдем: харамнан ике дирhәм истигъмаль кыйлырмын. Күршемдә бер яhүд бар иде, аның хакы, имеш. Шул ике дирhәм харамнан йөземә ике нокта тамды. Йөземнең каралыгы моннандыр, — диде. — Әмма йөземдә нур балкуының хикмәте пәйгамбәр галәйhиссәламгә әйткән сала-

---

[1] **Гозләт** — аерылу, читләшү.

ватым сәбәпле иде. Гыйбадәт арасында күп салават китермеш идем. Әмма сәхабәләр белән утырмакымның сәбәбе мөселманнарга кыйлган нәсыйхәтем вә вәгазем сәбәпледер. Бәс, гокуб явыз галәм сәбәпле вә кәрамәт галәмәте Аллаһы Тәгаләнең фазылыннан иде», — дип, шәех сүзен тәмам кыйлды.

---

*Кыямәт вәгазе.* Әй угыл! Белгел ки, кыямәт көнендә *«вә әмәнна һәзәл яумә әййүһәл-мөҗримун»* нидасыннан соң, җәннәт әһеле — җәннәткә вә тәмуг әһле тәмугка җибәрелеп, хисап тәмам булгач, 50 мең елдан соң хәзрәти Җәбраил Аллаһы Тәгаләгә мөнәҗәт кыйлыр, әйтер: «Илаһи, Мөхәммәднең җәмалына мөштак булдым[1]. Изен бир: барып күрешәем». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Бар, изен бирдем, күреш». Җәбраил әйтер: «Илаһи, минем бер дә һәдиям юктыр. Буш кул нәтәк бараем?» Аллаһы Тәгалә әйтер: «Бүләк алып бар. Ләкин Мөхәммәдкә мәхбүбрәк вә сәвеклерәк нәрсә алып бар». Җәбраил әйтер: «Илаһи, Мөхәммәдкә ни-нәрсә мәхбүбтер, белмәймен?». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Аның гөнаһлы өммәтләре тәмугта калмышлардыр. Тәмугка бар. Анда иманнарыны күрерсең. Аннан Мөхәммәд янына бар. Әйт, йә Мөхәммәд, сиңа сөенеч хәбәр алып килдем, вә сиңа һәдиям бар, әгәр эстәсәң китерәем, дигәйсең. Бәс, Мөхәммәд әйтер, ниндәен хәбәр, диип әйтер. Гөнаһ кәбирә ияләреннән синең өммәтләрең халән тәмугтадыр. Әгәр Мөхәммәд эстәсә, яңадан тәмугка бар, өммәтләрен тәмугтан алып чык», — дияр.

Бәс, аннан Җәбраил тәмугка барыр. Тәмугта бер җәмагатьне күрер ки, күмер кеби кап-кара янмышлар. Зәнҗерләр белән багланмышлар. Ул җәмагать арасыннан берсен чакырып чыгарыр. Күрер ки: йөзе ак, ике кулы, ике аягы ак. Җәбраил аның хәленнән сорашыр: «Син кайсы пәйгамбәр өммәтеннәнсең?». Ул кеше әйтер: «Инде исемен оныттым, кайсы пәйгамбәр дип әйтергә белмәймен», — дип, сәҗдәгә китәр. Җәбраилнең аягын үбәр, әйтер: «Йә Габдулла, миңа шәфәгать кыйлсана! Аллаһы Тәгаләдән шәфкать сорасана. Газапка такать торыр хәлем юк». Җәбраил әйтер: «Син пәйгамбәрләрнең исемен белмәйсең, нәтәк шәфәгать кыйлаем. Алай булса әйт соң, Аллаһы Тәгаләгә ни кәйфияттә гыйбадәт кыйлдың иде?» Ул кеше әйтер: «Елда 30 көн руза тоттым. Көн дә биш намаз укыдым». Җәбраил әйтер: «Мөхәммәд гыйбадәтедер. Алайса сез — Мөхәммәд өммәтеннәнсез». Бәс, бу кеше, Мөхәммәд исемен ишеткәч: «Йә Мөхәммәд, аһ, ва шәфигаһ!» — дип нида кыйлыр. Җәбраил әйтер: «Инде пәйгамбәреңнең исемен онытма. Мин Мөхәммәдкә барып хәбәр бирәем, шәфәгать кыйлгай». Аннан Җәбра-

---

[1] Мөштак булдым — сагындым.

ил җәннәткә килер. Күрер ки: Мөхәммәд галәйһиссәлам әһеле вә әсхабы белән тәнәгъгымдә утырырлар. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтер: «Йә Җәбраил, ни һәдия белән килдең?» Җәбраил әйтер: «Йә Мөхәммәд, һәдия белән килмәдем. Ләкин өммәтеңнән хәбәр китердем. Бәс, монда тәнәгъгымдәсең. Әмма өммәтләрең, тәмугта янып, күмер булмышлар».

Бәс, пәйгамбәр галәйһиссәлам бу сүзне ишеткәч, әсхабе белән барчасы җәннәттән чыгарлар. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтер: «Таки өммәтем ярлыканмай торып, оҗмахка кермәем». Аннан соң Җәбраил янә тәмугка килер. Җәһәннәм табәкаларында өммәтне эзләр. Табалмас. Мөнәҗәт кыйлыр: «Илаһи йа Рабби, Мөхәммәд янына ни йөзем белән бараем? Җәһәннәмдә ул өммәтне тапмадым, хәйран калдым». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Йә Җәбраил! Ул өммәтне Гай дигән чокырда эзлә, тәрикессалятлар урынидыр. Анда булыр».

Бәс, Җәбраил җәһәннәмгә килер. Гай чокырын эзләп табар. Ул өммәтне табар. Ул бәндә: «Йә Мәннан! Йә Мәннан!» — дип нида кыйлыр. Нида кыйлган саен, уттан качар. Җәбраил әйтер: «Йә гасый, әйдә минем белән чык. Оҗмахка алып бараем». Ул бәндә әйтер: «Мине монда калдыр. Моннан чыкмаймын. Бу урынга разыймын». Җәбраил әйтер: «Ут газабына ничек сабыр кыйласың?» Ул бәндә әйтер: «Ут газабы каты иде, Аллаһы Тәгалә исемен зикер кыйлмага кодрәтем юк вакытта. Хәлән аның исемен зикер кыйлдым, уттан курыкмаймын». Җәбраил әйтер: «Анда сәедең Мөхәммәд көтеп торыр». Бәндә әйтер: «Ва сәйда! Ва шәүкаһ али Мөхәммәд!» Ләкин йөзем караңгылы сәбәпле, Мөхәммәдкә карамага хәҗаләт кыйламын».

Бәс, Җәбраил аны тәмугтан алып чыгар. Пәйгамбәр галәйһиссәлам алдына китерер. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтер: «Әй өммәтем! Ни гөнаһың бар иде ки, бу замангача тәмугта калдың?» Бәндә әйтер: «Ва сәйдаһ! Ва әнбаһ! Алдыңда гөнаһымны зикер кыйлмага ояламын». Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтер: «Гөнаһыңны әйт, хәҗаләт кыйлма. 50 мең ел ни гөнаһ сәбәпле тәмугта калдың?» Бәндә әйтер: «Белә торып мөтәгаммидән[1] бервакыт намазны тәрк кыйлмыш идем, дөньяда гөнаһым шул иде»

Әй угыл, моннан фәһем ит ки, ни ояттыр кыямәт көнендә вә ни мосыйбәттер тәрикес-салятларга. Бервакыт намазны тәрк кыйлганнарның эше шөйлә булса, елда уникe ай намазын укымаган кешегә ни җәзалар булачактыр. Әлбәттә, җәзасы тәмугта калмактыр. Тәгамы — зарикъ вә шәрабы — зәкъкум булмактыр.

Пәйгамбәр галәйһиссәламнән риваять кыйлынды ки: тәрикес-салятның явызлыгы үзенең әһеленнән вә күршеләреннән

---

[1] Мөтәгаммидән — алдан уйлап.

житмеш кешегә кадәр тияр. Имам Сиути разыйаллаһу ганһу әйтте ки: «Мин әйтәмен ки, тәрикес-салятның явызлыгы вә кәсафәте бу көнемездән Адәм галәйһиссәлам заманынача булган мөэминнәргә кадәр ирешер», — диде. Вә моның хакыйкатен дәлилләр белән бәян кыйлды вә әйтте ки: «Бер мөсалли[1] әттәхияткә утырса, әлбәттә, әйтер: *«Әссаләму галәйна вә галя гыйбадилләһис-салихин»*. Бәс, моның савабы җәмигъ мөэминнәргә ирешсә кирәк. Кайсы пәйгамбәр өммәтеннән булган мөэмин булсын, бу дога белән файдаланыр. Тәрикес-салят бу файданы алардан манигътыр[2]. Бәс, җәмигъ мөэминнәргә явызлыгы тигән кеше кебек булыр», — диде. *Мәнига лилхайр моганид әсим.*

Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: *«Рабби тәлил Куръән юлгану»*. Әй угыл, ошбу сүздә күп серләр бардыр. Мәгълүмдер ки, намаз җаиз булмас, мәгәр кыйраәт Коръән илә җаиз булыр. Берәү намазда Коръән укыса, вәҗиб булып, зәкят бирмәсә, Коръән аңа ләгънәт кыйлыр. Ушандак бер кеше Коръәнне укыса, намазны тәрек кыйлса, Коръән аңа ләгънәт кыйлыр. Яки берәү Коръән укыса вә халыкка золым кыйлса, Коръән аңа ләгънәт кыйлыр. Вә берәү намаз укыса, Коръән укыса, хаҗ вәҗиб булып хаҗга бармаса, Коръән аңа ләгънәт кыйлыр. Гайбәт, яла, газап, ачу, хөсед, алдау, урлау һәм ушандактыр.

Белгел ки, әй угыл, намазның мисале — зибак мисаледер ки, фарсыча «симаб»[3] диләр, күнә суыдыр. Аллаһы Тәгалә намазны «сима» дип атады. *«Симаһум фи вуҗүһиһим мин әсәриссуҗүд»*, — диде. Симабның хасияте бардыр, гайре дәваларда ул хасият булмас. Берәү күнә суын угалап утырып, җепкә сөртеп, биленә баглап ятса, тәнендә булган бетне, борчаны үтерер. Биленә бу җеп буылган вакытта, тәнендә аслан бет, борча булмас. Ушандак Аллаһы Тәгалә үзенең бәндәсенә нәфес симабын, угалап, кимья-с-салят җебенә сөртеп, биленә бagламага әмер кыйлды. Таки фәхшә бетләре вә мөнкәр борчалары аннан качсыннар. *Иннә саләтә тәнһә ганил фәхшәъи вәл мүнкәри.* Әмма пәйгамбәребез сүзе: *Рабби тәлил-Куръәни вәл-Куръәну йәлагана. Кыйлә әннәһү фи хәккыйл-күффәрил-ләзинә кәну йәтәгәлләмунәл-Куръән-лихуҗҗәҗил-мүслимин вә әгъвәһум кәл-әхбәр вәл бүрһәнүл-ләзинә. Галиму сыйдкаль-Куръәни вә хакыйкатәһү вә кәтәмүһү.*

Тәхкыйк намаз фахишлектән һәм диндә кире кагылган әйберләрдән тыя. Әмма пәйгамбәремезнең сүзе: шулай Коръән укучы булыр, ә Коръән аны ләгънәт кыйлыр. Әйтелгән: тәхкыйк

[1] Мөсалли — намаз укучы.
[2] Манигътыр — тоткарлаучыдыр, тыючыдыр.
[3] Симаб — терекөмеш.

ул мөселманнарга каршы дәлилләр эзләү өчен генә Коръәнне өйрәнгән кяферләр хакында. Аларны Аллаһы адаштырган. Алар Коръәнне легендалар һәм таяныч кебек кулландылар. Коръәннең тугыры икәнлеген һәм аның хакыйкатен белделәр һәм яшерделәр.

———

Олуг мәшаихлардан сахиб әсрар вә сахиб кәрамәт бер шәех бар иде. Исмене Хәсән Бәсри диләр иде. 300 мөриде бар иде. Көннәрдән бер көн бу шәех мөридләре белән иртә намазын укыдылар, мактау догасыннан фаригъ булдылар. Рамазан ае иде. Бер кеше килеп керде, кулында таягы, иңендә рәддәсе бар. Шәехкә сәлам бирде. Намазга торды. Хозуг-хошуг белән кәмаль намаз укыды. Намаздан соң тәһлил укыды. Коръән укыды. Коръәннән фаригъ булгач, комганны алды да комганнан су эчте. Мөридләренә шәех әйтте: «Зарар юк, мөсафир кешедер. Эчсен. Ләкин су эчмәке тәгам сорамакына дәляләт кыйладыр. Тәгам китерегез», — диде.

Бәс, тәгам китереп, алдына куйдылар. Бу кеше: «Бисмиллаһ», — дип, тәгамны тәнавел кыйлды, әйтте: «Әм-муафәкать шарт», — диде. Шәех дәхи: «Баш өсте, бисмиллаһ», — дип, бу кеше белән тәгамны тәнавел кыйлды. Мөридләре моны күрделәр, шәехтән нәфрәт кыйлдылар. Вә игътикадларын бoздылар. «Бу шәех мокыйм[1] кешедер: Рамазанны ашады», — дип, шәех яныннан чыктылар. Шәех ул мөсафир белән калды. Ул кеше әйтте: «Шәкертләренә ни булды, качтылар», — диде. Шәех әйтте: «Зарар юк. Бәлки, шөгыльләре бардыр. Аллаһы Тәгаләнең хөкеме шөйләдер: бәгъзе кешене батыйннан заһирга чыгара вә бәгъзе кешене заһирдан батыйнга кертәдер», — диде.

Бу кеше, шәехнең сүзен ишеткәч, агарып китте, кызарып китте — төсе үзгәрде. Әмма мөридләре, ни хәл булыр икән? дип, читтән карап торырлар иде. Шәехнең бер гадәте бар иде: тәсбихен биленә баглап йөрер иде. Бәс, тәгамнан бушагач, бу кеше торып китәргә теләде. Шәех әйтте: «Әм-муафәкать шарт», — диден түгелме?» «Бәли, әйткән идем». Бәс, шәех торды да билендәге тәсбихен «бисмиллаһ» дип кисте. Әмма шәехнең шәкертләре һаман карап торырлар иде. Бу кеше әйтте: «Бәли, минем тәсбихем юктыр», — диде. Шәех әйтте: «Мин хак тәсбихемне дә кистем, син батыйль зөннарыңны[2] ник кисмәйсең?» — диде.

Бәс, бу кешенең хәле ачылды. 70 яшенә кадәр билендә кяферлек билгесе иде. Кулы белән тотты да зөннарын кисте: *«Ля иләһа иллә Аллаһ, әшһәдү әннә Мухәммәдер Рәсүлул-*

---

[1] Мокыйм — урнашкан, өендә торучы.

[2] Зөннарыңны — билбавыңны.

*лаh»*, — дип иман китерде. Аннан соң шәехнең мөридләре җыелып килделәр. Шәехнең кулын үптеләр. Гозер теләделәр вә әйттеләр: «Йә шәех, рузаңны ашадың, ни сәбәп иде?» Шәех әйтте: «Рузаны ни өчен тоталар? Мәгәр тоталар иблис башын кисмәк өчен. Мин 60 ел руза тоттым. Иблис башын кисмәгә кодрәтем булмады. Инде ошбу көн рузадан рузасын ашамак белән, әлхәмделиллаh, иблиснең башын кистем! Дәхи моннан да гаҗәбрәк ки: үземә 60 көн руза ваҗиб иттем. Ләкин бер кяферне исламга лаек итеп, вә муафәкать кыйлып, аны оҗмахка муафыйк иттем», — диде.

Инде, әй угыл, белгел ки, мөҗәррәд[1] Коръән укымак белән генә эш бетмәде. Коръәннең hәр сүрәсе фәкать укымак өчен генә назил булмады[2]. Бәлки, Коръәнне белеп, гамәл кыйлмак өчен назил булды. Ләкин мөҗәррәд Коръән укыган белән генә кеше оҗмахка кермәс, Коръән боерганча тәмәссек кыйлмаса вә Коръән нәhи кыйлган нәрсәдән тыелмаса. Моның мисале ошбудыр. Мәсәлән, бер падишаh үзенең мәмләкәтеннән бер шәhәргә бер кешене вали итеп җибәрсә, ул шәhәрнең әмирлеген вә рәислеген ул кешегә тапшырса, аңа бер намә язып бирер. Таки ул шәhәрнең халкы бу кешегә мотыйг булсыннар. Кайчан ки бу кеше, падишаh язган намәне алып, бу шәhәргә килсә, үзен мәгълүм итсә, шәhәр әhеле аңа мотыйг булырлар.

Бәс, моннан соң падишаh бу кешегә фәрман язды, шәhәрне ни тарикъча төзек тотмак кирәк? Вә дәхи әмер кыйлды: «Минем өчен ул шәhәрдә hәйбәт сарайлар вә олуг йортлар бина кыйлдыр. Ул шәhәргә барсам, шул йортка төшәрмен», — дип фәрман язды. Бәс, падишаhның фәрманнамәсе бу кешегә васыйл булды. Әмма падишаhның фәрманында мәгъмүр булган эшләрне әда кыйлмады: йортлар бина кыйлдырмады вә падишаh боерган эшләрнең берсен дә эшләмәде. Ләкин падишаhның фәрманнамәсен көн саен алып-алып укыды.

Бәс, көннәрдән бер көн падишаh бу шәhәргә килде, күрде: үзенең боерган эшләре берсе дә хәзер түгел. Инде бу кеше хилгатькә вә мәдехкә мөстәхак булырмы? Әлбәттә, булмас. Бәлки, җәзага вә хибескә мөстәхак булыр. Ушандак Коръән — ошбу фәрманнамә мәнзилендәдер. Аллаhы Тәгалә бәндәләренә Коръән укып, Коръән сүзләре белән гамәл кыйлып, әркян[3] динне гыймарәт кыйлмага боерды. Бәс, мөҗәррәд Коръән укымак — баягы фәрманны укымак белән бәрабәр булды. Бу сәбәпле генә оҗмах хасыйл булмас. *Җәзаъәм бимә кяну ягъмәлун*. Оҗмах — Коръән укып, Коръән белән гамәл кыйлмак җәзасынадыр.

---

[1] Мөҗәррәд — бары тик.
[2] Назил булмады — иңмәде.
[3] Әркян — нигез.

———

Көннәрдән бер көн Габдулла бин Мөбарәк Димәшкъ сәфәренә барганда бер үлгән ишәк күрде. Янында бер фәкыйрь кеше егълап утырыр. Габдулла әйтте: «Әй карендәш, ник егълыйсың?» Фәкыйрь әйтте: «Мин бер фәкыйрь адәммен. Гаялем күп. Бу ишәкне 300 дирһәмгә сатып алдым. Шул ишәгем үлде. Бик мохтаҗ булып калдым. Егъламакымның сәбәбе будыр», — диде. Габдулла әйтте: «Син аны хәл хәятында 300 дирһәмгә алмышсың. Мин, халән үлгән булса да, 500 дирһәмгә аламын», — диде. Фәкыйрь әйтте: «Әгәр раст әйтә торган булсаң, сана дирһәмнәреңне!» — диде. Бәс, Габдулла 500 дирһәм санап бирде. Фәкыйрь бу дирһәмнәрне алды. Шат булып, йортына, гаяле янына кайтты.

Шул кичне төшендә оҗмахны күрде. Оҗмах бакчаларыннан бер бакчада дәхи бер ишәк күрде: төрле зиннәт белән мөзәйян. Җөгәннәре — алтыннан. Дагалары — көмештән. Муенында — нурдан камыт. Вә ишәк янында бер фәрештә нида кыйлыр: «Кем дә кем кыямәт көнендә бу ишәккә атланса, сыйрат күпереннән яшен кебек үтәр. Вә пәйгамбәрләр вә садыйклар зөмрәсендә булыр!» — диде. Бәс, бу фәкыйрь ишәкне карады, таныды: бу — үзенең үлгән ишәге, имеш. Габдулла бин Мөбарәккә сатмыш иде. Бәс, фәкыйрь фәрештә янына килде, әйтте: «Бу — минем ишәгемдер, бир миңа аны!» — диде. Фәрештә әйтте: «Бәли, бу — синең ишәгең иде, ләкин үлгәненә сабыр итмәдең. Инде гайре кешенең ишәге булды. Әнә, кара: ияренең күкрәгенә язылмыш», — диде. Фәкыйрь карады, күрде: ияренә язылмыш ки: «Һәза мәркүб Габдулла бин Мөбарәк».

Моннан соң фәкыйрь йокысыннан уянды. «Вә әндәмнаһ!» — дип егълап, дирһәмне алды. Габдулланың саумәгасына килде, әйтте: «Мә, дирһәмнәренне ал, шәригатьтә мәетне сатмак җаиз түгел, имеш», — диде. Габдулла әйтте: «Инде синең әкаләң дөрес түгел. Ләкин син ишәкне төшеңдә күрдең; әнваг бизәк белән мөзәйян. Иярендә язылмыш, бу бәйгъне әкалә кыйлмак мөмкин түгел», — диде.

Әй угыл! Бу кыйссада бәшарәт бардыр. Вә гасый мөэминнәргә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте монда заһирдыр. Чөнки Габдулла бине Мөбарәк үлгән ишәкне сатып алды. Дирһәмнәре заигъ булмады. Аллаһы Тәгалә ишәген тергезде. Әнваг җәваһир белән бизәкләде. Инде ни гөманың бар, әй угыл! Нәфсе әмарә[1] — бер үлгән ишәктер. Аллаһы Тәгалә: *«Күнтум хайра умматин»,* — диде. Мөэминнәрнең малларын вә ишәкләрен, ягъни нәфселәрен сатып алды. Бәс, кайчан ки Аллаһы Тәгалә

---

[1] Нәфсе әмарә — нәфес билгесе.

Габдулланың мөштәрәсен заигъ кыйлмады, инде үзенең мөштәрәсен кайчан заигъ кыйлына? Ягъни нәфесләрен вә бәдәнләрен Ходай юлына тәсаддык кыйлмаклары. Вә мөэмин бәндәләрне ник хөрмәтләмәсең? Нитәкки хәдис коддеси: *агътайтукүм каблә ән тәсъәлүни вә вәһәбтү ләкүм каблә ән тәгъбүдуни*.

Көннәрдән бер көн мөэминнәрдән бер җәмәгать Гали разыйаллаһу ганһу янына килделәр. Гомәр разыйаллаһу ганһуның хәләфате заманы иде. Бу җәмәгать кыйссаларда мәгъруф карья әһеленнән иде. Ягъни, Муса галәйһиссәлам белән Хозыр галәйһиссәлам бер карьягә килеп, ул карья әһеле аларны зыяфәт кыйлмаганнар иде. Нитәкки Коръәндә *«фә әбәү ән йүдаййифүһүмә»* — алар хакындадыр.

Бу җәмәгать шул карья әһеленнән булган яһүдләр нәселеннән иде. Мөэмин булмышлар иде. Хәзрәти Галигә әйттеләр: «Йә әмирел-мөэминин, сиңа без бер хаҗәт белән килдек. Без Аллаһы Тәгаләнең вәхданиятенә[1] мөэминнәрбез. Мөхәммәд галәйһиссәламнең нәбүвәтенә мокыйрлармыз. Әгәр безнең хаҗәтемезне әда кыйлсаң, сиңа ун тәвә йөге алтын китерермез», — диделәр. «Йә әмирел мөэминин, һәрбер Коръән укыган кеше *«фә әбәү ән йүдаййифүһүмә»* дигән аять белән безнең әҗдадымызны[2] зәм кыйлалар. Сезнең әҗдадыңыз үзләре заманасындагы хәлифәдән дә саранрак булганнар, имеш. Хәтта Хозыр белән Муса галәйһиссәламгә ярты икмәк тә бирмәгәннәр, дип мәсхәрә кыйлалар. Бу безгә вә безнең әҗдадымызга каты гарьлектер. Без сиңа ун тәвә йөге алтын бирәек, «ба»ны «та» га тәбдил кыйлынса, таки: *«Фа ән языйфуһема»* булсын иде», — диделәр.

Бәс, Гали разыйаллаһу ганһу аларга бик ачигъланды: «Мин кяферлар вә монафикъләр таифәсеннән түгелмен ки, Кәламуллаһны тәхриф вә тәбдил кыйлып, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән мәтруд булаеммы?! Сезне сәясәт кыйлмак лазем!» — дип куып җибәрде.

Инде, әй угыл, бу кыйссадан хиссадар булгыл ки, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә васыйл булмак бик мөшкелдер. Әмма вакытында мәкъбульләр зөмрәсенә кермәк бик аз нәрсә белән хасыйл булыр. Вакытыннан соң ниндәен олуг вә газиз нәрсә белән дә хасыйл булмас. Бәс, ул карья әһеленең вакытында булса, ярты икмәк белән морадлары хасыйл булыр иде. Ягъни шул вакытта Муса һәм Хозырны ярты икмәк белән сыйлаган булсалар, йөзләренә гарьлек килмәс иде. Вакыты үткәч, ун тәвә йөге алтын белән дә морадлары хасыйл булмады. Монда

---

[1] Вәхданиятенә — бердәнберлегенә.
[2] Әҗдадымызны — ерак бабаларыбызны.

ишарәт бардыр ки, әй угыл: бүген, хәзерге көнеңдә вә хәятыңда изгелек хасыйл итмәктә бул. Бер хәсәнә ун хәсәнәгә тора торган көндә әҗер вә хәсәнә кәсеп кыйл. Чөнки бу хәятның мөтдәтендә ярты икмәк белән дә бу әҗерләрне табарсың. Үлгәннең соңында малың түгел, җаныңны-тәнеңне фида кыйлсаң да, таба алмассың. Үзеңнең хәятыңда бер дирһәм белән хасыйл була торган әҗер вә хәсәнәт үлгәнеңнән соң бер йөк белән дә хасыйл булмас.

Мөхәммәд галәйһиссәлам үзенең өммәтләренә мохтаҗмы, юкмы? Белгел ки, әй угыл, әгәр пәйгамбәр галәйһиссәлам безгә мохтаҗ булмаса иде, Аллаһы Тәгалә аның хакында: *«Йә әййуһәл ләзинә әмәну саллу галәйһи»*, — дип әйтмәс иде. Инде, әй угыл, монда максуд будыр ки: Аллаһы Тәгалә халаикны берберсенә мохтаҗ итеп яратты, вә барчасын үзенә мохтаҗ итте. Пәйгамбәрләр салаватка мохтаҗдыр. Өммәтләр шәфәгатькә мохтаҗдыр. Фәкыйрьләр байларга мохтаҗдыр. Байлар фәкыйрьләрнең хезмәтенә мохтаҗдыр. Шәкертләр голямага мохтаҗдыр. Галимнәр җаһилләрнең истимагына[1] мохтаҗдыр. Шәех мөридкә мохтаҗдыр. Мөрид шәехкә мохтаҗдыр. Ирләр хатыннарга мохтаҗдыр, хатыннар ирләргә мохтаҗдыр. Солтан гаскәргә мохтаҗдыр, гаскәр солтанга мохтаҗдыр. Хайван адәмгә мохтаҗдыр, адәм хайванга мохтаҗдыр. Шулай бер нәрсә бер нәрсәгә мохтаҗдыр. Мәгәр Аллаһы Тәгалә үзе генә бер нәрсәгә дә мохтаҗ түгел. *Аллаһы ганийүн ганил галәмин.*

---

Ошбу мәгънәдә бер хикәят. Көннәрдән бер көн Сөләйман галәйһиссәлам үзенең хәшәме[2] белән шәҗәрәтел хәлаф астыннан үтте. Бу агачның башында ләкләк бар иде вә астында, бер чыпчык агачының астында, оя ясаганнар иде. Сөләйман галәйһиссәлам ишетте: ләкләк белән чыпчык низаг кыйлышалар. Сөләйман галәйһиссәлам халкына әйтте: «Туктаңыз, бераз монда торыңыз. Болар ни сөйләшә икән, ишетәем», — диде. Ләкләк чыпчыкка әйтте: «Син минем бәдрәфемдә вә күләгәмдә торасың. Әгәр дә мин булмасам, балаларыңның һәммәсен еланнар ашар иде. Кояш көйдерер иде», — диде. Чыпчык әйтте: «Син миңа миннәт итмә! Бәлки, мин сиңа миннәт итсәм кирәк. Чөнки мин синең тереклегеңне вә балаларыңны кырмыскадан саклыймын. Чөнки Аллаһы Тәгалә синең томшыгыңны зур итеп яратты, кырмыскага кодрәтең җитмәй. Вә минем томшыгымны кечкенә итеп яратты, еланга кодрәтем җитмәй. Бәс, син миңа мохтаҗ, мин сиңа мохтаҗ. Вә барчамыз да Аллаһы Тәгаләгә мохтаҗдыр», — диде.

---

[1] Истимагына — тынлавына.
[2] Хәшәме — яраннары.

Әй угыл! Сөләйман галәйһиссәлам пәйгамбәр булып, чыпчыкның сүзен игътибар кыйлып тыңлап торды. Син һәм, шаять, бу «Җәваһирел хикәят»не игътибар кыйлып укысаң кирәк. Вә гайреләр укыганда, игътибар кыйлып тыңласаң кирәк. Инде белгел ки, әгәр дөнья галәменә карасаң, күрерсең: Аллаһы Тәгалә адәм угланнарын һәммәсен бертөрле итеп яратмагандыр. Төрлесен төрле сыйфатта итеп яратмыштыр. Күрәсең: берәүнең бите, йөзе берәүгә охшамай. Берәүнең холкы-фигыле икенче берәүнең холкы-фигыленә охшамай. Дәхи бәгъзесе — бай, бәгъзесе — фәкыйрь, бәгъзесе — галим, бәгъзесе — җаһил. Монда Аллаһы Тәгаләнең күп хикмәте бардыр. Әгәр дә адәм угланнары һәммәсе бертөрле сыйфатта булса, дөнья тереклегенең һич мәгънәсе булмас иде.

---

Әй угыл, белгел ки, үлемнең вакыты һичкемгә мәгълүм түгелдер. Әҗәл килмәс борын үлемгә хәзерләнгәйсең. Әмма үлемнең сыйфатын бәян кыйлмак мөмкин түгелдер. Атаңа-анаңа даим изгелек кыйл. Аларны рәнҗетмә, *гаф әл-вәлидәйн* булудан саклан. Әгәр берәү вафат булып, ата-анасы аннан разый булмаса, тәмугка салып, гөнаһларын югач та — пакьләнмәс. Вә гөнаһларыннан тәүбә кыйлып үлсә дә, атасы-анасы разый булмаса, пәйгамбәр галәйһиссәлам һәм разый булмас. Кыямәт көнендә шәфәгатьтән мәхрүм булыр.

---

Шәех Һарави разыйаллаһу ганһу — сахиб тарикать вә сахибе кәрамәт иде, вә олуг мәшаихлардан иде. Көннәрдән бер көн шәех Һарави янына бер карчык хатын килде. Кулында бер язуы бар иде, шәехкә бирде. Бәс, шәех Һарави язуны алып укыды, язылмыш иде ки: *«Иннәл матлубә мин ихсаникәддогаъу Аллаһы Тәгалә ән юслихә вәләди фәиннәһу мусиә».* Шәех әйтте: «Ни үкенечтер ул балага ки, ата-ана догасы төзәтмидер икән дә, шәех догасына мохтаҗ була. Ата-ана догасы белән төзәлмәгән бала шәех догасы белән төзәлерме?! Шәех догасы ата-ана догасыннан әсәрлерәк була алырмы? Йә гаҗүзә, инде син, бар, бу кич намаз укы, дога кыйл, Аллаһы Тәгаләдән сора. Шаять, Аллаһы Тәгалә углыңны ислах кыйлыр», — диде.

Бәс, карчык китте. Шәех әмеренчә кыйлды: намаз укыды, дога кыйлды. Күрде, һаман углы фисык-фәсадта вә анасын рәнҗетүдә. Янә шәехкә килде, әйтте: «Йә шәех, углым һаман заляләттәдер. Ләкин углыма мәхәббәтем бик зурдыр, зинһар, шәфкать кыйлсана. Куркамын ки, кыямәт көнендә фиcкы вә фәсаде сәбәпле тәмуг әһленнән булып, углымнан аерылмагай идем. Фиракына такать тотар хәлем юк. Дога кыйлсана: углымны вәгазь-нәсыйхәт кыйлсана, газаптан котыла торган тарикъны белдерсәнә?» — дип тилмереп егълады. Хәтта шәех һәм егъ-

лады. Шәфкать кыйлды. «Йә ухтым, бар, өеңә кайт. Ахшам булсын. Намазлыгыңны җәй, Аллаһы Тәгалә хозурында гыйбадәткә тор, тәзәррыг кыйл, дога кыйл. Мин һәм дога кыйлырмын. Өмидтер ки, Аллаһы Тәгалә углыңа тәүбә разый кыйлыр», — диде.

Бәс, карчык шәех яныннан кайтты. Гыйбадәткә каим булды, егълады, Аллаһы Тәгаләгә мөнәҗәт кыйлды, әйтте: «Илаһи, углыма тәүбә-тәүфыйк бир, изгелеккә күндер», — диде. Дәхи һәм ушандак үзенең мәнзилендә бу бала өчен догага мәшгуль булды. Бу вакытта карчыкның углы мәйханәдә иде. Кулына кадәх[1] тотып, хәмер эчмәгә ният иткән иде, кадәхтән бер тавыш ишетте: «Әгәр бу кич анаңны разый кыйлмасаң, дөньядан көфер китәрсең». Бәс, бу тавышны ишеткәч тә, кулыннан кадәхне ташлады. Каты аваз белән егълап, анасы янына кайтты. Әмма исерек иде. Анасын күрде. «Йә вәләдә», — дип кычкырып егълады.

Углы азрак айныды. Анасын күрде вә бик егълаганын әйтте. Анасының аягына төште, әйтте: «Әй ана! Миннән разый бул, бәхил бул, гафу ит!» — дип, бер мәртәбә: «Йә Аллаһы!» — дип кычкырды. Һушы китте. Аннан соң таң атканчы айнымады вә һушына килмәде. Анасы һаман егъламакта иде. Аннан, йөгереп шәех янына килде, углының хәлен сөйләде. Шәех әйтте: «Инде син углыңны атка сал, Кәгъбәгә алып бар. Бәйтуллаһ әл-хәрәм бәрәкәтендә һушына килер. Әгәр Кәгъбәдә һушына килмәсә, Ләбнан тагына алып бар», — диде.

Аннан соң карчык углыны Кәгъбәгә алып барды. Углы һаман һушына килмәде. Ләбнан тагына алып килде. Күрде: берәү вафат булмыш. Алты кеше җеназасы янында торырлар. Карчык әйтте: «Бу кем җеназасыдыр?» Әйттеләр: «Бу шәехемез җеназасыдыр, имамны көтеп торамыз. Ул имам безнең белән әүвәл бу мәеткә җеназа укыр. Аннан соң аны бу шәехемез урынына шәех кыйлырмыз», — диделәр. Карчык әйтте: «Имамыгыз кемдер?» Әйттеләр: «Йә гаҗүзә, синең углыңдыр. Синең догаң сәбәпле, углың әүлиялар дәрәҗәсенә иреште», — диделәр.

Бәс, шул заман карчыкның углы һушына килде. Аттан төште. Таһарәт алды. Җеназа намазына торды. «Аллаһу әкбәр», — дип тәкбир-тәхрим кыйлды. Янә хисапсыз тәкбир авазы ишетелде. Карчык әйтте: «Бу кадәр тәкбир авазы ишетелде, үзләре күренмәс», — диде. Әйттеләр: «Шәехнең җеназасына әйткән фәрештәләр авазыдыр», — диделәр. Бәс, җеназа намазыннан фаригъ булдылар[2]. Бу углан анасы белән мосафәхә кыйлды, бәхилләште. Әйтте: «Әй ана! Бар, кайт. Инде күрешмәк — кыяматкә калды», — диде. Анасы китте. Углы Ләбнан тагында

---

[1] Кадәх — шәраб эчә торган савыт.
[2] Фаригъ булдылар — бушандылар.

яраннары белән калды. Анасы, егълап, хәйран булып, мәҗнүн мисле китте.

Инде, әй угыл, бу кыйссадан хисса күрдеңме? Белгел ки: ата-ана догасы оҗмахка кертер. Ата-ана догасы тәмугка кертер. Инде даим тәүфыйк истә: атаңа-анаңа итагать кыйл. Вә дәхи, әй гаҗүз вә гаҗүзә, балаларыңнан аерылмак шөйлә мөшкелдер. Әммә иман вә исламнан аерылган кешенең хәле нитәк булыр? *Аллаһүммәхфазыйль имәнә вәл исләмә гыйндәл хәяти вәл мәмәти бирахмәтикә йә әрхәмәр-рахимин.*

---

Аллаһы Тәгалә үзенең Кәләмендә әйтте: *«Фи яумин кянә микъдәруһү хамсинә әлфә синәтин»*. Мөэминнәр гарасаты кыяматтә соруг-сөальдә 50 мең ел тәүкыйф кыйлсалар, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтенә вә кәрәменә лаекмыдыр? Вә дәхи *«вә һуә сәригул хисәб»* дигән сүзенә каршылыклы булмаймы? Монда ни сер бар? Инде, әй угыл, бу сөальнең җавабыннан мөкаддәм бер хикәят сөйләем. Таки хикәятнең мәфһүменнән сөаленнең җавабын фәһем иткәйсең.

Бәгъдад шәһәрендә бер хатиб бар иде. Көннәрдән бер көн намаз эчендә *«фи яумин кянә микъдәруһү хамсинә әлфә синәтин»* дигән сүзне укыды. Бу аятьнең мәгънәсендә бик фикергә калды, һәм, намаздан бушагач та мәгъмүм вә хәйран булып, бик озак фикерләп торды. Ахыр Аллаһы Тәгаләгә мөнәҗәт кыйлды, әйтте: «Илаһи, мөэмин вә мотыйг бәндәләрнең гарасаты кыяматтә 50 мең ел тәүкыйф кыйлмаклары үзеңнең кәрәмеңә вә рәхмәтеңә нәзарән лаек булмаган шикелле фәһем ителә. Вә халән ки, дөньяда бәндәләреңнең бар гомере 60—70 елдыр. Илаһи, бу аятьнең мәгънәсен миңа белдер вә монда ни сер бардыр, бу бәндәңә күрсәт, таки хәлас булаем», — диде.

Ул көн җомга көн иде. Бу хатиб торды. Җомгагача Диҗлә[1] суына барып госел кыйлмак булып күңеленнән әйтте: «Тукта, госелдән мөкаддәм җәмәгатемә ит алып китерәем, таки җомгадан чыгышка аш хәзер булсын», — дип, пәйгамбәр галәйһиссәламнең *«мин хәмәлә силгатән фәкад бәриъә минәл кибри»* дигән сүзенә тәмәссекән зәнбил алды.

Базарга барды. Ит алды. Җәмәгатенә китереп бирде. Моннан соң Диҗләгә госел коенмага китте. Чишенеп, Диҗләгә керде. Кулларын-йөзләрен юды. Хасыйле кәлям, тәмам таһарәт алды. Моның соңында суга чумды. Бер микъдар торып, янә судан башын чыгарды. Күзен ачты. Судан чыкты. Үзенең салып куйган киемен тапмады. Ары карады, бире карады. Күрде: бу җирләр бөтенләй башка җирдер. Бу җирләрне һич күргәне

---

[1] Диҗлә — Тигр елгасы.

юк, ят җирләрдер. Судан ерак түгел бер шәһәр күрде. Халыклары бөтенләй Бәгъдад халкына хилаф. Базарлары, билкөллия, Бәгъдад базарларына охшамаган.

Бәс, хатиб бу хәлдә хәйран торганда күрде: су янында берничә җәмәгать таһарәт алалар. Алардан сорады: «Әй җәмәгать, бу кайсы шәһәрдер?» — диде. Әйттеләр: «Бу — Бәсра шәһәредер». Бәс, бу хатиб судан чыкты. Гаурәтен тотарак шәһәргә килде. Бер мәсҗеткә керергә рөхсәт сорады. Рөхсәт бирделәр. Мәсҗеткә керде. Әйттеләр: «Йә мөсафир, синең киемең-салымың кайда?» — диделәр. Хатиб әйтте: «Мин бер фәкыйрь мөсафирмын. Киемем иске иде. Юлда истигъмальдән чыкты. Салып ташладым. Башка киемем юктыр», — диде.

Аннан соң, бәгъзеләре җөббә китереп, баштан-аяк киендерделәр. Мәсҗетнең бер почмагына барып утырды. Җомга намазы булды. Халык, җомга намазын укып, мәсҗеттән чыгып беттеләр. Хатиб мәсҗеттә ялгыз калды. «Инде ни эшләем?» дип фикердә торганда, күңеленнән әйтте: «Инде кайда бараем? Аллаһы Тәгалә минем бу урында булмакымны теләде. Әҗәлем җиткәнчә, монда тораем, ватаным бу булсын», — дип, шул мәсҗеттә калды. Коръән укымак белән мәшгуль булды.

Халык моның гыйлемен фәһемләп илтифат вә ригая кыйлдылар. Балаларын Коръән өйрәтмәгә китерә башладылар. Бу хатиб берничә заманнар бу шәһәрнең балаларына тәгълим бирде вә үзенең гыйлемен халыкка изһар кыйлды. Дәрес әйтә башлады. Ахыр бу шәһәрдә шөһрәт тапты. Күп талибәләре булды. Төрле фәннәрдән — фикъһедән, тәфсирдән, тыйбтан вә голүм гарәбиядән дәрес укыды.

Бәс, халык моның фазыйләтен тәмам фәһемләгәч, олуг адәмнәреннән берәүнең кызын никяхладылар. Ахыр бу хатиб Бәсра шәһәрендә 50 ел торды. Аллаһы Тәгалә аңа берничә әүлад рузи кыйлды. Моннан соң бу хатиб көннәрдән бер көн таһарәт алмага су янына килде. Таһарәт алды. Җомга көн иде. Җомга өчен госел кыйлмага касд кыйлды. Чишенеп суга керде. Госел коенды. Бер мәртәбә суга чумды. Башын судан чыгарып, күзен ачты. Диҗлә буенда салып куйган үзенең киемнәре янына чыкты. Күрде: Бәгъдад янында салып куйган киемнәре һаман торыр, һич кузгалганы юк. «Сөбханаллаһи», — дип, киемен киде. Тугыры җәмәгате янына кайтты. Күрде: алып китергән ите кайный. Хатыны казан янында торыр. Хатыны әйтте: «Ник ашыгып кайттың? Һаман ит пешкәне юк әле», — диде.

Бәс, хатиб мәсҗеткә килде. Җомганы җәмәгать белән укыды, һичкем бу хәлне белмәде. «Кайда идең, хәзрәт?» — дип берәү дә әйтмәде. Гадәти атнада була торган җомга, һич үзгәрү булмады. Бәс, хатиб, үзенең хәленә вә Аллаһы Тәгаләнең кодрәтенә хәйран булып, өенә кайтты.

Инде, әй угыл, син әйткән сүз, ягъни *«фи яумин кянә микъда-*

*руһу хәмсинә әлфә синәтин»* дигән сүз кяферләр хакындадыр. Әмма мөэминнәргә вә мотыйг бәндәләргә кыямәт хисабы бер сәгать урынына да тоелмас. Нитәкки хатибның кыйссасыннан мәгълүмдер ки, хатиб Бәсра шәһәрендә 50 ел гомер итте. Бәгъдад шәһәрендә ярты сәгать яки бер сәгать микъдары вакыт үтте. Инде, әй угыл, бу кыйссадан янә хисса будыр ки: мәзкүр хатибка бер сәгатьтә 50 еллык гомер иттерергә кадир булгучы Аллаһы Тәгалә мөэминнәргә, күз ачып йомганчы сыйрат күпереннән үткәреп, кыямәт куркуларыннан хәлас итеп, оҗмахка кертмәгә кадир булмасмы? Әлбәттә, кадидер ки, моны һичкем белмәс. Хәтта оҗмах сакчылары мөэминнәрдән сорар: «Әхваль кыямәтне ни кәйфияттә күрдеңез? Сыйрат күпереннән нитәк үттегез? Тәмугтан ничек хәлас булдыңыз?» — диләр. Мөэминнәр әйтер: «Кыямәт ни-нәрсәдер? Тәмуг ни-нәрсәдер? Сыйрат ни-нәрсәдер? Без белмәдек. Аллаһы Тәгаләгә сиррән итагать кыйлдык. Аллаһы Тәгалә сиррән безне оҗмахка кертте», — диерләр.

Риваять кыйлынды, пәйгамбәр галәйһиссәламнән сорадылар, әйттеләр: «Йә Рәсүлуллаһ, кайчан кем кыямәт көне булса, халаиклар, 50 мең ел кадәр күзләрен һавага текәп карап, хәйран булып торырлар. Ошбу көндә өммәтеңнең хәле ничек булыр», — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Бу минем өммәтемә түгелдер. Бәлки өммәтем каберләреннән торырлар, башларыннан тузанны селкерләр, әүвәл зөмрәдә оҗмахка керерләр», — диде.

Инде, әй угыл, ишеткел ки, мәзкүр хатибның хикәяте мөмкин булмаклыгын сиңа тәхкыйк кыйлаем. Чөнки бәгъзе кыска гакыйль адәмнәр — кяферләргә 50 мең ел кайгы иткән заман мөэминнәргә — торфәтүл-гайн кебек булыр икән, сүзне мөхальгә саер[1] вә ышанмас Гозәйир галәйһиссәлам кыйссасы белән ошбу серне изах вә бәян кыйлаем, ишет, әй угыл.

Коръәндә килде: *«Әукәлләзи мәрра галя кариятин вә һийә хавиятун галя гурушиһә»*. Көннәрдән бер көн Гозәйир галәйһиссәлам, ишәгенә атланган хәлдә бер екыйлмыш карьядән үтте. Бу урында туктап, бер агач астында ял итеп, бераз тәгам ашамага ният кыйлды. Үзе белән бер зәнбил инҗир вә бер савыт белән сөт бар иде. Ишәген үләнгә җибәрде. Инҗир белән сөтне янына куйды. Инҗир белән сөт ашамага утырганда, бу карьяне тамаша кыйлып карап торыр иде. Күрде: мәетләренең черемеш сөякләре таркалып ята. Моңар бик тәгаҗҗеб кыйлды: «Кайчан тергезер Аллаһы Тәгалә үлгәннең сонында боларны?» — диде. Бәс, Аллаһы Тәгалә Гозәйир галәйһиссәламнең җанын кабыз кыйлды. Йөз ел бу урында Гозәйир галәйһиссәлам мәет булып ятты. Бәгъзеләр: «Йөз ел каты йокы галәбә кыйлды», — диләр. Моннан соң, ягъни йөз елдан соң, Аллаһы Тәгалә аны тергезде вә әйтте: «Йә Гозәйир, күпме йокла-

---

[1] Мөхальгә саер — булмастай эшкә санар.

дың?» — диде. Бәс, Гозәйир галәйһиссәлам инҗиргә карады. Сөткә карады. Куйган рәвешчә тора. Һич тәгъйир тапмагач, әйтте: «Бер көн йоклаганмын. Яки бер көннән кимрәктер», — диде. Сөттән кыяс[1] кыйлды. Чөнки сөт бер көндә бозыладыр, әчидер. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Бел ки: йөз ел йокладың. Тәгамыңа кара. Бакчы, аслан үзгәрмәмеш. Һәм ишәгеңә кара: үлеп, сөякләре череп бетмеш. Сине адәмиләргә гыйбрәт өчен шөйлә кыйлдым. Таки гакыллылар белсеннәр вә фикер итсеннәр. Дәхи белсеннәр: үлекне тергезмәк Мөхәммәд өммәтен сыйрат күпереннән торфәтелгайн[2] эчендә йөргезмәк минем кодрәтемнән ерак түгел», — диде.

Аннан соң Гозәйир галәйһиссәлам ишәген бәйләп куйган урынга карады. Әллә кайчан үлеп, череп туфрак булмыш. Ләкин ишәк җибәргән җирдәге үләннәр һаман әлгәрегечә. Аннан соң янә нида килде: «Йә Гозәйир, ишәгеңнең сөякләрен кара! Нитәкки аның сөякләрен сачтык, моннан соң сөякләргә ит кидерермез», — диде. Бәс, Гозәйир галәйһиссәлам уңынасулына карады. Ишәкнең череп таралган сөякләре Аллаһы Тәгаләнең изене белән бер җиргә җыелды, урыны урынына тезелде: ит, сөяк, тире хасыйл булды. Аяк үзрә торды. Селкенде, нитәк хайваннар ятып торгач, селкенер. Үләнгә башын сузды, үлән ашый башлады. Бәс, кайчан ки Гозәйир галәйһиссәлам: *«Әхья вә әманә»*нең серен вә хикмәтен гаянән күрде, *«игъләм әннәллаһә галя кулли шәйин кадир»*, — диде.

Инде әй угыл, белгел ки, Гозәйир галәйһиссәламгә йөз елны бер көн мәнзиләндә итеп күрсәтергә кадир булгучы Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд өммәтен сыйраттан торфәтелгайн эчендә йөргезмәгә кадир булмасмы? Вә һәм Аллаһы Тәгалә үләнне инҗирне, сөтне йөз ел бозмай асрады. Вә халән ки, адәмнең тәне бу өчесеннән дә тизрәк бу черек йортта бозылырга якын нәрсә иде. Аслан тәгъйир вә фәсадсыз йөз ел асрады. Моңар кадир булгучы Аллаһы Тәгалә, үзенең дустының өммәтен гарасаты кыяммәттә аслан михнәт тузаны тирдермәенчә, оҗмахка кертмәгә кадир булмасмы? Аллаһы Тәгаләнең кодрәтендә аслан шик тотма, дип әйтәмен, әй угыл.

Вә дәхи Аллаһы Тәгаләнең кодрәтенә истихкям якын өчен «Әсхәбе кәһәф» кыйссасына кара. Таки Аллаһы Тәгаләнең сангына вә кодрәтенә мокыйр булгайсың. Нитәкки әсхабе кәһәф сигез нәфәр иделәр. Мәгарәдә өч йөз дә тугыз ел йокладылар. Бервакыт йокыларыннан уяндылар, бер-берсенә әйтештеләр: «Без күп йокладыкмы?» «Бер көн йокладык, яки бер көнгә дә тулмагандыр», — диделәр.

Алар белән Кыйтмир атлы этләре бар иде. Ул эт әйтте: «Юк сез өч йөз дә тугыз ел йокладыңыз. Мин моны беләмен.

---

[1] Кыяс — чагыштыру.

[2] Торфәтелгайн — күз ачып йомган ара.

Мин бер сәгать тә йокламадым. Көне-төне белән, ае-ае белән, елы-елы белән санап тордым», — диде. Әйттеләр: «Ник алай бер дә йокламадың?» Эт әйтте: «Әгәр йокласам, сез торырсыз да мине монда калдырып китәрсез дип курыктым. Минем сездән бер сәгать аерылып торырга такатем юктыр», — диде. Инде, әй гасый вә җафи бәндә, 50–60 ел мин бәндә, дип, күңелеңдә Аллаһы Тәгаләнең мәхәббәтен дәгъва кыйласың. Филхәкыйкать, Әсхабел кәһәф эте чаклы да юксың. Чөнки бу эт юлдашлары һәм дусларының фиракына сабыр итмәй өч көн артларыннан ияреп йөрде. Аларның фиракыннан куркып, 300 ел йокламады. Әмма син кичә-көндез йоклыйсың. Эт Мәүлясын эстәде. Син дөньяны эстисең. Эт, кулларын түшәп: «Илаһи, нәфсемне юлыңда фида кыйлдым. Башымны алдыңа салдым», — дип, башын кулы өстенә куеп ятты. Әмма син мәхәббәт дәгъвасын кыйласың, кулың белән мөселманнар башын сугасың. Вә аларга золымлык кыйласың. Ятимнәр малын кулың белән аласың, мөселманлык хакын җуясың. Үлем исереклеген онытмышсың. Син кыямәт куркуларын күңелеңнән алмышсың. Тәмуг газабына мөстәхак булып калмышсың.

---

Риваятьләрдә килмештер. Кайчан ки кыямәт көне булса, Аллаһы Тәгалә үзенең хозурына ике мөэминне хәзер кыйлдырыр. Берсе — мөэмин гасый, берсе — мөэмин мотыйг. Икесе дә иман белән үтмешләр. Аллаһы Тәгалә: «Мин бу бәндәдән разыймын», — дип, Ризванга әмер кыйлыр, мөэмин мотыйгны икрам кыйлып, оҗмахка илттерер. Вә янә Аллаһы Тәгалә зобанига әмер кыйлыр, мөэмин гасыйны кыйный-суга тәмугка илтерләр. Аллаһы Тәгалә әйтер: «Илт, илт ул бәндәне тәмугка! Эчкече иде».

Бәс, мөэмин мотыйг, шат булып, оҗмахка таба көлә-көлә барыр. Оҗмахка якынрак җиткәч, артыннан бер нида ишетер: «Әй дустым, валлаһи, миңа рәхим кыйл, шәфкать кыйл. Дөньяда дус булып йөрдек ләбаса! Бер-беремезгә шәфәгатьче булмакчы идек ләбаса?» Аннан соң бу мөэмин-мотыйг бу ниданы ишеткәч, урынында туктап торыр, оҗмахка кермәс. Ризван әйтер: «Әй бәндә! Оҗмахка кер! Шөкер кыйл: тәмугтан хәлас булдың». Бу мөэмин әйтер: «Юк, мин оҗмахка кермәймен, мине тәмугка илт». Ризван әйтер: «Мин сине ничек итеп тәмугка илтәем? Аллаһы Тәгалә сине оҗмахка илтмәгә боерды, вә сине икрам кыйлмага боерды». Дәхи бу мөэмин мотыйг әйтер: «Юк, мин икрамыңны да, оҗмахыңны да теләмәймен».

Аннан соң Ризванга Аллаһы Тәгаләдән нида килер: «Йә Ризван, мин бәндәмнең күңелендәге серен беләмен. Сорап кара, күңелендә ни сер барын син дә белерсең». Ризван әйтер: «Йә мөэмин, ник оҗмахка кермәйсең? Тәмугка разый буласың». Мөэмин әйтер: «Ул тәмугка җибәрелмеш гасый дөньяда минем дустым иде. Хәзер дә артымнан нида кыйлды, гозер кыйл-

ды, шәфәгать теләде. Халән минем аны тәмугтан алып калырга кодрәтем юк. Аннан башка ожмахка дәхи кермәгә такатем юк. Бары аның белән бергә тәмугта булсам кирәк», — дияр.

Аннан соң Аллаһы Тәгалә тарафыннан нида килер: «Әй мөэмин, мотыйг бәндәм, син юк хәлең белән вә зәгыйфлегең белән бер-ике көнлек дөньяда күргән, бер-ике көн мосахиб булган дустыңның тәмугка кермәкенә разый түгелсең. Инде сине нитәк гафу кыйлмамын ки, бөтен гомерең буе мине таныдың. 60–70 ел мине тәүхид кыйлдың. Бар, инде дустыңны алып кит. Җәннәткә аны сиңа һибә кыйлдым». Кайчан ки сиңа бер мәртәбә нида кыйлды, гозер кыйлды вә егълады, бер мәртәбә егъламакы өчен, бер мәртәбә нидасы өчен, син аның тәмугка төшүенә риза булмадың. Инде мин мөэминнәрне ничек ут белән газап кыйлаем? Кайчан ки мөэминнәрем гыйлем вә вәгазь мәҗлесендә егъладылар, җәмигъ гомерләрендә истигъфар кыйлынды егълыйлар. *Нәббиэ гыйбади әнни әнәл гафурур-рахим.*

---

Көннәрдән бер көн шәех Әбү Язид әл-Бистами мөридләре белән утырганда, мөридләреннән берсе аяк үзрә торды, әйтте: «Йә шәех, мин — мөридмен, син — шәехсең. Шәехнең мөрид үзәрендә хакы нидер? Вә мөриднең шәех үзәрендә хакы нидер? Миңа хәбәр бир ки, беләсем киләдер», — диде. Шәех әйтте: «Миннән зур сүз сорадың — олуг сердән сөаль кыйлдың. Ләкин мин сөалеңә җавап бирмәймен, таки минем хаҗәтемне әда кыйлмасаң», — диде. Мөрид әйтте: «Ни хаҗәтең бардыр?». Шәех әйтте: «Солтан Мәхмүдкә мин хат яздым. Шул хатымны солтан Мәхмүдкә илтеп бир. Аннан җавап алып кайт», — диде.

Солтан Мәхмүд Нисабур шәһәрендә иде. Шәех белән Нисабур арасы 60 фәрсах җир иде. Бәс, мөрид, дәрхаль, хатны алды, мәнзиленә дә кайтмады, азык вә хайван да алмады, җыенып китте. Нисабур шәһәренә җитте. Солтанның капусына килде, үзен белдерде. Солтан янына китерделәр. Солтан шәехнең хатын алып үпте. Ачып укыды вә әмер кыйлды. Мөридне хөрмәтләп, бер урынга утырттылар. Алдына нигъмәт китерделәр. Ашады. Су бирделәр. Эчте.

Аннан соң солтан бер җариясен җибәрде, әмер кыйлды: «Әгәр мөрид тәгам иштиһа кыйлса, хәзерләп бир», — диде. Бәс, җария мөрид янына килде. Мөрид ул җария белән хәлвәттә булды. Җария әйтте: «Нәфсең ни-нәрсә иштиһа кыйлыр: хәзерләп бирәм», — диде. Мөрид әйтте: «Хәзер сөтле аш пешермәк яхшы булыр иде, таки юл тузаннарыннан күкрәгем бушар иде», — диде.

Бәс, җария казан астына ут кабызырга торды. Иблис диде: «Мөриднең күңеленә шәһвәт утын кабызырга торды». Яхшы, кайчан ки мөрид җарияне күрде: озын сачлы, җәмал иясе җариядер. Торды. Җариянең сачына кулын суздь. Дәрхаль үзенә

шәһвәт галәбә кыйлып, сабырга такате калмады. Ишекне бикләде. Җариягә сарылды, зинага касд кыйлды.

Шул хәлдә Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән дивар ярылды. Шәех Әбү Язиднең һәйәте[1] заһир булды. Әйтте: «Гафил булма, мөрид», — диде. Мөрид бу вакыйганы күрде, әгъзалары калтырады, Аллаһы Тәгаләнең газабыннан курыкты. *«Раббәна заләмнә әнфусәнә»*, — дип, аннан чыкты. Солтан Мәхмүд янына килде, китмәгә дәстүр сорады, солтан дәстүр бирде. Шәех янына кайтып китте. Шәех ул мөридне күргәч тә әйтте: «Йә мөрид, сөаленнең җавабы хасыйл булдымы синдә», — диде. Мөрид: «Әйе», — дип хамуш булды[2]. Әбү Язид әйтте: «Инде шәехнең мөрид үзәрендәге хакыннандыр ки, мөрид шәех боергән нәрсәгә һәммәсенә мотыйг булгай. Вә мөриднең шәех үзәрендәге хакыннандыр ки, мөридне ригая кыйлгай вә җәмигъ әхвәлендә мөриднең эшенә мотталигъ[3] булгай вә мөридне хата вә гөнаһ эшләмәктән саклагай», — диде.

———

Аллаһы Тәгалә Кәлямендә әйтте: «Һич берегез калмас, барчагыз тәмугка ирешерсез», — диде. Вә дәхи пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Мөэминнәр сыйрат күпереннән яшен тик үтәрләр», — диде. Инде аять белән хәдис арасында каршылык булмайдырмы? Чөнки аятьтән фәһемләнә: барча халаиклар тәмугка ирешерләр. Вә хәдистән фәһемләнә: мөэминнәр торфәтел гайндә сыйрат күпереннән үтеп китәрләр. Җавап будыр ки: аять белән хәдис арасында каршылык юктыр. Чөнки ирешү гобур[4] мәгънәсендәдер, керә мәгънәсендә имәстер. Дәлил будыр ки: Муса галәйһиссәлам кыйссасында *«вәләммә вәрадә мәәъә мәдйәнә»* диде, *«вәләммә вәкага мәәъә мәдйәнә»* яки *«вәләммә вәрадә мәәъә мәдйәнә»* димәде. Ушандак, Мөхәммәд өммәтенең сыйрат үзрә ирешүе утка вә тәмугка керү мәгънәсендә түгелдер.

Дәхи белгел ки, әй угыл, утның ике хасияте бардыр ки: яктыртмак вә көйдермәк. Бәс, мөэминнәр вә кяферләр тәмугка төшteләр. Кяферлар өчен ут көйдермәк хасиятен истигъмаль кыйлыр, мөэминнәр өчен яктыртмак хасиятен истигъмаль кыйлыр. *Сөммә нунәҗҗил ләзинәт-тәкау вә нәзаруз-залимина фиһә җәсиян.*

Заман кадимдә бер гаттар[5] бар иде. Килгән фәкыйрьләрнең вә мескиннәрнең хаҗәтен әда кыйлыр иде. Көннәрдән бер көн бу гаттар янына нәҗес чистартучы килде. Кулын сузып, гаттардан гатыр сорады. Гаттар әйтте: «Мин сиңа гатыр бирмәм,

[1] Һәйәте — образы.
[2] Хамуш булды— дәшми торды.
[3] Мотталигъ — хәбәрдар.
[4] Гобур — кичү.
[5] Гаттар — хушбуйчы.

дип әйтмимен. Ләкин синең кулың бик кабахәт, гатыр тотарга салахиятле түгелдер. Бар, кулыңны юып кил, аннан соң гатыр бирермен», — диде.

Бәс, бу кәннас, үзенең гөманынча, бик олуг мәшәкатькә тарыды. Кулын юмак бик мәшәкать тоелды. Әгәр әүвәлдә гатырга әһел булса, эш сәһел булыр иде.

Бу кыйссадан хисса будыр: әй угыл, һич гөман кыйлмагыл ки, гафу итүнең эше гаттарның эшеннән кимдер дип. Гәрчә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте киң, ишеге ачык, җәннәт чатырлары мөбах булса да, ләкин бәндәләрнең куллары — нәҗес чистартучы кулы кебек пычранган җисемнәре ушандак гөнаһ пычрагы белән пычранган. Вә хөббе дөнья тузаннары белән калебләре пычранган. Шул җәһәттәндер Аллаһы Тәгалә: *«Вә ин минкүм иллә вәридуһә»*, — диде. Таки утка илтеп, ут белән гөнаһларын юып пакъламай торып, җәннәт гатырларын вә җәннәт нигъмәтләрен тотарга салахиятләре юктыр. «Әүвәл, тәмугка ирештерермен, аннан соң оҗмахка кертермен: җәннәтне сезнең өчен яраттым», — диде.

Инде, әй угыл, моның хасыйлы будыр ки: Аллаһы Тәгалә һәр бәндәне, суфиларны бер мәртәбә утка кертеп юып чыгарыр, аннан җәннәткә илтәр. Нитәкки әйтелде: *«Суфиян сафра, әүвәл бадузах мәй бәрәнд шист вә швиш микәнәнд, сани, ба җәннәт мәй бәрәнд»*, — дип.

---

Мәгълүмдер ки, калеб дигән бер җәүһәр шәрифтер. Чөнки әгъзаның шәриф булмаклыгы вә җәсәднең төзеклеге калебтәндер. Нитәкки пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: *«Иннә фи вүҗүди ибни адәмә, модгатән изә салихәт салүхә биһә сәируль җәсәди әлә вәһийәл-кальб»*, — диде. Калеб — адәмнең эчендә бер кисәк иттер, йөрәк тәгъбир кыйлыныр. Вә гыйһан күңел дигән сүзгә мөкабил булыр. Калеб лөгатьтә «әйләнмәк, дүнмәк» мәгънәсендәдер. Аллаһы Тәгаләнең мәхлуклары арасында калебтән шәрифрәк нәрсә юктыр. Калеб — бер раббани котычыктыр вә рәхмани энҗеләр белән тулыдыр. Аллаһы Тәгалә һәркөнне бәндәнең калебенә 360 мәртәбә карар.

Инде бу кадәр шәриф нәрсәне дүнмәк вә әйләнмәк мәгънәсендә булган «калеб» белән тәсәмма кыйлынмакында ни хикмәт бардыр? Җавап будыр ки, әй угыл: калеб вә күңел бик нечкә нәрсәдер. Бик тиз үзгәргүче нәрсәдер. Аз нәрсәгә разый була, аз нәрсәдән каладыр. Кайчакта бик күтәрелеп китә, кайчак бик төшеп китәдер. Кайчак анда йөгерә, кайчак монда йөгерәдер. Дөньяда күңелдән йөгерек нәрсә юк, дип шуның өчен әйткәннәрдер. Бер дәкыйкадә[1] бөтен җирне, күкне — бөтен дөньяны сәер кыйладыр. Әмма белгел ки, әй угыл: күңелнең

[1] Дәкыйкадә — аерым өлештә, кисәктә.

тәкаллебе үзенең затыннан түгелдер. Аллаһы Тәгаләдәндер. Нитәкки пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: *«Йә мукаллибәл кулуби сәббит кальби галя диникә»*.

---

Галәм кадимдә бер җумарт адәм бар иде. Аның гадәте бу иде: көндез кибетен ачмас иде. Кич булса, кибетен ачып, мизанын асып, чырасын яндырып утырыр иде. Моннан морады бу иде ки: халык арасындагы яман ялган дирһәмнәрне һәммәсен үзенә җыйды. Һәркем нәрсә алырга яман акча алып килсә, берсен дә кайтармады. Халык моны белгәннән соң, кайда ялган акча бар, һәммәсен моның кибетенә китереп, сирәк нәрсәсен алыр иде.

Бәс, бу бәкъкаль[1] һәммә ялган акчаларны бер җиргә җәмигъ кыйлды. Кайчан ки әҗәле якын килгәч, бу яман акчаларны чыгарып, һәммәсе янына куйды. Мөнаҗәт кыйлды, әйтте: «Илаһи, мин ялган дирһәмнәрне һәммәсен синең бәндәләреңнән кабул иттем. Бу — яман акча! дип йөзләрен ертмадым. Таки мине һәм гаепләрем белән кабул иткәйсең. Мин, фәкыйрь вә мохтаҗ була торып, шөйлә кыйлдым. Син — гани, син — моңсыз падишаһсың. Гаҗиз була торып, мин моны кыйлдым. Син — кадирсың», — диде. Аннан соң нида ишетте: «Әй бәндәм, кайгырма, син — мәкъбульләрдәнсең. *Лиәннә мин гадәтил кәрими ән якъбәләд-дүнәл-хасис. Фә әбшир фәинни кабилтукә лиәнни әнәл гафурур-рахим»*, — диде.

---

Гыйшык ни-нәрсә? Фәлән кеше фәлән кешегә гашыйк булды, ягъни аның тәнен тәне белән сөйде, җанын җаны белән сөйде мәгънәсендәме? Әгәр шулай булса, гыйшык мөҗанәсәтне[2] игътиза кыйладыр. Аллаһы Тәгаләгә гашыйк. Аллаһы Тәгаләнең гыйшкы. Гыйшык хакыйкый «Аллаһы Тәгаләгә гашыйк булмак» дигән кебек сүзләр Аллаһы Тәгалә хакында нисбәт итү ничек җаиз булыр? Җавап будыр ки: әй угыл, гыйшык дигән нәрсә бер сердер. Аны ачу мөмкин түгел. Һичкем аның хакыйкатен белгән юк. Әгәр берәү: «Мин гыйшыкка кадирмын», — дип әйтсә, белгел ки; ул кеше гыйшык ни икәнен үзе белмәйдер. Ләкин бары шуны белмәк тиеш: гыйшык — төтенсез уттыр, ачкычсыз йозактыр, дәвасыз сырхаудыр, кадәхсез шәрабтыр, йөксез авырлыктыр, мәнзилсез сәфәрдер. Гыйшык — шәвындыр, ишрактыр, игъррактыр, ихрактыр. Һәрнәрсә гыйшыктан мөтәләүвин[3] булыр. Гыйшыкның төсе юктыр. Дөнья кәйдендә[4], мал кәйдендә, хәят кәйдендә булган һәрбер кешенең

---

[1] Бәкъкаль — яшелчә кибете тотучы.
[2] Мөҗанәсәтне — бер женеслелекне.
[3] Мөтәләүвин — төрле төстә.
[4] Кәйдендә — мәкерендә, алдавында.

гыйшыктан хәтәре юктыр. Гыйшык гашыйктан мөштактыр. Гашыйк колмак шикелле агачка чорнашып үсә торган бер үләндер. Агачка, җимешкә ябышып үсәр. Ул гашәка үләне ябышып үскән нәрсәнең рөтубәте бетәр, корыр. Бакчачылар җимеш агачларын бу үләннән бик саклыйлар, йолкып ташлыйлар. Аны хайван ашый. Хайваннарның тизәген тиреслек башына түгәләр. Аннан бакчачы җыеп аладыр, бакчасының туфрагын ислах кыйладыр. Анда дәхи гашәка үләне үсәдер. Янә агачка вә җимешкә чорналадыр. Кисkәннең соңында, хайван ашаганның соңында янә асылына кайтадыр.

Гыйшык хәле һәм ушандактыр. Әгәр берәүгә егет вакытта гыйшык ирешсә, анда мөлязим булыр, һич аерылмас. Йөзенең нуры китәр. Шәһвәт вә ләззәтләрен кисәр, мизаҗын тәгъйир кыйлыр. Вә токымын киптерер, нәселен кисәр. Гыйшыклык бер кадәхтер ки, эчендә фәна уты янар: ул һәлак булыр. Ушандак мөэминнең Аллаһы Тәгаләгә гыйшкы шөйләдер. Мәңгегә аннан аерылмас, таки матлубка васыйл булганчы. *Каулүһү Тәгалә: вүҗүһүй-яумә изин нәзиратүн илә Раббиһә нәзиратүн.*

———

Әй угыл, белгел ки: кайчан кыямәт көне булса, Аллаһы Тәгалә Исрафилга сурын өрмәгә боерыр. Җәмигъ җаннар үләр. Мәгәр Газраил, Исрафил, Микаил, Җәбраил вә хамәләи Гарш кына калыр. Вә дәхи иблис калыр. Аннан соң Аллаһы Тәгалә иблиснең җанын алмага боерыр. Бәс, Газраил иблиснең җанын алмага касд кыйлыр. Иблис качар: җир астына керер — гаувaслар суга чумган кебек, җиргә чумар. Әүвәлдә Адәм туфрагыннан качты, ахырдан ул туфракка илтиҗа кыйлыр, туфракка сыеныр.

Инде, әй угыл, гасый бәндәләрнең дә вә бинамазларның да хәле шөйләдер. Дөньяда намаздан качарлар вә Аллаһы Тәгаләдән качарлар. Намазны дошман тотарлар. Дөньяны вә малны, вә байлыкны дус тотарлар. Кайчан ки кыямәт көне булса, намазга илтиҗа кыйлырлар вә Аллаһы Тәгалә алдында сәҗдә кыйлырлар, малларыннан качарлар. Чөнки дөньяда хәерсез маллар — зәкятсез маллар кыямәт көнендә елан, чаян сурәтендә булып иясенә ябышырлар. Вә дәхи дөньяда голямадан качарлар. Кыямәт көнендә күрерсең: голямадан шәфәгать эстәрләр.

Бәс, иблис җиргә кереп качар. Газраил барып җитәр. Иблис аннан һавага качар. Газраил артыннан барып җитәр. Дәрьяга керер. Газраил дәхи артыннан дәрьяга керер. Каф тавына качар. Газраил аның артыннан Каф тавына барыр. Хәтта Газраил гаҗиз булыр, иблисне тота алмас. Аллаһы Тәгаләгә мөнәҗәт кыйлыр, сәҗдә кыйлыр вә әйтер: «Илаһи, гаҗиз булдым, иблисне тота алмадым».

Бәс, Аллаһы Тәгаләдән нида килер: «Йә Газраил, тәмугка бар, мәләккә әйт: тәмуг этләреннән сиңа 70 мең эт бирсен.

Иблисне шул этләр белән ау кыйлырсың». Аннан соң Газраил җәһәннәмгә килер. Ул, этләрне ияртеп, иблис артыннан китәр. Этләр һәр әтрафтан иблискә ябышырлар, гаҗиз булырлар — тота алмаслар. Газраил янә мөнәҗәт кыйлыр, әйтер: «Илаһи, этләр һәм гаҗиз булды». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Янә шулкадәр эт җәһәннәмнән барып ал», — дияр. Шул рәвешчә, Газраил, җәһәннәмнән ничә йөз мең эт алып, этләр белән иблисне ау кыйлыр. Ахыр иблис гаҗиз булыр: җирдә-күктә, дәрьяда-һавада — һичкайда качарга вә сыенырга урын тапмас. Үзен җиргә атар — этләр, җыелып, иблисне таларлар. Ошбу җир — Адәм галәйһиссәламнең төрбәсе булыр. Газраил килеп күрер: иблис бу төрбә өстендә сәҗдә кыйлып ятыр. Газраил әйтер: «Йә мәлгунь, Адәмгә сәҗдә кыйлмага әмер булган вакытта, ник сәҗдә кыйлмадың да хәзер сәҗдә кыйласың?» Иблис әйтер: «Мин Адәмгә сәҗдә кыйлмаймын. Бу Адәм кабере микән? Мин белмәдем». Газраил әйтер: «Син белмәйсәң, мин беләмен, бу — Адәм кабередер». Аннан соң иблис туфрактан башын күтәрер, әйтер: «Алай булса, әйдә, мине җәһәннәмгә илт. Мин һәнүз Адәмгә сәҗдә кыйлмаймын».

Бәс, иблис качарга теләр. Газраил газап вә һәйбәт белән тотар, 70 мең җирдән хәрбәсе белән сугар. Әтрафтан җәһәннәм этләре килеп талар. Иблис төрле газаплар белән сәкарәте мәветне татыр. Бер мәртәбә шул кяфер кычкырыр ки, әгәр дә дөнья халкы ишетсә, кинәт үләр иде. Аннан соң Газраил иблиснең җанын алып, җәһәннәмгә — Мәликкә илтеп тапшырыр.

———

Бер җаһил хатын үзенең йортыннан хаҗ нияте белән сәфәргә чыкты. Мәккәгә барып җитте. Кәгъбәтулланың кәйфиятен күрде. Түбәсен, диварларын — һәммәсен тикшереп карады. Әйтте: «Бу Кәгъбәтулла дигәннәре минем өем кебек лә! Минем өемнән артык җире юк, имеш лә! Минем өем дә моннан ким түгел», — диде.

Инде, әй угыл, мин бу ләтыйфәне ни өчен әйттем? Бу ләтыйфәдән максуд будыр ки, мәҗлес әһеленең хәле һәм ушандак шул җаһил хатын хәле кебектер. Нитәкки ул хатын Кәгъбәтулла белән үз өендә аермалык тапмады. Бу, мәҗлес әһеле кәзалик җаһил кем, галим кем, аермалык кыйлып белмәсләр. Хәлбуки ярты галим — агудыр, бөтен галим — тирьяктыр[1]. Ягъни галим нәкыс[2] — агу кебектер вә галим кямил вә гамил — тирьяк кебектер. Бәс, тирьяк булган җирдә агуның куәте калмас.

———

Искәндәр Зөлкарнәенне, исемен Хакани диләр иде, бер галим кямил, хәким фазылы бар иде. Һөнәре — падишаһка тирь-

[1] Тирьяктыр — агуга каршы дарудыр.
[2] Нәкыс — кимлек.

як тәркиб кыйлыр иде. Тирьякны падишаһка ашатыр иде. Аның артыннан агу һәм эчерер иде. Зөлкарнәеннең сакалы китәр иде, төкләре һәм коелыр иде. Берничә мәртәбә шөйлә кыйлды.

Көннәрдән бер көн Зөлкарнәен әйтте: «Йә Хакани, син минем дустыммы яки дошманыммы?» Вәзир әйтте: «Һич дошманлыгым юктыр, мин — дустыңмын». Зөлкарнәен әйтте: «Дустым булсаң, ник миңа агу бирәсең?» — диде. Вәзир әйтте: «Мин сиңа агу бирәмен, үзең өчен тәркиб кыйлган тирьякны тәҗрибә кыйлмак җәһәтеннән. Ул тирьяк сине агудан хәлас кыйлырмы, кыйлмасмы, дип. Әгәр ул тирьякым үзем тәркиб кыйлган агудан хәлас кыйлса, гайре агулардан һич чиркәнмәймен», — диде.

Вакыйган, Зөлкарнәенгә дошманнары ничә мәртәбә агу бирделәр, вәзир тирьякы белән хәлас булды. Хәтта айда ничә мәртәбә агу эчәр иде, зарар итмәс иде. Инде, әй угыл, галим вагыйзның вәгазен тыңлагучы мөэмин вә мөселманнарның һәм хәле шөйләдер. Галимнәр — тирьяктыр, җаһиллар — агудыр. Сиңа Кәлям әзәли вә хәдис нөбуви тирьякын эчерттем. Мәгънәләр энҗесен куеныңа салдым. Мөддәгый вә накыйсел галимнәр сиңа агу җаһилне эчертмәгә мосадыйк булсалар да, сиңа зарар итмәс. Чөнки әүвәлән тирьяк эчтең. Инде җәһел агуын эчмәгә син мөстәгыйдсең. Ягъни зәляләт җәһалә сиңа зарар итмәс. *Вә зәккир фәиннәз-зикра тәнфәгуль-мүэминин.*

---

Көннәрдән бер көн Имам Әгъзам разыйаллаһу ганһу шәкертләре белән гыйлем мәҗлесендә иделәр. Имам Әгъзамны бер чаян килеп чакты. Шәкертләре бу чаянны үтермәгә касд кыйлдылар. Имам Әгъзам әйтте: «Әгәр минем мөхиб вә мөхлисләрем булсаңыз, тимәңез, үтермәңез», — диде. «Сәбәп нидер?» — диделәр. Имам Әгъзам әйтте: «Сәбәп шулдыр ки: үземне тәҗрибә кыйласым килде. Мин шул голяма җөмләсеннән микән ки, алар хакында пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте, *лухумул голямаъ мәсмумәт,* диде». Бәс, чаянны күрделәр: сәгать ба сәгать һаман зәгыйфьләнде. Качарга хәле калмады, шул җирдә үлде.

Инде, әй угыл, бу хикәяттән сиңа хисса шулдыр: мөэминнәрнең, хосусан галимнәрнең, гайбәтеннән зиядә саклангансың — голяма итен ашамактан гаять ихтираз кыйлгайсың. Чөнки кешене гайбәт кыйлмак — аның итен ашамак белән бәрабәрдер. Нитәкки адәм итен ашамак — харам, гайбәт кыйлмак та харамдыр. Гайбәтнең харамәте нас[1] белән сябиттер. *Каулә-*

---

[1] Нас — биредә: Коръән сүзе.

*һу Тәгалә: «Вә ля ягътәб бәгъдукум бәгъзан әюхиббу әхәдукум ән йәкулә ләхмә әхыйһи».* Таки гайбәт агуы беләи мәсмүм булган хәлендә үлмәгәйсең. Мин сиңа галим гамил гайбәтеннән саклан, дип хаслап әйттем. Чөнки галим гайре гамил, ягъни гыйльме белән гамәл кыйлмаган галим җаһил мәнзилендәдер. Шуның өчен гыйльме белән гамәл кыйлмаган галимнең сүзе берәүгә дә әсәр итмәс.

Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: *«Мисле гамимел голәмаъ кимсәл катрәтел әмтар».* Ягъмурның хасляте улдыр ки: мәкнүн вә мәстүр булган нәрсәләрне изһар кыйлыр. Мәсәлән, җирдән нәбатлар чыгарыр. Агачтан җимешләр үстерер. Сәдәфтән энҗеләр чыгарыр. Еланда зәһәр пәйда кыйлыр. Болар барсы да ягъмур хасиятеннәндер. Ушандак кайчан ки гамәл гамилләр гыйлем нәшер кыйлсалар, вә дәрес әйтсәләр, вә дәхи вәгазь вә нәсыйхәт кылсалар, гыйлем вә вәгазь тыңлагучыларга аның әсәре ирешсә, бәгъзеләреннән — тагать энҗесе чыгар, вә бәгъзеләреннән садака җимеше үсәр, вә бәгъзеләреннән тагать вә гыйбадәт сәмәрәсе зоһур итәр. Вә бәгъзеләреннән мәгъсыять вә нифак зәһәре пәйда булыр. Бәс, ул вәгазь вә гыйлем тәбгы сәлимнәр өчен — тирьяк вә тәбгы сәкыймнәр өчен — зәһәр булыр. Зирәки бу нәрсәләр галим вә голямаларның сәрләрендә[1] мәстүр иде. Бәс, гыйлем вә вәгазь тыңлаучыларга гыйлем тамчысы иреште, күңелләрендә мәстүр булган нәрсә зоһурга килде. Гыйлемнең хасияте һәм ягъмур хасияте кебектер: күңелләрдә мәдфүн булган[2] нәрсәне үстерер.

Аллаһы Тәгалә үзенең Кәлямендә: *«Яумә ля йәнфәгу мәлүн вә ля бәнүнә иллә мин әтәллаһу би калбүн сәлим»*, — диде. Бәс, *«калбүн сәлим»* нидер вә ни-нәрсәдер? Вә аның галәмәте нидер? Инде, әй угыл, бу сөальгә җавап бирәсе булсаң, әйт ки: гарәпләр, сәлим, диде шул кешегә ки, берәүне елан чакса, дәва вә тирьяк белән дәва итеп төзәлсә, үлми калса, *һәза риҗале сәлим* — елан чагып үлми калган кеше мәгънәсендәдер.

Бәс, калебе сәлим һәм ушандак: ул шундаен калебтер ки, аны иблис чакты. Бәс, калеб мәгъсыять зәһәре белән мәсмүм булды. Аннан соң галим гамилләрнең гыйльме белән вә вагыйзларның вәгазе белән дәва кыйлды. Тәүбә тирьякы эчте. Егълап-сыктап, үкенеп, Аллаһы Тәгаләнең ишегенә сыенды. Вә сынык күңел белән вә хозуг-хошуг белән тагать вә гыйбадәткә егылды. Бәс, бу кешегә калбүн сәлим рузи кыйлынды. Дәхи, әй

---

[1] Сәрләрендә — баш кешеләрендә.
[2] Мәдфүн булган — күмелгән.

угыл, калбүн сәлимнең галәмәте ошбудыр, мәсәлән, елан чаккан киндерәдән куркар — гавам мәкуләсе. Бу сүз китапларда һәм бардыр: *«Мән ләдә гатһүл хәяту яфирру минәл хәблил әблак»*. Вә дәхи фарсия: *«Тар гәзидә рәсман мәй тәрсәд»,* — диләр. Берәүне елан чакса, аннан сәламәтләнсә, җирдә яткан киндерәне күргән саен, елан түгел микән? дип куркып китәр. Бәс, ушандак иблиснең зәһәр угыннан җәрәхәтләнеп, тәүбә тирьякы белән терелгән калеб үзендә бер гөнаһ эш тапса, риҗаль сәлим киндерәдән курыккан шикелле: «Аһ, гөнаһлылар җөмләсеннән булдым бугай?» — дип, йөрәге гөлт итеп кубадыр. Бергә кадими гөнаһлары һәм исенә төшеп, калебе моңсар буладыр. Моңсыз калеб — бер хәзинәдер. Бәс, сынык күңелләрне төзәтүче — Аллаһы Тәгаләдер. *Фәйәкулүллаһү Тәгалә әннә җаируль кулүбил-мункәсират.*

———

Дауд галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә мөнәҗәт кыйлды: «Илаһи, һәрбер падишаһның хәзинәсе бардыр, әмма синең хәзинәң кайда?» — диде. Бәс, Аллаһы Тәгаләдән вәхи килде: «Йә Дауд, минем хәзинәм Гарештән биегрәк, Көрсидән киңрәк, таулардан олуграк, күктән зиннәтлерәк, җәннәттән нигъмәтлерәк, *әлә вәһиял колубүл мункәсират»,* — диде. Ягъни: агяһ бул ки, һәрбер сынык күңел — минем хәзинәмдер. Инде, әй угыл, калебе сәлимнең галәмәтен мин сиңа яңабаштан бәян кыйлам.

Кайчан ки Адәм галәйһиссәламгә иблиснең чагуы исабәт кыйлып, Аллаһы Тәгаләгә гасый булды, вә зилләт зәһәре белән мәсмүм булды. Бәс, җәннәттән чыгу сәбәпле, калебе вә күңеле яраланды. Сәрәндиб тагына инде. Вә Сәрәндиб тагында: *«Раббәнә заләмнә әнфусинә»*, — дип, 200 ел егълады. Йөзен җиргә куеп, сәҗдәдә ятты. Мөттасыйлән күзеннән аккан яшь белән этрафында печән үсте, башы вә тәне үлән эчендә күмелеп калды.

Зилаәсе хәтеренә килгән саен «аһ!» дисә, авызыннан ут чыгып, үләнне яндырыр иде. Хәтта тәүбәсе кабул булганчы шөйлә егълап ятты. Аллаһы Тәгалә васитасыз аңа нида кыйлды: «Йә Адәм, әнтә сафи», — диде. Адәм җавап бирмәде. Икенче мәртәбә Аллаһы Тәгалә янә: «Йә Адәм, әнтә сафи», — диде. Адәм һәнүз җавап бирмәде. Бәс, фәрештәләр куркудан тетрәнделәр: «Шиксез, һәммәмез һәлак буламыз, чөнки Адәм галәйһиссәлам Тәңресенә җавап бирмәде», — диделәр.

Аннан соң өченче мәртәбә нида килде: «Йә Адәм, әнтә сафи», — диде. Адәм дәхи җавап бирмәде. Ахыр Җәбраил галәйһиссәлам инде әйтте: «Йә Адәм, Раббың нидасын ишетмәдеңмени?» — диде. Адәм әйтте: «Ишеттем». Җәбраил әйтте: «Алайса, ник җавап бирмәдең?» — диде. Адәм галәйһиссәлам әйтте:

«Ул нида кыйлды, «әнтә сафи» диде. Мин нитәк сафи булаем? Мин — гыйсъян кыйлдым. Ләкин мин гөман кыйлдым ки, Аллаһы Тәгалә икенче Адәм яраткандыр да аңа нида кыйла торгандыр, дидем. Әгәр миңа нида кыйлса, *фәләббәйк Аллаһүммә ләббәйк*», — диде. Дәрхаль Аллаһы Тәгаләдән Җәбраилгә нида килде: «Йә Җәбраил, Адәмнән сора, мин васитасыз нида кыйлган вакытта, аның хәле ни кәйфияттә иде?». Җәбраил галәйһиссәлам сорады. Адәм әйтте: «Аллаһы Тәгаләдән гайре мәгъфирәт кыйлгучы юктыр, дип, күңелемнән әйтеп торадыр идем. Ләкин гөнаһым исемә төшкән саен, калебем мөнкәсир булды», — диде. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Йә Җәбраил, син гуаһ бул, мин сыных күңелләр янындамын», — диде.

Инде, әй угыл, һәр заман мәгъсыять сәбәпле, калеб мөнкәсир булса, ул калеб Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән өмидне кисмәс, мәгъсыятьтән куркуны онытмас. Риҗа белән хәвеф арасында мөтәхәйир булып торыр. Бәс, ошбу калеб — калбүн сәлимдер.

———

Нисабур шәһәрендә сахибет тарикать бер олуг шәех бар иде. Исемен Әбү Хифыс әл-Хәддади диләр иде. Бер кечкенә кызы бар иде. Бу кыз бәлягатькә ирешеп, бер кешегә никяхландырмак булды. Әмма бу шәех сурәттә — фәкыйрь, һиммәттә гани адәм иде. Кыз ишетте: атасы кияүгә бирергә тели, имеш. Атасы янына килде. Утырды. Егълады. Өстендә начар гына иске кием иде. Шәех әйтте: «Әй кызым, никях Аллаһы Тәгаләнең әҗередер, ник егълыйсың», — диде. Кызы әйтте: «Әй ата, минем егъламакым аның өчен түгелдер. Ләкин син — фәкыйрь кешесең, минем җиһазым юк. Халык безне хәкыйрь күрер. Халык арасында без намусланырмыз. Дәхи ят кеше янына горус булып кергәндә, җиһазым булмаса, кием-салым фәкыйранә булса, халык арасында хур-хәкыйрь күренермен, оялырмын, дип куркып егълыймын. Әмма синең Аллаһы Тәгалә каршында вә пәйгамбәрләр янында изге гамәлең булмаса, кабер җиһазына алып барырга җиһазың булмаса, кыямәт туенда киенергә гамәл киемең булмаса, синең хәлең ничек булыр? Гарасате кыямәттә мөэминнәр күзенә хур-хәкыйрь күренерсең ләбаса. Пәйгамбәрләр арасында вә Аллаһы Тәгалә каршында бик олуг хәҗаләткә төшәрсең ләбаса. Кыямәт горусына ни җиһаз хәзерләдең, әй мескин?»

Аннан соң шәех әйтте: «Әй кызым, дөрес әйтәсең: әсбаб дөньядан нәрсәмез юк — малымыз юк. Безнең насыйбымыз — ахирәттәдер, соң, нишләмәк кирәк?» — диде. Кызы әйтте: «Син фәкыйрь кеше булсаң да, Аллаһы Тәгалә байдыр, аннан сора, таки мин ирем алдында хәҗаләткә төшмәгәймен», — диде. Шәех

әйтте: «Бәли, шулай булсын. Синең өчен Аллаһы Тәгаләдән мал сораек, Аллаһы Тәгаләгә бу бик сәһел эштер», — диде.

Бәс, кич булды. Халык йоклады. Мәсҗет ул шәехнең якынында иде, торды да мәсҗеткә китте. Ике рәкәгать намаз укыды. Аннан соң Аллаһы Тәгаләгә мөнәҗәт кыйлды, әйтте: «Илаһи, ошбу сәгатьтә бетмәс-төкәнмәс хәзинәңнән миңа мал бир: таки кызым зәүҗе алдында хәҗил булмагай», — диде. Әмма җавап та ишетелмәде, бернәрсә дә күренмәде. Шәехнең ачигы килде, әйтте: «Илаһи, сораганымны бирмәсәң, ошбу таягымны алырмын, өеннең, ягъни мәсҗетнең, кандилләрен ватармын, өеңне ут салып яндырырмын. Киемнәремне ертырмын. Гомердә өеңә кермәмен», — диде.

Шул сәгать мәсҗетнең түшәме ярылды, түшәмнән алтын ага башлады. Бәс, шәех алтыннарны итәгенә, куенына тутырды, һаман түшәмнән алтын коела. Хәтта шәех: «Бәс! Бәс!» — димәккә мәҗбүр булды. Ягъни: «Җитәр! Җитәр!» — дип кычкырды. Алтын туктады.

Мәсҗетнең бер почмагында бер фәкыйрь кеше бар иде, шәехнең хәлен, һәммәсен күреп торды, әмма шәех мәсҗеттә кеше барын белмәде. Алтыннарны тутырып, мәсҗеттән чыга башлады. Ул арада мәзкүр фәкыйрь бу шәехкә каршы килеп чыкты: «Йә шәех, игенеңне җыйдың. *Вә эту хәккаһү яу мә хәсадиһи.* Инде гошереңне бир! Дога орлыгы синнән булса, «Амин» тубалы миннән булды», — диде. Бәс, шәех алтыннарны бу фәкыйрь белән тәкъсим кыйлышты. Нисфен фәкыйрьгә бирде. Фәкыйрь әйтте: «Йә шәех, бу малны Аллаһы Тәгаләдән сорадың, ни өчен әдәп тарикы илә сорамадың? Хәтта өеңне утка ягармын, кандилләреңне ватармын, дидең». Шәех әйтте: «Мин аннан гайре кешенең ишегенә бармаска, аннан гайре кешедән һичнәрсә сорамаска, аның белән гаһед кыйлышкан идем. Ул һәм миннән гайре кешедән сорама, үзем бирермен, дигән иде. Мин ошбу зәгыйфьлегем белән аның әмерен рәд кыйлмадым. Дәһи аның тыюына гөнаһлы булмадым. Хәлбуки ул кави вә ганидер. Әгәр сораганымны бирмәсә, тәхкыйк әйткәнемне кыйлыр идем», — диде. Фәкыйрь әйтте: «Бер дә курыкмадыңмы?» Шәех әйтте: «Әүвәл мәртәбә ул минем рухыма гыйшык утын ыргытты. Курку ташы белән минем йортымның кандилен сындырды. *Ку әнфусәкум вә әһликум нарә.* Мөнҗәникы белән саумәгамны харап итте. Миннән калебемне сорады. Мин ошбу гаҗизлегем вә зәгыйфьлегем белән ул сораганны аңа һәммәсен бирдем. Әмма ул шулкадәр кодрәте була торып, шулкадәр җәмигъ галәмнән моңсыз вә гани була торып. Әй борадәр, син мине бу алтыннарга разый булыр дип беләмесең?! Юк! *Фабилләһил-ләзи эл җәләлү сыйфәтүһү*. Әгәр

дә кыямәт көнендә күңеле сыныкларга мине шәфәгатьче кыйлмаса, җәмигъ гөнаһлыларны миңа һибә кыйлмаса, валлаһи, оҗмахка кермәмен. Касырларын, хурларын кабул итмәмен, һаман гөнаһлыларны таләп кыйлырмын, хәтта аларны хәлас кыйлырмын», — диде. Фәкыйрь әйтте: «Йә шәех, бу кәрамәтне ни белән таптың?» — диде. Шәех әйтте: «Аның бәндәләре өчен таләбем белән вә бәндәләренә догам белән таптым», — диде.

Инде, әй угыл, әгәр Аллаһы Тәгаләдән бу дәрәҗәне теләсәң, Аллаһы Тәгалә өчен хәлас гамәл кыйл. Үзең өчен нәрсә эстәмә, бәлки, Аллаһы Тәгаләнең бәндәләре өчен телә, нәфесеңне сындыр, һаваңны куй. Мәуляңа гыйбадәт кыйл. Аннан соң аның хәзинәсеннән теләсәң ни сора.

———

Шәех Зөннун Мисри разыйаллаһу ганһу хаҗ нияте белән чыкты. Мәккәгә барып, бер ел мөҗавир булды.

Көннәрдән бер көн Бәйтуллаһка тәваф кыйлмага чыкты. Күрде: Бәйтуллаһ янында бер авыру фәкыйрь кеше утырыр. Шәехнең башмак авазын ишетте, башын күтәреп әйтте: «Йә Зөннун, Раббыңнан истихья[1] кыйлмаймысың? 70 ел мин аның бәндәсемен, дип дога кыйлдың. Үзең Мәккәдән шәфәгать таләп кыйласың. Хәлбуки Мәккә җәмадәт[2] кабиленнәндер», — диде. Зөннун әйтте: «Бу сүзне ишеттем, күңелем шәһадәт бирде ки, бу кеше әүлияллаһтан бер вәлидер». Шәех Зөннун әйтте: «Әй карендәш, син кайдан килдең?» Авыру фәкыйрь әйтте: «Минһә халәкънәкүм вилаятеннән килдем». Шәех Зөннун әйтте: «Кайда барасың?» Авыру фәкыйрь әйтте: «*Вә фиһә нугыйдукум*» шәһәренә барамын». Шәех Зөннун әйтте: «Син габидмесең, заһидмысың, галиммесең? Син кемсең, ни исемлесең?» — диде. Авыру фәкыйрь әйтте: «Мин — бәндәмен, син моны миннән сорама. Хуҗа үзенең колын үзенә охшаганын теләсә, ни исем белән чакырыр? Минем исемне бу йорт иясеннән сора. Чөнки барча бәндәләрнең хуҗасы — ошбу йортның иясеdер. Мин һәм аның бәндәсемен. Үзем белмәймен, аның каршында минем исемем ничектер», — диде. Шәех әйтте: «Минем Аллаһы Тәгалә каршында ул кадәр дәрәҗәм юктыр, таки минем белән мөхатәбә кыйлыр иде», — диде. Авыру фәкыйрь әйтте: «Син әйт, Илаһи, ошбу сусаган мәрыйз фәкыйрьнең ике ирене хөрмәтенә миңа белдер: ул кемдер, дип әйт», — диде.

Бәс, Зөннун ул фәкыйрь әйткән кебек әйтте. Бәйтуллаһтан бер нида ишетте: «Һу Хәбиби, һу Хәбиби», — диде. Бәс, шәех

---

[1] Истихья — оялу, хәя.
[2] Җәмадәт — таш.

Зөннун ул фәкыйрьнең алдына барып егылды, кулын-аягын үпте. Фәкыйрь әйтте: «Йә Зөннун, ни хәбәр бар?» Зөннун әйтте: Син — мәкъбульләрдәнсең, чөнки мин Бәйтуллаһтан, «Һу Хәбиби» дип өч мәртәбә аваз ишеттем», — диде. Фәкыйрь әйтте: «Йә Зөннун, мин 40 елдан бирле бу авазны ишетәмен. Вә бу ниданы ишетә башлаганымнан бирле бер ширбәт су эчкәнем юк. Син шаһид бул. Һу Хәбиби. Чөнки Хәбиб «хәбиб» сүзен рәд кыйлмас», — диде.

Аннан соң бу фәкыйрь күзен күккә текәп озак карап торды. Йөзенә чебеннәр утырган иде. Зөннун ул чебеннәрне куып җибәрмәгә теләде. Фәкыйрь әйтте: «Тимә, йә Зөннун, мин ул чебеннәрнең бер-бер данәсе өчен гасыйлардан мең кешегә шәфәгать кыйлырмын. Минем шәфәгатем белән оҗмахка керерләр, *лиәннәллаһә лә юхлифул-мигад*», — диде. Аннан соң ул фәкыйрь нәзгъ[1] халәтенә иреште. Зөннун әйтте: «Ни-нәрсә иштиһа кыйласың, хәзер кыйлаем», — диде. Фәкыйрь әйтте: «Бер эчемлек китереп бирсәң, эчәр идем. Чөнки 40 елдан бирле Аллаһы Тәгаләнең *«биэсәш-шәрабу вә сәәъәт мүртәфәка»* дигән сүзеннән куркып, бер йотымлык су эчмәдем», — диде.

Бәс, Зөннун су алмага китте. Су алып килде, күрде: фәкыйрь вафат. Бәс, Зөннун ул фәкыйрьнең фиракыннан бер сәгать егълап утырды. Аннан соң Зөннун кәфенлек алмага базарга китте. Базардан кәфенлек алып килде. Күрде: фәкыйрь юылган, кәфенләнгән, җеназага куелган. Шәех Зөннун янә дүрт фәкыйрь белән җеназасын укыды. Кабер казыдылар. Мәетне кабергә куймага дип алырга килделәр. Мәет урынында юк. Мәет урыныннан мисек, ганбәр исе килеп торыр. Зөннун әйтте: «Ул гарибнең бер гасасы, бер сәҗҗадәсе бар иде. Сәҗҗадәсен җәеп, мизаб астында ике рәкәгать намаз укыдым, мөнәҗәт кыйлдым, Илаһи, Хәбибең кайда китте? Мин аның эшенә мөтәхәҗир булдым. Аның фиракы утыннан көйдем. Илаһи, аның хәлен миңа белдер, дидем. Бәс, һатифтән нида ишеттем: «Йә Зөннун, аның фиракы хәсрәтеннән көенүче бер син генә түгел. Җиде яшендә атасыннан-анасыннан аерылмыш иде. Атасы-анасы аның хәсрәт утында. Кирамен кятибин җир йөзен җиде мәртәбә тәваф кыйлды. Аны тапмады. Нәзгъ вакытында 70 мең фәрештә белән аны тапмады. Сөаль вакытында Мөнкир вә Нәкир аны тапмады. Бәс, ошбу затлар һәммәсе аның фиракында, аның гыйшкында. Аның һәйбәтеннән зобанилар качар, җәһәннәм уты сүрелер», — дип нида ишеттем. Әйттем: «Илаһи, бу сәгатьтә ул фәкыйрь кайдадыр?»

Янә нида килде: *«Һувә фи мәкъгади сыйдкыйн гыйндә*

---

[1] Нәзгъ — агония.

*мәликим-мокътәдир*». Янә әйттем: «Кыямәт көнендә аның шәфәгатенә кемнәр наил булыр?» — дидем. Әйтте: «Аның шәфәгатенә наил булыр шул кешеләр ки, кемнең күңеле сынык. Кемнең малы пәракәндә. Кемнең теле зикердә. Кемнең күзе гыйбрәттә. Кемнең дине куәттә. Кемнең рузасы фитырда. Кемнең киче сәхәрдә», — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Әгәр берәү минем исемемә кулын тиереп, моның соңында ул кулын ике ирне белән үбеп, күзләренә сөртсә, ул кеше үзенең Тәңресене күрер, нитәкки салихлар күрерләр. Вә минем шәфәгатемә наил булыр, әгәрчә гасый булса да», — диде.

---

Аллаһы Тәгалә үзенең пәйгамбәре хакында *«иннәкә мәҗит вә иннәһүм мәйитүн»* диде. Бәс, Аллаһы Тәгалә пәйгамбәрне мәет дип тәсмия кыйлмакы нитәк җаиз булыр? Монда ни хикмәт бардыр?

Инде, әй угыл, җавап будыр ки: Аллаһы Тәгалә үзенең бәндәләрен ничек тәсмия кыйлса да җаиздыр: мәет, дисә дә — җаиз, хәй, дисә дә — җаиз. Аллаһы Тәгаләнең шаэныннан сөаль кыйлынмас. Ләкин сиңа, миңа мондаен эшләр ярамас. Әгәр син: «Пәйгамбәр — мәеттер», — дисәң, сиңа җаиз түгелдер: чөнки пәйгамбәр мәет имәстер. Әгәр мәет булса, Аллаһы Тәгалә *«вә мә Мөхәммәд иллә Рәсүл»* дип әйтмәс иде, *«кәнә Рәсүлә»* дип әйтер иде. Гыйбарәт белән гыйбарәт арасында аерма бардыр. Син белгел ки: пәйгамбәр галәйһиссәлам — кыяматкәчә Рәсүлдер, мәет хөкемендә имәстер. Берзаман җир өстендә вәхине ишетте, хәзер дә ишетәдер. Вә өммәтенең эшеннән хәбәрдардыр. Нитәкки пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: *«Әсхаби вә ихвани саллү галәййә фи күлли яумил иснәйни вәл җүмүгати бәгъдә вәфәти фәинни әсмагу минкүм билә васитатин»*, — диде. Бәс, васитасыз ишетсә, нитәк ул мәет булсын? Әгәр ул мәет булса, нәбүвәте вә әхкяме аннан мөнфәк[1] булыр иде. Нитәкки әгәр бер падишаһ үлсә, әхкям солтанаты вә табыл нәүбәте аннан мөнфәк булып, гайрегә күчәдер. Әмма пәйгамбәрнең нәбүвәте вә солтанаты вә әхкяме мондак имәстер. Солтанаты, вә әхкяме вә шәригате кыяматкәчә бакыйдыр. Күрәсең: һәр көнне мәсҗетләрдә вә җамигъларда аның табыл нәбүвәте сугыладыр! «Табыл нәбүвәт»тән морад *«Әшһәдү әннә Мөхәммәд әр Рәсүлуллаһ»* кәлимәседер.

Пәйгамбәр галәйһиссәламнең вафатыннан соң хәзрәти Гомәр разыйаллаһу ганһудан сорадылар. Әйттеләр: «Йә әмирелмөэминин, пәйгамбәр үлдеме яки терекме?» Гомәр разыйаллаһу ганһу әйтте: «Каберендә ул теректер», — диде. Ул саил янә

---

[1] Мөнфәк — купкан, аерылган.

Әбү Бәкер разыйаллаһу ганһуга килеп сорады: «Йә әмирелмөэминин, каберендә пәйгамбәр терекме, мәетме?» — диде. Әбү Бәкер разыйаллаһу ганһу әйтте: «Мәеттер», — диде. Саил әйтте: «Бу ничек, син, мәет, дидең, Гомәр хәй, диде?» Әбү Бәкер разыйаллаһу ганһу әйтте: «Гомәр раст әйтә, таки мөэмининнәр вә мөвәххидләр шатлансын. Сөннәте бакыйдыр. Вә ул пәйгамбәр каберендә, белер, ишетер», — диде. Вә дәхи әйтте: «Мин һәм раст әйтәмен: мәеттер, дидем, таки көффарның тамгысы мөнкатигъ булсын, тәшәббеһ кыйлмасыннар. Нитәкки әйттеләр, «Аллаһ» диделәр, заһир азмак белән供 аздылар. Мин дә «нәби хәй» дип әйтергә курыктым, әйтмәдем, таки илаһияткә нисбәт кыйлмасыннар», — диде.

Инде, әй угыл, колак сал азрак. Аның бәгъзе сыйфатларын сиңа бәян кыйлаем, таки аның өммәтеннән булмаклыгыңа Мәүляна шөкер кыйлгайсың.

Кайчан ки Аллаһы Тәгалә Мөхәммәд галәйһиссәламнең рухын халк итте, мәкян юк иде, заман юк иде, Гарше юк иде, Фәрше юк иде. Күк юк иде, җир юк иде. Хәрәкәт юк иде, тынычлык юк иде. Фәкать юклык иде. Бәс, Аллаһы Тәгалә үзе теләгәнчә кәмаль әхвәл үзрә рухны халк итте. «Син кем?» — диде. Рух әйтте: «Инни Габделвәһһаб», — диде. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Габде» ни-нәрсә, «Вәһһаб» ни-нәрсә?», — диде. Рух әйтте: «Габде» — мәмлүктер ки, Мәүлясына тагать аңа важибтыр ки, ул — минмен. «Вәһһаб» шулдыр ки, үзенең теләгәнен бәндәсенә һибә кыйлыр, ул — синсең», — диде. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Йә Рух, эстә, миннән ни морадың бар?» Рух әйтте: «Матлубым шулдыр: миңа белдерсәң иде, кайсы исемең белән сиңа дога кыйлаем, ни кәйфияттә коллык кыйлаем?» — диде.

Бәс, Аллаһы Тәгалә аның теләгәнен үгрәтте. Араларында аслан васита юк иде. Нитәкки Кәлямендә: *«Вә галләмәкә мә ләм тәкүн тәгъләм»,* — диде. Вә ул Рух бу хәлвәт мәйданында Тәңресе белән ялгыз иде. Һич нәрсә яратылмаган иде. Бу хәлдә 100 мең мәртәбә мең ел торды. Рух әйтте: «Илаһи кәйфият гобудиятне миңа тәгълим кыйл, синнән таләбем будыр: миңа бер урын яса, саумәга хәзер кыйл, таки үземнең урынымда исемнәреңне укыр идем, гыйбадәт кыйлыр идем», — диде. Аннан соң Аллаһы Тәгалә үзенең кодрәте белән бер карурә яратты. *«Мисбахел гыйзәт»,* — дип, аны тәсмия кыйлды. Вә анда Мөхәммәднең нурын вәзыг кыйлды. Бәс, рух кандилгә кермәгә теләде. Кандилгә утырды. Ике мең ел — «Аллаһы», ике мең ел — «Рахман», ике мең ел «Рәхим» исемен зикер кыйлды. Таки Аллаһы Тәгаләнең мең дә бер исемен икешәр мең ел әйтте.

Бәс, Аллаһы Тәгаләнең «Каһһар» исеменә җиткәч, фикер кыйлды, әйтте: «Бу исемнең тәфсире күп нәрсәнең һәлакен тәказа кыйла[1]», — дип, озак заман фикердә торып, Каһһар исеменең хәефеннән тирләде. Бу тирнең нурыннан кандилнең заһирына тамчыланып чыкты. Нитәкки пыяла савытка су салсаң, тышкы ягында ротубәт хасыйл була — шуңар мисал.

Бәс, ошбу тамчылардан Аллаһы Тәгалә әнбия рухларын халк итте. Бу рухларның һәрберсенә бер кандил яратты, һәрбер рухны бер кандилгә куйды. Әрвахе әүлия кандилләрен рухы Мөхәммәд кандиле хәвалисенә баглады. Бәс, бу әрвахе әнбия Мөхәммәд галәйһиссәлам рухыннан ишеткән тәсбихларны әйттеләр. Нитәкки шәкертләр ни остазларыннан ишетәләр, аны әйтәләр. Аннан соң рухы Мөхәммәд «Гадел» исемен әйтте. «Гадел»нең мәгънәсе — фазыл газыйм вә тәгым җәзилне икътиза кыйла, дип фикердә калды. Мәгани әсмаи Гаделнең серенә вакыф булмаклыгы җәһәтеннән, Аллаһы Тәгаләдән истихья кыйлып тирләде. Янә кандилнең заһирында хәя нурларының тамчылары зоһур итте. Бу тамчылардан Аллаһы Тәгалә мөэминнәр вә мөвәххидләр рухларын яратты.

Инде, әй угыл, кемнең ибтидаи хыйлькате ошбу сыйфатлар үзрә булса, аны ничек мәет дип әйтерсең? Мәет, дип әйтмәссең. Инде Аллаһы Тәгаләдән матлуб шулдыр ки, өммәтен аннан аермагай. Чөнки кадимдә һәм өммәтнең әрвахы кандилдә бергә иделәр. Яратылган вакытта бергә иделәр, өмидләр ки, шаять, җәннәттә дә бергә бергә булырлар. Мөэминнәр аннандыр вә аның рухыннандыр. *Ләкад җаэәкум расулун хыйлькате әнфүсикум.*

———

Пәйгамбәр галәйһиссәламнең могҗизатыннандыр ки: Әбүҗаһилнең хөсен вә җәмал иясе бер углы бар иде. Исмен Гакрәмә диләр иде. «Мине мөселман итәр», — дип, һәр заман бу Гакрәмә пәйгамбәр галәйһиссәламнән качып йөрде.

Көннәрдән бер көн пәйгамбәр галәйһиссәлам Гакрәмә белән очрашты. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Йә Гакрәмә, әгәр дә син бу хөсен вә җәмалың белән миңа иман китерсәң, оҗмах әһеле булыр иден», — диде. Гакрәмә бу сүзне ишеткәч качты, хәтта шәһәрдән чыгып китте. Әйтте: «Әй, кяшки үлгән булсам! Мөхәммәд йөзен күрмәс идем», — диде. Аннан потханәгә[2] керде. Олуг санәмнәр алдында сәҗдә кыйлды. Әйтте:

---

[1] Тәказа кыйла — дәгъвалаша.
[2] Потханәгә — гыйбадәтханәгә.

«Илаһи, җанымны алыңыз, таки Мөхәммәд йөзен күрмәгәймен!» — диде. Бәс, олуг санәмнең эченнән аваз килде: «Тәхкыйк, Мөхәммәд синең мөселман булмакыңа һиммәт баглады. Аннан хәлас булырга чараң юктыр», — диде.

Бәс, Гакрәмә, бу авазны ишетеп, янә бик курыкты. «Инде ни кыйлмак кирәк?» — дип, озак фикердә утырды. Ахыр шәһәрдән чыгып, үзен дәрьяга атмакны мәслихәт күрде. Бәс, шәһәрдән чыкты. Дәрья янына килде. «Тукта, мөселман булганчы, үземне һәлак кыйлаем», — дип, үзен-үзе дәрьяга атты. Суга батты. Янә калды: Аллаһы Тәгаләнең изене белән вә Мөхәммәднең һиммәте белән су гарык кыйлмады. Инде, әй угыл, сиңа сөенеч булсын ки, Аллаһы Тәгалә үзенең пәйгамбәре өчен кяфер, мөнкәр, моганид була торып, Гакрәмәне дәрьяда гарык булудан саклады. Инде ибтидаи хыйлькаттән бергә булган өммәтенә ник шәфәгать кыйлмасын? Кыйлыр.

Гакрәмә дәрьяда бер чума, бер су өстендә калка торгач, бер тәҗирләр көймәсе килеп җитте. Күрделәр: дәрьяда берәү гарык булмага кариб. Мәлляхлар[1], барып, Гакрәмәне судан алдылар. Көймәгә утырттылар. Сорашалар: «Син кем? Кемнең углысың?» — диделәр. Гакрәмә әйтте: «Мин — Әбуҗаһил углы, исемем Гакрәмәдер», — диде. Бәс, тәҗирләр моны таныдылар. Кайгырыштылар, әйттеләр: «Кайда бардың? Кайдан кайтасың? Суга ничек төштең?» «Чөнки Мөхәммәд мине ислам диненә кертмәгә теләйдер. Көн саен яңа сихер күрсәтәдер, безнең динемезне тәбдил кыйлмага итәдер. Аталарымыз динен батыйн итәдер. Бәс, үз динемдә үлмәкне әүля күреп, үземне дәрьяга аттым», — диде. Аннан соң көймәнең бер тарафына барды. Уйлап утырды. Көймәдә бер мөселман тәҗир бар иде. Дәхи аның бер кечкенә углы бар иде. Улының кулында бер ләүх бар иде, ошбу аять язылмыш иде: *«Йә әййүһән-нәбийү хәсбукәллаһү вә мин тәбигакә, минәл-мөэминин»*. Ул тәҗирнең углы Коръән үгрәнер иде. Көймәдә ошбу аятьне, хифыз кыйлмак өчен, күркәм тавыш белән укыды. Бәс, Гакрәмә моны ишетте. Әйтте: «Әй углан, ни-нәрсә укыйсың? Бу тактаңа ни сүзләр язган?» — диде. Углан әйтте: «Коръән укыймын. Бу — Мөхәммәдкә назил булган сүзләрдер», — диде.

Бәс, Гакрәмәнең күңеле моңар мәил булды, әйтте: «Әгәр Коръән шөйлә булса, Мөхәммәдтән качмак җаиз түгелдер. Мин ишеткәнем юк иде. Моны ишеткәч, калебем нечкәрде, җаным моңар мәел кыйлды», — диде. Мәлляхка әйтте: «Йә мәллях,

---

[1] Мәлляхлар — дингезчеләр, матрослар.

көймәне читкә чыгар: мин төшеп каламын, Мөхәммәд янына барамын, сиңа ун динар бирәем», — диде. Мәллях әйтте: «Безнең юлымыз анда таба түгел. Юк, ун динар өчен анда кайтмасмын», — диде. Егерме динар бирде. «Юк», — диде. Хәтта мең динарга житте. Гакрәмәнең үзе белән мең динар бар иде. Биленнән чиште. Мәлляхка бирде. Мәллях Гакрәмәне диңгез читенә чыгарып куйды.

Бу жир шәһәрдән ун көнлек жир иде. Пәйгамбәр галәйһиссәламнең могжизасы белән бу мәсафәтне ярты көндә катгъ[1] кыйлды, пәйгамбәр галәйһиссәлам янына барды. Икенде вакыты иде. Шул хәлдә Жәбраил галәйһиссәлам *«вә ләкад күнтүм тәманнәүнәл-мәүтә мин кабли тәлкауһү фәкад рәәйтүмүһү вә әнтүм тәнзурун»* аятен иңдерде. Бәс, пәйгамбәр галәйһиссәлам әмер кыйлды: Гали разыйаллаһу ганһу кяферләрне жәмигъ кыйлды. Әбүжаһил һәм анда иде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам ошбу аятьне укыды. Мәгънәсен тәфсир кыйлды.

Гакрәмә белән дәхи ике кеше мөселман булырга иттифак кыйлмышлар иде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам сәхабәләре белән аларга каршы бардылар. Әбүжаһил дәхи юлдашлары белән иде. Әбүжаһил әйтте: «Әй угыл, кайда барырсың?» — диде. Гакрәмә әйтте: «Мөхәммәд янына барамын». Әбүжаһил әйтте: «Бу сахирга иман китерәмесең?» — диде. Гакрәмә әйтте: *«Йә абәти вә мә Мөхәммәдүн иллә Рәсүлүн фәлә тәкул ләһү сахир»*, — диде. Ягъни: «Әй ата, Мөхәммәднең Рәсүллегенә һич шик юктыр, син аны сахир димә». Бәс, Гакрәмә аннан узып китте. Пәйгамбәрне күрде. Ике юлдашы белән пәйгамбәр алдында йөзен жиргә куйды. *«Әшһәдү ән ля Иләһә иллә Аллаһү вә әшһәдү әннә Мөхәммәдүн Расүлүллаһ»*, — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәламнең сәхабәләреннән булды. Инде Гакрәмәгә разыйаллаһу ганһу дип әйтелер. Атасына Әбүжаһил галәйһиләгънә дип әйтелер.

Инде, әй угыл, бу сүзләрдән ни фәһем иттең? Кирәксен ки, Гакрәмә разыйаллаһу ганһу Коръәннән бер генә аять ишетмәк белән мөселман булды вә әсхаб Рәсүлдән булды. Инде Мөхәммәд өммәте Коръәнне тәмамән хифыз кыйлмаклары вә укымаклары белән гыйльме хикмәтне вә вәгазь-нәсыйхәтне истимаг кыйлмаклары белән әхбабе Аллаһы вә әүлияуллаһтан булсалар, ник гажәпләнәсең? Дәхи дә Мөхәммәд галәйһиссәлам Гакрамәгә бер мәртәбә карады. Шул сәбәпле аны дәрья суы гарык кыйлмады. Ун көнлек мәсафәтне ярты көн сәер кыйлды.

---

[1] Катгъ — кичү, үтү.

Әбүҗаһил 400 әсхабе белән аны исламнан мәныг кыйлмага кадире булмады. Инде Аллаһы Тәгалә мөэмин бәндәнең калебенә һәр көн 360 мәртәбә караса, Мөхәммәд галәйһиссәлам дәхи мөэмин өммәтләргә шәфәгать нәзары белән караса, зобанилар аны тәмугка сөйрәмәгә ничек кадир булырлар?! Вә аларны ут ничек яндырыр? Зобанилар да кадир булмас. Ут та яндырмас. *Йә гыйбади, лә хауфун галәйкүм вә ля әнтүм тәхзәнун.*

---

Аллаһы Тәгалә кадим пәйгамбәрләр белән сөйләште вә әүлиялар белән серләште. Бу заманда Аллаһы Тәгалә берәү-берәү белән сөйләшерме? Бу җаизмы? Инде, әй угыл, бу сүзгә җавап бирделәр ки: «Тәхкыйк, Аллаһы Тәгалә әһле иман белән мохатәбә кыйлышыр. Дәлиле будыр ки, әгәр дә Аллаһы Тәгалә бәндәләрнең калебенә хитаб кыйлмаса вә аларның калебләренә нәзар кыйлмаса, ул бәндәләрдән тәүбә дә зоһур итмәс иде; садака да зоһур итмәс иде. Намаз да зоһур итмәс иде. Зәкят тә зоһур итмәс иде. Тәхкыйк, Аллаһы Тәгалә бәндәләренең калебенә хитаб кыйлыр. Бәндәләре күңел колаклары белән ишетерләр, *билә саутин вәлә хәрф*. Әгәр алай булмаса, вагыйзларның вәгазен ишеткән вакытта, галимнәрнең гыйлемен тыңлаган вакытта, күңел йомшарып, егъласылары килмәс иде. Моңар дәлил будыр ки, Аллаһы Тәгалә Әбү Талибның күңеленә хитаб кыйлмады. Шуның өчен пәйгамбәрнең дә нәсыйхәте файда бирмәде. *Иннәкә ля тәһди мин әхбәбтә вә ләкиннә Аллаһә яһди.* Гакрәмә күңеленә Аллаһы Тәгалә хитаб кыйлды: «*Вә мә Мөхәммәдур-расул*» — диде, шуның өчен мөэмин булды.

---

Шәех Сәгыйд Әбелхәер разыйаллаһу ганһу зиядә картлык дәрәҗәсенә җитте. Хәтта түшәктә утырырга хәле калмады. Аның 400 мөриде бар иде. Шәехне, мохафәгә салып, урыннан урынга күтәреп йөртерләр иде. Мөридләреннән бер бик куәтле вә тәкъва мөриде бар иде. Ялгызы шәехне иң башына күтәреп, Тус шәһәреннән Нисабур шәһәренә илтте. Фәкыйрь шәкерт иде. Иң башы ялангач, яланаяк китте. Мөридләреннән берсенең күңеленә килде: иңбашын өртергә мизрәмне[1] әллә бирәсемме? Авырлыктан вә кояш эсселегеннән бичараның иң башы пешәр, дип уйлады. Бәс, шайтан дәхи күңеленә васвәсә салды: «Бирмә, үзеңә кирәк булыр», — диде. Аннан соң икенче мәртәбә дәхи Аллаһы Тәгалә илка кыйлды. «Бу шәкерткә миз-

[1] Мизрәмне — путамны.

рәмне бирсәм: өмидтер ки, Аллаһы Тәгалә аның өчен кыяметтә миңа хөллә кидерер», — диде. Янә шайтан икенче мәртәбә вәсвәсә кыйлды: «Юк, бирмә. Үзеңә хаҗәт булганда кайдан алырсың?» — диде. Өченче мәртәбә дәхи Аллаһы Тәгалә күңеленә салды: «Тукта, бирәем: моның сәбәпле Аллаһы Тәгалә миңа кәраматләр бирсә кирәк», — диде. Шайтан янә мәныг кыйлды: «Бирмә. Әгәр дә үзең фәкыйрьлеккә калсаң? Ул вакытта бу мизрәң бер эшкә ярар», — диде. Ахыр мизрәне ул шәкерткә бирмәде.

Аннан соң көннәрдән бер көн бу мизрә иясе шәкерт шәехтән бу мәсьәләне сорады, әйтте: «Йә шәех, бу гасырда Аллаһы Тәгалә берәү-берәү белән мохатәбә кыйлса җаизмы? Берәүнең күңеленә илһам кыйлса җаизмы?» — диде. Шәех кәрамәт иясе адәм иде. Әйтте: «Йә фәлән, тәхкыйк күрдең ки, Аллаһы Тәгалә мизрәң хакында сиңа өч мәртәбә хитаб кыйлды. Әмма син шайтан вәсвәсәсенә табигъ булдың, мизрәңне бирмәдең. Бәс, Аллаһы Тәгалә кәримдер, рәхимдер, хәлимдер. Мотыйг бәндәләренең күңеленә хитаб кыйлыр. Инде һәрнәрсә ки мөэминнәрнең күңеленә килер — изгелектән, тагатьтән, ихсаннан — һәммәсе мөэмин бәндәгә Аллаһы Тәгаләдән хитабтыр. Вә нәрсә ки бәндәләрнең күңелендә җари булыр — фәсадка касд кылудан вә гөнаһ эшләрдән — һәммәсе шайтан вәсвәсәсеннәндер. Моңар дәлил будыр ки: Аллаһы Тәгалә бәгъзе бәндәләренә төшендә хитаб кыйлыр; шул төшендә күргәне уяу чагында тугыры килер. Нитәкки бәгъзе төшләр тугыры киләдер. Моны рахмани төш, диләр. Шайтани төш дәхи буладыр.

---

Әнис әл-Әнсари разыйаллаһу ганһудан риваять кыйлынды. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Мин кыямәт көнендә өммәтемә шәфәгать кыйлырмын, җир йөзендә булган хаҗәрдән, болыттан түгелгән тамчылардан күбрәк», — диде. Вә дәхи пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Аллаһы Тәгалә миңа бәшарәт бирде, әйтте, йә Мөхәммәд, әгәр синең өммәтеңнән берәү бер мәртәбә, *лә иләһә илләаллаһы Мөхәммәдүну Рәсүлуллаһ,* дип әйтсә, кыямәт көнендә аның мизанында бу кәлимәләрнең савабын җирдән, күктән вә ма фиһә булган нәрсәләрдән авыррак кыйлырмын, диде».

Инде, әй угыл, фикъһе мәсьәләләреннән моның охшашы белән сиңа бу сүзне бәян кыйлаем. Мәсәлән, берәү бер нәрсәне берәүгә рәһен куйды 200 дирһәмгә. Ул кеше, рәһенне кабыз кыйлып, дирһәмнәрне аңа бирмәде. Өч көннән бирермен, дип вәгъдә кыйлды. Инде әгәр рәһен шул кешенең кулында шул өч

көн эчендә һәлак булса, шул вакытта: «Инде рәһен һәлак булды, мин дирһәмнәрне бирмәймен», — дип, мөртәһин әйтә алмас. Шәригать аңа ул дирһәмнәрне бирмәгә илтизам кыйладыр. Шәригать әйтәдер ки: «Син бу дирһәмнәрне ул кешегә гаһед вә вәгъдә кыйлдың. Рәһен бабында гаһед шарттыр. Син аңа заминсең. *Лиәннәл гыйддәтә — дин»*, — диде.

Инде, әй угыл, мәсьәләдән хисса алгыл ки, сөенеч сиңадыр. Шәригатьтә вәгъдәгә хилафлык кыйлмага рөхсәт юктыр, гәрчә мөртәһин фәкыйрь булса да. Пәйгамбәр галәйһиссәлам кыямәт көнендә өммәтләренә шәфәгать кыйлмага вәгъдә вә гаһед кыйлды: *«Әшфәгү яумәл кыямәти лиәксәри миммә галәләрзый мин хаҗәрин вә мәдәр»*, — диде. Син һәм аның өммәтеннәнсең. Вә дәхи: *«Лә иләһә илләаллаһу Мөхәммәдуну Расүлүллаһ»*, — дип әйткәнең өчен, Аллаһы Тәгалә сиңа мизанында күп савап вәгъдә кыйлды. *«Әрҗиһ мин фис-сәмәвәти вәл-әрзый вәмән фиһиннә»*, — диде. Мәхлук булып мәхлукка лазем вәгъдәсенә вафа кыйлмак. Вәгъдәгә хилаф кыйлмага һич мөэмин разый түгел.

Бәс, Аллаһы Тәгалә кәрим була торып, вәгъдәсенә нитәк хилаф кыйлсын? Кыйлмас! Пәйгамбәр галәйһиссәламгә дәхи нитәк җаиз булсын үзенең өммәтенә кыйлган вәгъдәсенә хилаф кыйлмак? Әлбәттә, җаиз түгел. Бәс, бер өммәт кыямәт көнендә иман белән вә кәлимәи шәһадәт белән килсә, пәйгамбәр шәфәгате бәрәкәтендә вә кәлимәи шәһадәт бәрәкәтендә, шиксез, Аллаһы Тәгалә ул бәндәне мәгъфирәт кыйлыр. *Иннә Аллаһә лә юхлифул-мигад.*

---

Мөнакыйб Әбү Хәнифә разыйаллаһу ганһу. Белгел ки, әй угыл: Аллаһы Тәгалә Имам Әгъзамны шәригать белән вә кәрамәт белән тәхсис кыйлды. Имам Әгъзамның кәрамәтеннәндер ки, Хозыр галәйһиссәлам Имам Әгъзам янына һәркөнне 50 елга кадәр, иртә намаз вакытында килеп-килеп, дәрес укыды. Әхкәм шәригатьне үгрәтте. Бәс, Имам Әгъзам вафат булгач, Хозыр галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә мөнәҗәт кыйлды, әйтте: «Илаһи, гыйндендә аз гына дәрәҗәм булса, Әбү Хәнифәгә изен бир, таки гадәте хисабынча мине кабереннән тәгълим кыйлса иде, таки кәмаль үзрә Мөхәммәднең шәригатен белеп, тарикать вә хакыйкать хасыйл итәр идем», — диде.

Хозыр галәйһиссәламгә нида килде: «Каберенә бар, теләгән нәрсәңне үгрән!» — диде.

Бәс, Хозыр галәйһиссәлам Имам Әгъзам каберенә килде. Яңадан 25 ел Имам Әгъзам кабереннән тәгълим алды. Тәмам

дәлилләре белән хатме көтеб кыйлды. Аннан соң янә Аллаһы Тәгаләгә мөнәҗәт кыйлды: «Илаһи, инде ни эшләем?» — диде. Янә нида килде: «Инде үз мәкамеңә бар, гыйбадәтең белән мәшгуль бул. Инде фәлән җиргә барып, фәлән кешегә тәгълим бир, дип, миннән әмер булганчы, анда тор», — диде.

Бәс, Хозыр үзенең мәкаменә кайтты. Берничә мөтдәттән соң Мәвараәннәһер шәһәрләреннән бер шәһәрдә Әбелкасыйм әл-Кышари дигән егет зоһур итте. Әбелкасыймның анасы бар иде. Анасын зиядә икрам вә ихтирам кыйлыр иде. Көннәрдән бер көн анасына әйтте: «Әй ана, хәзрәти Гали разыйаллаһу ганһуның *«мин кянә фи таләбил гыйльми кянәл җәннәтү ятълубуһ»* дигән сүзен күреп, таләбе гыйлемгә бик ихласым төште. Рөхсәт бирсәнә: Бохарага барып, гыйлем укыр идем», — диде. Анасы фикер кыйлды: «Әгәр изен бирмәсәм, манигатүн лил-хайр буламын. Әгәр изен бирсәм, фиракына сабыр кыйлыр хәлем юк», — диде.

Ахыр мөмкин булмады, изен бирде. Бәс, Кышари, анасы белән видаглашып, сәфәргә чыкты. Аның белән бер егет дәхи тәхсил гыйлем өчен бергә киттеләр. Кышариның анасы углының фиракына көенеп капка төбендә егълап калды. Әйтте: «Илаһи, үзең шаһид бул, гаһед кыйлдым: тәгамны вә шәрабны үземә харам кыйлдым. Таки углымны күрмәй торып, урынымнан купмамын», — дип гаһед кыйлды. Әй угыл, ишеттеңме, аналар һиммәте ни кыйладыр?

Бәс, Кышари үзенең юлдашы белән бер мәнзил киттеләр. Бер җирдә тәгам ашарга утырдылар. Кышари торып, бер тарафка истибрага китте. Истибра кыйлганда, киеменә бәвел сачрады. Аннан юлдашы янына килде, әйтте: «Бар, син тәхсилеңә бар, мин анам янына кайтамын», — диде. Юлдашы әйтте: «Ни сәбәпле болай уең үзгәрде?» — диде. Кышари әйтте: «Минем өчен бу сәфәр мөбарәк булмастыр. Әүвәлге мәнзилдә киемемә нәҗасәт тиде. Инде куркамын, икенче мәнзилдә тәнемә нәҗасәт тияр. Өченче мәнзилендә калебемә нәҗасәт тияр. Анам янында тормак миңа бу сәфәрдән әүлядыр», — дип, анасы янына кайтты. Анасы һаман шул видаглашкан урында утырып торыр иде. Торды. Углы белән күреште: *«Әлхәмделиллаһ»*, — диде.

Бәс, Аллаһы Тәгалә Хозырга әмер кыйлды, әйтте: «Бар, фәлән җиргә, Имам Әгъзамнан тәгълим алган нәрсәләренне һәммәсен Кышарига тәгълим бир. Зирәки Кышари анасын разый кыйлды», — диде.

Аннан соң Хозыр галәйһиссәлам бер көнне сәхәр вакытын-

да Кышари янына килде, әйтте: «Син таләп гыйлем өчен Бохарага чыкмыш икәнсең. Ананны разый кыйлмак өчен, дүнеп кайткан, имешсең. Аллаһы Тәгалә миңа әмер кыйлды: һәркөнне ошбу сәхәр вакытында килеп, анаң янында сиңа тәгълим бирсәм кирәк», — диде.

Бәс, Кышари Хозыр галәйһиссәламнән дәрес башлады. Хозыр галәйһиссәлам, көн саен килеп, дәрес бирде. Бу кәйфиятчә Кышари өч ел дәрес укыды. Бу мөгаллим Хозыр икәнен белмәде. Хозыр галәйһиссәлам Имам Әгъзамнан 30 елда хасыйл иткәнне өч елда хасыйл итте. Хакаик вә дәкаикъларны тәмам дәлаилләрне белде. Заманында мәшһүр вә фәрид гасыр[1] булды, имам аталды. Мең китап тасниф кыйлды. Кәрамәт иясе шәехләрдән булды. Мөридләре вә шәкертләре күбәйде.

Олуг пишкадәм вә мөтәдәйин[2] бер мөриде бар иде. Кичәкөндез Кышаридан һич мофарәкать кыйлмады. Бәс, ул мөриде алдында шәех үзенең язганнарыннан мең китап санады, бер сандыгына тутырды, бу мөридкә бирде. Әйтте: «Миңа бер эш зоһур итте. Барысын, бу бер сандык китапны — Җәйхун дәрьясына сал», — диде. Бәс, мөрид шәех яныннан чыкты. Сандыкны күтәреп китте. Күңеленнән әйтте: «Бу шәехнең китапларын ничек итеп суга ташлаем? Тукта. Бер җиргә яшереп куяем. Шәехкә суга салдым, дип әйтермен», — дип китте дә китапларны бер җиргә куйды. Шәех янына килде. Шәех әйтте: «Китапларны суга салдыңмы?» «Бәли, салдым», — диде. Шәех әйтте: «Салган вакытта ни галәмәт күрдең?» Мөрид әйтте: «Һичбер галәмәт күрмәдем», — диде. Шәех әйтте: «Бар, суга сал, һәнүз салмагансын», — диде. Мөрид янә китте. Китапларны Җәйхун дәрьясына салмага ирадә кыйлды. Һаман күңеле моңар разый булмады. Бер җиргә куйды. Шәех янына килде. Шәех әйтте: «Салдыңмы?» «Бәли, салдым», — диде. Шәех әйтте: «Ни галәмәт күрдең?» Мөрид әйтте: «Бер галәмәт тә беленмәде». Шәех әйтте: «Ташламагансың һәнүз. Бар, ташла: монда минем Аллаһ Тәгалә белән бер серем бардыр: ташламыйча мөмкин түгел», — диде.

Бәс, мөрид китте. Сандыкны Җәйхун дәрьясына салды. Күрде: судан бер кул чыкты, сандыкны тотты. Мөрид әйтте: «Син кем?» — диде. Судан бер нида килде: «Бу әманәтне сакламага мин мөвәккилмен. Хикмәтен шәехтән сора», — диде. Мөрид

---

[1] Фәрид гасыр — гасырның бердәнбере.

[2] Пишкадәм вә мөтәдәйин — укуда башкалардан алда барган шәкерт һәм диндар.

аннан шәех янына кайтты. Шәех әйтте: «Салдыңмы?» Мөрид: «Бәли, салдым», — диде. Шәех әйтте: «Ни галәмәт күрдең?» Мөрид әйтте: «Су ярылды. Судан бер кул чыкты. Сандыкны алды. Хәйран булдым. Йә шәех, бу серне бәян кыйла күргәйсең», — диде. Шәех әйтте: «Монда сер ошбудыр ки: кыямәт якын булса, Дәҗҗал чыкса, Гайсә Бәйтелмокатдәскә инсә, мәсҗетнең имамы әл-Галидән бер салих адәм булыр. Гайсәне белер, әйтер: «Михрабка син кич: безгә намаз укып бир». Гайсә әйтер: «Син Мөхәммәд шәригатенә табигъсың, безгә намаз укып бир». Бәс, намаз укып, намаздан фаригъ булырлар. Гайсә Дәҗҗалны үтермәгә касд кыйлыр. Дәҗҗал качар. Таки Гайсә Дәҗҗалның артыннан барып үтерер. Дәҗҗалның гаскәре мөнһәзим булыр. Аннан соң Дәҗҗалны үтергәч, үзенең янына «Инҗил»не куяр, әйтер: «Мөхәммәд шәригатенең китаплары кайда? Миңа Аллаһы Тәгалә аның китабы белән гамәл кыйлмага боерды», — дип.

Бәс, бөтен дөньяны эзләрләр, шәригать китапларыннан бер китап тапмаслар. Вә Коръәннән бер вәрак тапмаслар. Гайсә хәйран булыр, әйтер: «Илаһи, бәндәләрең арасында ни белән хөкем итәем? «Инҗил» китабыннан гайре китабым юктыр». Аннан соң Җәбраил галәйһиссәлам инәр, әйтер: «Аллаһы Тәгалә боерды ки: син Җәйхун дәрьясына бар. Дәрья янында ике рәкәгать намаз кыйл. Вә нида кыйл ки: *йә әминә кутуби Әбилкасыймил Кышари, сәллим лийәл кутубә мәгассундукый әнә Гыйсә бину Мәрьямә вә кад катәлтуд Дәҗҗал*».

Бәс, Гайсә, Аллаһы Тәгаләнең әмере белән, Җәйхун дәрьясына барыр. Ике рәкәгать намаз укыр. Җәбраил галәйһиссәлам әйткәнчә әйтер. Аннан соң Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән су ярылыр. Судан сандык чыгар. Ул сандыкны Гайсә ачып күрер: Кышариның мөһере дәхи мең китап. Ошбу китаплар белән гамәл кыйлыр. Җәбраил галәйһиссәламнән сорар: «Кышари бу кәрамәтне ни белән тапты?» — дияр. Җәбраил галәйһиссәлам әйтер: «Анасын разый кыйлмак белән тапты», — дип.

Инде, әй угыл, ата-ананы разый кыйлмакта күп кәрамәтләр бардыр.

———

Җөнәйд Бәгъдадый хәзрәтләренең бер олуг салих вә мөтәдәйин мөриде бар иде. Ул мөриднең кыю йөрәкле бер углы бар иде. Гаскәр эчендә күп йөрде. Күп газа кыйлды. Берзаман Рум газасында, әсир төшеп, мәхбүс булды. Анасы һәр көн шәех янына килеп еглар иде.

Көннәрдән бер көн әйтте: «Йә шәех, Аллаһы Тәгаләгә дога кыйл, углымны кяферләр кулыннан хәлас кыйлсын», — диде.

Шәех әйтте: «Йә хатын, көенмә, углың өчен дога кыйл. Мин һәм кыйлдым. Шаять, хәлас булыр, кайтыр», — диде. Хатын көн саен шәехкә килеп егълар иде, шәех шул ук җавапны бирер иде.

Беркөн бу хатын, углының фиракы гаять әсәр итеп, янә гадәте үзрә шәех янына килде. Әйтте: «Йә шәех, Аллаһ өчен дога кыйл: углым хәлас булсын, вә илла үземне һәлак кыйлырмын. Яки дога кыйл: Аллаһы Тәгалә минем җанымны алсын», — диде. Шәех әйтте: «Әй хатын, сабыр ит. Бар, өеңә кайт. Углың өчен сиңа дога кыйлырмын», — диде. Хатын әйтте: «Ошбу сәгатьтә дога кыйл», — диде. «Йә вәләд, аһ», — дип, тавыш белән егълады. Бәс, шәех, хәйран булып, башын түбән иеп, һич тәкәллем кыйлмаенча, бер микъдар торды. Күңеленнән әйтте: «Илаһи, бу хатынның углын хәлас кыйл», — диде. Өйлә вакыты иде. Аллаһы Тәгалә догасын кабул итте. Хатынга әйтте: «Әй хатын, бар, өеңә кайт. Кайгырма. Углың аягыннан зәнҗирләрне чиштеләр. Хәлас булды, кайтыр», — диде.

Бәс, хатын, шатланып, өенә кайтып китте. Һәм өч көннән соң углы да кайтып керде. Анасы торды. Углын кочаклады. Шәех янына килде. Шәех әйтте: «Углың кайттымы?» Хатын әйтте: «Бәли, кайтты, тәкъсыйр, минә углым белән килдем», — диде. Шәех шатланды. Егетне маңгаеннан үпте. «Әй егет, ни кәйфияттә хәлас булдың?» — диде. Егет әйтте: «Фәлән көн өйлә вакытында без 300 мөселман идек, безне шәһәрнең тышына чыгардылар, безгә хезмәт боердылар. Тора торгач, минем муенымнан, аягымнан чылбырлар, баулар, үзалдына чалтырап коелдылар. Мөвәккилләр моны күрделәр: «Аягыңнан богауларны ник чиштең?» — дип, мине кыйнадылар, суктылар. Яңадан тотып богауладылар. Янә аягымнан богаулар коелып төште. Бу хәлне падишаһка хәбәр бирделәр. Падишаһ боерды — мине падишаһ хозурына илттеләр. Янә богауладылар. Китә башладым. Богаулар янә коелып төште.

Бәс, бу хәлне күргәч, падишаһ бик гаҗәпләнде. «Бу эш нидән болай булмак кирәк?» Падишаһның җәлисләреннән бер олуг карт кеше бар иде. Торды. Миңа әйтте: «Әй егет, синең анаң бармы?» — диде. «Бәли, бар», — дидем. «Анаң синнән разыймы?» — диде. «Бәли, разый», — дидем. Аннан соң карт әйтте: «Әй падишаһ, гомерең озын булсын. Бу егетне азат кыйлып җибәр. Китсен анасы янына. Юкса хәвеф итәрмен ки, бу егет анасының догасы белән бу дияр харап булса кирәк», — диде. Аннан соң падишаһ әмер кыйлды, мине азат кыйлып җибәрделәр», — диде. Җөнәйд Бәгъдадый әйтте: «Ул карт раст әйтте», — диде.

Инде, әй угыл, моннан гыйбрәт ал. Ул егетнең анасы, разый булган сәбәпле, дөнья газабыннан вә әсирлек михнәтеннән хәлас булды. Инде ата-анасы разый булып вафат иткән бәндәне Аллаһы Тәгалә, кыямәт газапларыннан хәлас итеп, дөнья-ахирәт сәгыйдләр җөмләсеннән язса, ни гөманың бар?! *Ликаулиһи галәйһиссәлам: ихсәнүл әбәүәйни сәгадәтүд дәрайн.* Атаңанаң хәяттә булсалар, иҗтиһад кыйл: аларны разый кыйлмага тырыш.

---

Мәгълүмдер ки: дин — бердер. Әмма әиммәи әрбәганың[1] ихтилафында ни хикмәт бардыр? Мәсәлән, имам Әгъзам каршында намаз вакытының ахырында әфзаль. Имам Шәфыйг каршында вакытның әүвәлендә әфзал. Гайре мәсьәләләрне дәхи моңар кыяс кыйл. Инде, әй угыл, имамнар арасында ихтилаф күп. Һәр кайсының дәлиле бардыр. Мәсәлән, имам Әгъзам имам Шәфыйгка әйтсә: «Намазның ахыр вакытыннан әүвәл вакыты әфзальдер, диден, ни дәлил белән?» — дисә, имам Шәфыйг әйтер: «Мин куркамын ки, намаз укучы ахыр вакытыннан мөкаддәм үлсә, өстендә карыз калыр. Чөнки намазга вакыт шарт. Намазның вакыты керде. Әмма намазның әүвәл вакытыннан ахыр вакыты әфзаль, дип син ни дәлил белән әйтәсең?» — дисә, имам Әгъзам әйтер: «Аның өчен бәндәдән намазны әүвәл вакытында таләп кылынмай, ахыр вакытында таләп кыйлынадыр. Дәхи дә пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: *«Әл-үмүру бил хауатим»*, — диде. Шуның өчен, ахыр вакыты әфзальдер, дип әйтәмен», — диде.

Әй угыл, белгел ки: ошбу имамнарның ихтилафы — бәндәләргә Аллаһы Тәгаләнең гыйнаяте вә рәхмәтедер. Нитәкки: *«Ихтиләфүл голәмә-и рахмәтүн»*, — диделәр. Имамнар берберенә ихтилаф кыйлдылар шуның өчен ки, араларында хаклык мәстур булып калмасын. Нитәкки нәсара вә яһүдиләр арасында мәстур булып калды. Чөнки райи вахидкә иттифак кыйлдылар, хаклыкны изһар кыйлмак өчен бәхәсләшмәделәр. Аллаһы Тәгалә кыямәт көнендә алардан хакны сорар. Хакны эзләмәгән өчен, аларны җәза кыйлыр. Йөзләре каралыр, башларын түбән салып торырлар. Кайчан ки хисап Мөхәммәд өммәтенә ирешсә вә алардан хакны сораса, әиммә әрбәга хакны китерерләр. *Иннәһүм җәһәдү филләһи хакка җиһәдиһи.* Сөбүт булыр ки, әиммә әрбәга барча дәлилләре белән һичбер бәхәс кыйлмаган кәлимәне калдырмамышлардыр. Бәс, аларның хаклыгы заһир булыр. Аллаһы Тәгалә каршында йөзләре агарыр.

[1] Әиммәи әрбәганың — дүрт имамның.

Вә дәхи белгел ки: әй угыл, имамнарның ихтилафы шул мәсьәләдәдер ки. Мәсәлән, тажирларның гадәтеннәндер: кайчан ки, сәүдә кыйлып, күп рибех[1] ясасалар, күп кыйммәтле вә нәфис маллар алып, тиҗарәт өчен сәфәргә чыкмакны касд итеп ишетсәләр ки, алар китәсе юлда — угрылар вә катыйгыттарикълар бардыр. Бәс, кәрван башы әмер итәдер: бәгъзе куәтле егетләр белән кәрван алдыннан вә бәгъзе куәтле вә гайрәтле егетләр кәрван артыннан кораллар белән барып, угрылардан вә катыйгыттарикълардан имин булып, маллары вә кыйммәтле нәрсәләре сәламәт барып җитәдер.

Бәс, ошбу имамнар бигайниһи шуңар охшар. Ул имамнар, ахирәт тажирларының кәрван башларыдыр. Дөньяда күп мәшәкать чигеп, сәүдә кыйлдылар. Тагать вә хәсәнаттан[2] күп рибех хасыйл иттеләр. Дөньяда мөэмин өммәтләр вә голямалар мөсафирлардыр. Ахирәт юлында сәер кыйлалар. Бәс, ишеттеләр ки, юлда күп угрылар вә катыйгыттарикълар бардыр. Алар — шайтандыр. Бәс, бу өммәтнең куәтле вә бәһадир имамнары — әиммә әрбәгадер — чыктылар, вә бәгъзесе кәрван алдыннан, вә бәгъзесе кәрван артыннан йөреп, ахирәт кәрванын сакладылар. Инде имам Шәфыйг — намаз әүвәл вакытта әфзаль, имам Әгъзам — ахыр вакытта әфзаль, диделәр. Бу өммәтләр, ошбу имамнар арасында сау-сәламәт ахирәт сәфәрендә йөреп, сәләмин-иминин барып оҗмахка керерләр. Ләкаулә Тәгалә: *«Удхулуһә бисәләмин әминин»*.

Вә дәхи ошбу ике имам мизанның ике кәффәсе охшашлыдыр. Ике кәффәнең бәрабәр вә гаделлегендә, әлбәттә, аерма юктыр. Мәсәлән, берәү мизанда бернәрсә — кыйммәтле җәваһир үлчәсә, бер кәффәсенә — җәваһирны, бер кәффәсенә мигъяр саладыр, моның беләң җәваһирның микъдарын беләдер. Инде бу ике имам җир йөзендә Аллаһы Тәгалә мизанының икесе — ике кәффәседер. Бәс, бу мизанның үлчәме әмер шәргътер. Ошбу өммәт — баягы җәваһир вә алтын вә кыйммәтле маллардыр. *«Күнтүм хайра үммәтин үхърижәт лин нәс»*. Бәс, Аллаһы Тәгалә бу мизанны, бу үлчәмне ошбу әиммә әрбәга арасына куйды. Таки сафы вә хәлас булганы, нә бәһрәҗ вә мәгъшуш булганы заһир булсын. *Ләһәләкә мин һәләкә ган бәййинәтин вә яхъйә мин хәййә ган бәййинәти.*

Бәс, кайчан ки кыямәт көне булса, Аллаһы Тәгалә, алар арасыннан хәлас вә сафы булганын җыеп, оҗмахка кертер. Чөнки

---

[1] Рибех — табыш, файда.
[2] Хәсәнаттан — изгелектән.

алар Аллаһы Тәгаләнең хәзинәсенә лаек булдылар. Сыйраттан *кәл бәркыйль хатыйфи* мүрур итүчеләр — ошбулардыр. Аннан соң нә бәһрәҗ вә мәгъшуш булганнарын, утка салып яңадан саф вә хәлас итәр өчен, тәмуг кярханәсенә җибәрелер.

Инде, әй угыл, бу кыйссалардан яхшы хисса фәһемләсәң кирәк. Мәгәр калебеңә иблис каргасы оялаган булса гына, бу сүзләр калебеңә сеңмәс.

———

Мәгълүмдер ки: Мөхәммәд галәйһиссәлам — нәбиләрнең вә Рәсүлләрнең әфзаледер. Әмма ни хикмәт вә ни сер бардыр ки, Муса галәйһиссәлам Аллаһы Тәгаләгә Тур тавында мөнәҗәт кыйлды. Вә Аллаһы Тәгалә аңа васитасыз хитаб кыйлды Мөхәммәд галәйһиссәламгә Җәбраил васитасы белән хитап кыйлды. Инде, әй угыл, бу мәсьәләне пәйгамбәр галәйһиссәлам һәм *«Йә әййүһәл-мүддәссир кум фә әнзир»* сүрәсен индергән вакытта, Җәбраил галәйһиссәламнән сөаль кыйлды. Әйтте: «Йә Җәбраил, син боерамысың моны миңа яки Аллаһы Тәгаләме?» — диде. Җәбраил галәйһиссәлам әйтте: «Юк. Аллаһы Тәгалә сиңа боерды», — диде. Бәс, пәйгамбәр галәйһиссәлам мәгъмүм булды. Җәбраил галәйһиссәлам әйтте: «Йә Мөхәммәд, ник мәгъмүм булдың?» Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Мин һәнүз Муса дәрәҗәсенә ирешмәймешмен. Чөнки Аллаһы Тәгалә аңа васитасыз хитаб кыйлды, әмма миңа синең аркылы хитаб кыйлды», — диде. Аннан соң, Җәбраил галәйһиссәлам һәм хәйран булды. Ни вәҗеһ белән җавап бирмәк кирәк, белмәде. Хәтта Аллаһы Тәгаләгә мөнәҗәт кыйлды.

Бәс, Аллаһы Тәгалә моның җавабын Җәбраилга тәгълим кыйлды. Аннан соң Җәбраил галәйһиссәлам әйтте: «Йә Мөхәммәд, мин әфзальме яки җөмадшәҗәр әфзальме?» Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Әлбәттә, син әфзальсең», — диде. Җәбраил әйтте: «Алайса нигә мәгъмүм буласың?» Кайчан ки Аллаһы Тәгалә Мусага хитаб кыйлса, араларында шәҗәр васита булды. *Фәләммә этәһә нудийә мин шәтый-ил вәдил әймәни фил бәкъгатил мүбәракәт минәш-шәҗәрәти йә Муса инни әнә Аллаһү раббул галәмин.* «Йә Мөхәммәд, ошбу шәҗәр Муса өммәтеннән һичкемгә шәфәгать кыйлмас. Әмма мин — кыямәт көнендә өммәтләреңә шәфәгать кыйлгучымын. Коръән сүрәләре гадәденчә вә аятьләре, вә кәлимәләре вә хәрефләре гадәтенчә тәмугтан гасый өммәтләреңне шәфәгать кыйлып чыгаручымын. Мин Җәбраил әмин, мин — шәфигъ Раббелгаләминмен», — диде.

Инде белгел ки: ошбу өммәтне Аллаһы Тәгалә күп кәрамәтләр белән икрам кыйлды. Бу кәрамәтләр белән һичкайсы

өммәтне хөрмәтләмәде. Муса өммәте телле хайван кебек иделәр. Хайванны багламак өчен бауга мохтаждыр. Шуның өчен Аллаһы Тәгалә Җәбраилне Мусага җибәрде. Әйтте: «Әй Муса, кауменә әйт: һәркайсы беләкләренә күк төсле хирка багласыннар. Таки минем казамны онытмагайлар. Вә әгъмаль сәмагъ белән гамәл кыйлгайлар. Ахирәт гамәлләреннән, үлемнән, хисаптан гафил булгайлар», — диде.

Кайчан ки пәйгамбәрлек ошбу өммәткә, ягъни Мөхәммәд өммәтенә килде. Бәс, Муса кауменнән тәфрика булсын өчен, Аллаһы Тәгалә аларга әйтте: «Сез — минем дусларымсыз. Бер-берегезгә сүз белән нәсыйхәт кылышмак важиб булды. Минбәрләр куеңыз, галимнәреңез минбәргә ашсын, гавамнарыңызга вәгазь кыйлсын. Таки Муса өммәте белән ошбу өммәт арасында фәрекъ булгай. Муса өммәте яһүд иде. Аларның хиркалары кибрият[1] булыр кыямәт көнендә. Мөхәммәд өммәтенең галимнәре шәфәгать кыйлырлар кыямәттә. *Вәлләзинә утүл гыйльмә дәрәҗәт.*

---

Риваять кыйлынды. Бер хәҗҗам[2] пәйгамбәр галәйһиссәламгә кан алырга килде. Җилкәсенә мохҗәмәне куйды. Канны җыймак белән мәшгуль булды. Күңеленнән әйтте: «Бу канны, җыелгач, нитәем икән: күккә ыргытаеммы, җиргә түгәемме? Әгәр җиргә түксәм, җир әһле һәлак булыр дип куркамын. Чөнки Яхья галәйһиссәлам каны мең кешене һәлак кыйлды, җирдә карарланмады. Мөхәммәд галәйһиссәлам каны, әлбәттә, Яхья каныннан газизрәктер. Әгәр күккә атсам, өстемезгә таш явар дип куркамын. Инде миңа бу канны эчмәктән ары хәйлә булмас», — дип, Мөхәммәд галәйһиссәламнең канын алды да эчте. Балдан татлы, кардан салкын, майдан йомшак иде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Йә хәҗҗам, канны ни эшләдең?» — диде. Хәҗҗам әйтте: «Йә Рәсүлуллаһ, эчтем», — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Йә хәҗҗам, инде сиңа, әбәдән, эч авыруы ирешмәс», — диде.

Хәҗҗам бу сүзне ишетте, гаять мәсрур булды. Хәтта шатлыгыннан рәкыс кыйлды. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Йә хәҗҗам, сиңа ни булды?» Хәҗҗам әйтте: «Йә Рәсүлуллаһ, синең өммәтең өчен миңа бәшарәт хасыйл булды», — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Ни бәшарәт хасыйл булды?» Хәҗҗам әйтте: «Кайчан ки дәмеңне йоттым, эч авыруы ирешмәс дип, миңа сөенеч бирдең. Инде мөэмин бәндәләрең калебенә иблис ничек ирешсен? Вә халән ки, Аллаһы Тәгалә мөэминнәрең кале-

---

[1] Кибрият — күкерт.
[2] Хәҗҗам — кан алучы.

бләрен иман нуры белән зиннәтләде. Кыямәт көнендә зобанилар ник аларга якын килсен?» *Уләикә галә һүдәм мир Раббиһим вә уләикә һүмул-муфлихүн* — алар хакында нидадыр.

---

Кайчан ки Ибраһим галәйһиссәлам тоташ өч көнгә кадәр төшендә углы Исмәгыйльне зәбех кыйлмакны күрде, уянды, мөнәҗәт кыйлды: «Илаһи, Җәбраилне ник җибәрмәдең, таки зәбех гыйльмен миңа үгрәтер иде», — диде. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Син минем Хәлилемсең. Хәлил улмак васитаны тәказа кыйлмайдыр», — диде. Ибраһим галәйһиссәлам әйтте: «Углымны ни өчен зәбех кыйлаем?» — диде. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Йә Ибраһим, минем мәхәббәтемне дәгъва кыйласың, углыңны сәвәсең. Ике мәхәббәт бер күңелдә сыймайдыр», — диде.

Аннан соң Ибраһим галәйһиссәлам Һаҗәргә әмер кыйлды. Исмәгыйльнең башын-күзен юды. Яхшы кием кидерде. Ибраһим галәйһиссәлам Һаҗәрдән яшертен пычак алды, бау алды. Һаҗәр әйтте: «Углымны кайда алып барасың?» — диде. Ибраһим галәйһиссәлам әйтте: «Кунакка алып барамын», — диде. Һаҗәр: «Хәерле булсын. Аллаһыга тапшырдым», — дип калды. Бәс, Ибраһим галәйһиссәлам, Исмәгыйльне кулыннан җитәкләп, Мина тагына ашты. Кыйссасы мәгълүмдер.

Риваять кыйлынды ки: Ибраһим галәйһиссәлам пычакны Исмәгыйльнең муенына кырык мәртәбә куеп тартты, пычак кисмәде. Ибраһим галәйһиссәлам пычакны җиргә ыргытты, пычак ташка кереп китте. Бәс, Аллаһы Тәгалә пычакка тел бирде. Әйтте: «Мин ничек итәем». Хәлил әйтә: «Кис». Җәлил әйтә: «Кисмә! Җәлилнең әмере Хәлилнең әмереннән куәтлерәктер», — диде. Моннан соң Ибраһим галәйһиссәлам мөнәҗәт кыйлды: «Илаһи, пычак миңа итагать кыйлмады: Исмәгыйльне кисмәде», — диде. Нида килде: «Йә Ибраһим, ник аның бугазын пычак киссен? Өеңнән чыкканда, анасы аны безгә тапшырды, аның бугазын пычак кисмәс», — диде.

Инде, әй угыл, бер мәртәбә Аллаһы Тәгаләгә тапшырмак белән, Исмәгыйль зәбехтән хәлас булды. Вә аның фидасына Аллаһы Тәгалә оҗмахтан кучкар җибәрде. *Кад садәкатирруәйә вә кәзәликә нәҗзил-мухсинин*. Инде пәйгамбәр галәйһиссәлам вафаты вакытында өммәтләрен Аллаһы Тәгаләгә тапшырды. Бала туган вакытта, Аллаһы Тәгаләгә тапшырасың. Мәетне кабергә куйганда, Аллаһы Тәгаләгә тапшырасың: *«Бисмилләһи вә билләһи вә галә милләти рәсүлилләһ»*, — дисең.

Бәс, мөэмин бәндә Аллаһы Тәгаләгә ничә мәртәбә тапшырылса, ул бәндәне Аллаһы Тәгалә ник тәмуг утыннан хәлас

кыйлмасын?! Әлбәттә, кыйлыр. Исмәгыйльнең фидасына оҗмахтан кучкар җибәрелде. Кыямәт көнендә һәрбер мөэмин колның фидасына габәдәи венамнан вә мөшрикләрдән җитмешәр кешене җибәрелсә кирәк.

———

Шәех Хәсән Бәсри разыйаллаһу ганһу олуг кәрамәт иясе, әүлияи Аллаһыдан иде. Хәтта риваять кыйлыныр ки, кабердәге мәетләр белән мөкяләмә кыйлыр иде, хәл-әхвәлләрен сорашыр иде. Дәхи терекләргә мәетләр хәленнән хәбәр бирер иде. Кабергә куелгач, буласы вакыйгаларны әйтеп, адәмнәргә нәсыйхәт бирер иде. Беркөн Хәсән Бәсридән сорадылар: «Бу кәраматне ни белән таптың? Хәтта мәетләр сиңа сөйләшерләр», — диделәр. Әйтте: «Өч төрле эш белән бу кәраматне таптым. Әүвәл — Аллаһы Тәгаләгә тәслим вә тәүвыйз белән. Икенче көндез ашауны куймак белән, ягъни руза тотмак белән. Өченче — кич йоклауны куймак белән», — диде. Ягъни: «Һәрбер эшемне Аллаһыга тапшырдым. Көндез руза тоттым. Кич уяг тордым. Бәс, Аллаһы Тәгалә бу кәраматләрне бирде», — диде.

Риваять кыйлыныр ки: әгәр бер шарибел хәмер тәүбәсез булса, кыямәт көнендә аның кулына бер кадәх тулы эрен вә сары су бирерләр. Эчмәскә теләр. Ахыр нәгыйләҗ, бу кеше ул касине эчәр. Дәрхаль тәне күбәр. Йөзенең тиресе өзелеп-өзелеп төшәр. Шөйлә җәһәннәмгә илтерләр.

Пәйгамбәр галәйһиссәламнән риваять кыйлынды: «Әгәр бу хәмер эчүче хәмер белән мәшгуль булса, зина кыйлгучы — зина белән мәшгуль булса, аларның калебеннән иман чыгар. Болыт кебек баш өстендә торыр. Хәмердән вә зинадан бушаганга кадәр», — диде.

Гали разыйаллаһу ганһу әйтте: «Әгәр дә бер кадәх хәмер диңгезгә ташланса вә ул диңгез дулкыннары булып читкә чыкса, ул җирдә үлән үсеп, ул үләнне куй ашаса, ул куйны зәбех кыйлып пешерсәләр, мин ул итне ашамамын, эткә ташлармын», — диде. Инде әй угыл, бер кадәх хәмер диңгезгә әсәр итеп, ул судан хасыйл булган үләнне ашаган куй ите этләргә ташланса, шиксез, хәмер эчкән кеше тәүбәсез үлсә, әлбәттә, аны җәһәннәм этләренә ташласа кирәк.

———

Аллаһы Тәгалә үзенең Кәлям кадимендә биш нәрсәне кәбир[1] дип атады. Әүвәл, Аллаһы Тәгалә үзен кәбир дип тәсмия кыйлды: *«Зәликә биәннәллаһә һуәл галийүл кәбир»*, — диде.

---

[1] Кәбир — олы.

Икенче, галим ки кешегә боера, үзе гамәл кыйлмай, шундаен галимнең һәлакен кәбир дип атады: *«Кәбира мәкътән гыйндәллаһи ән тәкулү мә лә тәфгалүн»*, — диде. Өченче, бәндәләренә булгучы үзенең фазылын кәбир дип тәсмия кыйлды: *«Вә бәшширил-мөэминин биәннә ләһүм мин Аллаһыи фәдалән кәбиран»*, — диде. Дүртенче, ахирәт милкен кәбир атады: *«Вә изә раәйтә сәммә раәйтә нәгыймән вә милкән кәбира»*, — диде. Бишенче, хәмер эчмәкнең гөнаһын вә комарның[1] гөнаһын кәбир диде: *«Вә ясъәлүнәкә ганил хамри вәл-мәйсири куль фиһимә исмүн кәбир»,* — диде.

Инде, әй угыл, хәмер эчмәк вә комар уйнамак Аллаһы Тәгалә каршында олуг гөнаһ эш булса, дөньяда мондаен олуг гөнаһтан зиядә сакланмак тиеш.

---

Кайчан ки Дауд галәйһиссәламнең вафаты кариб булды, үзенең олуг углын вәли гаһед итмәгә ирадә кыйлды. Унике углы бар иде. Олуг углының исеме Яһшука иде. Бәс, Сөләйманның анасы әйтте: «Мин бу райга разый түгелмен, бәлки Сөләйманың вәли гаһед булсын», — диде.

Бу хосуста күп ихтилаф кыйлыштылар. Хәтта Бәни Исраил ике фирка булды. Бер фиркасы Сөләйман хәлифә булмакыны теләде. Бер фиркасы Яһшука хәлифә булмакыны теләде. Аннан соң Җәбраил галәйһиссәлам иңде. Әйтте: «Йә Дауд, Аллаһы Тәгалә сиңа сәлам укыды». Дәхи әйтте: «Хәлифәлеккә мөстәхак шул кеше ки, кем дә кем гыйлем белән мөттәсыйф булса. Ягъни хәлифә булган кеше галим булмак тиештер», — диде. Бәс, Бәни Исраил голямасы җыелып, мәслихәт белән биш мәсьәлә хәзерләделәр. «Бу мәсьәләләргә кайсы җавап бирсә, шул вәли гаһед булсын», — диделәр. Бу мәсьәләләрне үгрәтеп, бер кешене Сөләйман белән Яһшука янына җибәрделәр. Биш мәсьәлә ошбулардыр: 1) Дөньяда мөселман күпме, кяфер күпме? 2) Ирләр күпме, хатыннар күпме? 3) Әхсан әшья ни-нәрсә? 4) Әкъбәх әшья ни-нәрсә? 5) Дәхи, ул ике нәрсә ни-нәрсәдер ки, берсенең вөҗүде белән файда юк, икенчесенең вөҗүде булмаса? Алар белән өченчесе булмаса, ул икесенең юклыгы вөҗүде тиңдер — файда заһир булмас?

Бәс, Яһшукадан сорадылар. Бер мәсьәләгә дә җавап бирә алмады. Аннан соң Сөләйманга бардылар. Бәс, Сөләйман аларны күргәч тә көлде. Әйттеләр: «Бу углан һәнүз сабыйдыр». Сөләйман галәйһиссәламгә сәлам бирделәр. Сөләйман

---

[1] Комарның — отыш, акча уенының.

галәйһиссәлам сәлам кайтарды. Торды, аларны икрам белән кабул итте.

Бәс, болар мәсьәләне сорый башладылар. Аларның сүзе арасында Сөләйман кычкырды: *«Галәйкүм әс-сәлам вә рәхмәтуллаһи Тәгалә»*, — диде. Бәс, алар мәсьәләне сорап бетерделәр. Сөләйман галәйһиссәлам җавап бирде: «Кяферләр мөэминнәрдән күбрәктер», — диде. «Ни дәлил белән?» — диделәр. Әйтте: «Мөселманнар — мөселманнардыр, кяферләр, кяферләрдер, ә монафикълар кяферләр җөмләсеннәндер. Аннан соң шарибел хәмерләр дәхи кяферләр җөмләсеннәндер. Ошбу дәлил белән күбрәк дип әйтәмен», — диде. «Раст әйттең», — диделәр. «Әмма икенче мәсьәләңез: ирләрдән хатыннар күбрәктер, аның өчен ирләр — ирләрдер, хатыннар — хатыннардыр. Әмма хатыннар сүзе белән гамәл кыйлгучы ирләр алар һәм хатыннар җөмләсеннәндер. Вә дәхи ялганчылыкны үзенә гадәт итүче ирләр — алар һәм хатыннар хөкемендәдер», — диде. «Раст әйттең», — диделәр. Дәхи өченче мәсьәләңезгә җавап: *«Әхсәнү әшья — мәръәтүн салихәдер. Әкъбәхү әшья мәръәтүн сүэдер»*, — диде. «Раст әйттең», — диделәр. Дүртенче мәсьәләңезгә җавап: *«Әкъбәхү әшья вә әзәмму әшьяәш ширкү билләһи Тәгаләдер. Вә әшрафү әшья әл икрар би вәхдәниятилләһи Тәгаләдер*. Чөнки бер шәһәрдә ике падишаһ булмак җаиз түгел. Бәс, Аллаһы Тәгаләнең милкендә шәрик булмак нитәк җаиз булыр?» — диде. «Раст әйттең», — диделәр. Әмма бишенче мәсьәләңез җавабы будыр: «Берәүнең сурәт хасәнәсе булса, сакалы булмаса, аның җәмалы гадем хөкемендәдер. Акыл булмаганга. Берәүнең малы булса, сәхавәте булмаса, ул кеше фәкыйрь хөкемендәдер. Сәхавәте юклык сәбәпле. Чөнки саран кешенең малы — җир астында күмгән мал хәлендәдер, һичкемгә файдасы юктыр», — диде. «Раст әйттең», — диделәр.

Моннан соң Сөләйман галәйһиссәлам, шул биш мәсьәлә сәбәпле, җир йөзенә хәлифә вә падишаһ булды — атасы милкенә варис булды. Хәлбуки ул мәсьәләләрнең җавабын аңа кырмыска өйрәтте.

Бу габде зәгыйфь галимнәрдән, галимнәрнең китапларыннан җөзъи гыйлем хасыйл итте. Белгән кадәр язып интишар кыйлды, мәгънәләр энҗесен сачты. Укып файда алучылар белән бергә Аллаһы Тәгаләнең фазылы вә кәрәме белән ахирәт милкенә наил булсак гаҗәпмени?!

Бәс, Бәни Исраилнең ире Сөләйман хәлифә булмакына карар иткәч, Яһшука бик хафа булды. Әйтте: «Бу биш мәсьәләләрдән гайре мәсьәләне сорасалар, мин һәм җавап бирер идем», — диде. Дәхи әйтте: «Сөләйман хәлифә булды. Бу —

габен газимдер[1]. Даудның олут углы мин идем, хәлифәлеккә мин әлхак идем», — диде. Ул Яһшука гөман кыйлды ки, олуглык яшь беләндер. Белмәй ки, олуглык вә гыйлем вә дәрәҗә — Аллаһы Тәгаләнең әмере белән вә Аллаһы Тәгаләнең гыйнаяте беләндер.

———

Көннәрдән бер көн Һарун әр-Рәшиткә бер дәһри килде. Әйтте: «Йә әмирел-мөэминин, замананың голямасы Әбү Хәнифә, вә Әбү Йосыф, вә Мөхәммәд, вә Хәсән Бәсри иттифак кыйлмышлар ки, санигъ галим бардыр — галим хәдистер, галим мөтәгаҗирдер, дип әйтәләр. Ошбу галимнәреңнән фазылрак вә галимрәкләрен бу мәҗлескә хәзер кыйл. Таки күз алдында алар белән бәхәс кылышып, санигъ галим юклыгын исбат кыйлам», — диде.

Бәс, голяманың әфзале Әбү Хәнифә иде. Һарун әр-Рәшит аңа кеше җибәрде. Әйтте: «Йә имам-мөслимин, безгә бер дәһри килде. Санигъ галимне нәфи кыйладыр. Синең белән моназара кыйлмага ирадәсе бар. Килгәйсең, бәхәс белән аны илзәм кыйлгайсын», — диде. Аннан соң Әбү Хәнифә торды. Һарун Рәшиткә килде. Ләкин бераз кичегеп килде. Һарун әр-Рәшит истикъбаль кыйлып, дәһри янына алып керде. Әкябир вә эгъян дәүләт һәммәсе килеп җир-җиренә утырмышлар иде. Дәһри әйтте: «Йә Әбү Хәнифә, кичегебрәк килдең, ни сәбәп булды?» — диде. Әбү Хәнифә әйтте: «Миңа гаҗәп эш вакыйг булды, шуның өчен кичектем. Ягъни минем йортым Диҗләнең аргы ягындадыр. Өемнән чыктым. Диҗлә кәнаренә килдем. Диҗлә аркылы чыгарга көймә юк иде. Мәгәр күрдем: бер иске көймә ята. Такталары минем нәзарым вакыйг булды: шул сәгать таркалмыш такталары, үз алдына хәрәкәткә килеп, бер җиргә җыелды, бер-берсенә тоташты. Нәҗҗарсыз-гамәлсез бөтен көймә булды. Ул көймә белән Диҗлә аркылы чыктым. Монда килдем», — диде. Дәһри әйтте: «Әй эгъян дәүләт, ишетеңез: имамыңыз вә әфзаль замановыңыз ни әйтте? Моннан да ялган сүз ишеткәнеңез бармы?» — диде. Ватык көймә, нәҗҗарның гамәленнән башка хасыйл булырмы? Бу — ялганчы мәхәздер[2] ки, әфзале голямагыздан заһир итте!» — диде. Әбү Хәнифә әйтте: «Һи кяфер мотлак, әгәр дә көймә санигъсыз вә нәҗҗарсыз хасыйл булмаса, бу галәм санигъсыз нитәк заһир булсын? Син гадәм санигъ белән нитәк каил була беләсең?» — диде. Бәс, Һарун әр-Рәшит әмер кыйлды: дәһринең муенын суктылар, үтерделәр. Инде, әй угыл, моннан артык сиңа ничек дикъкать кыйлаем? Ничек изгелеккә күндерәем? *Ләкиннә әксәрә җәмгыйн*

---

[1] Габен газимдер — бик олы алдау.
[2] Мәхәздер — чын, чеп-чи.

*ля яфрикунэл хэммэмэ минэл үрзи вэ лэм яфһэму мэганил кэлэми вэ һүм яхсэбунэ энни энтыйкубилҗизэф.*

Һарун эр-Рэшитнең галим вэ фазыйл вэзире бар иде. Үз заманында назыйре юк иде. Лэкин Һарун-эр-Рэшит бу вэзирне башкалардан артык күрмэде. Үзеннэн дуннэр белэн аны бэрабэр күрде. Бэс, вэзир моңа хурланып эйтте: «Йэ эмирелмөэминин, вэзирлэрең вэ хезмэтчелэрең — бары да сукыр тавыклардыр. Арпаны бодайдан, дөгене хаммамнан фэрекъ кыйлмаслар. Безне һэм алар белэн бэрабэр күрэсең. Дэхи син үзең дэ безлэрдэн фазыйл кемдер, җаһил кемдер, тэфрика кыйлмассың. Дөге белэн хаммамны танымаган кеше фазыйл белэн ничек мөсави[1] булыр?!» — диде. Һарун-эр-Рэшит эйтте: «Аллаһ Тэгалэнең халкыннан дөге белэн хаммамны танымаган кеше аслан юктыр. Бу сүзең белэн бик ялгыш сөйлэдең», — диде. Вэзир эйтте: «Яхшы. Хаммам белэн дөгене танымаган кешене мин сиңа ничэне табып китерэем?» — диде. Һарун эйтте: «Ярар, эгэр табып китерсэң, кэлямеңне исбат кыйлсаң, сүз юк. Мин синең дэрэҗэңне күтэрермен», — диде. Бэс, вэзир гарэп сахрасына дөге белэн хаммамны белмэгэн кешене эзлэмэгэ җибэрде. Бэс, бер кешене таптылар ки, хаммам ни икэнне, дөге ни икэнен бер дэ белгэне юк, имеш.

Бэс, яхшы киемнэр киендереп, ул кешене Һарун янына керттелэр. Хэлифэ аның сурэтенэ карады, сиррэтенэ төшенмэде. Бэс, вэзир боерды: бер савыт дөге пешереп китерделэр. Хасыйле кэлям, дөгедэн пылау пешереп китерделэр. Гарэпнең алдына куйдылар. Гарэп тэнавел кыйлды. Моны күргэн юк иде: «Һай, бик һэйбэт, лэтыйф вэ нэгыйм нэрсэ, имеш», — дип мактап ашады, рэхэтлэнде, тирлэде. «Һай мөбарэк нэрсэ вэ яхшы нэрсэ», — дип ашады. Һарун эйтте: «Эй кардэш, ни-нэрсэ ашайсың?» — диде. Гарэп эйтте: «Белмим, эмма лэтыйф хаммам, дип гөман кыйламын», — диде. Һарун бик озак көлде. Эйтте: «Хаммам икэнен кайдан белэсең?» — диде. Гарэп эйтте: «Мин сахрада торамын.

Көннэрдэн бер көн, салкын су белэн госел кыйлган вакытымда, хаҗилар таифэсеннэн бер җэмэгать янымнан узды. Эйттелэр: «Эй адэм, ник хаммам өчен шэһэргэ бармайсың? Рэхэтлэнер идең. Тэнең тирлэр иде. Мөтэнэгъгыйм булыр идең. Салкын су белэн коенмак — гакыйльлэр эше түгелдер», — диделэр. Аларның сүзе хэтеремдэ калды. Шул көннэн бирле: «Һай, күрсэң иде! Ашап карасаң иде. Җисемем тэнэгъгым тапса иде», — дип, һэркөн уйлап йөрдем. Хэлэн, җисемем рэхэт тапты, тэнэгъгым кыйлдым. Шуның белэн хаммам икэнен белдем», — диде.

---

[1] Мөсави — тигез.

Һарун әр-Рәшит, моны ишеткәч, дәхи бик рәхәтләнеп көлде. Бик гаҗәпләнде. Вәзиргә хилгать кидерде. Башка вәзирләрдән аның дәрәҗәсен артык кыйлды. Бәс, белгел ки: әй угыл, җаһилләр белән галимнәрнең хәле шөйләдер. Чөнки җаһилләр галимнәрне вә фазыйлларны тәфрика кыйлып белмәсләр. Талибларны васыйллардан аерып танымаслар. Нечкә вә гыйбрәт сүзләрне мөстәхсән саймаслар[1].

Әй угыл, халыкның зирәклеген вә фазыйләтен тәҗрибә хисабынча, янә бер нөктә зикер кыйлаем. Риваятьләрдә мәнкульдер: кайчан ки пәйгамбәр галәйһиссәлам Мәккәне фәтех кыйлды, Кәгъбәдә 360 пот күрде: Кәгъбәнең дүрт диварына, биек җиргә тезеп куелмыш потлар иде. Бәс, пәйгамбәр галәйһиссәлам хәзрәти Галигә әйтте: «Йә Гали, бу утыннарны җыеп утка як! Янсын бу сурәтләр утта!» — диде. Гали разыйаллаһу ганһу торды. Берәм-берәм алып, сурәтләрне утка якты. Югарыдагыларын алганда, пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Йә Гали, югарыгыларны дивардан минем җилкәмә басып ал», — диде.

Бәс, Гали разыйаллаһу ганһу алды. Утка ташлады. Олуг потларны алмага нәүбәт җитте. Дәрхаль Җәбраил галәйһиссәлам килде, әйтте: «Йә Мөхәммәд, Аллаһы Тәгалә сиңа сәлам укыды. Әйтте, олуг сурәтләрне утка салмагайсың». Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Йә Җәбраил, ни өчендер?» Җәбраил әйтте: «Йә Мөхәммәд, ул кайсы сурәтләр, беләсең?» — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Юк, белмим», — диде. Җәбраил әйтте: «Ул шул сурәттер ки, Ибраһим заманында аның сыйдкы нәбүвәтенә, рәсүллегенә гуаһлык бирде. Аллаһы Тәгалә әйтте: «Ул сурәт халилемнең нәбүвәтенә шәһадәт бирде. Аны яндырмак җаиз булмас», — диде.

Бәс, пәйгамбәр галәйһиссәлам ошбу хәлне хәзрәти Галигә әйтте. Аннан соң Гали куйды. Бик көлде, мәсрурән тәгаҗҗеб кыйлды. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Йә Гали, ник тәгаҗҗеб кыйлдың, ни булды?» — диде. Гали әйтте: «Йә Рәсүлуллаһ, миңа өммәтең өчен бәшарәт хасыйл булды. Сурәт бер мәртәбә Аллаһы Тәгаләнең вахданиятенә[2] вә Ибраһимның нәбүвәтенә шәһадәт китерде. Аллаһы Тәгалә аны утка яндырудан мәныг кыйлды. Әмма гөнаһлы өммәтнең гомерләре буенча, *әшһәду ән лә Иләһә иллә Аллаһә вә әшһәду әннә Мухәммәдән габдуһу вә расүлуһ,* дип, Аллаһы Тәгаләнең вахданиятенә вә синең нәбүвәтенә шәһадәт китерерләр. Аллаһы Тәгалә аларны утта нәтәк яндырсын?! Яндырмас, бәлки, гафу кыйлып, җәннәткә кертер. *Иннә Аллаһә ягъфируз-зәнубә җәмиган.*

---

[1] Саймаслар — санамаслар.
[2] Вахданият — берлек, бердәнбер булу.

———

Мәгълүмдер ки, күп адәмнәр укырга белмәйләр. Хәреф танымайлар. Язу белмәйләр. Аллаһы Тәгалә *«икъра китабәкә!»* дип әйтмәкендә ни хикмәт бардыр? Җавап будыр ки, әй угыл, көннәрдән бер көн пәйгамбәр галәйһиссәламгә Җәбраил галәйһиссәлам назил булды. Әйтте: «Йә өмми, Аллаһы Тәгалә сиңа сәлам укыды». Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Йә Җәбраил, минем ни гөнаһым бар ки, мине өмми, диден». Җәбраил галәйһиссәлам әйтте: «Өмми, дип әйтмәдем, бәлки Аллаһы Тәгалә сине өмми тәсмия кыйлды». Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Ник өмми тәсмия кыйлды?» Җәбраил галәйһиссәлам әйтте: «Ике мәгънә белән сине өмми тәсмия кыйлды. Берсе шулдыр ки: Аллаһы Тәгаләнең фазылы вә өммәтеңә гыйнаятедер. Аның өчен кайчан ки кыямәт көне булса, *вәмтәзул ямә әййүһәл-мүҗримүн*, дип нида кыйлыр. Бәс, мөэминнәр мөҗримнәрдән аерылырлар. Өммиләр карилардан аерылырлар».

Бәс, Аллаһы Тәгалә боерыр: мөэминнәр вә кариләр җәннәткә керерләр. Пәйгамбәр галәйһиссәлам җәннәткә газым кыйлыр. Нида килер: «Йә Мөхәммәд, кайда барырсың? Мин сине, өмми, дип тәсмия кыйлдым. Туктап тор. Өммиләр белән бергә керерсең, аның өчен өмми өммиләр белән бергә булмак лазем» дип.

Бәс, пәйгамбәр галәйһиссәлам гасыйлар вә өммиләр килгәнче туктап торыр. Әйтер: «Илаһи, нигә кадәр монда тәвакkыф кыйлаем?» Аллаһы Тәгалә әйтер: «Гасыйлар вә өммиләр җыелып бетсен, аларга шәфәгать кыйлырсың», — дип. Кайчан ки гасыйлар вә өммиләр мөҗтәмигъ булсалар, пәйгамбәр сәҗдә кыйлыр, әйтер: *«Аллаһүммә һәбблийәл гусат вәл-музнибин»*. Аллаһы Тәгалә әйтер: «Йә Мөхәммәд, башыңны күтәр: сораганыңны сиңа һибә кыйлдым. *Вәләсауфә югътыйкә Раббукә фәтәрза*. Бәс, пәйгамбәр галәйһиссәлам, гасыйларны вә өммиләрне алып, оҗмахка керер.

Янә икенчесе — Аллаһы Тәгалә сине «өмми» диде. Өмминең мәгънәсе: анадан туды вә анага мәнсүб, дигән сүздер. Аллаһы Тәгалә сине «өмми» дип атады, өммәтеңә гыйнаять йөзеннән. Таки синнән соң өммәтләрең зәләләткә төшмәсеннәр. Нитәкки нәсарилар, Аллаһы Тәгалә, дип, зәләләткә төштеләр. Бәс, шул җәһәттән сине «өмми» дип тәсмия кыйлды, таки өммәтең могҗизатыңны күрсеннәр, зәләләткә төшмәсеннәр. Чөнки өммәтләрең белделәр ки, өммисең: *мәүлүд минәл умсән*, диде.

Янә дәхи белгел, әй угыл, тәгълим ике нәвыгтыр[1]. Бере — тәгълим заһири, инсани. Икенчесе — тәгълим батыйни, раббанидыр. Кайчан ки «икъра китәбәкә» дисә, тәгълим раббани хасыйл булыр. Бәс, тәгълим заһири, инсани ягъни дөньяда адәм кыйраәтен тәгълим кыйладыр вә китабәтне үгрәнәдер. Язган нәрсәсен беләдер. Вә тәгълим батыйни раббани кыямәт көнендә заһир булыр: *ликаулиһи Тәгалә ямә түбләс-сәраир*. Бәс, тәгълим инсани китабәт вә язмак белән генә булыр. Мәсәлән, бер кеше кәгазьгә бернәрсә язса, ул язган кәгазь өстенә язмаган кәгазь куйса, астындагы кәгазьгә ни язганын берәү дә белмәс, өстендәге кәгазьне алмасаң. Әмма тәгълим раббани һәм ушандак фил мәгъни, тәгълим инсани кебектер. Ягъни Аллаһы Тәгалә мөэмин бәндәнең калебенә тәүхид белән икърарны кодрәт каләме белән язды. *Уләэикә кәтәбә фи кулубиһимул-иман*. Бәс, гафләт, хирес, тул әмәл, бөхел, гайбәт, кәзеб, нифак, хосед, хыянәт — баягы язган кәгазь өстендә язуны язмаган кәгазь каплап торган шикелле, калебтә тәгълим раббанины каплап торадыр.

Бәс, кыямәт көн булса, бәндәнең калебеннән бу пәрдәләрне Аллаһы Тәгалә күтәрер. Бәндә үзенең китабын укый белер. Аллаһы Тәгалә бәндә калебеннән ул гауашиларны, ягъни каплап тора торган нәрсәләрне күтәрер. *«Кәтәбә фи кулубиһимул иман»* язуы заһир булыр. Аллаһы Тәгалә тарафыннан *«икъра китәбәкә кәфә бинәфсикәл ямә хәсибә»* нидасы килгәч, бәндә үзенең китабын укый белер. *Фәзәликә вәҗһүс-сирри һәзиһил аяти*.

Инде, әй угыл, Аллаһы Тәгаләнең кодрәтенә инкяр кыйлмагайсың. Аллаһы Тәгалә кәмаль Хакимдер вә Гафур Рәхимдер. Таштан нәка чыгарыр. Агачтан ут чыгарыр. Бозаудан нотык чыгарыр. Таяктан шәһадәт чыгарыр. Исмәгыйльгә кыйлыр куччарны фида; Ибраһимга утны кыйлыр суык. Бәс, Мөхәммәд өммәте Аллаһы Тәгаләнең әмере белән кыямәт көнендә кариэланып, сәййиәтләре хасәнәтенә мөнкалиб булса, гаҗәпме булыр? Инде, белгел ки, әй угыл, дөньяда укымаган кеше, бер дә язу танымаган кеше кыямәт көнендә үзенең гамәл китабын укый белер. Мин язу танымаймын, дип әйтә алмас.

———

Шарибел хәмернең намазы дөресме, дөрес түгелме? Белгел ки, әй угыл: җәваз[2] башка, кабул башка. Җәвазның хөкеме

[1] Нәвыгтыр — төрледер.
[2] Җәваз — дөреслек.

шулдыр: мәсәлән, шарибел хәмер намаз укыр. Зиммәсеннән сакыт булыр[1], ләкин намаз аның гөнаһларын вә яман эшләрен сакыт кыйлмас. *Иннәмәл хәсинәт юзһибунәс сәййиәт.* Әмма кабулның хөкеме шулдыр ки: зиммәсеннән намаз сакыт булыр, гөнаһлары вә яман эшләре һәм бергә сакыт булыр. Тәкәбберлекне китәрер, калебендә тәвазыйглык зоһур итәр. Мәсәлән, бер хужа үзенең колы белән язышты: әгәр миңа мең дирһәм табып китерсәң, син миннән азат, диде.

Бәс, колы китте дә шул үз хуҗасының мең дирһәм акчасын угырлады, хуҗасына китереп бирде. Бәс, бу хөкемнең заһирында кол азат буладыр. Хуҗасының үзенең малы булса да, хуҗасына мең дирһәмне түләр. Кол, хибес кыйлыныр да, шул мең дирһәмгә кадәр итәр. Бәс, һәр ике хәлдә мәшәкатьтән хәлас булмас. Инде шарибел хәмер һәм ушандактыр. Әгәр укыса — намазы дөрес булыр, ләкин аны җинаяте өчен тәмугта хибес кыйлмак лазем булыр вә гөнаһысы кадәр җәһәннәмдә газап кыйлыныр.

---

Хәзрәти Гали разыйаллаһу ганһу әйтте, әгәр бер кешедә ислам гайрәте булса, аннан ике төрле эш садир булмас. Әүвәл берәү үзенең әһле бәйтенә, вә кыз карендәшенә, вә анасына ят ирдән гайрәт итсә, ул кеше әҗнәбия белән зина кыйлмакка разый булмас. Вә үзенә зинаны, әбәдән, җаиз күрмәс. Әй угыл, бу гыйбрәтемне фәһемләмәсәң, икенче гыйбарәт белән бәян кыйлаем. Мәсәлән, бер кеше үзенең хатынын көнләшсә, ят ирләр белән зина кыйлмыш микән, дип тәфтиш кыйлса яки өйдән чыгарып җибәрсә, гайреләр белән зинага мәел кыйлмагай иде, дип, гайрәт вә көнчелек кыйлса, мондаен адәм үзе дә зинага мәел кыйлмайдыр. Хатынына гайрәт, вә хамият, вә көнчелек кыйлмаган кешене «дәййюс» диләр вә «картабан» диләр. Аны тәхриф кыйлып, «калтабан» дип һәм әйтерләр. Яки «кәрдәңкел» диләр. Бу сүз фарсычадыр. Мәгълүмдер ки, үзе зина артыннан йөргән кеше хатынына гайрәт вә хамият кыйла алмайдыр.

Дәхи икенчесе шулдыр ки: ул кеше хәмер эчмәс. Ягъни диндә гайрәт вә тәкъвалык кыйлып, хәмер эчмәс. Аның өчен ул кеше гакылы белән күрәдер ки һичкем, үлгән вакытта вә үлем сырхавы тигәч: «Минем хәмер мәҗлесендә булган якын дусларымны чакырыңыз, хәмер китереңез, мотрибләрне вә скрипкәчеләрне чакырыңыз. Сазларын чәлсеннәр, уйнап-көлеп хәмер эчәек, дип бер дә әйтмидер. Ләкин әйтер, мәсҗет има-

---

[1] Сакыт булыр — юкка чыгар.

мын китереңез. Җәмәгать килсен, мин тәүбә кыйлаем, миңа тәүбә үгрәтеңез. Шәһадәт тәлкыйн кыйлыңыз. Карилар килсен, Коръән укысын. Башым очына Коръән куеңыз. Минем өчен садака биреңез. Минем өчен фатиха укыңыз«, — дип әйтер.

Инде гакылы белән боларны фәһем кыйлган кеше хәмер эчәргә ник мәел кыйлсын? Инде, әй угыл, моның кыска гынасы шулдыр ки: диндә гайрәтле вә хамиятле булган кешегә вәгазь дә кирәк түгел, нәсыйхәт тә кирәк түгел. Чөнки диндә гайрәтле, вә хамиятле, вә көчле кеше үзе дә, зинаның әшәкелеген күреп, зинадан саклана, әһелен дәхи зинадан саклый. Шәрабхәмернең әшәкелеген күреп, хәмер эчүдән сакланыр.

———

Вагыйзлар вә галимнәр минбәргә менсәләр, кайсы бабтан сүзне күбрәк сөйләмәк кирәк: хәвеф бабыннанмы яки риҗә бабыннанмы?

Инде, әй угыл, җавап будыр: вагыйз булган кешегә важибтыр ки, риҗә бабыннан күбрәк сүз сөйләгәй. Чөнки Аллаһы Тәгалә әйтте: *«Вә рахмәти вәсигать күллә шәйин»*.

Әнәс бин Малик пәйгамбәр галәйһиссәламнән риваять кыйлды. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: *«Ләганәллаһүл-мөтәнәффирин»*, — диде. Өч мәртәбә әйтте, янә: *«Рахимәллаһүл-мөтәкәффилин»*, — диде, өч мәртәбә әйтте. Ягъни: «Минем өммәтемне Аллаһы Тәгалә рәхмәтеннән качыргучыларга Аллаһы Тәгаләнең ләгънәте булсын», — диде. Ягъни мөтәнәффирдән морад шундаен вагыйздыр ки, фәкать хәвеф бабыннан гына сүз сөйләр. Вә шулкадәр мөбәляга кыйлыр ки, хәтта вәгазь тыңлаучылар Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән өмид кисәрләр. Вә мөтәкяффилдән морад шундаен вагыйздыр ки, риҗә бабыннан сүз сөйләр. Вә шулкадәр тыңлагучылар, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтен өмид итеп, бер-беренә шәфәгатькә кяфил кыйлырлар. Ягъни Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте күп, имеш, дип, бер-берен изгелеккә димләшерләр.

———

Бер заманда Нисабур шәһәрендә кахтлык вә ачлык булды. Халык, хәтта ачлыкка гаҗиз булып, үләксә ите вә эт ите ашадылар. Ашамак өчен елан, чаян эзләмәгә вә тычкан эзләмәгә бер җәмәгать сахрага чыктылар. Бер карьягә барып җиттеләр. Күрделәр: урамда бер углан йөри, кулында таягы бар. Кәррә[1] уйнап торыр, нитәкки балалар гадәте шөйләдер. Ачлыкта, кахтлыкта хәбәре юк. Җәмәгатьтән бере ул углан янына бар-

[1] Кәррә — шар.

ды. Әйтте: «Әй углан, бу вакытта ул нинди кәррә уеныдыр? Белмәйсеңме, бу вакытта башкаларда ачлык кәррә вакытыдыр, кәррә уены вакыты түгелдер. Күрмәймесең, күз яшьләре ташу булмыш, сулышлары ут булмыш? Син кәррә уйныйсың», — диде. Углан әйтте: «Мин ачлыктан ник куркаем? Мин ач булырмын дип ник кайгыраем? Минем бер хуҗам бар. Хуҗамның амбар-амбар бодае бар. Малы күп, мөлкәте күп. Бәхете бар, тәхете бар. Вә күркәм кызы бар, миңа гакыд никях яздылар. Мин ник шатланмаем, ник уйнамаем?» — диде.

Инде, әй угыл, вагыйзлар сиңа риҗә бабыннан вәгазь әйтеп, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте белән, ник сиңа бәшарәт җибәрмәсеннәр? Җибәрерләр. Ул мәзкүр углан ки, хуҗасының хәятында бу өч көнлек дөньяда фани байлык өчен вә хәдис ачлык өчен ачлыкны фикер кыйлмаса, син ник кайгырасың? Хәлбуки синең хуҗаң — *әл-хәййүл каййүмү лә тәэхузүһү синәтүн вә лә нәумдыр*. Вә синең хуҗаң — хуҗаларның хуҗасы Раббел галәминдер. Вә һәм синең баең — *Аллаһү ганийүн вә әнтүмүл фүкарадыр*. Бәс, сиңа әүлядыр ки, андаен хуҗаның рәхмәтеннән риҗә кыйлып, тәүбә вә тәзәррыгың булганда, гөнаһың өчен ник куркасың, ник кайгырасың? *Иннә Аллаһү ягъфируз зөнүбә җәмиган.*

Әй угыл, әгәр бу вагыйзның вәгазен тыңласаң, гыйлем вә хикмәт мәҗлесендә булсаң, сиңа берничә нәрсә важибтыр, таки мәнфәгать хасыйл итәсең. Дөнья хәлләреннән вә дөнья малларыннан калебеңне бушатасың. Хәтереңне җыеп, күңелеңнән вәсвәсәләрне чыгарасың. Голяма мәҗлесендә һәрни ишетсәң, зиһенеңә аласың. Таки ишеткән сүзләреңне вә ишеткән хикмәтләреңне аннан чыгып икенче кешеләргә сөйләрлек буласың. Вә җәмигъ әгъмәлеңне халисән Аллаһы булмакыны ният итәсең. Бу кәйфияттә вәгазь тыңласаң, файда хасыйл булмакына мин кяфилмен.

———

Көннәрдән бер көн бер кеше бер олуг галим янына килде. Әйтте: «Йә имам-мөслимин, миңа бер вәгазь әйт, миңа гыйлемнән бер нәрсә үгрәт ки, аның белән гамәл кыйлып, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтеннән өлеш тапсам икән», — диде. Галим әйтте: «Сиңа гыйлемнән бер нәрсә үгрәнмәстән мөкаддәм үзеңнән ике мәсьәлә сорасым киләдер. Әгәр җавап бирсәң, теләгән нәрсәңне үгрәтермен», — диде. Ул кеше әйтте: «Сөаль кыйл». Галим әйтте: «Аллаһы Тәгалә ахирәтне дөньядан артык кыйлдымы, дөньяны ахирәттән артык кыйлдымы?» Ул кеше әйтте: «Аллаһы Тәгалә ахирәтне дөньядан артык итте». Галим әйтте:

«Ахирәтне дөньядан артык күрәмсең, дөньяны ахирәттән артык күрәмсең?» Ул кеше әйтте: «Мин дөньяны ахирәттән артык күрәмен», — диде. Моның соңында галим әйтте: «Мөхәммәд галәйһиссәлам байлардан фәкыйрьләрне артыграк сөйдеме, фәкыйрьләрдән байларны күбрәк сөйдеме?» Ул кеше әйтте: «Мөхәммәд галәйһиссәлам фәкыйрьләрне күбрәк сөйде». Галим әйтте: «Син фәкыйрьләрнеме, байларнымы күбрәк сөясең?» Ул кеше әйтте: «Бәли, байларны күбрәк яратамын», — диде. Галим әйтте: «Раст әйттең, бәрәкаллаһ. Инде син Аллаһы Тәгалә сөйгән нәрсәнең хилафына вә Рәсүлуллаһ сөйгән нәрсәнең хилафына икәнсең, вәгазь-нәсыйхәткә синең лиякатең[1] юк, имеш. Бар, кайт, бу ике мәсьәлә белән шаныңны төзәт вә гадәтеңне алыштыр: ахирәтеңне дөньядан алда күр. Фәкыйрьләрне байлардан яхшырак күр, таки Аллаһы Тәгаләнең дусларыннан булырсың вә җәннәт әһеленнән булырсың. *Удхулул-җәннәтә әнтүм вә әзвәҗүкүм түхбәрун*».

———

Кайчан кем, Нәүширван Гадел атасы вафат булгач, падишаһ булды, тәхеткә утырды. Беркөн голяма вә фозаланы җәмгъ кыйлды. Голяма вә хокяма һәммәсе мәҗлескә хәзер булдылар. Нәүширван алардан бер мәсьәлә сорады. Әйтте: «Дөньяда ни-нәрсә күркәм?» — диде. Мәҗлестә булган халык һәркайсысы бер сүз, төрлесе төрле сүз әйтте.

Бәс, Нәүширван алар әйткәнне берсен дә мөстәхсән күрмәде. Ул мәҗлестә бер галим фазыйл бар иде, заманында фәрид гасыр вә хәким иде. Әйтте: «Падишаһым, дөньяда өч нәрсәдән күркәм вә әфзаль нәрсә юктыр», — диде. Нәүширван әйтте: «Ни-нәрсәләрдер?» Хәким әйтте: «Әүвәл — үлем, икенче — хатыннар, өченче — мохтаҗлык», — диде. Нәүширван әйтте: «Инде алайса дөньяда болардан кабахәт нәрсә юктыр! Ни дәлил белән син бу нәрсәләрдән әфзаль юктыр, дип әйтәсең?» — диде. Хәким әйтте: «Үлем һәрнәрсәдән күркәм вә әфзаль, дидем, аның өчен әгәр дә үлем булмаса, атаң үлеп, тәхеткә утырмас идең, бу мәмләкәт сиңа тимәс иде». Нәүширван әйтте: «Раст әйтәсең». Янә хәким әйтте: «Нәрсәләрнең күркәмрәге хатындыр, дидем, аның өчен әгәр хатыннар булмаса, син дә мәүҗүд булмас идең». Нәүширван әйтте: «Раст әйтәсең». Янә хәким әйтте: «Мохтаҗлык һәрнәрсәдән яхшырактыр, дидем, аның өчен, әгәр ихтыяҗ булмаса, мәмләкәтеңдә вә хезмәтеңдә ми-

---

[1] Лиякатең — лаек булуың.

нем кебек галим булмас иде. Гаскәрең сиңа монкад булмас иде». Нәүширван әйтте: «Раст әйтәсең». Кыйммәтле хилгатьләр кидерде. Ошбу өч кәлимә өчен.

Инде әй угыл, бу кыйссадан ни фәһемләдең? Бәс, ул фазыйл вә хәким кеше дөнья падишаһларыннан бер кяфер падишаһ алдында үзенең хәлен гарыз кыйлды. Вә үзенең ихтыяҗын белдерде, йөз мең динар хасыйл итте. Вә кыйммәтле хилгать киде. Бәс, әй угыл, милкенә зәваль вә фәна ирешмәй торган әбәди вә әзәли булгучы падишаһларның падишаһына хаҗәтеңне гарыз кылсаң, үлгән вакытыңда *йүбәшшируһум Раббуһум бирахмәтин* бәшарәтен табып үләрсең. Вә кабердә *сәламүн каулән мир Раббир рахим* сәламәтлеген табарсың. Вә кыямәттә *йа гыйбәди лә хәуфүн галәйкүм* иминлеген табарсың. Вә җәннәттә *вә изә раәйтә суммә раәйтә нәгыймән вә мүлкән кәбира* мөлкәтен табарсың.

———

Әгәр берәү үзенең бәлягатькә ирешкән кызын бер кешегә тәзәвеҗ кыйлса, ул кеше бик озак үзенең мәнкүхасына килмәсә, күп мөтдәтләр үтсә, күп вакытны кияү белән килен арасында ызгыш вакыйг булып, кызның анасы әйтер: «Иртәгә казыйга барып, кияүне чакыртаем, кызымның мөһерен сораем һәм аны хибес кыйлдыраем», — дияр. Әмма әгәр ул кеше кыз янына никях бәгъдендә үк килсә, муафыйк кияү булмаса да, рәнҗеткүче булса, рәнҗетсә, хафа кыйлса да әйтерләр: «Сабыр итәек, гафу итәек, кызымызның хәтере өчен. Кызымызның гозере өчен ригая кыйлаек. Рәнҗетүче булса да, җәфасын йөкләек».

Күп гакыйльләрнең, күп фазыйлларның гореф вә гадәте ошбудыр. Син һәм ушандак, әй угыл, ошбу кияү мисалендәсең. Синең гамәлләреңне хафаза фәрештәләре Аллаһы Тәгаләгә гарыз кыйлырлар, әйтерләр: «Илаһи, ул бәндәнең гамәлендә ихлас юк. Күрәмез, гамәлләрендә — рия вә фигыльләрендә — калаэ хая». Бәс, Аллаһы Тәгалә әйтер: «Әй фәрештәләр, нитәкки бәндәләрем кызларның хәтәрәсе өчен кияүләрнең әзиятен вә яман холкын йөклиләр вә гафу кыйлалар, инде мин битарикъ үлә үземнең бәндәләремнеңноксанатын гафу кыйлмакым әүлядыр. *Иннә Аллаһы ягфируз зүнүбә җәмигән. Иннәһүл гафурур-рахим.*

———

Галимнәр вә вагыйзлар һәркайчан минбәргә менсәләр, Аллаһы Тәгаләгә мактау вә мөраҗәгать берлә салават әйтеп, Коръәннән вә хәдистән вәгазь вә нәсыйхәт итәләр. Әгәр бер шагыйрь, минбәргә чыгып, шигырь белән мактау вә салават әйтсә,

вә шигырь белән гыйлем әһелен мактаса, җаиз булырмы? «Булыр», — дип әйтер иден. Аллаһы Тәгалә: *«Вәш шугарау ятбәгуһүмүл гавун»*, — диде.

Җавап будыр ки: Аллаһы Тәгаләнең *«вәш шугарау ятбәгуһумүл гавун»* дигән сүзе мөфтиләр вә мотрибләр өчен, шигырь әйтүче шагыйрьләр хакындадыр. Әгәр бер шагыйрь, минбәргә менеп, голяма вә фозаланы вә фәкиһләрне мактаса яки васыф исламнан бер нәрсәне васыф кыйлса, яки гыйльме шәригатьне васыф кыйлса, *лә бәэсә биһи*, диделәр. Чөнки ул шагыйрьләр әркян исламны игъзаз вә гыйлемне икърар кыйладыр. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: *«Мин әкрамә галимән фәкад әкрамәни»*, — диде. Белгел ки, әй угыл: Аллаһы Тәгалә үзенең Кәлямендә галимнәрне мактады. *«Һәл ястәвил ләзинә йәгъләмунә вәлләзинә ля йәгъләмун»*, — диде.

Бәс, голяма гавам белән бердәй тигез түгел. Ләкин заһир булды: берәү голяманы мактаса, аятьнең мәгънәсе белән гамәл кыйлмыш булыр вә аятькә икътида кыйлмыш булыр. Аллаһы Тәгалә әйтте: *«Әлләзинә үтүл гыйлмә дәраҗәт»*, — диде. Бәс, голяманың дәрәҗәсеннәндер ки дөнья вә ахирәт мактаулгандыр. Бәс, шөйлә булганда, голяманы мактау кыйлмак вә хөрмәтләү гавамлар үзрә важибтыр.

Галимнәр вә вагыйзлар ни өчен минбәрдә хәрәкәтләнәләр, ни өчен кыймылдыйлар, монда ни савап бар икән? Җавап: бәли, галимнәр минбәрдә мозтариб булып, гяһан кулларыны күтәрсәләр, гяһан кулларын түбән салалар. Мөдәррисләр дәрес вакытында кәзалик кулларын тик тотмайлар. Аларга моннан бер мәгънә хасыйл буладыр.

Инде мин сиңа тәмсил белән моны бәян кыйлаем. Мәсәлән, берәүгә бер дусты яки карендәше кунак булып, аны зыяфәт кыйлмак теләсә, ул җиргә өч таган куя. Аңар китереп казан аса. Казанга су сала, ит сала. Аннан соң, күбрәк тәм хасыйл булсын өчен, сәбез үләннән бер уч сала. Суган турый. Бөтнек сала. Аннан соң казан астына утын сала. Утынга ут җибәрә. Янсын, дип, казан астын өрә. Аннан соң ут ялкынланып яна. Ялкын һәмишә мөтәхәррик нәрсәдер. Ялкынның хәрәкәтләнүеннән казан кайный. Аннан соң казанда җай белән аш пешәдер. Әгәр казан астына ут якмаса, ялкын мөтәхәррик булмас иде. Ялкын булмаса, казан кайнамас иде. Казан кайнамаса, аш пешмәс иде. Кунак һәм тәнәгъгым кыйлмас иде. Әмма казан астына утын салып, ут якса, аш пешеп, кунагына зыяфәт буладыр. Кунак мөтәнәгъгыйм буладыр, ашыйдыр, ләззәтләнәдер, рәхәтләнәдер. Бик разый булып, дога кыйлып китәдер. Кунак

разый була зыяфәтең ләззәтле булса. Ашка ләззәт хасыйл була, аш күп нәрсәдән тәркиб кыйлынса.

Әй угыл, моннан ни фәһемләдең? Инде белгел ки, мәхлукның казаны балчыктандыр. Халыкның казаны иттәндер. Вә дәхи мәхлукның казан асар өчен ясаган таганы өч каимәле. Халыкның казаны ике каимә өстендәдер. Инде халык казаны дигәнемез — голямадыр вә вагыйзлардыр. Минбәргә чыгып, ике аяк үзрә торалар. Ике каимә дигәнемез — ике аяктыр. Ашка ит, он, суган, борыч, бөтнек, серкә мисалы — вәгазь зыяфәтенә хаҗәт нәрсәләр бар ки: зәҗер суганы, шәригать мае, ләтыйфә ите, әмсаль борычы, риваять дөгесе, хакаик бөтнеге, мәсьәлә тозы, тәфсир серкәсе. «Бәс, минбәр утынына Аллаһы Тәгалә мәгърифәт нурыннан ут салыр. Шәригать шәгъләсе белән ул ут янды. Дәкаикъ вә хакаикъ ялкыннары күтәрелде. Бәс, кодрәт казаны кызды. Мәгънәләр шурпасы кайнады. Бәс, шуның өчен, мәгърифәт уты белән кодрәт казаны кайнаганда, вагыйзлар минбәрдә тик тормайлар. Чөнки аларның хәрәкәт вә истирабы харәрәтнең хәрәкәтеннәндер вә истуанның изтыйрабыннандыр. Бәс, алар зәүкы гыйрфан васитасы белән әһле иманны зыяфәт кыйлмак өчен, мәтбах Рахман казанында дәкаикъ гыйрфан ашлары пешкәнче шөйлә булырлар. Таки раихаи шайтаннан качып, мөэминнәр әбәдән мөтәнәгъгыйм булгайлар. Бәс, мәхлукның зыяфәтендә бәдән вә рух мөтәнәгъгыйм булыр. Рахман зыяфәтендә җисемнең, рухның морады хасыйл булыр. Монафикъ диния вә дөньявия хасыйл булыр. Ләззәт рухания мөляхәзәсе белән вә әнвар рухания мөляхәзәсе белән мөтәнәгъгыйм булыр. *Вә зәккир фәиннәз зикра тәнфәгул-мөэминин* — менә вагыйзларның минбәрдә хәрәкәт вә изтирабының сер вә хикмәте ошбудыр.

---

Белгел ки, әй угыл, дәһрия таифәсе кабердә мәетнең терелмәкенә инкяр кыйлалар, мохаль эш, диләр. Вә кыямәт көнендә халаикның терелеп кабердән кубарылмакыны инкяр кыйлалар, мохальгә саялар[1]. «Тәннәр череп, туфракка катышып беткәннән соң терелмәк — мохаль», — диләр. Әгәр берәү шулай дип гөман кыйлса, бәрабәрдер ки, Аллаһы Тәгалә адәмнән гаҗизрәк, дип гөман кыйлды. Аның өчен адәмнең төрлесе бар. Ягъни балта остасы бар, тукучы бар, тегүче бар. Вә гайре һәртөрле хәрәкәт вә һөнәр ияләре бар. Нәрсәне кисәләр, ялгыйлар, вата-

---

[1] **Мохальгә саялар** — мөмкин түгел дип саныйлар.

лар-төзәтәләр, таркаталар-җыялар. Мәсәлән, тегүче. Аның бары ике коралы бар: инә дә кайчы. Кайчысы белән киемне кисә, инәсе белән янә тоташтырып тегә. Киемне сүтеп ташлый, тәмам киемлектән чыгара. Аннан соң җыеп тегә, янә бөтен кием була.

Бәс, зәгыйфь бәндәгә шөйлә теләгәнчә таркатмак-җыймак, кисмәк-тоташтырмак мөмкин булса, ул әшьяга кадир булгучы Аллаһы Тәгалә үзе теләгәнчә үтермәк вә тергезмәк, туфрак булган җисеме «каф» белән «нун» арасында җыеп, янадан тергезмәккә кадирдыр. *Куль: юхйиһәл-ләзи әншәәһә әүвәлә мәрратин.*

———

Белгел, әй угыл, әһле хак мәзһәбе[1] ошбудыр: әфгалел гыйбад Аллаһы Тәгаләнең мәхлукыдыр. Вә Аллаһы Тәгаләнең макдурыдыр. Бәс, тәдбир — бәндәдән, тәкъдир — Аллаһы Тәгаләдәндер. Карамак — бәндәдән, күрдермәк — Аллаһы Тәгаләдәндер. Сукмак — бәндәдән, авырту иҗат кыйлмак — Аллаһы Тәгаләдәндер. Ук атмак — бәндәдән; ирештермәк — Аллаһы Тәгаләдәндер. Тагать — бәндәдән, тәүфыйк Аллаһы Тәгаләдәндер. Мәгъсыять — бәндәдән, ирадә — Аллаһы Тәгаләдәндер. Ләкин Аллаһы Тәгалә мәгъсыятькә разый түгелдер. *Мүридүл хайри вәш-шәррил кабихи. Вә ләкин лә йәрза бил мүхәл.*

———

Дин-ислам бердер, мәзһәб дүрттер. Монда ни хикмәт бар? Җавап будыр ки, әй угыл, дин-ислам — бер шәһәрдер. Аның дүрт юлы бар. Бер тарафтагы юлына Әбү Хәнифә тәмәссек[2] кыйлды. Икенче тарафтагы юлына имам Әхмәд бин Хәнбәл тәмәссек кыйлды. Әмма барысының да максудлары бердер. Ул дин шәһәрендә дүрт имам җыелдылар. Дүртесенең максудлары хасыйл булды. Мәсәлән, Казан шәһәренә дүрт яктан дүрт кеше килсә, Казанда алар бер-берсе белән күрешсәләр, берсе тапкан нәрсәне икенчеләре һәм таба. Һәммәсенең максудлары хасыйл буладыр.

Инде, әй угыл, бусын белгел, мәзһәбләрдән башка тагы мәзһәбләр бар. Мәсәлән, имам Зәфәр, имам Әбү Йосыф, имам Мөхәммәд Хәсин бин Зияд, Сөфьян Сяури, Шәгъби кебек голямалар. Бәс, дин бер хәймә[3] кебектер. Бу имамнар ул хәймәнең баулары кебектер. Хәймәнең баулары никадәр күп булса, хәй-

---

[1] Мәзһәбе — юлы.
[2] Тәмәссек — биредә: шул юлдан бару.
[3] Хәймә — чатыр, палатка.

мә шулкадәр мәхкәмрәк булыр. Кәзалик мәзһәб иясе күп булса, дин мәхкәм булыр.

---

Пәйгамбәр галәйһиссәлам вакытында Ногман исемле бер фәкыйрь кеше бер иде. Аның дәхи бер изге хатыны бар иде. Иренә хезмәтче вә иренә мотыйг бер хатын иде. Иреннән ризалык ищетмәй торып, намазын да укымады. Бик фәкыйрьләр иде. Өсләренә кияргә бары икесенә бер күлмәкләре бар иде. Ире киеп намаз укыганда — хатыны ялангач, вә хатыны намаз укыганда, ире ялангач утырыр иде.

Бер җомга көн иде. Ире, күлмәкне киеп, җомгага китте. Хатыны ялангач калды. Ләкин аслан фәкыйрлекләрен вә мохтаҗлыкларын күршеләренә дә белдермәделәр. Бәс, бу хатын, ире җомгага киткәч, казан астына ут якты, гүяки аш пешерер. Таһарәт алды. Кыйблага каршы торды. Әйтте: «Илаһи, әгәр дә хәзрәтең дәргяһында аз гына дәрәҗәм булса да, ризык җәһәтеннән иремнең кайгысын китәр: күп мал бир!» — дип дога кыйлды.

Һаман догадан бушаганы юк иде, күрде: өенең төнлегеннән ике капчык алтын туп итеп төште. Дәхи ике нәфис кием төште. Хатын карады: тәрәзә янында бер кеше тора. Әйтте: «Әй хатын, боларны ал, кайгырма, сезгә ахирәттә күп нигъмәтләр бардыр, күп саваплар бардыр. Аллаһы Тәгалә каршында дәрәҗәңез бардыр», — диде. Дәхи әйтте: «Йә хатын, тор, өеңнең төнлеген селкет», — диде. Бәс, хатын, барып, төнлекне селкетте. Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән төнлектән он коела башлады. Хәтта өенең почмагы тулды. Аннан соң бу хатын торды. Камыр изде. Икмәк пешерде.

Бәс, ире җомгадан кайтып күрде: хатын яхшы кием кимеш. Казанында аш пешмеш. Икмәк хәзерләнмеш. Ире әйтте: «Болар кайдан хасыйл булды?» — диде. Хатыны тәмам вакыйганы сөйләде. Ире һәм шат булды. Бәс, һәркайчан он кирәк булса, төнлекне селкетерләр иде. Төнлектән он коелыр иде. Төнлегенә тыгып куйган бер таш бар иде.

Көннәрдән бер көн хатын торды. Ташны чыгарып алды. Бернәрсә дә юк: он да юк, ни дә юк. Бу эшкә бик гаҗәпләнеп, ире торды. Пәйгамбәр галәйһиссәламгә китте. Кыйссаны хәбәр бирде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Ант итәмен ки, әгәр хатының төнлек тишегеннән ташны чыгарып алмаса, ул төнлектән кыяматкәчә он агар иде», — диде.

Бәс, бервакытны әҗәл җитеп, хатын вафат булды. Ире хатынны кыйблага каршы куйды. Мәетне юмак өчен кеше алма-

га китте. Бер хатын алып килде. Күрде: хатыны юылмыш, кәфенгә сарылмыш. Бәс, ире хатынның йөзен ачып карады, күрде: хатынның маңгаена язылмыш ки, ир хезмәтен куймады. Бәс, Аллаһы Тәгалә каршында мәкъбульләрдән булды.

Инде, әй угыл, күрдеңме: ирен разый кыйлган хатыннарның хәлен? Аллаһы Тәгалә ул хатынны, иренә хезмәт кыйлып ирен разый кыйлган өчен, мәетен юарга да хәҗәт калдырмаган. Дәхи бер хисса будыр ки: Аллаһы Тәгалә бу хатынга бер мәхлук булгучы иренә хезмәт итеп разый кыйлган өчен, бу кәрамәтләрне гата кыйлды. Инде әгәр бер мөэмин, халык хезмәтендә булып, үзенең халкын разый кыйлса, кичә-көндез аның хезмәтендә булса, Аллаһы Тәгалә ул бәндәнең дөньяда хаҗәтен әда кыйлмасмы? Аны ахирәттә тәмугка салып, зобаниларга газап кыйлдырырмы? Бел ки, мәгъфирәт кыйлып, җәннәткә кертер, *кад әфләхәл-мөэминүнәл-ләзинә фи саләтиһим хашигун.*

———

Көннәрдән бер көн Мансур Гомәр разыйаллаһу ганһу Бәсрага барды. Күрде бер биек сарай, аның янында зур йортлар. Бер кешедән сорады: «Бу кемнең мөсафирханәседер?» — диде. Ул кеше әйтте: «Тик тор, сөйләшмә, алай дип әйтмә. Бу — Бәсра падишаһының йортыдыр. Әгәр ишетсә, башыңны кисәр», — диде. Мансур әйтте: «Әгәр падишаһны күрсәм, аның башын мин кисәр идем», — диде. Бу кеше бик ачигъланды. Барып: «Берәү шөйлә сөйләшә», — дип, падишаһка хәбәр бирде.

Бәс, падишаһ әмер кыйлды. Мансурны тотып китерделәр. Минем йортымны вә касырымны «мөсафирханә» дип, син тәсмия кыйлдыңмы?» — диде. Мансур әйтте: «Бәли, мин әйттем. Раст әйттем, ялган әйтмәдем. Белдем ки, ул йорт ошбу көн мөсафирханәдер. Син аны тәсмия кыйласың «касыр» вә «сарай» дип», — диде.

Бәс, падишаһ ул сүзнең мәгънәсенә карады, сорады вә белде ки: бу Мансур тәхкыйк әһеленнәндер. Әйтте: «Йә шәех, бу касырны ник алай дип тәсмия кыйлдың?» Падишаһ әйтте: «Атамнан мирас калды». Мансур әйтте: «Атаң кемнән алды?» Падишаһ әйтте: «Бабамнан мирас калды». Мансур әйтте: «Ул кемнән алды?» Падишаһ әйтте: «Бабамның бабасыннан мирас калды». Мансур әйтте: «Бәс, мөсафирханәдән һәм максуд шулдыр: берәү китте, берәү килде», — диде. Бәс, падишаһ бер мәртәбә «аһ!» дип кычкырды, һушы китте. Һушына килгәч, падишаһлык киемен салды. Иске кием киде вә сарайны тәрк кыйлды.

Мансур әйтте: «Берничә заманнан соң бу падишаһны Кәгъбәдә күрдем. Нәзгъ[1] хәлендә иде. Егълап, Аллаһы Тәгаләгә мөнәҗәт кыйлды. Әйтте: «Илаһи, хәзрәтеңдә бер гарипмен. Мосахибым юктыр. Малым юктыр. Малымнан-милкемнән чыгардың, мосахибларымнан аердың. Инде рәхмәтеңнән чыгарма, васыятеңнән мәхрүм куйма», — диде.

Шул хәлдә җан тәслим кыйлды. Бик егъладым. Тәҗһиз кыйлмак өчен, халыкка хәбәр итәргә киттем. Бәс, тәҗһизенә халыкны алып килдем. Карадык: мәет урынында юк, хәйран булып торганда, кабердән бер аваз килде: «Йә Мансур, бик хәйран булма. Син аны йортыннан, мөлкәтеннән аердың. Вә сараеннан чыгардың. Хәзердә мин аны җиварыма керттем», — диде. «Хәзердә ул кайда, йа Рабби?» — дидем. Аваз килде: *«Фи мәкъгади сыйдкыйн гыйндә мәликим мукътәдир»*.

Инде, әй угыл, шаять, хакаикъ кәлямне фәһемләсәң кирәк. Белгел ки, хакаикъ кәлямне бәлмәгән вә фәһемләмәгән адәм вә морадның гаксен фәһемләмәгән адәм ошбу падишаһка охшар ки, хикәяте зикер кыйлыныр.

---

Заман кадимдә бер олуг бай падишаһ бар иде. Көннәрдән бер көн бер оста алтынчыга боерды: «Минем өчен нәфис, кыйммәтле бер йөзек ясап китер», — диде. Бәс, алтынчы, бар иҗтиһадын сарыф кыйлып, ләгыль вә якуттан каш куеп, бер кыйммәтле нәфис йөзек ясап китерде. Падишаһ йөзекне алды. Падишаһларның хас мәҗлесенә бармак өчен, йөзекне бармагына китерде. Әмма йөзекне ничек итеп кияргә белмәде. Йөзекнең кашын уч табанына таба киде. Остага ачигъланды, әйтте: «Бар, ул останы алып килеңез», — диде.

Бәс, алып килделәр. Падишаһ боерды, берничә камчы суктылар. Оста егълады, кычкырды: «Әй падишаһым, мине ни гөнаһым өчен сукмага әмер кыйлдың?» — диде. Падишаһ әйтте: «Син йөзекне кире ясагансың!» — диде. Оста күрде: падишаһ йөзекне бармагына ялгыш кигән, имеш, кашы уч табанына таба торыр. Әйтте: «Әй падишаһым, бу минем гаебемнән түгелдер, бәлки әмирнең үз гаебеннәндер. Әгәр әмир хәзрәтләре йөзекне бармагында әйләндерсә, кашы кул аркасына таба торыр», — диде. Падишаһ йөзекне әйләндерде. Кашы кул аркасына таба килде. Падишаһ шат булды. Әйтте: «Бу йөзек әйләндермәкне синнән үгрәндем. Бәхил бул», — дип, остага хилгать кидерде.

Инде, әй угыл, «Җәваһирел хикәят»не укучылар гәрчә бу

[1] Нәзгъ — агония.

фәкыйрьгә либас хилгате кидермәсәнез дә, тәхсин кәлям хилгате кидермәгә саранлык кыйлмагайсыз. Ул оста йөзек кашын әйләндергән кебек, кәлямне икенче җәһәткә әйләндердем.

———

Кайчан ки пәйгамбәр галәйһиссәлам сәхабәләре белән Бәдәр сугышына чыктылар, ике гаскәр очрашты. Пәйгамбәр галәйһиссәлам гәскәреннән Гобәйдулла әл-Хабәши вә Сәгыйд бин Ваккас бар иде. Дуслар иде. Бер-беренә кувәт бирерләр иде. Бәс, иттифакан көффар гаскәре эченә керделәр вә мөшрикләрне үтерделәр. Шулкадәр сугыштылар ки, Гобәйдулланың кылычы үтмәсләнде. Бәс, күрде ки: бу кылыч эшкә ярамас. Пәйгамбәр галәйһиссәлам янына килде. Әйтте: «Йә Рәсүлуллаһ, бу мөшрикләр белән мокабәлә кыйлмага ният иткән идем, кылычым үтмәсләнде», — диде.

Бәс, пәйгамбәр галәйһиссәлам аңа хөрмә ботагы бирде. Пәйгамбәр галәйһиссәламнең кулында бер хөрмә ботагы бар иде. Мәккәдән алмыш иде, камчы урынына истигъмаль кыйлыр иде. Гобәйдуллага әйтте: «Бар, бу шәмрах белән сугыш! Аллаһы Тәгаләдән өмид итәмен ки, иншаллаһ, бу хөрмә ботагы Аллаһы Тәгаләнең изене белән кылычтан үткенрәк булгай», — диде. Бәс, Гобәйдулла яшен кебек кяфер гаскәренә атылды. Хөрмә ботагы, Гобәйдулла һәрбер селтәнгәндә, икешәр йөз мөшрик башын кисәр иде. *Вә әннә җүндәнә ләһүмүл галибүн*. Бәс, кяферләр мөнһәзим булдылар, башлары киселде. Мөэминнәр хәлас булдылар, хөрмә ботагы сәбәпле.

Инде, әй угыл, аның өммәтләре кыямәт көнендә, җирне, күкне вә Мәккәне яраткучыдан алган хөрмә ботагы — шәфәгать сәбәпле гөнаһларыннан хәлас булсалар, һич гаҗәп булмас. *Вәләсәүфә югътыйкә Раббүкә фә тәрза*.

Аннан соң Гобәйдулла вә Сәгыйд Ваккас арыдылар. Бераз ял итү өчен бер якка таба чыктылар. Сәгыйд әйтте: «Йә Гобәйдулла, мин бу сәгать Аллаһы Тәгаләдән бер хаҗәтемне телимен, дога кыйламын. Чөнки хәзер дога кабул була торган вакыттыр. Миңа ярдәм кыйл: «Амин!» дип әйт», — диде. Аннан соң син хаҗәтеңне сора, дога кыйл. Мин сиңа ярдәм кыйлаем: «Амин!» дип әйтәем», — диде. Бәс, кулын күтәрде, әйтте: «Илаһи, ошбу кяферләр гаскәре эчендә булган бәһадир-мөбаризләргә мине мосалләт кыйл. Илаһи, кувәт вә носрәт бир, таки башларын кисәем!» — диде. Гобәйдулла: «Амин!» — дип торды. Моннан соң Гобәйдулла кулын күтәрде, әйтте: «Илаһи, ошбу кяферләр гаскәре эчендә булган кувәтле мөбаризләрне вә баталәне миңа мосалләт кыйл. Таки башымны киссеннәр.

Илаһи, ул кяферләрнең күңеленә сал: борынымны, колагымны, иренемне, телемне, аягымны киссеннәр — динең юлында әгъзамны турасыннар!» — диде. Сәгыйд: «Амин!» — дип торды.

Риваятьләрдә килмештер: кайчан кем кыямәт көне булса, Гарасат мәйданына халык җыелган вакытта, Гобәйдулланы китерерләр: гүяки бер ит кисәге кебек, колаксыз, кулсыз, аяксыз, телсез. Аллаһы Тәгалә тарафыннан бер мөнади нида кыйлыр: «Йә Гобәйдулла, кулларың кайда? Аякларың кайда? Борының кайда? Колакларың кайда? Телең кайда?» Гобәйдулла әйтер: «Илаһи, синең ризалыгың өчен әгъзамны дошманнарга бирдем». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Әгәр син минем ризалыгым өчен әгъзаңны дошманнарга биргән булсаң, бүген сиңа шәфәгатьне бирдем: үзең теләгән гасыйларга шәфәгать кыйл, үзең теләгән гасыйларны сиңа һибә кыйлдым. *Ликулли шәһидин-шәфәгатун яумәл кыямәти галә мә йүрид*». Кайчан ки Сәгыйд Ваккас вә Гобәйдулла Аллаһы Тәгаләгә дога кыйлдылар, шул сәгатьтә Аллаһы Тәгалә аларның догасын кабул итте, сораганнарын бирде. *Сәвабу газүә вә шәһәдәттер.*

Инде, әй угыл, безнең хәлемез һәм Сәгыйд Ваккас вә Гобәйдулла хәленә охшар. Тәхкыйк халаик гаскәреннән чыктык. Мәсҗеткә җыелдык. Аллаһы Тәгалә белән хәлвәттә булдык. Сәгыйд белән Гобәйдулла сахрада иделәр. Без хәзердә Аллаһы Тәгалә өендәмездер. Вә алар газа савабында иделәр. Без дәхи хәзер дә ничә төрле саваптамызлар. Мәсәлән, хәзер гыйбадәт савабы, истимаг гыйлем савабы, кыйраәт Коръән савабы, сөаль-җавап савабы, намаз савабы, руза савабы, садака савабы, зәкят савабы. Инде хәзер дога кыйла торган вакыттыр. Вә дога кабул вакытыдыр. «Амин!» дип, миңа могыйн буласыз. Аллаһы Тәгаләгә дога кыйлаек, Аллаһы Тәгаләдән хаҗәтемезне беләек. Шаять ки, Аллаһы Тәгалә һәркайсымызны ярлыкар. Шаять ки, Аллаһы Тәгалә догамызны кабул кыйлыр. *Үҗиб дәгъвәтәд-дагый изә дәган,* дип вәгъдә кыйлды.

Инде, әй угыл, янә сүземезгә кайттык. Аннан соң Сәгыйд вә Гобәйдулла мәгъръкәгә килделәр. Кяферләр арасына керделәр. Сәгыйд, бер тарафтан яу авазын салып, мөшрикләрне кырды. Кяферләр мөнһәзим булды. Гобәйдулла дәхи үз тарафыннан кяферләргә һөҗүм итте. 300 кяфернең башын кисте. Ахыр мөшрикләрнең Назар бин әл-Харис дигән бер пәһлеван белән сугышып, ул пәһлеван Гобәйдулланың башын кисте. Гобәйдулла атыннан егылып, шәһид булды.

Назар күңеленнән әйтте: «Шөкер, бу кеше безнең 350 кешемезне үтергән иде, моннан яхшырак интикам алаем», — дип,

атыннан төште. Гобәйдулланың колагын, борынын, телен, әгъзаларын кисте. Башын падишаһка алып барды, әйтте: «Әййүһәл мәлик, бу баш — мөселманнарның иң пәһлеваннарының башыдыр», — диде. Падишаһ Назарга хилгать кидерде. Әмма ул Назар падишаһ каршында үзе газиз вә хөрмәтле булган өчен түгелдер ки, хилгать киде, ләкин Гобәйдулла башының кәрамәте вә хөрмәте өчендер. Чөнки ул Назар Гобәйдулла башын кисмәгән булса, падишаһ аңа хилгать бирмәс иде.

Бәс, кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә Гобәйдуллага шәһадәт хилгате кидереп, гасыйларга шәфәгать кыйлса, һич гаҗәп юк. *Ликаулиһи галәйһиссәлам: «Әш-шуһәдәәү хавәссуль-лаһи Тәгалә».* Назар бин әл-Харис, падишаһ хилгать кидергәннән соң, падишаһ алдында мактанды. Әйтте, әййүһәл мәлик, инде кара, мөселманнар гаскәрен кырып бетерәем, дип. Үзен гаскәр арасына атты, мөселман гаскәренә һөҗүм итте. Бәс, аңа хәзрәти Гали мокабил булып, зөлфекар белән башын кисеп төшерде. Кяфер гаскәре мөнһәзим булып, ислам гаскәре носрәт тапты. *Вә янсуракәллаһу нәсъран газизән.*

---

Пәйгамбәр галәйһиссәлам заманында Җәмилә исемле бер хатын бар иде. Аның ике углы бар иде. Берәнең исеме — Харис вә берәнең исеме Мөхәммәд иде. Аталары Хатиб исемле иде, вафат булды. Бу хатын мөслимә, вә заһидә, вә габидә хатын иде. Бервакытны пәйгамбәр галәйһиссәламнән ишетте ки, дингә төзеклек вә салахият булмаган җирдә тормак җаиз түгелдер. Бәс, бу хатын дин мәслихәте өчен үзенең ике углы белән Хәбәш җиренә сәфәр кыйлды. Ул вакытта Мәккәдә кяферләр галиб иде. Мөселманнар аз иде. Кяферләрнең бер-бер төрле мәкерләре тимәсен дип, Хәбәш җиренә күчте.

Ишеттеңме, әй угыл? Ул заманада Җәмилә исемле салиха вә заһидә хатын бар, имеш. Исеме хатыннар исеме шикелле, әмма фигыле ирләр фигыле шикелледер. Инде без калдык шундаен заманада ки, ирләре — хатыннар шикелле, бәлки, хатыннардан да хабисрәк. Чөнки фигыльләре хатыннар фигыледер. Зиннәт дөньяны сөяләр. Ашамак-эчмәк, уйнамак-көлмәкне яратырлар. Вә явызлар белән сохбәт кыйлмакны яраталар. Үзләрендә ирләр фигыле, ирләр хамияте вә ирләр гайрәте юк.

Хатыннарында — тамаша вә сәйран;
Үзләре бичаралар, гаҗиз вә хәйран.

Ул Җәмилә хатын ике углы белән Хәбәш җиренә киттеләр. Балалары ул вакытта берсе — имчәк баласы, берсе им-

чәктән аерылган иде. Бу хатын Хәбәш җиредә ике баласы белән биш ел торды. Ахыр Хәбәш җирендә олуг ачлык вакыйг булды.

Бәс, Җәмилә ике баласын алды да Мәдинәгә газимәт кыйлды. Юлда бер гарәп җәмәгатенә очрады. Бу хатын алардан тәгам сорады. Аңа бер гарәп бер кисәк тәвә ите бирде. Әмма болар ул итне пешерергә вәҗһен тапмаенча, ул көн янә ач киттеләр. Мәдинәгә якын бер мәнзилгә туктадылар. Җәмилә, таган ясап, казан асты. Ике углы коры-сары утын җыйдылар. Казан астына ут яктылар. Итләре казанда кайный башлады, утыннары бетеп китте. Итләре пешеп җитмәде. Аналары әйтте: «Әй Харис, әйдә, син минем белән утын җыярга. Мөхәммәд, кечкенә кеше, казан янында калсын, ял итсен. Ул кечкенә кеше, юлда да миңа күп хезмәт кыйлды. Таһарәткә су алып килде», — диде. Әмма Мөхәммәд әйтмәде ки: «Әй ана, син кая? Казан янында ял ит. Без Харис белән утын җыеп киләек», — димәде, шул сүзләр белән анасын хөрмәт кыйла белмәде. Мосибәткә иреште.

Бәс, Җәмилә хатын Харис исемле углы белән утынга китте. Мөхәммәд күңеленнән әйтте: «Тукта, алар килгәнче, бу казандагы итне ашаем, азрак карынымны туйдыраем», — дип, казан янына килде. Казанны күтәреп алмага касд кыйлды, көче җитмәде. Казан янтаеп китте. Соң кулына кайнаган шулпа коелды, кулы пеште, һушсыз булып егылды.

Бәс, әй угыл, атаң-анаң хөрмәтен саклый күр. Күрмәйсеңме, бер кечкенә бала анасының хөрмәтен тәрк кыйлды. Соң кулы пеште. Әгәр дә балигъ вә гакыйль булып, ата-ана хөрмәтен куйсаң, никадәр куркынычлар бардыр. Ул бала кечкенә, сабый бала иде. Ана хөрмәтен ригая кыйлмады. Дөнья утына пеште. Балигъ булып ата-ананы ригая кыйлмасаң, җәһәннәм утына пешәрсең. Вә хәлял нәрсәне анадан яшереп ашаганың өчен, җәһәннәм утына төшәрсең. Әмма харамнан вә шәрабтан атаңа күрсәтмәен яшереп эчсәң, мәңге тәмуглыксың.

Аннан соң анасы углының *«вә уммәһ»* дип егълаганын ишетте. Төсе үзгәрде. Ашыгып, егълап йөгереп кайтты. Күрде: кечкенә углы һушы китеп егълап ята. Бер кулы пешкән. Казан аунап ята. Йөзен йөзгә куеп егълады. Харис һәм утын җыеп кайтып килде. Күрде: анасы белән кечкенә энесе егълап утырлар. Бу Харис, дәхи аларны күргәч: *«Ва ахәһ, ва әмах, ва хасрәта!»* — дип кычкырып егълады.

Әй ошбу «Җәваһир»не укучылар! Атадан-анадан аерылганнарыңыз бардыр, балаларыңыздан аерылганнарыңыз бардыр, ка-

рендәшләреңездән аерылганыңыз бардыр, җәмәгатеңездән вә әһелеңездән аерылганнарыңыз бардыр, вә дусларыңыздан аерылганнарыгыз бардыр, вә мал-милкеңездән аерылганнарыңыз бардыр; авыру белән мөбтәля булганнарыңыз бардыр, михнәт белән мөбтәля булганнарыңыз бардыр, җинаять гөнаһысы сәбәпле хуҗаларыныз ишегеннән аерылганнарыңыз бардыр, Аллаһы Тәгаләгә вә Рәсүленә гөнаһлы булганнарыңыз бардыр. Бәли, һәркайсыларыңыз — гасыйларсыз, хата кыйлгучыларсыз! Дөнья михнәте, дөнья горбәте бер көнлектер! Килеңез, кыямәт сәфәрендә булачак горбәтләреңез өчен егълашаек. Гөнаһларымыздан тәүбә кыйлаек вә истигъфар кыйлаек. Әй тәмам гасый! Ни үкенечтер сиңа! Әй зани гасый, ни үкенечтер сиңа! Әй угыры гасый, ни үкенечтер сиңа! Әй ялганчы гасый, ни үкенечтер сиңа! Әй залим гасый, ни үкенечтер сиңа! Әй мөхтәкир[1] гасый, ни үкенечтер сиңа! Әй хәмер эчкүчеләр, ни үкенечтер сезгә! Аллаһыны исеңезгә төшермәйсез, гүяки үзеңездән үзеңез бар ителмешсез! Үлемне искә төшермәйсез, гүяки дөньяга мәңгегә килмешсез! Аллаһы Тәгаләнең газабын вә гыйкабен исеңезгә төшермәйсез, гүяки сыйрат күперен кичмешсез? Вагыйзларның вәгазен ишетмәйсез, гүя гөман кыйлайсыз ки, алар сезгә ялган әйтә. Бу эшләреңездән кайтыңыз! Тәүбә кыйлыңыз! Вагыйзлар сүзен ишетеңез.

Моннан соң ул Җәмиләнең углы Харис күп егълады. Анасы әйтте: «Йә Харис, ашымыз да әрәм булды. Мөхәммәднең дә кулы пеште. Инде кайсы табибка бараек? Ни дару итәек? Пәйгамбәрдән башка кем безнең табибымыз бар? Дин дәвасын Аллаһы Тәгалә безгә андан рузи кыйлды. Җисем сихәтлеген дәхи Аллаһы Тәгалә аннан чыгарса кадир», — дип, углы Мөхәммәдне күтәреп, Харисны иярте, пәйгамбәр галәйһиссәламгә китте.

Үзенең хәленнән вә балаларының хәленнән хәбәр бирде, әйтте: «Йә Рәсүлуллаһ, углым Мөхәммәднең кулына бер дәваң юкмы?» — диде. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: «Бер сәгать сабыр кыйл: Җәбраил дустым килсен», — диде. Бәс, шул хәлдә Җәбраил инде, әйтте: «Йә Мөхәммәд, Аллаһы Тәгалә сиңа сәлам укыды, әйтте ки, Гайсә миңа дога кыйлды, Әбрасны вә Әкмане сихәтләндерде. Йә Мөхәммәд, син Гайсәдән әфзальсең. Ул сабыйның кулына мөбарәк нәфәсеңне[2] өр, сәламәтләнер», — диде.

Бәс, пәйгамбәр галәйһиссәлам ул баланың кулына мөбарәк нәфәсе белән өрде. Баланың кулы сихәтләнде.

---

[1] Мөхтәкир — спекулянт.
[2] Нәфәсеңне — сулышыңны.

Инде, әй угыл, бәшарәт безгәдер ки, пәйгамбәр галәйһиссәламнең мөбарәк нәфәсе белән дөнья утында пешкән куллар сихәтләнә — авырулар сихәт таба. Бәс, өмид итәек ки, кыямәт көнендә аның шәфагать нәфәсе белән гөнаһ җәрәхәтләремез, шаять, шифа тапкай.

---

Имам Мөхәммәд бин әл-Хәсән разыйаллаһу ганһу «Җәмигъ әс-сәгыйр» китабын тасниф кыйлды. Беркөнне тәсбих кыйлып, форуг мәсаилне төзәтеп утырганда, якында дивар өстенә бер карга утырды, кабахәт аваз белән кычкырды. Имам Мөхәммәдкә тәшвиш бирде. Имам Мөхәммәд карганың хәлен кабахәткә саеп, дога кыйлды. Әйтте: «Аллаһы Тәгалә башыңны кискәй», — диде.

Шул сәгать карганың башы киселде. Инде, әй угыл, зиядә саклан голяма догасыннан. Голяманы рәнҗетмә, дошман тотма. Гайбәткә төшмә. *«Лухумул голәмәэи мәсмумә»*, — диде пәйгамбәр галәйһиссәлам.

Имам Мөхәммәд кайчан ки «Җәмигъ әс-сәгыйр» китабын тасниф кыйлып бетерде, олуг мәҗлес хәзерләп, күп голяманы җыеп, «Җәмигъ әс-сәгыйр» китабын күрсәтте. Ул мәҗлестә бер галим мөшрик бар иде, китапны алды, моталәга кыйлып карады. Гыйбарәтләрен, ләфызларын вә мәгънәләрен фикер кыйлды, әйтте: «Бу китап — Мөхәммәд сәгыйр таснифымы, Мөхәммәдел кәбир таснифымы?» — диде. «Мөхәммәд сәгыйр таснифы», — диделәр. Мөшрик әйтте: «Аллаһу әкбәр. Бу — Мөхәммәд сәгыйрь кәрамәте, имеш. Мөхәммәдел кәбир кәрамәте ни дәрәҗәдә булмак кирәк? *Әшһәдән ля Илаһа иллаллаһ»*, — дип, мөселман булды.

Инде, әй угыл, Мөхәммәд бин әл-Хәсән тасниф кыйлган китапны күргәч, бер мөшрик иман белән мөшәррәф булды. Бәс, вагыйзлар вә галимнәр мәҗлесендә Кәламуллаһның тәфсирен ишетеп мәгънәсе белән вә хадис мәгънәсе белән гамәл кыйлганнар тәмуг утыннан хәлас булсалар, бер дә гаҗәп түгелдер. *Вә зәккир, фәиннәз зикра тәнфәгул-мөэминин.* Белгел ки, әй угыл, шәригатьтә бер мәсьәлә бардыр ки: әгәр бер бай кеше вафат булып, тәрәкә малын[1] кыйсмәттән мөкаддәм варисларның берсе үзенең өлешен сатса, җаизмы, түгелме? Имам Мөхәммәд: «Җаиз», — диде. Әбү Йосыф: «Бу бәйгъ — фәсад»[2], — диде. Имам Әгъзам әйтте: «Әгәр бу мөбәййәгъне баигъ һәм

---

[1] Тәрәкә малын — мирас булып калган малын.
[2] Фәсад — бозык эш.

белмәсә, мөштәри һәм белмәсә, ягъни сатылмыш нәрсә — ни-нәрсә вә никадәр икәнен сатучы да белмәсә, сатып алучы да белмәсә, җаиз түгелдер. Бәс, саткан кеше — ни-нәрсә сата, алган кеше ни-нәрсә ала, тәгаен белмәк кирәктер», — диде.

Инде, әй угыл, бу мәсьәлә алтын-көмешкә сатыла торган нәрсәләр хакындадыр, бәйгъ җаиз түгелдер: таки баигъ вә мөштәри тәгаен белсеннәр. Әмма әгәр намаз укучы намазның сәмәне ни-нәрсәдер, аны белмәсә, ике рәкәгать намазны, дүрт рәкәгать намазны сатмак ничек җаиз булыр? Вә халән ки, боларның сәмәне җәннәт вә мәгърифәт иде. Ягъни намазны ни өчен укый, аны белмәсә, әүвәлге рәкәгатьтә ни укыды, икенче рәкәгатьтә ни укыды, аны белмәсә, узган көн ни эшләде вә ни гамәл кыйлды, аны белмәсә, намаздан соң дога укыды.

Аллаһы Тәгаләдән ни сорады, белмәсә, вә үзе ни өчен халк ителде, аны белмәсә, ахирәттә шиксез, аның мәскәне тәмугтыр. Каулүһү Тәгалә: *«Мә сәләкәкум фи сәкари калу ләм нәкум минәл мөсаллин,* ягъни *ләм нәкум фис саләти мәгаль хушугый вәл иркән»*.

Әй угыл, яхшы фәһем кыйл: бу сүзләр җөзьи ифа ителмидер. Дәхи белгел ки, әй угыл, галим кешегә гыйлеме белән гамәл кыйлмак ваҗибтыр. Үзе гамәл кыйлмаганны кешегә бирмак тиеш түгелдер. Чөнки үзе гамәл кыйлмаса, кешегә боерса, ул вәгазьнең кешегә тәэсире булмас. Үзе дә гамәл кыйлса, кешегә дә боерса, әсәрлерәк вәгазь ошбудыр.

Нитәкки хикәят кыйлынды. Хәсән Бәсри заманында бер мөнәгъгыйм бай кеше бар иде. Аның бер кызы бар иде, һәркөн хөрмә ашар иде. Хәтта ул кызга күз авыруы пәйда булды. Атасы-анасы нәсыйхәт кыйлдылар: «Күп хөрмә ашама, күзеңә зарары тияр», — диделәр. Кыз аларның сүзен колакка алмады: «Сезнең сүзеңез белән хөрмә ашаудан тыелмам. Ләкин заманабызның имамы Хәсән Бәсри әйтсә, ашамам», — диде. Бәс, ул кызны Хәсән Бәсрига алып бардылар, әйттеләр: «Йә шәех, бу кызга бераз нәсыйхәт кыйлсаңыз ла: хөрмә ашамасын, күзенә зарар итәдер», — диделәр. Шәех әйтте: «Бүген кайтып торыңыз, иртәгә киленеңез, иртәгә нәсыйхәт кыйлырмын», — диде.

Киттеләр. Иртәгесен килделәр. Шәех әйтте: «Сиңа ваҗибтыр, әй кызым, минем сүземне вә нәсыйхәтемне тыңлап, хөрмә ашаудан тыелгайсың. Бер айга кадәр хөрмә ашама, күзең сихәтләнер», — диде. Кыз әйтте: «Сәмган вә тагатән, йә шәех, сүзеңне кабул кыйлдым», — диде. Кызның атасы әйтте: «Йә имамын-мөслимин, ни гаҗәп: кичә нәсыйхәт кыйлмадыңыз?» — диде. Шәех әйтте: «Кичә мин үзем хөрмә ашаган идем, шул

сәбәпле кызыңызга, хөрмә ашама, димәкне мөстәхсән күрмәдем. Бүген хөрмә ашаганым юк. Кызыңа хөрмә ашама, дип мәныг кыйлдым, таки тәэсир кыйлсын өчен», — диде.

Бәс, әй угыл, галим булган кеше үзенең гыйлеме белән гамәл кыйлмаса, гайрегә ул гамәлне боермамык важибтыр. Мәсәлән, үзең намаз укымасаң, гайре кешегә укы, дип боерсаң, тәэсир итмәс. Башка гамәлләрне моңар кыяс кыйл. Бәс, күрдеңме, әй угыл, Хәсән Бәсрилар заманында имамнарны вә галимнәрне ихтирам кыйлгучы кыз-хатыннар һәм бар иде. Голяма сүзе белән гамәл кыйлгучы хатын-кыз һәм бар иде. Хәтта галимнәр сүзе белән хәлял хөрмәне ашаудан да тыелдылар. Халән, без калдык шундаен заманага ки, ирләре хәтта Кәлимуллаһны да ихтирам кыйлмадылар. Голяма сүзен ишетеп, голяма кауле белән сарыф харамнан да тыелмыйлар. Галимнәр сүзен бер ләгу сүзгә[1] саялар. Гүя ки галимнәр үз файдаларына әйтәләр лә! Бу сәбәпле үз нәфселәренә залимлык кыйлалар. Һичшиксез, кыямәт көне булса, Аллаһы Тәгалә бу фигыльләре сәбәпле аларны могакыйб кыйлса кирәк. *Вә мәй ятәгаддә худүдәл-лаһи фәкад заләмә нәфсәһ.* Инде заманамызда галимнәремез һәм гавам эшендәдер. Таки бер нәкъзь-л-кавел галим зоһур итмәсә, зәляләттә калдык. Әй угыл, гыйлеме белән гамәл кыйлгучы галимнәрнең Аллаһы Тәгалә каршында хөрмәте бик олугдыр. *Вәлләзинә утүл-гыйльмә дәраҗәт.* Бәс, гыйлеме белән гамәл кыйлгучы галимнәрнең гыйлеме вә галимнәр сүзе белән гамәл кыйлгучы фәкыйрьләрнең догасы — кыямәттә гасыйларны уттан хәлас кыйлгучы нәрсәләрдер.

---

Әй угыл, җефетләнергә теләсәң, шундаен хатынны җефетлә ки, дин әһеле кулында тәрбияләнгән булсын. Вә әһеле салах, әһеле тәкъва тәрбиясендә торган булсын. Аның өчен хатыннар үзенең нәсәбеннән вә җенесеннән күргән белән тәхәррек кыйлырлар. Тәрбия әһеленнән күреп гадәтләнгән эшне тотарлар. Әүвәл башта тәрбия белән үскән кыз булмаса, син аны тәрбиягә кертермен димә. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: *«Мән тәзәүвәҗә би имраъәтин салихәтин фәкад әхразә нисъфә диниһи».*

Элгәреге замандагы мөселманнар һәммәсе диннең төзеклегенә иҗтиһад кыйлдылар. Дин вә дөньяның төзеклеге хатыннардандыр, бозыклыгы һәм хатыннардандыр. *Әз зәуҗәтус-салихәтү хайрум минәд дөнья вә мә фиһә* — хәдистер.

---

[1] Л ә г у с ү з г ә — юк сүз, чүп-чарга.

Сөләйман галәйһиссәлам заманында хөсен вә җәмал иясе бер егет бар иде. Көннәрдән бер көн бу егет Сөләйманга килде, хезмәтенә торды. Сөләйман галәйһиссәлам, бу егетне күреп, аның хөсненә вә җәмалына тәгаҗҗеб кыйлды: «Сөбханаллаһи, бәндәләрнең арасында бер катрә нотфәдән шөйлә җәмал иясе вә күркәм егет яратмышсың!» — дип, ул егетнең хөсен вә җәмалын фикерләп торганда, Газраил килде. Әйтте: «Йә Рәсүлуллаһ, бу егеткә әйт ки: ул егетнең бары өч көн гомере калды», — диде.

Бәс, Сөләйман галәйһиссәлам бу сүздән бик хафа булды. Кайгырды. Егълады. Кауме әйтте: «Йә Рәсүлуллаһ, ник бу кадәр егъладың?» — диделәр. Сөләйман галәйһиссәлам әйтте: «Барыңыз, шул җәмал иясе егетне алып килеңез, егъламакымның сәбәбен шунда белдерермен», — диде. Бәс, егетне Сөләйман галәйһиссәлам хозурына алып килделәр. Сөләйман галәйһиссәлам әйтте: «Әй егет, үлемгә хәзер бул. Газраил миңа бу сәгать хәбәр бирде ки, гомерең өч көндер, артык калмагандыр», — диде.

Кайчан ки ул егет Сөләйман галәйһиссәламнән бу хәбәрне ишетте, сихә кыйлды вә каты егълады. Вә әйтте: «Сә гарәбәт, аһ, үлемгә ничек такать тотаем?! Аһ, кайда бараем?! Ва әмаһ, сине кайдан табаем, вафатымнан соң мине тәҗһиз кыйлыр идең! Ваһ аху, аһ, сезне кайдан табаем, җеназам артыннан егълап калыр идеңез! Ва әсхаб, аһ, сезне кайдан табаем, җеназамны күтәреп барыр идеңез. Ва әкърибаһат, сезне кайдан табаем, җеназама ияреп барыр идеңез!» — дип үкереп егълады. Хәтта Сөләйман галәйһиссәлам гаскәре вә кауме — барчасы тәфәҗҗегъ кыйлдылар.

Шул хәлдә Сөләйман галәйһиссәламгә ике кош очып килде. Әйттеләр: «Йә Сөләйман, безгә изен биргел: таки бу егет белән бергә егълашаек. Безләр һәм мәҗрухел калебләрмез», — диделәр. Берсе әйтте: «Минем балам бар иде. Оядан егылып төште. Канаты сынды. Үлде. Фиракына такать тотар хәлем юк», — диде. Ул егетнең егълавына вә кош егълавына адәмиләр, җеннәр, кошлар егълаштылар. Инде, әй угыл, мәҗлес әһеле бармы сезнең араңыздан, горбәт әһеле вә мәҗрухел калеб булган адәм? Килеңез, үземезнең өчен вә нәфсемез өчен егълашаек. Чөнки һичбер чара юк ки, әлбәттә, үлсәк кирәк, әһле әүладтан, карендәшләрдән вә дуслардан аерылсак кирәк. Ялгыз баш кабергә керсәк кирәк.

Моннан соң егет Сөләйман галәйһиссәлам алдында йөзен җиргә куйды. Әйтте: «Йә Рәсүлуллаһ, минем атам бар, анам бар, җәмәгатем бар. Алар моннан бер айлык мәсафәдә тора-

лар. Хәлбуки минем гомерем бары өч көн калган, имеш. Миңа ни мәслихәт, таки мин аларны күреп, үлемем алар янында булса иде», — диде. Сөләйман галәйһиссәлам әйтте: «Минем «Гудувүһә шәһр» вә «Рауәхүһә шәһр» исемле җилләрем бар. Әмер кыйлаем: таки бер айлык мәсафәне бер көндә катыг кыйлырлар, әһел-әүладыңа ирештерерләр», — диде. Сөләйман галәйһиссәлам җилгә әмер кыйлды: бу егет җилнең җилкәсенә менеп утырды. Җил күтәреп китте. Бер көндә егетнең атасы-анасы янына җитте. Бу егет атасын-анасын күрде. Аякларына егылды, еглады: «Инде миннән бәхил булыңыз, разый булыңыз. Ике көннән соң сез мине күрмәссез, мин сезне күрмәмен. Тәхкыйк, үлем карибтер», — диде. Сөләйман галәйһиссәлам алдында булган мажараны хәбәр бирде. Аннан соң өченче көндә бу егет җан тәслим кыйлды. Анасы һушсыз булганча еглады. Карендәшләре вә дуслары якаларын ертып егладылар. Мин бәгъдә дәфен кыйлдылар.

Инде, әй угыл, ул егет әҗәле җиткәнен белеп, Сөләйман галәйһиссәламгә илтиҗа кыйлды. Сөләйман галәйһиссәлам аны җил белән атасы-анасы янына күндерде. Инде бу дөнья горбәтендә Аллаһы Тәгаләдән башка без кемгә илтиҗа кыйлаек? Шаять ки, Аллаһы Тәгалә дөнья вә ахирәт хаҗәтләремезне әда кыйлгай. Амин!

---

Корәешнең олуглары, даре нәдвәгә җыелып, пәйгамбәр галәйһиссәлам хакында мәшвәрәт кыйлдылар: ни мәслихәт вә ни хәйлә кирәк, Мөхәммәднең кулыннан хәлас булмак өчен? «Чөнки ул Мөхәммәд безнең аталарымызның вә бабаларымызның динен бозмакка касд кыйладыр», — диделәр. Әбүҗаһил әйтте: «Миңа бер җомга мөһләт бирегез. Мин бер хәйлә кыйлаем ки, бу хәйлә белән ул сахирны һәлак кыйлып, аннан хәлас булырмыз», — диде. Бер җомга узгач, Әбүҗаһил әйтте: «Минем фикерем шуңар карар тапты: мәсҗет ишеге төбенә тирән чокыр казып, өстен хөрмә чүбе белән каплап куяек. Мөхәммәднең гадәте шулдыр: төнлә мәсҗеткә килеп, намаз укыр. Мәсҗеткә килгәндә чокырга төшәр. Ул төшкәч, мин сезгә хәбәр бирермен. Килеп үтерерсез», — диде.

Бәс, Әбүҗаһил мәсҗет төбенә чокыр казыды. Өстен, бер хәйлә кыйлып, чытыр-чатыр белән каплады. Кич булды. Пәйгамбәр галәйһиссәлам мәсҗеткә бармага касд кыйлды. Дәрхаль Җәбраил галәйһиссәлам инде әйтте: «Йә Мөхәммәд, Аллаһы Тәгалә сиңа сәлам укыды. Әйтте, Әбүҗаһил бер эш тәдбир кыйлды. Мәсҗет төбендә, Мөхәммәд төшсен, дип, чокыр

казыды. Кайчан мәсҗет төбенә җитсәң, әйт: *вә әфәүвиду әмри иләллаhи иннәллаhә бәсыйрум бил гыйбәд*».

Бәс, пәйгамбәр галәйhиссәлам мәсҗеткә барып җитте. «*Вә әфәүвиду әмри иләллаhи*», — диде. Аллаhы Тәгаләнең изене белән чокыр өсте мәхкәм булды. Пәйгамбәр галәйhиссәлам узып китте. Мәсҗеткә керде. Бәс, Әбүҗаhил көн-төн көтте. Берничә көннәр үтте. Әбүҗаhилнең моряды булмады. Торды: «Ни булды икән?» — дип, тәфәххес кыйлмага, мәсҗеткә килде. Чокыр әсәре hич күрмәде. «Бу чокырга ни булды?» — дип, тәҗрибә өчен басып карады. Аллаhы Тәгаләнең әмере белән чокыр җимерелде. Әбүҗаhил үзе казыган чокырга төште. Моны пәйгамбәр галәйhиссәлам ишетте: «*Мән хафәра биәран ли әхыйhи вәкагә фиhи*», — диде. «Кешегә дип казыган чокырга үзең төшәрсең» дигән мәкаль моннан калмыштыр.

Бәс, анда Әбүҗаhилгә бау җибәрделәр, бау җитмәде. Икенче бау ялгадылар. Җитмәде. Өченче бау, дүртенче бау ялгадылар. Җитмәде. Җитмешкә чаклы бау ялгадылар. Җитмәде. Бау җибәргән саен, түбән китте. Әбүҗаhил кычкыра башлады. Әйтте: «Зинhар, Мөхәммәдтән илтимас кыйлыңыз. Шаять ки, ул чыгарыр. Бу җәмәгатьтән берәү дә мине чыгара алмас», — диде.

Кяферләр, җыелып, пәйгамбәр галәйhиссәламгә килделәр. «Әбүҗаhилне чыгар!» — дип илтимас кыйлдылар. Пәйгамбәр галәйhиссәлам әйтте: «Мин дошманымны коедан ник чыгарыйм?» — диде. Бәс, кяферләр Әбүҗаhилдән өмид кистеләр. Дәрхаль Җәбраил галәйhиссәлам инде. Әйтте: «Йә Мөхәммәд, Аллаhы Тәгалә сиңа сәлам укыды, әйтте, баргыл, Әбүҗаhилне коедан чыгаргыл», — диде. Пәйгамбәр галәйhиссәлам әйтте: «Йә Җәбраил — Әбүҗаhил — гадве Аллаhтыр. Аны чыгар, димәктә ни хикмәт бардыр?» Җәбраил галәйhиссәлам әйтте: «Йә Мөхәммәд, бу эштә сиңа бәшарәт бардыр: синең гасый өммәтләрең таки белсеннәр: Әбүҗаhил кяфер була торып, Аллаhы Тәгалә аны чокырда калдырмады. Чыгарды — хәлас кыйлды. Кыямәт көнендә өммәтләреңне тәмугта нитәк калдырсын?! Калдырмас. Бәлки, син, шәфәгать кыйлып, тәмугтан хәлас кыйлырсың, җәннәткә алып керерсең». Пәйгамбәр галәйhиссәлам әйтте: «*Шәфәгати ли әhлил кәбаир мин үммәти*». Аннан соң пәйгамбәр галәйhиссәлам чокыр янына килде, кулын сузды. Шулкадәр тирән чокырдан Әбүҗаhилне тартып чыгарды. Җитмеш бау җитмәс иде. Аннан соң пәйгамбәр галәйhиссәлам Әбүҗаhилгә әйтте: «*Әшhәдү ән лә Иләhү иллаллаhә,* дип иман китер, кяфер», — диде. Әбүҗаhил, hаман көферендә мокыйр булып: «*hәзә сихрум мүстәмирр*», — диде.

Инде белгел ки, әй угыл, Аллаһы Тәгалә бер бәндәгә тәүфыйк бирмәсә, иманга да мөстәхак булмайдыр.

———

Солтан Мәхмүд Газнәвинең гадәтеннән: гаепле вә гөнаһлы кешегә исемен сорамаенча җәза бирмәс иде. Көннәрдән бер көн бер угрыны тотып китерделәр. Солтан Мәхмүд ул угрыны асарга әмер кыйлды. Бәс, угрыга бау салдылар. Солтан әйтте: «Әй угры, син ни исемле?» — диде. Угры әйтте: «Әй шаһым, исемем Мәхмүдтер», — диде. Солтан әйтте: «Тимәгез, асмагыз. Аны азат кыйлыңыз», — диде. «Әй солтаным, ни сәбәпле аны гафу кыйлдыңыз?» — диделәр. Солтан әйтте: «Ул кеше минем белән исемдәш, имеш, шул сәбәпле азат кыйлдым», — диде.

Бәс, әй угыл, бу хикәяттә бәшарәт бардыр ки, солтан Мәхмүд үзе белән исемдәшен җәза кыйлмады, азат кыйлды. Кателдән хәлас кыйлды. Никадәр гаепле вә гөнаһлы булса да, гафу кыйлды. Инде Аллаһы Тәгалә сине утта ник газап кыйлсын? Хәлән ки үз исеме белән мөсәмма кыйлды. Гобудият белән үзенең исеменә изафә булган исем белән мөсәмма адәмнәргә дәхи монда бәшарәт бардыр. Мәсәлән, Габдулла, Габделхәй, Габделкаюм, Габдерахман, Габдерәхим вә гайреләр.

———

Гайсә галәйһиссәлам заманында Әхмәд әл-Җәвад исемле бер гаять жумарт адәм бар иде. 660 ел гомер сөрде. 17 кызы бар иде. Үзе балыкчы иде. Һәркөн, кызлары бәрәкәтендә ике балык тотып, берсе белән кызларын нәфәкаләндерер, берсе белән фәкыйрьләргә тәсаддык кыйлыр иде. Әй угыл, ул заманда һәрни булса, икедән берсен тәсаддык кыйлырлар иде. Хәлән без калдык шундаен заманда ки, меңнән берене тәсаддык кыйлмайлар. Җәһаләттәндер.

Вә дәхи ул Әхмәд әл-Җәвад бөтен гомер буе саим иде. Аллаһы Тәгалә бер кич аңа Җәбраилне җибәрде. Әхмәд әл-Җәвад йокыда иде. Җәбраил галәйһиссәлам селкетеп уятты. Әхмәд уянды. Күрде: алдында нур ялтырар. Вә Җәбраил галәйһиссәламне хөсен вә җәмал иясе бер егет сурәтендә күрде. Әхмәд әйтте: «Син кемсең?» Җәбраил галәйһиссәлам: «Мин — Рәсүл Раббел галәминмен, сиңа вәхи белән килдем. Тор. Таһарәтеңне яңарт. Ике рәкәгать намаз укы, сиңа рисаләтне әда кыйлаем», — диде. Бәс, Әхмәд тормады. Таһарәт яңартмады. Намаз укымады. Җәбраил галәйһиссәлам рисаләтне һәм тапшырмады. Әй угыл. Берәү тәрике-салят булса вә таһарәтсез йөрсә, җаиз булырмы ки, Аллаһы Тәгалә аңа мәгъфирәт белән бәшарәт бирсә, әлбәттә, җаиз булмас. Чөнки, *тәрикес-салятн бәгыйдум мир рахмәти*, диде Аллаһы Тәгалә.

Ахыр Әхмәд әл-Җәвад таһарәт алды. Ике рәкәгать намаз укыды. Җәбраил галәйһиссәлам әйтте: «Белгел, йә Әхмәд, Аллаһы Тәгалә сиңа газап кыйлды. Вә сиңа әйтте, бөтен гомерең буе миңа кыйлган тагатеңне вә минем өчен кыйлган гамәлеңне кабул кыйлмаймын. Әгъмәлеңне һәбәәм мәнсүра кыйлдым, ишегемнән сөрдем», — диде. Аннан соң Әхмәд әл-Җәвадның нәбувәт таҗы башыннан очты. Мәхәббәт либасе тәненнән төште. Мәкъбуль булганның соңында мәрдүд булды.

Бәс, шул вакытта фәрештәләр Аллаһы Тәгаләдән куркып егъладылар. Әйттеләр: «Бу Әхмәдкә болай булды. Безгә ни булыр?» — диделәр. Әхмәд әл-Җәвад ошбу хәбәрне ишеткәч, җирдән ике таш алды. Ике ташны ике кулына тотып, күкрәгенә сукты. Сихә кыйлды. Егълады. Әйтте: «*Вәә вәйләһү, вәә мусыйбәтәһү, вәә фиркатәһ.* Тәхкыйк мине дустым-дәргяһыннан сөрде вә ликасеннән мәхрүм итте, рәхмәтеннән аерды», — дип, һаман нәүхә кыйлып егълады. Адәмнәр, җеннәр, кошлар, хайваннар егълаштылар. Фәрештәләр егълаштылар. Әхмәд әл-Җәвадның йөзе каралды. Әйтте: «Йә Җәбраил, мин аннан гайре Тәңрегә гыйбадәт кыйлмадым. Аннан гайрегә итагать кыйлмадым. Минем ни җинаятем булды ки, мине мәсхәрә кыйлды. Һәрнәрсәнең хәйләсе бардыр. Минем хәйләм ни-нәрсәдер, йә Җәбраил?» — диде. Бәс, Җәбраил галәйһиссәлам дә аның өчен егълады, әйтте: «Йә Әхмәд, сабыр кыйл. Мин Аллаһы Тәгалә хәзрәтенә мөнәҗәт кыйлаем, синең җинаятеңнән сораем. Сине ни өчен сөрде, беләем», — диде. Бәс, мөнәҗәт кыйлды, әйтте: «Илаһи, ни сәбәпле бәндәң Әхмәдне ишегеңнән сөрдең. Бөтен гомер буе гыйбадәтеңне ихтыяр кыйлды. Бөтен гомере буе көндез руза тотты, кич уяу торды. Аның сәгадәтен шәкавәткә тәбдил кыйлдың! Ни сәбәптер, безгә моны белдер!» — диде.

Нида килде: «Йә Җәбраил, мин аны ишегемнән сөрдем, рәхмәтемнән ерак иттем аның өчен: ул Әхмәд үзенең балаларына вә кызларына әйтер иде: мәгыйшәтеңез сәбәбе миннәндер, ди иде. Ризыкыңыз — минем иҗтиһадымнандыр, минем шәфәгатемнәндер, ди иде. Ул белмәде ки, миннән гайре Рәззак[1] юктыр. Бәндәләремне үземнән гайре итгам кыйлгучы юктыр. *Вә мә мин дәббәтин фил әрзый иллә галә Аллаһыи ризкуһә.* Әгәр берәү ризыкым үземнең кәсебемнәндер вә иҗтиһадымнандыр, дип гөман кыйлса, ул кешегә рәхмәтемнән өлеш юктыр. Дәхи дә мин аңа яшьлегендә күп мал бирдем, иститагать рузи кыйлдым. Өемә хаҗ кыйлмады. Төшендә бәйтемә хаҗ кыйл, дип илһам кыйлдым. Ул әйтер

[1] Рәззак — ризыкландыручы.

булды, бай вакытымда хаж кыйлмадым, хәзердә фәкыйрьләнгәч, ничек хаж кыйлаем, диде. Төшендә янә, фәкыйрь булсаң да, хаж синнән сакыйт булмады, дип илһам кыйлдым. Бәс, минем әмремә имтисаль кыйлмады. Шуның өчен ишегемнән сөрдем», — диде.

Инде, әй угыл, бу кыйссадан максуд будыр ки: бәндә булган кешегә важибтыр ки, хәвефтә булсын. Ризыкны Аллаһы Тәгаләдән дип белсен, үзенең кәсебеннән дип игътикад кыйлмасын. Әгәр хаж важиб булса, хаж кыйлсын. Һәрзаман үзенең хәрәкәтендә вә сәканәтендә Аллаһы Тәгаләдән куркучан булсын. Сиррән вә җәһрән Аллаһыны зикер кыйлсын. Инде бәндәнең хәлен Әхмәд Җәвадның хәле белән чагыштырып кара. Аның өчен Әхмәд әл-Җәвад шул тәкъвалыгы белән вә пәйгамбәрлеге белән ошбу хәлгә дучар булды. Инде, әй угыл, ошбу гадәтемез белән, ошбу гөнаһымыз белән тәүбәсез үлсәк, Аллаһы Тәгаләнең рәхмәте ишегеннән мәтруд булмакымыз хәвефе бардыр. *Нәгузе биллаһ мән заликәл хәл.*

Аннан соң Җәбраил галәйһиссәлам Аллаһы Тәгалә хозурында сәҗдә кыйлды. Әйтте: «Илаһи, гыйззәтең, җәлалең хөрмәтенә Әхмәднең тәүбәсен кабул ит. Тәхкыйк гөнаһыннан ул тәүбә кыйлды», — диде. Нида килде: «Йә Җәбраил, аңа әйт, әгәр тәүбәсен кабул кыйлмакны теләсә, Кәгъбәгә барсын: миңа сәҗдә кыйлсын, таки барча җинаятен гафу кыйлырмын», — диде.

Белгел ки, әй угыл, Әхмәд Җәвад хакында Җәбраил Әмин шәфәгать кыйлды. Инде Аллаһы Тәгалә каршында без гөнаһлы бәндәләргә кем шәфәгать кыйлыр? Әлхәмделиллаһ, үземез мөттәкыйлардан булсак, безнең дә шәфәгатемез бар. Әмма икенче җәһәттән ошбу өммәткә важибтыр ки, галәддәвам шөкер кыйлмак, аның өчен Аллаһы Тәгалә ошбу өммәтне башка өммәтләрдән әфзаль кыйлды. Мәсәлән, Аллаһы Тәгалә башка өммәтнең тәүбәсен — Кәгъбәгә барып тәүбә кыйлмакны, яки Бәйтуллаһ мөкаддәскә барып тәүбә кыйлгаенча кабул итмәде. Хата вә гөнаһлары булса, Кәгъбәгә, Бәйтуллаһ мөкаддәскә барып тәүбә кыйлдылар. Хәзер дә ошбу өммәтнең тәүбәсен шәһәрләрдә вә карьяләрдә, мәсҗетләрдә вә өйләрдә һәм кабул итәдер. *Вә һүвәл-ләзи якъбәлут тәүбәтә ган гыйбәдиһ.*

Бәс, моннан соң Җәбраил галәйһиссәлам килде. «Тәүбәң кабул булды», — диде. Әхмәд әл-Җәвадка бәшарәт бирде. Аннан соң Әхмәд әл-Җәвад Кәгъбәгә сәфәр кыйлмакны газимәт кыйлды. Кызлары әйтте: «Йә ата, син кайтканчы, без ни ашарбыз. Ни эчәрмез? Ни киярмез?» — диделәр. Әхмәд әйтте: «Аллаһы Тәгалә Рәззактыр, ризыкыңызны ирештерер», — дип, сәфәр таягын алды. Сәфәргә чыкты. Гомерендә бер мәртәбә сәфәргә чыкканы юк иде. Мәшәкать чикте. Сусады. Аяклары кабарды.

Юл адашты. Җиде көн ач вә сусыз йөрде. Бер карьягә дә, бер диварга да очрамады. Гаҗиз булды. Хәйран булды. Каты егълады.

Җиде көннән соң, бара торгач, бер шәһәр күрде. Шәһәргә якын килде. «Бу кайсы шәһәрдер?» — диде. «Бу — Багъдад шәһәредер», — диделәр. Күрде: шәһәрнең тарафында ике бала бер нәрсә өчен тарткалашалар. Олуграгы килде дә кечерәгенең кулыннан нәрсәсен тартып алды. Кечерәге әйтте: «Тукта, сабыр ит, менә Әхмәд әл-Җәвад безгә хөкем итәргә килә», — диде. Бәс, Әхмәд боларның сүзен ишетте, күңеленнән бик тәгаҗҗеб кыйлды, әйтте: «Бу бала мине ничек таныды?» — дип, аларга якынрак барды: «Әссәламүгаләйкүм», — диде. Ул бала: «Вәгаләйкүмәссәлам, йә Әхмәд әл-Җәвад», — диде. Әхмәт әйтте: «Әй бала, минем Әхмәд әл-Җәвад икәнемне кайдан белдең?» — диде. Ул балалар әйттеләр: «Сиңа мәгърифәт рузи кыйлган Аллаһы Тәгалә безгә дә мәгърифәт рузи кыйлды», — диделәр. Әхмәд әл-Җәвад аларны солых кыйлыштырды.

Аннан шәһәргә керде. Халыктан бернәрсә сорамага ирадә кыйлды, ләкин сорамакны җаиз күрмәде. Аны күргән бер кеше: «Һәзә Әхмәд әл-Җавад», — диделәр. Өйләренә чакырып керттеләр. Алдына тәгам китерделәр. Ләкин Әхмәд әл-Җәвад аларның тәгамнарын һич тәнавел кыйлмады. Күңеленнән әйтте: «Аллаһы Тәгалә тәүбәмне кабул иттеме-итмәдеме, тәхкыйк белгәенчә торып, тәгамнарын ашамаем», — диде. Кайчан ки Әхмәд ихлас белән тәүбә кыйлды вә гөнаһысыннан икърар кыйлды, Аллаһы Тәгалә бәндәләре арасында аны мәшһүр кыйлды. Күргән бер кеше аны таныды. Алдына табак-табак мәхәббәт тәгамы куйдылар. Ягъни күргән бер кеше аңа мәхәббәт итте.

Инде, әй угыл, син тәүбә кыйл вә гөнаһыңа икърар кыйл, күргән бер кеше сиңа мәхәббәт итәр. Каберендә җәннәтән әнваг тәгама хәзер кыйлырлар. Яхшы булырга боер вә начарлыктан тый. Гыйбадәткә димчелек кыйл, таки кыямәт көнендә пәйгамбәрләр, мөэминнәр арасында мәшһүр булырсың. *Симаһүм фи вүҗүһиһим мән әсәрис-сөҗүд*.

Аннан соң Әхмәд ач вә сусаган хәлдә шәһәрдән чыкты. Җиде көн ифтар кыйлмады: тәүбәм рәд кыйлыныр, кабул булмас, дип курыкты. Әй угыл, күрмәсмесең, Әхмәд әл-Җәвад, Аллаһы Тәгалә каршында тәүбәм кабул булмас, дип куркып, хәлял тәгамны дә ашамады. Акыл — мәртәбә: син харам ширбәтне эчмәктән иҗтинаб кыйл. Күрмәймесең, әй угыл, кадим заманында ниндәен кешеләр бар иде. Инде без калдык шундаен заманда ки, харамны сугышып ашыйлар, хәмерне талашып эчәрләр. Мәгъсыятьтән вә горурлыктан иҗтинаб кыйлмайлар. Ля

җәрәм кыямәт көнендә шәрабы вә тәгамы зәкъкум вә хәмим булса кирәк. *Вә суку мәә-ән хәмимән вәкуттыйга әмгаъуһүм.*

Аннан соң Әхмәд әл-Җәвад, шәһәрдән чыгып, юлда күп мәшәкать чикте. Ял өчен юл янына утырды. Өйлә вакыты иде. Йокы галәбә кыйлып йоклады. Уянып күрсә: кояш баеп бара! Өйлә намазы, икенде намазы андан фәүт булды. Таһарәт алмага су эзләде, тапмады. Мөнәҗәт кыйлды: «Илаһи, әгәр тәүбәмне кабул иткән булсаң, ошбу таштан су чыгар вә кояшка әмер кыйл: урынына кайтсын, таки таһарәт алып, калган намазларымны әда кыйлаем», — диде. Шул хәлдә кояш урынына кайтты. Аллаһы Тәгаләнең кодрәте белән таш ярылды, су чыкты. Бәс, Әхмәд торды. Таһарәт алды. Намазларын укыды: «*Әлхәмду лилләһил ләзи бәййәнә ли кабулә тагати вә гуфра мәгъсыяти, вә каза хәҗәти вә һувә әрхәмур-рахимин*», — диде.

Инде, әй угыл, бу сүздән гыйбрәт ал. Әхмәд әл-Җәвад ки ихлас күңеле белән тәүбәи нәсух кыйлды, Аллаһы Тәгалә аңа таштан су чыгарды. Кояшны кайтарды. Һәрни эстәгәнең Аллаһы Тәгаләдән тапты. Әй мескин бәндә, син һәм тәүбәи нәсух кыйл, таки каберең раузатүн мин риязил җәннәт булгай. Вә анда Сәлсәбил вә Зәнҗәбил җылгалары аккай. Сәйиатың хәсәнәткә тәбдил кыйлынып, һәрни Аллаһы Тәгаләдән эстәгәненңе тапкайсың. *Вә ләкум фиһә мә тәддәгунә нузуләм мин гафурир рахим.*

Кайчан ки Әхмәд әл-Җәвад намаз укыды, Аллаһы Тәгаләгә дога кыйлды. Аннан сәфәрне газимәт кыйлып китте. Күрде: бер карчыга бер күгәрченне куып килер. Бәс, күгәрчен Әхмәднең иңбашына кунды: «Әл аман! Әл аман!» — диде. Аннан соң Әхмәд ул күгәрченне тотты. Карчыга килеп җитте. Әйтте: «Йә Әхмәд, син — җумарт. Халән минем хакымда үтә саран булдың, ризыкымны мәныг кыйлдың», — диде. «Мин гомеремдә һичбер хайванны, һичбер кошны иза кыйлганым юк вә үтергәнем юк. Син мине комсыз, дип тәсмия кыйлдың?» — диде. Карчыга әйтте: «Моннан артык комсыз булырмы: мин өч көннән бирле авызыма тәгам капканым юк. Ачмын. Халән минем ризыкымны мәныг кыйлдың», — диде. Әхмәд әйтте: «Мин ни өчен мәныг кыйлмам? Вә халән ки күгәрчен миннән әман эстәп килде. Миңа илтиҗа кыйлды. Бу мәзлүм кошның гозерен кабул итмәсәм, Аллаһы Тәгалә минем тагатемне кабул итәрме? Аллаһы Тәгалә миңа нosрәт бирерме?» — диде.

Инде, әй гасый вә мөфлис угыл, синең хәлең кыямәт көнендә ничек булыр?! Күп мөселманнарга залимлык кыйлдың, гозерләрен кабул кыйлмадың. Сүзләрен ишетмәдең. «Әл аман! Әл аман! Аллаһы Тәгалә мине мәрдүдләрдән кыйлмагай иде»

дип курыкмаймысың! *Сөммә нунҗил ләзинәт тәкау вә нәзәруз-залиминә фиһә җисиййә.* Аннан соң карчыга әйтте: «Мин ни кыйлаем? Син күгәрченнең һәлакенә разый булмадың да минем ач үлгәнемә разый буласың? Күгәрченне дә, мине дә халән ки Аллаһы Тәгалә яраткан, икемез һәм Хода мәхлукларымыз. Хакым синең зиммеңдә калсын!» — диде.

Бәс, Әхмәд егълады. «Инде ни кыйлмак кирәк? Йә карчыга, разый булырмысың, күгәрчен кадәр үз итемне кисеп бирәем. Ашарсың. Күгәрченне миңа һибә кыйлырсың», — диде. Карчыга әйтте: «Разый булырмын шул шарт белән ки, әгәр дә мин теләгән җиреңнән кисеп бирсәң», — диде. Әхмәд әйтте: «Яхшы, сүз юк», — диде. Карчыга әйтте: «Бир ике күзеңне», — диде. Бәс, Әхмәт әл-Җәвад пычак алды, күзләрен казып чыгарды, карчыгага бирде. Күзе агырганга такать тота алмыйча, күгәрченне кулыннан ычкындырып җибәрде. Әйтте: «Ва хәсрәта! Раббымның йортына житмәс борын, күзсез калдым лабаса!» — дип каты егълады.

Бәс, күгәрченгә шәфкать кыйлып, Әхмәд әл-Җәвад карчыгага күзен һибә кыйлды. Инде, әй мәгърур! Ишегеңнән саилләрне мәхрүм җибәрәсең. Карендәшләрең вә күршеләрең — фәкыйрь, ач, ялангач. Үзең икешәр-өчәр табакале йортларында әлван нигъмәт белән корсагыңны тутырасың. Мескиннәрне ач калдырасың. Фәкыйрь өлешен ихтикяр[1] кыйласың. Аллаһы Тәгаләдән курыкмаймысың? Үлемне исеңә төшермәймесең? Аллаһы Тәгаләнең *«лән тәнәлул бирра хәттә түнфику миммә түхиббунә»* дигән сүзен ишетмәдеңме?

Моннан соң Әхмәд: «Ва хәсрәтә Кәгъбәне күрмәктән мәхрүм калдым, морадыма ирешмәс борын, күзсез булдым, вә дәрига!» — дип егълады.

Инде, әй угыл, гыйбрәт ал: азмы мәгъррурлар йөз ел тормакны фараз кыйлалар, хәлбуки елга да житмәйләр. Азмы мәгъррурлар хажга бармакны ният кыйлалар, хәлбуки күрше авылга да барып җитмәйләр. Азмы мәгъррурлар гаетне көтеп торалар, гәрәфә кичне дә күрмәйләр.

Кайчан ки Әхмәд әл-Җәвад тәәссеф кыйлып егълады, карчыга вә күгәрчен тавыш бирделәр. Әйттеләр: «Йә Әхмәд, кайгырма! Мин Җәбраилмен вә бу карендәшем Микаилдер. Сине тәҗрибә кыйлмак өчен килдек. Бәгъдад шәһәренә кермәстән, мөкаддәм ике егет күрдең. Алар һәм без идек. Вә дәхи ул шәһәрдә синең алдыңа әнваг нигъмәт китерделәр, алар мокариб фәрештәләр

---

[1] Ихтикяр — спекуляция.

иделәр. Бәшарәт сиңадыр ки: Аллаһы Тәгалә тәүбәңне кабул итте. Без шөйлә мәэмур булдык», — дип, Мәккә юлына Әхмәдне озатып җибәрделәр. Гаиб булдылар.

Бәс, Әхмәд әл-Җәвад, хаҗ кыйлып, юлга кайтып чыкты. Аның унҗиде кызы, бер углы бар иде. Кәгъбәдән кайтканда, юлда бер төш күрде. Бу төшнең тәэвиленә караганда, углының мәетеннән хәвеф тапты, һәрбер мәнзилгә җиткән саен: «Углым сәламәт микән?» — дип сорашыр иде. Кайчан ки шәһәренә якын килде, дуслары вә күршеләре каршы чыктылар. Алардан сорашты: «Йә, углымны күрдегезме? Ник углым чыкмады? Вәә хәсрәтаһ! *Вәә куррата гайнәһ!*» — дип егълады. Үзенең йортына җитте. «Углың вафат», — дип хәбәр бирделәр.

Аның соңында углының анасы килде: биле бөгелмеш. Углының хәсрәтеннән йөзе саргаймыш! Әйтте: «Йә зәүҗә, бәхил бул: углымның фиракына такатем юк», — дип, бер сәйха кыйлды, һушсыз булып егылды. «Тор!» — дип селкетеп карадылар. Ник торсын?! Вафат булмыш күрделәр.

———

Галәэтдин солтан бер залим падишаһ иде. Адәмиләргә һәр заман золымы тияр иде. Көннәрдән бер көн заһид вә мөнәгъгыйм адәмгә залимлык кыйлды. Зиядә бай кемсәнә иде. Хәтта Галәэтдиннең золымы сәбәпле фәкыйрьлеккә төште. Бәддога кыйлды, әйтте: «Илаһи, ошбу падишаһка бер залимне мосалләт кыйл, таки залимлыкның маһиятен белсен!» — диде.

Бәс, Аллаһы Тәгалә ул заһидның догасын кабул кыйлды: аңа Сәнҗар солтанны мосалләт кыйлды. Хәтта мәмләкәтен алды, үзен урыныннан төшерде. Бәс, Галәэтдин солтан бик фәкыйрьлеккә төште. Саилчелек кыйлып йөрде. Тапканын ашар иде. Кайда тугыры килсә, анда йоклар иде.

Инде, белгел ки, әй угыл: дөньяның малы шөйләдер. Дөньяның бәһасе юктыр, вафасы юктыр. Бөтен дөньяга малик булсаң да, торганы мәшәкатьтер, ахыры — гөнаһ, языктыр.

Бәс, бу Галәэтдин көннәрдән бер көн бер җирдә күрде: берәү казан аскан, ут яккан. Казанына борчак салган, пешереп ята. Бу кеше баягы мөнәгъгыйм иде, Галәэтдингә кычкырды: «Әй минем бәлам белән бәлаләнмеш кемсәнә!» — диде. Галәэтдин әйтте: «Нидән алай дип әйтәсең?» — диде. Ул кеше әйтте: «Аның өчен ки, мин синең кулыңнан бу фәкыйрьлек бәласенә мөбтәля булдым. Әмма син минем калебемнән бу бәлагә мөбтәля булдың. Чөнки мин бай вә мөнәгъгыйм адәм идем, миңа залимлек кыйлдың. Шул сәбәпле мин бу хәлгә төштем. Ихлас күңел белән Аллаһы Тәгаләгә дога кыйлдым: син бу хәлгә төштең. Мин си-

нең сәбәпле, син минем сәбәпле мөбтәля булдык. Инде минем янымнан китмә: як казан астына, пешер борчак, ашармыз, — диде. — Дәхи артканын сатармыз. Сәмән беләй файдаланырмыз, — диде. — Син дә минем дәрәҗәмә төштең», — диде.

Аннан соң Галәэтдин разый булды. Аерылмаска гаһед кыйлды. Бәс, берсе борчак пешерде, берсе сатты. Берничә көннәр залим вә мәзлум бергә тереклек кыйлдылар.

Кичләрдән бер кич намазга тордылар. Намаз укыдылар. Егъладылар, тәүбә кыйлдылар, *раббәнә заләмнә әнфүсәнә*, дип, Аллаһы Тәгаләдән мәгъфирәт эстәделәр вә тәзәррыг кыйлдылар. Бәс, Аллаһы Тәгалә аларның догасын кабул итте.

Көннәрдән бер көн болар яныннан Сәнҗар солтанның хаҗибе үтте. Галәэтдин солтанның хәлен күрде: иске кием кимеш, казан астына ут ягып, борчак пешерер. Бите-кулы капкара. Бу хаҗиб аларны кызганып егълады. Аллаһы Тәгаләгә истигазә[1] кыйлды. Сәнҗар мәлик янына егълап кайтты. Сәнҗар әйтте: «Нигә егъларсың? Дошманың бармы? Әйт миңа, интикам[2] алаем. Бер-бер шикаятең бармы, ярдәм кыйлаем», — диде. Хаҗиб әйтте: «Әй солтан, белгел ки, ошбу дөньяның бәкасе[3] юк. Синең солтанатыңның да вафасы юк. Солтан Галәэтдин, үзенең золымы сәбәпле, синең кулыңда мөбтәля булды. Халән аны шөйлә хәлдә күрдем ки, аягы-кулы кара. Киеме иске. Казан янында борчак пешерер. Юлдашы ул пешкән борчакны сатар. Шөйлә тереклек кыйлырлар», — диде. Аннан соң әйтте: «Әй солтаным, куркамын ки, ахыр әмереңдә синең хәлең дә шөйлә булмагай иде». Сәнҗар әйтте: «Бар, Галәэтдинне монда алып кил. Хәлен күрәем. Хәленә мәрхәмәт кыйлаем», — диде.

Бәс, хаҗиб китте. Галәэтдинне алып килде. Солтан Сәнҗар күрде: өстендә иске кием, йөзе-кулы кара. Солтан Сәнҗар әйтте: «Бу киемеңне юарга кулың юкмы? Йөзеңне-кулыңны юарга кодрәтеңнән килмәйме?» — диде.

Бәс, солтан Галәэтдин сәҗдәгә китте, әйтте: «Әй солтан, кулымны да юдым, йөземне дә юдым. Кайчан ки башым үз башым иде, таҗ кидем, либасе фахирә кидем. Халән башым, җисмем көллесе синең хөкемеңдә. Ничек итеп юаем, алар синеңдер. Менә башым: теләсәң кис, теләсәң ю», — диде. Бәс, Сәнҗар бу сүзләрне ишетте, зарилыгын күрде, хилгать кидерде. Нисабур милкен аңа игъта кыйлды. Кулына мәншүр язып бирде.

---

[1] Истигазә — ялыну.
[2] Интикам — үч.
[3] Бәкасе — бирелә: тотрыклылыгы.

Инде, әй угыл, күрдеңме? Галәэтдин солтан Сәнҗар алдында тәвазыйглык кыйлды. Үзенең гаҗизлеген икърар кыйлды. Вә үзен солтан Сәнҗарның әмеренә тәгъвиз вә хәвалә кыйлды.

Бәс, солтан Сәнҗар, аңа мәрхәмәт кыйлып, яңадан дәрәҗәгә мендерде. Сәнҗар белән Галәэтдин арасында дошманлык бар иде. Кайчан кем мәлик Сәнҗар Галәэтдиннең тәвазыйглыгын күрде, хәленә мотталигъ булды, тәэссеф кыйлды вә аңа шәфкать кыйлды: хилгать кидереп, Нисабур милкен игъта кыйлды. Инде мөэминнәр, Аллаһы Тәгалә хозурында, күп зикер белән, күп сәҗдә белән вә күп тәзәррыг вә гыйбадәт белән нәфесен вә калебен юып агартса, вә Аллаһы Тәгалә каршында үзенең гаҗизлеген икърар кыйлса, вә җөмлә әмерен аңа тәгъвиз кыйлса, Аллаһы Тәгалә дәхи үзенең мөэмин бәндәсен дус тотадыр. Инде шөйлә булганда, үзенең рәхмәтеннән мәхрүм куярмы? Бәли, мәхрүм кыйлмас, мәгъфирәт кыйлып, вә иманнарының мәншурләрен язып, кулларына бирер. *Йүсәббитуллаһүл ләзинә әмәну бил каулис-сәбити фил хәятид дүнья*. Өсләренә җәннәт хөлләләреннән хилгать кидерер. *Вә либәсуһүм фиһә хәрир*. Җәннәт милкен бирер: *сөммә раәйтә нәгыймән вә мүлкән кәбира*.

## *Хатимә*

Инде, әй угыл, белгел ки, ошбу «Җәваһирел хикәят» китабында күп мәшаихларның вә күп газизләрнең хикәяләре зикер кыйлынды. Газизләр вә мәшаихлар хикәятен вә аларның сүзләрен ишетмәктә вә тыңламакта күп файдалар бардыр.

«Төхфәтел әнис» китабында мәзкүрдер ки, хәзрәти Җөнәйд Бәгъдадыйдан сөаль кыйлдылар: «Шәех вә газизләр хикәятенең мөридләргә ни файдасы бардыр?» — диделәр. Җөнәйд Бәгъдадый хәзрәтләре җавап бирде, әйтте: «Аллаһы Тәгалә Коръәндә боерыр ки: *«Вә күллән нәкуссу галәйкә мин әнбәъир-русүл мә нүсәббиту биһи фүәдәкә»*. Ягъни: пәйгамбәрләрнең кыйссаларын вә хәбәрләрен, йә Мөхәммәд, сиңа бәян кыйлдык вә аларның әхвәленнән сине агаһ иттек, таки синең калебеңә сәбат хасыйл булсын өчен вә калебеңә кувәт хасыйл булсын өчен. Вә кайчан ки сиңа кауменнән бер зәхмәт вә авырлык ирешсә, аларның әхвәлен мөляхәзә итәсең. Вә дәхи беләсең ки: аларга да мондаен зәхмәт мондак авырлык вә мәшәкать ирешеп, сабыр вә тәхәммел кыйлдылар. Тәвәкәлләрен вә тәгъвизләрен арттырдылар. Синең күңелеңдә дәхи сабыр вә тәхәммелне вә сәбатны арттырыр», — диде.

Бәс, әй угыл, шул вәҗеһ белән изгеләрнең вә мәшаихларның хикәятен укымак, вә тыңламак, вә аларның әхвәлен вә хикәятен моталәга кыйлмак, аларның гадәте белән гадәтләнмәгә вә аларның холкы белән холыкланмага сәбәп булыр. Бәла вә

каза вакытларында сабыр вә тәхәммелгә вә эшеңне Аллаһ Тәгаләгә тәгъвиз кыйлмага, гайрәт вә һимматкә сәбәп булыр.

Нитәкки пәйгамбәр галәйһиссәламнән сөаль кыйлдылар: «Берәү әулияи Аллаһыдан бер кешегә мәхәббәт итәдер, әмма ул әулияи Аллаһы эшләгән нәрсәне эшләмәгә кулыннан килмәй. «Моның хәле ничек булыр?» — диделәр. Пәйгамбәр галәйһиссәлам әйтте: *«Әл-мәръү мәга мин әхәббә*, ягъни һәр кеше үзенең мәхәббәт иткән кешесе белән бергә булыр», — диде. Бәс, берәү бер газизгә вә мәшаихларга күңеленнән мәхәббәт итсә, кыямәт көнендә ул газиз анда шәфәгатьче булып, ожмахта бергә булса кирәк.

Вә дәхи пәйгамбәр галәйһиссәламнән риваять кыйлынды: кыямәт көнендә гөнаһлы бәндә, изге гамәле юклык сәбәпле, нәүмиз булып калыр. Аллаһы Тәгалә әйтер: «Әй бәндәм, фәлән җирдә минем галим вә мөттәкый бәндәм бар иде. Аны белермесең. Таныйрмысың?» Ул бәндә әйтер: «Йа Рабби, беләмен, таныймын». Аллаһы Тәгалә әйтер: «Алайса бар аның янына, сине аңа багышладым».

Инде, әй угыл, Аллаһы Тәгаләнең изге колларын вә газизләрне фәкать белмәк кенә дә нәҗатка сәбәп булса, аларга мәхәббәт итеп алар юлы белән йөрмәк вә аларның гадәтен тотмак, аларның кауле белән гамәл кыйлмак битарикый үлә нәҗатка вә хәласкә сәбәп булса кирәк. Вә дәхи хикәятләрен укымак ул газизләрне дус тотмакка сәбәп булса кирәк. Фазыйл бин Гаяз разыйаллаһу ганһу әйтте: «Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә бәндәләренә әйтер: *«Йә бин Адәм, әммә зуһдукә фид-дөнья фә иннәмә таләбтәр-рахәтә линәфсикә вә әммән кыйтагукә иләййә фә иннәмә таләбтәл гыйззә ли нәфсикә вә ләкин һәл гадәйтә гадувән вә вәләйтә ли вәлиян»*.

Бәс, әй угыл, газизләрнең хикәятен укысаң, күрерсең вә белерсең ки: синең үзеңнең әхвәлең вә әфгалең ул газизләрнең әхвәле кебек түгелдер. Үзеңнең хатаңны танучы булырсың. Гоҗеб[1] вә рияДан хәлас булырсың. Кайчан ки мәшаихлар сүзен ишетсәң вә хикәятләрен укысаң, күңелеңә әсәрен белеп, җаның белән аларның фигыльләренә вә сирәтләренә мәел итәрсең. Ягъни: «Һай, шул газизләр кебек булсаң иде!» — дип әйтерсең.

«Җәваһирел хикәят» тәмам булды.

---

[1] Гоҗеб — мәгърурлык.

## ЭЧТӘЛЕК

Фәвакиһел җөләса

3

Җәваһирел хикәят

250

Литературно-художественное издание

*Каюм Насыри*

ИЗБРАННОЕ

в четырех томах

Том 2

(на татарском языке)

Мөхәррире *В.Р.Камалиева*
Рәссамы *Р.Х.Хәсәншин*
Бизәлеш мөхәррире *Р.Г.Шәмсетдинов*
Техник мөхәррире һәм компьютерда биткә салучы *А.С.Газизҗанова*
Корректорлары *Л.Х.Касыймова*, *Г.Х.Сундукова*, *Г.М.Хәбибуллина*

Нәшриятка 04184 нче номерлы лицензия 2001 елның 6 мартында бирелгән.

Оригинал-макеттан басарга кул куелды 22.10.2004. Форматы $84 \times 108^1/_{32}$.
Офсет кәгазе. «Antiqua» гарнитурасы. Офсет басма.
Шартлы басма табагы 21,00 + фор. 0,21. Шартлы буяу-оттиск 21,94.
Нәшер-хисап табагы 22,48 + фор. 0,36. Тиражы 3000 д. Заказ Э-742

Татарстан китап нәшрияты. 420111. Казан, Бауман ур., 19.
Татарское книжное издательство. 420111. Казань, ул. Баумана, 19
http://www.tatarstan.ru/books/ E-mail: tki@books.kazan.ru

Оригинал-макет Jahat™ программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде.

«Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексы
Дәүләт унитар предприятиесендә басылды.
420066, Казан, Декабристлар ур., 2.